ISSN 0206—418

# КАЗАН УТЛАРЫ

10. 1991





# КАЗАН УТЛАРЫ


АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ: ТАТАРСТАН ССРның ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**10**

**1991**

КАЗАН


## *Бу санда*


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Г. ТАВЛИН. Афәт. *Роман* ........ 3
Н. ХӘСӘНОВ. Ак балык. *Повесть* ........ 77
Н. КӘРИМОВА. Карурманнан чыккан юлчылар. *Кыйсса* ........ 99

ШИГЪРИЯТ

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Казан алды. *Шигырьләр* ........ 70
Р. МИНГАЛИМ. Югалган яшен. *Шигырьләр* ........ 75
Р. ЮНЫС. Качалар күселәр... *Шигырьләр* ........ 122
С. МУЛЛАГАЛИЕВ. Милләтем. *Шигырьләр* ........ 126

ДРАМАТУРГИЯ

Р. ХӘМИД. Актамырлар иле. *Трагедия-реквием* ........ 128

ШАГЫЙРЬ АРХИВЫННАН

Х. КАМАЛОВ. Ихласлык
Р. РӘХИМОВ. Шигырьләр ........ 152

ПУБЛИЦИСТИКА

Т. МИҢНЕБАЕВ. Татар халкының холкы: икътисади тамырлары, сәяси тормышта чагылышы ........ 155
А. ХӘСӘНОВ. Бәрәңге ........ 160

Коръән сүрәләре ........ 165

КИТАП КҮЗӘТҮ

Г. РАМАЗАНОВ. Заманыбыз шундый булгач ........ 176
Л. КӘШФИЕВА. Күрше тавыгы күләк ........ 179

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

М. ЗӘКИЕВ. Халкыбыз турында тулы белем ........ 181
М. МӘҺДИЕВ. Өлкән әдип белән очрашуларым ........ 186

*Баш мөхәррир*

**РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН**

*Редколлегия*

**ГАРИФ АХУНОВ**
**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**ФЛУС ЛАТЫЙФИ**
*(җаваплы сәркәтип)*
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
**ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**МАРАТ МӨЛЕКОВ**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
**РАШАТ НИЗАМИЕВ**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**ГӘРӘЙ РӘХИМ**
**КОЯШ ТИМБИКОВА**
*(бүлек мөхәррире)*
**МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ**
**ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ**
*(бүлек мөхәррире)*
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Б е з н е ң  а д р е с: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркәтип — 53-36-12.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

Котлыйбыз! ........ 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 189
Тышлыктагы сурәтләр ........ 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: начало романа Г. ТАВЛИНА «Рок», повесть Н. ХАСАНОВА «Белая рыба», повесть Н. КАРИМОВОЙ «Странники из дремучего леса»; стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Р. МИНГАЛИМ, Р. ЮНЫС, С. МУЛЛАГАЛИЕВА.

«Драматургия»: трагедия-реквием Р. ХАМИДА «Страна белых корней».

«Из архива поэта»: стихи Р. РАХИМОВА.

«Публицистика»: Т. МИННЕБАЕВ «Характер татарского народа», очерк А. ХАСАНОВА «Картофель».

Суры из Корана.

«Книжное обозрение»: Г. РАМАЗАНОВ рецензирует книгу Р. Мухамадиева «Львы и канарейки»; Л. КАШФИЕВА книгу Л. Лерона «Соседская курица».

«К истории культуры»: М. ЗАКИЕВ «Полное знание о нашем народе», М. МАГДИЕВ «Встречи с поэтом».

Поздравляем юбиляра.

Дневник общественно-политической жизни.

На наших обложках: «Свадебное полотенце»; известный татарский писатель В. Нуруллин.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Шамил Маннапов, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Г. Хөснетдинова.

Производствога бирелде 15.08.1991 ел. Басарга кул куелды 10.10.1991 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70×108. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 38541. Заказ И-390. Бәясе 1 сум 50 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1991 ел.

## Гурий Тавлин

# АФӘТ

РОМАННЫҢ ИКЕНЧЕ КИСӘГЕ

### Кара болыт эчендә

### Беренче бүлек

1

Заманың өчен үги булудан да авыр нәрсә юктыр, мөгаен.

Язмыштан узмыш юк, ди халык. Язмыш... Четерекле һәм сәер нәрсә ул, бер уйласаң. Аның берәүләрне башларыннан сыйпап, аркаларыннан сөеп өзлексез иркәләве, шуларның янәшәсендәге үк икенче берәүләрне яңакларына чалтыратып даими кыерсытуы яшәештә табигый хәл. Нигә берәүләрнең һәр көне нурларга төренеп, елмаеп туа, икенчеләрнең көннәре төннән чак аерыла? Моңа җавап табу кыен. Тормыш — буталчык табышмак. Бу һич тә арттыру түгел, ихлас шулай. Моңа мин үз тәҗрибәмдә инандым.

Кешенең киләчәге үз кулында, ул — үз язмышының хуҗасы, диләр. Алаймы икән? Ышанмыйм. Бәхәсле бу.

1949 елның ахыры иде. Минем туган көнем. Шул көнне безнең педагогия институтының төп бинасы фойесында мондый игълан пәйда булды: «Бүген унтугыз сәгатьтә икенче каттагы түгәрәк залда ябык партия җыелышы була. Җыелышта тарих-филология факультетының IV курс студенты И. С. Кадыйровның персональ эше карала», — диелгән иде анда.

Игъланны укыгач, курсташым Мөхәммәтдин Закиров:

— Җыелышның түгәрәк залда булуы яхшы, Ирек дус, анда синә бишенче почмакны эзләргә туры килмәячәк, — дип шаяртты.

Гурий ТАВЛИН (1925) — *әдип. «Сары яфраклар коела», «Йолдызлар безгә янәшә», «Тәвәккәл таш яра» һәм башка китаплар авторы. Казанда яши. Ә «Афәт» романының беренче китабы узган елгы «Казан утлары»ның 3 һәм 4 саннарында басылып чыккан иде.*

Әсәр журнал вариантында бирелә. Журнал өчен әзерләүче — Шамил Маннапов.

Түгәрәк залда минем язмышым хәл ителәчәк иде. Тычканга үлем, мәчегә көлке, бәла үзенә кагылмаганда төкерә сиңа кеше! Өч көн элек мине партбюро утырышында тикшерделәр һәм: «Партиядән чыгарырга!» — дигән карар кабул иттеләр. Бүгенге җыелыш әнә шул катгый карарны раслаячак яки кире кагачак. Персональ эшемне туган көнемә юри туры китергәннәр диярсең!.. Юньле кешене дөньяга килгән шатлыклы көнендә якыннары, дус-ишләре, таныш-белешләре, иптәшләре тәбрикләп бәхетшатлык, сәламәтлек, озын гомер, уңышлар, тагын әллә ниләр тели. Мине исә коммунист иптәшләрем, тетмәмне тетеп, ник туганыма үкенерлек итәчәкләр. Мөхәммәтдингә нәрсә, ул фиркале түгел, шуңа авыз ера. Партиядән чыгарылуның кеше өчен үтә яман җәза, чын фаҗига икәнен ул гамендә дә кертми.

Партбюро утырышында мине Бөек Октябрь революциясенә кадәрге һәм аннан соңгы татар әдәбиятына караган лекция барышында курсташларымны репрессияләнгән буржуаз милләтче Галимҗан Ибраһимовның совет строена һәм социалистик чынбарлыкка яла ягучы әсәрләрен өйрәнергә чакыруда гаепләделәр. Моңа минем укытучыга биргән соравым сәбәпче булды. «Без XX гасырның беренче яртысындагы рус әдәбиятын өйрәнгәндә мөһаҗир рус язучысы, совет дәүләтенең килешмәс дошманы, Нобель бүләге лауреаты Иван Бунинны, 1938 елда мөһаҗирлектән илебезгә әйләнеп кайткан Александр Купринны, Ватаныбыз һәм халкыбыз алдында теге яки бу күләмдә гаепләре булган кайбер башка каләм әһелләрен бүгенге көн таләпләреннән чыгып бәялибез, — дидем мин. — Ә менә туган әдәбиятыбызда кайчандыр күренекле урын тоткан кайбер татар язучылары турында нигәдер берни дә ишетмибез. Мисалга, Галимҗан Ибраһимовны алырга мөмкин. Өлкән буын вәкилләренең сөйләүләренә караганда, ул 1905 елдан соңгы кара елларда патша хакимиятенең асылын фаш иткән әсәрләр язган. Аның әсәрләренең барысын да дегет белән лычкылдатылып, бүген бөтенләй телгә дә алынмаслыкмыни?», — дигән сорау бирдем. Бу соравым укытучыбыз Бану Гыйбатовнаны бер агартты, бер күгәртте. Шактый вакыт ни әйтергә белми торгач ул, иреннәрен бәлшәйтеп:

— Авызыңны пычратып, ничек телгә аласың шул кабәхәтне, Кадыйров? Үзең коммунист җитмәсә. Синең өчен оят миңа, — диде.

— Үземне кызыксындырган нәрсәне мин төпченмәскә тиешмени, Бану Гыйбатовна?

— Халык дошманнарының пычрак әсәрләре белән дә, аларның чирканыч тормышлары белән дә кызыксынмаска киңәш бирәм сиңа, Кадыйров. Бел, ул яхшыга илтмәс сине...

Бану Гыйбатовнаның күрәзәлеге дөрескә чыкты...

Җыелыш билгеләнгән вакытта башланды. Аны институт парткомы секретаре Шәймурзин ачты. Ул алтын кысалы күзлеген маңгаена күтәреп, караласы мәсьәләне бөтенләй оныткан төсле, сүзенерактан башлады:

— Иптәшләр! ВКП(б) Үзәк Комитеты быелның 9 июлендә чыгарган «ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты эше турында»гы карары республикабыз партия оешмасы тормышында зур вакыйга булды. Анда Татарстанда партия-политик эшнең торышына һәрьяклап анализ ясалды. Сугыштан соңгы беренче елларда, бөтен илебездәге кебек үк, Татарстанда да идеология мәсьәләләренә карата игътибар шактый йомшарган иде. Бу мөһим эшнең якындагы бурычларын дөрес бәяләү өчен Үзәк Комитет 1946 елда «Звезда» һәм «Ленинград» журналлары турында», «Драма театрларының репертуары һәм аны яхшырту чаралары турында», «Зур тормыш» кинофильмы турында» 1948 елда — «В. Мураделиның «Бөек дуслык» операсы турында», «Партия сафларының үсүе, ВКП(б)га яңа кергәннәр белән партия-оештыру һәм партия-политик эшне көчәйтү чаралары турында» бик әһәмиятле карарлар кабул итте. Аларда совет халкын, бигрәк тә яшьләрне идея ягыннан тәрбияләүнең беренче чираттагы бурычлары куелды. Партия Үзәк Комитеты сәнгать иҗаты өчен ленинчыл партиялелек

принцибының мөһимлеген, социалистик чынбарлыкны дөрес чагылдыруда дөньяга марксистик-ленинчыл карашның ролен бөтен тулылыгы белән ачып бирде...

Боларның минем эшемә ни катнашы бар, нигә кирәк инде алар, дип уйладым мин, сүзне турыдан-туры башласа ни булыр иде? Мәсьәлә бюро утырышында инде хәл ителде, буш сүзләр белән нигә вакыт уздырырга? Судан май язуга охшый ич бу...

— Оят ки,— дип дәвам итте секретарь,— безнең арабызда да дошман тегерменәнә су коючы, кесәсендә партбилет йөртүче бер гарип зат бар. Ул — тарих-филология факультетының IV курс студенты Кадыйров. Партбюро утырышында без Кадыйровны курсташларын ленинчыл милли политиканың дошманы, язган әсәрләрендә илебездә Бөек Октябрь революциясе тарафыннан тар-мар ителгән буржуаз стройны тергезергә чакырган, рус кардәшләребезне төрлечә кимсеткән, бөек Коммунистлар партиясенә яла яккан, шулар өчен репрессияләнгән татар язучысы Галимҗан Ибраһимовның бик хаклы рәвештә тыелып, тарих чүплегенә ташланган зарарлы язмаларын өйрәнергә чакырганы өчен партиядән чыгардык. Партбюро утырышы кабул иткән карарга карата кемдә нинди фикерләр туды, сөйләгез, иптәшләр.

Трибуна артына беренче булып һәр җыелышта сөйләми калмый торган география факультеты доценты Хөршәтов чыгып басты.

— Репрессияләнгән милләтче Галимҗан Ибраһимовка иптәш Шәймурзин бик дөрес бәя бирде. Мин аның сүзләренә өстәп тагын шуны әйтә алам: Ибраһимов үзенең «Адәмнәр» дигән хикәясендә туган халкын — татарларны кеше ашаучылар итеп күрсәтүдән дә тартынмаган. Аның әсәрләрендә реалистик образларны көндез чыра яндырып эзләсәң дә табарлык түгел. Партбюро Кадыйровны партиядән чыгарып бик дөрес эшләгән. Мин партбюро карарын хуплыйм.

Доцент Хөршәтов артыннан чыгыш ясаган бүтән иптәшләр дә репрессияләнгән халык дошманы Галимҗан Ибраһимовны сүктеләр. Гүя җыелыш минем персональ эшемне карауга түгел, әдипнең иҗатына бәя бирүгә багышланган иде. Бу җыелышта мин ул язучының буржуаз милләтче генә түгел, фашист икәнен дә белдем. Трибуна артына чыккан иптәшләрдән мине бары XIX йөз рус әдәбиятын укытучы доцент Семен Николаевич Никольский гына яклап чыкты. Ул биргән соравымның сәяси гаепләүгә нигез була алмавын дәлилләргә тырышты.

— Мин Галимҗан Ибраһимовның егерменче елларның ахырында һәм утызынчы елларның башында Казанда академүзәкне җитәкләгәнен, аның зур галим, актив җәмәгать эшлеклесе булганын беләм. 1932 елда аңа иҗат эшчәнлегенә егерме ел тулу уңае белән хөкүмәтебезнең Хезмәт герое дигән мактаулы исем бирүе дә хәтеремдә. Моның белән мин Ибраһимовның ялгышлары булмагандыр, ул урынсызга репрессияләнгәндер димим. Эш анда түгел, биредә сүз ул турыда бармый. Менә сез, иптәш Гаҗиева,— Семен Николаевич җыелыш президиумында утырган Бану Гыйбатовнага борылды,— студент Кадыйровка Ибраһимов әсәрләрендәге бүгенге яшьләр өчен нинди зарарлы нәрсәләр барын ачыкламагансыз, без аны монда, бу җыелышта, студентларыбызга ачарга ярамаган сер дип исәплик, сез аны биредәге коммунистларга кыскача гына аңлатсагыз иде. Мин үземдә Ибраһимовның моннан унбиш-егерме еллар элек рус телендә чыккан кайбер әсәрләре белән генә таныш.

— Мин сезнең таләбегезне үти алмыйм, иптәш Никольский. Онытмагыз, биредә минем түгел, студент Кадыйровның персональ эше карала.

— Тем более...

— Мин ул буржуаз милләтченең әсәрләре турында сөйләүне үзем өчен түбәнлек саныйм, Семен Николаевич, гафу итегез...

— Без бит монда зур тормышка әле кереп кенә килүче иптәшебез яшь коммунистның язмышын хәл итәбез. Мәсьәләгә ачыклык кертергә кирәк, иптәш Гаҗиева.

— Мин инде әйтәсе сүземне әйттем, башка сүзем юк.

Шәймурзин, күзлеген маңгаеннан борынына төшереп, урыныннан торды. Ул:

— Мәсьәлә тулысынча ачыкланды, нигә сез күпчелек фикеренә каршы киләсез, иптәш Никольский? Сезнең Кадыйровны яклавыгыз мәгълүм хикмәттәге бөтен рота дөрес атлаганда бер ефрейторның ялгыш атлап ротаны үзенә ияртеп атлатырга маташуына охшый түгелме?—диде.

— Мин, Ленин призывында партиягә кергән утыз алты еллык партия стажлы коммунист буларак, фронтта, Ватаныбызны фашист илбасарлардан азат иткәндә партиягә кергән һәм илебезгә, марксизм-ленинизм тәгълиматларына турылыклы булуын кулларына корал тотып ут эчендә исбатлаган яшь коммунистны яклыйм. Аның кыюлыгын, фидакарьлеген түшендәге югары хөкүмәт бүләкләре — ике хәрби орден гына да әйтеп тора. Мин Кадыйровны партиядән чыгармаска, аңа шелтә бирү белән чикләнергә тәкъдим итәм.

Семен Николаевичның тәкъдименә колак салучы табылмады. Җыелыш, күпчелек тавыш белән, минё партиядән чыгарырга дигән карарны раслады.

Җыелыштан соң берничә көн үз-үземне кая куярга белмәдем. Нигә язмыш мине җай чыккан саен тәпәләү, кимсетү ягын гына карый, аның ялгышып булса да иркәләвен миңа инде татырга беркайчан да насыйп булмас микәнни, дип өзгәләндем. Партиядән чыгарылуым миңа кыерсытылуымның иң югары ноктасы булып күренде. Курсташ иптәшләремнең кайберләре хәлемә керергә, тынычландырырга тырыштылар, минем исә беркем белән дә аралашасым, сөйләшәсем, берәүне дә күрәсем килмәде. Башымда, нигә дип яшим, кемгә кирәгем бар, үз-үземә кул салу бәлки хәерлерәктер, кебек өметсез уйлар тулганды. Кешеләрне үземә нәфрәтләнеп, җирәнеп карыйлар итеп тойдым. Шуңа күрә Яңа — 1950 елны да, беркая да бармыйча, тулай торакта ялгызым гына каршыларга булдым.

## 2

Фронтта чакта, һөҗүм вакытларында, һәркөнне нарком «өлеше» белән сыйласалар да, мин эчәргә, аракыдан тәм, ләззәт табарга өйрәнә алмадым. Шулай булса да, Яңа елга аяк басканда, минем исергәнче эчәсем, күпмедер вакытка борчылуларымнан арынып торасым килде. Бу уемны эшкә ашыру өчен бер ярты ак аракы алдым. Утыз беренче декабрь көнне сәгать кичке тугызлар тирәсендә тулай торакта чагыштырмача тынлык урнашты, студентлар Яңа елны каршыларга төрлесе төрле җирләргә таралыштылар. Мин, тумбочкамда өстәл лампасын яндырып, эчкәч кабарга ипи, суган, казылык әзерләгәч, шешәне ачып, чәй стаканыма тутырып аракы салдым. Башымда уйлар өермәсе купты, эчәргә ашыкмадым. Күпмедер утыргач, миңа аракыдан юаныч эзләү үз-үземнән көлү булып күренде. Хәтеремә нииндидер китаптамы, журналдамы укыган, кеше беркайчан да кем икәнен анык белми, ул үзенә тиешледән күпкә югары бәя бирергә тырыша, дигән сүзләр килде. Бәлки мине партиядән чыгарып дөрес эшләгәннәрдер, мин үземне урынсызга кыерсытылдым дип исәпли торганмын? Ярар, хәзер исереп беразга онытылып торырмын, айныгач, авыр уйлар яңадан борчый башлаячак бит. Аракыдан юаныч табарга азаплануымны әти, һич шикләнмим, мактамас иде. Ул, эчеп организмнарын агулаучы, аракыдан тәм, ләззәт эзләүче бәндәләрне аңламыйм да, аңларга да теләмим, дия иде бит. Әти һәм әни, сез кайда? Сез исәнме әле, әллә инде каберләрегез өстен күптән кычыткан, тигәнәк, шайтан таягы бастымы? Сезнең язмышыгыз нигә минем өчен шулай билгесезлек белән чикләнде? Нигә, бик күпләр гамьсез гомер кичергәндә, сезнең тормышыгыз шомлы таш диварлар артына кереп адашты? Нигә?.. Сезнең утыз җиденче елдан соңгы язышыгызны ачыкларга теләп күп кенә югары оешмаларга язып карадым, ләкин эзләнүләрем нәтиҗә бирмәде. Сез беркем күрмәгәндә һәм искәрмәгәндә, гүя, суга баттыгыз кебек. Бәлки мин сезне юксынган, сезне

эзләгән шикелле, сез дә мине эзли торгансыз? Юк, эзләмисездер. Моталлап абыйның хатыны Мәчтүрә җиңги Казанда икәнемне белә, эзләсәгез аңа мөрәҗәгать итми калмас һәм адреслар бюросы аша мине күптән табар идегез инде. Безнең аерылышуга унөч ел үтте. Сезне кулга алгач, хөкемгә тартып, унар ел бирсәләр дә, инде артыгы белән булды ул ун ел. Мин инде элек сез белгән ярдәмгә мохтаҗ малай түгел, утызга якынлашам, чәчләремә чал куна башлады. Балалар йортын үттем, сугыш авырлыкларын кичердем, менә педагогия институтын тәмамлау алдында торам. Киләчәктә, әти, укытучы булып, синең ярты юлда калган эшеңне дәвам итәргә хыялым...

Бүлмәдә утны сүндереп, урамга чыктым. Төн салкын, җилсез, аяз. Гадәтемчә, исәпсез-хисапсыз йолдызлар белән бизәлгән күктә Җидегәнне эзләп таптым. Күз алдыма үз тирәсеннән төн карасын читкәрәк куарга тырышып дөрләп янган кайнар учак, җәйге сихри урман, Әләкси әрчүе, пошкыра-пошкыра тыныч кына үлән кыркучы атлар, сыңар күзле Камали бабай, Гайфи, Кәрим, Сөләй килде. Балачак дусларым кайда һәм нишлиләр икән хәзер? Сугыш зилзиләсен алар барысы да исән кичтеләрме икән? Бәлки алар хәзер өчесе бергә Яңа елны каршыларга әзерләнәләрдер? Бәлки араларыннан кайсы да булса бу минутта, минем күк Җидегәнгә төбәлеп, уйларында еллар чытырманлыкларында адашып артта калган балачагыбызга кайткандыр?..

Күктә йолдызлар, күпчелек тәрәзәләрдә чыршы утлары җемелди, кайдандыр тонык кына булып җыр, музыка ишетелә. Кайбер түземсез җаннар инде бәйрәм итә башлаганнар да бугай. Ә ярты төнгә, Яңа елга аяк басарга шактый бит әле.

Үзем дә сизмәстән, мин Черек күл буена — республика дәүләт иминлеге министрлыгы урнашкан бина янына барып чыктым. Әнине мин соңгы тапкыр шунда күргән идем, аның белән шунда аерылышкан идек бит. Әнә ул кереп киткән ишек, еллар үтсә дә, үзгәрмәгән, һаман элеккечә үк... Миңа әни аннан менә-менә килеп чыгар кебек.

Черек күлдәге балалар паркында аллы-гөлле гирляндаларда төрле зурлыктагы лампочкалар яна, һәр ботагы зәвыклы матур уенчыклар белән бизәлгән, түбәсенә зур кызыл йолдыз куелган иләмсез биек Яңа ел чыршысы тирәсендә бәйрәмчел халык тулгана, көчле репродукторлардан тирәюньдәге төнге караңгылыкка дәртле музыка аһәңе тарала. Кешеләргә яңа бәхетләр, яңа шатлыклар, яңа уңышлар алып Яңа ел килә. Миңа ул нәрсә китерер, барыр сукмакларымны кай тарафларга илтеп чыгарыр, кемнәр белән очраштырыр, кемнәр белән аралаштырыр? Мин институтны тәмамлап диплом алу, зур тормышка ныклап аяк басып, атлап китү алдында торам бит. Әти белән әни хәзер бу хәлемдә күрсәләр шатланырлармы, әллә борчылырлар идеме икән? Беләм, әтинең, һичшиксез, кәефе кырылыр, кашлары җыерылыр, битендәге яра җөе тартыша башлар, әни тирән көрсенеп: «Әй бала, бала»,— дип хәсрәтләнеп башын селкер иде. Партиядән кулу уен эш түгел бит. Гаҗәп, күпме генә уйласам да гаебемне сизмим, нинди хата эшләвемне аңламыйм. Бердәнбер «ахмак» соравым нигә бөтен үткәнемә күләгә төшерергә җитә калды әле?

Үз алдыма куйган төрле сорауларыма җаваплар таба алмый башымны тинтерәтеп тулай торакка кайткач, бүлмәбез тәрәзәсендә ут күреп, туктап калдым. Аннан утны сүндереп чыккан идем ич, кем кайтты икән? Бүлмәдәш алты иптәшемнең дүртесе өченче көн ук Яңа елны каршыларга әти-әниләре янына кайтып киттеләр. Авыллары Казанга якын студентларга бу берни түгел, поездга утыралар да теләсәләр кайчан сәфәр чыгалар, йә шундук тасырдап кайтып җитәләр. Бүген алар кайтмаска тиеш иде. Бишенче бүлмәдәшем тарих факультетында укучы Әнәс Байбурин аягын сындырып больницада ята, аның да кайткан булуы икеле, әле кичә генә янына курсташлары барган иде. Әнәснең ай ярым, ике айсыз аякка басарына ышанырлык түгел, диделәр. Корея студент Ли Ин Сан ниндидер йомыш белән Мәскәүгә китте. Бүлмәбездә хәзер бербашым. Кем керде, кем ут алды икән анда?..

Бүлмәбездә ут алучы тарих факультеты студенты Мөхит Капкаев булып чыкты. Ул тулай торакта яшәми, фатирда тора. Без аның белән дуслар, икебез дә кыен фронт юлларын таптаган, кысыр сугыш шулпасын чөмергән кешеләр. Мөхит миннән ике яшькә өлкән, әмма кайберәүләр кебек үзенең «картлыгы»на басым ясаганы, акыл өйрәткәне юк.

— Көттем, көттем, панимаеш, син юк, ачудан стаканыңдагы аракыңны кәгеп, шешәң белән гәп куертып утырам. Кайда йөрдең, байгыш сыңары? Хәзер Подлужная урамына таныш кызлар янына китәбез. Аларга синең буш общагада япа-ялгыз каңгырып утыруыңны әйткәч: «Тиз генә монда алып кил аны»,— диделәр. Бигрәк тә медта укучы Гайния өндәде. Сиңа аның узган ел ук күзе төшкән иде ич инде, берәү булса күптән дамкага чыгар, авыз ачып йөрмәс иде.— Мөхит стаканга тутырып аракы салды.— Мә, тот. Эч тә, китәбез, алар көтәләр.

— Эчмим, дус, кыстама.

Мөхит, кашларын җыерып, бер-беренә якын соры күзләрен миңа текәде.

— Эчмәслек булгач нигә алып кайттың да, нигә ачтың соң син бу хәерче малаен? Әйдә, мине дус санасаң, якын итсәң, тыңла сүземне, сал.

— Дуслык, якынлык аракы чөмереп дәлилләнми, эчмим.

— Ул нәрсә белән дәлилләнә соң?

— Менә синең мул бәйрәм табынын, кызлар компаниясен калдырып иренмичә мине эзләп тулай торакка килүең якын итүеңнең дәлиле. Мин эчмим, дус, үпкәләмә. Яңа елны мин аек баш белән каршыларга булдым.

— Кызлар янында да эчмәссеңмени?

— Мин бит әле анда барам димәдем сиңа.

— Бармыйсың, киреләнәсеңмени?

— Киреләнмим, Яңа елны мин ялгызым гына каршыламакчы булам.

— Анда дүрт күз белән көтәләр безне! Сине үз күргән, якын иткән кешеләрдән нигә читләшергә, бармавың белән аларның нигә кәефләрен кырырга? Кешеләр белән хисаплашырга, аларны уважать итәргә киңәш бирәм мин сиңа, брат. Йә һаман да чыгымчылыйсыңмы?

Инде ярым исерек дустымның нәсыйхәте саруымны кайната башлады. Тизрәк һавага алып чыгарга кирәк аны, бераз айный төшсен, юкса бүлмәдә егылуы бар, дип уйладым.

— Булды. Чыгымчыламыйм, күндердең. Әйдә киттек.

— Стаканга салган бу аракыны нишләтәбез?

— Калсын шул килеш, иртәгә баш төзәтербез.

3

Яңа ел иртәсендә йокыда идем әле, кемнеңдер кыюсыз гына ишек шакуына уяндым. Кайсына кирәгем чыкты икән?.. Бүлмәдә бүтән кеше юк, ялгызым бит.

— Керегез,— дидем, башымны мендәрдән күтәреп.

Ишекне сак кына ачып, өстенә кат-кат юылудан төсе шактый уңган коңгырт халат кигән, уртадан түбәнрәк буйлы, озынчарак йөзле, саргылт бөдрә чәчләре килешле генә тузгып иңнәренә төшеп торган бер кыз кереп, бусага төбендә туктап калды.

— Исәнмесез. Яңа ел белән тәбриклим сезне.

— Үзегезне дә. Исәнмесез.

— Гафу итегез, миңа Ирек Кадыйров кирәк иде.

Мин кызга төбәп карадым. Моңарчы күргән-белгән кешем түгел, аңа ни хаҗәтем чыкты икән?

— Сезгә кирәк кеше мин булам. Рәхим итеп узыгыз бире. Әнә урындык, утырыгыз.

— Узып тормыйм, йокыгызны бүлдем, гафу итегез. Чыгыйм, йоклагыз, соңыннанрак керермен.— Кыз ишеккә борылды.

— Коридорда көтегез, китмәгез, мин замәт арасында киенәм дә чыгам.

Мин коридорга чыккач, без таныштык. Кыз үзен Ольга дип атады. Ул шактый кыю күренә. Танышу белән үзенең безнең факультетта беренче курста укуын, тулай торакта әле күптән түгел генә тора башлавын әйтте. Минем янымa аны курсташы Ася Фоминаның запискасы керткән.

— Без кичә, сәгать төнге уникенче киткәч, Ася белән сезне эзләп килгән идек, өйдә булмадыгыз. Аның сезне бик күрәсе килә,— диде Оля, үзенең мине көтмәгәндә бимазалавына уңайсызланганын сиздереп.— Менә запискасы. Ася, сез аның белән очрашырга каршы килмәсәгез, аның фатирына барырга, риза булмасагыз, кош теле кадәр генә җавап язарга кушты.

— Мин аның кайда торганын белмим, записка гына язармын.

— Барсагыз, үзем озатырмын.

Без төштән соң очрашырга килештек. Бүлмәгә кергәч, мин бөти ясап төргән записканы сүтеп, аңа күз йөртеп чыктым.

«Иптәш Кадыйров! Сезне Яңа ел белән тәбрикләп шатлык-куанычлар телим. Борчуым өчен түбәнчелек белән гафу үтенәм. Уйламагыз, бу записканы мин үз мәнфәгатемне күздә тотып язмыйм, аллам сакласын, аны язуны вөҗданым таләп итә. Безгә очрашырга, икәүдән-икәү генә утырып гәпләшергә кирәк. Мин сезне партиядән чыгарып дөрес эшләмәделәр дип саныйм. Коммунист буларак, җыелыш кабул иткән ул гаделсез карар белән мин килешә алмыйм. Дөрес, ул карарны яклап үзем дә кул күтәрдем, хәзер менә шуңа борчылам, бәргәләнәм. Мөмкин санасагыз, без көндезге сәгать өчтә очрашыйк әле. Адресымны бу записканы сезгә тапшырачак кыз белә, ул сезне минем фатирыма озатып куяр. Үтенәм, запискамны үзегездә калдырмагыз, Оляга кире кайтарыгыз.

Борчуым өчен янә бер кат гафу үтенеп: Ася Ф.»

Записка кәефемне җибәрде, ачуымны кабартты. Ул борчыла, бәргәләнә, имеш. Мине партиядән чыгарганда башкаларга ияреп кул күтәрүенә пошына, көяләнә. Аның белән очрашу күңелемдәге сулгып әрнегән авыр ярага кайта кагылып, аны өстәмә өтәләү булачак. Нигә дип ул үзен миннән тынычландыртырга тели әле? Бәлки бу аның үзенчә хәлемә керүе, син ялгыз түгел, сине яклап чыккан Семен Николаевич Никольский янында мин дә бар, диюедер? Алай булса, нигә ул аны җыелышта әйтмәгән, авызына су капкандай мыштым гына утырган соң? Вакыт узгач, инде нигә көяләнеп күңел ачыттырырга? Бу бит бераүне унлап кешенең җыйнаулашып тәпәләвен ваемсыз гына карап торган һәм соңыннан, сине ул кансызлар изгәндә мин синең яклы идем, әмма булышырга кодрәтем җитмәде, дию белән бер. Халыкның, кара сакалың кая барсаң да үзеңнән калмый, дигәне урынлы. Минем дә менә узган елгы бәла-казаларым былтырда тоткарланып, бөялеп калмаганнар, үзем белән бергә быелга атлап кергәннәр. Сакалның хуҗасыннан калмавы, аңа ияреп йөрүе бәлки яхшыгадыр ул? Тормыш бер үк эздән ага, аның туктап калырга да, юлын үзгәртергә дә чарасы юк. Яшәешнең даимилеге, үзгәрешсезлеге, төплелеге сокланырлык. Эзлеклелекне берни дә алыштыра алмый.

Мине адәм актыгы иткән партия җыелышы күз алдымнан кабатланып яңадан үтте. Гаделсезлеге, дорфалыгы, алдагы язмышыма сукырлыгы белән ул әнә Фоминаның да тынгылыгын алганга охшый. Аңа минем белән очрашу, гәпләшү нәрсәгә кирәктер, һич аңлашылмый. Тукта, ул бюро члены бит. Бәлки аңа йомыш тапшырганнардыр һәм ул шуны үтидер? Алай булса нигә аны ачыктан-ачык язмый, записканы иптәш кызына кире кайтаруымны сорый? Анда кысага сыймастай нәрсә язылмаган бит. Партбюро утырышында персональ эшемне тикшергәндә ул кыз миңа бер сорау да бирмәде, анда очраклы гына кергән кеше төсле битараф утырды. Мине партиядән чыгарырга дигән тәкъдим тавышка куелгач, кулын беренче булып күтәрде һәм миннәнме, ашыгуына уңайсызланыпмы, комач күк кызарды.

Мин ул кызны бөтенләй диярлек белмим. Институтта укый башлаганчы китапханәдә эшли иде шикелле. Төсе-бите, килеш-килбәте белән ул институттагы кызлар арасында чебиләр төркемендә ялгыш килеп эләккән үрдәк бәбкәсе күк аерылып тора. Буе базык, гәүдәсе калын, чырае беренче күрүдә үк хәтердә калырлык: куе сипкел чуарлаган табак бит, почык бо-

рын, бер-беренә тоташкан калын аксыл кашлар астында кырау суккан күзгә чәчәкне хәтерләткән кечкенә соры күзләр, бөдрәләтелгән аксыл чәч. Аның белән минем моңарчы сөйләшкәнем түгел, хәтта исәнләшкәнем дә юк иде. Мин, гомумән, хатын-кызлардан ераграк йөрергә тырышам, алардан уңайсызланам. Ир-атлар белән дә дуслашырга, аралашырга, әшнәләшергә атлыгып тормыйм.

Төштән соң Оля безнең бүлмәгә яңадан керде.

— Йә, нинди карарга килдегез, барасызмы?

— Бармыйм, Оля күгәрченкәй. Ахирәт дустыгызга хәлемә керергә тырышканы һәм миңа юллаган Яңа ел теләкләре өчен рәхмәт тапшырыгыз. Аны үзен дә Яңа ел белән тәбрикләп, тиз арада барлык борчылулары белән хушлашуын телегез. Үпкәләмәсен, аның белән очрашуны кирәк санамыйм. Ул запискасын кире кайтаруны сораган, мәгез, тапшырырсыз,— дип, записка1 яңа танышыма суздым.

Оля бу керүендә кышкы киемнән иде. Өстендә иске курач пальто, башында ап-ак мамык шәл. Бу кыяфәтендә ул миңа ничектер бала гына төсле күренде. Башыма ирексездән аңа карата, йомышчы кыз, дигән кимсетүле уй килде.

— Асяны дөрес аңламагансыз, минемчә. Ул сезгә чын күңеленнән яхшылык тели, һичшиксез, очрашырга кирәк сезгә. Кешеләрдән йөз чөереп үз кузыгызга бикләнмәгез, зинһар. Ялгызлыкның, уй-фикерләреңне, борчу-изалануларыңны уртаклашучы булмауның нәрсә икәнен үзем дә кичердем, беләм. Ася белән очрашуга каршы килмәгез, ул сездән бигрәк, Ася өчен мөһим.

— Гафу итегез сеңлем, кемнеңдер китек күңелен бөтәйтергә һич теләгем юк. Үз кайгым үземә җиткән...

— Ярар алайса, бармасагыз хет монда бикләнеп утырмагыз, һавага чыгыгыз, көн әнә нинди матур.

— Һава сулап керү зыян итмәс, анысы.

— Киенегез алайса, Асяның фатирына кадәр озатырсыз мине.

Ут кыз бу, мине әле күпме генә белә, без әллә кайчаннан якын танышлар диярсең, инде ничек командалык итә, моңа якты йөз күрсәтсәң, минут тынгы бирмәс, дидем үз-үземә. Мәгәр яңа танышымның үҗәтлеге, үзсүзлеге миндә аңа карата ихтирам, җылы хис тә уятты.

Без урамга чыктык. Көн җилсез, тыныч. Черек күл ягыннан кичәге кебек үк музыка яңгырый.

— Сез тышта телегезне туңдырудан куркып сөйләшмисезме әллә? — дип кызыксынды Оля, без тулай тораклан байтак җир киткәч.

— Тел тибрәтүең бер алтын булса, аны тик тотуың мең алтын, дигән бит бер акыл иясе.

— Без, үз уйларыбызга бирелеп, бер-беребезгә битараф атласак, очраган кешеләр, болар нидер бүлешә алмаганнар, Яңа елны әчелешеп башлаганнар ахры, диючәре бар.

— Кызык кеше сез, әйдә, үзегез турында сөйләгез алайса. Сүздән сүз үрчер бәлки. Кайдан сез? Кемнәрегез бар? Нәрсәләр белән кызыксынасыз?

— Башта бәлки сез сөйләрсез, аннары — мин...

— Барыбер түгелмени?

— Ярар, сезнеңчә булсын. Горький өлкәсеннән мин. Әтием юк, миңа биш яшь вакытта дөнья куйды. Энем бар, бала чакта тиешле тәрбия алмады, юлдан язды, хәзер төрмәдә. Моңа әнием гаепле. Ул абруйлы кеше — җитен комбинаты директоры. Гаҗәпләнмәгез, аның белән минем инде дүртенче ел бернинди бәйләнешем дә, алыш-бирешем дә юк. Ул гади кешеләрне санга сукмый торган үтә һавалы хатын. Әнием белән арабыз өзелүнең ничек килеп чыгуын да сөйлим. Сугыш алдыннан ул үзеннән ундүрт яшь кече бер егетне йортка кертте. Әнинең булачак ире, шәһәрдә ниндидер уку йортын тәмамлагач, җитен комбинатына механик булып килде. Әни аны фатирга үзенә кертте. Озакламый алар өйләнештеләр һәм шуннан соң әниебез энем белән минем дөньяда барлыгыбызны онытты. Әтием дә әнием аркасында дөнья куйды дисәм, ялган булмас. Ул йомшак

холыклы, эчкерсез, бала җанлы, карусыз кеше иде. Кайдадыр бик нык салкын тидергәч, әни аны исерткәнче эчереп, чирен тирләтеп чыгарырга диеп, эссе мунчага япты, әти шунда җан бирде. Әтидән без биш бала калган идек, ул үлгәч, бер ел эчендә өчебез тәрбиясезлектән дөнья куйды. Энем белән мин ничек исән калганбыз, әйтә алмыйм. Кырык беренче елны сугыш башлангач, әнинең яшь ирен армиягә алдылар. Аннан ул, сау-сәламәт калып, эчәргә өйрәнеп кайтты. Фашистларны кыйнагандырмы, юктырмы, белмим, фронтны кайдадыр тылда гына үткәрде бугай, түшенә башкалар кебек орден-медальләр тагып кайтмады. Әни аның янына сугыш барышында берничә тапкыр азык-төлек, тәм-том төяп барып кайтты. Мәсьәлә анда түгел. Әнинең ире, әни өйдә юк чакта, исергән саен үзенең каһәрләнгән язмышыннан зарлана, мине үзе белән кая да булса качып китәргә димли, безгә тик мине яратканы өчен генә кайтканын, урынсызга кыерсытылган сабый кебек, җылый-җылый сөйли торган булды. Аны мин түкми-чәчми әнигә сөйләп бирдем. Шуннан соң әнием мине үзенең көндәше санап, күрәлмәс булды. Миңа аның «түгәрәк» тормышын бозмас өчен өйдән чыгып китүдән бүтән чара калмады. Менә инде дүртенче елым үз көнемне үзем күрәм.— Оля, кашларын җыерып, тирән көрсенде.— Йә, ничек уйлыйсыз, кызыгырлыкмы тормышым?

— Сез беркаян да ярдәм алмыйсыз, стипендия исәбенә генә яшисез булып чыга?

— Юк, мин эшлим бит.

— Кайда, нинди эштә?

— Киез итек-фетр фабрикасында контролер мин.

— Бер үк вакытта эшләү дә, уку да авырдыр ич?

— Нихәл итим, башка чарам юк.

Юк, кем нәрсә кушса, шуны үтәргә атлыгып торучы йомышчы кызчык түгел икән Оля. Чит-ят шәһәрдә ялгызы үз көнен үзе күреп, укырга һәм эшләргә никадәр ихтыяр көче, тырышлык, сабырлык кирәк. Ә бит ул үз тормышындагы кыенлыкларны җәелеп сөйләмәде, сүз уңаенда гына телгә алды.

— Сер булмаса әйтегез әле, сезне Ася Фомина белән нәрсә бәйли, ул нииндирәк кеше?

Бу минем яктан, сез иптәшегезнең кемлеген бәяләгез, шуннан мин сезнең кем икәнегезне чамалармын, дигән кебегрәк сорау булды. Мәгәр Оля аңа игътибар итмәде.

— Миңа Асяның кешелеклелеге, беркатлылыгы, эчкерсезлеге ошый. Ул мине ник якын итәдер белмим.

Чернышевский урамында «Пионер» кинотеатры урнашкан элекке Пассаж бинасына җиткәч, Оля туктап калды.

— Ася шушы бинаның өченче катында тора, керик булмаса...

— Хәлемә керергә теләгәне өчен Фоминага рәхмәт әйтегез.

— Сез хәзер тулай торакка кайтасызмы?

— Кайтмыйм, бирелә әнә Леонид Леонов драмасы буенча эшләнгән «Ябырылу» фильмы бара икән, шуны карарга кирәм.

— Авырсынмасагыз, миңа да билет алыгыз. Мәгез акча, мин хәзер чыгармын.

— Акчагыз кирәкми, билет алырмын.

Кинотеатрдан Оля да, мин дә тетрәнеп чыктык. Кинофильм тормышны көзгедәгечә чагылдырмый, әлбәттә. Аның мохитне, тарихи сәхифәләрне, тегe яки бу вакыйгаларны гәүдәләндерүдә үз кануннары, үз таләпләре бар. Әмма «Ябырылу» фильмы тарихи җирлектә тетрәткеч итеп эшләнгән дияр идем мин.

— Артист Жаков күңелгә уелырлык күркәм образ тудырган. Әмма фильмдагы Федор шикелле үзен аямый торган кешеләр тормышта бераңсәрән генә очрый,— диде Оля шактый вакыт сүзсез баргач, үз алдына сөйләнгәндәй.— Федор — Жаковның тышкы кыяфәте, үз-үзен тотышы башта аңа карата нәфрәт, җирәнү уята. Аннары әлеге саф намуслы, олы

җанлы кеше өчен борчыла, аны якын итә башлыйсың. Сезгә фильм ошадымы?

Мин «Ябырылу» кебек житди әйберне ялгызым гына карарга яратам. Нинди генә сәнгать әсәренә дә өзеп уңай, йә кире бәя бирергә ашыкмыйм. Андый бәя миңа күн төшсә отып, иләк төшсә оттырып акчалы уйнау кебек тоела.

— Фильм әйбәт,— дидем мин, юлдашымның соравын җавапсыз калдырмас өчен.— Кинотеатрга мин үземә кирәк нәрсәне сайларга киемнәр кибетенә кергән кебек кермим. Минем күз алдымда әле һаман фильмдагы Федор үзе түгел, аның бөтен экранны тутырып сыек ләпәк ерып атлаучы зур, котсыз итекләре тора.

— Уйламый биргән соравым өчен ачуланмагыз. Мин аны, бер-берләре белән әрләшкән кешеләр төсле, сөйләшми кайтуыбыздан арыну өчен генә бирдем. Сез әйткән котсыз итекләр нәни деталь генә ич алар.

— Алай карасаң, тамчы да диңгез өчен әһәмиятсез деталь генә ич.

Оля башкача бәхәскә кермәде. Без тулай торакка кайтып җиткәнче сүз катмадык. Аерылганда Оля миңа:

— Сезнең нинди кеше икәнегезне аңлавы кыен, Ирек,— диде.

Мин:

— Булыр, кайчак үземне үзем дә аңлый алмыйм мин, Оля, үпкәләмәгез дорфалыгым өчен. Кино карашканыгыз өчен рәхмәт,— дидем.

## Икенче бүлек

### 1

Бишбалта... Бакалтай... Бу сүзләр нинди мәгънә аңлата, аларны исем итеп кем кушкан? Нигә Дүртбалта, Сигезбалта, йә булмаса Унбалта түгел, ә Бишбалта? Бакалтай да шулай ук. Казанда андый серле, сәер исемнәрне чал тарих байтак калдырган. Тегәрҗеп, Аккомасты, Сабанчы урамнары...

Казандагы исемнәр мине күптәннән кызыксындыра. Алар барысы да серле. Шуңа күрә институтта укый башлаганнан бирле Казан тарихына бәйләнешле күпме материалны укып өйрәндем инде, мәгәр кызыксыну кытлыгымның йөздән бер өлешен генә дә канәгатьләндерә алганым юк әле. Укыган саен бутала гына барам. Һәр тарихчы үзенә ничек уңайлы, шулай фикер йөртә, теге яки бу нәрсәне үзенә ничек җайлы, шулай аңлата. «Казанны буйсындыру турында кенәз Курбский хикәяте»н, П. Рычков, С. Порфильев, К. Фукс, М. Рябушкин, А. Артемьев, Н. Загоскин, С. Шпилевский, П. Дульский, М. Худяков язмаларын укыйсың һәм аларның кайсына ышанырга белми аңгы-миңге киләсең. Бу язмаларда, 1552 елда Явыз Иван җитәкчелегендәге рус явы Казан ханлыгын буйсындырырга килгәч, аларның кай урыннарда шартлатулар оештырганнарын да, астына казанлыларны су белән тәэмин итүче чишмә урнашкан Мөрәле баштысын шартлатырга, аңардан җир асты юлы казыла башлаган Таһир мунчасының кай җирдә урнашкан булуын да төгәл белмисең. Алда телгә алынган авторларның язмаларын укыгач, каланың Түмән, Аталык, Арча капкалары, Таһир мунчасы кай урында булганнар диген сорауга, ак болыт турында, дип җавап бирүдән бүтән чара калмый. Бер генә тарихчы да аларның кайда булуларын төгәл әйтеп язмый, хәзер ул урыннарны ничек табарга икәнен күрсәтми. Казандагы урамнарның да элекке исемнәре күптән юк. Эт, Түбәтәй тыкрыкларын, Ташаяк урамын, Әрмән бистәсен эзләп кара — таба алмый җаның чыгар.

Мин, Ленин исемендәге үзәк республика китапханәсенең уку залында М. Пинегинның 1890 елда Санкт-Петербургта чыккан һәм моңарчы кулыма төшмәгән «Казанның узганы һәм хәзергесе» исемле китабын иртәдән бирле конспектлаштырып утырдым да, арыгач кайтырга чыктым. Инде караңгы төшкән иде, көне буена авызыма бер бөртек ризык кермәгәнен искә

төшереп, кайту юлымда университетның студентлар ашханәсендә капкалап чыгарга булдым. Анда кырык-илле кеше чиратка баскан, кимендә бер сәгатьсез өстәл артына утырырлык түгел иде. Басаргамы чиратка, басмаскамы, дип икеләнә калдым. Шулай бүрегем белән киңәшеп аптырап торганда:

— Ирек, бирегә килегез, сезгә нәрсәләр алыйм? — дип кемнеңдер үземә дәшүен ишеттем.

Оля икән. Кышкы имтиханнар тапшырып йөреп, аны Яңа елдан бирле күргәнем юк иде, янына барып исәнләштем. Аңа инде кассага җитәргә дүрт кеше калган иде.

— Үзегезгә нәрсәләр алсагыз, миңа да шуларны ук алыгыз.

— Ерак китмәгез, миңа булышырсыз. Кашыклар, чәнечкеләр әзерләп, урын ала торыгыз.

Ашагач тулай торакка кайтырга чыктык.

— Теге көнне мин үзем турында сөйләгән идем, бүген бәлки сез үзегез турында сөйләрсез? — диде Оля, мине култыклап.— Имтиханнар ничек бара, тапшырасызмы?

— Зарланырлык түгел, әйбәт. Үзегезнең ничек?

— Минем көчкә-көчкә шыгырдый.

— Нишләп алай?

— Әзерләнергә вакыт тими, эш.

Кызның гадилеге, эчкерсезлеге, кешелеклелеге мине җиңде. Аңарчы үзем турында бик аз кешеләргә генә ачылганым бар иде, үткәннәремне вәзенләп сөйләсәм, әңгәмәдәшемдә үземә дошманлык туар дип шөлли идем.

— Үткәннәрем авыр әкият минем,— дип Такташ сүзләре белән башладым хикәяләвемне,— мин дә синең кебек үк әти-әнисез. Алар утыз җиденче елның ахырында бер-бер артлы икесе тиң кулга алындылар һәм суга төшкән кебек, югалдылар...

Без ул кичне Оля белән урамнар буйлап озак йөрдек. Мин аңа башта үзем турында сөйләдем, аннары үзебез йөргән урамнарга кагылышлы тарихи сәхифәләргә, Казанда яшәгән атаклы кешеләргә, аларга бәйләнешле кызыклы истәлекләргә күчтем.

Оля мине кызыксынып тыңлады. Ахырдан:

— Мин Лев Николаевич Толстойның «Балдан соң» исемле хикәясенең ничек язылуын да, Горькийның Казанда яшәгәндәге тормышын да, язучы Аксаковның Казан университетының беренче студенты булганын да, дөнья культурасының горурлыгы мәшһүр Шаляпинның Казанда туганын да белми идем,— диде.

Мин сөйләгәннәремне шулай игътибар белән тыңлаучы кешене очратуыма чиксез шатландым. Шул кичтән соң без тагын ике тапкыр очраштык. Кышкы сессия тәмамлангач, 21 январьда, җомга көнне, Оля Валисьево ял йортына китте.

Ул киткәнгә әле тәүлек тә юк, инде аны ел буе күрмәдем кебек. Бәлки, гашыйк булганмын аңа? Кешегә мәхәббәт шулай сиздерми килеп, сөю ялкыны шулай искәрмәстән кабынамы икән әллә? Бу, минем бала чакта гомерем буена хатын-кызлар белән аралашмам, бәйләнешмәм, дигән антыма хыянәт итүем түгелдер ләбаса? Каян килеп чыкты ул, тынычлыгымны алган кыз, нигә кирәк иде безнең очрашуыбыз, ансыз да азмы минем маза-мәшәкатьләрем? Тиргәнгә киткәнче чик куярга! Башымны бүтән әйләндермәскә кирәк. Оля үзенә башка әңгәмәдәш тапсын...

## 2

Алдагы җәйдә мин, кулыма диплом алып, Татарстанның иң ерак районнарының берсенә укытырга китәчәкмен дип күңелемә күптән беркетеп куйдым инде. Бәлки Каран районына кайтырмын?.. Юк, хәзергә ярамый әле ул районга аяк басып йөрәгемдәге иске яраларны әрнетү. Башта әзрәк

кеше кәмаленә керергә, тернәкләнергә, күңел төпкеленә утырган хәвефле юшкыннардан арына төшәргә, борчулар талкыган җанны тынычландырырга, аны төрле күңелсезлекләрдән киртәләргә кирәк. Аннары гына Каран районына, төгәлрәге, Бәешкә кайтып, әтинең ярты юлда өзелеп калган укытучылык хезмәтен дәвам итәргә ярый. Тоныкк күләгәгә охшап анда кайтудан файда юк. Бәешкә мин уравыч юллардан ашыкмый кайтырга тиеш...

Курсташларым барысы да каникулны өйләрендә әти-әниләре, туганнары катында үткәрәчәкләр. Минем кайдадыр китеп торучым юк, институт профкомы ял йортына барырга путевка бирде, каникулымның яртысын шул путевка белән Васильевода үткәрәчәкмен. Анда кичә үк китәргә тиеш идем инде, әмма тоткарлана калдым. Шимбә көнне кышкы сессиядәге актыккы имтиханнан соң факультетыбыз деканы Илья Александрович Рахлин миңа кичекмәстән институт директоры Йосып Әхмәтҗанович Туишев янына керергә кушты. Бу боерыктан пошаманга калдым. Өркетелгән карга куактан да курка, диләр бит, күңелемне борчу-шөбһә биләде, директор кадәр директорга нигә кирәгем чыкты икән, тәгаен институттан сөрергә булгандыр, чакыруы шуңадыр, дип борчылдым. Шунда ук, алай дисәң, институт директоры олы башын кече итеп үз катына дәшеп тормас, приказ чыгарыр да эше бетәр иде, ул бәлки приказны җылы килеш үз кулыма тапшырырга һәм, партиядән куылган студентка институтта урын булырга тиеш түгел, Кадыйров, үзеңә үпкәлә, хәзер дүрт ягың кыйбла синең, дияргә чакырадыр дип тә хафаландым.

Кердем. Йосып Әхмәтҗанович кем беләндер телефоннан сөйләшә иде, исәнләшүемә, телефон трубкасыннан аерылмый, баш кагып кына җавап кайтарды. Һәрвакыт ачык йөзле бу кешенең җитдилеге шигемне үрчетте — юньлегә чакырмаган ул, дип эчем жу итте.

Сөйләшүен тәмамлагач директор, гадәтенчә әдәпле елмаеп, миңа утырырга урын күрсәтте.

— Кәефләр ничек, Кадыйров, имтиханнарны ничек тапшырдыгыз? — дип сүз башлады аннары.— Борчулы вакытыгыз иде, алган белгеләрегездән канәгать калдыгызмы?

— Кәефемне шәп дия алмыйм, Йосып Әхмәтҗанович, имтиханнарны каударланусыз тапшырдым, билгеләрне дә электәгендән түбән куймадылар — бишлеләр алдым.

— Молодец. Фронтта чыныгу үткән егет сынатмаска, башкаларга үрнәк булырга тиеш. Ә кәефне күтәрергә кирәк, күтәрергә...

Нәрсә бу, институт директоры мине үз кабинетына кәефемне барларга, кышкы сессияне ничек төгәлләвемне белергә чакырган микәнни? Юк, бу кереш сораулар гына, мәсьәлә бөтенләй башка булырга тиеш монда.

— Институттан соң нинди эшкә керешергә уйлыйсыз? Периферияга китәргәме, әллә шәһәрдә калырга исәп тотасызмы?

— Алдан кычкырган күкенең башы авырта, диләр, Йосып Әхмәтҗанович. Институтны бетерәсе бар бит әле.

— Бетерәсез институтны, Кадыйров, кызыл диплом белән бетерәсез сез аны. Аңа минем аз гына да шигем юк. Киләчәккә сезнең планнарыгыз нинди, мине шул кызыксындыра.

— Партиядән чыгарылгач, минем бөтен планнарым чәлпәрәмә килде, киләчәгемә бөтен ышанычым какшады. Гафу итегез, алдагы тормышымны әлегә мин күзаллый алмыйм.

Бу җавабым директорның йөзендәге ихлас елмаюның йогын да калдырмады, сүндерде. Ул миңа җитди текәлеп беравык сүзсез утырды.

— Ә элекке планнарыгыз, сер булмаса, ничек иде?

— Исәбем — Казаннан ерактагы бер районга китеп эшләү иде.

— Фәнни эшкә җигелү, аспирантурага керү турында хыялланмый идегезмени?

— Юк, Йосып Әхмәтҗанович, галим булырга белемем сай минем. Аспирантурага керер өчен киң эрудиция, аналитик фикерли белү кирәк. Минем, галим булмасаң булмассың, әмма кандидат исеме йөртергә бурычлысың, дигән тәгъбиргә ярашасым килми.

Директор шаркылдап көлде.

— Некрасовның зирәк афоризмына ачы перифраз бу. Халык башлы, башлы. Бөек Тукай аны тикмәгә генә, халык әдип ул, шагыйрь ул, димәгән. Миңа калса, әйбәт галим чыгар иде сездән. Кешегә үз фикереңне көчләп тагып булмый, язмышын һәркем үзе хәл итә. Каникулны кайда үткәрергә уйлыйсыз? Казанда гынамы, әллә берәр яры китепме?

Бусы нәрсә тагын, аңа минем укудан буш вакытымны кайда, ничек үткәрүем барыбер түгелмени? Ни өчен чакыруын нигә турыдан-туры әйтми ул, кар астындагы яткылыгына хәйләләп эз яздырган куян сыман, юк-бар сораулар белән чамасыз суза?

— Миңа Васильево ял йортына барырга путевка бирделәр, иртәгә уникe көнгә шунда китәм.

Директорның йөзе яңадан җитдиләнде. Ул, күзләрен миннән алып, өстәлендәге кәгазьләрне бер читкә этәреп куйды. Аннары тавышын кыса төшеп:

— Казаннан берничә көн беркая да китми торыгыз, Кадыйров. Киләсе атнада райком бюросында эшегез караласын хәбәр иттеләр миңа. Ул сезнең файдага хәл ителергә охшый,— диде.

Йөрәккә май кебек яткан бу сүзләрне ишеткәч, тыным кысылып, эчемдә шатлыгым тулып ашты, башын иеп өстәл тартмасыннан нәрсәдер эзли башлаган Йосып Әхмәтҗановичны барып кочаклыйсым килде. Шундый куанычлы хәбәрне ник ул керү белән әйтмәде, сузды икән? Сөенеченнән бу һушыннан язмасын диптер, башта имтиханнарны ничек тапшыруым белән кызыксынды, аннары... Ярар, молодец кеше икән директор, рәхмәт, мең рәхмәт аңа...

— Путевкамны кемгәдер бирергә кирәк алайса. Йосып Әхмәтҗанович, юкка чыкмасын...

— Дөрес әйтәсез, берәр иптәшегезгә бирегез аны. Мин сезгә, райкомда эшегез беткәч, Кырым яки Кавказ санаторийларының берсенә барырга путевка юллармын. Ә хәзер барыгыз, тынычлап ял итегез.— Директор, өстәле артыннан чыгып, миңа кул бирде.— Хушыгыз, Кадыйров. Райком бюросының кайчан буласын хәбәр итәрләр, көтегез. Уңыш телим сезгә.

— Яхшы теләгегез өчен зур рәхмәт, Йосып Әхмәтҗанович. Сау булыгыз.

Институт директоры кабинеты уртасында нигәдер башын иеп, бөрешеп, мескен кыяфәттә басып калды, мин ашыгып чыгып киттем. Үземә куанычлы хәбәр әйткән кешенең нигә шулай капылт кына үзгәрүе турында уйлыйсым килмәде, аның сүзләре иңнәремә, әйтерсең, канатлар үстерде, үз кайгым кайгы иде. Мин партиядә калачакмын! Бу — дөньяда әле хаклык бар, ул исән, яши дигән сүз...

Өстемнән тау төштемени! Институттан тулай торакка кайтканда очраган һәр кеше белән шатлыгымны уртаклашасым, җәелеп сөйләшәсем килде. Соңгы дүрт атна эчендә мин ут йотып, үз-үземне кая куярга, нишләргә белми яшәдем. Урынсызга тора салып мәсхәрәләнүне, түбәнсетелүне кем тыныч кына үткәреп җибәрә алыр икән?..

## 3

22 январьда, якшәмбе көнне, иртән бүлмәдәшем беренче курс студенты Мирза Хөснимәрдәнов белән ашарга әзерләп йөргәндә, ишегебезне шакып та тормастан, бүлмәбезгә Оля атылып килеп керде. Мин аптырап калдым. Оляның йөзе суырылган, күзләре кызарып шешенгән, шәле астыннан таралмаган чәчләре бөселеп чыккан иде. Башымнан ял йортына киткән кеше бит ул, ничек монда, әллә берәр бәхетсезлеккә дучар булганмы югыйсә, дигән шомлы уй узды.

— Син исән, исән! Мин сау-сәламәт килеш күрермен дип өметләнмәгән идем инде сине,— дип, ул һич тартынусыз муеныма сарылып, бит алмаларымны, күзләремне, иреннәремне шашып үбә башлады.

Нишләргә белми катып калдым. Мирза, боларга комачауламыйм диптер, бүлмәдән шым гына чыгып китте.

— Миңа ни булсын, шайтан таягына кырау тияме соң? — дидем мин. Оляны үземнән аерып.

Ул нигәдер каударланып дулкынланган иде, тиз генә тынычлана алмады.

— Сиңа хәвеф-хәтәр булмаганга ышана алмыйм, сиңа көлке, ниндидер шайтан таягын искә аласың. Синең өчен борсаланып төне буе керфек какмый җылап чыктым.

— Нинди хәвеф-хәтәр булырга тиеш иде соң миңа?

— Мин коточкыч төш күрдем. Әле дә акылыма килә алмыйм.— Оля мөлдерәмә яшь тулган күзләрен читкә борды.— Ул төш миемне түнтәрде, җанымны тетрәтте. Төшемдә син төпсез салкын упкыннан, үтә кызганыч тавыш белән инәлеп, миннән ярдәм сорадың. Мин упкын өстендә ары чаптым, бире чаптым, ләкин берни эшли алмадым, син миңа ялварып кап-караңгы упкын төбендә тилмереп калдың. Сиңа ниндидер бәхетсезлек килгәндер, дип, төне буе җаным талкынды.

— Бәхетсезлек килмәде, киресенчә, мин шатлык кичерәм, Оля күгәрченкәй. Хәлемә керүең өчен рәхмәт. Тик ялынны бүлеп монда кайтуың начар, тыныч кына ял итәргә кирәк сиңа. Кичә институт директоры Йосып Әхмәтҗанович мине кабинетына чакырып якын көннәрдә эшемнең райком бюросында каралачагын һәм аның минем өчен куанычлы бетү өмете барлыгын, шуңа күрә миңа соңгы көннәрдә Казаннан беркая да китми торырга кирәклеген әйтте. Әйдә, чишен өстеңне, хәзер аш сосам, ашарбыз.

Оля карышып тормады, өстен чишенеп, ашарга утырды. Үзе һаман:

— Миңа шундый куркыныч төшнең керүе тикмәгә түгел, күңел күрәзә, дип юкка әйтмиләр,— дип сөйләнде.

Мин көлдем.

— Сөйләмә әбиләр сүзен, оныт төшеңне, ташла төрле юк-барга ышануыңны!..

Әмма юкка көлгәнмен. Оляга куркыныч төш кергәндә йөрәк түремә уеласы тирән ярадан кан саркый башларга күп калмаган, мине кулга алу турындагы ордерга республика прокуроры кул куеп, мөһерен салган булган инде.

Менә төшкә чынбарлыкка бернинди бәйләнеше дә булмаган саташу дип кара шуннан соң...

## Өченче бүлек

### 1

1950 елның 23 январенда, дүшәмбе көнне, сәгать кичке унберләр тирәсендә тулай торактагы без торган бүлмәгә мине сорап өч кеше килеп керде. Мин йокы алдыннан юынып керергә туалетка чыгарга җыенган идем, кулларыма сабын, сөлге тоткан килеш, туктап калдым. Керүчелер танышларым да, күргән белгән кешеләрем дә түгел иде.

— Ни йомышыгыз бар? Сезгә кирәк Кадыйров мин ул,— дидем, кызыксынып.

— Без партиянең шәһәр комитетыннан,— диде кętелмәгән кунакларның бүлмә уртасына ук үткән калын гәүдәлесе.— Безгә сезнең берничә ай партия взносы түләмәгәнегезне хәбәр иттеләр. Без менә, эштән соң юл уңаенда шуны ачыкларга кердек. Рәхим итеп партбилетыгызны күрсәтегезче, иптәш Кадыйров.

Икеләнә калдым. Чит-ят кешеләргә ничек партбилет тоттырыйм, взносларым түләнгән, аны миңа килеп түгел, парткомга барып тикшерергә була. Бәладән башаяк, күрсәтим партбилетны.

Таләбен канәгатьләндерергә ашыкмавымны күргән калын гәүдәле бәндә куен кесәсеннән үз партбилетын чыгарып миңа сузды.

— Үзегезгә таныш түгел кешеләргә изге билетыгызны күрсәтергә атлыкмавыгызны хуплыйм. Дөрес эшлисез. Минем фамилиям Михеев. Менә партбилетым, карагыз.

Мин үземә сузылган документны кулыма алып, аны тиз генә карадым да чалбар кесәмнән документларым салынган бумажнигымны чыгардым. Михеев аны кулымнан йолкып диярлек алып озын буйлы, какча гәүдәле иптәшенә бирде. Аннары түш кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарды.

— Мәгез танышыгыз һәм танышуыгызны раслап имзагызны салыгыз. Каләмегез бармы?

— Бар.

Мин үземә тоттырылган кәгазьдә «Кулга алу турында ордер», дигән сүзләрне укыдым. Менә сиңа мә!..

— Әйтегез әле, 58 нче статья нәрсәне аңлата?

Бүлмәгә коридордан кемдер керергә, дип ишекне ачкан иде, кертмәделәр. Михеевның чытык чырайлы, турсайган иренле иптәше минем артымдагы тәрәзә янына барып басты. Төньяк Кореядән килеп укучы студент Ли Ин Санга башка бүлмәгә кереп торырга куштылар.

— Ул статья террорны, шпионажны, КРАны, ягъни контрреволюцион агитацияне аңлата. Курыкмагыз, алар сезгә кагылмыйлар, ордерга ул статья чама белән генә куелган. Без сезне кайбер нәрсәләрне ачыклау өчен иң күбе өч көнгә кулга алабыз. Сезнең урыныгыз кайсы, әйберләрегез кайда, китап-кәгазьләрегезне кайда саклыйсыз?

— Әнә анда.— Мин әйберләремне күрсәтергә тумбочкам янына үтәргә теләдем, янәшәмдә торган Михеев иңемә кулын салды.

— Сез урыныгыздан кузгалмый менә шушында, өстәл янында, тыныч кына утырыгыз. Борчылмагыз, әйберләрегезне иптәшләр, тәртип белән, бутамый-нитми үзләре тикшерерләр.

Михеевның әйберләремне актарган иптәшләре тумбочкамнан, матрацым астыннан гарәп хәрефләре белән басылган иске китапларымны, утыз җиде-утыз сигезенче елларда репрессияләнгән татар һәм рус язучыларының тыелган әсәрләрен берәм-берәм чыгарып өстәлгә тезә бардылар. Кулларына алган һәр китапның эченнән нәрсәдер эзләп битләрен җентекләп актардылар, матрацымны, мендәремне, калын юрганымны вәзенләп каткат капшадылар, карават астындагы чемоданымны ачып, астын-өскә китерделәр, орденнарым һәм медальләрем тагылган хәрби кителемны кулына алган тентүче:

— Бу кем кителе, синекеме? — диде, миңа текәлеп.

— Моңарчы минеке иде, моннан ары кемнеке булыр, белмим,— дидем.

Әйберләремдә чит кешеләрнең әдәпсез казынуларына йөрәгем әрнеде, тик нишлим, түздем.

Тентү ярыйсы ук озак барды. Ахырда ашыкмый гына беркетмә яздылар. Бүлмәдәшләремнән педагогия факультеты студенты чуваш егете Васильев белән тарих факультеты студенты Корнешин шаһитләр сыйфатында беркетмәгә имзаларын салдылар.

Михеев эшләре төгәлләнгәч миңа:

— Киенегез, үзегез белән аласы нәрсәләрегезне алыгыз да, китәбез,— диде.

— Өч көннән мин монда кайтасы ич, берни дә алмыйм,— дидем.

— Алмашка чиста күлмәк-штаннарыңны, әнә теге калын свитерыңны һәм булган кадәр азык-төлегеңне ал.

— Өч көнгә миңа берни дә кирәкми,— дип үҗәтләнеп каршы килдем.

— Киреләнмә, бәлки кирәгер, ал.

— Чемоданга үзегез кирәк санаган нәрсәләрне төягез алайса.

Киткәндә Михеев бүлмәдәшләремә:

— Егетләр, болай килешәбез, телегез авызыгызга сыйсын, бирегә берни дә булмады һәм сез бернәрсә дә күрмәдегез. Аңладыгызмы мине? — диде.

— Аңладык, аңладык,— дип ашыгып җавап кайтарды аңа егетләр.

Гаҗәп, нигә бүлмәбездә тентү булганны, минем кулга алынуымны бирәү дә белергә тиеш түгел икән?..

Бүлмәдән чыкканда миңа чемоданымны һәм бер бәйләм китапларымны тоттырдылар. Калган китап-кәгазьләремнең ике төргәген Михеевның иптәшләре күтәрде.

Тулай тораktан чыгып барганда титан янында кайнашкан швейцар апа кызыксынып:

— Ирек, төн ката кая барасың, ялга китешеңме әллә? — диде.

Михеев аңа:

— Авылга әти-әниләре янына кайта, без озатабыз аны,— дип минем өчен җавап кайтарды.

— Ни, синең әти-әниләрең җук бугай бит, Ирек? — диде апа, аптырап.

Аңа минем, кышкы каникулларда да, җәйге каникулларда да ник бер кая да бармыйсың, дип кызыксынгач, үзем турында кайбер нәрсәләрне сөйләгәнем бар иде.

— Бар, ник булмасын, дөньяда ата-анасыз кеше юк ул,— диде Михеев, ишектән чыкканда, артка борылып.

Мин исә, әйе, чынлап та әти белән әни янына барам бит, дип уйладым ачынып.

## 2

Тулай торак капка төбендә безне җиңел машина көтеп торган, чемоданымны, китап-кәгазь бәйләмнәрен аның багажнигына салгач, машинаның арткы урынында Михеевның юлдашлары, мине уртада калдырып, икесе ике ягыма утырдылар. Михеев үзе шофер янәшәсенә урнашты. Машина капылт кына алга талпынып, кузгалып китте. Шулчак башыма, ул мине кая илтер, дигән тәшвишле уй килде. Кая булсын, Черек күл буенадыр... Күз алдымнан әти белән әни уздылар. Ниһаять, мине дә алар сукмагына аяк бастыралар була... Әмма мин алар утырган төрмәгә озакка түгел, берничә көнгә генә, нәрсәләрнедер ачыклаганчы гына барам. Беләсе иде, нәрсәләрне ачыкларга булдылар икән? Галимҗан Ибраһимовка кагылган урынсыз кызыксынуым өчен җәза алдым, бер үк нәрсәне кат-кат кузгатмаслар. Ордерда, 58 нче статьяга нигезләп кулга алына, диелгән. Михеев аны КРАны, ягъни контрреволюцион агитацияне белдерә, дип аңлатты. Кайда, кемнәр белән һәм нинди контрреволюцион агитация алып бардым мин?..

Уйларым, җай гына тәгәрәгән машина шып туктагач, киселде. Әйе, без нәкъ Татарстан дәүләт иминлеге министрлыгы урнашкан бина алдына килгәнбез. Күңелемдә шушы бина алдында ялгызым калган көн яңарды һәм йөрәгем әрнеп тырналгандай булды. Бәлки мине монда әтием һәм әнием белән күрештерергә алып килгәннәрдер?..

Бина эченә кергәч, борылмалы баскычтан башта икеме, өчме кат өскә мендек тә шундук яңадан аска төштек һкм ниндидер тын коридорны үткәч, мине озынча бер бүлмәгә кертеп, кулга алучыларым каядыр киттеләр. Кабинетта яңагы яулык белән бәйләнгән бер капитан нәрсәдер язып утыра иде. Михеев, аның колагына гына пышылдап нәрсәдер әйтте дә, ашыгып чыгып китте. Ул чыккач, капитан урыныннан торып тәмәке кабызды һәм миңа акаеп карап, йөрәксенеп:

— Тәк, тәк... Хөкүмәтебезне яманлап тормышыбызга яла яккан, социалистик Ватаныбызга пычрак аткан өчен сиңа күпме түләделәр, хәсис? — диде.

Бу дорфа, мәсхәрәле сорау миңа ток суккандай тәэсир итте. Капитанның барып якасына ябышасым килде. Әмма тыелып калдым.

— Сез кем беләндер бутыйсыз мине...

— Бутамыйм, кемлегең чыраеңа язылган синең. Автобиографияңне сөйлә әле, бутыйммы, юкмы, күрербез.

— Мин кызыл командир улы. Коммунист. Фронтовик. Хәзер студент. Сугышта фашистларны тукмаштым.

— Һәммә сүзең ялган! Фашистларны тукмаштың, имеш. Син үзең фашист бит!..

— Нәрсә?!.— Мин урынымнан сикереп торып урындыгыма ябыштым.— Замат арасында гафу үтен, юкса күрсәтәм мин сиңа фашистны, адәм актыгы!..

Капитан билендәге ялтыр кобурасыннан пистолетын тартып чыгарды. Аның сирәк кашлары бер-берләренә тоташып җыерылды, йөзе бозылып ямьсезләнде. Эш нәрсә белән беткән булыр иде, белмим, шул чак кабинетка Михеев килеп керде.

— Сәлимов, үзеңне кулга ал, пистолетыңны кобураңа тык, б... а тимә, сасысы чыгар, тынычлан.

— Чыкмас, дөмектерәм мин бу зинадан туган фашист нәҗесен!

— Җүләрләнмә. Афонин күк трибуналга эләгәсең килмәсә, пистолетыңны сал да урынына, тынычлан. Аны тиешле җиргә тапшыргач, мин синең янга керермен, көт.



### 3

Михеев белән без, яңагы яулык белән бәйләнгән кыдрач капитанны ялгызын калдырып, яңадан коридор-лабиринтлардан, йомшак тар келәм җәелгән борылмалы баскычлардан үтеп аскы катка, бердәнбер тәрәзәсе калын тимер рәшәткә белән ныгытылган, түрендә өстенә «Чит кешеләргә керү тыела» сүзләре язылган һәм эт башы чамалы кара йозак белән бикләнгән ишектән бер читтә зур килбәтсез язу өстәле һәм дүртме, бишме урындык торган, стеналары күңел кайтаргыч куе яшел төскә буялган ярыйсы ук зур бүлмәгә төштек. Анда ике сержант мавыгып карта уйныйлар иде, башта бүлмәләрендә үзләре генә түгеллекләрен абайламадылар. Михеев тамак кырды, сержантлар аңа күтәрелеп карап, урыннарыннан сикереп тордылар һәм, карталарын тиз генә өстәл тартмасына сибереп төшереп, үрә каттылар.

— Здравье желаем, товарищ капитан!

— Вольно, вольно. Бу бәндәне миннән кабул итеп алуыгызны раслап менә бу кәгазьгә имзагызны салыгыз да, сезгә һәрвакыттагыча артык комачауламам, егетләр, юлымда булырмын.

Сержантларның түшенә Җиңү медале таккан өлкәнрәге нинди дер кәгазьгә мышный-мышный кул куйгач, Михеев аларга хәерле төн теләп чыгып китте. Чыкканда ул минем якка хәтта күз дә салмады.

Калын иренле яшьрәк сержант миңа чишенергә кушты. Пальтомны, бүрегемне салып култык астыма кыстырдым.

— Нәрсә көтәсең, мунча кергәндәге шикелле шәрә калганчы чишен. Аяк өсте йоклама, җәһәтрәк кыймылда! — дип ашыктырды сержант.

— Тәнем чиста, өченче көн генә мунча кердем, юынып тормасам да була,— дидем мин.

— Монда син юынган мунча түгел, сине без үзебез юындырырбыз, чишен тизрәк, ачуны чыгарма.

Бу ике кәбестә кучәне мине шаяртмакчы, шәрә калдырып үзләренә ниндидер кызык ясамакчы булалар, ахры, дип шикләнеп, теләр-теләмәс кенә чишендем.

Түшенә Җиңү медале таккан сержант киемнәремне өстәлләренә салып, бүлмәнең сул як стенасындагы ниндидер тар гына ишекне барып ачты.

— Кил, кер бокска.

Сержантның бокс дигәне киңлеге күп булса алтмыш-алтмыш биш сантиметрлар, биеклеге метр ярым чамасындагы кысан тартма икән. Мин аңа ничек кирәк алай кереп урнашкач, сержант тартма ишеген тыш яктан ябып шалтыратып бикләп куйды. Курач һәм тар бокс эчендә утырып та,

теләгәнчә басып торырлык та түгел иде, мин анда, уңайсыз җыерылып, алда тагын нәрсә буласын көтә башладым. Вакыт бөтенләй туктады шикелле, нервлар киеренкелегеннән колакларым томаланды, башым шаулый башлады, әчемә погонлы кәбестә күчәннәре шушында шәрә килеш төне буе утыртмакчыларымы икән әллә, дип пошаман кердә. Кысан тартмадан мин сержантларның үзара быдыр-быдыр нәрсәдер сөйләшкәннәрен, ниндидер материяне шытырдатып ертуларын, таш идәнгә нәрсәләрнеңдер ара-тирә чыкылдап төшүләрен нәрсәгә юрарга белми борчылып тыңладым.

Ниһаять, бокс ишеге ачылды, миңа чыгарга куштылар. Тезләремне уңайсыз бөгеп торудан аякларым оеп берни тоймас булганга, тар ишектән чыгуга лап итеп идәнгә аудым.

— Ипләбрәк кыйлан,— диде калын иренле сержант,—ашыкма, поездга соңга калмыйсың. Әнә киемнәрең, киен.

Кальсонымны киеп төймәләмәкче булдым, төймәләрен тапмадым, алардан җилләр искән иде. Чалбарым да төймәләреннән, каптырмаларыннан мәхрүм калган, пинҗәкнең дә, пальтоның да, башка нәрсәләрнең дә төймә-каптырмалары калмаган булып чыкты. Өстәвенә, пинҗәгем белән пальтомның иңбашларын кубарганнар, якаларын, кайтармаларын сүткәннәр. Кыскасы, барлык киемнәрем, таланып, кияргә яраксыз хәлгә китерелгән. Үртәлеп бәгырем телгәләнүдән күзләремә яшь тыгылды.

— Бу киемнәрдә ни ачуыгыз бар иде, ник аларны утиль чүпрәкләренә әверелдердегез? Мин монда иң күбе өч көнгә килгән кеше бит, оят түгелме сезгә? — дидем, еларга җитешеп.

— Әйттең сүз,— дип шаркылдады калын иренле сержант,— бу төрмәгә эләккән кеше ун елсыз иреккә чыкмый. Монда керү ишеге киң, чыгу ишеге кыл гына сыярлык. Аннан кеше түгел, чебен дә үтәлми. Әйдә, тоткарлама безне, киен дә камерага озатырбыз, инде таң атар вакыт җитә.

— Ничек киеним, киемнәремнең киярлеге юк, аларның юнен-башын калдырмагансыз бит.

— Тап җаен, без сиңа бер ничек тә булыша алмыйбыз.

— Мин бу эшегезне болай калдырмаячакмын, өстегездән жалу бирәчәкмен.

Сержантлар эчләре катып көлделәр.

— Безне кемгә әләкләмәкче буласың, зәңки? Кем сине тыңлап ярдәм кулы сузар дисең монда?..

Ярар, сүз куертуның файдасызлыгын аңлатырлык, күңелгә үтәрлек җавап кайтарды сержант, рәхмәт аңа. Авызымны тәмсезләп бүтән бер сүз дә әйтмим бу ике аяклы этләргә, тәкъдиремдә язганы булыр...

Ничек кирәк алай киендем. Миңа урын-җир әйберләре, алюмин табак, шундый ук кашык һәм бәләкәй кружка бирделәр. Аннары медальле сержант «Чит кешеләргә керергә ярамый» дигән язулы ишекнең йозагын ачты.

— Әйдә, кер, төкле аягың белән!..

Кызык, монда мин чит түгел, үз кеше саналам булып чыга. Кемнәр чит кеше исәпләнәләр, ишектәге язу кемнәрнең юлын кисәргә кадакланган, аңлашылмый...

## Дүртенче бүлек

### 1

Калын иренле сержант мине тар төрмә коридорына алып керде. Коридорның сул ягында ишекләр тезелгән. Һәр ишектә зур йозак асылынып тора. Уң якта тоташ стена. Аяк астында йомшак тар палас юл.

Кемнәр утыра икән бу дәү йозаклар белән бикләнгән серле, кырыс ишекләр артында?

Танышларымнан кемнеңдер, төрмәдә уголовниклар камераларына беренче кат атлап кергән кешенең аяк астына йонын әйләндереп тун таш-

лыйлар, керүче аңа басып аякларын тун йонына ышкып сөртсә, ул кешене уркалар үз итәләр, тунны әйләнеп үтсә, аңа рәхим-шәфкать күрсәтмиләр, көне-төне җәберлиләр, имеш, дип кайчандыр сөйләгәне хәтеремдә яңарды.

— Зинһар мине, уголовниклар, рецидивистлар янына кертә күрмәгез,— дидем сержантка.

— Нинди уголовниклар, нинди рецидивистлар белән саташасың, акылыңа кил. Алар юк бездә һәм булмыйлар да. Моның эчке төрмә — халык дошманнары төрмәсе икәнен борыныңа киертлә.

Менә инде монда кемнәрнең чит, кемнәрнең үз кешеләр икәнлеге аңлашылды.

Бормалы озын коридорны үтеп, төрмәнең икенче катына күтәрелгәч, калын иренле сержант андагы утыз биш-кырык яшьләр тирәсендәге яньчек борынлы надзиратель хатынга, бер ишек алдында туктап, аны ачарга кушты һәм камерага кергәч миңа:

— Үзеңне өеңдәге кебек хис ит, әмма кунакта икәнеңне онытма, менә сиңа карават, йокла,— дип стенага беркетелеп, йозак белән бикләп куелган, һәр тишегенә баш сыярлык челтәрле котсыз металл рамны ачып, идәнгә бастырды.

Старшина карават дип аталган тимер корамага мин өркеп карадым. Аңа ничек ятасың, кабыргаларың имгәнүне көт тә тор.

— Мин идәнгә генә ятармын,— дидем кулымдагы урын-җир әйберләрен аерылмаслык итеп стенага беркетелгән кечкенә генә өстәлгә куеп.

— Бездә идәнгә ятарга ярамый.

— Ярамаса ярамас, әмма мин бу караватка ятмыйм, үзегез күрәсез, аңа ятарлык түгел.

— Ятмыйсыз?

— Ятмыйм.

Сержант чыгып китте, ишек тыштан бикләнде. Мин камера эченә күз йөртә башладым. Түр стенада буй җитмәс биеклектә тимер рәшәткәле тәрәзә. Тәрәзә турында аста нечкә тимерчыбыктан үрелгән, сирәк челтәр белән капланган җылыткыч батареялар. Сулда, идәннән бер метр чамасы биеклектә, стенага кузгатылмаслык итеп беркетелгән уртакул тумбочка өсте кадәр өстәлчек, аның янәшәсендә шулай ук стенага кубарылмаслык итеп ныгытылган тар утыргыч. Утыргычта зур алюмин чәйнек тора. Өстәл турысында, стенада пыялалы рамда, эчке тәртип кагыйдәләре. Уң якта карават корамасы, ишек катында авыл хатыннарының күмер чүлмәкләренә охшаган өсте капкачлы калай савыт утыра. Ишек өстендәге тирән уемтыкта эре челтәр астында кимендә йөз илле шәмле электр лампасы келпи. Аның яктысы йомык күзгә дә сизелерлек. Камера кысан, иңе ике ярым, буе дүрт метр чамасы гына.

Башымнан, монда өч көндәге бертөрлелектән, эч пошудан, җаның кыйналудан җык күреп акылыңа зыян килүе мөмкин икән дигән хафалы уй узды. Өстәл каршына барып эчке тәртип кагыйдәләре белән танышырга керештем. Күзләремә ышанмадым, монда бары тик суларга гына ярый, бүтән бөтен нәрсәләр тыела икән. Җырлама, сызгырма, кычкырып сөйләшмә, тәрәзәгә менмә, стеналарга шакыма, ишеккә якын барма, почмакка посма, надзирательләргә сүз кушма, үзеңә кисәтү ясаганда әрепләшмә һәм башкалар, һәм башкалар.

Авыр ыңгырашып ишек ачылды. Сержант миңа ятарга топчан кертте. Молодец, калын ирен! Хәзер инде караватт корамасына топчанны салып, ятарга була.

Кичә Оля белән тулай торак кызыл почмагында төне буе сөйләшеп утырып күз дә йоммаган идем, йокларга кирәк, дип урын җәеп ятуым гына булды, ишек артыннан надзиратель хатынның ачулы тавышы ишетелде:

— Тор, ишеккә карап ят.

Тәрәзәгә карап яттым ни дә, ишеккә карап яттым ни, барыбер түгелме икәнни аңа?

Борылып, башымны электр яктысыннан юрган астына яшереп яттым. Надзиратель хатын тагын ишек шакыды.

— Башыңны каплама, ач!
— Ничек ятсам да барыбер түгелмени сезгә?
— Түгел, глазоктан мин синең башыңны күрергә тиеш.
— Миңа ут комачаулый бит, бәлки сүндерерсез?..
— Утны сүндерергә ярамый, стенага борылып ят.
Борылып яттым. Ишек өстендәге ул Газраил күзеннән борылып ятып кына арынып булмый икән шул. Нинди гөнаһларым өчен чиләнәм, җәфаланам мин? Бу ләгънәт төшкән лапма, гүя, миемне кайната, рәтле-башлы уйларга бирми.
Йокыга әле киткән генә идем бугай, алагаем каты итеп ишек шакыдылар:
— Подъем! Тор, туалетка чыгарга әзерлән.
Тордым. Тәнемне таяклар белән каезлаганнармени, сулгып авырта, башыма, әйтерсең, кургашын койганнар, күзләрем йомыла, алдымда әлҗемөлҗе утлар уйный сыман. Ни булган миңа, нәрсә җанны талкый, баса, миңгерәүли? Эзләнеп, як-ягыма карандым. Лампа, ишек өстендәге көчле электр лампасы җанга тия, рәнҗетә, мәсхәрәли, түбәнсетә түгелме? Әйе, камерада ул артык, монда аның кирәге юк. Әнә ул дәҗҗал кояшы үз-үзеннән үтә канәгать төстә келпи. Әгәр ватсам аны? Ләкин ничек ватасың? Ул югарыда тимер челтәр артында, ә минем кул астымда аны дөмектерерлек берни юк. Шуны белептәр, ул, күзләрне камаштырып, тантана итә.
Ишек ачылды. Бусагадан яньчек борынлы надзиратель хатынның ачулы тавышы ишетелде:
— Ник киенмәдең, кемнеңдер кереп киендергәнен көттеңме әллә? Туалетка чыгарга әзерлән, диелде ич сиңа. Әйдә, шушы килеш бар алайса.
Мин, төймәләреннән мәхрүм калган кольцонымны кулларым белән тотып, ишектән коридорга чыктым.
— Борыл, парашаңны ал, калдырма. Аны әллә миннән илттермәкче буласыңмы?
— Нәрсә ул параша? Мин белмим бит.
— Һәй, аңгыра сарык, әнә бит почмакта тора, ал да шуны, атла җәтрәк. Монда бер син генә түгел, бүтән косыкларны да чыгарасы бар. Әйдә, атла, торма катып.
Кулларым белән парашаның тоткаларына ябышуым булды, кольцоным сыерылып тубыкларыма төште. Инде нишләргә? Парашаны алсам, кольцоным төшә, кольцоныма тотынсам, парашаны күтәрә алмыйм.
— Беләсезме, мин туалетка бармыйм.
— Ничек бармыйсың? Син монда үз уставың белән килдеңмени? Сиңа карават ярамый, ут комачаулый, инде туалетка барудан баш тартасың. Ярар, калсын парашаң, аны кич түгәрсең. Хәзер болай гына бар. Сөлгең кая? Моңарчы ничек яшәгәнсең син, сантый, гаҗәп. Күренә, шушы яшеңә житкәнче атаң-анаң җилкәсендә утыруың, пакыч. Әйдә, тизрәк кыймылда!..
Яньчек борын миңа ияреп туалетка да керде. Ни уйларга белмәдем, ир кеше белән бергә ирләр туалетына керергә ничек тартынмый ул?
«Җан сакчым» ишек борысына сөялеп күзәтеп торды, мин, аннан-моннан гына юынып, сөртенә башладым. Миңа кешечә юынырга кольцонымның тотрыксызлыгы һәм җан көеге надзиратель комачаулады.
Камерага кайткач күп тә үтмәде, ишектә кинотеатр кассаларының күрәкарау тәрәзәләре зурлыгындагы тишек пәйда булды. Аннан:
— Ипи ал, чәйнегеңне бир,— диде кемдер.
Мин, стенага беркетелгән утыргычтагы чәйнекне алып, тишеккә суздым. Аның эчендә сумы, бүтән нәрсәме бар иде, карамадым. Шундук миңа ипи, бераздан чәйнегемне кире бирделәр.
— Шикәр комына савыт бир.
Нинди савыт бирергә, дип як-ягыма карандым, күземә алюмин табак чалынды. Аны кулыма алып, тиз генә ишектәге тишеккә тыктым.
— Булды, ал табагыңны. Приятный аппетит!

Алдым, табак төбенә бер чәй кашыгы чамасы шикәр комы салынган иде.

Ишектәге тишек шап итеп ябылды.

Минем ашыйсым килми иде әле, кольцоным белән чалбарымны тубыкларыма сыерылып төшмәслек хәлгә ничек китеру турында баш ватарга керештем. Өске бөрмәләрен нәрсә белән тишәргә аларның? Тукта, надзирательдән пычак сорыйм әле.

Ишекне шакыдым.

— Ни булды? Ник шакыйсың?

— Пычак бирегез әле.

— Нәрсә?!. Аңламадым, нәрсә әйттең?

— Пычак бирегез дим.

— Пычак? Менә сиңа пычак!..— Янчек борынлы надзиратель хатын ишектәге бүре күзеннән миңа «кәҗә тоягы» күрсәтте.— Син суеласы, миңа җавап бирәсе, тот капчыгың!..

— Суелырга түгел, кольцон белән чалбар бөрмәләрен тишәргә кирәк миңа пычак.

— Җитте, карцерга эләгәсең килмәсә, бүтән тының чыкмасын!

Кольцоным бөрмәсен дә, чалбарым бөрмәсен дә алюмин кашык сабы белән көчкә тишеп, аларны билемнән төшмәс хәлгә китердем. Сержантлар аларны төймәләрен кискәндә үк тишсәләр ни булган инде, тишмәделәр, үзең җаен тап, дип авыз җырдылар. Таш йөрәкле, гамьсез, кешелексез, туң җанлы бәндәләрне кайдан җыйганнар монда?..

## 2

Сәгать иртәнге уннар тирәсендә камера ишеге авыру кеше кебек ыңгырашып ачылды һәм бусага төбендә балыкныкы шикелле калку күзле, бөтен битен кызыл бетчәләр баскан утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге старшина пәйда булды. Ул, тиз генә камера эченә атлап, уң кулының күрсәткеч бармагын пистолет сыман миңа төбәде.

— Фамилияң?

— Кадыйров.

— Исемең?

Анысын да әйттем.

— Чык.

Камера ишеге ямьсез ыңгырашып ябыла калды, старшина терсәкләремне куллары белән шытырдатып кысып, мине коридор буйлап каядыр алып китте.

— Мине чыгаралармы әллә? — дидем старшинага бераз баргач.

— Яп пилмән савытыңны, сүз катма! — дип җикерде ул, ярсып.— Колагыңа киртләп куй, монда эләккән кеше тиз генә чыкмый.

— Гаебе булмаса дамы?

— Телең тый! Кисәтәм, тагын да лыгырдасаң, тешләреңне коям мин синең!..

— Орынып кара!..

Сүзләремне әйтергә генә өлгердем, балык күз, терсәкләремне ычкындырып, кулларын кушйодрыклап ипи шүрлегемә кундырды. Мин, тигезлегемне югалтып, башым белән коридор стенасына барып төртелдем.

— Кабахәт, башлыкларыңа әйтеп бүген үк кудырам сине моннан…

Старшина йодрыкларын яңадан төйнәп, миңа тагын сугарга итте, мин, аның сакланмавыннан файдаланып, күз ачып йомганчы аяк астына кундырдым. Балык күз, башын артка кайшалтып, авыр капчык сыман сыртына ауды. Шуннан соң мин билемнән түбәнгә шуышкан каптырма-төймәләре таланган чалбарымны күтәреп рәтләргә тотындым.

Старшина, башын әле бер, әле икенче якка боргалап, авырлык белән торды.

— Бу сугуыңны йөзе белән кайтарырмын мин сиңа, фашист!

— Син үзең фашист, кабәхәт. Мин — коммунист!.. Кулыңны миңа тагын күтәреп кара, эһ тә итми дөмектерермен. Мин — боксер. Синең ише калай әтәчләрне замат юашландырам.

— Телең тый, яп авызың, сволочь!

— Мәсхәрәләмә, син үзең сволочь.

Бетчәле битне, мин боксер, диюем шөлләтте бугай, кулын бүтән эшкә җикмәде.

Ниһаять, ул мине борылмалы баскыч һәм коридорлар аша Республика дәүләт иминлеге министрлыгы бинасының икенче катына, тәрәзәләре Черек күл бакчасына караган, пөхтә җиһазланган зур һәм якты кабинетка алып керде.

— Китердем, иптәш полковник.

— Күрәм, рәхмәт.

Кабинетка кергәч, күзләремә беренче булып өсте кыйммәтле нәзек яшел постау белән тышланган иске стильдәге ике тумбалы зур өстәл һәм аның артында утырган калын бәдәнле, ямьшәйгән иренле, танавы уңган сирень чәчәге төсендәге полковник ташланды. Мин аңа артымнан ишек ябылу белән:

— Иптәш полковник, нигә мине монда фашист дип мәсхәрәлиләр, нигә миңа кул күтәрәләр, нинди гаебем бар? Мин гестапода түгел, совет учреждениесендәдер бит? — дидем.

— Кем мәсхәрәли сине, кем кул күтәрә? — Полковник бу сүзләрне «р»авазын «г»лаштырып әйтте һәм урыныннан торып өстәл артыннан чыкты.— Әйт әле, гестаподагы тәртипләрне син каян беләсең?

— Киноларда күреп, газета-журналлардан, китаплардан укып беләм. Менә ул мине фашист дип мәсхәрәләде, яңагыма да менем төште.— Мин янымда гамьсез генә басып торган балык күзле старшинага күрсәттем.

— Аның сине мәсхәрәләвен кем ишетте, сукканын кем күрде?

— Беркем дә ишетмәде, күрмәде.

Полковник төссез күзләрен старшинага төбәде.

— Син мәсхәрәләдеңме аны, суктыңмы аңа?

— Мәсхәрәләмәдем дә, сукмадым да, иптәш полковник. Ул миңа нахак бәла яга.

— Иптәш полковник, ышанмагыз аңа, дөресен әйтергә курка ул.

— Мин безнең күптәннән сыналган работникка яла ягучыга иптәш түгел. Синең иптәшләрең мари урманнарында төннәрен Айга карап улый, шулар сиңа иптәш!

Мин ни уйларга да белмәдем. Бу полковник кем, кая килеп эләктем мин?

— Зинһар әйтегез, минем нинди гаебем бар, нигә кулга алындым?

Полковник, уң кашын маңгаена сикертеп, миңа текәлде.

— Ә үзең ничек уйлыйсың?

— Мин үземне төрмәгә ябарлык нindидер гаебем барын белмим.

— Старшина, озат аны камерасына, башта нигә кулга алынганын уйласын.

Балык күз мине җилтерәтеп камерама алып төште.

Күп булса ун-унбиш минут үткәндер, камера ишеге тагын ыңгырашып ачылды һәм балык күзле шул ук старшина бусаганы атлап уң кулының күрсәткеч бармагын пистолет сыман итеп миңа төбәде.

— Фамилияң?..

Шәмәхә танаулы полковник янына ул мине яңадан алып менде. Бусында полковник өстәл артына утырмаган, Черек күлгә караган зур тәрәзә янында басып тора иде. Бераздан борылып миңа:

— Йә, әйт, ни өчен кулга алдык без сине? — диде.

— Мин үземнең кулга алып төрмәгә ябарлык гаебем барын белмим.

— Сине нахакка утырттыкмыни?

— Шулай килеп чыга.

— Бар, нинди гаепләрең барын камераңда әйбәтләп уйла...

Бу көнне мине полковник янына тугызмы, унмы тапкыр алып менделәр, чутын югалттым. Һәр менүемдә ул:

— Без сине ни өчен кулга алдык? — дип бер үк сорауны кабатлады. Министрлыктагы бу вөҗдансыз түрәнең (соңыннан мин аның Татарстан дәүләт иминлеге министры урынбасары икәнен белдем) шундый тупас уеннан үзенә ләззәт эзләве чыгырымнан чыгарды.

— Без сине ни өчен кулга алдык?

— Мәче үзе тоткан тычкан белән аны ашар алдыннан уйнаган шикелле уйнар өчен.

— Нәрсә? Нәрсә?..— Полковник кыска аякларын идәндәге калын паласка вак-вак басып каршыма килде.— Нәрсә дидең тагын кабатла әле!..

— Мин тычкан, сез мәче түгел, мине мыскылларга хакыгыз юк!..

Полковникның күзләре акайды, яңак мускуллары биеп алды.

— Син үзеңнең кем белән сөйләшкәнеңне беләсеңме, хәсис!

— Инквизитор белән сөйләшәм.

Полковникның йодрыгы белән күкрәк авызыма төртүен мин абайламый калдым, кинәт тыным капланып бөгелеп төштем.

— Алып чыгыгыз моннан бу үләксәне!..

Коридордан ике солдат кереп, мине ике култыгымнан әләктерделәр.

Камерама төшкәч тә бик озак тынычлана алмадым. Чыннан да нигә кулга алдылар мине? Урлашмадым, кеше үтермәдем, Ватанга хыянәт итмәдем, берәүне дә кыерсытмадым. Нигә иректән мәхрүм ителдем, нәрсә өчен монда кимсетеләм, түбәнсетеләм, мәсхәрәләнәм? Балык күзле старшина белән шәмәхә танаулы полковникның миңа кул күтәрергә ни хаклары бар?.. Катыйль Ежовның кемлеге фаш ителүгә ун ел бит инде, аның иярченнәре монда ничек сакланганнар, алар өчен совет законнары тик кәгазьдә генә микәнни?..

## Бишенче бүлек

### I

Старшина белән полковникның йодрыкларын татыгач, мин төрмәдәге тәртипләргә һәм анда эшләүче кешеләргә шикләнеп карый башладым. Полковник беренче көнне тугызмы, унмы тапкыр чакыртып ни өчен кулга алынуымны әйттерә алмагач, инде мине атна буена борчучы юк, онытты-лар. Михеевның тулай торакта, сине кайбер нәрсәләрне ачыклау өчен иң күбе өч көнгә кулга алабыз, дип тынычландыруы ялган булды, күрәсең.

Тоткынлыкта ниләр генә уйламыйсың, башка нәрсәләр генә килми!.. Хәтердә, узганда әллә кайчан булып онытылган, ирекгә яңадан гамьгә дә кермәстәй сәхифәләр яңара, китаплардан укылган яки кайчандыр ишеткән гыйбрәтле хәлләр кабат күз алдыннан үтә. Кичә мин һич уйламаганда Леонардо да Винчиның бер әкиятен исемә төшердем. Ул әкияттә купшы чыпчыкның читлеккә эләккән балаларын тоткынлык газабыннан коткару өчен авызларына агулы үлән салып үтерүе сурәтләнә. Купшы чыпчык балаларын чиксез ярата, әмма аларның читлектә интегеп тереклек итүләреннән үлүләрен артыграк күрә. Купшылның бу мәрхәмәтсезлеге, таш йөрәклелегеме? Юк, бу — аның олы җанлылыгы. Мәшһүр акыл иясе Леонардо да Винчиның әлеге әкиятеннән җан иясе читлектә — тоткынлыкта газап чигәргә тиеш түгел, ирекле булырга, теләгән җирендә бәйсез яшәргә тиеш, дигән фикер аңлашыла.

Менә тагын:

Кояш чыга да бата,
Төрмәм минем караңгы...

— җыры.

Бер-бер артлы тезелеп килгән бу алты сүздә никадәр сагыш, өметсезлек, газаплы тирән кичереш! Тоткынлыкны үзе татымаган кеше бу җыр-

ның чын асылына, тирән мәгънәсенә төшенә аламы икән? Юктыр. Ачның хәлен тук белми, дип юкка әйтмәгәннәр. Ирекле кеше белән төрмәдәге тоткын иректәге бәйсез кош белән читлектәге кош шикелле. Әти белән әни кулга алынгач та тоткынлыкның берни белән дә чагыштыргысыз фаҗига икәне миңа үзем халык дошманнарының балалары өчен оештырылган колониягә эләккәч кенә барып җитте. Бала чагымда мәктәптә А. С. Пушкинның «Мәхбүс» шигырен ятлаганда да мин аның эчтәлегенә бөтенләй игътибар итмәгән булганмын. Ә ул шигырь искиткеч тирән мәгънәле бит!

Әйтерсең, ул юлларны бөек шагыйрь мәхбүс хәлен үзе кичергәндә язган. Хәер, аның лицейны тәмамлап чыкканнан соңгы тормышының яртысы диярлек сөргендә үткән бит, ул үзе теләгәнчә яши алмаган, жандармнар күзәтүе астында нәкъ читлектәге кош хәлендә булган, туктаусыз эзәрлекләнгән...

Берәү дә үзенең киләчәгендә күңелсезлекләр көтми, кемгә дә алдагы көннәре якты һәм матур булыр төсле тоела. Күпчелек очракта кеше алдана, аның көткәненең уннан бере дә акланмый.

Кичә, бөтенләй уйламаганда, мин үземне төшемдә чегән хатыныннан бәхет юратам итеп күрдем. Имеш, карт чегән хатыны уң кулымның бармакларыннан тоткан да, учыма карап ашыга-ашыга такылдый:

— Һай, бәхетсез, бик бәхетсез икән син, Ирек, (каян исемемне белгән, гаҗәп). Менә аркылыга-буйга кисешкән уч сызыкларың әтиең белән әниеңнең күптән тоткынлыкта икәнен сөйлиләр. Озакламый син алар белән очрашырсың, алар сине танымаслар, син аларны танымассың. Сине озак тоткынлык көтә. Ләкин өметеңне өзмә, яшәвеңә сөен, кордашларың күбесе яу кырында мәңгегә ятып калды. Алар синең бүгенге хәлеңнән мең өлеш кыенрак хәлләргә дә шатланып риза булырлар иде. Син яшисең. Яшәү — тоткынлыкта да чиксез бәхет ул...

Ялгыз камерада вакыт ташбака адымнары белән үтә. Дүрт стена эчендә үз-үзеңә урын таба алмаудан берсеннән-берсе тәшвишле уйлар килә башка. Миңа инде кысан камерамның һәр карышы таныш. Кулга алынуымның икенче көнендә үк аның стеналарында үземә кадәр җәфаланган кешеләрнең нинди дә булса истәлекләре калмаганмы дип эзләдем. Миңа бу камерада әти яки әни утырганнардыр, анда аларның ниндидер ядкарьләре калгандыр кебек иде, әмма стеналарда сүзләр генә түгел, чак сизелерлек тамгалар да тапмадым. Баштагы көннәрдә, авыр уйлардан арынып тору нияте белән, камерада утызар, кырыгар мең адым ясый идем. Инде санамыйм, борчулы уйлар дәрьясында чайкалуны артыграк күрәм. Бүген әтигә күңелемнән генә хат язарга, үткәндәге тормышым һәм үземә кагылышлы башка нәрсәләр турында сөйләргә булдым. Хәзер минем өчен дөньяда иң якын кеше — әти. Аны да, минем кебек үк, нахакка утырттылар бит. Әтинең кулга алынганда әйткән: «Партия каршында да, халкыбыз каршында да, синең алдыңда да намусым пакь, улым»,— дигәне әле дә колак төбемдә. Ул мине аңлар, аңламый калмас...

## 2

Әти, син мине һаман да Бәештә калган үсмер малай итеп күз алдыңа китерә торгансыңдыр. Мин инде ир уртасы булып килəм, Бәештән күптән киттем. 1937 елның ноябрь ае азагында әни белән без сине эзләп Казанга килдек. Миңа анда әни белән дә, гамьсез бала чагым белән дә аерылышырга туры килде. Әнине дә кулга алдылар. Сиңа да, аңа да нинди гаеп якканнардыр, белмим. Мин чит-ят шәһәрдә, үземә бөтенләй таныш түгел кешеләр арасында бербашым калдым. Нишләргә, кая барырга, ярдәм сорап кемгә сүз кушарга? Берүзем калгач, беренче төнемне республика НКВДысы урнашкан бинаның пропусклар бүлеге ишеге төбендә үткәрдем. Җиңенә кызыл бәйләвеч таккан бер кыдрач милиционер мине аннан урамга куып чыгарырга теләде, аңа эчкә кереп киткән әнинең чыгуын көткәнемне, әнидән башка бинадан чыкмаячагымны әйттем. Икенче көнне, төш алдын-

нан мине бәләкәй генә бер бүлмәгә алып кереп ашаткач, караңгы машинага утыртып каядыр алып киттеләр. Озак бардык. Ахырда машина урман уртасында, кыш булса да суы катмаган зур күл буена урнашкан, тирәсе таш койма белән әйләндереп алынган, биек манаралары өстендә ялтыравыклы тәреләре кукраеп торган монастырь алдына барып туктады. Ул халык дошманнары балалары өчен махсус оештырылган колония булып чыкты. Ләкин анда караклыкта йөргән тәрбиячесез балалар да җитәрлек иде. Алып килүчеләрем мине шадра йөзле, кырыс карашлы, туп шикелле йомры бүксәле урта яшьләрдәге хәрбигә тапшыргач, китеп бардылар. Кырыс хәрби мине шундук якындагы биналарның берсенә алып китте. Бина коридорында көпә-көндез ут янса да, караңгы иде. Безне анда зур мыеклы хәрби каршылады. Мине китерүче аңа: «Бу әрәмтамакны җиденче камерага урнаштыр»,— дип борылып чыгып китте. Соңыннан мин ул кешенең колония башлыгы икәнен, колониядәгә балалар аны Бүкән дип йөрткәннәрен белдем.

Камерада мине төрле яшьләрдәге утызлап малай каршылады. Арадан берсе:

— Мальчики, Павлик Морозов пришел, устроим темную!..— дип муенымдагы галстугыма килеп ябышты.

Калган малайлар шул ук вакытта башыма ниндидер чүпрәк каплап, акырыша-бакырыша дөмбәсләргә тотындылар. Коридордагы мыеклы хәрби кереп араламаса, бу тәпәләү ничек бетәр иде, белмим. Хәрби абый мине, камерадан алып чыгып, ниндидер караңгы бүлмәгә бикләде. Борыным каный, иреннәрем күбеп чыккан иде, идәнгә чалкан яттым. Кемнәр янына китерделәр мине? Кызыл галстук ник ошамады ул ахмакларга? Нигә мин аларга Павлик Морозов булып күрендем, аның белән нинди уртаклыгым бар?..

Икенче көнне мине җиденче камерага кертмәделәр, бүтән камерага яптылар. Муенымдагы кызыл галстугымны анда кергәндә коридордагы кизү милиционер салдырып алып калды. Яңа камерада да колач җәеп шатланып каршыламадылар. Кереп беркавым үтүгә, бөтенләй диярлек ялангач калдым. Камерадагы малайларның берсенә пальтом, икенчесенә бүрегем, өченчесенә итекләрем, дүртенчесенә чалбарым, калганнарына өстемдәге бүтән киемнәрем ошады. Стеналары бер метрдан артык калынлыктагы ярыйсы ук салкын камерада шәрә калуым берәүне дә борчымады. Андагы малайлар һәммәсе дә үзләрен генә кайгырттылар. Коридордагы милиционер мине чишендерүне ишектәге «бүре күзе»ннән карап торган иде, күрәсең, беравыктан ишекне ачып:

— Мохтар, ишетсен колагың, яңа малайга бөтен киемнәрен кире кайтарт. Әгәр моны үтәмәсәң, ун көнгә карцерга ябам,— дип кисәтте.

Базык гәүдәле, тар маңгайлы малай аягына басып:

— Миша абыйның нәрсә әйткәнен барыгыз да ишетте, бу маймылның,— Мохтар миңа төртеп күрсәтте,— киемнәрен замат кире кайтарыгыз. Мин ике лыгырдарга яратмыйм, беләсез,— дип боерды.

Әһә, бу малай монда башлык икән, дигән уй узды башымнан. Бөтен киемнәремне үземә яңадан кире кайтаргач, тиз-тиз киендем.

Кинәт кормушка капкачы ачылды. Аннан милиционер Миша абый Мохтарга миңа сәндерәдән урын бирергә кушты. Әгәр яңадан да кыерсытылсам, бөтен камераның биш көнгә ач каласын белдерде.

Кормушка капкачы ябылгач, малайлар минем кем булуым, ни өчен утыртылуым, бу төрмәгә кайчан килүем белән кызыксындылар. Авылдан икәнемне, Казанга әле берничә көн элек кенә килүемне, ни өчен кулга алынуымны белмәвемне әйттем. Алдашма, монда юкка япмыйлар, дөресен сөйлә. Миша абый сиңа кем, ник ул сине яклый, ачып сал, юкса темный ясап ник туганыңа үкендерербез, дип янадылар. Мин, әти, синең дә, әнинең дә кулга алынуыгыз турында әйтергә курыктым. Кичә җиденче камерада муенымда кызыл галстук күрүгә якама ябыштылар, сезнең төрмәдә икәнегезне белсәләр, эһ тә итми буарлар, дип уйладым. Рәхмәт Мохтарга, ул ярдәмгә килде. Иптәшләренә:

— Б...ка тисәң сасысы чыга, калдырыгыз бүгенгә, берничә көннән сөйләтербез әле, монда соңгы көнебез түгел бит,— диде.

Тормышымның Казан туфрагына аяк баскач капылт үзгәрүе, гүя, миемне түнтәрде, акылымны алды, исемне җибәрде. Үземне мин өндә түгел, аяк өсте төш күрәм итеп тойдым, әти. Син кулга алынганның иртәгесен мәктәпкә баргач, иптәшләрем, фашист дип мәсхәрәләп, дәррәү ябырылып дөмбәсләделәр. Һаҗәр апа, сәвит мәктәбендә халык дошманы баласына урын юк, дәрескә бүтән килмә, дип класстан куып чыгарды. Менә инде без өчебез дә — син дә, әни дә, мин дә — төрмәдә... Бәхетле балачак... Чынбарлыкны чагылдырмаучы бу купшы төшенчә аллы-гөлле ялган төсләр уйнаклаткан сабын куыгы белән бер икән.

Февраль башында колониянең суык бинасында салкын тиеп, аяктан егылдым. Тәнемне чуан басты, чирләшкә сарык күк гырык-гырык ютәлләдем, температурам кырык градуска җитте. Кыскасы, яшәү белән үлем арасында калдым — әҗәлем якама ябышты. Мине изоляторга күчерделәр. Анда, кыш булса да, ягылмый иде, берничә юрганга төреп салсалар да, туңудан тешләрем тешкә тимәс булды. Колониядә врач юк, авызына гел челем кабып йөрүче яшь җилкуар фельдшер гына бар иде, ул иртән кереп исәнлегемне барлый да, бер чәй кашыгы әрем шикелле ниндидер ачы дару эчереп, чыгып китә һәм иртәгәгә кадәр изоляторга аяк басмый иде. Көннәрем бүлмәдәге суык һәм авыруым белән тарткалашып бер-бер артлы акрын гына узды. Тамагыма берни үтмәде. Колониядә чирле кешене тиешенчә тукландырып аякка бастырырдай ризыклар булдымы икән, белмим. Булсалар да кемгә кирәгем бар, кем өчен хаҗәт идем соң мин? Дөньям үзем яткан салкын, котсыз изолятор зурлыгына гына калып кысылды, күңелемне сүлпәнлек, төшенкелек, өметсезлек биләп алды, шатлык-куанычлар, хөрлек-иркенлекләр, гүя, бөтенләй булмагандай юкка чыктылар.

Соңгы сәгатем сугарга инде күп калмады бугай, дип ачынып уйланып ятканда, бер көнне кичкә таба изоляторга өстенә ап-ак кайры тун кигән, калын иреннәре арасыннан алтын тешләре ялтырап торган бер кеше керде. Ул, яныма килеп, маңгаемны тотып карагач, борылып чыгып китте. Башымнан, бу врач булды ахры, дигән ялкау уй узды. Күп тә үтмәде, икеме, өчме калын юрган һәм бер иске бәрән толып күтәреп, ул кеше изоляторга яңадан керде, ашыкмый гына мине юрганнарга төреп, өстемә толып япты.

— Ничек, туңарлык түгелме хәзер? — диде ул аннары, маңгаема яңадан кайнар учын куеп.— Мондагы мичләргә ягучы Никодим карт, салкын изоляторда бер малай үлем хәлендә ята, дигәч кердем монда. Моңарчы белмәдем, белсәм күптән кергән булыр идем. Кайдан син, әти-әниләрең бармы? Бу җәһәннәм базына ничек килеп каптың? — дип тезеп китте аннары.

Мин аның сорауларына, теләр-теләмәс кенә, берничә сүз белән җавап бирдем.

Алтын тешле абый, җәелеп сөйләшәргә атлыгып тормавымны күрептер, өстемдәге толыпның чабуларын астыма тыккач:

— Сине, энем, мондагы эт көтүеннән араламасам, исемем Кәбир булмасын,— диде, өзеп.

Икенче көнне ул, иртүк килеп, кура җиләге кагы кертте. Аннары, мәтрүшкә салып, чәй кайнатып эчерде.

— Мин сине, энем, үз өемә алып кайтып аякка бастырырга булдым. Хәлеңне сөйләгәч, җәмәгатем дә, мотлака үзебезгә алып кайт баланы булдыра алсаң, аны күрәләтә зинданда харап иттермә, дип кисәтте. Хәзер менә сине моннан алып китәргә рөхсәт алырга нәчәлник янына керәм, каршы килмәс, сүземне тыңлар, мине ул арка таянычы исәпли, нык уважайт итә. Потамушты аның бер эше дә минсез бармый. Мин монда нәчәлник, аның уң кулы — хуҗалык мөдире бит,— диде.

Туп күк йомры бүксәле начальник, бер әрәм тамак колониядә аяк суззы ни дә, бүтән җирдә дөмекте ни, дигәндер инде, Кәбир абыйга мине өенә алып китүгә каршы килмәде.

Яңа урында, җылы авыл өендә, мин тиз тернәкләндем. Температурам төште, ютәлләвем кимеде, атна-ун көннән, урыннан торып, йөри дә башладым. Игелекле һәм риясыз яңа тәрбиячеләрем Кәбир абый белән Мәрьям апа мине авылдашларына күрсәтмәскә тырыштылар. Көннәр шулай бер-бер артлы үтә торды, яз якынлашты. Үземне алда нәрсә көткәнен мин уйламаска тырыштым. Күз алдымда гел әни белән син тордың, әти. Бәлки инде сез мин авырып ятканда иреккә чыккансыз, мине эзлисездер, дип төннәр йокламадым. Кәбир абый бер көнне, эштән кайткач: «Колония начальнигына мин сине үлде дидем, яңадан да ул җәһәннәм базына убыласың килмәсә, кеше-карага күренми өйдә шым гына утыр. Бу дөньяда син юк — син ләхеттә, энем»,— диде. Минем шундук, ничек ул алай, бу инде мин яшәүдән туктадым дигән сүз түгелме соң, дигән шомлы уй тетрәтте. Кешеләргә күренми тере мәет булып ничек көн итәрмен?.. Кәбир абый, ни уйлавымны сизенгәндәй, фамилияңне, исемеңне алмаштырбыз, синең үткәндә кем булуыңны берәү дә белмәс, җимертеп яшәрсең, кайгырма, диде, канәгать елмаеп. Фамилиямне дә, исемемне дә алыштырмыйм, бүтән исем-фамилиягә күчсәм, әти белән әни ничек табарлар мине, дип каршы төштем. Кәбир абый, башын кашып, минем белән ризалашты һәм: «Дөрес, энем, син хаклы, сиңа җил-яңгыр тидермәс өчен башка чара табарга туры килер»,— диде. Бер атнадан ул мине үзенең Дөмбез районындагы апасына илтеп ташлады. Шунда яшәп урта мәктәпне бетердем. Кәбир абый ярдәм итеп торды, Мәрьям апа белән Кәбир абыйның үз балалары юк иде, мине уллары кебек үстерделәр...

Балачагым менә шундый язмышка дучар булды, әти...

## 3

Кинәт кенә мине бүтән камерага күчерделәр. Көтелмәгән бу үзгәрешкә шатландым. Яңа «фатирым» моңарчы утырган камерамнан бермә-бер зур да, җылы да төсле күренде. Иң шәбе анда кеше бар иде—ялгызлыктан котылдым. Ул камерада миңа кадәр утырган, миңа алда иптәш буласы кешенең авызы колагына җитте. Артымнан ишек ябылу белән ул:

— Әйдүк, туганкай, шөкер, алла бар икән әле, ялгызлыгыма чик куйды,— дип куанып каршылады.

Таныштык. Казан кешесе икән. Бу каһәрләнгән эчке төрмәдән өч кенә квартал ары яшәдем, Яңа бистәдә кибет директоры идем, Сәхи Гафуров дип бәлки ишеткәнең дә булгандыр. Үземә күрә дәрәҗәм дә, кешеләр арасында хәйран гына абруем да бар иде, дошманнарым бәхетемне, уңышларымны күпсенделәр, муеннары асларына килсен көнче этләрнең, ди. Ул монда унбер ай утыра икән инде. Тагын күпме канымны эчеп, җелегемне корытырлар, белмим, түземем тәмам төкәнде, алтабан нишләрмен, бу тик бер ходайга гына мәгълүм, дип сукранды. Аннары камерага керү белән ятакка салып ташлаган бүрегемне алып, аның эчен шашынып иснәргә керешге. Үзе:

— Ирек коңгысын татымавыма биш балтыр, туганкай, сагындым ирек коңгыларын... Син аннан бу тозакка күптән капмаганга охшыйсың, бүрегең чәч алдыргач чәчтарашлар сипкән хушбуй исен гаип итәргә өлгермәгән, бөркелеп тора,— дип сөйләнде әсәрләнеп.— Кайчан утырдың? Нинди яңалыклар бар иректә? Халык тормыштан бик зарланмыймы?

Сәхи агайның соңгы ятышсыз соравы мине сагайтты. Халык тормыштан ник зарланырга тиеш? Агайның аның белән кызыксынуы тикмәгәме? Кулга алынганчы кайбер китапларда яңа тоткыннарны яшерен шымчылар янына утырту турында укыганым бар иде, шул келт итеп исемә төште. Бәладән башаяк дип, күңелемнән үземне сак булырга, сөйләгәндә телемне тыярга кисәттем.

— Утыруыма әле атна да юк. Студент мин, халык белән аралашуым өчле-тугызлы гына иде,— дидем, ялкау гына.

— Базарда, кибетләрдә, трамвайларда кешеләрнең үзара сөйләшүләренә бер дә колак салганың булмадымыни?

— Һәй, абый, студентның кайгысы бер генә, ул да булса — уку. Аңа арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит.

— Анысы шулай билгеле. Тик сине монда юкка япмаганнардыр, бит?..

— Минем өчен ул кырыгынчы хәсрәт, абый.

— Алаймы икән?..

— Шулай, абый. Укып эттәй арыган идем, монда рәхәтләнеп ял итәм.

— Син монда ял иткәндә әти-әниләрең төн йокламыйлар, хәсрәт чигәләрдер бит?

— Минем өчен беркем дә хәсрәт чикми, ятим мин. Дөньяда берүзем, якыннарым да, туган-тумачаларым да юк.

Камерадашымның үзен ничектер риялы тотуы мине шикләндерде. Нигә төпченә ул? Үз-үземне янә дә аның белән җәелеп сөйләшмәскә, үтә сак булырга, дип кисәттем. Беркавымнан ул:

— Төрмәгә элэгүеңә исең китми күренә, нинди гаеп яктылар син бәхетсезгә? — дип яңадан кызыксынды.

— Гаебемне белмим, әле әйтмәделәр.

— Төрмә — көнче кешеләрнең үч алу урыны. Көнчелекле дусларың күп булгандыр синең. Бәлки сәләтеңне, күркәм кыяфәтеңне көнләшмәгәннәрдер. Кешене монда тыгу өчен кош теле кадәр кәгазьгә өч-дүрт сүз язу җитә, энем.

— Аны сез каян беләсез? Әллә үзегезнең дә шундый ошаклар язганыгыз бар идеме? — дидем агайга турыдан-туры.

Ул күзләрен зур ачып, катып калды:

— Мин шундый кешегә ошаганмынмы әллә?

— Андый кешене күргәнәм юк-югын, ошак ясауны бик белеп сөйләвегезгә таянып әйттем.

— Бу таш капчыкта минем күк унбер ай утырсагыз, сез дә белерсез. Гаебем булса икән, печтик тә гаебем юк, менә моның гына кадәр дә.— Сәхи агай баш бармагы белән күрсәткеч бармагының очын бүлеп күрсәтте.— Казанда урыслар алып узды, татарга көн бетте, алар безне төрлечә каһәрлиләр, кысрыклыйлар, шул кяферләр аркасында гореф-гадәтләребез, туган телебезне елдан-ел оныта барабыз, дәррәү күтәрелеп аларны акылга утыртырга, койрыкларына басарга кирәк, без тамырларыбызда бөек Чыңгыз каны акканны оныттык, дип сөйләп йөргәнмен, имеш. Шул булдымы дөреслек? Бердәнбер кызым урыста кияүдә үземнең. Оныгымда мөселман каны гына түгел, яртысы урыс каны. Безне эчәргә, тартырга, сүгенергә, бүтән бозыклыкларга өйрәтүчеләр кем? Урыслар. Бабаларыбыз, бүгенге хәлебезгә борчылып, каберләрендә әйләнгәләп яталардыр инде. Кем идек, кем булдык — адәм көлкесе! Оят бит. Син менә татар, үзеңне ник утырткаңнарын кандаш кардәшеңнән — миннән яшерәсең. Әйт ник утырттылар сине?

Каян таптылар миңа бу шәмәхә танаулы полковник сыңарын? Ни өчен утыртылуымны үзем белсәм икән...

— Аны белү сезгә бик кирәкмени, агай?

— Ә кәк же. Камерадашымның кем булуын белергә тиеш мин.

— Иртәрәк туганмын мин, шуңа утырдым.

— Тфү! Аның белән кешечә сөйләшәләр, ул авыз җыра!..— Агай камераның ишектән кергәч сульяк стенасы буендагы асты-өскә капланган табутка охшаган ятагына юрганын дүрткә бөкләп җәеп, намаз укырга утырды. Күп тә үтмәде, куллары белән шәрә башын чәбәкләде дә, урыныннан сикереп торып тез күмәче шикелле ялтырап торган такыр түбәсенә чалбар кесәсеннән керле кара түбәтәен чыгарып каплады.

— Нервларымны кузгаттың тәки, синең аркаңда ходай хәзрәтләренә хисап бирергә башымны капламый утырдым. Адәмчә гәпләшә белмисең, мөселман түгел, керәшендер син, валлаһи!..

Аның кергәннән бирле саруымны кайнатуына түземем төкәнде, арабызда кабынган мәгънәсез әңгәмәгә чик куярга булдым.

— Абый, зинһар, косасымны китермә, мин сиңа әйтәсемне әйттем, башыңа түбәтәең урынына парашаны киясең килмәсә, үтенәм, телеңне тик тот, эчемне пошырма.

— Вәт үсте яшьләр, олыны олы, кечене кече итү юк, миңа — әтисе булырлык кешегә яный, әй-йәй-йәй...

— Минем синең кебек тозсыз атам юк.

— Йә әйт әле, минем нәрсәм начар?

— Телең тәмсез, кыяфәтең юха җылан кыяфәте. Булды, тәгаллик тел чарлауны.

Сәхи агай миңа нәрсәдер әйтмәкче булып авызын ачты, ләкин мин ачу белән почмактагы парашага карагач, сүз катарга базмады.



## Алтынчы бүлек

### 1

Сәхи агай янына күчерелгәннең икенче иртәсендә камера ишегебез шалтырап ачылды һәм бусага төбендә балык күзле таныш старшина пәйда булды.

— Фамилияң? — диде ул миңа уң кулының күрсәткеч бармагын пистолеттай төбәп.

— Кадыйров.

— Киттек.— Старшина мине куллары белән беләкләремнән кысып, коридор башындагы каравыл бүлмәсе аша борылмалы мәрмәр баскычтан иминлек бинасының өченче катына алып менде. Бу көнне ул мине шәмәхә танаулы полковник янына түгел, ябык чырайлы ниндидер майор янына алып керде. Старшина бүлмәдән чыгып киткәч, майор мине тиз генә күздән кичереп, утырырга урын күрсәтте.

— Танышыйк, минем фамилиям Апышев,— диде ул, гади генә итеп.— Миңа сезнең белән эшегезгә кагылышлы мәсьәлә буенча гәп куертырга куштылар. Каршы килмисездер бит?

— Килмим, әлбәттә.

— Алай...— Майор, өстәлендә чәчелеп яткан ниндидер кәгазьләрне бергә җыйгач, янымя килеп утырды.— Йә, студент, күнегеп буламы яңа шартларга?

— Мин фронтовик бит, иптәш майор, уңайсызлыкларга исем китми, Төрмә кунак йорты түгел бит, талымла-талымлама, үзгәреш булмаячак. Ни өчен кулга алынуым борчый мине, шуны беләсем килә.

— Сезне советка каршы контрреволюцион агитация алып баруыгыз өчен кулга алдылар.

— Коммунист башым белән ничек советка каршы контрреволюцион агитация алып барыйм, сафсата бу, иптәш майор.

— Юк, Кадыйров, бер дә сафсата түгел. Телисезме, мин сезгә ташланган гаепнең нигезлелеген раслыйм? — Майор миңа сынаулы текәлде.

— Телим, иптәш майор, сузмагыз, тизрәк раслагыз, зинһар.

— Сез Сатаров Рианны беләсезме?

— Беләм. Тик Сатаров түгел, Саттаров аның фамилиясе, иптәш майор.

— Юк, нәкъ менә Сатаров ул, ягъни, Продастов.

— Һич нәрсә аңламыйм, минем эшемә аның ни катнашы бар?

— Бар, Кадыйров. Сезнең бу йортка китерелүегезгә Сатаровның турыдан-туры катнашы бар.— Апышев, урыныннан торып, өстәленнән ниндидер кәгазьләр алып килде.

— Мә, танышыгыз.

Мин, кәгазьләрне кулыма алып, аларның иң өстәгесенә күз йөртә башладым. «Мин — Казан дәүләт университеты студенты Саттаров Риан

Сәетович, Республика дәүләт иминлеге министрлыгына үз иркем белән түбәндәгеләрне белдерүне кирәк санапйм. 1946 елның язында мин советка каршы контрреволюцион яшерен оешмада катнашканым өчен университеттан куылдым. Ләкин аңа карап советка каршы эшчәнлегемне ташламадым, дәвам иттем, үзем кебек үк уйлаучы, үзем кебек үк совет хөкүмәтен, илебездә урнашкан тәртипләрне яратмаучы иптәшләр эзләдем һәм аларны таптым. Шундый иптәшләремнең берсе Казан дәүләт педагогия институты студенты, әтисе дә, әнисе дә 1937 елда халык дошманнары буларак кулга алынган Кадыйров Ирек Сабирович...»

Фамилиямә, исемемә, әтием исеменә юлыккач мине кинәт ток суккандай булды, күз алларым караңгыланды, тыным кысылды, аркамнан, гүя, бер төркем салкын кырмыскалар чабышып узды. Күтәрелеп майорга карадым, ул үз эше белән мәшгуль, нәрсәдер яза иде. Дулкынланудан маңгаема тир бәреп чыкты, кулымдагы кабәхәт кәгазь бармакларымны кайнар күмер кебек пешерә кебек булды. Башымнан, Риан... Риан... әллә ул акылыннан шашканмы икән, нигә дип миңа нахак бәла яга, әти-әниемнең монда ни катнашлары бар, дигән хафалы уй узды. Беравык шулай аптырап утыргач, кулымдагы кәгазьләргә янә күз йөртә башладым. «...Кадыйров — фронтовик, коммунист. Әмма ул минем совет властена каршы сөйләгән бер генә сүземә дә каршы килмәде, киресенчә, үзе дә миңа кушылып совет строен, Коммунистлар партиясе сәясәтен, колхозларны, илебездәге бөтен тормышны төрлечә хурлады, сугыштан соңгы кыенлыкларны бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинның беркемнең дә сүзенә колак салмыйча тик үзенчә генә эш итүеннән күрде...»

Минем төшемә дә кермәгән уйдырмаларны язарга ничек кулы барган Рианның. Фикерләү шөрепләре какшагандыр аның, юкса башны себер җибәрердәй ялганнарны каян алыр иде! Карыйм әле, кайчан язды икән бу уйдырмаларын. Мин тимерчыбык кыстыргыч белән бер-берләренә беркетелгән кәгазьләрнең иң астагысына күз салдым. Анда 1949 елның 7 июне дип язылган һәм «бирелә хикәя ителгән нәрсәләрнең барын да раслыйм Р. Саттаров» дип имза куелганын күрдем. Шундук Р. S. (Постскриптум) билгеләре салынып, бирелә фаш ителгән Кадыйров һәм үзем белән аралашучы башка фикердәшләрем турында мин сезгә даими хәбәр итеп торуны өстемә алам, диелгән иде. Менә ни өчен юк сәбәпләрне бар итеп минем белән аралашкан булган ул. Мин ахмак исә ул торган фатирга барып чыгуны үзем өчен җилләп кайтуга гына. саный идем. Бәлки ул фатирдаш иптәшләре Әүдәкиев белән Йөзәевне дә пычракка буяп үзенә кирәкканчә беләү-янавычы белән игәүләгәндер. Юк икән, фатирдаш иптәшләренә кара якмаган, тик ахырда гына Әүдәкиев белән Йөзәев бирелә язганнардан Кадыйровка кагылышлыларының кайберләрен раслый алалар дигән. Алар нәрсәләрне раслый алалар? Германиядәге, шулай ук сугыш вакытында миңа күрергә туры килгән башка Европа илләрендәге юлларның иркенлеге, төзеклеге, авылларның бездәге шикелле тиреслек башына охшамаулары, майлы буяулар белән язылган нәфис картиналардагы шикелле соклангыч булулары, авыл хуҗалыгы машиналарының күплеге, андагы халыкның культурасы турында сөйләвемне Риан язмаларында совет чынбарлыгына яла ягу дип бәяләгән, аның сүзләрендәге агуга, гаделсезлекләргә искитмәле. Риан да, аның фатирдаш иптәшләре Әүдәкиев белән Йөзәев тә чит илләрдә күргәннәремне юри кат-кат сөйләткәннәр булып чыга. Әмма мин сөйләгәндә, сугыш калдырган җимерекләрне яңадан торгызып, берничә елдан безнең илебезнең дә төзек һәм купшы чит илләрне куып җитеп узып китәчәгенә шикләнмәвемне басым ясап әйтергә онытмый идем.

Риан белән мине театр училищесы студенты Мәүлә Хәсәнов таныштырды.

— Әнә булачак классик килә,— диде ул Ленин бакчасында бер сөйләшеп утырганда Пушкин урамыннан безнең якка атлаучы, озын чәчләре иңнәренә төшеп торган, базык гәүдәле бер егеткә күрсәтеп.— Дустым ул, безнең кебек үк студент, таныштырыйммы?

Миңа булачак классикның башын бик һавалы тотып, атлаганда башта үкчәләренә, аннары гына тулы табанына басуы, бөтен кыяфәте белән үзен бакчада тик ул гына бар кебек тотуы ошамады.

— Бүген түгел, Мәүлә, башка вакытта,— дидем, читкә борылып.

Әмма дустым мине тыңламады.

— Баеган кеше, күрмәмешкә салышып узып бара. Кил, утыр әле безнең янга, ял ит, Риан.

— Ә, Мәүлә, сәлам. Утырып тормыйм, малай, ашыгам.

— Сөйләмә юкны. Ашыккан кеше адымнарын синең күк иренеп атламый. Утыр әле, менә бу иптәш белән таныштырыйм сине.

«Булачак классик» теләр-теләмәс кенә безнең янга килде, ләкин утырмады, аяк өсте калды. Башта ул Мәүлә белән кул биреп исәнләште, аннары кулын миңа сузды.

— Риан.

Мин, үз исемемне атап, аның кулын кыстым.

Яңа танышымны үзем түгел, түшемдәге поляк ордены — Грюнвальд тәресе кызыксындырды. Аның җәенке кыска борынына атландырылган калын пыялалы күзлеге астындагы коры бака ефәге төсендәге күзләре шул орденнан бүтән берни дә күрмәделәр.

— Кызык тәре. Тотып карарга ярыймы аны? — диде ул, ниһаять, карашын орденнан аера алмыйча.

— Карагыз. Поляк ордены ул. Икенче класслы Грюнвальд тәресе дип атала.

Риан тәрене төрлечә әйләндереп карады.

— Татар түшендә, гомумән, совет кешесе түшендә, чит ил орденын беренче күрәм. Кайдан алдыгыз аны?

— Сугышта бүләкләделәр.

— Сез сугышта булдыгызмыни?

— Ул сугышның ахыргы ел ярымында поляк армиясендә хезмәт иткән,— дип ярдәмгә килде миңа Мәүлә.

— Кызык. Сөйләгез әле үзегез турында. Кем сез? Кайдан? — дип Риан янәшәмә утырды.

— Мин педагогия институты студенты, Зур Кызыл урамындагы тулай торакта яшим. Сезне кызыксындырган башка нәрсәләр турында хәзер түгел, башка бер очрашканда сөйләргә тырышырмын.

— Минем сезнең үзегез турында сөйләвегезне бүген үк ишетәсем килә...

— Башка вакытта, Риан иптәш, бүген кәефем юк, гафу итегез...— Яңа танышымның тәкәллефсезлеге җенемне чыгарды.

Дустын өнәмәвемне күреп, Мәүлә миңа ярдәмгә килде:

— Ашыгам, дигән идең бит син, хәтта туктарга да исәбең юк иде,— дип төрттерде аңа.

— Ситуация алмашынды, картлач, ситуация. Тере сюжет утыра янәшәмдә. Мин аны вәзенле белми торып тынычланмаячакмын. Карагыз әле, бәлки әллә кайчанга калдырмый, үзегез турында бүген сөйләрсез, Ирек иптәш?

— Өч сүз белән ярыймы?

— Юк, өч сүз белән кызык түгел, миңа бөтен ваклыкларын белергә кирәк.

— Сагызланма, Риан, кеше сиңа, башка вакытта, ди, көт башка вакытны.

Мәүләнең бу сүзләреннән соң Риан эскәмиядән хәтере калган кыяфәттә торып, яңадан күрешкәнгә кадәр, дип кулларыбызны кыскач, бер яккарак кыйшайган башын безнең янга килгәндәгечә үк һавалы тотып, атлаганда аякларын башта үкчәләренә, аннары гына тулы табаннарына басып, кай ягы беләндер цирк шамакаен хәтерләтеп китеп барды.

Рианның үз-үзен тотышы, ясалмалыгы, бәйләнчеклеге саруымны кайнатты. Ул нигә кылана, шуның белән үзе турында кешеләрдә кире тәэсир калдыруын аңламыймы, әллә кешеләрне юри үзенә игътибар иттерер өчен

оригиналлык маскасы кияме? Мәүлә аны булачак классик диде, бәлки Риан үзе дә моңа инде тулысынча ышангандыр һәм аның һаваланууның чыганагы шулдыр?

— Син яңа гына минем белән таныштырган иптәшеңне булачак даһи дип бик югары бәяләдең. Матбугатта чыккан әсәрләре бармы соң аның, нәрсәләрен укырга мөмкин?

Беркатлы эчкерсез Мәүлә, миңа җавап бирү урынына, үзе сорау бирде:

— Синдә ул әйбәт тәэсир калдырмады бугай. Ялгышмыйммы?

— Ялгышмыйсың, дус, нәкъ өстенә бастың.

— Инде соравыңа җавап бирәм. Рианның хәзергә матбугатта чыккан әйберләре юк. Ул көн-төн «Безнең заман герое» исемле шигъри роман өстендә утыра. Кулымны кисәргә бирәм, шәп әйбер, татар әдәбиятында моңарчы күрелмәгән шедевр булачак ул. Теле сокландыргыч. Миңа ул әсәреннең кайбер өзекләрен укыды, таң калдым. Андагы сурәтләү чаралары, метафоралар кемне дә дулкынландырырлык!

— Үзеңә мәгълүм, мин шигърият нечкәлекләрен авыр аңлыйм, Мәүлә. Әйбернең үзен кулга тотып укымыйча бәяли алмыйм.

— Анысы шулай инде. Риан синең белән кызыксынып иртәгә үк минем янга килә, күр дә тор.

— Минем белән кызыксынып нигә сиңа килә, ә үз яныма түгел?

— Хәйләкәр ул. Башта кызыксынган кешесе турында кирәк кадәр мәгълүмат җыя, аннары гына аның үзенә мөрәҗәгать итә.

— Үпкәләмә, ошамады миңа дустың.

— Шуңа күрә син аның кем икәнен дә сорамыйсың.

— Аны мин, гомумән, белергә теләмим. Уйнавы өч тиен тормаслык сәләтсез артист күк синең дустың. Турысын әйтүемә, зинһар, ачуланма.

— Син хаклы, нигә ачуланыйм. Әйдә аның турында сүзне туктатыйк, шаулатмыйк колагын...

Рианның кулымдагы кәгазьләрдәге дивана саташуларыннан җирәнеп, өстән-өстән генә карап чыккач, аптыраудан нәрсә уйларга белмәдем. Тилебәрән орлыгы ашагандыр бу, акылы камил кеше шундый нәрсәләр язамы? Монда телгә алынган гаепләрнең йөздән бер өлеше генә дөрес булса да, коточарлык бит! Ул мине ни өчен үзенең фикердәшенә әверелдергән, ни ачуы булган миндә, аңлашылмый. Теләсәң, һәр сүздән икенче мәгънә чыгарырга була булуын, әмма аның миңа ташлаган гаепләре юмга корылган бит. Бу теге, «атарга, ярамый калдырырга» тәгъбирендәге өтернең урынын күчерүдән бөтенләй капма-каршы мәгънә туган кебек бит. «Атарга ярамый, калдырырга...» Хәзер миңа мәнә акның кара, караның ак түгеллеген исбатларга кирәк.

Мин кулымдагы кәгазьләрне майорның өстәленә илтеп салдым.

— Таныштыгыз дамы? — диде ул, башын күтәреп.— Тиз тоттыгыз, игътибар белән укымадыгыз ахыры?

— Ул пычрак пасквильнең нинди укырлыгы булсын, иптәш майор? Дивана саташуын укыдың ни дә, укымадың ни.

— Дустыгызны сезнең рухи чатаклыгыгыз, идеологиягезнең ялгыш эздән китүе борчый, сез аны диванага саныйсыз. Ярамый алай, ярамый, Кадыйров.

— Монда язылганнарның бер сүзе дә дөрес түгел бит, иптәш майор.

— Сатаровның үзе турында язганнары дамы?

— Мин үз өстемә ташланган гаепләр турында әйтәм, аның гаепләрен белмим.

— Сез аның белән күптәннән танышмы?

— Якыннан бер ел чамасы.

— Арагыз ничек иде, бәлки сез аны үпкәләткәнсез, хәтерен калдыргансыз?

— Хәтерләмим. Андый нәрсәнең булганы юк иде шикелле, иптәш майор.

— Сатаров безгә язып биргән нәрсәләрнең уйдырма икәнлеген нәрсә белән дәлилли аласыз?

— Берничек тә дәлилли алмыйм, әмма намусым пакь. Кемлегемне барлык курсташларымнан, тулай торакта бергә яшәгән иптәшләремнән сораша аласыз, алар әйтерләр.

Майор Рианның кәгазьләрен почмагына эре хәрефләр белән ХРАНИТЬ ВЕЧНО сүзләре язылган юка гына зәңгәр папка эченә салып куйды.

— Ярар, хакыйкатьне ачыкларга тырышырбыз. Ничек кенә булмасын, дустыгызның дөрес фамилиясе Сатаров сезнең. Турысын әйтәм, хаклыгызны дәлилләү авыр булыр сезгә, Кадыйров. Что написано пером, не вырубишь топором, ди халык. Гаепләү сөземтәсе белән таныштым, дип менә бу кәгазьгә кулыгызны куегыз. Уңыш телим сезгә.

Мин майор биргән кәгазьгә имзамны салдым.

Майор Апышев белән мин бүтән очрашмадым, эшемне башка тикшерүчегә бирделәр.

## 2

Тикшерүчем капитан Горшенинны мин беренче очрашуда ук ошатмадым. Ул Апышев кебек әдәпле-илтифатлы түгел, аның капма-каршысы булып чыкты. Горшенин мине кабинеты уртасында аяк очларыннан үкчәләренә, үкчәләреннән аяк очларына атынып, кулларын чалбар кесәләренә батырган килеш каршылады. Аннары исәнләшүемә башын кагып кына җавап кайтаргач, ишек катындагы сул почмакта паркетка кыймшатылмаслык итеп беркетелгән табуретка күрсәтте.

— Утыр. Танышыйк, мин синең тикшерүчең Семен Андреевич Горшенин.

— Аңлашылды,— дидем мин. Үзем, әһә, бу теге шәмәхә танаулы полковник шәкерте икән, дип уйлап алдым.

Эше урыныннан кешенең кемлеген һәм нәрсәгә сәләтле икәнен ялгышусыз әйтеп була, дия иде институтта безнең факультет деканы Илья Александрович Рахлин. Карыйм әле, бу кабинет үз хуҗасы турында нәрсә әйтер икән? Уң стенада — Советлар Союзы маршалы киемендә Лаврентий Павлович Берия портреты. Ул ялтыр пыялалы пенснесе аша төймә шикелле түгәрәк һәм калку бәбәкләрен туп-туры миңа төбәгән кебек. Портреттагы Берия кай ягы беләндер ачулы зәһәр еланны хәтерләтә. Аның алтынланган рамы астында ук капитанның йомшак урындыгы һәм урындык алдында өстенә кара дерматин тартылган ике баганалы зур эш өстәле. Өстәлдә кәгазьләр һәм берничә папка ята, эченә төсле һәм гади карандашлар, ручкалар утыртылган биек агач стакан, өске калфаклары ачык ике массив пыяла кара савытлы язу приборы, төпчек савыты һәм телефон. Өстәлнең тәрәзәгә караган башында зур сейф. Кабинетның ике тәрәзәсе дә пөхтә эшләнгән җыйнак тимер рәшәткәләр белән ныгытылган. Собакевич бүлмәсе тибындагы бу кабинетка җыйнак бәдәнле, ябык чырайлы капитан ничектер очраклы рәвештә генә килеп кергән кеше кебек.

Тикшерүчем, мин аның кабинетын өйрәнгәндә, күтәрелеп карамады, төпчек савытында учак тергезеп, ниндидер ярамас кәгазьләрен яндыру белән шөгыльләнде. Мин аны җентекләп күзәткәч, акылга сайрак адәм булырга тиеш бу, дигән нәтиҗәгә килдем. Ялгышмаганмын икән. Тикшерү барышында ул үз фикерен генә дөрескә исәпләүче, үзен киң эрудицияле, тирән белемле гыйлем бәндәгә санаучы буш кеше икәнен күрсәтте.

— Йә, Кадыйров, үзеңнең советка каршы эшчәнлегең турында яшерми сөйлә әле,— дип башлады ул сүзен, төпчек савытында кәгазьләр яндыруын дәвам итеп.— Әйе, боргаланмый дөресен сөйлә. Синең совет законнарына сыймый торган ул эшчәнлегеңнең һәр адымы безгә мәгълүм.

— Кызык, сез кабыргасы белән куясыз мәсьәләне, капитан.

— Гражданин капитан.

— Ярый, сезнеңчә булсын.

— Бу минем назлануым түгел, шулай кирәк. Син — тикшерелүдәге кеше, мин — тикшерүче.

— Ә нигә иптәш капитан түгел?

— Синең иптәшләрең — урмандагы бүреләр, мин сиңа иптәш түгел.

— Сез дә, мин дә совет гражданлыгын югалтканыбыз юктыр ич әле, кая ашыгырга? Бәлки минем намусым сезнекеннән чистарактыр, аны белмисез бит сез.

— Беләбез. Әйдә, демагогияңне калдыр, кабатлап әйтәм, сөйлә үзеңнең совет властена каршы эшчәнлегең турында. Минем синең белән бушка сүз куертырга вакытым да теләгем дә юк.

— Сез, безгә һәммә нәрсә мәгълүм, дидегез бит, нигә алайса аны тагын миннән сөйләтеп кадерле вакытыгызны әрәм итәсез соң?

— Аның өчен башың авыртмасын, монысы — минем эшем.

— Мин совет властена каршы бернинди эшчәнлек тә алып бармадым һәм андый мәгънәсез нәрсәнең уема да килгәне булмады.

— Ә менә бу делодагы чын йөзеңне фаш итүче материалларны кая куясың?

— Аларны сез теләсә кая куегыз, мин үзем өчен үзем җавап бирәм. Сезнең өчен нәрсә мөһимрәк, җансыз кәгазьләрме, мин үземме?

— Делодагы документлар гади кәгазьләр түгел, алар синең чын йөзеңне фаш итәләр.

— Ул «документлар» кем кулы белән язылган соң? Фронтта, сугыш кырында да, танкны дошман снаряды сафтан чыгаргач, оперативниклар хәрби машина сугышырга яраксыз хәлгә килгәндә экипаж ничек исән калды, нигә сез танк белән бергә янмадыгыз, дип теңкә корыталар, аңа дошман снаряды тигәндә сез кайда утыра идегез, снаряд башта танкның кай җиренә, аннары кай җиренә тиде, дип безнең хәрби машина белән бергә янмавыбызга аптырыйлар, безне куркаклыкта гаепләргә маташалар иде. Сез дә шулай.

— Мин монда сине әкият сатарга чакырмадым, тагын кабатлыйм, син миңа, бернинди боргаланусыз, үзеңнең совет властена каршы контрреволюцион эшчәнлегең турында сөйлә.

— Мин совет властена каршы бернинди эшчәнлек тә алып бармадым. Эшләмәгән нәрсәне өстемә ала алмыйм, капитан.

— Гражданин капитан!..— дип төзәтте тикшерүчем.

— Господин капитан! — дидем мин үҗәтләнеп.

— Нәрсә?!.

— Ни ишетсәң, шул!

Тикшерүчем күзләрен акайтып, урыныннан сикереп торды. Аның чыраена аклы-күкле тимгелләр бәреп чыкты.

— Йәле кабатла!

— Җикермә миңа, кешечә сөйләш. Нигә сиңа биргән җаваплар ошамый? Элекке патша жандармериясе дә, гестапо да түгел, совет учреждениеседер ич бу? Гражданин капитан... гражданин капитан. Мин конституцион хокуклардан мәхрүм ителгән кешемени инде? Нигә син миңа үзеңә генә кулай нәрсәне тагарга тырышасың? Монда мин аяк басу белән сүзеңне кимсетүле «син»нән башладың, мин синең әшнәң дә, туганың да, кайнешең дә, малай чакта бергә шар суккан иптәшең дә түгел. Утыр, имеш. Мин — түрә, син — кол дигән сүз бит бу. Кесәңдә партбилеттыр әле үзеңнең, ә намусың сукыр бер тиенлек тә юк...

Капитан мине бүлмичә тыңлады, ул үзен кабынып китүдән көчкә тыйды шикелле, яңак мускуллары туктаусыз тартыштылар.

— Беттеме? — дидел ул ахырда.

— Бетмәде. Миңа ягылган гаепне синең объектив тикшерүеңә ышанмыйм, шуңа күрә монда мине бүтән чакырып азапланма. Бу безнең беренче һәм соңгы әңгәмәбез булсын.

Капитан мәкерле елмаеп өстәле артыннан чыкты.

— Син миннән баш тартырга, миңа ультиматум куярга карар бирдең, димәк?

— Әйе. Мин үзара мөгамәләләрдәге элементарь нәрсәләрне дә белмәгән надан һәм дорфа кеше белән эш итәргә теләмим.

Өстәлдә телефон шалтырады. Капитан үрелеп трубканы алды.

— Тыңлыйм. Әйе, Горшенин тыңлый. Хәзер үкме? Мин сорау алам бит, буш түгел. Тиз кирәк дисез? Аңлашылды. Аны эшләү авыр булмас, иптәш прокурор. Мин сез сораган нәрсәне бүген үк әзерләрмен. Хушыгыз.— Тикшерүчем, телефон трубкасын йомшак кына итеп үз урынына куйды.— Бүгенге әңгәмәне без шушында өзик, Кадыйров, миңа ашыгыч эш йөкләделәр, аны үтәргә кирәк. Син яхшылап уйла, мин ашыктырмыйм. Безнең бу йортка гаепсез кеше керми, бу — закон. Наданмы, дорфамы мин, ничек булсам шулай кабул итәрсең. Син, гаебем юк, дисең. Ышанмыйм, яхшылап эзләсәң, теләсә кемдә гаеп табып була, тик аны эзли белергә генә кирәк. Моннан соң мин сезне син дип атамаска тырышырмын, сез дә мине бүтән господин димәгез. Килештекме? Субординацияне бозмыйк.

— Килешмәдек, капитан. Мин эшемне сез түгел, бүтән кеше тикшерүен телим.

— Без монда кулга алынучылар кубызына биемибез, аларны үз кубызыбызга биетәбез, Кадыйров.

— Мин сезнең белән моннан соң, гомумән, сөйләшмәячәкмен.

— Карарбыз. Бог даст день, он же даст пищу, ди торган иде минем әби...

3

Сәхи ага белән без уртак тел тапмадык. Ул киемле аяклары белән минем күңелемә үтеп керергә, анда җаны теләгәнчә таптанырга чамалады шикелле, мин исә үземне ярыйсы ук тилемсә, бернигә дә исем китми торган зат итеп күрсәтергә тырыштым. Берничә көннән соң иртән төрмә начальнигы, гадәтенчә обход ясаганда кереп, миңа нинди үтенечләрегез, сорауларыгыз бар, дигәч, мин аңардан үземне яңадан баштагы камерама күчертүен үтендем.

— Сәбәп? — диде начальник.

— Камерадашым белән бер-беребезне күрәлмибез. Ул саруымны кайната,— дидем.

— Ә сез нәрсә әйтәсез?

— Минем дә аны җенем сөйми,— дип җавап кайтарды төрмә начальнигына Сәхи ага.— Аерыгыз безне, зинһар, аерыгыз. Ул укыган кеше, борын күтәрә, минем белән сөйләшми. Яныма үзем кебек прастуй мужикны кертегез. Ә аны алыгыз моннан.

Котылдым Сәхи агайдан, тәки тыңлады төрмә начальнигы сүземне. Әмма мине башта утырган ялгыз камерага түгел, яңадан ике кешелек камерага керттеләр.

Яңа камераның бусагасын атлавыма алдыма зур борынлы, ияген, яңакларын кую кара сакал баскан кырык-кырык биш яшьләр тирәсендәге әрмән тибындагы кеше килеп басты.

— Мине сатарга сине махсус керттеләр бит монда, шулаймы? Сат, бөтен эчәк-бавырларым белән сат, мин каршы түгелмен. Монда күп керделәр инде синең кебекләр, тик рәт чыгара алмадылар. Ялгыз утырудан туйдым, инде өч атна үзем генә идем, син кем булсаң да, безгә икәү күңеллерәк булыр,— диде ул миңа, зур моңсу күзләрен ялтыратып.— Мин — Геваргиз. Геваргиз — фамилиям, исемем — Икир. Бу төрмәдә тугызынчы аемны утырам. Тагын күпме тотарлар, белмим. Сталинны үтерергә җыенуда гаеплиләр мине. Казанда торып Мәскәүдә бихисап кешеләр саклаган бәндәне ничек үтерим ди инде? Үзең уйлап кара, мин — Казанда, ул — Мәскәүдә, ассириялеләр — ахмаклар, дия торганнардыр. Без — совет подданныйлары түгел, шуңа совет хөкүмәтенә, Сталинга дошманмы? Булмый торсын! Ассирияле ни, урыс ни, татар ни, грузин ни — алла өчен барыбыз да тигез. Каннарыбыз гына төрле. Тикшерүчемә, Сталин, вакыты җиткәч, мин үтермәсәм дә үләр, берәү дә

дөньяга мәңгегә килми, дикоем ярамады. Берәүләр азрак, икенчеләр күбрәк яшиләр, аерма шунда гына. Кешене купме яшәтү — алла эше. Йөзгә тикле яшәсен мыеклы грузин, жәл түгел. Аңа үпкәм булса икән. Итеген чистарттырып ялтыраттыргач, акча бирми китмәде бит ул миңа. Андыйлар аз булдымы? Мин юаш, тыйнак адәм, хәтта аларның берсенә дә үлем теләмәдем...

Камера хуҗасы каршыма баскан килеш туктаусыз такылдады, мине ишек катыннан түргә үткәрү башына килмәде. Бу агайның шариклары йә тулмас, йә, киресенчә, берничәгә артыктыр, дип уйладым ирексездән. Ярый әле ишек артындагы надзиратель ярдәмгә килде. Ул:

— Буре күзен капламагыз, китегез ишектән! — дип кычкырды.

— Пажалысты, пажалысты, начальник, китәбез синең кадерле волчогыңнан, күзең атылып чыкканчы күзәт безне,— дип мыгырданды Геваргиз үз алдына.

Ассирияле?.. Андый милләт вәкилләре дә бармы икәнни әле дөньяда?..

Мин, кулымдагы әйберләремне асты өскә әйләндерелеп капланган табутка охшаган буш ятакка ташлап, шулар өстенә утырдым.

Борынгы ассириялеләр турында минем кайбер нәрсәләрне укыганым бар бит. Кече Азия, Мессопотамия үзәнлеге, Тигр һәм Евфрат елгалары, Ниневия шәһәре, шумерлар, сугышлар, зиннәтле сарайлар, чөй язмалар... Тукта, ничек соң әле ниндидер ассирияле безнең заманда Казанда бу төрмәгә килеп эләккән?.. Ассирияле һәм мин... Бу мөмкинме? Юк, юк...

— Иркенләп сөйләргә дә бирми гуталин авыз, бүре күзен капламагыз, ди, бәхеттән мәхрүм ике тоткынның бер-берләре белән очрашуларын теләгәненчә күрми калудан курка. Камера — сәхнә, без — артистлар бит аңа. Безнең мондагы мескен тормышыбыз, көндәлек газапларыбыз театр белән бер ул күзле букәннәргә. Сары йортта да шулай. Анда да диваналар тормышы түләүсез спектакль ул этләргә. Атаклы артистка тиң мин монда, сары йортта да тугыз айда инде өч тапкыр гастрольдә булып кайттым. Тәңре үземә юмартлык күрсәтеп, сәламәтлектән генә мәхрүм итмәсен... Дөньяда сәламәтлектән дә кыйммәтлē нәрсә юк...

Камерадашым мин кергәннән бирле өзлексез такылдый. Ул туктаусыз лыгырдавы белән мине аз арада да туйдырырга өлгерде. Ассирияле, сары йорт, театр... Акылы зәгыйфьтер аның. Психик авырудыр ул. Сары йортка өч тапкыр гастрольгә барган, имеш... Нигә ирекка чыгармыйлар икән ул мескенне?..

— Минем аяк киемнәре төзәтү һәм чистарту будкам Бауман урамында зур театр янында. Бәлки иректә чакта очрашканбыздыр да әле, бәлки миннән ботинкаларыңны яки итекләреңне чистарттыргансың. Кемнәрнең генә аяк киемнәрен чистартмадым инде мин үз гомеремдә! Узган елның элеккесендә атаклы Рәшит Бейбутов Казанга гастрольләргә килгәч, үзенең искиткеч матур туфлиләрен бүтән кешедән түгел, миннән чистарттырды. «Яле, якташ, ялтырат туфлиләрне, нурлар уйнатып күзләрне чагылдырсыннар, буш итмәм»,— ди бу. Мине әрмәнме, әзербәйҗанмы дип уйлады, безне күпләр Кавказ кешеләренә санйилар. Бөтен сәләтемне җигеп ялтыраттым атаклы җырчының туфлиләрен. Шуннан соң үземнең эш кирәкяракларымны җыештыра-җыештыра, аршин мал алан, хожу по дворам, дип сузып җибәрдем. Бейбутов миңа кушылып җырны күтәреп алды. Аның урамда гуталинчы Геваргиз белән җырлавын ишетеп, яныбызга әллә ничаклы халык җыйналды. Җырлап туктагач, тавышың матур синең, җиңел җырлыйсың, молодец, дип мактады. Мин синең белән, якташ, сәхнәдә дә парлап җырлаудан тартынмас идем, диде. Аннары кесәсеннән шыгырдап торган өр-яңа кызыл утызлык чыгарып миңа тоттырды. Мә, хезмәтең өчен дә, җырың өчен дә, ди. Мин тешем-тырнагым белән каршы килдем акчаны алмаска, ә ул, үпкәлим алмасаң, якташ, валлаһи үпкәлим, дип утызлыгын минем түш кесәмә тыгып, елмаеп китеп барды. Бейбутов биргән утызлыкны миннән безнең җырлаганны тыңларга туктаучыларның берсе йөз сумга сатып алырга теләде, сатмадым, өйгә алып кайтып пыяла астына рамга куйдым. Ул хәзер дә стенабызда эленеп тора...

Геваргизның, ничек теле армыйдыр, туктаусыз сөйли. Тыңлыйммы аны, тыңламыйммы — аңа барыбер. Минем башымда аның үзен ассирияле дип атавы бутала. Татарстаннан ерактагы Тигр һәм Евфрат елгалары арасында урнашкан борынгы Ассирия дәүләте турында белгәннәремне исемә төшерергә тырышам. Әмма камерадашымның өзлексез тәтелдәве миңа хәтеремдә казынырга комачаулый.

— Сиңа кадәр бу камерада минем белән бер Кырым татары утырды. Кырым татарларын, оккупация вакытында фашистларга булышуда гаепләп, 1944 елның маенда Кырымнан сөргән булганнар икән. Кеше башына уналты килограмм әйбер алырга рөхсәт иттеләр, шул уналты килога киемнәр аласыңмы, ашамлыкмы, анарда, безне туган җиребездән аеручыларның гамьнәре булмады, ашыктырдылар, ди. Кырымда татарлардан берәүне дә калдырмадылар, картлар, карчыклар, хатын-кызлар, бала-чага, яшьләр — барысы сөрелде. Безнең авыл кешеләре төялгән эшелонны ни өчендер башта Мари урманнарына китереп бушаттылар. Күпме кеше кырылды анда, әйтергә имәнгеч, мин үзем шунда, бөтен якыннарымны югалтып, ялгызым калдым. Хәсрәтемнән үзем дә үләргә теләдем, булмады. Аннары, күпмедер үткәч, исән калганнарыбызны Урта Азиягә озаттылар. Анда баргач, күп гасырлар буена ата-бабаларыбызга гүр тынычлыгы биргән туган җирләребездән сөрелүчеләр бер Кырым татарлары гына түгел икәнен күрдек. Корееләләр, калмыклар, чеченнәр, ингушлар, балкарлар, Идел буе немецлары да туган җирләреннән куылган булып чыктылар, диде ул офтанып. Бу камерада берничә көн утырды ул татар. Фамилиясе Әлимов аның. Мари урманнарында җирләнгән якыннарының каберләрен рәтләргә, өсләренә кулыннан килгәнчә һәйкәл торгызырга дип Үзбәкстаннан килгән булган. Бәхетсезгә җил каршы диләр, тотканнар моны Казанда, ясыйсы һәйкәле өчен цемент юнәтеп йөргәндә документларын тикшергәннәр. Аларның паспортларында сөргендә дигән махсус билге бар икән. Нигә син сөрген урыныңнан рөхсәтсез киттең, дип бәйләнгәннәр моңа. Хәзер инде, син Казандагы хәрби заводлар турында мәгълүматлар җыярга махсус килгәнсең, ярдәмчеләрең кем, Казанда кемнәр белән очрашырга, алда нәрсәләр эшләргә тиеш идең, дип теңкәгә тиયәләр, ди. Тууым хәерле сәгатькә туры килмәгән, бәхетсез мин, бәхетем булса хатыным, өч балам, энем, әтием һәм әнием белән бергә үлгән булыр идем, бүген бу таш капчыкта ут йотып утырмас идем, дип өзгәләнә мескен... Әйт әле менә син, мин мондагылар уйлаганча дошман булыйм ди, шуңа таянып Казандагы бөтен ассирияләләрне картын-карчыгын, баласын-чагасын, ирләрен-хатыннарын, егетләрен-кызларын, сез Геваргиз белән бер милләттән, сез — дошманнар, сыпыртыгыз сөргенгә, дисәләр, дөрес булырмы? Бүтән бер генә илдә дә эшләнми бит андый башбаштаклык, ә дөньяда иң гуман ил саналган Советлар Союзында эшләнә. Кем уйлап чыгарган икән моны ә?.. Җавап бирмисең? Мыеклы Газраил — Сталин уйлап чыгарган аны. Ник йөзең чытасың, дөрес әйтмимме әллә? Ялгышсам төзәт, аңлат мин наданга. Әмма мин сүземнән кайтмаячакмын. Советлар Союзына кем хуҗа? Халыкмы? Булмый торсын! Сталин хуҗа. Ул әйткәнгә кем каршы килә ала? Берәү дә каршы килә алмый. Сталин ни теләсә, шуны эшли. Ник син авызыңа су капкан шикелле ләм-мим сүз әйтмисең? Телсез түгелдерсең бит? Сөйлә үзең турында. Сине дә монда чибәрлегең өчен утыртмаганнардыр, шәт? Их, егет, егет, котыңны алганнар синең, хәзер син хәтта үз шәүләңнән дә куркасың булыр. Алда яшисең бар бит әле. Колагыңа киртлә, хәтернең якты тәрәзәләре генә түгел, караңгы ярыклары да бар. Син кайчан да булса якты хәтер тәрәзәләреңнән үзеңнең үткәндәге батырлыкларыңа караганда аның караңгы ярыкларыннан өркәк тараканнар күк бүгенге куркуларың да баш төртерләр. Ул чакта син үз-үзеңнән җиренерсең. Бу сүзләремне дә колагыңа киртләп куй. Еллар үткәч, хәтер хәзинәңне барлаганда бу сүзләремә юлыкк̌ач, кара, ассирияле Геваргиз тәки хаклы булган бит, хәерсез, диярсең...

Дөрес утырткannar монда бу бәндәне, дип уйладым мин камерадашым Сталинга тел тидергән вакытларда. Ул үзе бер яктан хаклы да кебек. Кы-

рым татарлары турында дөрес әйтә такылдык. Тулы бер халыкны яшен, картын җинаятьче итеп туган төбәгеннән каядыр җәһәннәм астына сөрү гаделлекме? Һич юк. Берни белән дә аклап булмый торган кыргыйлык, кыргыйлык кына түгел вәхшилек ул. Кырым татарлары гынамы? Алардан тыш тагын дистәләп халык көтүдәге терлекләр кебек куылуда бит. Иректә чакта бу нәрсә берничә тапкыр колагыма кергән иде, аңа илтифат итмәскә тырыштым. Монда Геваргиз аларны Сталинга илтеп тоташтырды. Бу турыда сөйләү түгел, уйларга да куркыныч...

Камерадашым, беравык сөйләвеннән туктап торгач, миңа:

— Син үз телеңне яхшы беләсеңме? — диде.

Бу сорау мине гаҗәпләндерде. Аның ана телемне белү-белмәвемдә ни эше бар?

— Нигә мин аны начар белергә тиеш?

Геваргиз көлде.

— Сез — татарлар телегезне дә, милләтегезне дә, гореф-гадәтләрегезне дә яратмыйсыз, шуңа әйтәм.

Менә сиңа мә!.. Кызык кеше бу ассирияле.

— Сез хаклы түгел,— дидем, җавапсыз калуны яхшысынмыйча.

— Хаклы, бик хаклы,— дип эләктереп алды сүземне камерадашым,— күбегез бер-берегез белән дә үз телегездә сөйләшергә тартынасыз. Тугач кушылган исемегезне урыслаштырасыз. Милли киемнәрдән йөрүчеләрегез бармак белән генә санарлык. Казан елдан-ел үз йөзен югалта, әллә ул татар шәһәре, әллә урыс шәһәре — үзенчәлеге бетә бара.

— Ялгышасыз, иптәш, телебез дә, үзенчәлегебез дә, гореф-гадәтләребез дә саклана безнең.

— Электән сакланып калган нәрсәгез — бер сабан туегыз гына. Сугышка кадәрге Казанны күрсәтер идем мин сезгә. Бүгенге татарлар белән ул чактагы татарлар — җир белән күк арасы.

— Юк, мин сезнең белән килешмим,— дип каршы төштем Геваргизга.— Безнең үз республикабыз, үз культурабыз, галимнәребез, язучыларыбыз, рәссамнарыбыз, артистларыбыз бар. Ә сезнең торырга үз илегез дә юк бит, безгә, үз-үзләрен хөрмәт итми торган татарларга килеп сыенгансыз.

Камерадашым минем сүзләремнән кабынып китте.

— Үз илебез юк, анысы дөрес. Ләкин без аңа карап туган телебезне дә, борынгы гореф-гадәтләребезне дә онытмыйбыз. Без борынгы бабаларыбызга турылыклы. Сез татарлар монда узган тарихыгызны гына түгел, хәтта бишенче бабагызны да белмисез. Сез менә ничәнче бабагызны беләсез? Алар кем булганнар һәм ничек көн күргәннәр, нәрсәләр эшләгәннәр?

Мин җавап бирмәдем. Камерадашымның шелтәсе урынлы. Әти ягыннан да, әни ягыннан да мин бишенче бабамны гына түгел, өченче бабамны да аннан-моннан гына беләм. Алар кем булганнар, нәрсә белән кызыксынганнар, нәрсә эшләгәннәр — ул турыда уйлау гамемә дә кермәде. Халкыбыз тарихын беләмме? Җүнләп белмим. Борынгы Ассирия турындагы мәгълүматларым үз төбәгебез турындагы мәгълүматлардан күпкә тирән...

Камерадашымның җавабымны көтеп хәйләкәр елмаюы ачуымны чыгарды. Үзе, үзе беләме икән ул туган телен, бабаларын, үз халкының тарихын, дип уйладым, үртәлеп.

Геваргиз сорауларыма ашыкмый гына җавап бирде.

— Без телебезне онытмадык. Советлар Союзында хәзер егерме меңгә якын ассирияле бар, без һәммәбез дә үз телебездә чатлатып сөйләшәбез. Яшьләребез үз милләтебез кызларына өйләнәләр, бездә кан катнашы бөтендәй юк диярлек. Үземнең ата-бабаларымны белүемә килгәндә, мактанып әйтмим, мин аларны унҗиденче буынга кадәр санап чыга алам. Бабаларымның нәрсә эшләгәннәре дә, кайларда яшәгәннәре дә, кемнәр белән аралашканнары да миңа мәгълүм. Аны ике кызым белән улым Даниэль дә беләләр, мин аларга ерак һәм якын бабалары турында өзлексез тукып торам. Бабаларым йөзгә кызыллык китерерлек яшәмәгән, гадел һәм тырыш кешеләр булганнар. Борынгы Ассирия тарихы да миңа, азмы-күпме таныш.

Үз тарихын оныткан халыкның киләчәге караңгы, ул кармаланып бара, яшәми, тик тереклек кенә итә, дия иде миңа әти. Һәр халыкның...

Ишектә ачкыч борылганы ишетелгәч, камерадашымның сүзе бүленде.

— Прогулкага чыгыгыз! — диде безгә надзиратель.

Мин прогулка мәйданына чыккач та, аннан яңадан камерага кергәч тә Геваргиз әйткән, үз тарихын оныткан халыкның киләчәге караңгы, ул аңа кармаланып бара, ул халык яшәми, тереклек кенә итә, дигән сүзләре турында уйландым. Беренче карашка тилемсә генә кеше күк бу Геваргиз, әсөйләгәннәре төпле, мәгънәле. Бәлки ул юри тилемсә булып кыланадыр?..



## Җиденче бүлек

### 1

Өч көннән соң капитан Горшенин мине сорау алырга тагын чакыртты.

— Уйларга сезгә ярыйсы ук озак вакыт бирдем, акылыгызга килгәнсез инде, шәт? — дип каршылады ул мине урындыгына ярым яткан килеш папирос пыскытып.

— Сездән аерымлы буларак, үземне акылым зәгыйфьләнгән итеп исәпләмим мин, Семен Андреевич. Теге көнне сезгә бер соравыгызга да җавап бирмәячәгемне әйттем, юкка чакыргансыз, безнең арада бернинди дә бәйләнеш булырга мөмкин түгел. Мин тикшерүчемнең башка кеше булуын телим.

Капитанның чырае чытылды.

— Бу нигезсез теләгегез нәтиҗә бирмәячәк, Кадыйров. Сез яхшылыкны аңламыйсыз, карышасыз, димәк?

— Минем эшне башка кеше тикшерсен, сез гадел түгел, үз сүзегез генә сүз.

— Чит йортка кеше үз уставы белән килми, дигән әйтем сезгә таныштыр, монда без хуҗа. Һәр гаепләнүче үз таләпләрен куя башласа, монда безнең ни хаҗәтебез кала?

— Сез миннән сорау алганда прокурор катнашсын, мин сезгә прокурордан башка җавап бирмәячәкмен. Сез тагарга тырышкан җинаятьләрне үз өстемә ала алмыйм мин.

Горшенин, өстәле артыннан чыгып, арлы-бирле йөреп алды.

— Сөттән ак, судан пакь булып кыланмагыз, сезнең кулга алынганга кадәрге һәр адымыгыз безгә яхшы таныш.

— Таныш булгач, нигә миңа әллә нинди гаепләр ягарга тырышасыз соң?

— Сез әле яшь кеше, бөтен тормышыгыз алда, без сезнең эшләгән җинаятьләрегезне танып, дөрес юлга басуыгызны телибез.

— Минем сез уйлаганча җинаятьләр эшләгәнем дә, ялгыш юлга басканым да юк.

— Сез милләтче дә түгелме?

— Түгел.

Капитан тирән итеп көрсенде.

— Күзгә карап ялганлыйсыз бит, Кадыйров. Менә бу фотоны карагыз әле, кайда һәм кемнәр алдында нотык сөйлисез монда? — Горшенин үз алдында яткан зәңгәр папкадан дәфтәр бите зурлыгындагы фоторәсем чыгарып, миңа сузды.— Менә килеп карагыз да, алдашмыйча гына әйтегез, качышлы уйнавыгыздан гарык мин.

— Мин үземне башка тикшерүчегә тапшыруыгызны, миннән баш тартуыгызны таләп итәм, таләбемә нигә колак салмыйсыз?

— Житәр, чәйнәмәгез бер балык башын, сорауга җавап бирегез. Йә...

Фотода мин үземне бәйрәмчә бизәлгән Яңа ел чыршысы фонында кулыма мөлдерәмә тутырып шәраб салынган рюмка тотып, нәрсәдер әйтергә авызымны ачып басып торуымны күрдем. Подлужная урамында Яңа елны

каршылау мәҗлесендә төшерелгән ич бу. Объективка туп-туры карап торам. Анда берәүнең дә фотоаппараты юк иде бугай бит, кайсы ничек төшереп алган мине?..

— Бу фото Подлужная урамында быелгы Яңа елны каршылау мәҗлесендә төшерелгән. Аны төшергәндә нәрсә сөйләвемне әйтә алмыйм, күренеп тора, мәҗлестәге иптәшләрне Яңа ел белән тәбрикләп, аларга бәхетшатлыклар телим булыр.

Капитан Горшенин, иреннәрен ямьшәйтеп, башын чайкады.

— Ялганларга ничек тартынмыйсыз сез, просто гаҗәп. Ул мәҗлестә катнашкан Солтанов белән Аитов бөтенләй башка нәрсә әйтәләр бит. Бәлки сез ул егетләрне дә белми торгансыз?

— Нигә белмим, беләм. Алар икесе дә студентлар, Солтанов юридик институттан, Аитов төзелеш инженерлары институтыннан.

— Браво, браво, хет бер соравыма дөрес җавап бирдегез. Ярый, эмоцияне куеп торыйк, дәвам итегез, кайчан һәм ничек таныштыгыз алар белән? Бер-берегезгә мөнәсәбәтегез ничек иде?

— Мин аларны беренче һәм соңгы кат шул Яңа ел кичәсендә очраттым. Икесен дә якыннан белмим.

— Ул мәҗлескә сезне дә, аларны да кем чакырган иде?

— Мине анда үзебезнең институтның тарих факультеты студенты Мөхит Капкаев алып барды, аларның анда ничек килгәннәрен белмим.

— Сез кичәдә катнашкан кызлар белән электән үк таныш идегезме?

— Кайберләре белән таныш идем.

— Ул мәҗлестә катнашкан кызлар башка институтта укыйлар бит, алар белән ничек таныштыгыз?

— Аларның да институтлары җир читендә түгел, Казанда ич. Егетләрнең кызлар белән ничек танышуын белмисезмени?

Капитан фоторәсемне миннән алып папкага яшергәч, тагын папирос кабызды.

— Сез ул Яңа елын каршылау мәҗлесендә русларга каршы агитация алып баргансыз, ничек булды ул, шуны сөйләгез.

Мин урынымнан сикереп тордым.

— Бу нинди уйдырма тагын? Сез миңа ташлаган гаепләр берсеннән-берсе мәгънәсезрәк бит, аңлыйсызмы шуны?

— Утырыгыз урыныгызга, аякларыгызны талдырмагыз. Милләтчелек асылыгызны сез берничек тә яшерә алмыйсыз инде, чибәр егет. Бу — факт. Алда телгә алынган Солтанов белән Аитов сезнең турыда, кичәдә Кадыйров безнең барыбызны да рус җырларын җырлаудан тыйды, моны мәҗлестә катнашкан унҗиде кешенең унҗидесе дә раслый алалар, дип күрсәттеләр. Димәк, аны сез үзегез дә раслыйсыз дигән сүз бу. Йә, моны ничек кире кагарсыз?

— Солтанов белән Аитов телгә алырга да лаек түгел нәрсәне бозып күрсәтәләр. Һич башыма сыймый, мәҗлестә мине фотога төшерү кемгә кирәк булган? Сез миңа ташлаган гаеп тә, мин нәрсәдер әйткәндә төшерелгән фото да кемнеңдер алдан уйланган планы буенча эшәнгән ич.

— Акыл сатмагыз, сорауга җавап бирегез.

— Яхшы..Яңа елны каршылау мәҗлесендә без, Солтанов белән Аитов әйткәнчә, бөтенебез унҗиде татар җыйналдык, арабызда бер генә рус та, башка милләт вәкилләре дә юк иде. Анда теләсә нинди көйне өздереп уйный торган, бер дигән баянчы да бар иде. Мәҗлес буенча берөзлексез рус җырлары җырлады. Яңа елны каршылап бокал күтәргәннән соң, биеп арыгач, мин, әйдәгез үзебезнең татар җырларын да җырлыйк әле, алар да аһәңлелекләре, рухи сафлык, эчтәлек, тирәнлекләре белән рус җырларыннан аз гына да калышмыйлар бит, дидем. Моңа берәү дә каршы килмәде. Туган халкымның җырларын җырларга чакыруда мин бернинди гаеп тә күрмим. Без Совет Татарстанында яшибез, үз милли телебез, культурабыз, әдәбиятыбыз, сәнгатебез, ерак гасырларга барып тоташкан бай тарихыбыз бар. Халкыбызның башка милләтләр арасында абруе да бәхәссез. Мин туган культурамны, җырларыбызны, көйләребезне яратмаска, алардан йөз

чөерергә, тик рус культурасына гына табынырга тиешмени? Габдулла Тукайны без күп еллар халык шагыйре дип түгел, милли чикләнгән вак буржуа шагыйре дип йөрттек. Ә Тукай татарлар өчен генә түгел, Башка милләтләр өчен дә рус шагыйре Александр Сергеевич Пушкин кебек үк бөек шәхес. Ул үзе үк:

> Шигъре Лермонтов вә Пушкин — олугъ саф диңгез ул.
> Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул,

— ди.

Бәлки сез миңа Габдулла Тукайдан да йөз борырга тәкъдим итәрсез?

— Димәк, сез Яңа елны каршылау мәҗлесендә иптәшләрегезгә рус җырларын җырлауны тыюыгызны инкяр итмисез?

— Кичәдә эшнең ничек булганын сөйләдем ич сезгә, нигә үз сүзегез генә сүз сезнең Семен Андреевич?

— Сезнең дә үз бишегез генә биш бит, искәрәсездер?

— Төрмәдә сез түгел, мин утырам. Сезгә тырнак астыннан кер эзләү нигә хаҗәттер, белмим. Күпме генә тырышсагыз да мине совет хөкүмәтенә, Коммунистлар партиясенә дошман итә алмаячаксыз. Көнне күрә торып төн, төнне дә шулай ук көн дип булмый, юкка мәшәкатьләнмәгез, зинһар.

— Бәлки сез үзегезне төрмәдән бүген үк иреккә чыгарырга кушарсыз?

— Монда мин үз теләгем белән килмәдем, аны сез хәл итегез.

— Хәл итегез, имеш. Аңа атлыгып торсагыз, булышсагыз икән.

— Минем һәр адымым сезгә билгеле, дидегез ич, шулай булгач нәрсә комачаулый?

— Без икебез ике телдә сөйләшәбез. Артык сүз куертмыйк, мин арыдым, мәгез беркетмәне укыгыз да кул куегыз.

Мин капитан Горшенин тутырган сорау алу беркетмәсен җентекләп укып чыктым, анда, Солтанов белән Аитов ташлаган гаепләрне мин тулысынча таныйм, дип язылган иде. Беркетмәгә кул куюдан катгый рәвештә баш тарттым.

— Сволочь сез, хәтта үз сүзләрегездән үзегез үк танасыз,— дип акырды капитан, минем ул корган капкынга эләгергә теләмәвемә үртәлеп...— Сытарга, таптарга, изәргә кирәк сезнең ише нәҗесләрне!..

— Ә намуслары тапсыз кешеләрдә дә тик җинаятьчеләрне генә күрүче сезне судсыз атарга кирәк, Семен Андреевич!

Тикшерүчем, яр туфрагына судан чыгарып ташланган балык күк авызын киереп ачып, миңа текәлде. Аннары тотлыга-тотлыга:

— Мин сезне Солтанов һәм Аитов белән кара-каршы очраштырам, анда боргалана алмассыз,— диде.

— Бик яхшы, ул очрашуга прокурорны да чакырырга онытмагыз, юкса мин ачлык игълан итәчәкмен.

Капитан мыскыллы көлде:

— Әйдә, әйдә, кыланып карагыз...

## 2

Тикшерүче яныннан төшеп камера бусагасын атлауга, каршыма Геваргиз килеп басты.

— Йә, саттыңмы? — диде ул, мыскыллы елмаеп.

— Саруымны кайнатма әле, Геваргиз, болай да күңелем болганып тора! — дидем үз урыныма үтеп.

Камерадашым, ишек янында бераз тулганды да, парашага утырды.

— Сатсаң саттым, сатмасаң сатмадым диген, турысын әйт, аның гаебе юк. Без монда банкага салынган үрмәкүчләр белән бер. Кем кемне...

— Син мине үз аршының белән үлчәмә, Геваргиз.

— Минем аршыныма нәрсә булган? Йә, әйт, нәрсә булган? — Мин — мин, син — син. Монда һәр кеше үз шкурасын кайгырта.

— Әгәр син сату, сатмау турында тагын да лыгырдасаң, ипи шүрлегеңнең җимереләсен көт тә тор.

— Ипи шүрлеге миндә генә түгел, синдә дә бар ич ул. Кем кемне...

Мин уң кулымның күрсәткеч бармагын чигәмә терәп боргаладым:

— Дивана син, Геваргиз.

Камерадашым гарьләвемә җавап кайтармады, эшен бетереп парашадан торгач, яныма килеп утырды.

— Мин сиңа менә бер нәрсә сөйлим, тыңла әле.

— Тыңламыйм, борчыма мине, хет ярты гына сәгатькә булса да телеңне тыя аласыңдыр бит син?

— Алам, кәнишне. Мин атна, ай буе ләм-мим сүз әйтми дә тора алам. Син минем хатын күк, ул өйдә, тиктормас телеңне төбеннән шарт итеп кисеп алып эткә атар идем, дип гомер буе теңкәмне корытты, монда — син...

Шулчак ыңгырашып ишек ачылды һәм балык күзле старшина бусага аша безнең янга үтеп лыгырдык камерадашыма күрсәткеч бармагын төбәде.

— Фамилияң?

— Геваргиз.

— Киттек.

Камерада үзем генә калгач, иркенләп сулу алдым. Гаҗәп, минем эшем, юеш көнне таудан тәгәрәгән кар йомарлагы күк, үсә бара. Инде капитан Горшенин миңа милләтчелек ямавы да ябыштырырга азаплана. Институтта курсташларымны янәсе милләтче язучы Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен өйрәнергә чакыруда гаепләп, партиядән чыгардылар. Болар чылбырдагы бер-берләренә тоташкан һәм бер-берләренә охшаш боҗраларны искә төшерә бит. Милләтче?.. Бәлки мин, чыннан да, җисемем белән милләтчемен? Институтта тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыдым, кулга алынганда тумбочкамнан һәм матрац астыннан репрессияләнгән татар язучыларының бер кочак тыелган китапларын таптылар. Киләчәктә капитан Горшенин, нигә ул зарарлы китапларны сакладың, аларны кемнәргә укырга бирдең, дип бәйләнәчәк. Аны чүп өстенә чүмәлә дими ни дисең тагын? Телебезнең һәм культурабызның бетүгә баруын белә торып, нигә укыдым мин татар теле һәм әдәбияты бүлегендә? Башка факультетларга да кереп укый алган булыр идем бит югыйсә. Күрәчәгең тигәнәк күк чабуыңа ябышып йөри, дип юкка гына әйтмәгән булган Зада апа. Иптәш Сталин ВКП(б)ның XVI съездында милли телләрнең һәм милли культураларның бетәчәге, аларның бер гомумтелгә һәм бер гомумкультурага берләшәчәкләре турында бик ачык әйткән ич. Хәзер шуңа барабыз. Әмма ике йөздән артык төрле төсле ташлардан торган сокландыргыч мозаикадан бер котсыз монолит ясауга охшый түгелме соң бу? Юк, юк, иптәш Сталин хаклы. Хаклы... Ләкин йөзләгән балыкчы көймәләреннән корамаланган линкорга охшаячак ул культура. Балыкчы көймәләрен корамалап сугыш корабыңа әверелдереп булмаган шикелле, бер гомуммонолит тел дә, бер гомуммонолит культура да тормышка ашмас буш хыял түгелме? Бихисап яфраклары булган бер агачта, бер агачта гына түгел, урмандагы агачларда да бер-берләренә охшаган, бер-берләрен кабатлаган ике яфрак юк, ә монда күп гасырлар дәвамында формалашкан тере телләр, кабатланмас культуралар лабаса...

## 3

Геваргиз тикшерүчесе яныннан минем кебек сөмсере коелып түгел, ничектер канатланып, җанланып төште.

— Үлемгә хөкем ителгән бәндә шикелле күз көеге булып, хәсрәтләнеп утырма әле. Монда бер син генә түгел, мин дә бар, кыяфәтең ачуымны чыгара, нервларымны кузгата,— диде ул, каршыма утырып.— Мин өч папирос алып төштем, мә берсен, тарт, күңелең ачылып китәр.

— Рәхмәт, тартмыйм.

Камерадашым мине сул беләгемнән тотып үзенә каратты:
— Тарт, әйдә. Бу папиросларда синең дә өлешең бар. Сине сату бәрабәренә бирделәр аны миңа,— диде ул шомырт-кара күзләрен сәер ялтыратып.— Син мине сатарга өлгергәнче, мин сине алданрак сатыйм дидем.
Мин Геваргиз шаярта, үзенчә мине ирештерә дип уйладым.
— Сатсаң, бәям өч папирослык кына булдымыни? — дидем.
— Өч папирос ул задаток кына, үзләренә булышканым өчен алар мине иреккә чыгарырлар, менә нинди бәягә саттым мин сине. Сиңа кадәр теге Кырым татарын да саткан идем инде.
— Минем турымда нәрсәләр сайрадың соң? Син бит мине бөтенләй белмисең дә.
— Беләм, милләтче син — урысларны яратмыйсың. Сиздем мин сине!
Мин өстәлдән яртылаш сулы алюмин чәйнекне алып, көч белән камерадашымның башына оруымны сизми дә калдым.
Ул куллары белән башын тотып кыргый тавыш белән:
— Коткарыгыз, үтерә, үтерә мәлгунь! — дип бөтен төрмәгә сөрән салды.
Шундук ишектәге кормушка тәрәзәсе шартлап ачылды:
— Нәрсә булды, ник дөнья сасытасың?
— Менә ул... башымны ярды. Алыгыз аны бу камерадан, зинһар, үтертмәгез!..
Надзирательләр кереп ассирияле камерадашымның канлы ярасын бәйләгәч, мине карцерга төшереп яптылар.

## Сигезенче бүлек

### 1

Карцерның үзе һәм аның чирканыч исемне безгә кайсы илдән һәм кайсы телдән кергәндер, әйтә алмыйм, аның белән кызыксынганым булмады, хәзер ул котсыз сүзне ишетсәм, елның кай вакытында да тәнемә салкын йөгерә. Хәтеремдә ирексездән таш идәнле, авыр тимер ишекле, гүр кебек караңгы һәм тынны буа торган тынчу һавалы тар баз-бүлмә яңара. Карцер — тоткыннарны рухи һәм әхлакый яктан җәзага тарту урыны. Минемчә, аны урта гасырларның иң кансыз инквизиторлары уйлап чыгарган булгандыр. Егерменче гасыр уртасында теләсә нинди кабахәтлекләргә дә сәләтле вәхши немец фашизмын тар-мар иткән социалистик Ватаныбызда залим патша Явыз Иван опричникларының үз дошманнарыннан үч алу һәм мәсхәрәләү урыны саналган җәза бүлмәләренең сакланып калуларын һәм аларның электәге үк имәнгеч вазифаларын әле дә үтәүләрен мин башыма сыйдыра алмыйм.
Артымда тимер ишек шомлы шалтырап ябылгач, дегет күк кое караңгыда мин нишләргә белми аптырап, озак басып тордым. Аннары кулларым белән кармаланып утырыр урын эзли башладым. Таш капчыкта, аны башкача атарлык түгел иде, мин авыл апаларының капкачлы күмер савытларын искә төшергән сасы парашадан башка нәрсәгә юлыкмадым. Монда бер йә ике кешелек камералардагы төсле стенага беркетелгән кечкенә өстәл дә, бәләкәй утыргыч та, көндезгә стенага күтәреп бикләнә торган примитив карават корамасы да, хәтта тимер челтәр артына яшерелгән, яктысы миеңне кайнатырлык өч йөз шәмле катыйль лампочка да юк иде.
Мин, стенага бәрелмәс өчен кулларымны алга сузып, арлы-бирле йөренергә тотындым.
Ахмак, чын-чынлап ахмак бәндә бу ассирияле Геваргиз. Ул, камерадашларын фаш итәргә булыша да, иреккә чыга, имеш. Ошаклык шөгылен ул инде монда күптән үти булыр, әнә, Кырым татарын да саттым, дип мактанды, тинтәк. Үзе исә, мине камерасына китереп керткәч, каршыма

басып: «Мине сатарга бирегә сине махсус керттеләр бит, шулаймы? Сат, бөтен эчәк-бавырларым белән сат, мин каршы түгел, монда күп керделәр инде синең кебекләр, барыбер рәт чыгара алмадылар»,— дип тезеп киткән иде. Бу аның үзенчә саклану чарасы булган күрәсең. Ә нигә ул минем өстемнән тикшерүчегә ошак ясап төшүен үземә ачыктан-ачык әйтте, яшермәде. Милләтчелектә гаепләнүемне ул каян белде икән? Капитан Горшениннандыр, мөгаен. Мине Геврагиз янына утыртучы да ул, димәк. Ассирияленең тикшерүчесе дә капитан Горшенинмы икән әллә? Нигә Геваргиздан «милләтчелегем»не кемгә «тишүен» сорамадым, башына тизрәк чәйнек белән тондырдым, ашыктыручы юк иде бит мине.

Нигә миңа тормышымда гел шундый ошакчы бәндәләр генә очрый? Риан, Бану Гыйбатовна, Солтанов, Аитов, менә хәзер — Геваргиз. Болары белгәннәре, ә белмәгәннәре күпмедер?!. Аларның кайсына комачауладым, кайсының юлын аркылы чыктым, белмим. Дөресен сөйләсәләр, гарьләнмәс идең хет, бер генә хак сүзләре дә юк ич...

Тукта, Яңа елны каршылау мәҗлесендә минем, милли җырларыбызны җырлыйк, дигән тәкъдимем кемнең эчен пошырды икән?.. Ничек барып эләккән идем әле мин анда? Көчләп диярлек Мөхит Капкаев алып барган иде. Зарифа көтә, ул сиңа күптәннән гашыйк, зинһар, алып кил аны, дип инәлде, дип ялганлаган иде җитмәсә. Баргач, Зарифа мине бар дип тә белмәде, бөтен мәҗлес дәвамында күңел өчен генә бер тапкыр да минем ягыма борылып карамады. Аитов белән чөкердәште, Аитов белән биеде. Мине Яңа елны каршылау кичәсенә алып бару Капкаев өчен кирәк булган, күрәсең. Зарифага узган ел ул үзе гашыйк иде. Мине монда килеп чагучыларның берсе шул Мөхит Капкаев түгелме икән? Капитан Горшенин миңа Солтанов белән Аитов турында әйткәч үк, ничек ул башыма килмәде? Менә дус дип йөр, якын ит кешене!.. Сугыш зилзиләсен үзем кебек үк исән кичкән һәркемне туганым кук күргәнгә, мин ул бәндәнең кемлеген абайламаганмын күрәсең.

Мин, йөрүдән туктап, ишек төбендә чүмәштем.

Бу җәһәннәм базында күпме утырырмын икән? Нишләп акыл ирешмәслек сәер, шәфкатьсез җир бу эчке төрмә — камераларында көнетөне күзләрне чагылдырып өчәр йөз шәмле катыйль лампочкалар келпи, ә карцерында җәһәннәм чокырындагы караңгылык. Акылдан шашу да озак түгелдер монда... Берни күрмәүче тома сукырларның хәле чын-чынлап аяныч икән. Мин дә хәзер аларга тиң. Сукырлар яктылыкның нәрсә икәнен гомерләре буе белмиләр. Яктылыкның ниндилеген аларга тел белән аңлату мөмкин түгел, алар аның тәэсирен, көчен, гаммаларын, гүзәллеген берничек тә сиземли алмыйлар. Бу безнең — күзле кешеләрнең — иксез-чиксез галәм бушлыгын күз алдыбызга китереп иңли, тоя алмавыбызга бәрабәрдер, мөгаен. Сукырлар, галәм бушлыгы, сиземләүләр, күзаллаулар нәрсәгә кирәк әле миңа монда? Бәлки мин үзем дә инде сукырдыр? Күзле сукыр...

Кинәт сул кулыма, әйтерсең, утлы очкын төште. Миң аякларыма басып уң кулым белән сул кулымның әрнегән җирен кыстым. Юеш. Нәрсә бу, әллә елан чактымы мине? Булмаганны! Кыш көне монда елан кайдан килсен, без Африкада түгел ләбаса. Елан чакмады, күсе тешләде кулымны. Күселәр, минут саен оятсызлана барып, аякларыма тия-тия чабышалар. Монда тагын да калсам, талап үтерә болар мине. Юашландыру күлмәге кидерсә кидерсеннәр, юеш карцерга ябылырга да риза, анда мондагыдан да яман түгелдер, дөбердәтим ишекне, нәрсә югалтам?..

Ишеккә биш минут чамасы өзлексез типтем, килүче булмады. Ишекне дөбердәтеп арыгач, туктап тыңлана башладым. Ник бер шылт иткән тавыш ишетелсен. Күселәр, аякларым белән тимер ишекне дөмбәсләвемнән курыктылар бугай, чабышудан, чыелдашудан туктадылар. Тирәмдә кабер тынлыгы, шомлы караңгылык. Бүгенем чирканыч, иртәгәм нинди булыр? Кулым каный, иртәгә кадәр тере калуым икеле...

Мин ишекне дөмбәсләвемне дәвам иттем. Озак дөмбәсләдем. Ниһаять, кемдер коридордан:

— Акылдан шаштыңмы әллә, чебен дулап тәрәзә ватамы? Кайда икәнеңне оныттыңмы әллә? — диде.

— Чыгарыгыз мине моннан, ябыгыз юеш карцерга, күселәр талый мине, кулым каный,— дидем ярсып.

— Ярар, син дигәнчә булыр, тик алдан ук килешик, үкенмә соңыннан.

— Үкенмәм.

Кулларымны юдырып ярамны йод сөртеп бәйләгәч, надзирательләр мине бер кешелек гадәти камерага яптылар. Шуңа гаҗәпләндем, минем урын-җир әйберләрем анда күчерелгән булып чыкты. Күселе караңгы карцердан соң үземне өстемнән тау төште кебек тойдым.



## 2

Көннәр үтә торды, түземсезләнеп көттем, капитан Горшенин мине Солтанов һәм Аитов белән кара-каршы очраштырырга чакыртмады. Бәлки, ул таләбемә колак салып, эшемне бүтән тикшерүчегә биргәндер, шуңа чакырмыйдыр, дип уйладым. Ләкин ялгыштым.

Капитан Горшенин утырган кабинетка мине яңадан февраль урталарында гына алып менделәр. Кысан тынчу камерадан соң саф һавалы иркен бүлмәгә аяк басу миңа сөрсү баздан котылып, хөрлеккә ирешү шикелле булды. Әнә ачык форточкадан электр чыбыгына ябышып аска сузылган өчдүрт карыш озынлыгындагы ялтыравыклы боз сөңгесе күренә, кечкенә генә көмеш кыңгырау чыңын хәтерләтеп, якында гына песнәк сайраганы ишетелә. Ашарына азык эзли, күрәсең. Тоткыннарны да җаннарын сакларлык кына тукландырган бу төрмә тирәсендә ул месркенкәй үзенә кирәк кадәр ашамлык табаламы икән? Табадыр, тапмаса, пинь-пинь-пинь дип шатлыклы сайрамас иде. Песнәк бәхетле, ул минем кебек читлектә түгел, ирektә, эзләгән азыгын бер җирдә тапмаса, бүтән җиргә оча ала.

Мине кабинетка китерткәндә анда капитан Горшенин каратут йөзле, метрдан аз гына калку буйлы яшүсмергә охшаган ниндидер өлкән лейтенант белән чайкала-чайкала шаркылдыйлар иде. Исәнләшүемә игътибар итмәделәр. Тикшерүчемнең, утыр, дигәнен көтмәдем, ишек катындагы табуретка үттем. Капитан белән өлкән лейтенант, эчләрен тота-тота, шаркылдауларын дәвам иттеләр. Шаккаттым, монда эшләүче кешеләр дә көлә беләләр икән ләбаса! Капитан Горшенинны әллә алыштырганнармы? Күзләремә ышанмыйм, ул бүген бөтенләй бүтән, бернинди ясалмалыгы калмаган, рәхәтләнә көлеп.

— Мин ирле чибәрләргә йөрмим, ирсезләрнең генә пружиннарын тикшерәм.

— Ирлеләрдән куркасың, димәк?

— Бер караватта өчәүләп яту кызык түгел бит.

— Ничек өчәүләп?

— Мин, ул, аның ире.

— Ә хатыныңны кая куясың? Хатының белән дүртәү буласыз ич!..

— Андый очракта хатынымны мин үземә ияртмим, балалар белән калдырам.

— Хәйләкәр син, хәйләкәр, Сема!..

Тормыштагы бөтен кызыклары аларның тик шул гына микәнни, дип уйладым мин. Капитан Горшенин хатыныннан качып ирсез чибәрләр янына йөри була. Алар белән ничек гәпләшә, нәрсә турында сөйләшә икән?

Эштән соң очрашырга килешкәч, өлкән лейтенант чыгып китте. Капитан Горшенин, кабинетында ялгызы калгач, гадәти хәленә кайтты: кашлары җыерылды, йөзе кырысланды, күзләрендәге җанлылык юкка чыкты. Минем бүлмәдә икәнемне белгәнен аның үз-үзен тотышы гына сиздерде. Хамелеон, чын хамелеон бу адәм, дигән уй узды башымнан. Тикшерүчем башта бик җентекләп уң кулының, аннан соң сул кулының бармакларындагы тырнакларын тикшерде. Аннары ашыкмый гына тәмәке кабызды. Бу

кеше дә эшлим дип исәплидер үзен, дидем күңелемнән аны тын гына күзәтеп. Ниһаять, өстәлендәге кәгазьләрен рәтләгәч, ул миңа төбәлде:

— Син минем башымны күпме әйләндерергә уйлыйсың, чибәр егет? Һәр нәрсәнең чиге барын беләсеңдер бит, ә?

— Без яңадан сингә күчтекмени, түрә әфәнде? Бел, мин синең белән бүтән сөйләшергә теләмим, озат мине камерама. Чибәр егет, имеш. Минем фамилиям бар. Синең белән минем кайдадыр дуңгызлар көткәнем дә, ирсез тәтәйләрнең караватын пружиналарын тикшерергә барганым да юк. Әйе, һәр нәрсәнең чиге бар, дөрес әйтәсең.

— Гаебемне таныйм, Кадыйров, үтенәм, гафу итегез, тәкәллефсез тонны миннән бүтән ишетмәссез, сүз бирәм. Әйдәгез, бер-беребезнең башын әйләндерми, әйбәтләп кенә сөйләшик...

— Мин түгел, сез баш әйләндерәсез, капитан. Эшләмәгән җинаятьләрне мин өстемә ала алмыйм. Кулны аяк дип булмый, шулай ук аякны да нормаль кешеләр кул димиләр...

Тикшерүчем калтыранган куллары белән өстәлендәге папкаларны бер урыннан икенче урынга күчерде.

— Сез һаман бер үк җырны җырлыйсыз.

— Тагын нинди җыр кирәк сезгә?

— Дөрес җыр, без теләгән җыр.

— Сез теләгән җыр өчен кемне хөкем итәрләр: минеме, сезнеме?

— Тел кашыдык, булды.— Капитан папиросын алдындагы төпчек савытына басып сүндерде.— Инде эшкә күчик. Колхоз строена яла ягуыгызны да аяк терәп танасызмы сез?

— Армиядән демобилизацияләнеп кайткач, авыл хатыннарының сабанга җигелеп җир сөрүләрен, кешеләрнең ачтан шешенүләрен күрүем колхоз строена яла ягумы?

— Аңлагыз, шуны очраган бер кешегә сөйләп йөрүегез советка каршы агитация ул.

— Ачтан шешенгән кешеләр, сабанга ат урынына җигелеп җир сөрүче хатын-кызлар совет кешеләре түгелмени? Биредә аларны үз күзләрем белән күргән мине түгел, ул кешеләрне шул хәлгә җиткерүчеләрне гаепләргә, менә идәнгә беркетелгән бу табуретка аларны утыртырга кирәк.

— Әлегә ул табуретта сез утырасыз, сез җавап бирегез.

— Мин бу урынны сатып алмадым, аны теләсә кемгә, хәтта сезнең үзегезгә дә саба итә алам.

— Телегезгә салынмагыз. Димәк, сезнең күргәннәрегезне Саттаровка сөйләгәннәрегез колхозларга да, совет строена да яла ягу түгел?

— Түгел, әлбәттә. Сез бүген дә кайсы гына районга кайтсагыз да авыл кешеләренең шәһәр кешеләреннән ярлырак яшәүләрен күрәчәксез. Бу мин уйлап чыгарган нәрсә түгел, бу — хакыйкать.

— Аңа сугыш гаепле.

— Сугыш Татарстан аша үтмәде.

— Ул бөтен ил аша үтте.

— Биш ел элек үтте. Авылдагы тормышны шәһәрдәге тормыш белән һич чагыштырып булмый.

— Нигә?

— Авыл шәһәрдән күпкә ярлырак яши, ул үзеннән элек шәһәрне тәэмин итә. Кешеләр хәзер колхоздан аңа борылып карарга куркып качалар, аларның бушка эшлиселәре килми.

— Нәрсә әйтергә теләвегез аңлашылды, хәзергә калдырып торыйк ул турыда.

— Сез теге көнне мине Солтанов һәм Аитов белән кара-каршы очраштырачагыгызны әйткән идегез. Алар очрашудан әллә баш тарттылармы?

— Алар Казанда булмадылар, каникуллар вакытында ял итәргә икесе дә авылларына кайтып киткәннәр иде.

— Аңлашылды. Минем дустым Мөхит Капкаевны да алар белән бергә монда чакыртырсыз, бәлки?

— Аның сезнең эшегезгә ни катнашы бар?

— Мин рус җырларын җырлауны «тыйган» мәҗлестә ул да бар иде бит.

— Монда кемне чакыру чакырмау — безнең эш, юк белән башыгызны авырттырмагыз.

— Кайгыртучанлык күрсәтүегез өчен рәхмәт, капитан.

— Хәзер сез, арабыздагы бу әңгәмәне онытып, Адольф Гитлерны Иосиф Виссарионович Сталиннан ничек өстен итеп куюыгызны, сөекле юлбашчыбызга ничек пычрак атуыгызны, аңа яла ягуыгызны хәтерләгез.

— Аңламыйм, ничек мин иптәш Сталинга яла ягыйм, ничек каннибал Гитлерны бөек даһидан өстен куйыйм? Кем әйтә аны? Акылыгыздамы сез?

— Борчылмагыз, акылымда мин. Ул турыда дустыгыз Риан Саттаров әйтә. Имеш, Гитлер авызын ерып гармун уйный, иптәш Сталин: «Настал мой последний денечек»,— дип җырлый.

— Ә-ә, аңлашылды, сүз листовка турында бара. Саттаров сезгә ялган сөйләгән. Берлинны алганда безнең авиация немецларга кан коюны туктатырга, капитуляция ясарга тәкъдим итеп, алар өстенә бик күп листовкалар ташлады. Анда бер листовкада иптәш Сталин гармун уйный һәм «Азат илелде туган Ватаныбыз, Гитлер дөмегә үзенең өнендә»,— дип җырлый, ә Гитлер, почмакка посып: «Настал мой последний денечек»,— дип шыңшый итеп сурәтләнгән иде. Аны мин үз күзләрем белән күрдем.

— Сез аны Риан Саттаровка нәкъ киресенчә сөйләгәнсез.

— Юк, киресенчә сөйләмәдем, яла яга ул. Батальоныбыз командиры майор Друков Берлин тирәсендә безнең авиация ташлаган ул листовканы күргәч, 1943 ел башында фашистлар Сталинград өчен барган сугышларда безгә ташлаган листовкаларында Гитлерны гармун уйнатып һәм җырлатып төшергәннәр иде, молодец, безнекеләр шуның үчен кайтардылар, фрицлар соклансыннар хәзер үзләренең фюрерларына, дип көлгән иде. Шуны әйтүемне бутый булыр Риан.

— Бутыймы икән?

— Алай дисәгез, кая сезнең логикагыз? Гитлер инде күптән юк, дөмекте, ә иптәш Сталин нинди авыр сугышта илне җиңүгә китерде, ярты Европаны фашизм коллыгыннан азат итте, яши! Сезнеңчә, Риан сөйләгәннәр дөрес, ә мин әйткәннәр ялган. Бу гаепләвегезнең ак җеп белән тегелүен үзегез үк күрмисезмени соң?

— Ярый, бу турыда да хәзер калдырып, тагын бер нәрсәне ачыклыйк. Чит илләрдәге тормышны, техниканы, шәһәр-авылларны, алардагы чисталыкны, культураны, юлларны да мактамадыгызмы?

— Сез үзегез сугыш вакытында һәм сугыштан соң чит илләрдә булдыгызмы соң, Семен Андреевич?

Тикшерүчем сагаеп, миңа төбәлде.

— Булмадым. Нәрсә әйтергә телисез моның белән?

— Берни дә әйтергә теләмим, болай гына сорадым, беләсем килде.

— Мин җавап бирдем, хәзер сез сорауга җавап бирегез.

— Сугыш вакытында һәм сугыштан соң үзем булган илләрдәге халыкларның көндәлек тормышлары, интереслары турында мин берни дә әйтә алмыйм, чөнки мин ул илләрнең халыклары белән аралашмадым, сөйләшмәдем. Моңа, беренче чиратта, рус һәм татар телләреннән кала башка телләрне белмәвем комачаулады. Аннары безнең өчен чит, ят тормыш мине кызыксындырмады да. Анда мин ул максат белән бармаган да идем. Чит илләрдәге техника мәсьәләсенә килсәк, күп кенә машиналарны анда мин гомеремдә беренче тапкыр күрдем. Алар яхшы булганнардырмы, начармы — әйтә алмыйм, техникадан хәбәрдарлыгым тракторны автомобильдән, автомобильне гади ат арбасыннан аера алудан узмый. Ник көләсез, алдашаммы әллә?

— Игътибар итмәгез, мин сезне дикъкать белән тыңлыйм, бүленмәгез.

— Шәһәр-авыллар, Польшаны исәпкә кертмим, Германиядә, Чехословакиядә, Венгрия һәм Австриядә сокланырлык. Алар искиткеч төзек, чиста. Урманнар анда шәһәр парклары кебек. Аларда бер генә имгәнгән яки корыган агач та, җирдә аунап яткан кечкенә генә ботак кисәге дә күрмисең.

Культура да бездәге белән чагыштырырлык түгел ул илләрдә. Шәһәрләр һәм авыллар урамнарында мин лаякыл исерек сүгенеп йөрүчеләрне дә, теләсә кайда егылып ятучыларны да очратканым булмады. Ә юллар безнең күрше илләрдә кем дә сокланырлык, аларны бездәге казылмалы, баткаклы юллар белән һич чагыштырырлык түгел. Шунысы бар, Германиядәге автобаннарны немецлар үзләре сузмаганнар, аларны Гитлер басып алган илләрдән куып китерелгән кешеләр — XX гасыр коллары төзегән.

Тикшерүчем урыныннан калкып, папирос кабызды.

— Җитеп торсын бүгенгә. Калганын киләсе очрашуда дәвам итәрсез. Ихлас күңелдән сөйләмисез сез, боргаланасыз. Шуңа протокол да тутырмадым, сезгә кул куеп азапланасы юк. Сезнең ялганыгызны тыңлап эт булып арыдым мин. Ял итим, сез дә ял итегез.

Тикшерүчем өстәлендәге яшерен кнопкага басты бугай, кабинетка мине алырга кизү надзиратель керде.

Мин табуреттан тордым.

— Хушыгыз, капитан.

— Хушыгыз, Кадыйров. Сезгә мин акылга килергә, эшләгән җинаятьләрегезне яшерми ачыктан-ачык сөйләргә киңәш бирәм. Безнең белән качышлы уйнаудан файда булмас сезгә.

## 3

Әти, сиңа күңелемдә язган хатым теге көнне бүленгән иде, бүген аны дәвам итәм. Эшем бутала бара. Тикшерүчем капитан Горшенин, Бәештәге Габбас абый кебегрәк кеше, мин нәрсә әйтсәм дә, аны икенчегә борырга, ничек тә үзенә кирәкле калыпка салырга тырыша. Акылга сайракмы ул, башлыкларына ярарга омтыламы, аңламыйм. Гомумән, монда кергәннән бирле кешеләрнең әдәплелекләренә, гаделлекләренә ышанычым көннән-көн төкәнә минем.

Өстемнән ошак язып мине монда кертүче — Риан Саттаров дигән бәндә. Син аны белмисең, әти. Ул Казан дәүләт университеты студенты. Мин аның белән соңрак район газетасында эшләгәндә аралашкан идем. Педагогия институтының беренче курсын тәмамлагач, җәйге каникуллар вакытында, колхозларда урып-җыю кампаниесе башланыр алдыннан, «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясе мине Гәмберт районына хәбәрче итеп җибәрде. Аннан район колхозларында башта урып-җыюга әзерлек, аннары урып-җыюның барышы турында газетага көн аралаш репортажлар бирә бардым. Барган хуҗалыклардан язган мәкаләләремне район газетасында да кире какмый, бик теләп бастылар. Ахырда район газетасы редакторы тәҗрибәле журналист Нур ага Хәйруллин миңа, институтта читтән торып укуга күчеп, газеталарында эшкә калырга тәкъдим итте. Синең беркаян да ярдәм алыр урының юк, энем, берәр елга кал Гәмберттә, бераз өс-башыңны да бөтәйтерсең, язарга да өйрәнерсең, диде. Ачлы-туклы студент тормышы теңкәмә инде ярыйсы ук тигәнгә, ике дә уйламый Нур аганың сүзен тоттым.

Көз көне, редакция йомышы белән бер авылга баргач, һич уйламаганда Риан очрады. Аның белән мине Казанда чакта театр училищесында укучы бер дустым таныштырган иде.

Бу көтелмәгән очрашуга без икебез дә гаҗәпләндек.

— Син ничек монда килеп чыктың? — диде миңа Риан, балаларча беркатлылык белән.

— Ә син нигә университетта түгел? — дидем мин аңа.

— Мин академик ял алдым, тормышны өйрәнәм. Син, син ничек килеп эләктең монда?

— Мин сезнең районда чыга торган «Ильич юлы» газетасының әдәби хезмәткәре бит, монда газетабызда терлекчелек биналарын кышка әзерләүнең барышын яктыртырга материал юлларга килдем.

— Соңгы вакытларда «Ильич юлы»ның һәр санында диярлек укучыларны интригалы исемнәре һәм чын әдәби тел белән язылган мәкаләләр астында Кадыйров фамилиясен очраткач, безнең район газетасында да ярыйсы ук шома телле журналист эшли башлаган икән, аның белән, һичшиксез, танышырга кирәк булыр, дип күңелемә беркеткән идем, ә ул журналист синдер диеп уема да кертмәдем. Укудан минем күк син дә туйдыңмыни?

— Укудан туймадым, шәһәрдә яшәргә кесәм такыр, читтән торып укыйм.

— Авырткан җиреңә кагылдым, картлач, гафу ит...

Риан шуннан соң редакциягә ике көннең берендә килә башлады. Аларның авыллары белән район үзәге Гөмберт арасы җиде генә чакрым. Озакламый ул, ВЛКСМ райкомына инструктор булып урнашып, Гөмбертка күчеп килде. Без эштән буш вакытларыбызны бергә үткәрә башладык. Мин аңа беренче очрашуларыбызда ук әни белән синең утыз җиденче елда кулга алынып юкка чыгуыгыз һәм үземнең сез утырганнан соң башланган куанычсыз бөтен үткәнемне сөйләдем. Сөйләгәннәремнең күбесен ул язган ошагында миңа каршы файдаланган, мине социалистик стройга дошман, сезнең өчен үч алырга ант эчкән кеше итеп сурәтләгән. Моны ул ни өчен эшләде соң дигән сорау куярсың син миңа. Белмим, әти. Район газетасында бер ел эшләгәч, мин кабат Казанга килеп тулай торакка урнаштым да, институтка йөреп укый башладым. Сентябрь урталарында Риан да, ВЛКСМ райкомындагы эшеннән чыгып, Казанга килде. Аның шәһәрдә торыр урыны юк иде, бер атнага якын минем янда тулай торакта кунып йөрде. Ахырда бер көнне, без лекцияләр тыңларга киткәч, ул бүлмәдәшем Шәриф Сәйфуллинның шинелен урлап, юкка чыкты. Мин Рианның ул этлеге турында әти-әниләренә хат яздым. Ул миннән, бәлки, шуның үчен алгандыр? Кияренә шинеле янында пальтосы да булган хәлле студентның әйберенә кул сузса бер хәл иде, бүлмәбездәге иң фәкыйрь студентны ялангач калдырды Риан. Хатыма каршы аның әти-әнисеннән җавап алмадым. Бер елдан соң очрашкач, ул хат турында искә алып, аның, син миңа юкка бәла яктың, дип үпкә белдергәне булмады.

Теге чакта синә күңелемдә язган хатымны балалар колониясенең хуҗалык мөдире Кәбир абыйның мине Дөмбәз районындагы Дәвек авылында яшәүче туганы Исламия апа янына илтеп ташлавы белән өзгән идем.

Исламия апа миңа кадәр өендә ялгыз башы яшәгән, гариплеге аркасында кияүгә чыкмый калган, алтмышка якынлашып килүче карт кыз иде. Аның әзер утынны өйгә кертерлек тә, коедан ярты чиләк су күтәреп кайтырлык та чамасы юк иде. Дәвеккә килгәч, аның бөтен хуҗалык эшләрен мин башкардым. Кәбир абый безгә яшәү өчен бөтен кирәк-яракларны китереп торды. Мине ул гарип апасына ярдәмче булганым өченме, үзләренең баласызлыклары аркасындамы, улы кебек күрде.

Кырык икенче елны, сугыш вакытында, мин урта мәктәпне тәмамлагач, күп тә үтмәде, армиягә алындым. Кәбир абый мине, хезмәткә бик хәтәр вакытта китәсең, исән йөреп сау кайт, Мәрьям апаң белән картлык көнебездә безнең бөтен ышанычыбыз синдә, дип бик моңаеп озатып калды. Ул үзе, кече яшьтәге җинаятьчеләрне төзәтү колониясендә эшләгәнгә, хәрби хезмәттә исәпләнә иде, дәһшәтле елларны сугышка бармады, тылда үткәрде. Фашистларны минем өчен дә тукма, дип озатты ул мине. Сугыштан мин исән кайттым, әмма Кәбир абый белән Мәрьям апага таяныч була алмадым, алар, мунча кергәндә ис тиеп, икесе тиң дөнья куйганнар. Дәвектәге Исламия апа да алардан соң озак яшәмәгән, кырык бишенче елның кышында бәкегә төшеп үлгән иде. Авыр минутларымда игелеклелек күрсәтеп бәладән аралаган, үз балаларын караган кебек карап зур тормышның олы юлына чыгарга булышкан кешеләрне сугыштан кайткач очратмау миңа бик авыр булды. Аларны мин әни белән сине сагынган кебек үк сагынам, әти. Алар өчесе дә киң күңелле, олы җанлы, илгәзәк кешеләр иде.

Армиягә алыну белән мин фронтка җибәрелмәдем, алты ай буена Казанда танк училищесында укыдым. Тәүге сугыш чирканчыгын Курск дугасында алдым. Ул сугышта һавада хәрби самолетлар, җирдә танклар һәм үзйөрешле туплар моторларының дәһшәтле үкерүләре, әйләнә-тирәне дер селкетеп бомбалар, снарядлар, миналарның өзлексез шартлаулары, җанны тетрәтеп «катюша»лар чыелдавы, танк тракларының күңелгә тиеп чыкырдаганы һич онытылмый. Мин андый яман бәрелешне, андый ут давылын бүтән күрмәдем. Тамаровка янындагы коточкыч сугышта безнең танкыбыз янып, экипажымдагы дүрт кешедән ниндидер могҗиза белән берүзем исән калдым. Соңыннан газеталарда, Курск, Орел, Белгород районнарындагы бәрелешләр Бөек Ватан сугышы чорында гына түгел, тулаем, икенче бөтендөнья сугышындагы бәрелешләрнең иң хәтәре дип телгә алындылар. Газеталарда, анда немецларның сайланган һәм көчле төркемдәшләре тармар ителеп кенә калмады, немец халкында һәм Гитлерның союздашларында фашистлар Германиясе җитәкчеләренә ышанычлары какшады, дип язып чыктылар.

Әти! Мин сиңа алга таба ничек сугышуым, фашистлар өне Берлинга ничек барып җитеп, Рейхстаг стенасына фамилиябезне уюымны сөйләп тормыйм. Үземнең сездән соң йөземә кызыллык китерерлек яшәмәвемне, кыенлыклар алдында тез чүкмәвемне, сугышта иң кыен чакларда да башкалар артына ышыкланмавымны әйтүем җитәр дип саныйм. Син белмисеңдер, Моталлап абый хәбәрсез югалган. Армиядән демобилизацияләнгәч, әни белән синең турыңда берәр төрле хәбәр алмаммы дип, Сарайлыга кайттым. Сарайлы миңа сугыштан соң анда үскән елларымдагы шикелле төзек тә, матур да төсле күренмәде. Бәлки бу Моталлап абыйның сугыштан кайтмавына, Мәчтүрә җиңгинең, ул югалган елны ук башка берәүгә тормышка чыгып, үткәненә борылып карарга да иренүенә ачынудан килгәндер. Минем бүтән Сарайлыга да, Бәешкә дә кайтканым булмады. Ул авылларга кайтырга, дөресен әйтәм, атлыгып та тормадым. Кайчангыдыр шатлыкларымның, татлы хыялларымның каберләре кебек тоелалар миңа ул авыллар. Хатымда, әти, мин сиңа күңелле нәрсәләргә караганда күбрәк күңелсез нәрсәләр турында сөйләдем, ул бөтен үткән тормышым шикелле үк бик буталчык килеп чыкты, зинһар, гафу ит...

## Тугызынчы бүлек

### 1

Капитан Горшенин миңе сорауга ике көннең берендә чакыра. Ул хәзер баштагы кебек түгел, үзгәрде, киң күңелле, хаер-хаһ кеше булып күренергә тырыша. Биргән җавапларымны сорау алу беркетмәсенә, мин әйткәнчә язмаса, кул куюдан баш тартуыма кызып китүен онытты, «киреләнүемне» үзе өчен гадәти хәл исәпләгән кыяфәт белән исе китмичә:

— Ярар, протоколга кул куюдан баш тартты, дип терким дә, вәссәлам,— дия торган булды.

Солтанов, Аитов һәм Риан белән кара-каршы очраштыруны нигә сузуы белән кызыксынуыма, авызын ерып, даими рәвештә:

— Ашыкмыйк, ашыккан ашка пешкән, ди халык. Алар, сезнең файдага сөйләмәячәкләр, Кадыйров, көтмәгез, моңа минем иманым камил,— дип кабатлады.

Мин тикшерүчемнең баштагыдан диаметраль үзгәрүен нәрсәгә юрарга белмәдем. Мәгънәсез һәм сәер кеше капитан Горшенин. Кабинетына чакыртып менгергәч эшкә шунда ук керешми, өстәлендә казына, карандашлар очлый, телефоннан кемнәргәдер шалтырата, папкаларын актара. Аның бөтен кыланышлары ясалма, үзен тотышында, сөйләшүендә, көлүендә, язуында, урындыгында утыруында, хәтта тәмәке тартуында да кемгәдер охшарга тырышуы, кемнеңдер хәрәкәтләрен сантыйларча кабатлавы сизелә.

Капитан Горшенин куршесендә — өлкән лейтенант Хафизов кабинеты. Хафизов та Горшенин кебек үк тикшерүче. Ул сугыш вакытында немецларга әсир төшкән татар сугышчыларыннан фашистлар оештырган Идел-Урал легионында булган кешеләр белән эш итә. Үтә нервлы бәндәгә охшый Хафизов. Стена аша аның, тикшерүчем мине сорауга чакырган саен күкле-яшелле тавышлар чыгарып сүгенүен, сорауга чакырткан кешесен төрлечә мәсхәрәләвен, котырынып өстәл төюен ишетми калмыйм. Үзе ул — кеше димәсәң, хәтере калырлык. Ни буе, ни кыяфәте. Чырае күксел, яшькелт күзләре өч көн ач торган мәченеке төсле. Аның еш кына тартырына булмый, Горшенин янына ул папирос теләнергә керә.

— Йә, Хафизыч, тикшерелүдәге камыр батырыңны нокаутка җибәрүең белән мактана аласыңмы бүген? — ди аңа тикшерүчем, ярым җитди, ярым шаярып.

— Мин синең кебек нечкә күңелле түгел, Семен Андреевич, алар белән кодалашасым юк. Үзеңә мәгълүм, мин фашист этләре белән эш итәм, аларны тик йодрык белән генә игә китереп була. Эшемдә бүген дә үзгәреш юк, һәрвакыттагыча.

— Молодец, өлкән лейтенант! Җинаятьчеләр белән мин кодалашаммы? Аллам сакласын!.. Җирәнәм, күрәлмим мин аларны...

— Шулай да синең үз «кошлар»ыңны канга батырганыңны күргәнем юк минем.

— Уметь надо, Хафизыч, уметь!.. Тупаслыкны җенем сөйми минем.

— Тупаслыктан башка аларны җиңеп булмый, Андреевич.

— Була, агайне, иренмә генә. Ач тоту—бер, карцер — ике, берничә төнгә сузылган конвейер — иптәшләр белән бергәләп атна буена төннәрен үзең дә йокламау, җинаятьчене дә йоклатмау — өч. Ул ысулларны сиңа сөйләп торасы юк, үзең дә беләсең. Дөресен әйтәм, синең ныклыгыңнан, үз дигәнеңә ирешү өчен берни алдында да тукталып калмавыңнан көнләшәм мин.

— Мин синең хәйләкәр төлкелегеңнән көнләшәм.

— Юк, Хафизыч, мин төлке түгел, көзән. Көзәннең төнлә тавык кетәгенә кергәч нишләвен беләсеңме син? Белмисең? Ул анда беренче эше итеп әйбәтләп аркасына ята һәм бик шәпләп эчендәге газын чыгара. Куначадагы тавыкларның берничәсе, шул газдан миңгерәүләнеп, кетәк идәненә егылып төшәләр. Көзәнгә шул гына кирәк. Ул төлке шикелле комсызланып тавыкларга ташланмый, ашыкмый гына аларның башларын тишеп миләрен эчә дә үз юлына китә. Менә шул, йә төлке белән көзән арасында аерма бармы, ничек уйлыйсың?

— Бар, Андреевич. Кая, тагын бер папирос бир дә, чыгыйм үз ысулларымны кулланырга. Мин монда синең белән сөйләшкән арада тавыгым йоклап утырмасын анда.

— Мә, берне генә түгел, икене ал. Йокласа, моннан соң өч көн күзен дә йоммаслык итәсең син аны. Беләм мин сине.

Хафизов чыгып киткәч күп тә үтмәде, аның кабинетыннан кемнеңдер:

— Сез миңа кул күтәргәндә чал чәчле атагызны күз алдыгызга китерегез,— дигән сыкранулы сүзләре ишетелде.

— Телең тый, минем атам синең күк хыянәтче дә, сатлык җан да түгел,— диде аңа Хафизов.

— Үзегез минем урынымда нишләр идегез икән? — Безнең бөтен армиябез чолганышта калып әсир төште, бер мин генә түгел...

— Атаң турында уйла, минем урынымда булсаң нишләр идең икән, имеш. Син үзең өчен үзең җавап бир, гаебеңне кешегә аударма. Мин сине дөресен сөйләргә мәҗбүр итәрмен, фашист көчеге!.. Бу Германия түгел сиңа. Аннан илебездә нинди корткычлыклар эшләргә задание алып кайттың, сөйлә?..

Тикшерүчем урыныннан торып:

— Ярар, җитәр, без дә эшкә керешик,— диде.— Заем кампаниясенә яла ягып, нәрсә сөйләгән идегез Саттаровка, искә төшерегез әле шуны.

Менә тагын тырнак астыннан кер эзләү башлана. Заем, заем кампаниясе... Сүз монда, Гәмберт районындагы бер колхозга заем кампаниясен үткәрешергә районнан вәкил булып баргач, үзем тап булган трагикомик хәл турында барса кирәк. Гаепләремне бөртеклəп җыйган Риан, иренмәгән. Тик ул хәлнең политикага ни катнашы бар? Аңламыйм. Капитаннан соравын ачыклатыйм әле, бәлки сүз бу очракта бөтенләй башка нәрсә турында барадыр...

— Соравыгыз аңлашылмады, яңадан кабатлагыз әле, Семен Андреевич.

— Боргаланмагыз, бик аңлашылды. Сез Гәмберт районында редакциядә эшләгәндә заем кампаниясе вакытында «Тырыш» колхозына вәкил итеп җибәрелгәнсез...

— Аңлашылды, дәвам итмәгез. Тик анда булган хәлне районга кайткач Рианга сөйләвемне ничек итеп партия политикасына яла ягу диярлек икән? Аның ничек булганын сөйлим хәзер. Мин заем кампаниясендә вәкил булып барган авыл зур түгел, нибары кырык җиде хуҗалык исәпләнә. Авыл ярлы, хәлле хуҗалыклар уннан артмый. Заемга өйләргә йөреп яздырганчы, колхоз идарәсендә башта исемлек төзеп, авылдагы һәр хуҗалыкка күпмешәр яздыра алуны билгеләп чыктылар. Колхоз председателе бер мең биш йөз сумга, хисапчы бер мең өч йөз сумга, партоешма секретаре бер мең ике йөз сумга язылдык, дип, үзләрен төп исемлеккә кертмичә аерым кәгазьгә теркәделәр. Шуннан соң без җиде кеше — биш хатын-кыз һәм колхоз председателе белән мин — өй борынча йөрергә чыктык. Турысын әйтәм, кешеләр заемга бик авыр язылдылар. Сугыш тәмамланганга әле өч кенә ел, халык яңа тернәкләнеп кенә килгән чак иде бу. Районнан мине «Тырыш» колхозына вәкил итеп җибәргәндә, анда заем унике мең сумлык таратылырга, шуның кимендә өчтән бер өлеше, ягъни дүрт мең сумы заемга язылу белән акчалата кертелгән булырга тиеш, диделәр. Бер агай, иптәшләр, бу эш ихтыяри-мәҗбүри бит, мин сез исемлегегездә билгеләгән сумманың ике йөзенә рәхәтләнеп язылам, бүтәнен сорамагыз, хәлемә керегез, тормышым авыр, үзегез күрәсез, дип карады, әмма колхоз председателе аңа төрлечә янап, йомышың төшеп миңа килгәндә мин дә сине тыңламам, ат кирәк булырмы сиңа, кирәк булыр, тиздән менә бакча утыртырсың, сабанга хатыныңны җигәрсеңме, дип агайны исемлектә билгеләнгән суммага тәки ризалаштырды. Без берәүнең дә сүзенә колак салмадык, һәр өйдә исемлектә билгеләнгәннән артыграк яздыру ягын карадык. Авылда район билгеләгән сумма арттырып үтәлсә, бу колхоз җитәкчеләренә һәм авыл активистларына мактау китерәчәк иде. Моңа колхоз председателе бөтен тырышлыгын җикте. Заемга яздыру бер хәл, шуның өстенә 4000 гә якын акча да җыярга кирәк иде бит. Анысы заемга яздырудан да кыенрак барды. Шулай өй борынча йөргәндә, кулыңа таяк алып күпме генә селтәнсәң дә бер йорт дирбиясе эләкмәслек эче шыр ялангач бер өйгә кердек. Без кергәч, өч бала мич башыннан, бу кешеләр әллә безне алырга килделәрме икән, дигән кебек, куркып кына башларын суздылар. Берни җәелмәгән коры сәке өстендә ике борын тишегеннән сары маңкасы агып төшкән ике-өч яшьлек дүртенче бала Сталин сурәтле Җиңү медален сәке тактасына бәрә-бәрә чылтыратып утыра, өстенә кырык ямаулы иске күлмәк кигән хуҗа хатын казан тирәсендә кайнаша иде. Без кергәч ул күлмәгенең биле өлешендәге ертыгыннан елтыраган тәнен күрсәтмәскә тырышып, арты белән гөлбәчкә—мич арасына чигенде.

— Исәнме, Фирая, хәл-әхвәлең ничек, балаларың сау-тазалармы? — дип тезеп китте председатель, ишектән керү белән.

— Исән, исән, Госман абый. Хәл-әхвәлемнең мактанырлыгы юк, тормышым әнә күз алдыгызда.

— Әйдә, чык әле монда, гөлбәчкә качып сөйләшмә. Без сине заемга яздырырга кердек. Дәүләткә булышырга кирәк, понимаешь.

Фирая гөлбәчендә калды, чыкмады.

— Мин сезне, җыйнаулашып үзегез миңа ярдәм итәргә кердегез, дип шатланган идем. Миннән дә булышлык сорарлык хәлгә калдымыни

дәүләтебез? Сугышта бөтен сәламәтлеген югалтып гарипләнеп кайткан ирем биш баламны ятим, үземне тол калдырып үлеп киткәч, дәүләтебез миңа ярдәм итәр дип уйлый идем мин исәр баш, ул оялмыйча мин хәерчедән булышлык сорый. Күпме кирәк ди?

— Сиңа күп яздырмыйбыз, илле сум гына куйдык.

— Мин тол хатынны кешеләрдән читтә калдырмаганыгыз өчен рәхмәт инде, Госман абый. Ләкин илле сум күп миңа. Бәлки бер юлга яздырмый калдырырсыз? Ялгызыма биш баланы, үземне асрау бик авыр, хәлемә керегез. Минем бер килерем дә юк бит.

— Булмый, Фирая, илле сумны ел әйләнәсендә ничек тә түләрсең.

— Илле сум миңа күп, Госман абый. Ярар, кеше рәтеннән калып булмас, шуның яртысына риза мин. Егерме биш сумны ничек тә табармын. Тик хәзер үк акча дауламагыз, бир тиенем дә юк, соңыннан үз җаем белән түләрмен.

— Юк, илле сумга кул куй, Фирая.

— Егерме биш сумга риза, Госман абый, илле күп. Әтиләре өчен балаларыма чыккан 76 сум пенсиядән бүтән килерем юк минем.

— Һәй, Фирая, килерем юк, имеш!.. Синең ата казың да акча эшли диләр ич...

Ата казының акча эшләвен ишетү хуҗа хатынны гөлбәченнән чыгарып колхоз председателе каршына бастырды. Ул аңа, ярсып:

— Әйе, ата казым акча эшли минем, күрше-тирәләремдәге хатыннар, балаларымны кызганып, казларын ата казымнан бастырырга керткәннәре өчен ун сум түлиләр. Ата казның акча эшләү коралы бармак очы кадәр генә, ә синең Госман абый, беләк буедыр, син шуның белән күпме эшлисең, кибетче Сәхия белән Купшы Бибинур сиңа күпмешәр түлиләр? — диде.

Өйгә кергәч моңарчы сүзсез басып торган активисткалар бер-берләренә карап пырхылдап көлеп җибәрделәр, председатель уңайсызланудан кыпкызыл булды. Ул хуҗа хатыннан кырт борылып:

— Телеңә тилчә чыксын синең, Фирая, нәрсә сөйләгәнен белми,— дип ишеккә юнәлде.

— Карале, Госман абый, ата казым белән тәҗрибә уртаклашырга ашыксаң, хәзер өйдә юк ул, аның янына кич кил, кичкә кайтыр,— диде аңа хуҗа хатын, мыскыллы көлеп.

Без председатель артыннан урамга чыктык.

— Мин бу трагикомик вакыйгада заем кампаниясенә дә, партиябез политикасына да бернинди яла ягу да күрмим, Семен Андреевич.

— Сез мәсьәләнең асылына политик күзлектән карый белмисез. Маңкалы бала, аның кулында бөек юлбашчыбызның сурәте төшерелгән Җиңү медале... Ул медаль балалар уенчыгымы?..

— Аларның өйләрендә бүтән уйнарлык әйбер булмагач, бала әтисеннән калган шул медаль белән уйнамый нишләсен? Медальдә ул илебездәге барлык балаларны бәхетле иткән кешенең сурәте барын белми бит.

— Менә сез бу сүзләрегез белән үзегезнең төп асылыгызны ачып салдыгыз инде.

— Юк, капитан, сез дөрес фараз итмисез, жиргә төшегез, әйләнә-тирәгездәге кешеләрнең ничек яшәүләренә күз салыгыз...

— Бетте, корыны бушка аудармыйк, сез үз фикерегездә каласыз, мин үз фикеремдә калам. Протоколга да шулай теркәдем. Укып чыгыгыз.

Мин сорау алу протоколын укып чыктым да:

— Биредә сез язган уйдырмалар логикага туры килмиләр, капитан. Авылда заем кампаниясен үткәргәндәге бозулар Мәскәүдән килеп эшләнмиләр бит, урыннардагы җитәкчеләрнең башбаштаклыклары, һәр кампанияне ничек теләсәләр, шулай үткәрүләренә ачынуны сез нигә партия политикасына яла ягу дип саныйсыз?

— Димәк, сез бүген дә сорау алу протоколына кул куюдан баш тартасыз?

— Әйе, бүген дә кул куюдан баш тартам, чөнки анда бер генә сүз дә мин әйткәнчә язылмаган.

— Мәйлегез. Кирелегегез сезгә барыбер ярдәм итмәячәк.

— Моның белән сез Советлар Союзында хакыйкатьне инде табуы авыр димәкче буласызмы? Сез, бәхеткә каршы, соңгы инстанция түгел бит, Семен Андреевич. Дөнья сезнең министрлык һәм эчке төрмә белән генә чикләнми, зур ул. Алда тагын суд, югары органнар бар, һәр җирдә сезнең күк муртайган черек төпләр утырмыйлардыр дим.

Тикшерүчем ашыкмый гына тәмәке кабызды да төтенен минем якка өреп:

— Поживем увидим,— диде, зәһәрле көлеп.

2

Бер көнне мин уңъяк стенама күрше камерадан кемнеңдер сак кына шакуын ишеттем. Шаку озакка сузылмады, туктады. Аннары билгесез күршем яңадан шакый башлады. Стенама башта ике тапкыр, азрак пауза ясап биш тапкыр шакыды. Шуннан соң тагын пауза ясады да дүрт һәм өч тапкыр шакыды, кабат аз гына пауза ясагач, өч һәм дүрт тапкыр шакыды. Аннары 1 + 3 һәм 2 + 4 шакыды да туктады. Мин сагая калдым. Бераздан шаку шул ук тәртиптә яңадан кабатланды. Күрше камерадагы кеше миннән, сез кем? дип сорый иде. Җавап бирергәме аңа, юкмы? Бәлки, бу провокациядер? Сорау сак кына тагын кабатланды. Мин, тәвәккәлләп, шакучыга үзем сорау бирдем. Ә сез кем? Күршем, Мәҗит, дип шакыды. Фамилияң? дидем. Рафи... дип шакыгач, мин, аңлавымны белдереп, стенага ике тапкыр чиерттем дә, татарча, ишәк арык, тау биек, дип шакыдым. Ул, өмет зур, кесә та... дип шакыгач, стенага яңадан ике тапкыр чиерттем һәм, мин — Ирек, дип шакыдым. Аңладым, дигәнне белдереп, Мәҗит стенага ике тапкыр чиертте. Кайчан кулга алындың? дидем. Беренче апрельдә, дип җавап кайтарды Мәҗит. Тикшерүчең кем? Капитан Горшенин. Гаебең нинди? Сталинны яратмау. Ә синең? Милләтчелек.

Коридорда аяк тавышлары ишетелгәч, мин стенага йодрыгым белән өч тапкыр сугып, ишекле-түрле йөрергә керештем.

Мәҗит, кешелекле, шаян, киң эрудицияле Мәҗит. Аның бу таш капчыкка килеп керүенә һич ышанырлык түгел. Гаебе Сталинны өнәмәү, имеш. Нигә дип өнәмәсен ул Сталинны? Шаяртадыр. Аның белән без гәпләшә-гәпләшә күпме кичләрне бергә үткәрдек, нәрсәләр турында гына тел кашымадык, әмма Мәҗитнең Сталинны бер генә тапкыр да телгә алганы, аңа нәфрәтләнгәне булмады. Безнең үзара әңгәмәләребез авылларның сугыштан соңгы хәерчелекләре, колхозчыларның эшләгән хезмәт көннәренә берни дә алмаулары, илебездә бөтен нәрсәнең әрәм-шәрәм ителүе, һәр тармакта хуҗасызлык хөкем сөрүе, Башкортстандагы иң уңдырышлы җирләрнең нефтьчеләр тарафыннан яраксыз хәлгә китерелүләре, нефтькә ияреп чыккан газның бушка янып әрәм булуы, ирләре фронтларда башларын салган тол хатыннарның, әтиләре сугыштан кайта алмаган ятимнәрнең авыр тормышлары, егетләре сугыш кырында башларын салгач, кияүгә чыгалмыйча картаючы бәхетсез кызлар, укуыбыз турында бара иде. Гаебе — Сталинны яратмау. Юк, шаярта булыр ул. Ләкин шаяртканда нигә Сталин кадәр Сталинны телгә ала? Кеше күңеле — карурман, кемнең кемлеген һич аңламассың...

Бәештә чакта Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр» романын укыгач, андагы төрмә алфавитын өйрәнүебез, Гайфи, Сөләй, Кәрим һәм мин нәрсә турында сөйләшүебезне башка малайлардан яшерер өчен шул алфавитны куллануыбызның кайчандыр кирәге чыгарын кем уйлаган.

Мәҗит — сугыш инвалиды. Умыртка баганасын снаряд кыйпылчыгы зарарлаган, көчкә йөри, сул кулының өч бармагы юк. Без икебез дә: ул — университетта, мин — пединститутта, соңгы курс студентлары идек. Без еш очраша, фронтта үткән көннәребезне искә ала, киләчәгебез турын-

да хыяллана, аны үзебезчә күзалларга тырыша идек. Бервакыт ул миңа шаярып: «Ишәк арык, тау биек, өмет зур, кесә такыр, кесәдә җилләр уйнагач, өметкә канатлар үсми»,— дигән иде. Мин аңа аның, чыннан да, Мәҗит икәненә ышанып өчен шул шаяртуның башын шакый башладым, ул аны дәвам итте. Мәҗит — Башкортстаннан. Сугышка кадәр Оренбург медицина техникумын бетергән. Үзе теләп фронтка киткән. Сугышта санинструктор булган. Җор сүзле, сабыр холыклы, тормышның ачысын-төчесен шактый татырга өлгергән егет. Татар һәм рус телләрендә шигырьләр яза. Берничә шигыре матбугатта да чыкты. Киләчәктә ул зур шагыйрь булырга хыяллана. Аның ничек Сталинны яратмавы мөмкин? Әйткәне дөрестер, бәлки, монда кеше Рианише «гадел зат»лар ошагы белән ялгыш әйткән бер кәлимә сүз өчен дә килеп каба! Башта — пионерда, аннары комсомолда тәрбияләнгән, сугышны тиешенчә үтеп, фронтта Ленин партиясенә кабул ителгән мин — милләтчеме? Татар ни, рус ни, чуваш ни, илебездәге башка милләтләр ни — барысы да бер миңа. Башкалардан аермам — татар культурасына, телебезгә, туган әдәбиятыбызга бөтен барлыгым белән гашыйк булуымда гына. Мин туган телемне, гасырлар аша исән үтеп, бүгенгебезгә үзләренең рухи сафлыкларын югалтмый килеп җиткән көйләребезне, җырларыбызны, тыйнак гореф-гадәтләребезне яратам. Әгәр халкыма, аның тарихи үткәненә хөрмәт белән карау, ул үткән алдында баш ию милләтчелек саналса, мин гаепле. Узган көз Мәҗит миңа бер хикмәтле хикәят сөйләгән иде.

Башкортстанда, Мәҗитнең туган авылы Күгәрчен янәшәсендәге мәгърур кыя өстендә, бик матур бер ялгыз карагай үскән. Ул кешеләрнең игътибарын ерактан ук үзенә җәлеп итә, сокландыра торган булган. Мәҗитләр авылында беркем белән дә хисаплашмый, тик бүреге белән генә киңәшеп эш итә торган үзсүзле бер агай бар икән. Бу агай, Мәҗит аны Гайяр агай дигән иде шикелле, бер яз көне кыядагы карагайны тамырлары на зыян китермичә казып алып үз өе янына кайтарып утырта. Мәһабәт карагайдан мәхрүм ителгән кыя моңсуланып, шыксызланып кала. Карагай яңа урында мантып китә алмый, гүя кыясын, әйләнә-тирәсендәге элекке иркенлекне сагынып җирси. Беренче елда ул теләр-теләмәс яңарса да, икенче елны корый. Гайяр агай, үзенең ялгышын аңлап, кыя башына яңа карагай утырта, әмма ул яңармый, корый.

Тормышның үз юлыннан агуына комачаулап, орып-бәреп эшләнгән ялгышны төзәтү күп очракта мөмкин булмый. Кызык, менә Мәҗит белән мине дә үскән туфрагыбыздан аердылар. Без дә яңа урында — чит туфракта тамыр җибәреп мантып китә алырбызмы, әллә безне теге күчереп утыртылган карагай язмышы көтәме?

Мин Мәҗитнең шакуын көттем, аннары аңа берничә тапкыр шакып карадым, ләкин җавап булмады.

Иртәгесен Мәҗит стенага шакып, исәнлеген белдерде. Мин аның шакуларыма кичә нигә җавап бирмәве белән кызыксындым.

— Сорау алырга чакырдылар,— дип җавап кайтарды ул.

Мине юк белән тинтерәткән кебек, аны да шулай тинтерәтә микән капитан Горшенин? Сугышта кан түгеп ярты сәламәтлеген югалткан кеше бит Мәҗит. Быел аның да минем кебек үк диплом аласы елы иде. Институтны бетерергә миңа Риан аяк чалды, аңа кем комачаулады икән?

— Сине ни өчен кулга алдылар? — дип шакыдым.

— Тормышыбыздан канәгать булмаганга.

— Газраилең кем?

— Белмим. Синең кем?

— Риан.

— Саттаровмы?

— Әйе.

— Ул үзе дә монда бит, белмисеңмени?

— Ышанмыйм. Бу йортка хезмәт итеп тамак туйдырган ич ул.

— Ул март башында кулга алынды.

Бу яңалык миндә уйлар өермәсе кузгатты. Димәк, аучы салган буанакка куян чабып барганда башын үзе илтеп тыккан кебек, Риан да монда үз ихтыяры, үз теләге белән килеп керде булып чыга. Риан үзе өчен үзе җавап бирер, ә нигә ул мине дә үзенә ияртте, аңламыйм.

Риан турында, аның бирегә язган кабахәт ошагын укыганнан соң, туктаусыз уйланам мин. Нормаль, үз акылындагы кеше андый этлекне эшли аламы? Һич юк. Ул тик хаин җанлы бәндәнең генә кулыннан килә торгандыр. Тыныч кына атлап үз юлыннан барган кешенең артыннан сиздермичә килеп кинәт башына таш орган кебек бит ул өскә атылган уйдырма гаепләр, урынсыз нахак бәлаләр...

Сугыш вакытында хыянәтчеләр, әсирләр арасында һәм гитлерчылар басып алган районнарда коммунистларны, комиссарларны, яһүдләрне фашистларга сатучылар, вәхши полицайлар, старосталар каян килде? Алар тик үзләре, үз файдалары турында гына уйлаучылар, кешеләрне куралмаучылар иде. Риан да шулар токымыннан микәнни? Сугыш вакытында андыйларга хәтта пуля да әрәм итмиләр, аларны бөтен халык алдында дарга асалар иде. Риан үзенең ошагында бер миңа гына түгел, күп кешеләргә яла яккан. Аларның кайберләре турында миннән сорадылар инде, ләкин мин аларның күбесенең дөньяда барлыкларын да белми идем, берни дә әйтә алмадым. Бәлки Риан «фаш иткән» ул кешеләр дә инде монда минем хәлдәдер, кем белә?..

### 3

Кичке аштан соң сорауга йөртә торган «шофер» мине Республика дәүләт иминлеге министрлыгының тикшерүләр бүлеге башлыгы майор Салихов кабинетына алып менде. Салмак хәрәкәтле, цирк көрәшчесенеке шикелле таза һәм ыспай гәүдәле, уйчан йөзле ул кеше миңа бу хәтәр учреждениедә сөмсез козгыннар өеренә ялгышып эләккән ак карга сыман тоела иде. Майор Салихов, капитан Горшенин мине сорауга чакыргач, кайбер көннәрне керә, кергәч минем белән исәнләшми калмый иде. Горшенин янына эшләре юктанмы, яки ниндидер йомыш беләнме керүче бүтән офицерлар миңа баш кагып кына булса да сәлам бирү түгел, мин утырган почмакка күз дә салмыйлар иде. Алар эчке төрмәдә потенциаль дошманнар гына утыра дип уйлыйлар иде, күрәсең. Майор Салихов исә кайчан керсә дә сәлам бирми калмый, тикшерүчемә дә, миңа да ләм-мим сүз катмый өстәл янындагы өч урындыкның берсенә кунаклап, йә тәмәке кабыза, йә кесәсеннән кечкенә игәү чыгарып, тырнакларын игәүли башлый, йә тәрәзәдән тышны күзәтә, аннары кергәндәге төсле үк шыпырт кына чыгып китә иде. Аның министрлыктагы башка офицерларныкы кебек аякларындагы итекләренең шыркылдап шыгырдаганнарын да, шома паркет идәнне үкчәләрендәге тимер дагалары белән шак-шок төеп атлавын да миңа ишетергә туры килмәде. Йөргәндә ул күнитекләрен салып, оекбашлардан гына йөри кебек иде. Ә авырлыгы майорның йөз егерме килограммнан да ким булмагандыр. Сөйләшкәндә дә ул тавышын күтәрми, ипләп кенә сөйләшә, ашыкмый, кыскасы, Салихов минем тикшерүчем капитан Горшенинның капма-каршысы иде.

Мине керткәндә электр чәйнеген розеткага тоташтырып торган майор, исәнләшүемә:

— Исәнмесез, Кадыйров, исәнмесез. Узыгыз түргә, утырыгыз әнә өстәл янындагы буш урындыкка,— диде. Чәйнеген электр челтәренә тоташтыргач, стена буенда торган ике урындыкның берсен алып килеп каршыма утырды.— Кәефләр ничек, Кадыйров?

«Бу майорга миннән нәрсә кирәк?» — дип уйладым шикләнеп.

— Дагасы төшкән ат тоягы кебек.

— Ничек аңларга бу сүзегезне, Кадыйров. Мин кавалерист түгел, аңлатыгыз.

— Кәефем даими бер төрлелектән ерак, юктан гына да үзгәрә, ягъни тотрыклы түгел, тая тора, диюем.

— Тинтәк сорау бирүем өчен гафу итегез, Кадыйров. Камерада, бигрәк тә ялгыз камерада утыручы кешенең кәефе ничек ал да гөл булсын, төшенке, үзгәреп тора билгеле.

— Шулай да анда карцердагы кебек үк түгел, гражданин майор.

— Сез карцерда да булырга өлгердегезмени инде?

— Өлгердем, әлбәттә. Аңа монда күп сорамыйлар бит, әлегә юешенә әләгә алмадым, күселесендә генә буллым.

— Әйткәнегезне тагын төшенмәдем, карцер бездә бер генә төрле, ул юешкә һәм күселегә аерылмый, минемчә.

— Менә бу кулымны күсе түгел, мин үзем тешләдем микәнни анда әләккәч, майор?

— Күселе карцер минем өчен яңалык, Кадыйров. Сез үзегезнең карцерга ни өчен әләгүегез, аның ниндилеген сөйләгез әле.

Мин майор Салиховка ассирияле Геворгиз белән булган хәлне, карцерның ниндилеген, аның тимер ишеген дөмбәсли башлагач, коридордагы надзирательнең мине юашландыру кулмәге киертү һәм юеш карцерга күчерү белән янавын сөйләп бирдем. Сөйләвемне тыңлаганда майор үзен учреждениеләрендәге серле урыннар турында беренче тапкыр ишетә кебек тотты.

— Сөйләгәнегезгә һич ышанасым килми,— диде ул ахырда урыныннан торып.

— Надзирательләрне чакыртып сорагыз,— дидем мин,— алар сезгә минем кебек ялганламаслар, дөресен сөйләрләр. Теләсәгез үзегез белән шунда төшә алабыз.

Мин, майор Салиховның үземне нигә чакыртканын белмәсәм дә, аның белән ачыктан-ачык сөйләшергә булдым. Кабинет хуҗасы никтер миңа намуслы, гадел һәм эчкерсез кеше булып күренде. Биргән сорауларымны гаепкә ала икән, ала бирсен, ни югалтам, ул эчке төрмәдән дә ары җибәрмәс әле, дип уйладым.

— Минем кайбер нәрсәләрне ачыклыйсым килә, гражданин майор, мөмкинме?

— Нинди нәрсәләрне, мәсәлән?

— Безнең совет Конституциясендә сүз ирегe, матбугат ирегe дигән төшенчәләр бар. Кулга алынганчы, мин аларны теләсәң нәрсә турында сөйләргә, теләсәң нәрсә турында язарга мөмкин дип аңлый идем. Монда кергәч, миндә ул ирекләрнең чынлыгына шик туды. Сүз ирегeн сез ничек аңлыйсыз, бәлки әйтерсез?

Майор уйчан елмайды.

— Сүз ирегe уйлаганыңны ярып салу, минемчә.

— Ә нигә соң мине колхозчыларның хезмәтләре өчен тиешенчә түләү алу гына түгел, хәтта рәхмәт сүзе дә ишетмәүләренә борчылуымны монда колхоз строена яла ягу саныйлар. Мин күргәнемә күз йомарга тиеш идемме? Чирен яшергән — үлгән, малын яшергән — бөлгән, ди бит халык. Мин нигә Гали белән Вәлиләр кебек кенә уйларга, үз фикерләремне, үз карашларымны, тегe яки бу күренешләр тудырган тәэсирләнүләремне яшерергә, тормышыбыздагы җитешсезлекләрне күрмәскә, аларга күз йомарга тиеш? Сугыш азагында Европа илләрендә мин сокландыргыч юллар, берсеннән-берсе төзек һәм матур авыллар, шәһәрләр күрдем. Ирексездән ул юлларны, алардан чабышкан елгыр машиналарны бездәге чокыр-чакырлы, баткак-түмгәкле юллар, аларда батылып яткан машиналар, йортларының түбәләре салам белән ябылган, тиреслек башына охшаган ярлы авыллар белән чагыштырдым. Мин күрше илләрдә күргәннәремне дегеткә буяп сөйләргә, үзебездәге күңелне сыкрата торган күренешләрне күккә чөеп мактарга тиеш идеммени?

Мине бүлмичә тыңлаган майор елмаеп:

— Чит илләрдә күргәннәрегез турында теләсә кемгә сөйләп йөрү нигә кирәкте сезгә? — диде.

— Минем үз тормышыбызны да, юлларыбызны да, башка нәрсәләребезне дә матур итеп күрәсем килә, бездәге җимереклекләргә, хуҗасызлыкка, ваемсызлыкка, ахмаклыкка җаным әрни. Газеталар, радио алар турында ләм-мим. Җитешсезлекләребезне нигә яшерәбез без? Нигә һәр адымда, фәләнгә ирештек, фәләнне эшләдек, фәләнне булдырдык, дип лаф орырга? Асылда, илебездә сугыштан соң күтәрелеш, ирешкән уңышларыбыз әлегә юк дәрәҗәдә бит. Без сугыш вакытында, фашистлар уйлый белмиләр, алар җанлы автоматлар, тере курчаклар, фрицлар өчен фюрер уйлый, дип немецлардан көлә идек. Без үзебез дә шул фрицлар төсле түгелмени? Кеше бүтән тереклек ияләреннән уйлый, фикер йөртә белүе белән аерыла. Минем өчен кемдер бөтенесен хәл иткәндә миңа дөньяда яшәүнең ни кызыгы бар?

Майор Салихов урыныннан торып тәмәке кабызды да, салмак адымнар белән ишекле-түрле үткәч, тәрәзә буена барып сөялде.

Бераздан ул:

— Миңа ачыктан-ачык әйткән бу фикерләрегезнең үзегезгә зыян китерү мөмкинлекләрен уйламыйсызмы? — диде акрын гына.

— Сез дә миңа хәтта үз күләгәмнән дә куркырга киңәш итәсезмени? Мин үземне сарык, сезне бүре дип уйламыйм.

— Күләгәгездән куркырга киңәш итмим, ялгыш аңламагыз. Әйтегез әле, сез капитан Горшенин белән дә менә монда хәзер минем белән сөйләшкән кебек сөйләшәсезме?

— Аның белән ничек сөйләшкәнемне сез үзегез беләсез, безне бергенә тыңламадыгыз. Ясалма, үз-үзенә соклана торган бәндә белән ачылып сөйләшеп булмый.

— Ә нигә дип сез миңа ачылырга карар бирдегез?

— Сез икейөзле, мәкерле кешегә охшамаган, никтер ышанам мин сезгә.

Майор, тәрәзә яныннан китеп, күптән кайнап чыккан чәйнеген розеткадан аерды.

— Әйдә, чәй эчеп, бераз тамак ялгыйк. Сез миңа үзегезнең кем икәнегезне, әти-әниләрегезнең кайда яшәүләре, кем булып эшләүләре хакында сөйләрсез. Гәп куертабыз, юкса мин сезнең турыда берни дә белмим бит.

Хәйләле майор, ничек инде үзе җитәкләгән бүлектә биш ай буе тикшерелгән тоткын турында берни дә белмәсен ул, дип уйладым мин һәм:

— Кулга алынганчы мин студент идем, хәзер менә сездә тикшерелү үтәм, милләтчелектә, советка каршы агитация алып баруда гаепләнәм. Әтием белән әниемнең кайда икәннәрен белмим, алар 1937 елның азагында кулга алындылар. Әнием фельдшер, әтием укытучы һәм запастагы командир иде. Аларның эзләре шушы йортта өзелде, кайда алар, тереләрме, үлеләрме — белмим.

Майор мине, өстәле артына утырып, йөзен куллары белән каплаган хәлдә, тыныч кына тыңлады. Азактан:

— Әтиегез белән әниегезнең дә фамилияләре Кадыйров идеме? — диде.

— Әйе. Әти — Сабир, әни Мәликә исемле иде.

— Мин аларның язмышларын ачыкларга тырышырмын. Әйдәгез, чәй эчик. Тартынмагыз, өстәлдә нәрсә бар, ашагыз. Аннары радио тыңларбыз. Мин сезне бүген юри радио тыңларга чакырдым.— Майор сәгатенә карап алды.— Тагын җиде минуттан опера һәм балет театрында Нәҗип Җиһановның «Намус» операсын тапшыра башлаячаклар. Тукта, тыңлатыйм әле яңа операны Горшенинның милләтче студентына да, дидем. Яңа опера культурабыз тарихына яңа сәхифә өсти бит, аның белән сез таныш булырга тиеш дип санадым.

Мин гаҗәпләндем, ничек аңларга бу кешене?

— Сез сорауга чакырттыгыз дип уйлаган идем мин, рәхмәт.

— Эх, Кадыйров, мин сездән сорау алу урынына чалбарыгызны салдырып, йомшак җирегезне озын телегез өчен яшь кычыткан белән бик шәплән пешекләр идем дә, моннан җилтерәтеп куып чыгарыр идем. Сез

минем җәзамны гомерегез буена онытмас һәм аннан ары һәр сүзегезне моны әйтергә ярыймы, юкмы дип күңелегез иләге аша үткәреп кенә әйтер идегез.— Майор өстәле артыннан чыгып идән буйлап, кулларын артка куеп, бер тапкыр әйләнгәч: — Сорау алу протоколларына кул куюдан баш тартып дөрес эшлисез сез,— диде, үз алдына сөйләнгәндәй.— Миңа берәр төрле үтенечегез юкмы?

— Китаплар, газеталар бирдертсәгез иде...

— Китаплар бирерләр, әйтермен, ә газеталарны вәгъдә итмим, аларны моннан чыккач укырсыз. Китаплар да сез теләгәннәр булмас, классик әсәрләрне һәм бүгенге чүп-чарны гына бирерләр.

— Рәхмәт, ни бирсәләр дә бирсеннәр генә, талымламам.

Майор радионы тоташтырды. Бүлмәгә тантаналы салмак музыка агыла башлады...



## Унынчы бүлек

### 1

Кыш һәм яз артта калды, җәй килде. Әмма минем әле яшеллек күргәнем юк, җәй килүен көннәрнең җылынуыннан, камерамның бөркүләнүеннән генә сизәм. Камерамда иректә чакта күнегелгән үсемлекләрнең исләре дә юк, иңе унбиш, буе егерме метрлы прогулка мәйданчыгында да үләннәр үсми, аңа соры асфальт түшәлгән. Әйләнә-тирәгә дә җәй чибәрлеге яшеллекне эзләп күз ташларлык түгел, мәйданчыкның ике ягында кызыл кирпечтән өелгән биек стена, калган ике ягында без утыра торган дүрт катлы эчке төрмә корпусы. Прогулка мәйданчыгында үзеңне иркен кое төбендә итеп тоясың, анда кояш нурлары үтеп керә алмый, аларга бар яктан да юл киртәләнгән. Кулларыңны артка куеп, башыңны иеп, зоопарктагы җанвар сыман, мәйданчык буйлап сәгать телләре юнәлешендә әйләнчек сарык күк күзләреңне тондырып егерме минут йөрисең дә тынчу камерага керәсең. Прогулка мәйданчыгында һава авыр, аяк астындагы асфальт сасысы тынны кыса, анда биек кирпеч стеналар һәм дүрт катлы котсыз төрмә корпусы аша җил беркайчан да үтеп керә алмый. Шуңа мин прогулкага чыгарга атлыгып тормыйм. Әмма берничә көн элек прокулкага чыккач, мин биек кирпеч стенаны ничектер күзләрем белән гамьсез генә капшап үттем һәм гаҗәпләнеп туктап калдым. Стенаның бер урынында, кирпечләрне бер-берләренә тоташтырган измә җегендә, аяк очларына басып үрелсәң кул җитәрлек биеклектә, зурлыклары бармак бите кадәр генә өч яшел яфрак күрдем. Аларны ялгыш күрмимме, дип күзләремне бер йомдым, бер ачтым. Яфраклар юкка чыкмады, урыннарында калды. Гаҗәп, стенадагы измә җегенә ниндидер үсемлекнең орлыгы могҗиза белән эләгеп, тишелеп чыккан!.. Бер урында туктап озак тордым ахры, прокулкага чыгарган надзиратель ишек төбеннән:

— Торма бер урында, атла, йөр! — дип кычкырды.

Мин, әмергә буйсынып, кузгалып киттем, ләкин башка вакытлардагы кебек башымны аска иеп бөртек яргыч күперен әйләндерергә җигелгән, инде бүтән эшкә ярамый торган карт атка охшап атламадым, күзләрем стенадагы өч яшел яфракта булды...

Икенче көнне прогулкага чыкмадым, тикшерүчем мине Солтанов һәм Аитов белән кара-каршы очраштырды. Егетләр Яңа елда күргәндәгедән тазарганнар һәм инде кояшта янарга өлгергәннәр иде. Болай да каратут йөзле Солтановны мин хәтта чүл гарәбенә охшаттым, Аитов, оялчан авыл малае төсле, мине күргәч ничектер югалып калды, уңайсызланды.

Алар белән мине аерым-аерым очраштырдылар. Башта Солтановны күрдем. Ул, булачак юрист бит, тикшерүче һәм прокурор алдында үзен өендәгедәй иркен тотты.

— Сез бу кешене беләсезме? — диде аңа капитан Горшенин, мине күрсәтеп.

— Беләм,— диде Солтанов, миңа сөзеп карап.
— Күптән танышлармы? Үзара мөнәсәбәтләрегез нинди иде?
— Кадыйровны мин тәүге һәм соңгы тапкыр быелгы Яңа елны каршылау мәҗлесендә күрдем. Үзара мөнәсәбәтебез нормаль дия алам. Ачуланышмадык, талашмадык.* Аралашуыбыз мәҗлестә танышканда бер-беребезнең кулларыбызны кысып, фамилияләребезне атаудан узмады.
Капитан Горшенин, Солтановның җавапларын беркетмәгә теркәгәч, миңа мөрәҗәгать итте:
— Сез, Кадыйров, Солтанов әйткәннәргә нәрсә өсти аласыз?
— Берни дә өстәмим, ул бөтенесен ничек бар, шулай әйтте.
— Солтановка берәр төрле дәгъвагыз юкмы сезнең?
— Очраклы танышлар арасында нинди дәгъва булырга мөмкин? Юк.
— Иптәш Солтанов, сез Кадыйровның милли чикләнгәнлеге турында нәрсә әйтә аласыз? Ул Яңа елны каршылау мәҗлесендә үзен ничек тотты, шуны сөйләгез әле?
— Аның милли чикләнгәнлеген тоймадым мин, ул турыда берни дә әйтә алмыйм. Кадыйров кәефсез иде шикелле ул көнне. Аз сөйләште, дорфаланмады, үзен тыныч тотты.
— Мәҗлестә эчтеме ул?
— Эчмәде, миңа ярамый, диде.
— Ә рус җырларын җырлауны ничек тыйды?
— Мин бу урында тыйды сүзен кулланмас идем, иптәш капитан.
— Тыйды урынына нинди сүз кулланыр идегез?
— Тәкъдим итте дияр идем.
— Йә, нәрсә тәкъдим итте?
— Рус җырларын җырлап туйгач, үзебезнең татар җырларын җырларга тәкъдим итте.
— Рус җырларын ул хурладымы?
— Юк, без ул җырларны көн саен радиодан да ишетәбез, җай чыккан саен җырлыйбыз да, ә милли җырларыбызны рус җырлары исәбенә еш кына үги итәбез, безнең үз җырларыбыз да рус җырларыннан алама түгел, әйдәгез, хәзер аларны җырлыйк, диде.
— Мәҗлестә аның бу тәкъдименә берәрегез каршы килдеме?
— Юк, һәммәбез дә рәхәтләнеп риза булдык.
— Кадыйров, сезнең иптәш Солтановка нинди дә булса соравыгыз бармы?
— Юк, ул бернине дә арттырмады да, киметмәде дә, эш ничек булса, шулай сөйләп бирде.
Кара-каршы очрашу беркетмәсенә башта Солтановка, аннары миңа кул куйдыргач, мине камерама озаттылар. Ләкин 10—15 минуттан тагын тикшерүчем кабинетына алып менделәр. Бу менүемдә анда икенче очраклы танышым Аитовны күрдем.
Капитан Горшенин аңа мине күрсәтеп:
— Сез бу кешене беләсезме? — дип сорагач, ул миңа теләр-теләмәскенә карап алды да, акрын гына:
— Беләм дә, белмим дә кебек,— диде.
— Ничек инде ул, беләсез дә, белмисез дә? Фамилиясе ничек аның, әйтә аласызмы?
— Кадыйров бугай. Мин беренче күргәндә ул мондый түгел, чәче бар, таза иде,,инде коры сөяккә калган. Хәзер элекке кыяфәтен тик чалымларлык кына.
— Кадыйров белән сезнең үзара мөнәсәбәтегез ничек иде? Аңа ачу тотмыйсызмы?
— Бөтенләй белмим диярлек мин аны, бернинди ачуым да юк.
— Сез Яңа елны каршылау мәҗлесендә таныштыгыз бит. Сөйләгез әле, ул мәҗлесне ничек үткәрдегез?
— Мәҗлес гадәттәгечә үтте. Эчтек, күңел ачтык, җырладык, биедек.
— Кадыйров нишләде?
— Мин аңа игътибар итмәдем, ул күбрәк тик утырды бугай.

— Кадыйров жырладымы?

— Анда без барыбыз да жырладык, Кадыйров та читтә калмады.

— Рус жырларын жырладымы ул?

— Жырлады.

— Рус жырларын калдырып, татар жырларын жырларга кем тәкъдим итте?

— Кадыйров.

— Ничек тәкъдим итте?

— Житәр рус жырларын жырлау, үзебезнең татар жырларын жырлыйк, диде.

— Сез январь аенда бу турыда үзегездән сорау алганда, житәр рус жырларын жырлау, туйган алардан, диде дигән идегез, шул сүзләрне хәзер дә кабатлый аласызмы?

Аитов, бу сораудан агарынып бөреште, башын түбән иде.

— Кабатлыйм...

— Кадыйров, сез иптәш Аитовның әйткәне белән килешәсезме?

— Юк, мин алай әйтмәдем, рус жырларын жырлаганда үз жырларыбызны үги итмик, әйдәгез аларны да жырлыйк, дидем.

— Иптәш Аитов, моңа сез нәрсә әйтәсез?

— Мин әйткәнемнән танмыйм, беренче сорау алганда ялганласам, хөкемгә тартылырга кисәтелүемне раслап кул куйдым.

— Их, син,— дидем мин әрнеп,— ялганламыйсың, имеш. Әйт дөресен, күпмегә сатылдың син? Мине коры сөяккә калдыручыларның берсе үзең түгелме? Хәзер аның элекке кыяфәтен чамаларлык кына, имеш. Кеше түгел син, адәм актыгы!..

— Кадыйров, телеңне тый, шаһитне мәсхәрәләмә, тынычлан,— диде миңа тикшерүчем.

Прокурор Солтанов белән очрашканда да, Аитов белән очрашканда да ләм-мим сүз әйтмәде.

## 2

Бер көнне камерада Л. Н. Толстойның «Сугыш һәм дөнья» романын мавыгып укып утырганда (майор Салихов үтенечемне канәгатьләндерде, аның янында булганның икенче иртәсендә үк миңа шул китапны китерделәр) күрше камераларның берсендә кемнеңдер әтәч булып кычкыруын ишетеп башымны күтәрдем. Тавыш тагын кабатланды. Аптырап як-ягыма карандым. Башымнан, кемдер акылдан шашкан күрәсең, дигән уй узды. Ул да булмады, әтәч булып кычкыручы әллә нинди ямьсез тавышлар чыгарып кычкырырга, төрлечә сүгенергә, мәче кебек мыраударга, эт шикелле өрергә, кешнәргә тотынды. Озак та үтмәде, ул бөтен көченә төрле командалар бирә башлады, бераздан командалар бала кебек ими сорап елауга күчте. Бу сәер спектакль ничек кинәт башланса, шулай кинәт тынды да. Бер үк вакытта үзен әтәч тә, эт тә, мәче дә, командир да, имчәк баласы да итеп санаучы мескен бәндәне надзирательләр кереп бүлделәрме, ул үзе арып туктадымы,— белә алмадым. Аны мин, менә биредәге шартлар кешене нишләтә, дип чын күңелдән кызгандым. Кем икән ул, нәрсә өчен кулга алынды икән, дигән кызыксыну миемне тинтерәтте. Уңъяк стенама да, сулъяк стенама да шакып карадым, җавап бирүче булмады. Мәҗит белән без теге вакытта стена аша шакышып тик ике генә көн сөйләшеп калдык, әллә аны башка камерага күчерделәр, әллә бөтенләй чыгарып җибәрделәр, белә алмадым. Сәер спектакль исә икенче көнне дә, өченче, дүртенче көннәрдә дә кабатланды. Репертуары аның бай түгел, ярлы иде. «Артист»ның чыгышына тагын кәҗә мекердәве, сыерны-үгезме мөгрәве, дуңгыз мыркылдавы, ишәк бакыруы гына өстәлде. «Артист»ка ишәк тавышы аеруча ошый иде шикелле, ул аны бер кабатлый башласа, тамагы карлыкмый кабатлаудан туктамый иде. Шулай берәр атна чамасы үткәч,

төрмә элекке тынычлыгына кайтты. Соңыннан тоткыннарга һәм надзирательләргә бу сәер спектакльләрне оештыручы «артист»ның Татарстанның элекке прокуроры Надеев булганын, аның ришвәтчелеге өчен утыртылуын сөйләделәр. Кулга алынганнан соң бу хәсрәт «закон сакчысы», катгый хөкемнән җиңел генә котылырга ниятләп, акылыннан шашуны симуляцияли башлаган. Аны Казандагы бөтен Союзга билгеле психиатрия шифаханәсенә салып җентекләп тикшергәннәр, ләкин республика юстиция генералының акылы зәгыйфьләнүне расламаганнар, ул сәламәт, акылының нормадан тайпылышы юк, «авыру» акылдан шашкан булып кылана гына, дигән нәтиҗә чыгарганнар. Сугыштан соң Казанда законсыз юл белән дәүләт чималыннан сабын кайнаткан һәм әлеге сабынны сатудан килгән акчаны тулысы белән үз кесәләренә салып барган бер төркем махинаторлар, эшләгән җинаятьләре фаш ителгәч, судан мөмкин кадәр корырак чыгу өчен, республика прокуроры Надеевка 200 мең сум ришвәт биргән булганнар. Республика прокуроры аша алар җиңел юл белән көч куймый табылган акчаларына Казандагы хөкем органнарында эшләүче бик күп эшмәкәрләрне сатып алуга ирешкәннер. Махинаторлар кәгазьдә «Динамо» спорт җәмгыяте хезмәткәрләре саналганнар. Эчке төрмәдә мин утырганда аларны футбол командасы дип йөртәләр, алар 12 кеше иде шикелле. Берничә миллион сум дәүләт акчасын үзләштергән бу «футболчылар»га Казандагы Фимида әһелләре кайсына бер ел, кайсына ел ярым, кайсына ике ел срок биреп, семьяларыннан еракка озатмыйча, җирле хезмәт белән төзәтү колониясенә утырткannar. «Футбол командасы» членнары колониядә курорттагы шикелле яшәгәннәр. Ник яшәмәскә, аларның ришвәт бирүдән калган урлаган акчалары җитәрлек булган, яңнарына көн аралаш диярлек якыннары, «буялмый» иректә калган иптәшләре килеп торган. «Футболчылар», эшләгән җинаятьләре өчен бирелгән аз срокларга да канәгать булмыйча, эшләрен яңадан карауны таләп итеп, СССР Верховный судына, Сталинга, ВКП(б) ҮКына һәм башка инстанцияләргә шикаять артыннан шикаять язганнар. Сабынчы махинаторларның җирле хезмәт белән төзәтү колониясендә аркылыны буйга да алып салмыйча яшәүләре, үзләрен иректәге кебек иркен тотулары андагы барлык тоткыннарның саруларын кайнаткан. Күп тә үтми, складында биш кисәк сабын җитмәгән өчен хөкемгә тартылып утыртылган бер элекке склад мөдире СССР прокуратурасына үз җинаяте белән «футбол командасы» членнары җинаяте арасында нинди аерма барын, нигә «футболчыларга», дәүләткә миллионлаган сум зыян китерсәләр дә, бер елдан алып өч елга кадәр генә сроклар бирелүен, үзенә исә складында биш кисәк сабын җитмәгән өчен дә ун ел чәпелүен аңлатуны сорап хат язган. Шуннан соң, күпмедер үткәч, сабынчы махинаторларның эшләрен яңабаштан тикшергәннәр. Нәтиҗәдә, аларны беренче тапкыр хөкем иткән судьялар да, бу җинаятьне ак җеп белән аннан-моннан гына теккән тикшерүчеләр дә, ата ришвәтче республика прокуроры Надеев та, махинаторлар үзләре дә хөкемгә тартылып, тиешле җәзаларын алганнар. Надеев, хөкем вакытында, психик авыру икәнен исбатларга тырышып, судьяларга үз тизәген ашап күрсәткән, әмма аңа бу иң соңгы чарасы да ярдәм итмәгән, ул тиешлесен алган. Кешене нәфесе, комсызлыгы нинди генә түбәнлекләргә төшерми дә, нинди чирканыч эшләр эшләтми!..

Сәгать уннар тирәсендә шартлап ишектәге кормушка капкачы ачылды һәм аннан бетчә битле старшинаның чытык йөзе күренде.

— Фамилияң? — диде ул, теш арасыннан гына.

— Кадыйров.

— Передача ал.

— Нинди передача? Кемнән?

Ачылган кормушка капкачында эреле-ваклы кәгазь төргәкләр пәйда булды. Мин аларны алырга да, алмаска да белми аптырап калдым. Кемнән бу передача, кем мине искә төшергән? Бәлки, майор Салихов оештыргандыр аны?..

Старшина ашыктырды.

— Нигә катып калдың, ал тизрәк, монда бер син генә түгел, башкаларга да бирәсем бар.

— Алмыйм. Миңа передача кирәкми.

Старшинаның күзләре шакмак булды.

— Ничек алмыйсың?

— Шулай алмыйм.

— Вәт сантый!.. Әйдә, менә бу кәгазьгә кул куй да, китәм мин, синең белән сатулашырга вакытым юк...

Старшина миңа уч төбе кадәр генә кәгазь тоттырды. Анда фамилиям, инициалларым куелган һәм төргәкләрдә нәрсәләр барлыгы язылган булып чыкты. Язучының кулын танымадым.

— Передачаны китергән кешесенә кире кайтарыгыз, мин аны алудан баш тартам,— дип кәгазьне старшинага кире бирдем.

— Мөгаен, акылың зәгыйфьләнгәндер синең,— диде ул, минем киреләнүемә үртәлеп.— Передача китергәч, берәүләрнең авызлары колакларына җитә, кош тоткандай булалар, кем әйткәндәй, башлары күккә тия, ә син тинтәк аңардан баш тартасың. Ал, ач бит син...

Адәм көлкесе, монда утыртылуымның икенче көнендә үк яңагыма кундырган бәндә, бүре сарыкны кызганган кук, мине кызгана...

— Кем китергәнен белми торып, алмыйм мин аны.

— Мәйлең.— Старшина кәгазь төргәкләрне кочагына җыеп, кормушка капкачын япты...

«Кем дөньяда барлыгымны искә төшергән, кемгә кирәгем чыккан?» — дидем, гаҗәпләнеп үз-үземә. Передачаны алмый дөрес эшләдемме? Тукта, нәрсәләр бар иде әле анда? Прәннек, шоколад, конфетлар, печенье, казылык, май, күмәч. Папирос һәм шырпы юк. Димәк, аны китергән кеше минем тартмавымны белә. Кем ул? Мине якын итеп аз гына булса да ярдәм кулы сузарга карар биргән кешенең әйберләрен алмый дөрес эшләдемме?.. Дөрес эшләдем, минем иректә калган кешеләр белән берниндн бәйләнешым да юк. Тукта, бәлки аны Мәҗит Рафиков китергәндер?.. Алай дисәң, монда утырып чыккан кеше передачасында тәмтомнарга басым ясар идеме? Юк, әлбәттә. Без монда прәннек, конфетлар, шоколад, печеньеләр турында уйламыйбыз, бер туйганчы кара ипи ашарга хыялланабыз бит...

Бераздан кормушка капкачы тагын ачылды. Аннан бетчәле бит старшина башын сузып:

— Әйдә, ашамлыкларыңны ал, аларны сиңа Ольга исемле чибәр кыз китергән. Тизрәк ал, җылый ул анда, үпкәләтмә аны, кеше бул,— диде.

Ольга исемен ишеткәч, мин югалып калдым. Ул минем турыда уйлый, борчыла, онытмаган, ә мин аны инде күптән исемнән чыгарган идем бит, үз кайгым кайгы иде...

Мин кәгазьгә «Оля, син миңа бүтән берни дә китермә, зинһар, оныт мине», дип язып, передачаны алдым, старшинаны:

— Яңадан ул кыздан беркайчан да передача кабул итмәгез,— дип кисәттем.

Оля!.. Оля!.. Бу китергән әйберләрең белән нигә син миңа үзеңне искә төшердең? Мин инде сине күңелемнән бөтенләй сызып ташлаган идем. Шәхси бәхетенә юлы киселгән кешенең сиңа нигә кирәге бар? Безнең арабызда син Васильевода төшеңдә күргән тирән упкын бит. Хәзер без — икебез ике дөнья кешеләре. Синең болай да тормышың авыр, нигә аны минем турыда кайгыртып тагын да авырайтырга?..

Минем бу газаплы уйларым Оляга барып җитмәделәр, әлбәттә, үземдә калдылар. Кайдан белгән ул монда эчке төрмәдә утыруымны, кем әйтте икән, әйе, кем әйтте икән?..

Минем күз алдымда 1937 елда, әтине эзләп әни белән Казанга килгәч, әтигә передача бирергә иртәдән кичкә кадәр салкын урамда озын чиратта торуыбыз яңарды. Анда бер генә ир-ат та юк, тик хатын-кыз һәм бала-чагалар гына иде. Ул чиратта торучы кешеләрнең хәсрәтле борчулы чырайлары кабеременә хәтеремә уелдылар. МГБ бинасы алдында андый чират

әле дә шулай озынмы икән?.. Оля аңа бәлки таңнан ук килеп баскан булгандыр. Эштән соң яки эшкә барганда килгәндер ул каһәрләнүчеләр арасына. Нәрсәләр уйлады икән Оля?.. Мин аңа яңадан передача китермәскә кушып дөрес эшләдем. Килмәсен ул монда яңадан, болай да иңрәп әрнегән йөрәк ярамны миһербан-шәфкате белән тоз сипкәндәгедәй әрнетмәсен...

## Унберенче бүлек

### 1

Кулга алынуыма инде алтынчы ай китте, әмма тоткын тормышына һич күнегә алмыйм, иректәге тормыш йоклаганда да исемнән чыкмый—төшемә керә. Кыяфәтем инде тере мәетне хәтерләтә булыр, чамасыз ябыктым, шыр сөяккә калдым. Хөкүмәт, безне асрауга юмартлык күрсәтеп, тәүлеккә дүрт йөз грамм искергән ипи (ул кайчакта бөтенләй күгәреп беткән, авызга да алмаслык була), бер чәй кашыгы шикәр комы, иртән һәм кичен суррогат кофеле яки чәй димәсәң хәтере калырлык җылымса су, көндез ярты тәлинкә ачы кәбестә шулпасы белән шырпы кабы зурлык тозлы балык кисәге, бер кашык кысыр сыек тары боткасы, кичен тагын шул ук күләмдә бирелгән солы кесәле җан сакларлык кына. Башта, төрмәгә кергәч тә, камера идәненең буе биш, иңе өч адым гына булса да, мин ишекле-түрле йөрергә тырыша, кайбер көннәрне өзлексез егермешәр, утызар мең адым ясый идем. Алай вакыт та тизрәк үтә сыман тоела, адымнарны санауга мавыгып, авыр уйлардан күпмедер арынып та торыла иде. Хәзер алай йөри алмыйм, утыз-кырык адым атлауга башым әйләнә, күз алдымда аллы-гөлле, күкле-яшелле, сарылы-кызыллы очкыннар бии башлый. Ашау җитмәү галәмәте бу. Надзиратель хатынга минем стенага беркетелгән урындыкта кагаеп утыруым ошамый. Ул ишектәге бүре күзенә баш бармагы сыярлык борын тишекләрен терәп һаман:

— Утырма, тор, йөре, йөре!..— дип боера тора.

Минем йөрер рәтем көннән-көн төкәнә барганын белми Песнәк! Мин аның исемен белмим, башына кара берет, муенына кара шарф бәйләп, өстенә сары кофта кигәнгә аңа Песнәк кушаматы тактым. Үтә чәүчәлә к надзиратель Песнәк, камера эченә ике-өч минутта бер күз салмаса, сакчылык вазифам төгәл үтәлмәс дип курка, күрәсең. Ул бүре күзеннән карагандa син стенага да сөялеп торма, тик тә утырма, ишеккә дә якын килмә. Өендә дә шулай булса, гаилә әгъзалары ничек түзәләрдер аңа, белмим. Хәер, гаиләсе бармы икән ул хәсрәтнең? Юктыр, дорфалыгына артка борылып карамый качарлык бит аның. Ир надзирательләрнең күбесенең коридорда барлыкларын да сизмисең. Алар кизү торганда өстәлгә таянып азрак черем итеп алырга да була. Ә юбкалы дәҗҗаллар кизү чакта андый иркенлектән тоткын мәхрүм.

Инде бер атна була, камерамда мин ялгыз түгел, иптәшем бар. Иптәш дигәч тә ике аяклы, ике куллы, кирәк чакта гәпләшерлек иптәш түгел,— чебен ул.

Ялгыз камерада кеше хәтта чебенгә дә шат. Үз янында җан иясе барын тою зур бәхет.

Камерама чебен ачык форточкадан очып кердеме, коридорданмы, искәрми калдым. Ул беренче тапкыр мин өстәлгә таянып уйланып утырганда беләгемә килеп кунды. Шатланып:

— Исәнме,— дидем аңа, акрын гына.— Кемнән сәлам алып килдең миңа?

Чебен алгы аяклары белән ашыкмый гына битен юды, аннары арткы аяклары белән сыпырып канатларын төзәтте. Мин аны суларга да куркып күзәттем. Мин менә ул хәзер беләгемнән күтәрелер дә, форточкадан очып чыгып китәр төсле тоелды. Әмма чебен, арыган иде ахры, беләгемнән аерылырга ашыкмады.

— Утырма, тор, йөре, йөре! — диде надзиратель хатын коридордан.

— Утырсам ни дә, торсам ни сиңа, дәҗҗал, дидем аңа үртәлеп эчемнән. Тәртип бозсам, черем итеп утырсам икән. Күрә бит йокламый уйланып утыруымны, юк, үзенекен тукымаса, Песнәк булмый ул.

Теләр-теләмәс кенә урынымнан тордым. Чебен беләгемнән аерылып өстәлгә кунды. Мин җиңел сулап куйдым. Бәхетем бар икән, мине камерада ягъызымны калдырып чыгып китмәде ул. Чебенне куркытудан шөлләп сак кына ишекле-түрле үттем. Кунагым исә өстәлдән кузгалмады, тын гына утыра бирде. Куркак түгел икәнсең ләбаса үзең, дип уйладым шатланып. Үземә ияләштерү өчен нәрсә белән сыйларга икән сине? Бернием дә юк шул. Кунакка килереңне белсәм, ичмасам шикәремне калдырган булыр идем, белмәдем...

Кунагым камерадан чыгып китәр дип куркуым юкка булды. Чебен ул көнне дә, икенче, өченче, дүртенче көннәрне дә, аннан соң да беркая да китмәде, янымда калды. Миңа аның белән күңеллерәк булган кебек, аңа да минем белән күңелле иде, күрәсең. Мин йокыдан тору белән ул, сәламләгән кебек, тирәмдә оча башлый, иртән ипи, чәй, шикәр комы биргәч, өстәлгә кунып, үзенә өлеш чыгарганымны көтә. Мин аны шикәрле суда җебетелгән ипи кисәгеннән болай да өзмим өзүен, әмма чебенгә иске «ризыгы»ннан яңасы ошыйрак төшә шикелле. Мин прогулкага чыкканда ялгызы калгач, ул нишли торгандыр, белмим. Ә прогулкадан кергәч, шатлангандай тирәмдә бөтерелүе хак. Аңа мин инде шундый күнектем, күренми торса, борчылып эзли башыйм. Ул исә йә стенага, йә идәнгә, йә ишеккә кунган була. Торып йөри башласам, яныма килә. Кешеләр дә шул риясыз чебен кебек дуслыклы, хыянәтсез булсалар икән. Аны камерага беркем дә көчләп кертмәде, үзе килеп керде, форточка ачык, ул теләгән вакытында чыгып китә ала. Юк, чыкмый, ялгызлыкның газап, тилмерткеч җәфа икәнен аңлагандай минем белән камерада яши бирә. Рәхмәт, чебен дус, игелеклелегең өчен рәхмәт сиңа...

Ниһаять, тикшерүчем мине Риан белән кара-каршы очраштырды. Надзиратель мине Горшенин кабинетына менгергәндә Риан анда иде инде. Аны идәнгә беркетелгән табуретка кунаклатмаганнар, гадәти урындыкка утыртканнар, табурет миңа калган. Исәнләшүемә, тикшерүчем белән прокурор җиңелчә генә баш кактылар, Риан исә без әле берничә көн генә күрешмәгән кешеләрчә киң елмаеп:

— Сәлам, картлач,— диде.

Аның арабызда берни булмагандай, хаиннәрчә елмаеп сәлам бирүе, тикшерүче кабинетында үзен өендәгечә иркен тотуы җенемне чыгарды. Миңа ул хәр күренергә тырышса да, кыяфәтеннән аның да әллә ни әтәчләнер җире калмаганын аңладым. Эчке төрмә аны да үз калыбына утырткан: башы минеке кебек үк такыр, «классиклыгын раслап» иңнәренә үк төшеп торган ялын кырыкканнар, чиертсәң каны чәчрәп чыгарлык тулы бит алмалары шиңеп суырылган, кояш ашаган имчәкле бәрәңгене хәтерләткән шешенке симез борыны юкарып яңа гына бәбкә чыгарган ана казның ни аксыл, ни көксел томшыгы төсенә кергән, колаклары әрсез агач гөмбәсе күк тырпайган, иреннәре ямьшәйгән. Бу кыяфәтендә ул калын пыялалы күзлеген салып урамда очраса, аны мин хәзер танымас идем. Ирексездән башымнан, бәлки тышкы кыяфәте белән бергә акылы да үзгәргәндер бу хамелеонның, дигән уй узды. Косарлык бит, ничек егетләрчә тотарга тырыша үзен... Бөкрене кабер генә төзәтә, дип юкка әйтмәгән бабайлар. Ул нигә шулай кәпрәя, аңлый алмыйм. Юк, аңардан мәрхәмәт көтәрлек түгел, оятын да, намусын да югалткан ул. Бәлки кешелек сыйфатлары аңарда туганда ук булмагандыр?.. Камерада мин аның акылына килүе мөмкинлегенә, миңа яккан уйдырмаларыннан баш тартуына өметләнгән идем. Ахмакның акылы үзгәргәнне көтсәң, мәгълүм әкияттәге ач төлкенең болында утлап йөргән үгезнең йомыркалары өзелеп төшкәнне көтеп, үзенә башка азык эзләми ачтан аяк сузуына иш буласыңны көт тә тор...

Капитан Горшенин, прокурор белән нәрсә турындадыр шыпырт кына сүз алышкач, Риан белән миңа текәлде.

— Ярый, эшкә керешик,— диде ул, кулындагы ручкасын карага манып.— Сезнең икегезгә дә бер үк сорауны куям: сез танышлармы?
— Танышлар,— диде Риан, миңа елмаеп карап.
Мин, әйе, дигәнне аңлатып баш кактым.
— Бер-берегез белән арагыз ничек?
— Нормаль шикелле,— диде Риан.
— Нормаль иде,— дидем мин дә.
— Димәк, бер-берегезгә бернинди дәгъвагыз да юк?
— Юк,— диярга ашыкты Риан.
— Элек юк иде бугай,— дидем мин.
— Ә хәзер?
Риан сагаеп миңа карады.
— Хәзер бар,— дидем мин.
— Хәзергесе исәпкә алынмый,— диде тикшерүче.
Мин гаҗәпләндем.
— Ничек исәпкә алынмый? Минем Саттаровка берничә соравым бар, шул сорауларыма аның җавапларын ишетми торып, безнең бу кара-каршы очрашуыбыз тиешенчә үтәр дип санамыйм. Гражданин прокурор, Саттаровка мөрәҗәгать итәргә мөмкинме?
— Итегез, ләкин аңа биргән сорауларыгыз эшегездән читкә чыкмасын.
— Рәхмәт. Риан, яшерми әйт әле, безнең прогрессив егерменче гасыр уртасында син ничек итеп хаин Иуда Искариот юлына баса алдың? Бу — бер. Инде икенче сорау: башкаларга яла якканың өчен сиңа күпме түләделәр?
Аңарчы зур эш кырган кеше кебек кәпрәеп утырган Риан бөрешеп, башын түбән иде, гүя, тишелгән шар кебек, эчендәге бар һавасы чыгып бетте, мескенләнеп калды. Әмма бу озакка сузылмады, ул үзен тиз кулга алды.
— Мин берәүне дә сатмадым, Ирек, ялгышасың. Сезгә мин, беләсең килсә, һәлакәт упкыныннан чыгарга кул суздым.
Рианга тикшерүче капитан Горшенин ярдәмгә килде.
— Ярый, әрепләшүне бетерик, төп мәсьәләгә күчәбез. Беренче сорау — сезгә, Саттаров. Безгә биргән Кадыйровка кагылышлы мәгълүматларыгызны аның үз алдында раслыйсызмы?
— Нинди мәгълүматларны, мәсәлән?
— Аның совет строена, партия политикасына, колхозларга, илебездәге тормышка, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга яла ягуларын һәм башкаларны.
— Раслыйм, әлбәттә.
— Ә сез, Кадыйров, моңа нәрсә әйтәсез?
— Мин үземнең элекке җавапларыма берни дә өсти алмыйм. Миңа Саттаров яккан бөтен нахак гаепләр — уйдырма.
Риан җанланды, ул зәңгәрсу төстәге калын күзлеген ялтыратып миңа:
— Илебездәге сайлау кампанияләре турындагы әңгәмәбезне хәтерлә син, бездә демократик сайлаулар юк, югарыда утыручы түрәләр алар җырын җырлаучы, алар хуп күргән, аларга якын кешеләрне депутатлыкка кандидат итеп билгелиләр дә — шуның белән вәссәлам. Сайлаучыларның сайлау урналарына бюллетень төшерүләре тик гомуми спектакльдә катнашу, сайлауларга берни белән дә бәйләнмәгән формаль акт кына, диген идең. Бу да мин уйлап чыгарган оятсыз уйдырмамы? — диде.
— Юк, бусы уйдырма түгел, бусы синең иудалыгыңның кире каккысыз дәлиле — агулы тешләреңне минем намусыма тагын да тирәнрәк батырырга тырышуың, хаин әфәнде. Ә бит сайлаулар турындагы әңгәмәне мин түгел, син башлаган идең. Үзеңне шундый тугры, саф намуслы итеп санагач, нигә син мине шундук төзәтмәдең, ялгышымны йөземә бәреп әйтмәдең? Безнең сайлауларда бер урынга бер генә кандидат билгеләнүе, альтернатив кандидатлар теркәлмәве, билгеләнгән бер кандидатның да халык тарафыннан түгел, югары органнар тарафыннан күрсәтелүе дөрес түгелмени?..

Прокурор янә Саттаровка мөрәҗәгать итте:

— Кадыйровны сез милләтче дисез. Аның милләтчелеген ничек һәм нәрсә белән дәлилли аласыз?

— Күп нәрсәләр белән. Ул безнё — татарларны руслар басып алдылар, татар теле, татар культурасы бетүгә хөкем ителде, республикабыздагы югары уку йортларына татар егетләренә һәм татар кызларына кереп укый алу авыр, гарәп графигындагы алфавиттан башта латин алфавитына, латин алфавитыннан рус графигына күчереп безне халкыбызның бөтен язма мирасыннан колак кактырдылар, дигән фикердә тора.

— Бу да сезгә яла ягумы, Кадыйров?

— Әйе, Саттаров миңа үз фикерләрен тагарга азаплана. Мин андый уйда түгел, руслар белән безнең дуслыгыбыз ерак гасырлардан килә. Сезгә мин моны дәлилләү өчен бөек Тукаебызның: «Рус белән тормыш кичердек сайрашып, тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып» — дигән юлларын янә хәтерегезгә төшерәм.

Мин үземнең гаепсезлегемне ничек кенә дәлилләргә тырышсам да, тикшерүчемнең Риан белән кара-каршы очраштыруы минем файдага булмады. Риан үз дигәнендә, мин үз дигәнемдә калдым. Ул җитлекми туган күзлекле ахмак нигә шундый түбәнлеккә тәгәрәгәндер, үтерсеннәр, аңламыйм. Мине һәм тагын кемнәрнедер иректән мәхрүм иттерүдән аңа дөнья иркенәйдеме? Әллә ул таш капчыкта ялгызым гына булмыйм, мин газапланганда дусларым рәхәт чикмәсеннәр, алар да минем белән бергә интексеннәр дидеме? Көнчелек корты бәндәне ниләр генә кыландырмый, нинди генә этлекләргә этәрми. Андый тар күңелле, йөрәкләре урынында мүкле таш яткан адәм актыклары күктән төшмиләр, арабызда яшиләр, безнең белән бер үк һаваны сулыйлар, кемнәрнедер яраталар, нәсел калдыралар бит. Сугыш вакытында без фашистларның кеше икәнлекләренә шикләнә, аларны ике аяклы җанварлар итеп күз алдыбызга китерә идек. Рианның, Риан ише үтләвекләрнең, капитан Горшенинның, өлкән лейтенант Хафизовның, полковник Литманның, эчке төрмәдәге байтак надзирательләрнең гаепсез кешеләрне газ камераларына, крематорий мичләренә һәркөнне меңәрләп озаткан вәхши фашистлардан аермасы нәрсәдә соң?

Тикшерүчем мине Риан үзенең шаһитләре итеп күрсәткән фатирдашлары Вил Йозаев һәм Алексей Әүдәкиев белән дә кара-каршы очраштырды. Ноль белән Әпчи дә (Риан шаяртып Вилне — Ноль, Алексейны — Әпчи дип атый иде) минем чит илләрдәге тормышны күкләргә күтәреп мактавымны, безнең көнкүрешебезне эттән алып эткә салып хурлавымны, патриот түгеллегемне сөйләделәр. Аларга мин тротуарлар астындагы теплотрассаларда, тузанлы салкын чардакларда, караңгы юеш подвалларда, кысан утын сарайларында ачлы-туклы яшәгән, торыр урыннары булмаган ватандашларымның тормышларына сокланырга, чит илләрдә үз күзләрем белән күргән һәркайсы шәхси бүлмәләрендә яшәүче, бар нәрсәләре мул, житеш «мескеннәр»не яманларга, сүгәргә тиеш булганмын, күрәсең. Берәр вакыт үз-үзебезне алдамый яши торган заман килерме икән безгә, беләсе иде...

*Ахыры киләсе санда*

# Равил Фәйзуллин

## Казан алды

Казан арты! Казан арты!
Телдән төшмәгән яклар!
Булгандыр бит Казан алды
дип тә йөртелгән чаклар.

Кала түгел, абзарның да
була арты, ал ягы...
Фасад ягына эленә
һәр Ил-Йортның байрагы!

Казан алды! Казан алды!
Зөяле ул, Иделле!
Шушы якларны камады
яулар килеп иң элек.

Идел күрке булган Казан —
калаларның шанлысы.
Агым булып ташып төшкән
дулкыннарның канлысы.

Дошман явы җир җимертеп
аударгач төп капканы,
Казан алдында коелган
күпме асыл зат каны!

Казан алдында күпләрнең
яшәү җелеге кипкән.
Казан алдында Ил-бишек
ватылып-тузгып беткән...

...Фаҗига — башларны яргач,
зиһенне «ача» икән!
Җиңгәннәр — итеге белән
күзеңә баса икән!..

Шул чагында исән калган
калаламы калада?
Казан артына күчә Ил
арбада һәм чанада.

Көнчыгышка таба кемдер
җан саклап качып киткән,
кемдер, көч белән кайтырга
үч белән ярсып киткән.
Киткән...
Киткән!..
Киткән!..

Инде менә ничә гасыр
Казан арты ал булган.
Шул төбәктә тамырланып
Калган милли бар-булган.

Без беркадәр белгән тарих
шушы якка тоташа
Курсавыйлар, Мәрҗаниләр,
Тукай, Камаллар аша.

Бүген дә әле бу төбәкнең
байтак асыл затлары
арабызда. Эшләренә
мөһер — халык яклавы.

Тәкъдир итик, даннар юллыйк
шанлы Казан артына,
булган һәм янә булачак
Казан алды хакына!

...Менеп бас та, Сөембикә —
Хан мәчете кашына,
Казан алды әкият булып
җәйрәп ятыр каршында!

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943) — *шагыйрь, татар һәм рус телләрендә басылган күпсанлы китап авторы, Г. Тукай һәм М. Җәлил премияләре лауреаты, Бөтендөнья Рыцарьлар җәмгыяте әгъзасы. Казанда яши.*

Бу иркенлек — безнең җир бит,
безнең җир бит бу Ватан!
Безнеке бит бу искән җил,
безнеке бит бу ал таң!

Казан өстеннән ераграк
күренә шул офыклар.
Бөек Болгарга табамы
ашыга бу болытлар?

Ярга каккан дулкыннарның
юлы дисез кайларга?
Агабазар аша күчә
борынгы Сарайларга!

Юлында — безнең зурлыкка
шаһит таулар, атаулар...
Күпме тарихи катламнар
безсез өнсез яталар!

Биеклектән тирәнлеккә
бак, ачылыр үткәнең —
Иделнең тулысы белән
безнең елга икәне...

Җанга, канга, җырга сеңгән
Иделе, даласы да...
Мишәре дә, типтәре дә
һәм нугай баласы да.

Теге чакта, Казан аугач,
дошман әйткәндер: «Бетте!..»
...Таш ярыр гөлләр шикелле
яшь буын үсеп чыгасын
шәһитләр белми китте...

Казан алды алынды, дип,
баскын туйлаган чакта,
Шомбай кебек, вакытлыча,
бордырдык алны артка.

Алдыбыздан алынып килә
җәбер-золым япмасы.
Казан алды түгелме соң
Шәрык-гәреп капкасы!

Казан алдында очрашыр,
ил-дәүләтләр кул биреп,
Сәяхлар сокланып узар,
«Татар иле шулмы?» дип.

Хаклыкка йөз белән карап,
бәйсезлек яулаганда,
үз әләмебез астында,
дөнья шаһит булырлык
көрәшләр тора алда.

Безгә күптән вакыт инде
бу дөньяның уңын-сулын,
алдын-артын аңларга!
Биеккә карарга өнди
манарада айлар да.

Казан алды! Казан алды!
Телгә менәчәк яклар!
...Тарихларда калып бара
«Казан арты», «Казан арты!» —
дип кенә әйткән чаклар.

## Үткәннәр — бүгеннең башы...

*Ялгыз калулардан куркасың син.*
*Тынлыгыңнан өркеп качасың...*
*Килми синең үткәннәргә кайтып,*
*Хатирәләр бигең ачасың.*

Хәтерләүләрдән курыкмыйм.
Нигә куркырга?
Хурлык-каза китермәдем
Идел-Йортыма.

Әгәр кемдер үткәннәргә
күзен йоммакчы,
димәк, гөнаһсы аның
көн кебек ачык.

Нинди серле мәкерне дә
Вакыт бер чишә!
Кешелекне кеше иткән
Хакыйкать — чишмә!

...Безгә кадәр дә акыллар
булып киткәннәр.
Киләчәкне күреп була
фәкать үткәннән.

*

*Карап бак бер дөнья картасына —*
*күпме анда безнең исемнәр!*
*Әле исән калганы гына...*

Туган якта күпме атамалар! —
«яңартылганнар» да яңалар!
Төтен-бетон оялары корып,
яңа исем китереп тагалар...

Завод асларында сеңеп кала
җанга изге күпме исемнәр!
Алар әүвәл, чишмәләрдәй тибеп,
халыкның рухыннан тишелгән.

Килгән-киткәннәргә нәрсә исемең!
Җирең яхшы — бирсә акча, дан...
Шунсы авыр: бар бит арабызда
үз исемен дә саклый алмаган.

Әй, кардәшем!
Белмисеңме, тамыр корткан өчен
килер буын кызарып янасын?
Анаң иренәнә салыр суны
килмешәк кулына саласың!

*

Таулар кузгатыр идегез
Халыклар күчергәнче!
Икмәк үстерер идегез
Каберләрне сөргәнче!
Җырлар чыгарыр идегез
указлар чыгарганчы!
...Котырына шулай вәхши
үз канын чыгарганчы.

## Елан тавыннан карадым...

*(төш)*

Елан тавыннан карадым —
дуңгыз котүен күрдем.
Казансуда таш һәйкәлнең
агып китүен күрдем.

Елан тавыннан карадым —
Ослан тауларын күрдем.
Идел төпләренә багып,
сагыш ярларын күрдем.

Елан тавыннан карадым —
биш балта сабын күрдем.
Акпатшаның айбалтада
күзенең агын күрдем.

## Биеклек

Тау өсләрендә наратлар
җилләрдә чайкалалар.
Очлары белән күкләргә
нидер язмак булалар?

Бөркетләр узышып яулый
күкнең яңа катларын.
Янәсе, киң офык күрсен
хакимлек канатларын!

Төнге күктән күп йолдызлар
атыла яна-яна.
Биектәнрәк төшкәне
күзләргә сеңеп кала.

Кеше дә үрләмәкче гел...
Ә рухының — үз күге.
Кылган игелеге белән
үлчәнә биеклеге.

*

Санамагыз киткән торналарны!
Килер язны искә алыгыз...
Төркемдәге кошлар кимрәк чыкса —
сыкранып куяр җаныгыз.

...Ә кем белә: алар кайтканчы
тигез торырбызмы барыбыз?

*

Зәңгәр күктә бер ак болыт
җәйге эссе чиллэдә.
Аккош булып тибрәнә
җәйрәп яткан күлләрдә.

Ә һәр күлнең үз юравы:
ак болыт — аңа гына!
Керфек-камышлар эченә
бу бәхет таман гына!

Шул уйда һәр тымызык су
үзе йөзендәгегә —
коедагы да, баздагы да,
тояк эзендәге дә...

Ә болыт йөзә челләдә...
Күк йөзе — зәңгәр-зәңгәр!
Болытның да үз хыялы —
«Тулышып җитсәм әгәр,
ташлап бушлыкның катларын,
Җиргә төшеп килешкә,
кушылыр идем тамчы булып,
чишмәгә, йә инешкә».

Тәрәз ачып, бер чибәр кыз
толымын тарап тора.

Зәңгәр күктә ак бер болыт
тукталып карап тора.
Толымнарын сүтмәк булып,
шук җилләр исеп тора.
Җил тегермәне аларның
канатын кисеп тора.

## Арканланган ат янынннан үтә идем...

*(Куктубәдә булган хәл)*

Котырынып өскә килде ат.
Мин сискәнеп, абынып егылдым.

Керфекләргә тияр-тимәс кенә
яшьнәп үтте күздән тояклар.

Шул дүрт бәкәл, шул дүрт тояк
җыйган иде дүрт тарафның,
бар дөньяның бөтен дәһшәтен!

Минем өчен бу мәл юк иде
сәяхәт тә,
        ил дә,
            сөйгән дә...

Ята иде җирдә ихтыярсыз
коты очкан тере бер капчык.

...Ат ярсулы булган, ә мин гамьсез.
Күктә тургай иде, җирдә гөл.

# Рөстәм Мингалим

## Югалган яшен

И беренче мәхәббәтнең
якты да хәтәр чагы!
Онытылып бара идең,
ник искә төштең тагы?

Бик еракта калып яктың,
ара һаман үсте лә.
Инде картлык болытлары
өелә гомерем өстенә.

Онытылып бара идең,
һәм шулай кирәк иде.
Син сызып узган — җанымның
ярасы тирән иде...

Узыйм тагы бер, дидеңме,
җанының ярасыннан:
күкләрнең
күкрәген ертып
югалган яшен сыман?!

## Томаннарга таба илттеләр

Сары бодай кыры җилдә кайный,
әйләнәсе — тимер сак иде...
Үҗәтләнеп безнең үсеп йөргән,
гел ашыйсы килгән чак иде...
Бирмәделәр ипи туган якта,
читтә бәхет вәгъдә иттеләр.
Төяп-төяп безне поездларга,
томаннарга таба илттеләр.
Безне суга сипте пароходлар,
машиналар җиргә таратты.
Кемдер сугып тешне койды безнең,
каршылады кемдер яратып...

Әвереләдек моңлы килмешәккә,
чын йөрәктән җырлар чыгардык.
Җырыбызга тыгылып үләр чакта,
туган якны уйлап чыдадык.
Табалмадык анда бәхет димим,
бөтенләй үк бушкул кайтмадык.
Туган якка кайткач, күпләребез
энкәйләрне генә тапмадык.
Инде безнең күңел шул вакыттан
мәңгелеккә хәтле өшегән...
Киләчәкнең тимер түрәләре
ни күрсәтер тагы кешегә?!

## Кеше булыйк

Пычак алган имансызлар,
имансызлар учак яккан!
Чалынган ил чалкан яткан,
без сарыклар кебек калдык.
Илең сау көн, телең бар көн
килмәс димә — уйга килер!
Кеше булган уйлый белер,
без сарыклар кебек калдык.
Саттылар бит, алдадылар,
алдадылар әйдәп кенә,
Алдадылар әйбәт кенә —
без сарыклар кебек калдык.

Татарларым — толпарларым,
кайда тезген бирдегез сез?
Кемгә тезген бирдегез дә
без сарыклар кебек калдык.
Бүленгәнне — бүре ашый,
аерылганны — аю ашый,
бергә барсак — «дуслар» ашый:
без сарыклар кебек калдык.
Ярый бераз хәл барында
хәлебезне сизеп алдык.
Инде булсак — кеше булыйк,
без сарыклар булып калмыйк!

---

Рөстәм МИНГАЛИМ (1937) — *танылган шагыйрь, драматург, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән күпсанлы лирика һәм балалар өчен китаплар авторы. Ул — ТССРның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Чәчәк

Каян килә икән талау рухы,
алдау рухы килә кайлардан?!
Буып, талап, суеп байый берәү,
икенчесе талый аңардан...
Яна сүздә, күздә — көрәш уты,
тирә-юньгә янап, пешереп...
Җыелып, өелеп, сүгенеп сугышкан да,
сибелеп җирне талый кешелек.
«Изге» максат булып талау калды,
маяк булды — шулай таныл:
Нинди алла уйлап чыгардык та,
бу соң әле нинди табыну?
Мондый юлга ничек кердек икән,
чыгу юлын һаман күрмибез...
— Тиздән Җир дә бетә,
кешеләр дә
бергә бетә, — диеп йөрибез.
...Кешелекне кеше бетерсә дә,
Җир җилләнеп калыр төслерәк:
һәм
    җиңүче булып,
                чәчәк чыгар
безнең уртак кабер өстенә.

## Көйләреңне каян алдың

Җырладың да — тулды моңнар,
тулды күңелләремә...
Күңелемә тулды гөлләр,
нур иңде гөлләремә.
Гөл күзләре мөлдерәмә —
ник чылана таң нуры?
Әллә кояшлы кайгым бу,
әллә шатлык яңгыры?

Көйләреңне каян алдың,
нинди тылсым беләсең?
Сандугачлар мәктәбендә
укыдыңмы әллә син?
Гөл күзләре мөлдерәмә —
ник чылана таң нуры?
Әллә кояшлы кайгым бу,
әллә шатлык яңгыры?

## Чәчмә әсәрләр

# Нурислам Хәсәнов

# АК БАЛЫК

ПОВЕСТЬ



Урман кисүчеләр янына ашыккан Җиһангирның йөрәге ярсып типте. Ара ерак та калмаган, югыйсә. Үр генә менеп җитәсе. Әнә, агачлар өстеннән калкып торган юан имән — кул сузымында гына. Корыган ботакларын тамыр сыман җәеп, яшәргә хокук даулагандай, әле һаман җир өстендә нык тора. Ә менә аңа таба йөгергән Җиһангирның аяклары, ныклыгын җуеп, әле уңга, әле сулга авыша. Әйтерсең, ул үлчәү тәлинкәсенең әле бер, әле икенче ягына китереп баса. Ул йөгергән уңайга кырлар, урманнар белән бергә карт имән дә чайкала. Күңелендә — имән башына ук менгән бер малай шәүләсе. Ертык күлмәктән, ялан тәпиле. Куллары имәнгә чытырдап ябышкан, бите буйлап күз яшьләре тәгәри. Карашын олы юлга төбәгән. Иртәме-кичме әнә шул баганалы юлдан аның әтисе кайтырга тиеш. Әтисез читен, бик читен! Нигә һаман сугыш бетми? Кайтыр иде, кайтыр иде ул... Карт имән дә, ачлык-ялангачлыктан интеккән малайның өзгәләнүен сизгәндәй, җил-давылларга каршы тора, шул ныклыгы белән ниләрдәр аңлатырга тели. Ә кешеләр аны аңламый, башында әнә шул сугыш чоры малае — яшь Җиһангир утырып торган имәнне кисеп аударырга телиләр. Бүген, хәзер... Югыйсә кемнәргә генә мөрәҗәгать итеп карамады. «Бездән тормый...» — дип иңбашларын гына сикертәләр. Әйтерсең, бу җирләр колхозныкы да, районныкы да түгел, хуҗасыз... Кырлар өчен кадерле урман почмагын нигә кисәргә? Имеш, газ үткәрүче белгечләр торбаны каян сузарга икәнен беләләр... Белсәләр соң! Аз гына читләтеп узарга ярамыймыни?!

Җиһангир соңгарды... Ул килеп җиткәндә имән ава иде инде. Колач җитмәс юан имән! Авылның таза-таза ир-егетләре, аяк асларында аунаган коры ботакларны таптый-сындыра, дәррәү читкә тайпылдылар. Баһадир гәүдәле Җиһангир исә кабалана-кабалана бер агач төбенә килеп басты. Маңгаена бәреп чыккан тирен сөртергә онытып, күңеленнән «ах!» дип куйды һәм җанында яңарган истәлекләрдән тын калды. Әкрен-әкрен генә авыша барган имән дөнья белән хушлаша, Җиһангирның әтисенә бәйләнешле чор истәлекләрен үзе белән алып, ул киткән якка ава. Имәннең як-якка җәелгән тармаклары салмак кына аккан болытларга тотынып калмакчы була, киселеп бетмәгән үзәге шатыр-шотыр йолкына, Җиһангирның йөрәк тамырларын кубарып алгандай итә. Менә ул гөрселдәп авар да, өстеннән тузанын коярга теләп аунаган аттай, бер тетрәнеп алыр һәм мәңгегә тынып калыр... Җиһангир имәннән күзен алмады, онытылып карап торды. Көтте. Урман кисүчеләр арасыннан кемдер кинәт ачыргаланып кычкырды:

— Җиһангир, кит тизрәк! Йөгер!..

---

Нурислам ХӘСӘНОВ (1941) — *прозаик, «Бәхилләрме йөрәк», «Язмышын сыналганда» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Җиһангир әллә ишетте, әллә ишетмәде. Коточкыч хәл күз ачып йомганчы булды. Авып барган имәнне яшен уты урталай ярып уздымыни! Баш очындагы агачта эленеп калган бер имән ботагы, ычкынып китеп, Җиһангирның башына китереп бәрде. Ул, ни булганын аңларга да өлгермичә, имәннән алдарак җиргә ауды... Иптәшләре аны, җигүле арбага салып, урманнан олы юлга алып чыктылар. Узгынчы бер машинаны туктатып, Лаеш шифаханәсенә озаттылар.

Казаннан килеп операция ясарга тиешле хирургны сабырсызланып көттеләр. Ниһаять, түземлек бетте, район шифаханәсе хирургы Галия Габдрахмановна үзе ясады операцияне. Җиһангирның баш сөяге уң яктан чәрдәкләнгән, батып кергән иде. Ми күзәкәнләренә, нервыларына зыян тигән...

Аңына килә алмый озак ятты. Хәл белешергә килгән кешеләрне танымады, үзен саклап кунган хатыны Хәлимәне дә белештермәде.

Бик озак интеккәннән соң аның аңына бер көнне яктылык нуры үтеп кергәндәй булды. Әмма бу хәл озакка бармады, авыру янә саташа башлады. Әйтерсең, аның хәтереннән бүгенге көннәр бөтенләйгә сызылып ташланган, аңында балачак хатирәләре генә торып калган иде.

...Әнә алар, бер урам малайлары, язын Камадан су кереп калган уйсулыкка — Кече күлгә килеп туктадылар. Талчыбыктан үргән кәрҗиннәрен җиргә куйдылар да анадан тума чишенеп ташладылар. Сугыштан соңгы ачлыкны татыган малайларның тәннәре язын шыткан үлән-кузгалаклар ашыйашый күксел-яшел төскә керә башлаган, арада сакау Сафаның гына каратут тәнендә күкселлек әллә ни сизелми, башкаларының тәне тимгел-тимгел иде. Малайлар кәрҗин белән балык сөзмәкче булып килделәр. Алар кояш нурыннан җылынып өлгергән күл суына йөгерешеп килеп керделәр. Артларыннан күл төбе дуены болганып, су куерып калды. Күлне аркылыга-буйга сөзделәр. Тыныч кына йөзеп йөргән балыклар, көтелмәгән хәлдән куркып, яр буе чокырларына, тал төпләренә качып беткәннәрдер. Иң элек сакау Сафаның түземлеге төкәнде:

— Сиһангир, Сиһангир! Син тегендәрәк бар! Тегендәрәк! Ишетәсеңме, Сиһангир, миңа каршы кил син, миңа каршы кил!

Дәшми-тынмый гына сөзгечен су төбеннән йөрткән Җиһангир кәрҗинен судан күтәреп карады. Ник ичмаса ялгыш кына бер кәрәкә эләксен кәрҗингә.

Балык эләкмәүдән Сафаның ачуы кабарды, ул күңеленә килгән уен әйтте:

— Әйдәгез, малайлар, суны яхсылап болгатабыз, суннан соң балыкларың өскә калыкмый карасыннар!

— Әйдә, бер биеп алыйк әле!

— Әйдәгез, бас, кызым Әпипә, син басмасаң, мин басам... Һап-ләл-лә!..

Күлдә, малайлар белән бергә, тамчылар, дулкыннар бии башлады. Кем ничек булдыра ала. Сафаның чуендай карасу тәне, ике аксыл гәүдәдән аерылып, бөтерелә-бөтерелә елкылдый, ул чумып-чумып та алгалый.

Күлдәге бу тамаша озак дәвам итте. Ниһаять, балыклар бу мәхшәргә чыдаша алмыйча, үз авырлыкларын югалткандай, берән-сәрән өскә калка башладылар. Башын күрсәткән беренче балыкны сакау Сафа елгыр мәчедәй эләктереп алды да күтәреп селекте:

— Сигангир! Күрдеңме? Миңа кысыл канат эләкте!

— Бәртәс ич ул,— диде Җиһангир.

— Ә сулай икән сул...

Озак та үтмәде, читтәрәк йөрүен белгән йомыкый Йосыфның да авызы ерылды. Ул корбан балыгы эләктергән иде. Җиһангир әле күлнең тынып калуын теләми, сикерә-сикерә чабуын белә иде. Каршысында ук, түгәрәк дулкын ясап, бер балык күтәрелде, ул аны эләктереп алды. Балык малай өметләнгәннән шактый кечкенә булып чыкты. Шуңа да карамастан, Җиһангирның йөзенә гаҗәпләнү катыш соклану җәелде. Ул, балыкның матурлыгына аһ итеп:

— Ак балык! — дип кычкырып җибәрүен сизми дә калды. Учында тыпырчынган тере, асыл затның матурлыгын иптәшләренә күрсәтеп мактанды.

— Иң тәмле балык сусыдыр инде,— диде сакау Сафа телгә килеп.

Җиһангир дәшмәде. Бу минутта аның күңелен бүтән уй биләп алган иде. Күзләрен мөлдерәмә ачып, оялчан нәни кызчык сыман баккан балык аңа кызганыч булып тоелды. Җиһангир, аны җәлләп, якыннан гына җәелеп аккан Кама ярына таба йөгерде. Иптәшләренең: «Тукта, качма!» — дип кычкырып калуларына да җавап кайтармады. Яр читенә килеп җитүгә, Ак балыкны суга җибәрде. Балык, кинәт кенә саубуллашып йөзеп китәргә арусынмагандай, бер мәлгә тынып калды, аннары нәфис койрыгын әкрен-әкрен генә хәрәкәтләндереп, үз иркенә китеп барды.

Җиһангир күлгә кире йөгереп менгәч, Сафа аңа:

— Әйдә, күл суын ерып, Камага агызып төсерәбез, сунда балык та сөзеп алабыз,— диде.

Көрәкләр алып килеп, күл читен казыдылар, үзләре казыган ерганакка кәрҗиннәрен тезеп куйдылар. Кәрҗингә балык кереп калуын түземсезлек белән көттеләр. Аккан су ишәйгәннән-ишәя барды. Малайларның йөзләре җитдиләнә төште. Әшне абайлап алган Сафа оран салды:

— Сиһангир! Кәрҗинне ныграк тот! Су ярны исеп ага-а!..

Отыры ишәя барган су күл бугазын ашап чыкты да, ташкынга әверелеп, малайларны кәрҗиннәре белән Камага агызып китте...

Шифаханә койкасында саташып яткан Җиһангир шул ташкыннан йөзеп чыгарга теләп, кул хәрәкәтләре ясый. «Коткарыгыз!» — дип ялвара. Чырае сытылган. Авыр ыңгырашкан тавышына йөгереп килгән яшь шәфкать туташы аяк очында туктап кала, сызлануларын йөрәгенә алып, аңа кызганып карый. Байтак аптырап торгач, даруларын тумбочка өстенә куеп китеп бара.

Ул озак уяна алмый ятты. Азапланып ыңгырашты. Тынычлангандай булды. Томаланган аңына янә якты нур үтеп керде. Хәтеренең бер почмагы ачылды. Күз алдында яңа күренешләр пәйда булды.

Ул, акбүз атка атланып, Имәнкискә болыннары буйлап чаба. Болын өстеннән яшел дулкыннар йөгерә. Юк, ул ат өстендә түгел, дулкыннар өстендә тирбәлеп бара, ә атлар аның белән янәшә чабалар. Шушында бит инде, шушында ат көтүләре болыттай ябырылып чабалар, узышалар, эңгер тынлыгын ярып кешниләр. Сабан туе ич бу, сабан туе... Алтын табак чаклы булып офык артына төшеп барган кояшка таба оча Җиһангир. Тирә-як тын. Бик тын. Үзәннәргә күгелҗем томан сарыла. Ак кашка кушаяклап җир күкрәгенә барабан суга. Аңа кушылып, йөрәк дөп-дөп килә. Чаптар ашкынып чаба. Менә ул, томанланып торган әрәмәлек арасына барып керә дә, туктап кала. Шунда Җиһангир кинәт, күлгә килеп терәлгән чаптарның башы аркылы, суга мәтәлеп төшә һәм... уянып китә...

Ни хикмәт бу? Кайда ята соң ул? Ул керфекләрен йома, күз алдында аллы-гөлле тәңкәләр биешә. Алар каяндыр килеп чыгалар да, балык тәңкәләре төсле ялык-йолык килеп, каядыр китеп югалалар...

Менә ул камышлы күл буена килеп чыга. Чалбар балаклары сызганулы, бер ялгызы кәрҗин белән балык сөзеп йөри. Чуртан балык, әйе, чуртан балык керсен иде аның кәрҗиненә! Тал төпләрен урап узарга кирәк, берәрсе шунда качып ятмыймы? Кинәт ул артка чигенә. Камышлар арасыннан башын күтәреп елан карап тора. Йөрәге жу-у итә! Еланның баш түбәсендә ясмак чаклы ике сары тап — тузбаш ич бу! Тузбаш еланы чакмый. Нишли соң ул? Кара, кыл кебек нечкә телен ничек итеп сузган. Тел очыннан көмеш очкыннар чәчри. Ниҗтер ысылдый. Бака аулый икән ич! Күр әле, күр! Бичара баканы әсир иткән. Тегесе кыймылдый да алмый. Күзен буган ул баканың. Бака артка чигенмәк була, үзе аякларын тери-тери елан авызына якынлаша. Үлемен сизеп, җан ачысы белән тартыша...

...Җиһангир, кәрҗинен кулына тоткан көе, камышлы күлне ера-ера, сай суда йөзгән балыкларны күзәтеп бара. Маймычлар аның аяк яныннан көтүләре белән агылалар. Әллә каян гына килеп чыгалар да болыт шәүләләре сыман җемелдәп юкка чыгалар.

Җиһангир ниндидер зур бер балыкның якыннан гына дулкын ярып узганын шәйләде. Чуртан! Балык артыннан ташланды ул. Аны суга куып кертте. Кысрыклап килә-килә, кәрҗинен өстенә бастырам дигәндә генә, балык кул астыннан шуып ычкынды.

...Җиһангир балык эләкмәгәнгә күңелсезләнеп кайта. Арылган, талчыккан. Аяклар атлар-атламас. Әллә ничек аны, зур югалту кичергән кешедәй, авыр моң баскан. Әтисе сугышта булмаса, болай ук читенгә килмәс тә иде.

...Шулчак, әллә каян гына, каршысына сакау Сафа килеп чыга. Аны күргәч, Җиһангирның күңеле ачылып китә. Икесенең дә тамаклары ач, алар әрәмәлеккә таба борылалар. Анда акы, акбаш, күшә үсә. Бара торгач, Җиһангир әйтә:

— Борчак өлгерсә, туйганчы ашар идек...

— Туйгансы асар идек,— ди Сафа.— Каравылсы картны нисек тә алдар идек әле.

Урман аланнарын йөреп әйләнгәннән соң Сафа туктап кала:

— Тамак асты, малай!

— Минем дә тамак ачты,— ди Җиһангир.

Сакау Сафа, Җиһангирдан аерылып, агачлар арасына кереп югала.

— Сиһангир! Сиһангир! Кил әле, кил! — дип дәшә ул.

Җиһангир килгәндә, Сафа агач башындагы кош оясына үрмәли, дустын сөендерергә теләп кычкыра:

— Хәзер күкәй песереп асыйбыз...

Җиһангир агач төбендә, башын артка авыштырып сорый:

— Бармы?

Сафа ризасыз гына җавап кайтара:

— Юк бер нәрсә... Иске оя бу...

Ачуы чыккан Сафа ояны бөтенләй туздырып ташларга теләп, йодрыгы белән суга, кош оясына оялаган зур бер бөҗәк Сафаның күлмәк изүенә керә. Сафа өтәләнә-өтәләнә кычкыра, аякларын агач ботакларына сыдырта-сыдырта аска шуыша. Җиргә төшеп җиткәч, тәгәри-тәгәри елый. Берни дә аңламый карап торган Җиһангирга: «Сөпсә, сөпсә!» — дип акыра. Җиһангир аның күлмәген салдыра. Сафаның тәне күбеп, күтәреп чыккан. Бармак башы чаклы шөпшә аның ятып аунавыннан имгәнгән. Җиһангир аны кепкасы белән басып үтерә. Сафа үксеп елавыннан туктый алмый.

— Кос оясына бүтән менмәс ием, менмәс ием...

Бүген Җиһангир әтисен исенә төшереп озак саташты. Аның сугыштан исән-сау кайтып килүен күргәч, әй сөенгән иде, әй сөенгән иде! Баксаң, бер кулы яраланып, бармаклары бөрешеп калган икән. Күкрәгендәге орден-медальләрен тотып-тотып карады. Аларны күрше малайларына күрсәтеп, мактанып йөрде. Әтисе җиккән нәселле айгырга утыртып та йөрде. Авылдашлары аның сугыштан яраланып кайткан әтисенә: «Үзебезнең Ярулла!»,— дип, председательлек эшен тапшырганнар иде. Ә менә бүген аны район үзәгенә — Лаешка чакыртып алдылар. Җәяү китте. Җиһангир да әтисенә иярде. Анда алар кибетләргә кереп яңа чалбар, яңа күлмәк алачаклар.

Җиһангир үзалдына уйланып барган әтисенә әйтте:

— Әти-әти, синең пләмәнни айгырыңны ничек үтергәннәр? — диде.

Ярулла малаена теләр-теләмәс кенә җавап кайтарды.

— Тиргә батканчы куганнар да салкын су эчергәннәр.

— Нигә?

— Үч итеп...

— Кемгә?

Ярулла дәшмәде. Җиһангир аңа икенче соравын бирде:

— Кемнәр?

— Кемнәр икәнен белсәм икән...

— Хәзер сине аның өчен нишләтәләр?

— Рәхмәт әйтмәсләр инде...

Әтисе, яралы кулын өскәрәк күтәреп, сүзсез генә атлый. Җиһангир аны кызганды: бомба шартлаганда җир астына күмелеп калган бит ул! Ярый әле казып алганнар үзен. Колакка шунда катыланган.

Урман почмагындагы калкулыкка җиткәч, әтисе якында гына үсеп утырган агачларга карап торды.

— Әти, нәрсә бар анда? — диде Җиһангир.

Әтисе яралы кулын урман ягына таба ишарәләде:

— Әнә теге юл буендагы зур юан имәнне күрәсеңме?

— Күрәм, әти, күрәм... Ботаклары корган имәнме?

— Әйе... Безне сугышка озатып калган имән ул. Әниеңнең мичкә тәгәрәткән бәрәңгесен икәү шул имән төбенә утырып ашаган идек. Шуннан кул болгап калган иде.

Сүзсез атладылар.

— Син сугыштан хатка язып җибәргән җырны мин яттан беләм.

— Кайсы җыр икән ул, балам?

— Менә болай:

Машиналарда барабыз,
Төшеп сулар алабыз.
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Ут эченә барабыз...

Әтисенең күңеле нечкәреп китте. Ул алга таба кузгалып:

— Сугыш сугыш инде ул, балам,— диде. Аннары тагын сүзсез атлады. Малаена судка барганын әйтеп тормады. Эшнең ни белән бетәсен белми иде.

Лаешка җиткәч, Җиһангир калай түбәле озынча бер агач йортның зәңгәр рәшәткәләре буенда әтисенең әйләнеп чыкканын көтте. Нинди-дер кешеләр аның ике якка ачылмалы ишегеннән керделәр дә чыктылар. Араларында биек фуражка кигән милиционер абыйлары да очрап куя. Төз гәүдәлеләр, пөхтә киенгәннәр. Чистартып шомартылган төймәләре кояш нурында ялт-йолт килә. Җиһангирны аларның шундый матур формадан йөрүләре соклandырды. Үскәч, үзенең дә шундый кием киеп йөрисе, алар кебек буласы килде. Беренче тапкыр ул милиционер абыйсын авылларында, кәнсәләр төбендә күргән иде. Кемнәрнедер авыл советына чакыртып, сорау

алган иде. Җиһангир яраксыз эш кылган кешенең тизрәк табылуын теләде, ләкин чакыртылган кешеләрнең нидә гаепләнүләрен белми иде әле. Икенче көнне бераз аптырашта калды: районнан килгән абыйлар йөзенә сипкел чәчелгән, мыштым гына, сүзсез йөргән, какча яңаклы Сәләхи абыйны атка утыртып алып киттеләр. Хатыны белән малае үкси-үкси елап калдылар. Аларны беркем дә юатмады. Капка төпләренә җыелган апалар үзара пыш-пыш килделәр. Имеш, Сәләхинең колхозга керәсе килмәгән, сыерын илтеп бирүдән баш тарткан, балаларымны нәрсә белән туйдырырмын дип бәхәсләшкән. Районнан килүчеләр аңа: «Ах, син кулак калдыгы!» — дип өстәл сукканнар. Шул вакыйгалар, томанлы гына булса да, Җиһангирның күңелендә саклана әле.

...Калай түбәле йорттан һаман чыкмыйлар. Җиһангир, көтеп арыгач, каршындагы кибетләрне карап килергә булды. Башта чалбарлар кибетенә керде. Киштәләргә тезеп тә, элеп тә куелган чалбарларның әле берсенә, әле икенчесенә кызыгып карап торды. Шулай ымсынып торганда янына зәңгәр күлмәк кигән кызыл иренле сатучы апа килеп басты.

— Сиңа нәрсә, энекәш? — диде.

Җиһангир сүзсез калды. Сатучы апаның елтыраган җете күзләреннән шикләнеп чаткылар чәчрәде. Каушатты. Җиһангир, башын аска иеп, читкә борылды, арырак эленеп торган фуражкалар ягына китте. Анда каты козыреклы коңгырт фуражкаларга карап тора башлады. Әтисеннән тик фуражка гына алдыртачак ул, бүтән берни дә кирәкми...

Бераздан ул инде «Культтовары» дип язылган кибетнең велосипедлар бүлегендә иде. Ялтыравыклы бер велосипедның руленнән тотып-тотып карады. Андый велосипед авылда мәктәп директоры малаенда гына бар. Кешегә бирми, үзе генә йөри. Җиһангир да кызыга велосипедка, тик анысына әтисенең акчасы җитмәс шул, фуражка да аласы булгач...

Җиһангир кире урамга чыкканда, кояш төшлектән авышкан иде. Әтисе нигәдер озаклады.

Ул рәшәткәгә сөялгән җиреннән кинәт талпынып куйды. Калай түбәле йорт ишегеннән кемнәрдер чыга башлаган иде. Әтисен каршыларга дип бина эченә керде, шунда дәррәү аптырап калды. Әтисенең ике ягыннан ике милиционер атлый. Әтисенең йөзе, каны качкан кешенекедәй, агарып калган. Нишләткәннәр аны?

Әтисе, улын күргәч, дерт итеп китте. Тавышы калтыранып чыкты:

— Улым, бар син кайт, кайт, яме, үскәнем...

— Ә син? — Җиһангир әтисенә таба атлады.

— Миңа монда калырга кирәк... — Ярулла, чак кына туктала төшеп, каршы ишеккә башын изәде.

— Әти, әти!.. Мин дә синнән калмыйм... — диде Җиһангир. Тик аның юлына кызыл каймалы фуражка кигән милиционер каршы төште. Икенчесе аны этеп үк җибәрде:

— Кая тыгыласың?!

Аның усал тавышы малайны яшен утыдай куырып алды. Бер тын ни әйтергә белми катып калган Җиһангир кинәт, шушы минутта, бер яшькә үсеп киткәндәй булды. Ул җан өшеткеч ачы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Әти, китмә!

Коридордан узучылар, ихтыярсыз, тавышка борылып карадылар. Тик берсе дә якын килергә базмады.

Юлга чыккан Җиһангир, күзләренә бөялгән яшьне сөртә-сөртә, Имәнкискәгә таба йөгерде. Офыктагы карачкы болытлар салкын кургашын төсле. Күз алдындагы томанлы үзәннәр, күксел таулар рәшә дулкыннарында тибрәнә. Тәгәрмәч эзләре уелган, еландай борма юллар аны алдап упкынга алып төшәр кебек. Артка борылып карау куркыныч, аннан аны берьюлы ике милиционер куа килә сыман. Аларның усал, чәнечкеле караш-ларын бүтән күрәсе килми, юк! Кызыл каймалы фуражкалар да, ялтыравыклы итекләре дә кирәкми! Әтисе белән сөйләшергә дә ирек бирмәделәр. Аны тик торганда төрмәгә ябып куйдылар... Сугыш беткәч бит, зарыгып көтеп алгач...

Кем аңа этлек эшләгән, кем? Ат караучы Борһанмы? Әллә башкасымы?

Җиһангирның йөрәге каты-каты типте. Ул кечкенә кояш тәгәрәгән урман читенә якынайды, берни белештермичә, туп-туры имәнгә таба йөгерде. Нәрсә уйлап?

Урман буе агачлары тын. Бу малайга ни булган, диләрме? Кошлар тавышы да ишетелми.

Җиһангир кигән шапкә, колачын җәеп, карт имәнгә сарылды. Үксеп-үксеп елады. Бармаклары калтыранып, кытыршы имән кайрысына сыдырыла-сыдырыла аска таба шуды. Башын чөеп, өскә карады. Тамыр сымак корыган ботаклар, шифалы яңгыр көткәндәй, күккә сузылган.

— Имән! Имәнем! Әтиемне алып киттеләр... Ул сиңа бик озак карап торды. Саубуллашуы булды микәнни?

Кәкре-бөкре имән ботаклары Җиһангирга әтисенең сугышта яраланып кайткан бармакларын хәтерләттеләр. Ул, яклаучысын эзләгәндәй, имәнгә ныграк сыена, әйтерсең аның куллары әтисенең кайрыдай сырлы муенына чытырдап ябышкан.

— Әти, әти... Мин болай ничек әнием янына кайтыйм инде?

Аның тәненнән калтырау уза, вакыт-вакыт авыртудан чырае сытылып килә. Тозакка эләккән киек җәнлектәй, ул як-якка бәргәләнә, ярдәм сорап кемгәдер дәшәргә тели. Маңгаена тир бәреп чыга.

...Иртә таңнан Кырач тау итәгенә каян килеп чыкты соң? Бередә җиләкнең нинди генә юк: күгән җиләк, кура җиләк, җир җиләге. Карлыган, бөрлегән... Җыеп кына өлгер.

Ул бер караганда — җиләкле аланлыкта, икенче караганда — гөлҗимеш куаклары арасында йөри. Мәрҗәннәр кебек чуар гөлҗимешләр кай арада кызарып өлгергәннәр?! Аларны аңа күп итеп җыярга кирәк, күп, капчыкларны тутырганчы. Өч кило гөлҗимешкә бер кило бәрәңге бирәләр. Аларның бәрәңгеләре аз, үзләре күбәү. Әниләре бәрәңгене әрчеп тә тормый, юып, шул килеш кенә пешерә, кабыкка чыгармый. Аннары тагын бәрәңге сатып алырга дип түбән очның Таҗирәсе каршына барасы бар. Үлчәгәндә берне дә артык салмый. Үлчәүдә арткан бәрәңгене пычагы белән ярып ала. Энеләрем, сеңелләрем күплеген белми...

Җиһангир ашыга-ашыга гөлҗимеш җыя, вакытны бушка уздырырга ярамый. Әтисе урынына калган егет! Камага баржа килгән. Иртәгә малайлар белән йөк бушатырга барырга кирәк... Тачка тәгәрәтеп йөрүләре авыр. Басма такталардан тәгәрмәч җиңел генә узмый, әле уңга, әле сулга каера. Күз аллары әлҗе-мөлҗе килә, утлы ноктала биешә... Чү, чү!.. Ай-й!.. Әллә ничек кенә аягы таеп китте дә тачка аны үзе артыннан аска сөйрәде. Кычкырмакчы була, кычкыра алмый. Торып китәргә тели, тора алмый. Аягы сынган ич аның...

...Ул көнне Җиһангирның җигүле үгезе киреләнеп юлдан читкә чыгып чапты. Җиһангир дилбегәне аякларын терәп тартса да, хайван үз киреләнгән эшләде: тәртәләрне вата-сындыра, Панса елгасына кереп китте. Җиһангир арбага төялгән утын өстеннән сикереп төшеп калды. Әле төзәлеп, ныгып җитмәгән аягының яңгырап китүен тойды. Үгез инеш уртасында тугарылып бетте, йөген калдырып, елганың аръягына чыкты. Җиһангир чарасызлыгыннан җиргә ятып үкседе. «Син булсаң, әти, болай интекмәс идем... Утынлы да, ипиле дә булыр идек... — Җиһангир җирне тырмап учына алган туфракны кысты.— син булсаң, шушы кыр уртасында кире беткән үгез белән чиләнер идеммени?! Айгыр үлгәнне сиңа сылтаганнар. Күрәләтә... Ашлыкны труддингә күбрәк бирергә кирәк, дип дәгъвалашкан икәнсең бит... Ни гомер хәбәрең юк...»

Йөрәге ярсыды. Әтине үчлек иткән кешене белсә, шундук ботарлап ташлар иде. Кем икән ул, эт җан?

...Җиһангир калкулыкта утыра. Кемдер юлдан җәяүләп килә. Кем икән? Әтиседерме? Торды, килүчегә таба атлады. Туктады. Ул түгел. Йөреше бүтән. Әтисә алга сөрлегеп атлый ич аның. Пинҗәк төймәләрен ычкындырып җибәргән бүлыр, изүләре ачык. Кепкасын маңгаена басып кигән. Юк, бу ул түгел, түгел...

— Нәрсә, энекәш, үгезне җигеп булмадымы? — ди килүче. Ул бик дәү, куллары кувалда чаклы, күзләр кара, шомырт кара, тишеп карый торган. Менә ул чишенде. Кызыл каймалы фуражкасын салуга, чәче кырылган чүлмәк башы ялтырап китте. Бу соң әтисен ябып куйган милиционер түгелме?

— Чишен, йөзә беләсеңдер ич! — ди ул Җиһангирга.

— Беләм,— ди Җиһангир күңеленнән, әмма никтер тавышы ишетелми.

Ул да түгел, милиционер өстен бөтенләй чишенеп бетерде дә Җиһангирны суга төртеп төшерде. Икәүләп йөзәләр. Милиционерның уң як ботында энә белән кадап ясаган кыз сурәте. «Моны тегендә ясатты микән? —дип уйлый Җиһангир.— Аякларын күр! Кирза итеге дә кырык дүртенче размер бугай. Ә нигә соң ул, ялангач булса да, кирза итеген салмаган?»

— Камытны... Менә болай кысалар аны, энекәш,— ди милиционер һәм Җиһангирның башына тезен терәп, камыт бавын тарта башлый. Ә үзе сорый:

— Әтиеңнән хат киләме?

— Килгәне юк.

Милиционер кашларын җыера, аннары:

— Да-а... — ди.

* * *

Инде ничәнче көн Җиһангир һәлакәт дулкынында йөзә. Баш түбәсенең бер ягы янган учак кебек көйдереп тора. Аның авыруы көчәеп киткән. Әллә врачларның соңгы тапкыр биргән дарулары килешмәдеме? Күзләре тоныкяргa чыгарып ташлаган балыкныкы сыман мәгънәсез...

Йокыдан язган Хәлимә бу хәлгә бик борчыла. Җиһангиры рәтләп танымагач, йөрәге кысылып килде. Шулай да ул сабырлыгын җыеп, хәсрәтен эченә йотты. Улы янында озаклап утырды. Турыга ярып тараган кара чәчен яулыгы астына җыйнаштыргалап алды. Авыруны багучылар алдында ул ыспай-җыйнак булып күренергә тели иде. Бүген врачлар аның белән озак сөйләшеп тормадылар. Әллә вакытлары тар иде, әллә өметләрен өзделәр. Кем белә бит алда ни буласын?..

Хәлимә район больницасыннан башын аска иеп чыкты. Машина кабинасында юл буе сөйләшми кайтты. Ферма турында төшеп каласы итте. Гадәттә, сыерлар белән тулы утар бүген буш, сыерлар җәйләүгә киткәч, монда эчпошыргыч җансызлык иде. Чатны борылгач, каршына кардәш апасы Сәкинә килеп чыкты. Әбәткә кайтып барадыр инде. Үзенә күрә ыспай-пөхтә киенергә тырышкан. Иннеген дә җете итеп сөртергә онытмаган. Юка иреннәре холыксызлыгын, һәр нәрсәне өзеп ташларга әзер икәнлеген сиздереп тора.

— Исәнме, Хәлимә? — диде ул беренче дәшеп.— Бульнистән кайтып киләсеңме?

— Бульнистән кайтып киләм.

— Нихәл соң? Аруланамы?

Хәлимә теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

— Юк шул, аруланмый әле.

Сәкинәнең ябык чыраена уйчанлык чыкты.

— И сеңелем, сиңа ни дип кенә әйтим инде...

— Нигә алай дисең?

Кинәт тын булып калды. Бераздан Сәкинә, сеңлесенең хәленә кереп, кызганулы тавыш белән:

— Кеше булмый бит инде ул,— диде.

Хәлимә үзендә аңа җавап бирерлек көч тапмады. Сәкинә авыр кагылам дип уйлап та тормады, йөрәк ярасына тозны учлап сипте:

— Тинтәккә әйләнер. Аннары гомереңбуе газап чигәрсеңме? Аллам сакласын! Лутчы...

Хәлимә бер мәлгә өнсез калды, теле тотлыкты, тавышы калтыранып китте.

— Балаларыма эти булып торыр... тимә син аңа, тимә...

Һәм ул рәнҗүле караш белән тиз генә китеп барды. Борылып та карамады. Сәкинәнең сүзе йөрәген авырттырып торды. «Үз туганың шулай дисен инде. Берәр җылы сүз әйтәсе урынга... Ничек теле әйләнә? Алдагысын кем белә әле аның. Врачлар үзләре дә ачык кына әйтә алмыйлар. Тазалыгы бар, бәлки, бирешмәс...»

Капка төбендә Тарзан кушаматлы кара йөнтәс эт ләре койрык болгап каршы алды. Эт Хәлиманең күзләренә төбәлде, гүя ул да хуҗасын зарыгып көтә, кайчан кайта ул дип ялварып сорый. Әмма ни хәлитмәк кирәк? Хәлимә дәшми генә үтте. Такталары каклана төшкән капканы төртеп кенә ачты да ишек алдына керде. Тарзан аның артыннан иярде. Капка ябылган тавышны ишетеп, ак яулыгын ияк астына төшереп бәйләгән Гөлчирә әби, Хәлиманең әнисе, тәрәзәгә килде. Ул өйгә, балаларга күз-колак булып калган иде. Кечкенә кызлары Айгөлгә алты гына яшь, Фәрите өченче класста укый. Хәлимә әнисенең тәрәзәдән карап торуын күрмәде. Ул, ишегә салына төшкән абзар почмагы янында тукталып, иптәшләре теге көнне үзләре белән алып кайткан, Җиһангир башына төшкән кәкре имән ботагына төбәлде. Шул ботак аңа, инде ничәнче көн, тынгылык бирми. Яндырып, көлен Җиһангир каны тамган җиргә күмеп кайтырга җөрьәт итә алмый йөри. Ә шулай эшләргә кирәклеген күршеләр әйтеп тора. Юраган юш килә. Бәлки, чыннан да, Җиһангиры шуңа да озак терелә алмыйдыр? Юк, бу эшне бүгеннән дә калдырмый эшләргә кирәк...

Хәлимә әнисенең эчке яктан тәрәзә шакуына сискәнеп борылды. Гөлчирә карчык, ябык кулын өскәрәк күтәреп, аңа «Кер!» дип ишарә ясый, икенче кулына тоткан хатны селкеп күрсәтә иде. Хәлимә, Фәездәндер инде дип, Казандагы улын уйлады.

Яңа гына училище тәмамлаган улының, яхшы гына эшләп йөрим, дигән хатын укып, чәй эчеп алгач, Хәлимә ишегалдына чыкты. Кулына пычкы алды.

Әнә, сынган ботакның «ачык» авызлы башы аңа карап тора. Хәлимә түтинең чырае качты, шул минутта аның җанында ботакка карата үчлек хисе

калкып чыкты һәм ул күз көеге булып яткан ботакның сыртына зәһәрләнеп пычкысын сызды. Пычкы тиз генә батып керергә теләмәде, тырылдап сикерә-сикерә янга тайпылды. Кара син зәхмәтне! Ачуы ташыган Хәлимә ботакка үҗәтләнебрәк ябышты, пычкысын турылап ышкыды һәм ботакны бер сулыштан диярлек кисеп чыгарды. Маңгаена чәчелеп төшкән чәчләрен төзәтте. Яман эштә тотылгандай, як-ягына каранды. Алгы тәпиләренә башын салган Тарзан оясыннан моңсу гына карап тора иде. Эт, Хәлимәнең йөрәк ярасын аңлагандай, сузып кына шыңшып куйды. Хәлимә, вакытны сузмаска теләп, янә үҗәтләнеп ботакка ябышты. Җаны тулышкан иде. Күзләреннән ике тамчы яшь сытылып чыкты. Яшь элпәсе каплаган күз алдына сабан туе батырыдай, кыска җиңле аксыл күлмәген кигән Җиһангиры килеп басты. Ул мәйдан уртасында берүзе калган. Кулларында икешәр потлы гер, аларны бер күтәрә, бер төшерә. Гер күтәрү буенча авылда да, районда да беренчелекне бирми. Аңа авылдашлары: «Тагын берне! Тагын берне!» — дип көч-куәт биреп торалар. Җиһангир тирләп, кызарып чыккан, беләк мускуллары елгыр атныкыдай уйный. Менә ул барысын да уздырды, менә аның муенына чигүле озын сөлге урыйлар. Ул шат, аның өчен янып-көеп, шаулатып кул чабалар...

Хәлимә күңел хатирәләреннән дулкынланып, туктап калды. Аннары, бик тәҗел бер эше эшләнми калудан куркып, тагын пычкысына ябышты. Киселгән пүләннәрне кочагына күтәреп өенә керде. Имән ботаклары шапылдап идәнгә төшүгә, Гөлчирә карчык:

— Хәзер үк ягасыңмы? — дип сорады.

— Хәзер үк,— диде Хәлимә.

Гөлчирә карчык бүтән дәшмәде, түр якка кереп китте.

Хәлимә мич казнасы кырыендагы чырагачтан кабызлык чыра телде, мич төбендәге көлне канат белән себереп чыгарды, калакларны ачты. Имән ботакларын мич эченә аркылы-торкылы тезгәч, кабызлыгына ут элдереп, ботаклар астына тыкты.

Бераздан ул сәке йөзлегенә чүмәшеп, мичтә дөрләп кабынган сары утка карап, уйга калды. Куллары бүтән эшкә бармастай хәлсезләнеп, алдына салынып төшкән иде. Ялкын телләре имән ботакларын айкап, еландай үрли, утлы күмерләр өстендә бии. Хәлимә күңелендәге шик-шөбһәләрне арттыра. «Терелмәс микәнни? — ди ул үз-үзенә.— Нинди таза ир иде. Бәлкем, терелер әле... Менә шушы ботакның көлен күмеп кайткач, аруланмасмы? Ни куаныч булыр иде!..»

Утка карап утыра торгач, ничә төннәр йокы күрмәгән күзләре йомыла башлады. Мич алдын тутырып уйнаган ялкын шәүләләре зиһенендә янә Җиһангир сурәтен калкытты. Җиһангир ялкын эчендә. Үзен бу афәттән йолып алыгыз дип ялвара. Хәлимә, мич каршында кызган битен учлары белән каплап, сызлаган чигәләрен уып утырды.

Аның болай янган учаклар каршында авыр кичерешләргә уралганы юк иде. Күңелендә сөенеч-шатлык ташыган чаклар булды. Еллар авыр булса да, уен-көлке, шаянлык-шуклык авылда бетеп тормый иде...

Ул кыз чагында, авыл яшьләре көймәләргә төялеп, Камада йөриләр, утрауларга чыгып уйныйлар иде. Их, шул чакта яккан учаклар тирәсендә гармунга кушылып җырлап утырулар! Җиһангирның дусты юаш Йосыф шаулатып гармун уйный, төнге утрау егет-кызларның күңелле тавышларыннан гөр килеп тора иде. Андый кичләрдә яшерен серләре булганнар парлаша, кул буйларына, әрәмәлек араларына китеп югала. Җиһангир да аны янган учак яныннан кул читенә алып китә. Ул карыша алмый, үзенең шундый күндәмлегенә сәерсенә иде.

Утрауны «Мәхәббәт утравы» дип атадылар. Анда төн урталары якынлашып, кайтыр вакыт җиткәч, көймәләр янына җыелалар. Гөрләшә-гөрләшә зур көймәләргә төяләләр дә, гармунчыны уртага алып, җыр сузалар. Ишкәкләр уйнап тора. Утрауда янып калган ике учак аларны Имәнкискәгә кадәр озатып куя.

Җаһангир белән Хәлимә урыны янәшә. Учаклар яктысы алтын сөңге булып Кама төпләренә сузыла. Хәер, вак дулкыннар ул яктылыкны алтын толымнарга әйләндереп бетә. Җиһангир Хәлимә колагына пышылдый:

— Әнә чәч толымнарыңның шәүләсен күрәсеңме?

Хәлимә көлә:

— И хыялый...—ди.

Берсендә алар, ярга чыгып җитәрәк, көймәләре белән суга капландылар. Кемдер, көймә төбеннән су керә дип, кырыйга басты да көймәне чайкалдырып җибәрде. Ярый әле, Җиһангиры янында иде. Йөзә дә белмәгәч, беттем, суга батам дип, коты алынган иде.

Аннары ул Җиһангирны солдатка озатты, зарыгып көтте. Сөйгәненең хезмәтен тутырып кайткан көне һич кенә дә исеннән чыкмый. Сөтле чиләген күтәреп, иртә таңнан сепаратка барышы иде. Җиһангир төн уртасында кайт-

кан. Рәтләп йоклый алмагач, таңнан капка төпләренә чыгып баскан. Башта аны урамның икенче ягыннан узып барган Хәлимә үзе күреп алды. Битенә ут капты, йөрәге тасырдап тибә башлады. Җиһангир, елмаеп, аңа таба ашыкты. Сөтле чиләк җиргә төшеп утырды. Хәлимә солдатка кыюсыз гына кул сузды:

— Исәнме, Җиһангир абый! Исән-сау гына кайттыңмы?

Җиһангир аның йомшак җылы кулларын учыннан җибәрми торды. Хисләре ташыды, дулкынлануын тыя алмыйча, Хәлимәне кочаклап үк алды. Кызның колак читләрен кытыклап пышылдады: «Кайттым, бәгърем, кайттым...»

Егет кочагыннан чыга алмый торган Хәлимәнең әллә ничек башы әйләнеп китте, һәм ул Җиһангирның җәтмәсенә эләккән тере балыктай тыпырчынып куйды.

— Җибәр!.. Иртә таңнан кеше күрсә... — диде.

Җиһангир аның артыннан:

— Кичкә күрешербез, яме! — дип, болын ягына баш изәде, җирдә торып калган сөтле чиләккә күзе төште.

— Хәлимә-ә-әү!

Кызый борылып карады.

— Чиләгең кала ич...

Хәлимә кып-кызыл булып, оялып, чиләген килеп алды да, аяк астындагы җирне тоймыйча, йөгереп диярлек китеп барды...

Күңелендә яңарган хатирәләре аны аз гына булса да тынычландыргандай итте. Мичтәге ялкын котырынып бии, шашына, төнлеккә тартылган төтенне куа. Утлы күмерләр, сунәргә теләмәгәндәй, бер кабына, бер тоныклана.

Хәлимә соңгы очкыннар сүнгәнче өметләнеп көтәчәк...

Мичтәге ботаклар, ниһаять, янып бетте. Көле суына төшкәч, Хәлимә аны кечкенә бер капчыкка җыеп салды, яхшылап төрде. Аннан, инде нишләргә дигәндәй, әле сәгатькә, әле тәрәзәгә карады. Янтык урманына кадәр җәяүләп кенә чыкса, соң булыр күк тоелды. Бер ниятләгән эшен өстендә йөк итеп тотасы килмәде, бүген үк очлап куярга теләде. Шулчак тәрәзәдән күрше Сәйфулланың җигүле аты капка төпләренә кайтып туктаганын күреп алды. Аның янына ашыкты: атын биреп тормасмы?

Куе җирән чәчле, авыр гәүдәле, салмак хәрәкәтле Сәйфулла, күршесенең йомышы нәрсәдә икәнлеген аңлагач, калын иреннәрен ашыкмый гына кыймылдатып:

— Хәлимә килен! Урманга ялгызың гына бару кыен булмасмы? — диде.

— Кыен дип... Урынын беләм. Бер мәртәбә барып күргән идем...

Сәйфулла аның ихтыярына каршы килмәде.

— Ярар, алайса, кем, Хәлимә килен... Хәерле сәгатьтә... Хозер юлдашың булсын дигәндәй...

Хәлимә утырган җигүле ат авылны чыгып Янтык урманына таба менеп бара. Ул якты күздә тизрәк әйләнәп кайтырга дип каударлана: «На-а, на-а, малкай!» Дилбегә кагуга гына алаша бик ашыгып төшми, тырык-тырык кына юырткан була.

Тирә-як тын. Кырлар киңлегендә фәкать ат аягы тавышлары, арба тәгәрмәчләренең тыркылдап баруы гына ишетелә. Юл буйларында өлгереп килгән арышлар, тынлыкка изерәп, башларын игәннәр. Арба артыннан күтәрелеп калган тузан юл читләрендә үскән зәңгәр чәчәкләргә бөркелә. Шул тузан Хәлимәнең дә күңеленә хәсрәт томаны булып утыра...

Бара-бара да арба төбенә салынган көл капчыгын капшап карый, аның әле качып бетәргә өлгермәгән җылысын тоя. Арба төбендә дыңгырдап барган тимер көрәген рәтләп куя. Офыкка тәгәрәгән кояшка карагач, дилбегәсен җиллерәк тарткалый башлый. Сул ягыннан, отыры озынәя барып, калышмый шуышкан шәүләсенә борылып карый. Буш арба өстендә утырган ялгыз куләгә күңелендә әллә нинди рәнҗү хисе уята. Бу юллардан Җиһангиры белән бергәләп узып йөргәндә, күләгә дә пар иде... «И-и, ходаем, ялгызым калсам нишләрмен, ничекләр итеп түзәрмен? Әллә мин бәхетсез җан булып тудым микән?» — дип уйлый ул.

Дөньяның ачысын-төчесен аз татымады. Әтиләре сугышта һәлак булгач, бер анага дүрт кыз утырып калганнар иде. Әнисенең карап торган бердәнбер ярдәмчесе булды. Кичләрен җиделе лампа яктысында, ярты литр керосинга да интегә-интегә, шәл бәйләде, тегү текте. Бәгырьләре суырылып килде. Инде тынычланып, тернәкләнеп яши, балалар үстерә башлагач кына... өметләрең өзелмәсен иде. «Юк, бәхетем Җиһангир белән минем. И дөнья! Күпсенмә син аны миннән, савыктыр, балаларым хакына...»

Берсендә, бу үрләрне менгәндә, ниндидер сүзгә ялгап Җиһангир аңа: «Ир — ир кеше инде ул»,— дигән иде. Дөрес әйткән шул. Эшнең җаен белеп эшләде. Урманга ботак-сатакка барганда, урман каравылчысы килеп чыкса, билгеле, хатын-кыз белән сөйләшеп тормый, аның белән эш итә, какмый иде.

Ирсез хатын булсаң, белмим, санлап торыр иде микән? «Ир — терәк»,— дип тә тикмәгә әйтмәгәннәр. Эшкә җәптәшлеге булды. Кулыннан килде. Карусыз, кушканга атлыгып торды... Әй, бу күрәчәкне... Колхозга беренче автоүлчәгечләрне корып йөргән чаклар күңелле булган икән. Йөрәкле иде Җиһангиры. Автоүлчәгечне үзем корам дип, тәки тәвәккәлләп тотынды. Узган-барганнар үлчәү урнашачак чокыр кырыена килеп туктарлар иде дә гаҗәпләнеп калырлар иде. Кайсыберләре мыек астыннан елмаеп:

— Бу эшне башкарып чыгар өчен инженер белеме кирәк бит,— дип төрттереп тә куярлар иде. Ә аның Җиһангирына хәрби хезмәттә чакта төрле-төрле эшләр башкарырга, сызымнар белән дә танышырга туры килгән. Кайсы әйбер ничек булырга, ничек үз урынына ятарга тиешлеген чамалый иде ул. Үзенә ярдәмгә Хәлимәне һәм тагын бер хатынны гына сорап алды. Стеналарын өйде, терәк тумбаларын салды. Үлчәү үз урынына төшеп утыргач, председатель Хасият пеләш башын ялтырата-ялтырата үзе килеп җитте. Эшне йөкләгәндә Җиһангирга бик үк ышанып җитәсе килмәгән иде. Ә үлчәү кирәк. Башкарылган эш һәр яктан тикшерелде. Үлчәүне сынап, эшләтеп карыйсы гына калды. Хасият үлчәүне кат-кат әйләнеп чыкты, үз күзенә үзе ышанмагандай, карап-карап торды, канәгатьлеген яшерә алмыйча, бер үк сүзләрен кабатлады:

— Үлчи бит бу, малай! Үлчи!..

Әйе, шул автоүлчәгечне корганнары өчен алар икесенә утыз алты сум акча алганнар иде. Ул чакта бу акча да күп тоелды. Шуннан соң Җиһангирга ышаныч тагын да артты. Силос базлары салу, фермалар кору — берсе дә калмады...

Табигатьне аңлау кыен. Көн тыныч кына сүнеп бара иде. Урманга якынлашып килгәндә, кинәт көчле җил чыкты. Орчыктай бөтерелеп купкан «пәри туйлары» тузанны өере белән әле тегендә, әле монда күчерә башлады. Хәлимәнең күңеле шөбһәләнде. Үз көенә чабып барган ат та, ушәнләнеп, адымлауга күчте. Колакларын тырпайткалады, нәрсәдер сизенгәндәй, алда тоташ кара-кучкылланып шаулаган урманга барасы килми бугай. Хәлимә, кире борылдым юк дигәндәй, үз карарында торып, дилбегәсен ныклабрак тартты. Ат барыбер юыртып китәргә ашыкмады, дилбегә тотучыны хатын-кыз буларак санлыйсы килмәдеме? Үз көенә генә атлады. Инде ерак та булмаган урманның ярсынып шаулавы аермачык ишетелә башлады. Егерме алтынчы делянка башланган почмакка килеп җиткәндә, урман бар көченә шаулый иде.

Йөрәге чәнчешеп китүен сизенсә дә, атын куалавын белде. Урманга караңгылык иңгәнче тизрәк барып җитәргә кирәк. «Әйдә, малкай, әйдә!»

Ат кинәт туктады. Хәлимә сискәнеп китте. Караса, ауган имәннәр янына килеп тә җителгән икән. Ат теге көнне килгән җирен белеп туктады. Аркылы-торкылы егылган кабыксыз имәннәр, гәрәбәдәй саргылт кәүсәләрен ялтыратып, яшел үлән арасында яталар. Баш очларында иелә-бөгелә шаулашкан ыругдашларын тын калып тыңлыйлар сыман.

Хәлимә үзен тыныч тотарга тырышты. Арбадан төшүгә, як-ягына каранып алды, курку-шикләнүләрен эченә йотып, кабалана-кабалана көрәген, кечкенә капчыгын алды һәм теге чакта Җиһангиры басып торган агач төбенә юнәлде. Бераз баргач, башын артка чөеп, өстәге агач ботакларына карады: «Юкмы тагын берәр эленеп торган ботак?»

Юкә агачы төбенә килеп туктагач, көрәген җиргә кадады. Шул мәл колагында ниндидер чыңлау булып алды. Әйтерсең, тимер көрәк очы, Җиһангирның нервысына эләккән кебек, нечкә бер кылга тиеп узды.

Хәлимә тын калды һәм иелеп төенчеген җиргә куйды, аны саклык белән генә чиште. Көл әле суынып та җитмәгән иде.

Тимер көрәк җиргә батып керде. Хәлимә иреннәре дерелдәвен сизми иде. Җаны тырмала, елыйсы килә иде. Кабаландыра, күңелендә уйнаган җилдавылга каршы торып, эшен тизрәк башкарып чыгарга итә. Ни булса да, бирешмәскә, бирешмәскә!..

Сулышы кысылганнан-кысыла барды. Шулчак якында гына бер корыган агач шартлап сынгандай булды. Ул дерт итеп сискәнеп китте. Кемдер бар! Агач аның аяк басуыннан сынды булса кирәк. Бу уй аны як-ягына каранырга мәҗбүр итте. Куркудан йөрәге чамасыз тибенде. Ни булырын көтте. Юк, тавыш кабатланмады. Кемдер тынып, күзәтеп торамы әллә? Аңа болай көтү газаплы иде. Казыган чокырын тизрәк күмәргә дә кузгалырга! Ул янә көрәгенә тотынды. Бер-ике тапкыр балчык салуга, кулы кабат тыңламас булды. Әллә каян гына Җиһангир тавышы яңгырап киткәндәй тоелды:

— Хәлимә!

Күз алды караңгыланды. Каршындагы агачлар сыек томан эчендә калдылар. Алар арасында Җиһангир гәүдәсе шәйләнә сыман. Чигәсе тартылган нечкә кылдай чыңлап-чыңлап ала. «Чү, чү!.. Болай ярамый, йә башым бөтенләй әйләнеп китәр...» Ул, үзен тынычландырырга теләп, көрәк сабына

ныклабрак тотынды. Чокырга соңгы балчыкларны салды. Билен язып, алга караса, каршысына олы кабан дуңгызы килә. «Ә-не-кә-ем!» — дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды. Шулчак урман эчен яңгыратып Тарзан өреп җибәрде. Хәлимә артыннан бәен өзеп чапкан эт, атылып кабан дуңгызы каршына килеп басты да, өрә-өрә дошманын кире борды. Бер мәлгә һушсызөнсез калган Хәлимә иреннәрен дерелдәтеп этенә дәште:

— Тарзан! Тарзан...

Эчке тоемы алдамаган, арттан мышный-мышный чапкан эт шунда ук кырт борылып, хуҗабикәсе каршына килеп чыкты. Ни боерасың дигәндәй, аның күзләренә карап койрыгын болгады.

Озак та үтмәде, җигүле арба, урман аша чыгып, офыкка тәгәрәгән кояшка таба дырк-дырк бара иде инде. Арба артыннан ияргән эт, койрыгын текә тотып, юлның әле бер ягына, әле икенче ягына сугылды.

* * *

Ниһаять, Җиһангир күзен ачты. Кайдалыгын төшенмичә, гаҗәпләнеп торды: бүлмәгә сеңгән дару исен тойды. Күз алдында эленеп торган томанлы пәрдә әкрен-әкрен юкка чыкты, тирә-юненә ачыклык иңде. Шунысы гаҗәп: бүлмә эче тып-тын, якты. Җиһангир, аптырап һәм саклана төшеп, башын чак кына сулга борды. Иң элек күзе стена буендагы карават аркасына пушка көпшәседәй күтәртеп куелган гипслы бер аякка төште. Авыруның гипс эченнән күренеп торган баш бармагын алсуландырып, тәрәз почмагыннан кыйгачлап сузылган нур көлтәсе яктырта. «Ул да һәлакәткә юлыкты микән? Бәла аяк астында шул». Карашын авыруның йөзенә күчерде. Караватта кара чәчле, калын гына иренле бер егет йоклап ята иде.

Җиһангир уң ягында кем барын беләсе килеп, шул якка борылды. Икенче авыруның гәүдәсе караватына иңеп, чак кына калкып тора. Җиһангирның кызыксынуы артты: бу кадәр бетеренер икән. Сулыш алуы да беленер-беленмәс. Сырхау карт булса кирәк. Одеал астыннан чыгып торган кулы — шыр сөяк, зәңгәрсу тескә кергән тамырлары калку. Бер бармагы кәкре. Шул бармакны күрүгә, Җиһангирның тәне чымырдап китте. Чаңгы башы кебек кәкрәйгән бармакны аның күргәне бар иде бит. «Бу шул кеше түгелме?» — дигән уй башыннан яшьнәп узды. Карашын аның йөзенә күчерде һәм кинәт, барган җиреннән кире чигенергә теләгән кешедәй, күзләрен читкә алды, аптырап калды. Ул, үзе!.. Сырхауның куркыныч йөзе күз алдында тора. Битендәге сипкелләре, ак мендәргә чәчрәгән эре тамчылар сымак, ачылып калган. Яңаклары чокыраеп баткан, сөякләре тырпая төшкән. Кайчандыр утлы күмергә охшап янган күзләрендә салкын, сүлпән тоныклык. Җыерылган кашлары түшәмгә сәнәктәй тырпайган. Батынкы күз куышлыгыннан өметсезлек рухы бөркелә.

Җиһангирның тәннәре кызышты, әйтерсең, аны мең төрле энәләр чәнчештерә. Бер караш нәтиҗәсендә туган тискәре йогынты аны секундлар эчендә әллә нишләтеп җибәрде һәм дәррәү уянган уйлары хәтер төпкелләрен актарырга кереште. Әтисе җигеп йөргән айгыр — Ак кашка, олы таш өсләренә чәчрәп менгән шарламадай, җилләрдә ялларын җилпи-җилпи ихтыярсыздан күз алдына килде. Килде дә арт аякларына басты, тирә-якны яңгыратып кешнәп җибәрде. Аннан борылып, өермә куптарып чапты һәм бераз баруга туктап калды, җиргә гөрселдәп ауды. Тибенә-тибенә аунарга керешә. Ярсыган йөрәгенә чыдаша алмады. Берничә тапкыр сикереп торырга омтылып карады, ләкин... Ниндидер көч аны эчтән куырып алган, гүя билгесез упкынга өстери иде. Ак кашка тартыша, мөлдерәмә күзләрен зәңгәр күккә төбәгән. Кемнәндер ярдәм сорый, шәфкать көтә... Янында беркем дә күренми. Юк, ялгыша. Моннан бераз гына элек аның янында бер кеше бар иде. Ул, ярым караңгылык эчендә саргылтым йөнтәс кулын ялтыратып, ат алдыннан салкын сулы чиләген җәһәт кенә алып, янә караңгылык эченә кереп чумды. Менә хәзер ул йөнтәс, бер бармагы имгәнеп кәкрәйгән, кайчандыр яман эш кылган кул янәшәдәге караватта юрган астыннан чыгып тора. Әтисенең Себер төрмәләрендә мәңгегә ятып калуына сәбәпче булган кул. Сәләхи кулы!

Төрмәдән кайткач, Сәләхи Җиһангирның әтисе белән исәп-хисапны өзгән... Яшь-яшь барысы ачыклангач, әтисен утырткан кешенең тәмам ул икәнен ышангач, Җиһангир Сәләхигә дәшмәс булды. Хәзер дә теле әйләнерлек түгел иде. Һәм ул монда тиз генә савыгып китә алмасын да тойды.

Көндезге йокы сәгате җитсә дә, Сәләхинең күзләре ачык. Аны бирегә алып килгәннәренә өченче көн. Ул Җиһангирның уянуын да, аның үзенә төбәлгән карашын да сизде. Тынып торды, көтте. Көтеп бетерә алмагач, үзе дәште.

— Уяндыңмы, Җиһангир?..— Аның хәлсез тавышы калтыранып чыкты.

Җиһангир беркавым буталчык уйларыннан арына алмый торды. Сәләхи хыянәтеннән соң, аны күңеленнән төгәл ачыклаганнан бирле, ул аны күрергә дә теләмәде, юлда очраша, йә күрмәмешкә салыша, йә читкә борылып китә иде. Берсендә башына шундый усал уй да килгән иде: аулакта очратып кирәген бирергә... Алай эшли алмады ул. Шулай да Сәләхине күрәлмәү йөрәк ярасына тирән сеңеп калды, онытылмады. Сәләхинең каш астыннан караган төксе, шикле күзләрен сизеп, тоеп яшәде. Тик ачыктан-ачык сөйләшә алмады.

— Сәләхи абый, синме соң бу? — Җиһангир шулай йомшак кына дәшәргә булды.

— Мин шул...— Сәләхинең тавышы тонык иде.

— Син дә авырып киттеңмени?

Карт җавабын көттереп бирде:

— Вакыттыр инде...

Аның кәкре бармаклы кулы дерелдәп куйды. Ул тагын нәрсәдер әйтергә теләде бугай, башын күтәрмәкче булды, тик күтәрә алмады, тынып калды. Нәрсәдер күкрәгеи кызыштырды. Тамагына килеп тыгылган төер сулышын кысты. Җаны бимазаланудан көлсу, кипшенгән иреннәрен кыймылдатты, тешсез авызыннан тавышы ышылдап чыкты.

— Хәл юк.

— Ә-ә...

Җиһангирның шулай килешүчәнлек күрсәтеп, Сәләхи сүзен җөпләп куюдан башка чарасы калмады. Ул ихтыярсыздан: «Хәлле чакларың бар иде синең...» — дип кенә уйлады.

Ике арада аңлашылмас авыр тынлык урнашты. Юк, тынлык кына түгел, күзгә күренмәс кыр-дала пәйда булды. Җиһангир өчен упкынга тиң ара. Әгәр бу хәл озак дәвам итсә, аның савыгып җитмәгән нервылары кабат какшамасмы? Соңгы өмете дә сүнмәсме?

Сәләхи картның эчкә баткан күзләре түшәмгә текәлгән. Аны гомер буе борчыган сораулар, соңгы чиктә аннан җавап көтеп, карашын түшәмгә төбәткән, дөнья белән саубуллашыр алдыннан сүзсез калдырган шикелле...

Менә ул, одеялыннан җылы эзләгәндәй, бөрешеп калды. Күзләрен түшәмнән алмыйча, сүзен каян, ничек башларга аптырап торды. Җәй көне булуга карамастан, бөтен санын калтыратып бизгәк тота башлар кебек иде. Аңа җылы җитми. Аяк бармаклары очыннан тәненә салкын үрмәли. Ул ялан аякларга Кама ярларыннан силпе дулкыннар кага. Кире чигенгән дулкыннар ярдагы шома ташларны, агач тамырларын калкытып чыгара, Сәләхи хәтерендәге тормыш сәхифәләрен актара, уйларын үз артыннан ияртеп, аны тайга урманнарына алып чыга...

Урмандагы чыршылар зыкы салкыннардан тын калып үрә каткан. Сәләхи тишек итегеннән чыгып торган туңган бармакларын кызгана. Аларны учларына алып җылытырдай була. Аларга кулы җитми, биле каткан, хәле юк. Ачлыктан шыр сөяккә калган гәүдәсе, чыкмаган җаны гына бар. Чыңлаган колагыннан туң ботак чапкан хәлсез балта тавышы китми. Ихтыярсыздан башына килгән уйларына җаны тетрәп-тетрәп куя: «Иленнән, туганнарыннан еракта, шушы Югары Тура елгасы буйларында мәңгегә ятып калыр микәнни ул? Бүген, бүген булмаса иртәгә йә агач китереп басар. Басты ич, басты ич Мәскәү егетен. Авып барган озын чыршы, кыеклап китеп, төбе черек булган каен өстенә килеп төшә, каен сынып аңа китереп бәрә. Янган учак янында җылынып торган җиреннән. Сигез чакрым араны, кар ерып, әле авырган килеш килгән иде. Иртән врачка барып, эштән азат итүләрен сорап караган, температурасы бик югары булмагач, азат итмәгәннәр».

Нишләр, нишләр иде Сәләхи тагын бераз шул тайга урманнарында агач кисү эшендә калса? Ярый әле, бәхетенә, тоткыннар лагерена врачлар комиссиясе килде. Комиссиядә аңа да чират җитте.

— Доходяга!..

Сары чәчле хатын-кыз врачның аңа карата әйтелгән беренче сүзе шул булды. Врач тыштан җитди, хәтта усалрак күренсә дә, аның мизгел эчендә ялтырап киткән күзләре шәфкать нуры чәчте. Сәләхинең хәлен бер яктан айкап, үтәли күреп алды сыман.

— Сиңа монда урман кисәргә түгел, Кырымда җиләк-җимеш җыярга гына калган,— дип шаяртты ул аннары.

Билгеле, аңа Кара диңгез буйларында җиләк-җимеш җыярга туры килмәде. Шунысына шөкерана кылды: аны вакытлыча гына булса да урман кисү эшеннән алып, тоткыннарның ертык-портык киемнәрен — тишек бүрек, бияләй, телогрейкаларын ямап торырга күчерделәр. Моңа ул бик тә сөенде, югыйсә бит әле бәдрәф чистартып торырга кушмакчылар иде.

Беркөнне ул, эштән бушаган арада, урманда очкыннар тишкәләгән бүреген бик пөхтәләп, матур итеп ямады. Кичен, баракка кайтышлый ук, әллә каян гына килеп чыккан бер тоткын аның башындагы бүреген эләктереп алды да, үз искесен ташлап, сарайлар артындагы эңгер-меңгер эченә кереп югалды. Йөзен чак кына шәйләп калды. Кара кеше иде, таза бәдәнле. Күзләрен чалгы янатып, як-ягына айкап алды да шылды...

Өч көн узганнан соң тайгага качкан тоткыннар ачыкланды. Аларның этләр талап бетергән үле гәүдәләре янында туктагач, Сәләхи куркып калды, тәне чымырдап китте. Араларында теге егет тә бар. Башында — аның бүреге. Телогрейкасы да яңа, үзенеке түгел. Тырмалып беткән йөзе көчкә танырлык. Тайгага рәтлерәк кием киеп качарга булганнар икән...

Сәләхинең палата түшәменә мөгездәй тырпаеп торган кашлары бер җыерылып, бер язылып килде. Тоныкъ таплар хасил булган күзләрендә очкыннар чагылып узды. Күз алдында үлемнән чак котылган көне гәүдәләнде.

...Ул йокыга китә алмый ята иде. Кинәт, төнге казарма тәрәзәсеннән төшкән тоныкъ яктылыкны кисеп, кемнеңдер бирге якка үтеп керүе сизелде. Шул якка таба Сәләхинең башы күтәрелә төште. Кем икән? Йөрәге еш-еш тибә башлады. Күзәтте. Теге тоткын, песи кебек кенә басып, бу почмакка таба килә. Тын да алмый көткән Сәләхи кинәт эченнән: «Ул! — дип куйды.— Кылый күз Чуркин!» Һаман да аңа бәйләнеп йөрүче. Әхмәтшин дигән бер яшь кенә егетне кыерсытканда яклаган өчен. Шуннан бирле ике арада бер-берсен куралмаучылык туды. Чуркин яный, тәрлечә куркыта. Сәләхинең тынычлыгы бетте. Моны ул авыр кичерде, җаны талкынды. Тагын нәрсә кирәктер ул Чуркинга? Сәләхи йоклаганга салынып ятты. Җаны эчтән актарылды: «Нинди хәйлә, нинди мәкер белән килә ул?» Шушы сорауларга җавап эзләгән Сәләхи яңак мускулларының тартышып килүен тойды. Шулай да тынычлыгын соңгы чиккәчә саклап калырга тырышты.

Чуркин аның янына килеп җитте. Бераз тын торды, як-ягына каранып алды. Ниһаять, бер карарга килеп, Сәләхинең касыгына төртте.

— Әй, син, тор әле!

Сәләхи дерт итеп китте һәм, куркуын сиздермәскә тырышып, торып басты.

— Син нәрсә?

Чуркинның тавышы ата казныкыдай ысылдап чыкты:

— Сөйләшәсе бар, тегендә узыйк әле.— Ул башын киемнәр эленгән караңгы почмакка изәде.

Сәләхи килешмәде.

— Монда гына сөйлә.

Чуркинга бу ошамады. Тешен шыкырдатты.

— Бурычыңны бир, кабәхәт.

— Нинди бурыч?

— Башыңны тилегә салма! — Чуркинның арткарак яшергән кулы селкенеп куйды.— Дежур көнне, урын җир алыштырганда, миндәр астыннан алган илле сумны оныттыңмы?

Сәләхинең яңак тамырлары янә тартылып килде. Сагая төште.

— Мин анда бер нәрсә дә күрмәдем. Син нәрсә?

Чуркинның кыек күзләре зәһәр ялтырады.

— Мин барысын да беләм. Хәйләләмә! Бир диләр сиңа! — Чуркин яшергән пычагын Сәләхинең күкрәгенә китереп терәде.— Акчаң юк икән, бүтәнчә түлә...

Сәләхи коточкыч ишарәдән телсез-өнсез калды. Тешләре пыяла ваклагандай шыгырдап килде. Чуркин, пауза ясауның уңышка китермәгәнен белеп, һөҗүмгә күчте:

— Йә?

Сәләхи мондый чакта озак уйланып торырга ярамаганлыкны аңлады. Сеңерләре болай да соңгы чиккә җитеп тартылган иде. Ул, пычактан сакланып, бер адым артка чигенде дә, бар көченә кычкырып җибәрде:

— Ку-се!

Кисә карагына ишарә ясаган бу тавыш һәммәсен урыннарыннан сикертеп торгызды. Чуркинның пычагы, ялтырап, Сәләхи кулына күтәргән урындыкка килеп кадалды. Урыннарыннан дәррәү күтәрелгән тоткыннар баракның теге почмагыннан да, бу почмагыннан да йөгерешеп килделәр. Китте акырыш-бакырыш, китте сугыш. Өскә эскәмия, нар такталары очты. Котырынган тоткыннарның йөзләре канга батты, тешләре сынды. Идәннең бер почмагына барып төшкән Сәләхине, инде аңын югалтуга карамастан, типкәләп уздылар...

Шул бәрелештән соң озак, бик озак авырды ул. Аягына басып йөри башлагач та аны теге яклылар күздән ычкындырмадылар. Һәр адымын күзәтеп йөрделәр. Белмим, ничек исән калыр иде ул, әгәр аны «Кислый» кушаматлы

таза Чистай егете үз канаты астына алмаса. Моның өчен ул аңа мең рәхмәтле. Сытыграк чырайлы, аз сүзле «Кислый» аны үз янына, такта яру эшенә алдыртты. Сәләхинең бармагы шул эштә гарипләнеп кәкрәйгән иде. Берсендә тар тимер юлдан такталарны ары башка тәгәрәтеп бара иде, ул шунда кемнеңдер кулын саллы гына итеп җилкәсенә куюын сизеп туктап калды. Борылып караса, «Кислый» икән. Сулышына ут капкан диярсең!

— Сәләхи! Яңа хәбәр ишеттеңме әле? — диде ул гомерендә булмаган ачык йөз белән.

— Юк. Нинди хәбәр?

«Кислый» калын иреннәрен җәеп, теге сугышкан көнне сынган тешен күрсәтеп елмайды:

— Ам-нис-тия!

Әлеге хәбәр Сәләхи җанын коштай талпындырды. Шатлыгыннан йөккә тотынган кулын ычкындырып җибәрүе булды, ишелеп төшкән такталар арасына бармагы кереп тә китте. Сеңере тартылып өзелгәнен дә сизмәде.

Бүрек колакчыны бер якка салынып төшкән «Кислый» аңа карап елмайды да:

— Көт, якташ! Тиздән ирекккә чыгабыз,— дип үз юлына китеп барды.

«И-их, мине дә җибәрсәләр, ә?» — дип уйланды Сәләхи. Ун елның дүртесен генә утырды шул әле. Верховныйга язган хатларына җавап та килмәде. Югыйсә, ни гаебе бар? Колхозга сыерын биреп кермәгәне өчен «халык дошманы» саналсын инде! Кайтарсыннар, кайтарсыннар иде аны... Галимәсен, улын ничек сагынуларын бер үзе генә белә...

Бу чак уйга бирелгән Сәләхинең карашы ниндидер билгесезлеккә төбәлгән иде. Алдындагы энҗе кар бөртекләре яз кояшыннан җемелди, моңсулык сарган күзләрен чагылдыра. Күз һаман шунда — нурлар кисешкән бер ноктага карап тора. Нурлар чагылышында гүя Галимәсенең аксыл көләч йөзе балкый. Уймакланып баткан бит чокырларында пәйда булган икенче кояш җанына җылы биреп, күңелен иркәли, үзенә тартып, ымсындырып тора. Елмаюлары эчкерсез, саф. Карашлары мөлаем... Кинәт барысы да үзгәрде (әллә Сәләхи сөйгәненә күз тидердеме?!). Галимәнең көләч йөзен болытлар каплап китте, кайгы сарды. Судтагыча янә Сәләхине якларга тотынды, җыелган халыкка гозерләнеп дәште: «Авылдашлар! Җибәрегез иремне! Яклагыз... Шушы балам хакына булса да... Сәләхи авылның чишмәләрен карап тора, суын барыбыз да эчәбез... Кызганыгыз аны!..»

...Чү! Нишләп ул эрбет чикләвеге җыям дип, куе урманга кереп адашты соң? Быел уңган дисәләр дә ник бер агачы табылсын. Кая карама — чыршы! Шәм кебек төз чыршы! Зәңгәр күккә уктай кадалганнар. Ә монысы — миләш, туган як истәлеге! Сиңа мин түбәнчелек белән баш иям. Кыпкызыл тәлгәшләрең күңелем түрендәге яшәү чаткылары сыман яна. Яфраклар арасына биек агачлар өстеннән кояш нуры үтеп кергән. Буй калкыта алмый түбәндәрәк калуыңа кимсенәсең булыр, миләш. Әллә шул язмышың белән килешмәгәнгә моңаеп утырасыңмы? Әйт әле, миләш?! Мин соң бу җирләрдән исән-сау кайта алырмынмы? Дәшмисең. Оялчан кызлар кебек, янәсе, үзең аңла... Аңлар идем дә, кем кабере өстендә шытып чыкканыңны белмим... Сыйлан? Рәхмәт башыңны иеп, җимешләреңне тәкъдим итүеңә... Тәмле икән. Бер дә әче түгел. Менә күз явын алырлык кызыл тәлгәшеңне куенума тыгам, баракка кайткач, дустым «Кислый» белән бергәләп ашарбыз. Хуш, яме?..

...Каяндыр сөрем, төтен исләре килә. Әле күптән түгел генә урманнар янган иде. Шуның галәмәте микән? Бер яна башлаган урманны тиз генә сүндерермен димә. Төтен сине каян да эзләп таба. Надзиратель кебек. Күз кызарып йөри. Ике ай сүнмәгән утны ярый әле тоташтан яуган яңгырлар сүндерде.

Мин сазлык ягына карап барам икән ич. Мүк җиләкләре күп булып үскән төшкә. Аяк асты ничек бата! Моннан да ары китәргә ярамый, җир суыра башласа — беттең... Бу ни? Сазлык ягыннан кеше тавышлары килә:

— Кот-ка-ры-гыз! Ба-та-быз!..

Әллә тоткыннарны юри шул алдавычка куып керткәннәрме?

Җиләккә дип. Тизрәк котылыр өчен. Яхшы җәтмә! Алдауга корылган дөньяның газаплары чиксез! Их, туганнар! Кичерегез мине, сезгә ярдәм кулы суза алмыйм. Алдавыч сазлыкның корбаны буласым килми. Болай да аякларым көчкә атлый.

Нигә, нигә дип килеп кердем мин монда? Кем адаштырды мине, кем? Барысы өчен дә син гаепле моңа, Ярулла, син! Авылдашыңны күрәлмәдең. Ник? Колхозга сыер бирмәүне сәбәп итеп кенә калмадың, сиңа минем «Зингер» машинасында тегү теккән дә ярамады. Янәсе, мин чит ил кешеләрен — немецларны өстен күрәм, аларга йөз тотам. Советка каршы фикер йөртәм булып чыга. Шул уйдырмаларыңны алга сөрмәсәң, аз гына булса да якларга

теләсәң, мин монда, тайга урманнарында газап чигәсе кеше идеммени?! Их, бер кайтып күрсәм иде үзеңне, күрсәм иде... Белер идем...

Мин тәмам адаштым бугай. Миңа бу яккарак борылырга кирәктер, мөгаен. Чыннан да, монда тәбә аяк асты катылана барган кук. Ничек тә сазлык ягыннан читкәрәк китәргә иде. Шушылай турыга барыйк, ни булса шул!.. Менә аяк асты әкренләп җир белән тигезләнә. Тагын, тагын бераз барам да, чак кына ял итәм. Әнә теге ак каенга сөялеп. Инде җитәр! Кош сайрый! Нинди кош икән бу? Бер дә безнең як кошларына охшамаган. Тавышы тирәннән, үзәкләрне өзеп чыга. Урман эчләренә сарылган сагышлы моң аның җан рухыннан сарыккан, мондагы сыкраулы җаннарның өн гамьнәреннән иңгән сыман... Сайра, сайра, кошкаем! Син мондагы күп кенә яшерен эшләрнең шаһиты да, сагыну-сыкрауларны, шәфкать көткән күзләрдән аккан хисмоңнарны йөрәгеңә кабул итүче һәм аларны иң югары дәрәҗәдә башкаручы затларның берсе дә, моңсарым! Бу моңнарың үлемнәрдән котылган Сәләхигә шатлыклы хәбәр булсын! Тындың? Әллә минем юравымны кабул итә алмадыңмы, кошкаем? Әллә монда сиңа да лагерь башлыгы: «Телеңне кисәм!» — дип бармак яныймы? Шул гына җитмәгән! Безнең телләрне күп кистеләр инде. Шуңа да карамастан, мин сиңа бүген үзебезчә — татарча сөйлим, татарча көйлим. Көй-моңнар бар телләрдә дә аңлашыла, хокуклар чикләнсә дә. Ә син сайра, сайра, кошкаем, моңнарыңа дөнья киң...

Тукта! Бу нинди киңлек? Сәхрә түгелме? Тизрәк, тизрәк! Үзебезнең Имәнкискә кыры кебек. Аяк атлавы сизелми дә. Әнә болыннар, басулар ачылганнан ачыла бара, кояш нурларына кочакларын киңрәк җәяләр. Гаҗәп! Чәчәкле басуларда кошлар сайрый, ә астарак, Панса елгасына охшаш инеш буенда, язгы карлар эреп бетмәгән, җир ала-кола. Җил. Соры, алама кием кигән тоткыннар төркем-төркем булып шул елгага таба баралар. Берсе дә артына борылып карамый. Исәпләре — елганың аръягына чыгу. Елгадан ургылып ташу ага, бозлар ага. Әнә кайберәүләр боздан-бозга сикереп, аргы якка чыгалар. Кайберләре бозларның иңләп килгәнен көтеп ала. Берсе дә суга төшми, җиңел генә узып китәләр. Ә мин ни көтәм? Миңа да алардан калышмаска кирәк! Мин килеп җиткәч, бозлар сирәгәйде, елга буйлап агымга каршы чабам. Нишләргә? Бозлар берән-сәрән генә агып килә. Әллә бөялеп калганнармы? Ахры, шулай. Әнә теге борылыштан этешә-төртешә, ватылаҗимерелә агып киләләр. Өсләренә керергә куркыныч, тибеш аккан су боз астына бөтереп алып кебек. Менә бу тар борылышка җитсеннәр әле... бөялеп калмасалармы? Үз күземә үзем ышанмыйм: өметләнгәнем рас килде. Һәм мин, ни гаҗәп, бозлар өстеннән песи кебек кенә чыгып китәм...

Караватына сеңеп яткан Сәләхинең күңеленнән әлеге вакыйгалар төш сыман агылды. Тоткынлыкта узган көннәренә бәйле кичерешләреннән тиз генә арына алмады.

Беркөнне аны, төнге эштән кайткач, кара мыеклы надзиратель төртеп уятты:

— Касыймов, тор! Соңыннан йокларсың.

Әле яңа гына йокыга киткән Сәләхи, чыраен сытып, үпкәсен белдерде:

— Мин ял итәргә тиеш, әле кайттым гына бит.

Надзиратель мыегы бер якка авышып кабарды һәм ул тавышын күтәрә төште:

— Ерак этапка китәсең...

Бу сүзләрне ишеткәч, аның коты очты. «Тагын нишләтмәк булалар икән?» Йөзе агарып чыкты. Надзиратель, бернигә игътибар итмәстән, үзенекен тукыды:

— Киемнәреңне дә ал!

Җыенып беткән Сәләхи кара мыеклы надзиратель артыннан ияртде. Берни дә аңламаган иптәшләре аны аптырашып озатып калдылар. Урамга чыгып, йөз метрлар чамасы киткәч, надзиратель кинәт туктады, аңа таба кырт борылды, кара мыегы янә кыйшайды.

— Өеңә кайтасың.

Сәләхинең күзеннән яшь бәреп чыкты... Верховныйга язган икенче хаты тиешле кешеләр кулына барып җиткән икән...

Ни аяныч! Больница түшәменә багып хатирәләргә бирелгән Сәләхинең аякларына җылы керәсе итмәде. Күңеле нидер көтә иде. Ул менә шулай, яткан килеш, көймәдәй салмак кына агып барыр-барыр да, үзе дә сизмәстән юкка чыгар шикелле. Торып-торып гасабиланды, ышану өметен югалтасы килми иде. Күкрәгенә авыр таш бастырып куйган төсле. Сулышы кысыла, торып китәргә ирек бирми. Юкса, тыштан караганда, күкрәгендә кәкре бармаклы кулыннан битәр берни дә юк ич. Бар икән, тегендә чакта кытай карасына манылган энә белән төрткәләп ясалган Сталин! Аңа ышанычын югалтканнан

бирле җаны тетри, рәсеме дә тиресен ярып, тегеп куйган таш кебек тоела. Ул ачып куйган изүен төймәләп йөри башлады, кешеләр алдында чишенүдән тарсынды, хәтта хатыны белән мунча керүдән дә читләште.

Әмма Сәләхинең күкрәк читлеген бүген бүтән нәрсә кыса. Җанын Җиһангир каршындагы гаебе, теге чакта кылган яман хыянәте кимерә. Аны шулай ук лагерь юлларын таптаган, коточкыч сынауларга дучар булган һәм шунда билгесез кабердә ятып калган Ярулла рухы газаплый. Кайта-кайта истәлекләргә бирелергә, шактый охшаш үткәннәрен, хәтер чоңгылын кузгатырга мәҗбүр итә. Дөньялыкта кылган гөнаһларын үзе белән алып китәсе килми аның. Җиһангир кичерә алса, ул аңардан гафу үтенер иде. Җан тынычлыгы өчен, алла хакына!.. Тик ул сүзен каян, ничек башлап җибәрергә белми.

Менә Сәләхинең түшәмгә төбәлгән тонык күзләре ялтырап китте. Күкрәк өстенә куйган кулы дерелдәде. Аны икенче кулы белән тотып туктатырга ниятләнде. Учындагы өч тиенлек бакыр зурлыгындагы миңен күргәч, керфекләрен каккалап алды. Хәтер төбендә янә бер очкын кабынды. Лагерь барагында сугышканнан соң аның шушы кулы һәм бармак эзләрен махсус кәгазьгә бастырып «баян уйнатканнар» иде. Ул шул чакта аерым билгеләре янына шушы миңен үзе әйтеп яздырткан иде. Сәләхи күңеленнән: «Яманлык та, миң кебек, артыңнан калмый икән»,— дигән нәтиҗә ясады. Онытылмый. Чалгы йөзе кебек үткер, кырыс карашлы, күн тужурка кигән район агенты да онытылмый, сорауларын ялалы күңелгә учлап сибә:

— Сыерың бармы?

— Бар.

— Сарыгың ничәү?

— Дүрт.

— Тавыгың?

— Биш.

— Тагын нәрсәләрең бар?

— Мәчебез бар...

Агент сикереп тора. Сәләхи янына авызын чалшайтып килә.

— Күрсәтермен мин сиңа мәчеңне!..

Китә кызып, китә... Авыл Советы рәисе Ярулла бер почмакта дәшми утыра. Аңа, бәлки, дәшмәскә кушылгандыр. Кем белә, бәлки Сәләхи алдан каралган «план» корбаны булгандыр...

Сәләхи күз карашын Җиһангирга төбәде, әйтерсең, аның каршында Ярулла үзе ята.

— Җиһангир...— Картның тавышы тоник, ялварулы.

— Нәрсә, Сәләхи абый?

Сулышы кысылып, күгелҗем-зәңгәрсу иреннәре калтыранды.

— Син мине гафу итә күр инде...

— Нәрсә өчен?

— Теге чакта... Әтиеңнең айгырын мин үтергән идем... Ялгышлык эшләдем... Кичерә алсаң, кичер, зинһар...

Ни дип тә әйтергә белмәгән Җиһангирның авызы ачылып калды. Җавап көткән палата эче тып-тын иде...

— Хет монысы өчен рәхмәт...

Иртәгесен Җиһангир уянып киткәндә, Сәләхи картның койкасы буш иде инде...

Врачлар Җиһангирның арка миеннән сары су алдылар...

Бер тәүлектән соң авыруның хәле бераз җиңеләйгән сыман булды. Ул баш авыртуының кимүен сизде. Күз алдында эленеп торган томанлы пәрдә чак кына ачыла төште. Шулай да зарарланган нервыларның элекке хәленә кайтуы, ай-һай, шикле...

Бер айдан соң гына таякка таянып больница коридорына чыга алды.

Бүген әкренләп йөри башлавының икенче көне. Шактый интеккәч, тынгысыз җанына урын таба алмыйча, коридорның бер уентыгына урнашкан аквариум янына килеп утырды. Борчулы уйларыннан арынып, онытылып торасы килде аның. «Пыяла йорт» эчендә вак балыклар йөзеп йөри, алар савыт төбенә салынган ком, чуерташ, әкәм-төкәм кабыклары өстеннән, нәзек сабаклы яшел үләннәр арасыннан ялт та йолт узып торалар. Берсен-берсе куышып шаяралар, тәрәзәдән төшкән кояш нурларына куанып бетә алмагандай, иркәләнеп йөзәләр. Зуррак кызыл канатлысы аллы-гөлле нурлар чәчә. Аңардан ваграклары, уктай атылып, көмештәй ялтырап, «пыяла йорт»та рәхәт чигәләр. Гүзәл җан ияләре. Ни генә әйтмә, күлләр һәм елга сулары тере балыклары белән матур. Әнә дәүрәк балыкның нәфис канатлары кызыл әләмчек булып җилферди. Яшел үләннәр арасына кергән дә, ял итәргә теләгәндәй, туктап калган. Саңаклары бер ачылып, бер ябылып тибрәнә,

ниндидер көй көйлимени! Күзләрен тутырып Җиһангирга карап тора. Авыз кырыендагы мыекларын тырпайткан. Янында гына койрык җемелдәтеп узып киткән балыкка да игътибар итмәде. Бер урында озак тору ялыктырды булса кирәк, кызыл әләм канатларын җилфердәтеп, хәрәкәткә килде, үз авырлыгын күтәрә алмаган сыман, батып төпкә төште, чуар ташлар арасыннан эзләнеп чемченгәндәй итте, калкып торган үлән тамырларына мыегы белән кагылып китүгә, туптай атылып кире чигенде. Әйтерсең ярамас нәрсәгә юлыкты, сагаеп калды һәм, янга борыла төшеп, ары узды.

Балыкларның мәш килүен күзәтү күңелле. Ихтыярсыздан, уй йомгагы Кама суларына барып ялганды. Куәтле ГЭСлар кору чорында су астында калган иксез-чиксез болыннар, әрәмәлекләр, җиләкле аланнар, шунда калган гомер, онытылмаслык яшьлек эзләре хәтерендә яңарды. Алай гынамы соң, язын су тулган күлләр кулына килеп кергән искиткеч матур Ак балык хәтеренә килде. Исән булса, зур үскәндер инде...

Болыннар, болыннар! Заманында аларның сусыл печәненә патша хәзрәтләренең чаптарлары өчен Питердән әллә ничә йөз олау килә торган булган. Әй, нинди хозур иде ул болыннар! Курортларың бер якта торсын! Аларның ямен, хуш исен сөйләп кенә бетерерлекме? Шул болыннарга печән өстендә җигүле атларга төялеп төшүе җан рәхәте иде бит! Ул елларда, тамак әллә ни тук булмаса да, барына шатлана белә идек. Ул болын өсләре сабан туе мәйданыдай гөр килер иде. Кайсыдыр чалгысын яный, кемдер тек тә тек чүки. Яшь җилкенчәкләр, күбәләктәй очынып, печән тарата. Казан асларында учаклар дөрли. Бил тиңентен чишенеп аткан егетләр күкрәктән булып үскән печәнне, бер-берсе белән ярышып, пакусларга салып баралар. Ул тау буендагы җиләклек! Өзеп авызга каптыңмы — хуш исеннән сулышлар иркенәеп, җаннар рәхәтләнеп китә. Печән чабучы егетләр артларыннан басырып килүчеләргә карап-карап алалар. Бирештем юк! Маңгай тирләрен сыпырырга онытып, пакусларын суза бирәләр. Артларыннан читләп-читләп кенә булса да, инсафлы, эчкерсез кызларның мөлаем гына елмаеп күзәтүләрен дә тоеп атлыйлар. Кызлар кайчак, җил чыгып, каз мамыклары күтәрелеп очкандай, көлешеп, шау-гөр килеп алалар. Аларның көләчлеге күңелләргә дәрт, беләкләргә көч өсти. Ул да булмый, аш-су өлгергәнлеген хәбәр итеп, учак янындагы казыкка бәйләнгән чуенга сугалар. Чалгыларын иңнәренә аскан егетләр ашыкмый гына, төрлесе төрле яктан болын табынына җыела. Түгәрәк табын болын сәхнәсенә әйләнеп кала. Күр күңелле яшьләрнең телләрендә уен-көлке. Аннары, бераз көн сүрелгәнче, арба асларына, шалаш куләгәләренә ятып, черем итеп алу, ат эчерү, су керү башлана. Әбәт вакыты чыгуга, янә дәррәү эшкә тотыналар. Кибеп өлгергән печәннәр ике җәпле агач сәнәкләр белән тетәкләнә бара. Болындагы бәйрәм ярыш төсен ала. Ярыш бригадалар арасында гына калмый, печәнгә төшкән күрше авыл яшьләренә дә барып җитә. Калкып чыккан печән кибәннәре ярыша. Имәнкискәнекеләр, сер бирмәс өчен, хәйлә кора: печән богылларын бөтенләй очлап бетермиләр. Кайтыр вакыт җитәрәк кенә очлап куялар да, күршеләрнең күзе ут була. Кибән очларына печәнне озын, җәпле агач сәнәге белән Җиһангир тондыра. Ул өйгән кибәннәргә яңгыр суы үтте юк! Кичке эңгер төшкәндә, башкарган эшләренә сөенешеп, атларын чуклап-матурлап җигәләр. Берсеннән-берсе сылу кызлар ап-ак алъяпкычларын селкеп кага, нәзек билләрен буып бәйлиләр дә арбаларга тезелеп утыралар. Гармунчы Йосыфны урталарына алып, дәррәү җырлап җибәрәләр. Башларын дугаларына күтәртеп бәйләгән атлар тезелешеп кайта. Зыңлаган кыңгыраулар яшьләрнең җырын озата бара. Чая егетләрнең кулын тойган атлар алга ыргыла. Арбадагылар артка сөрлегеп куя. Янәшәсендә утырган шомырт кара чәчле Хәлимә Җиһангирның беләгенә ябышып кала...

Үткән көннәрен күңеленнән кичергән Җиһангирның йөзе моңсу иде. Аның янында узып барган врач Галия Габдрахмановна моны сизде, авыру янына тукталып:

— Сабиров! Хәлегез ничек? — диде, Җиһангирның беләзегеннән кулы белән тотып, пульсын санап карады.

— Ярыйсы кебек,— диде Җиһангир уңайсызланып.— Тик менә баш сызлый, аннары... менә... аяк-кулны җибәрми...

Галия Габдрахмановна, аңлыйм дигән шикелле, башын кагып куйды.

— Түзми булмый инде, түзик,— диде.— Яңа дарулардан соң вакыт үзе булышмасмы?

— Озакка барыр микән?

— Төгәл генә әйтүе кыен. Иң мөһиме — борчылмагыз...

Врач китеп баруга, Җиһангирны уколга дәштеләр.

Ул көндезге ял сәгатендә йокыга китә алмый ятты. Палатада тагын ике авыру бар иде. Берсе утыз яшьләр тирәсендә. Юлда бәрелеп, машинасында капланган, чәче тәүлек эчендә агарып калган, кабыргаларына зыян килгән.

Икенчесе, аягын пушка көпшәседәй караватына терәп ятканы, инде гипссыз гына гырлап йоклый. Сулышыннан стенадагы обой ертыгы дерелдәп куя. Бирегә кергәндә йөзе танырлык түгел иде. Кайдадыр үз тиңнәре белән тәпәләшкәннәр, моңа да типкәләгәннәр, Яңак сөякләре дә кыйшайган иде. Башта рәтләп сөйләшә дә алмады. Җиһангир үз алдына: «Бу яшьләргә нәрсә җитми? — дип борчылып уйлады.— Кешене шул хәлгә төшерсеннәр инде, ә?! Имансызлар. Алар өчен кеше имгәтү берни тормый. Нужа чиккәннәре юк...— Ул, ихтыярсыздан, малае Фәезне искә төшерде.— Калада безнеке нишләп йөри икән? Болай акылсыз түгел иде түгелен. Кем белә бит...»

Малаена бәйле уйлары куерып китте. Училищены тәмамлап, яңа гына төзелештә эшли башлаган улы аңа:

— Әти, беренче алган акчамны сезгә бирергә булдым,— дип сөендергән иде аны. Күп итеп акча биргән иде.

Гаҗәпләнгән Җиһангир ул чакта хәтта улына ышанмыйчарак торды.

— Улым! Барысы да үз акчаларыңмы соң?

Фәез бу сораудан көлемсерәгән иде.

— Ни дигән сүзең, әти? Каян килсен миңа бүтән акча?

— Болай гына соравым, бик күп ич,— диде Җиһангир, учындагы акчаларын нишләтергә белмәгән төсле.

Фәезнең бераз үз дәрәҗәсен күтәрәсе дә килде:

— Мине бит монтажниклар бригадасына алдылар.

Әтисе моңа ихлас куанды.

— Яраган, улым, бик яраган! Монтажчы һөнәре гади һөнәр түгел... Исән була күр, балам...

Шул сөйләшүдән соң ике атналап вакыт узгач, Җиһангир, Казанга килешли, малае эшләгән трестка кереп чыгасы итте. Тәртибен-мазарын да белеп чыгармын, дип уйлады. Беренче айны ук шул кадәр акча бирүләренә һаман да ышанып җитми иде.

Трест бухгалтериясендә Җиһангирны шәм төсенә буялган чәчләрен күпертеп куйган, өстәвенә хушбуйны мулдан сипкән кырык яшьләр тирәсендәге бер ханым каршылады. Алдындагы журналын ачып, исемлек буйлап ялтыравык күзләрен йөгертә-йөгертә сорап куйды:

— Кемегез соң ул Сабиров?

— Улым.

Алтын балдаклы бармагы исемлек уртасына җиткәч, ханым туктады.

— Бар андый егет,— диде башын күтәрми генә.— Монтажниклар бригадасында эшли. Шуннан? Аңа ни булган?

— Узган айда күпме акча алганын беләсем килгән иде.

Бухгалтер хатын, сагая төшеп, Җиһангирга карады.

— Нәрсә? Әллә тиешен түләмәгәннәрме?

Җиһангир аның ул соравына уңайсызлана калды.

— Юк,— диде ул сүзен чак кына әвәләп,— артык түләмәделәрме, дим...

Бухгалтер гаҗәпләнүеннән көлеп җибәрде.

— Абый! Монда кереп «Аз түләгәнсез!» — дип кенә башны катыралар, ә сез...— Ханым янә исемлегенә карады.— Малаеңа өч йөз илле сум акча түләнгән...

Җиһангир, дөрес икән дип уйлап, рәхмәтен әйтеп чыгып китте.

Ә бер айдан Фәезне, әле унсигез яше тулып җитмәгән дип, монтажчылардан балта осталары бригадасына күчерделәр. Шуннан соң Җиһангир: «Нигә кирәк иде миңа тыкшынып йөрергә?» — дип борчылып уйлады. Әтисенең башы имгәнгәч, Фәезе больницага да килеп киткән, соңыннан әйттеләр, ә ул чагында Җиһангир берни белештермәгән иде.

Җиһангирның сул ягын, әйтерсең, катырып куйганнар. «Башның уң яктагы нервылары ничек итеп сул аяк-кулга бәреләә икән?» — дип гаҗәпләнде ул. Аны зиһененең элеккечә ачылып китмәве борчый. Керфекләрен йомды исә, күз алдына әллә ниткән сурәтләр килә, машинадан ычкынган тәгәрмәчләр сыман әйләнеп, берсе артыннан икенчесе чыгып кына тора. Минем кайсыдыр бер почмагы ялкынсынып көйри. Йокы керми. Эштән арып кайткач, башы мендәргә тиюгә изрәп йокыга китә иде бит ул...

Бүген Хәлимәсе никтер килеп чыга алмады. Үзе авырып китә күрмәсен инде. Аңардан башка Җиһангир — ике кулсыз.

* * *

Озак интекте Җиһангир. Кырык алтынчы тәүлегендә генә таякка таянып больницадан чыкты.

Август иртәсе. Көн җылы, кояшлы. Аны алырга авылдашы Йосыф малае килгән. Җиһангир машинага кадәр араны курка-курка, сагаеп атлады. Шофер

егет аны янынннан саклабрак барды, бер кулына сумкасын тотты, икенчесе белән җитәкләде.

— Ашыкма, Җиһангир абый, ашыкма... Җитешербез...

Кызулап киткәч, егет тагын юатты:

— Рәтләнерсең, Җиһангир абый. Әҗәл чире түгел бит.

Җиһангир авыр көрсенде.

— Белмим инде... Саулык бер ычкынмасын икән... — Җиһангирның таянган таягы калтырап китте.— Инвалидлык бирергә тиешләр... Икенче группа булырмы, өченчеме...

Машина янында Мансур аңа кабинага керергә булышты. Әкрен генә кузгалып киттеләр.

Авылга кергәч, машинаны капка төпләренә кадәр иттереп тормады. Бәрәңге бакчасы янында туктаттырды. Шуннан бакча тыкрыгы аша гына күтәреләсе итте.

Машина гөрләп кузгалып киткәч, ул бер тын бакча киртәләренә сөялеп торды. Әйләнә-тирә тын. Бар нәрсә, җылы кояш нурларында изрәп, йокыга талган. Һәммәсе таныш, җанга якын. Бәрәңге бакчаларының кыйшайган киртәләренә кадәр якын. Таныш өйләр, таныш каралтылар. Искеләрен яңалары алыштыра, үзгәрә тора... Әнә, күпләр быел тезмәгә сыймаган печәннәрне чүмәлә-чүмәлә итеп тә өйгәннәр. Печән кирәк, печән кадерле... Фәезе Казаннан кайтып булышып китсә, ярар иде. Үзе чалгы тоталмас инде...

Җиһангир Камага ике күздәй карап торган зәңгәр тәрәзәләренә караш ташлады. Аларда агымсу өстендә уйнаган нурлар чагыла. Тәрәзәдән Хәлимәсе күреп алырмы? Әллә өйдә юкмы? Ул янә елга өстенә карады. Дулкыннар ярны ашап килә. Тора-бара гомер иткән нигезгә дә куркыныч янаячак. Ул, шуны хәзер генә аңлагандай, йөзен чытып куйды. «Бу ярның берәр чарасын күрми калмаслар,— дип уйланды. Моннан, чүтеки, асфальт юл уза. Җир асты торбалары. Ком өйдертеп булса да ныгытырлар ярны...»

Ул, бакча киртәсенә тотынып, кузгалырга талпынды. Күптән кагылган казык авышып, сынып чыкты. Яңартып тормасаң, искерәләр шул... Әнә, киртә буйларын билчән, кычыткан баскан. Сукыр кычытканнарга юлыккач, аларның шәмәхә-зәңгәр чәчәкләрен үзенә төнәтмә ясап эчәргә кирәклеген исенә төшерде. Врач шулай киңәш итте бит. Бераз гына атлауга, үлән арасындагы калган-поскан ташларга сөртенмим тагын дип, читкәрәк тайпылды. Таяк тоткан кул, хәлсезлек тоеп, дерелдәп-дерелдәп алды. Кемнәндер ярдәм көткәндәй, башын күтәреп, алга карады. Күңеле сизгән, Хәлимәсе каршына килә иде.

— Нишләп монда төшеп калдың? — диде хатыны, упкәләгән сыман һәм килеп җитүгә иренең кулыннан сумкасын алды.

— Үз көемә җәяүләп кенә кайтасым килгән иде,— дип акланды Җиһангир.

Хатыны аны култыклап алды, алар сукмактан янәшә атладылар.

* * *

Җиһангирның күңеле вакыт-вакыт ачылып, дәртләнеп киткәләде. Шушы хәлдә таякка таянып йөрүенә, әле ярый исән калуына шөкерана кылды. Йорт-җир арасында тегеңә-моңа күз-колак булсаң да, вак-төягенә көчең җиткәнчә булыша алсаң да ярый әле, дип үз-үзен юатты. Элеккечә җигелеп эшлисе иде дә, көче җитми шул...

Ул көннән-көн савыга бару өмете белән янды, саташулары кимеде, торабара йокы тынгысызлыгы да узар әле дип уйлады. Әмма хәле, һава шартлары алышынуын төгәл сизгән барометрдай, гел үзгәреп торды. Кичке якларда кәефенең начарланып китүен, талчыгуын сизде.

Җиһангир өчен ут йотып йөргән Хәлимә иренең һаман да мантып китә алмавына аптырый, төрле үләннәрдән төнәтмәләр ясап бирә. Иренең какшаган нервылары тиз генә тынычланырга юл куймый. Моңарчы ничек түзгәндер (кешене өмет яшәтә!). Җиһангирның һаман тернәкләнеп китмәвенә бик борчыла, йөрәк әрнүләренә чыдаша алмыйча, хафага төшеп, йөзен учларына каплап, үксеп-үксеп елый. Кайларга барып бәрелергә белми, тамагыннан аш үтми. Фермасына барса да күңеле тыныч түгел, өйләренә кайтса да. Сер уртаклашыр кешесен тапмый, аптырагач, күзләрен мөлдерәтеп карап торган бозаулары белән сөйләшә, аларның шома, йомшак йонлы муеннарыннан сыйпый-сыйпый, уйларына урала, йөрәге пәрә-пәрә килә. Шул тетрәнүләреннән сары лимон кебек бөрешеп, чагаеп калды, йөзен сагыш сарды. Болар берсе дә эзсез калмады. Җиһангиры аз гына начарланып китте исә, йөрәге урыныннан куба. «Тагын авырса, нишләрмен?» — дип уйлый.

Хәлимә эшкә киткән иде. Җиһангир, юк, болай, уйланып ятып булмас, хәрәкәтләнә алганда бераз кыймылдарга кирәк дип, ишегалдына чыкты. Бәйдәге Тарзан хуҗасын койрык болгап каршы алды. Сөенеченнән аңа башларын чайкый-суза, иркәләнәсе, назланасы килә бугай. Җиһангир:«Һайт сине, һайт сине!» — дип кара йөнтәс этенә якын килде, башыннан сыйпады.

— Шатланасыңмы? Маладис син, авырсам да адәмнәр кебек йөз чөерүне белмисең... Ихлас бәндә син, Тарзан!

Аннары ул өй каршындагы кечкенә бакчага чыкты. Рәшәткә ишеген япкач, бер тын Фәезе утырткан миләш агачына карап торды. Агач төбендә әбисе каберенә дип улы койган таш шомартылып бетмәгән килеш ята. Җиһангир, аның бер ягын булса да шомартып куйсаң ярар иде, дигән уй белән йорт бүрәнәләренә таяна-таяна әчкәрәк узды. Саплы чүмеч эленгән сулы мичкә янындагы тәбәнәк урындыкка килеп утырды. Ташны яртылаш сынык кайрак белән шомартырга кереште. Ташның ташка ышкылуы, теш арасыңа кергән ком сымак, нервысына тиде, шуның галәмәте буларак, чырае сытылып чыкты. Борыны таштан күтәрелгән тузанны сизүгә, мичкәгә эленгән чүмечкә үрелде. Иске чүмечнең бер як төбе ачык ялтырап, мич казанына кыршылакыршыла тишелеп чыгар дәрәҗәгә җиткән иде. Таш өстенә су җәелгәч, шыкыртау бераз кими төшкән кук булды.

Җиһангирның төрле хәрәкәтләр ясап, таш ышкыган кулы вакыт-вакыт туктап кала, бил-аякларының эчтән тартышып килүен сизгәч, артык көч кую ярамас дип, сагая. Бераз тынып торуга, тагын эшкә керешә.

Таш өстенә миләш яфраклары куләгәсеннән ятьмә үрелгән. Күз-күз күләгәләр Җиһангир кул аркасында биешә, качышлы уйный. Җиһангирның уе Фәез тирәсендә чуала башлады.

...Малайга унике яшьләр. Әтисе алып кайткан ботинкалы тимераякларны тоткан да нишләргә белми! Авылда аныкы төсле тимераяк беркемдә юк. Шуңа да ул әтисен кочаклап үпте. Аннары оекбаш өстеннән чүпрәкләр чорнап, чак кына зуррак ботинкасын тыгызлап, бауларын тарттырып бәйләде дә, үзләреннән ерак та түгел генә Әнәч суына — боз өстенә чыгып чапты. Җиһангир аның артыннан кычкырып калды:

— Улым! Боз бар җирдә дә тигез катмаган әле, карап йөр, бата күрмә!

Фәез аның сүзләрен әллә ишетте, әллә юк. Ул инде бу минутта хыялында бозлар өстеннән коштай оча иде.

Берәр сәгать чамасы узды микән, ул билдән суга батып, өйгә канатларын салындырып шакы-шокы кайтып керде. Еламый. Авызын ерган да:

— Баттым! — дип идән уртасында басып тора.

Күңеленнән узган шушы хатирәләрдән соң Җиһангир:

— Хәзергесе көндә исән-сау гына йөрсеннәр инде,— диде. Кайтмый әле, бераз тегесен-монысын карашыр иде...

Кинәт Җиһангирның ташка сузылган куллары машина кычкырткан тавышка туктап калды. Ул торды, миләш агачлары арасыннан үрелеп, урамга карады. Каршы якта — кояшның алсу нурларына коенып, сап-сары чыршы бүрәнәләрдән салынган күрше Җамалетдиннар йорты янына ак «Жигули» килеп туктаган икән. Малае Сәлимҗан кайткан, җәмәгате белән. Аларны күзәткән Җиһангирның, ни хикмәт, йөзе ачылганнан-ачыла барды. Күкрәгенә шифалы дулкын бәрелеп киттемени, бик якын кешесен каршылаган төсле, канәгатьлек хисләре кичерде, үз-үзенә сөйләнеп тә алды: «Җамалетдин абыйның малайлары да үзенә охшаган, шәфкатьле, кешелекле. Каберен дә, йорт-җирен дә карап торалар. Туган нигезләрен ташламыйлар, кайтып-килеп йөриләр...»

Сәлимҗанның чук кебек киенгән хатыны, алсу йөзен балкытып, олы капканы ачты. «Жигули» машинасы ишегалдындагы яшел чирәм өстенә ак коштай кереп кунаклады. Капка ябылуга, сары бүрәнәле Җамалетдин йорты, кунаклар кайтканга сөенгәндәй, балкып китте. «Их, үзе исән булса... — диде Җиһангир. Йортның яңасын салган гына иде, яшәү насыйп булмады. Хатынын җирләү кайгысын күтәрә алмагандыр инде...»

Җиһангир, үзалдына нидер уйлап, талпынып куйды. «Булмаса керим әле, әйтәсе сүземне генә әйтеп чыгыйм»,— диде дә, таягына таянып, урамга чыкты, Сәлимҗаннар капкасына таба атлады. Аның Сәлимҗанга башын иеп фәкать бер сүз: «Рәхмәт!»—диясе бар. Төп нигезләрен онытмаганнары өчен...

* * *

Көндез бераз черем итеп алса, Җиһангирга ару булып китә иде. Бүген йоклый алмады, аптырагач, шөбһәле халәтеннән котылырга теләпме, урамнарны әйләнеп кайтырга булды.

Башта олы юлга чыкты. Яныннан гына бер малай мотоциклда узып китте. «Чәчләре тузгыган, гәүдәсен уклау йоткандай катырган, ә исәнләшү кирәген

белми. Әллә теләмиме? Элек бит авылда олысы-кечесе исәнләшми калмый иде. Кем малае икән? Хәзергеләрне танырлык та түгел... Үзләре күрмәмешкә салышып узалар. Ай, тиз үзгәрә кешең. Санлау юк... Авыру хәлен сау белми шул. Мәгънәсез малай-шалайдан ни көтәсең?»

Җиһангир, юл кырыйлап, авыл башына таба атлады. Машиналарга ягулык салу урынына җиткәч, тукталып калды. Ягулык агып сеңүдән шактый гына җирнең пеләшләнеп калуын күреп, кашлары җыерылды. Аннары ул сукалап узган ызан буйлап түбән таба — Кама ягына атлады. Ызан буенда ашламадан бушаган бер полиэтилен капчык яртылаш җиргә күмелеп, туфракта кысылып калган да җилфердәп утыра. «Тәртипсезлек инде,— дип уйлады Җиһангир.— Болай барса, бөтен дөньясын чүп басар, адәм чирдән арына алмас... Кая барабыз, белгән юк. Үләт базын да онытгык, тиресе бүреккә дип атылган эт үләксәсе дә инеш буенда ауный...»

Кама ярына җиткәч, Җиһангир үзен берәз икенчерәк сизде. Кәефе күтәрелгәндәй булды. Алтын комлы яр буенда йөзтүбән каплап куйган аллюмин көймәләр, дулкын кагып чыгарган эре балыклардай, ялтырап ята. Өстәрәк, яр ныгытыр өчен дип утыртылган тирәк кисентеләре, яшел тармаклар җибәреп, тернәкләнеп киткәннәр. Бакча артларына чыгарып өйгән тирес кучләре дөя сыртыдай калку. Шунда, киртә буенда, бер ала бозау күшәп тора. Каралты-курадан читкәрәк чыгарып салынган мунчаларның морҗа башларына иске чиләкләр каплап куелган. Саргая башлаган агачлар көзге моңсулыкта тынып калганнар. Җиһангирлар өенең Камага караган зәңгәр тәрәзәләре тагын да ачылып, тагын да зәңгәрләнеберәк киткән кук. Ул, балыкка йөри торган көймәсенә утырып, карашын шул зәңгәр тәрәзәләренә төби дә Камышлы күл тирәләренә таба ишкәк ишә иде. Хәзер дә, көймә борынындагы транзисторын тыңлый-тыңлый, кармак саласы килеп китте. Дөнья мәшәкатьләрен, авырту-сызлануларын онытып, күлгә керәсе килде. Юк, әлегә күлгә керергә ярамый, башы әйләнеп китмәгәе...

Авыл читеннән үк башланган басу-кырлар ерактагы урманга барып тоташа. Кояш нурына коенган басуларга сокланып, рәхәтләнеп яшәргә иде дә.

Тирә-якны эчке бер дулкынлану белән, моңаеп күзәткән Җиһангир, муенын суза төшеп, Камага текәлде. Кинәт башы әйләнеп китте. Вак дулкыннар уйнаган су өсте чайкалды. Ул, һавага тотынып калырга теләгәндәй, алга сөрлекте. Шул минутта күз алдына Фәезе килде. Ул төзелеш мәйданында, чиләкләрен күтәреп, йөгерә-йөгерә кайнар сумала ташый. Ашыга, кабалана, эшне тизрәк бетерергә кирәк. Аның авылга кайтасы бар — бүген җомга көн. Автобустан каласы килми. Менә ул ач яңаклы, сары чәчле егет янында туктап кала. Бригадирлары булса кирәк. Аңа нидер аңлата. Тегесенең калайланган күзләре ялтырый, Фәезгә бармак яный:

— Кайтарырмын мин сине!.. Синең өчен түбә җәйләрен кем ябыштырыр? Пушкинмы?

Фәез ачуы килеп китеп бара, тагын сумала ташырга керешә. Түзми, зарлана: «Эшлим дигәндә үзләрен кузгата алмыйсың... Әбәттә аракы чөмереп, икешәр сәгать кәрт суга лар да, смена ахырында кабаланырга тотыналар...»

Фәез эшне үз белдеге белән ташлап китәргә кыймый, кайнар сумаланы зур гына тимер мичкәдән каерып-каерып ала. Теләге — тиз генә ташырга да китеп барырга. Бәлки, соңгы автобуска өлгерер...

Менә югарыдан аңа кемдер кычкыра:

— Фәез, җитәр!..

Юк, аның тукталып каласы килми, ул: мәгез, күңелегез булсын, дип, соңгы чиләген каерып алырга тимер мичкә эченә иелә. Кулы белән таянган капкачы шуып китә дә мичкә эченә әйләнеп тә төшә...

Кайнар сумала эченнән чыккан Фәез нишләргә белми сикергәләнә. Җиһангир улы янына барып җитә алмый, аяклары авырайганнан-авырая...

...Җаны күбәләктәй бәргәләнгән Җиһангир шәфкать туташларын орыша.

— Ник мине малаем янына кертмисез? Мин бит аның әтисе...

— Ул әле белештерми...

— Белештермәсен! Күреп кенә чыгыйм... Әй, улым, улым... Ни хәлгә төшкәнсең... Ач әле күзеңне, ач?! Әтиең бу, әтиең... Менә шулай. Сөйләшә дә алмыйсыңмыни?

Врачлар Җиһангирны ашыктыралар:

— Ярамый, ярамый...

Ул Фәезеннән күзен алмыйча, артка чигенә.

— Алайса мин китим инде, улым...

Әйләнеп килгәндә, аның улы палатада юк, аны күчергәннәр иде...

...Җиһангир урамнан агылган кешеләргә юл биреп бетерә алмый. Бер тукталышта трамвайга утырырга ниятләп караган иде, кысып чыгардылар, таягы чак кулыннан төшеп китмәде. Икенче трамвайны көтте, анысы да ты-

гыз иде. Шулай да утырып китә алды. Ике тукталышны авырткан аягына басып барды, яшьләрдән аңа берәү дә игътибар итмәде. Алар йә тәрәзәгә карап баралар, йә дөньяларын онытып, сөйләшеп утыралар иде. Тик олы яшьтәге бер ир-ат кына, аның таякка таянып торуын күргәч, урын бирде. Шәһәр урамнарын, биек йортларны күздән кичереп барды ул. Халык арасыннан Фәезе килеп чыгар төсле күренде, улына охшаган егетләр күңелен ымсындыра иде. Коңгырт чәчләрен тузгытып, яланбаш йөри торган, аркасына спорт сумкасы аскан Фәез күренми...

Бара торгач, ул аптырый: күзалдында бер чалынган йортлар, урамнар гел кабатлана. Карале, трамвайда икенче мәртәбә әйләнә икән ич ул! Кешеләр инде төшеп беткән. Каршысында яшь кенә бер кыз басып тора.

— Кызым! Миңа Кремльгә барырга кирәк ие. Кайда төшәргә соң миңа?

— Әйдәгез, абый, менә шушында төшик тә беренче троллейбуска утырырбыз,— диде кыз, йомшак тавыш белән.

— Рәхмәт, кызым, минем өчен вакыт әрәм итеп йөрмәсәгез дә ярар ие...

— Минем бүген ял көне,— диде кыз.— Шәһәрне бер әйләнәп кайтыйм дип чыккан идем. Юксынуларымны таратып йөрүем.

— Ә-ә... Кемне юксынасың?

— Якын кешемне югалттым.

— Ә-ә...

Алар, троллейбуска утырып өч тукталыш узгач, урамга чыктылар.

— Абый! Менә шушыннан менеп, Кремль манарасы астыннан эчкә узарсыз.

— Рәхмәт, кызым. Аңладым. Ни генә бирим икән соң үзеңә?

— Юк, абый, миңа берни дә кирәкми, борчылмагыз.

— Алайса, игелек күр, кызым. Бәхетле бул, яме...

Җиһангир Кремль тавыннан югарыга атлады. Аякларының җегаре бетте, сулышы капты. Хәл алырга тукталды. Китеп барган кызның исемен сорамавына үкенеп куйды. Аның зиһененә соңыннан гына барып ирешкән «юксынып йөрим» дигән сүзләрен хәтерләде. Нигә икән? Бәлки, ул минем малайның сөйгән кызыдыр? Кем белә бит аны...

Җиһангир, шома чер ташларга таягын төртә-төртә, азаплык белән генә күтәрелде. Аяклары «богауланган» Җәлил яныннан узып, Кремль ишегалдына барып керде. Ике катлы бик озын бинаның беренче ишеге янында туктап, язуын укып торды. Эчкә үтте. Ике юан хатын, өстәлдән башларын күтәреп, аңа төбәлделәр.

Бүлмәдә утыручы бердәнбер ир заты, юкарган чәчен артка сыпырып куйган да, керүчегә игътибар да итмәстән, кәгазь актаруын белә.

Җиһангир, кыюсызлыгын җиңеп:

— Әй, туганнар, мин дөрес кердемме соң? — диде.

— Сезгә кем кирәк, абзый?

— Техника куркынычсызлыгы оешмасы шушыдыр бит инде?

— Әйе, ни йомыш?

— Төзелештә малаем сумалага пеште. Шуны белешмәкче идем...

— Кайчан булды ул хәл?

— Узган атнада.

— Ничек? Бездә андый хәлнең булганы юк...

...Җиһангир, саташулы уйларыннан айнып, ачыргаланып, таягын болгый-болгый кычкырды:

— Их сез, имансызлар! Минем улымны белмисез... Кайтарып бирегез Фәеземне, кайтарып бирегез!..

Ул, чигенә-чигенә, Кама ярыннан түбән тәгәрәде.

Диңгездәй җәелгән Каманың урта бер җирендә дулкыннар җемелдәшә, «чияк-чияк» килеп акчарлаклар очып йөри.

Чү! Бу ни? Ак түшләрен ялтыратып, үле балыклар ага! Ак балыклар! Тегечакта Җиһангирның күлдә биешкәндә тоткан ак балыгы сыман. Әллә учка тотып ярга җибәрелгән шул балыктан үрчеделәр микән? Алар да, Җиһангир гәүдәсе артыннан калышмаска тырышкандай, дөнья белән хушлаша... Бу хәлне күрмәскә теләп, кояш та болытлар арасына кереп югалган иде.

Яңа кабер еpактан күренә. Кабер янында тукталган Фәезнең башы аска иелгән. Аның бар гамен зират тынлыгы биләгән. Менә ул кулларын дүрт почмаклап корылган рәшәткә башларына тигезеп-тигезеп алды.

— И-и әти, әти!.. Шушындый фаҗигале язмышка дучар булмасаң соң?! — диде, башын чайкап.— Мин әби каберенә дип койган ташны үзеңә ашыктыргансың икән бит...

Фәезнең күзләреннән кайнар яшь сытылып чыкты да яңаклары буйлап тәгәрәде.

— Тыныч йокла, әти, авыр туфрагың җиңел булсын!

# Нәзифә Кәримова

## КАРУРМАННАН ЧЫККАН ЮЛЧЫЛАР

Кыйсса

I



Күрәзәчеләр, фалчылар, багучылар, йолдызларга карап язмыш сукмакларын ачып бирүчеләр белән дөнья тулды хәзер. Кемдер — тылсым көче белән, кайсысы — йөрәк сере белән, кайберәүләр — мәрткә китеп уянганнан соң, бу кодрәтләргә ия булганнар, имеш. Баштарак дәррәү кубарылып кызыксынсалар да, хәзер инде кешеләрдә әлеге шаккатулар узып бара, күңелләрдә битарафлык хөкем сөрә. Болары бүгенге көндә. Чөнки заманасы шундыйга әйләнде. Элекке ышанулар белән хәзерге ышанулар арасында аерма — әйтеп бетергесез.

Ә элегрәк, мин бала чакта — илленче елларда — нинди беркатлы, сабыйларча ышанучан иде минем авылдашлар. Өмет белән ышаныч иде халыкның ике канаты. Хәер, безнең халыкның өметсез яшәгән чагы булды микән?

Әнә шул еллардан бирле бүгенге көнгә кадәр үзем өчен серле бер истәлек булып калган вакыйгаларны бик еш искә төшерәм мин. Аның серенә һаман да төшенеп бетә алганым юк.

Ул вакытта әле авылда радио да, электр да юк. Шуңа күрә авылга читтән берәр кеше кайтса, өй тулып халык җыелып, дөнья хәлләрен сораштырып белә торган заман. Шунысын да әйтергә кирәк, ул вакытта әле авыл советының да бик абруйлы чагы. Зурларын әйтмим дә инде, бала-чагалар да берберсен «Авыл совет Хәбригә әйтәм!» — дип куркыта торган иде. Ә бит Хәбринең ягымлы һәм тәмле телле чаклары да булган. Донбасстан яшь хатын ияртеп, сул кулына кара пирчәткә киеп кайтканнан бирле, йөзен күтәреп, кешегә бер генә яхшы сүз дә әйтмәгән бу кеше турында: «Җен алыштыргандыр моны», — ди торганнар иде. Инде кайтып, ни арада авыл советы рәисе дә булып алгач, «Кара кул» дигән кушамат таксалар да, «Урындагы кеше — урындагы кеше инде, хөкүмәт шулай кушадыр», — дип, котлары алынып яшиләр иде Хәбридән.

Илленче еллар... Туклыклы, әйбәт, ипиле тормышка халыкның өмете түгәрәкләнеп килгән чаклар. Андый вакытта фал ачтыру үзе бер күңелле хәл, чөнки алдагы тормыш матур, киләчәк якты икәнен фалчылардан башка да беләбез. Тик менә шул матур киләчәктә шәхсән үзем ничек яшәрмен икән, дигән хыял ачтыра ул фалны. Әлбәттә, ул «якты киләчәк» әле һаман да җир белән күк тоташкан урында, һаман да барып җитә алганыбыз юк. Без югарыга күтәрелгән саен офыклар киңәйгән кебек тә, тик «якты киләчәк» кенә һаман алга йөгерә, куып җитеп булмый. Ә ул вакытта... Якында, бик якында иде ул якты киләчәк. Бәхет дигән кадерле нәрсә, йә берәрсенең ире, икенчеләренең улы булып, сугыш кырларында ятып калса да, өмет әле сүнмәгән, өмет әле күңелләрдә; яшәргә көч тә, бәгырьләргә ныклык та, сагышларга яктылык та өсти торган өмет иде ул...

Безнең бакча артыннан ук башланган, кул сузсаң — орынырга торган, каракучкыл күгелҗем урман. Адаштыра торган урман. Бигрәк тә кыш

---

Нәзифә КӘРИМОВА — *матбугатта чыккан хикәяләр һәм балалар өчен «Җәнлекләр кайта» дигән китап авторы. Проза әсәре белән журналда беренче тапкыр катнаша.*

көннәрендә. Хәер сорашып кайтканда, безнең авылның Гөлҗамал исемле кызы адашып, туңып үлгән ул кара урманда. Әнә шул Гөлҗамал өргәге адаштыра кешеләрне. Авылга кайтырга юл эзли торгандыр инде. Юл табуы авыр шул карурманда. Төннәр буе Гөлҗамал өргәге. Ипи сорый. Кыш көннәрендә, бигрәк тә кояш баеган вакытта серле, куркыныч, тереклек качкан дөнья чите булып күренә миңа безнең урман. Тик ниндидер сихри көч белән үзенә тарта ул мине. Әни дә миңа, кояш баеган вакытның ниндидер тылсымлы мизгел икәнлегенә басым ясап: «Кояш баеганда кычкырып көлмә, җырлама, ипләп йөре — зәхмәтле урынга басарсың, ходайдан бәхетеңне, тәүфыйгыңны сора!» — ди. Бу сүзләрне әни кояш чыккан мәлләрдә дә әйтә әйтүен, тик ул вакытта бик үк куркыныч түгел. Ә менә кояш баеганда... Караңгылык та күктән төшми кебек кыш көннәрендә, әнә шул кара урманнан күтәрелгән күгелҗем кара җәймә әкрен генә авыл өстен каплый сыман. Мин, бакча ягына чыгып, шул серле, куркыныч урманга карыйм да, ходайдан бәхетемне, тәүфыйгымны сорыйм. Урманда адашып, ач көе туңып үлгән Гөлҗамалны кызганам. Йөрәкне әллә нинди, миңа аңлашылмый торган сагыш биләп ала, елыйсы килә башлый.

Юк, бик озак моңсуланып торырга мөмкинлек бирмиләр миңа. Чөнки бу вакытта өйдә эшнең иң күп чагы. Мал карыйсы бар, су китерәсе, дәресләргә утырасы. Җитмәсә, бала карау да минем өстә.

Ә инде эшләр беткәч, кич утырачаклар. Әни оек бәйләр. Әти киез итекләргә олтан салырга утырыр. Әгәр кич утырырга күршеләр дә керсә, бик күңелле була кичләр.

Әти инде, ике унлы лампага да керосин салып, өйгә кертеп элде. Әни, тәрәзәдән төшкән сүрән яктылыкка карап лампа куыкларын чистартты да, берсенә ут алып, сыер саварга чыгып китте.

Әти малларны карап бетергән, күрәсең, мал өеннән аның кычкырып-кычкырып сарык бәрәннәрен сөйгәне ишетелә:

— Ну, тәтә соң безнең каракай! — шап-шоп, шап-шоп...

Безнең беребезне дә болай каты яратканы юк әтинең. Бозауны ярата, сарык бәрәннәрен сөя. Ә нигә безне дә шулай каты итеп яратмый икән? Бөтен яратуын бәрәннәргә бирә дә бетерә. Бишектәге сеңелемне сөйгәне бар барын:

— Ну, тәтә соң безнең кыз! — дигәне бар.

Ә мине яратырга вакыты җитми, күрәсең. Бәләкәй чакта ятраткандыр әле, дип уйлыйм. Мин хәзер олы кыз инде. Тик шулай да бер дә бала карыйсым килми. Бишек янына бәйләп куймыйча булмый инде сине, ди әни. Әле менә бүген дә — бер генә өйдә утырасым килми шул — балага имезлек чәйнәп салдым да, бишек бавын энемә тоттырып, ишегалдына чыктым.

Бакча ягына чыга торган җил капка бар безнең. Бернинди атынгыч та кирәкми бакча капкасы булганда. Аратасына басып, баганасыннан җиңелчә генә этеп җибәрәсең дә, рәхәтләнеп атынасың. Капка ачылган чакта ишегалдына карыйсың, капка ябылганда — урманга. Әти күрсә, кирәкне бирер иде инде, тик ул — мал өендә, мине күрми. Күгәнен каерып чыгарырмын дип курка, шуңа күрә атындырмый капкада. Ә капка әкрен генә ачыла да ябыла, ачыла да ябыла... Ишегалды — урман, урман — ишегалды, урман... Кинәт, урман караңгылыгыннан ниндидер карамчык аерылып чыкты. Гөлҗамал өргәге! Әнекәем! Мин, күзләремне чытырдатып йомдым да, аска таба сикердем. Әллә күземә күренде инде... Бик каты курыксам да, башымны күтәреп, урман ягына карадым. Бу карамчык торган саен үсте, әкрен генә безнең бакчага якынлашты. Уф! Кешеләр икән. Икәү. Эчемә җылы йөгерде. Кемнәр икән болар, шулай соңлатып? Шушы кышкы кичтә, әрәкле урманда нишләп йөрделәр икән? Мин яңадан җил капкага үрмәләдем. Тегеләр, тыкырык буйлап төштеләр дә, безнең урамга керделәр. Тукта әле, каршыларына чыгыйм әле, кемнәргә керерләр икән?.. Шулвакыт, мине дерт итеп сискәндереп, әнинең тавышы яңгырады:

— Һаман киртә башында! Кереп кит өйгә! Бала елый торгандыр!..

Эчемнән генә әнигә үпкәләп, теге кешеләрне уйлый-уйлый, утынлыкка таба киттем. «Бәхетле кешеләргә кунак кайта, ә миңа карап калырга да ярамый...»

Әкрен генә, утыннарның вагракларын сайлый-сайлый, кочагыма төядем дә, өйгә кертеп мич каршысына бушаттым. Бала да еламый, ут та төшмәгән. Тик бала карап арыган энем генә: «Мин дә урамга чыгам!» — дип шыңшырга тотынды.

— Үскәнем, еламасаң, мин сиңа кипкән җиләк бирәм...

— Җиләк? Бир...

— Хәзер, яме. Тәрәзәдән карап тор, мин хәзер керәм. Әнә теге лапас торыгы астындагы урман печәне арасында җиләкләр бар. Җиләкле аланнан чапкан печән анда... Көтеп тор, яме...

Бу малайдан котылуыма сөенеп, урамга йөгердем. Ләкин теге кешеләр юк иде инде урамда. Тәрәзәгә карап алдым. Тәрәзәнең катмый калган өске өлешеннән энемнең ялтырап торган маңгаен күреп алдым. Җиләк кетә инде бу малай. Ишегалдында эңгер-меңгер. Табарсың бу караңгыда җиләк! Эзләргә кирәк инде, көтеп тора бит. Кабат бала янында калдырып булмас аннары. Мин әле көндез ук торык астындагы печән кибәнендә җиләк яфраклары күргән идем. Кибәннән учмалап-учмалап печән йолкырга керештем. Шулай да, күп йолкый торгач, бер тәлгәш таптым бит! Кибеп, корышып бетсәләр дә, җиләк-җиләк инде ул. Урман исләре килеп тора! Берсен генә авызыма каптым да, калганнарын, энемә дип, бияләем эченә тыктым.

Шулвакыт урам капкасыннан ишегалдына бер көтү кеше килеп керде. Капка тавышына, чиләк күтәреп, әни дә килеп чыкты. Бер көтү дигән идем, өч кенә кеше булып чыкты болар. Берсе Сәмигулла абый. Безнең урамның хәтәр озын кушамат тагып йөрүче «Кыл өстендә калды Сәми». Ә теге икесе? Болар бит теге мин күргән, урманнан чыккан кешеләр! Шулар, шулар! Таныдым мин аларны. Кулларындагы таяклары да, аркаларындагы биштәрләре дә... Шулар...

— Исәннәрмесез!— диде Сәмигулла абый, ни өчендер як-ягына каранып.

— Әйбәт кенә әле... Әллә кунаклар белән инде син, Сәмигулла?— диде әни.

Кунаклар инде, кунаклар. Безнең авыллар түгел бит. Киемнәре әллә нинди, сәер... Ир дигәненең өстендә — солдат шинеленнән теккән пәлтә. Аркасында кычыткан капчыктан ясалган зур гына биштәр. Кулын хатынының иңбашына салган. Әстәгъфирулла! Сукыр бит бу кеше. Сукыр шул... Безгә дә йөзе белән карап тормый, янбашы белән баскан, күзләре гел икенче якка караган... Ә йөзендә, борчыдык инде, гафу итегез, дигән сыман оялчан гына елмаю. Ә хатыны... Бигрәк ябык, бигрәк бәләкәй, шундый мескен кыяфәттә. Өстендә — сырып теккән кыска бишмәт. Бишмәтенең астыннан чуар чәчәкле күлмәге күренеп тора. Ә башындагы шәлендә берничә ямавы да бар. Иңенә букча сымак кечкенә янчык аскан. Аягында — олтанлы киез итек. Ә бите апак. Шушы кышкы салкында да алсуланмаган, ичмасам. Әллә урманда туңып үлгән Гөлҗамал инде?.. Ул Гөлҗамалны гомеремдә күргәнем булмаса да, бу ак йөзле апа бик охшаган кебек иде мин җәлли торган Гөлҗамалга...

— Кунаклар дип инде, Мәүҗидә апа... Мосафирлар, ди... Бер кич булса да куныш чыгарга кирәк икән аларга... Кая алып барырга да белмәдем. Авыл советына барырга соң инде. Хәбри абыйларның өенә барырга курыктым. Айсылуттиләргә кергән идек, юк, юк, кертә алмыйм, өебез бәләкәй, дип кире борып чыгарды...

— Безнең өйдән дә бәләкәй түгел инде аларның өе,— диде әни.

Сукыр абый, йөзеннән елмаюын бер дә сүндермичә:

— Сезнең күңел киңрәк...— дип куйды.

— Мәүҗидә апа, без китап ачучылар, диләр алар. Ничек була микән ул? Синең ишеткәнең бармы?

— Һәр кешедә тары бөртегедәй әүлиялек бар дип әйтәләр, ә бу абыйда әүлиялек бар да бар,— диде әни.— Шулай булмаса, каян белсен ул минем күңелнең киң икәнен. Өйдәгез, өйгә керегез. Туңып беткәнсез бит. Ерактан киләсезме?

Тегеләр бер авыз сүз дә чыгармадылар. Берсе сукыр, әллә икенчесе саңгырау инде?

— Мәүҗидә апа,— диде Сәмигулла абый пышылдап кына,— Харис абый нәрсә дип әйтер икән?

— Анысы өчен кайгырма, Сәмигулла. Ул авыл сәвите түгел, кергән кешене куып чыгармас.

Өйгә килеп керүгә, бала бишегенә тотындым, тик теге кунаклардан күземне алмадым. Әни аларга җылы итекләр бирде, киемнәрен элеште, самавыр куеп җибәрде. Сәмигулла абый да чыгып китәргә ашыкмады. Ишек төбендәге сандык өстенә утырып, ярдәм итәргә әзер торулы кыяфәт белән, китап ачучыларны күзәтте.

Әни ишегалдында биргән соравын тагын бер мәртәбә кабатлады:

— Ерактан киләсезме? Кайсы яклар сез?

— Ерактан...

— Нишләп кичкә каршы юлга чыктыгыз соң?

— Без чыкканда көн иде. Юлда кич булды. Урманыгыз адаштыра икән. Юл таба алмый йөрдек...

Әйткән идем аны!

Кунак апа һаман да җылыга тиенми, ике кулын мичтән алмады. Ә сукыр абый, биштәрен кулыннан төшермичә, сәке йөзлегенә урнашып кымшанмый да утыра бирде.

— Шулай инде, шулай...— дип җөпләп алды әни. Кышкы юлның җәяүлесе — хәзер кич була...

— Әле бүген ерактан килмибез. Кичә күршегездәге авылда идек. Сезнең авылны мактап, юл күрсәтеп озатып җибәрделәр иртән. Гел караңгы төшкәнче монда килеп җитүебезгә бик сөендек әле. Урманы — урман, басуларда да юл юк...

— Быел кар тирән басуларда. Юкка гына «көртлекләр» димиләр инде безне. Иңкүлектә утырабыз бит. Юлны белмичә йөрсәң, адаштыра аның басуы да, урманы да. Нинди эшләр чыгарды соң сезне кышкы юлга? Кәсеп итеп йөрисезме?

— Кәсеп итеп дип инде...— дип сузды сукыр абый.— Рәхмәт төшсен, безне алып килүче егеткә әйткән идек инде. Китап ачучылар без. Фалчылар. Ишеткәнегез бардыр инде.

— Нәрсә сөйли соң сезнең китап?

— Үткәнне, киләчәкне, язмышны сөйли...

— Язмышы кеше кулында түгел инде, анысы,— диде әни.— Багучыга барма, башыңа бәла алма диләр. Куркам мин багучылардан,— диде ул көлеп.— Йә үләсең,— дип әйтерләр.

— Үлмисең...— диде фалчы сузып кына.— Әнә теге чакта, Иделдән чыкканда көймәгез капланган булса, үлә идең. Ә хәзер юк, яшисең әле!

— Әнекәйләрем! Әллә син дә бар идеңме ул көймәдә, абыкаем!— диде әни шаккатып.— Безнең авылда да бар берәү, ногыт борчагы белән фал ача. Тик мондый күрәзәне ишеткәнем юк иде әле.

Әни тиз-тиз табын әзерләргә тотынды. Сандык өстендә дөньясын онытып утырган, авызы бер карыш ачылган Сәмигулла абыйга борылып:

— Ишеттеңме, Сәмигулла? Менә күрдеңме инде нинди кешеләр килгән безнең авылга,— диде.— Бар, бу хәбәрне авылга тарат. Язмыш турында сөйли торган фалчылар килгән диген, яме? Аның хакы күпме соң? Хакын нәрсә белән аласыз?

— Акча белән. Өч тәңкә,— диде сукыр абый.

Ишек тоткасына тотынган Сәмигулла абый, ишетелер-ишетелмәс итеп кенә «өч тәңкә» дип кабатлады да, ачык ишектән кергән суык пар эчендә йомылып калгандай юкка чыкты.

Кеше керсә ни күп сөйләшә торган әни, арып килгән юлчыларны күп сүз белән интектермәде. Безнең белән дә сабыр булырга тырышып, ашатты-эчертте дә, барыбызга да урын түши башлады. Чынлап та, күңелең киң булса, урын табыла икән. Без — бала-чагалар — сәкегә тәгәрәдек. Фалчыларга урынны идәнгә җәйде әни. Ә инде безнең күп сөйләшми торган эти, бу хәбәрне урамнан ук ишетеп кайткан иде, күрәсең, әнинең ризалык көткән сораулы карашына: «Ярар, гомерлеккә килмәгәннәрдер әле»,— диде дә, сәндерәгә менеп ятты.

Икенче көнне бу хәбәрне ишеткәч, авыл беркавымга гөжләп торды. Хәбәрне таратуга Сәмигулла абый көчен җәлләмәгән, күрәсең. Каравыл өенә җыелынырга кергән фермада эшләүчеләрнең дә, пожарныйда кич утырырга җыелган ирләрнең дә, су буендагы хатын-кызларның телендә дә «фалчылар» дигән сүз булган. Ишетмәгәне ишеткән булып, ишеткәне күргән кебек итеп сөйләгән.

Кичке якта чишмә буена җыелган хатыннар тагын шул сүзне башладылар.

— Бүре Бәдәренең кодачасы килгән ди Ушмыдан, бу кешеләр алар авылында булган икән. Шул кодача сөйләп торган ди, аларның күршесенә: «Үләсең, быелдан калмыйсың!» — дип әйтеп әйткән ди...

— Әнекәем! Юк, юк, гомердә дә ачтырасым юк ул фалны! Турыдан-туры: «Үләсең!» — дигән кешегә өч тәңкә акча чыгарып тоттырырга монда! Әндри казнасы юк!

— Ышанмагыз шул Бүре Бәдәренең сүзенә, кызлар. Ногыт борчагына фал ачтыручылар бетәр дип курка ул. Бер генә тамчы да дөрес күрсәтми борчагы. Ачтырып караганым бар инде. Килгән саен: «Быелдан калмыйсың, чыгасың кияүгә!» — дип җибәргән була. Йә, әйтегез әле, кая соң ул кияү?

— Мич алдында күмер ашый сиңа дигән кияү...

— Ашасын иде әле. Миңа насыйп була дисәләр, үскәнен көтәргә дә риза. Ә Бәдәр сибә генә борчагын...

— Әй, сөйләп тормагыз әле шуның сүзен. Уйлап чыгарырга булса аңар куш инде. Җиләк пешә башладымы — урманда качкыннар да гел аңар гына очрый. Чикләвек җитлегә башласа — котырган бүре белән кабан дуңгызы да гел аңар гына ташлана. Килен булып сезнең авылга килгәннән бирле шаккатып йөрим мин. Бигрәк беркатлылар сезнең авыллар. Шуның сүзенә ышанып җиләксез дә, чикләвексез дә каласыз. Җәй җиттеме — урманга кермәслек итеп халыкны куркыта да куя. Безнең авыллар булса, күптән инде акылга

утыртырлар иде. Ә инде кыш буе — кипкән җиләкме, чикләвекме — ул гына сата.

— Кызлар, ишеттегезме, Өстерелек Абдул белән йөри, дип әйтәләр аны.

— Йөрер шул, йөрмичә, урманда икәве генә калгач!

— Икәү генә дигәннән, бу китап ачучылар да икәү, ди. Ирле-хатынлы.

— Китапны ире генә ача икән, ә хатыны иптәшкә йөри ди.

— И-и кызлар! Икәү вакыт — бәхетле вакыт инде ул. Сукыр булса да, ир — ир инде ул. Аның бөтен җире дә сукыр булмый. Көлмәгез, кызлар, көлмәгез. Их, Ризагым исән булса! Белмим, кызлар, кемгә — нәрсә, мин үзем үткән гомерем турында сорар идем. Алдагысы кирәк түгел, язмышны да алла кулында... Ризагым исән чакта матур яшәгәнбез икән, кадерләрен генә белмәгәнмен. Шундый өметле күренгән иде тормыш... Ул бала-чагаларны ничек аякка бастырырмын...

— И-и, Фәгыйлә! Өметең сүндемени шулай ук? Ирнең үгие булмый аның. Хатын-кызның унике чырасы була, берсе сүнсә — икенчесе яна, диләр. Шушы яшеңнән киләчәгем кирәк түгел, дип торасың. Утыз улың булганчы...

— Әй, сөйләп торма әле, Фаягөл! Миңа түгел, әнә яшь-яшь Нәсимәгә дә юк ул кияү. Кырды бит сугыш өрлектәй ирләрне. Яралары булмаса, әллә минем Ризагым исән булмас иде дисеңме?

— Алай димә син, язган булса...

— Булмас, булмас... Ымсынмыйм да. Аннан соң, тәкәрлек кукәе шикелле кендеккә кадәр сипкелле бу тәнемне күрсәтәмме соң башка иргә!

— Кара әле, үткәнеңне тагын бер ишетер өчен акчаңны җәлләмәс идеңме?

— Тамчы да җәлләмәс идем, акчасы юк әле аның!

— Мәүҗидә апаларда ди ул фалчылар. Менәбезме бүген кич белән?

— Менмичә, менәбез! Үзебезнекен белмәсәк тә, кешенекен ишетербез.

Хатыннар, берсе артыннан берсе тезелешеп, су буеннан ярга менә башладылар.

— Кызлар, карагыз әле теге якка,— диде Фаягөл.— Күрдегезме?

Югары очтан, елганың теге ягыннан, чиләк-көянтә аскан Хәбри хатыны су буена төшеп бара иде.

— Нигә шулай кеше сөймәс микән бу хатын?— диде Фаягөл.

— Иреннән курка торгандыр,— диде Фәгыйлә.— Хәбри җанын ала бит аның. Ничә ел бит инде авылда, күршеләренә дә керми, диләр аны.

— Мескен,— диде Нәсимә.— Ни — туганы, ни — тумачасы.

— Аның каравы — ире Хәбри,— диде Фаягөл.

— Ире-е... «Хәбри хатыны» булмаган хатын сирәктер безнең авылда,— диде Нәсимә.

— Әллә синең дә капканы кактымы?

— Хәзер, сезгә барысын да әйт, барысын сөйлә,— дип сүзне уенга борды Нәсимә. Тик шунда ук җитди тавыш белән:— Кагып карасын!— диде.— Хатынын җәллим мин аның. Нишләп тора диген? Баласы-чагасы юк... Дүрт ягы кыйбла.

— Яратып тора. Ач-ялангач түгел,— диде Фаягөл.

— Яраткан кеше алай яшәми ул,— диде Фәгыйлә.— Донбасс тикле җирдән нишләп ияреп кайткан диген син аны? Хәзер, бик китәсе килсә дә, милиция белән кайтартам мин сине, дип әйтеп әйтә ди Хәбри. Китеп кая барсын... Бөтен җирдә дә бер кояш.

Хатыннарның чиләкләрендәге суларының өсләре чиерап, боз булып капланып бара иде инде. Әле чатка барып җиткәч тә аерылып китәр кебек түгелләр иде. Тик шулвакыт, Кәнсә урамыннан бураннар уйнатып килгән, ак айгыр җигелгән кошевканы күргәч, төрле якка сибелделәр. Кошевка сыздыртып үтеп китте, ә анда толыпка төренеп кырын яткан кеше — авыл Советы рәисе, Кара кул Хәбри иде.

## 2

Фалчылар турында һәр өйдә сөйләштеләр. Бөтенесе дә кичне көтте. Югыйсә, читтән килеп, кәсеп итеп йөрүчеләр авыл өчен бер дә ят нәрсә түгел инде. Безнең авылда самавыр төзәтүчеләр дә, кием тегүчеләр дә юк. Бу эшләрнең барысын да әнә шулай, фалчылар кебек, читтән килгән кешеләр эшләп китә. Яз җиттеме, ике көннең берендә, тәрәзә артыннан көйләп әйтелгән моңлы тавыш ишетелә:

— Самавыр төзәтергә юкмы? Самавыр!

Авыл халкы бу тавышка күнеккән инде. Бары тик бала-чагалар гына, мондый кешеләрдән кызык табып, аларга ияреп, әче тавыш белән самавыр төзәтүчеләргә «ярдәмгә» чыгалар.

— Самавыр төзәтергә юкмы? Комган!

Әнә шулай кычкырып, арбаларын тартышып, авыл башына чаклы озаталар ул кешеләрне. Кычкыруга оста без, башкасын булдыра алмасак та. Ә гомумән алганда, безнең авыл кешеләре яхшы күңелле, эчкерсез, беркатлылар. Үзләренең беркатлылыкларына сөенеп, тәм табып яшиләр. Хәйләсезләр. Шуңа күрә, кәсепләре дә юк аларның. Кәсепле кешегә кирәк ул хәйлә. Ә боларның, кәсебе булмагач, нәфесе дә юк. Безнең авылның иң зур керем чыганагы — бәрәңге. Шул бәрәңгесен озатып налогын да түли, киемен дә ала, тормышын да алып бара. Безнең авылларның беркатлылыгын күрсәткән бер хәлне сөйләп китсәм, безнең кем икәнлегебезгә тәмам ышанырсыз.

Әнә шул бәрәңге сатып көн күргән вакытларда, күршебез Касыйм абыйның мактанып сөйләшкәнен ишеткәнем бар.

— Кенәгеш базарда Иске Комазаннарны күрдем әле. Билләһи, үзләре танып, килеп күрештеләр.

— Безнең кодалар түгелдер бит? — диде, капка төбенә җыелышкан ирләрнең берсе.

— Юк ла... Белгән кешеләрем түгел... Менәтерәк, «Абый, син Арташтанмы әллә?» — дигәч, шаккаттым. Нәрсә, мин әйтәм, маңгайга язылганмы әллә, фәлән-фәсмәтән!

— «Һәй, сезне танымаска, Көртлекләрне!» ди бит теге, билләһи! Башта, мине таныдылар дип сөенгән идем, «Көртлекләр» дигәч, ачу чыкты, малай! Үземнең субсунный кушаматны да әйтсә, билләһи дип әйтәм, базар уртасы дип тору юк иде, тозлап-борычлап яңак тамырына ямау салам дип, менә шушы йодырыкны чытырдатып йомарлаган идем, эш алайга ук барып җитмәде, авызы ерык тегенең. Көлеп торган кешегә ничек сосмак кирәк. Ярый, мин әйтәм, күргәнең-күрмәгәнең шул булсын, таныгансың икән, таны, әйдә. «Һәй, сезне танымаска! — ди бу һаман. — Мин бит синең үзеңнән түгел, атың белән арбаңнан таныйм! Дилбегәңдә ничә төен? Атыңның аркасына ыңгырчак суккан!.. Сездә генә бит ул төенле дилбегә. Атыңның дагасы да юктыр әле... Әйтәм бит, арба тәгәрмәчләреңдә дә агач чәкүшкә! Май чүлмәгенең тышыннан билгеле диләрме әле, әллә кайдан күренеп тора Арташтан икәнең!» — ди.

— Каян килгән эз танучы малай, мин әйтәм. Әйе шул, безнең авыллар югала торган түгел! Сезгә барып арбага чәкүшкә сораган юк әле. Ә дилбегәдәге төеннәрне Гөлсирә апаң бәйләп җибәрде, мин әйтәм; аласы әйберләр төене ул, онытмаска. «Ярар, — ди бу, — шаяртып кына әйтәм... Шул төен чаклы әйбер бөтен кибетләрендә дә юк бит ул. Серкәң бер дә су күтәрми икән. Арташларны бик ачык күңелле кешеләр дип ишеткән идем», — ди. Шуннан дуслашып киттек.

— Дуслашып? Ул сине мыскыл итеп торсын, ә син, дуслаштык дип сөенеп торасың, сабый!

— Минме? Нишләп мыскыл итсен ул мине?! Дилбегә — синеке! Әле Гөлсирә апаңа сылтаганга рәхмәт әйт. Бу — бер! Ат — колхозныкы. Бу — ике. Арба — Шәйдинеке! Бу — өч! Арбадагы бәрәңге үземнеке иде, анысын күз ачып йомган арада, талашып алып бетерделәр!

— Очсыз җибәрдеңме әллә?

— Очсыз дип инде... Бәрәңге бәһасе... Шәһәр хатыннары белән сатулашып торырга... — Касыйм абый көлеп җибәрде. — Кызык халык бит шәһәр хатыннары, каһәр! Кайсы мыегымны мактый, кайсы чиләгемне яратты, аның бәрәңгесен әйтмим дә инде. Ә менә берсе... — Касыйм абый пышылдауга күчте. — Гөлсирә апаң чаклы ике булыр, ипидер менә, ул ирennәр, мин сиңа әйтим, кып-кызыл, ул йөрешләр! Бар бит шәһәр җирендә хатыннар! Анысының өенә үк илтеп бирдем. Карап торуга, лашман бияседәй, ә үзе боргаланган була: бик авыр булды бит әле, бәлки ярдәм итәрсез тол хатынга, дигән була.

— Потлы чиләкләр белән җибәрдеңме әллә?

— Потлы инде, потлы. Бәрәңге бит ул, җиләк түгел. Ашасыннар рәхәтләнеп. Тегене әйтәм әле, башка вакыт килгәндә атыңны үземә куеп торырсың дип, каш сикертеп, бил уйнатып калды озатканда. Кара әле, монысын сиңа гына сөйлим, дилбегә биреп торганың өчен, кешегә тишә күрмә, яме. Базарга бара-нитә калсаң, әдрисен сиңа да бирермен.

Әнә шундый безнең авыллар. Барысы булмаса да, күбесе шундый. Фал ачучылар бик белеп килгән безнең авылга.

...Кич белән, өй тулып халык җыелса да, берсе дә: «Менә, мә өч тәңкәмне, кара әле китабыңны, нәрсә дип әйтә микән?» — диярgә базмады. Бик тыйнак кына, шаулашмый гына, авыл хәлләрен сөйләшеп утыра башладылар.

Кешеләр җыелгач, фалчы абый янында гына яткан капчыгын капшарга тотынды. Ә фалчының ап-ак йөзле хатыны да үзенә эш тапты: бертуктаусыз бала бишеген тирбәтте. Әллә кайчан йоклаган баланы тирбәтә дә тирбәтә.

Безнең өйгә килеп кергәннән бирле «рәхмәт сезгә»дән башка бер генә сүзе дә ишетелмәде әле аның. Әле әнинең сөйләшеп утырырга вакыты гына юк, безнең әни телсезне дә сөйләштерә ул. Аулакта гына калсыннар әле. Исемен дә белгәнем юк әле. Үзе әйтми, ә мин сорарга да оялам. Эчемнән генә Гөлҗамал дип исем бирдем инде мин аңар.

Фалчы абый, капчыгын чиште дә, берсе артыннан берсен чыгарып, өстәл өстенә өч китап тезеп салды. Башын югары күтәребрәк, ярым йомык күзен түшәмгә төрәп, бар серләре дә эчендә микән диган шикелле, китап битләрен бик җентекләп капшарга тотынды. Мин, арттан гына килеп, үрелеп, теге китапка карадым. Әнекәем! Бер генә хәреф тә юк аның эчендә! Төртке дә төртке! Менә нинди була икән ул фал китабы...

Сукыр фалчы кинәт елмаеп җибәрде, тамагын кырып куйды да, басынкы тавыш белән:

— Әһ-һем, мин сезнең авылга бер генә көнгә кердем, иртәгә китәм...— диде.

Җыелышкан хатыннар, аның ни әйтергә теләгәнен тиз аңлап, берсен-берсе кыстарга тотындылар.

— Әнекәем, бармагы белән укый...— дип пышылдады Фаягөл, шәл бәйләвеннән туктап.

Барысыннан да алдан килеп сандык өстеннән урын алган Сәмигулла, бу хикмәтне табуда үзенең дә өлеше барлыкны нык сиздереп, мич казнасына арка терәп утырган хатыннарга тантаналы караш ташлады.

— Ягез инде, бер батыр да юкмыни, яшьләр! Әйдәгез инде, безнең түй узган, түн тузган,— диде җеп катып утыручы Миңлеҗамал апа.

— Әнә, Сәми чүт тыелып утыра, өстерәгез әле шуны уртага!— диде, ак җепле кәтүктән челтәр бәйләп утыручы Нәсимә.— Кайчан өйләнәсен әйтер үзенә. Йөри шунда йөрәк яндырып!.

— Әйдә, әйдә, Сәмигулла! Гомер буе «Кыл өстендә калды Сәми» булырга димәгән, ал әле беренчелекне!

Сәмигулланың бу озын кушаматы — үзе туганчы ук нәселе табып куйган кушамат түгел, үзе дөньяга килгәч, аның үзенә генә атап тагылган кушамат. Бу хәл болай була: Сәмигулла яңа туып, берничә айлык булгач, әбисе белән бабасы күрше авылга кунакка китәләр. Үзләре генә калган әтисе белән әнисе, аулак өй ясап, өй тутырып яшьтәшләрен җыялар. Китә уен, китә җыр. Кысып биләүгә бәйләнгән баланы мендәргә салалар да, сәке түренә куялар. Уен-көлкеләрдән соң, яшь-җилкенчәкләрнең күбесе аулак өйдә кунарга кала. Кайсыдыр, баланы күрмичә мендәрен тартып алганмы, ничек булгандыр инде — бала тәгәрәп китә дә, сәке йөзлегенә килеп җитеп, идәнгә төште дигәндә генә, әтисе эләктереп ала моны.

— Ну, егетләр, кыл өстендә калды Сәми!— дип кычкыра ул, сабыен түшенә кысып.

Әнә шулай әтисенең сүзләре кушамат булып ябыша да кала Сәмигуллага. Шул вакытта «кыл өстендә калган» Сәмигулла — һаман да кыл өстендә. Шуңа күрә бар нәрсәдән дә куркып өйрәнгән ул. Гомер буе нахак сүз, нахак бәла белән көрәшә Сәмигулла. Каравыл өендә мич юшкәсе югалгач та, гаепләне бик төпченеп эзләп тормадылар, Сәмигуллага сылтадылар да куйдылар. Авыл советы җыелышында бу хәлне тикшергәннән соң, Кара кул Хәбри аның үн хезмәт көнен кисәргә дигән карар чыгаргач, авыл халкы:

— Кыл өстендә калды Сәми!— диде.— Ярый әле, заманасы икенчерәк, авыл советының зәһәре кимегән заман! Теге елларда булса, болай гына калмас иде. Кыл өстендә калса да, бәхете бар икән!

— Тентү белән керсәләр табалар иде инде...— диде җыелыштан чыгып килүчеләрнең берсе.

— Юк миндә ул нәрсә, юк!— диде Сәмигулла, ачынып.

— Нишләп булмасын! Ә мичегездә нәрсә, төннекмени?

— Анысы әллә кайчангы бит аның, үзебезнеке!

— Кәҗүнни нәрсәгә катнашкач, кубарып та чыгарлар, шаяртма!

Нәрсә дисен Сәмигулла, бәхете шундый булгач. «Их!» диде дә йотты. Ун хезмәт көне нәрсә ул бер уйлаганда? Ике йөз граммнан өләшсәләр дә — ике кило арыш. Шул да булдымы югалту? Тик андамыни эш! Гарьлек бит, оят, кызлар каршында, их!

## 3

Фәгыйлә апа чабуыннан тарта торгач, Сәмигулла урыныннан торды, салкын суга башы белән чумарга әзерләнгән кешедәй «Ух!» дип куйды.

— Әй, булмаса булган икән!— диде ул, кулындагы бүреген сандык өстенә бәреп.— Абзый, менә сиңа өчлек, ышанмасаң әнә, җиңәчәйдән сора.— Бала

тирбәтеп утырган фалчының хатынын сискәндереп, өчлекне аңар да күрсәтте.— Кулым җиңел минем. Калганын син әйт!

— Утыр!— диде фалчы.

Сәмигулла, тезелешеп утырган «тамашачыларга» каш сикертеп алды да, фалчы янындагы букәнгә чүмекте.

— Исемеңнең баш хәрефе?— дип сорады фалчы.

Аннары, өч тәңкәне учына кысты да, бармаклары белән китабының битләрен капшарга керешге. Акчалы кулы белән укыды китабын. Күрәсезме, сезнең акча йөртә минем бармакларны, дип әйтүе микән бу аның, әллә акчасыз ачылмый микән аның фалы?

— Бер дә сүзең үтми икән,— диде фалчы.— Ышандыра алмыйсың кешеләрне. Шуңа күрә, үзеңне дә нахактан саклый алмыйсың... Күптән түгел сине тимер әйберсе урлауда гаепләгәннәр... Тик синең эшең түгел бу, бередә башка кул уйнаган...

Бу сүзләрдән исе киткән Сәмигулла, тирләп чыккан битен сыпырып куйды да, фалчының авызына керердәй булып, алга иелде. Сукыр абый әкрен генә китабының тагын бер битен ачты... Тик Сәмигулланың алга таба әйткәннәрне көтәргә тамчы да түземлеге калмаган иде, күрәсең, ул урыныннан сикереп торды:

— Менә шулай, авылдашлар! Ишеттегезме инде?! Еландай телләремне чыгарып ялындым бит: «Мин түгел!»— дидем. Ышанмадылар. Ун хезмәт көнемне кистеләр шул гайбәт өчен! Менә, минем сүзгә ышанмасагыз, гөнаһсыз сукыр әйтте дә бирде!

Фалчыга «сукыр» диган сүзне күп ишетергә туры килгәндер, күрәсең, йөзен дә бозмады, каршы да әйтмәде, бары тик сукыр күзләре генә тартышып куйды.

— Булды, абзый!— диде Сәмигулла.—Шунысы иде главный. Калганы— пүчтәк. Хөснүрия апага әйтерсең күбрәк итеп. Калган акчасы хәердән булыр. Тоталар да: «Сәми каравыл өеннән юшкә урлаган»,— диләр. Ишеттегезме инде: ур-ла-ма-ган! Сүз үтми минем, анысы да дөрес.

— Урыныңны бушат,— диде фалчы.

— Утыр, Хөснүрия апа, рингитка синең чират!— диде Сәмигулла «Минем яхшылыгымны белеп бетермисез әле сез», дигәндәй, өй тулы халыкны тагын бер мәртәбә күздән кичерде. Сандык өстендәге бүреген табып башына киде дә, ат тоткандай сөенеп, өйдән чыгып китте. Ишегалдында да фалчыга килүчеләр җыелган иде. Сәмигулла чират көтеп торучы яшьтиләре янына килде.

— Кая, көйрәтик әле,—диде ул, кулын сузып.— Кайсыгызда бар? Ишеттегезме инде?

— Ишеттек, ишеттек,— дип көлештеләр тегеләр.— Синең шул хәтле кычкыруың Хәбригә дә ишетелгәндер ул.

— Ишетелсен!— диде Сәмигулла.—Җитәр инде, кот алынып күпме яшәргә була. Егетләр, әйтеп калыгыз яхшы чакта, өч тәңкәмне жәлләмим, валлаһи, яңадан кереп сорыйм— барыбер табам кемдә икәнен!

Әле бу минутка чаклы бу юшкәне эзләү, табу аның башына да килмәгән иде. Ә хәзер табасы килеп китте. Кемдер алган бит инде аны...

Ул, нидер исенә төшкәндәй, кызу атлап, каравыл өенә таба китте. Юл уңаенда пожарныйга да кереп чыкты. Андагы кич утыручылар авылның соңгы хәбәрләрен сөйлиләр иде. Ә менә Сәмигулланың соңгы хәбәре егып салды кич утыручыларны. Ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр. Шулай да кайберәүләр, төпчекләренә төкереп, урыннарыннан кузгалды.

Ә Сәмигулла, фалчы әйткән сүзләрне тагын бер мәртәбә күңеленнән үткәреп, авылның буш урамы буйлап фермалар ягына китеп барды. Нәрсәләр диде соң әле аңар фалчы? «Юшкәне син урламагансың»,— диде... Тагын нәрсә диде соң? Башка бер сүз дә әйтмәгән бит бу! Ә язмыш? Ә алдагы көн? Их!

Сәмигулла шушы уйлар белән каравыл өенә килеп җитте. Анда ут яна: димәк, эчендә кем булса да бар. Тик Сәмигулланың шатлыгы алай ук түгел иде инде. Хәзер аның бу хәбәргә ачуы да килеп китте. Шул ачу белән каравыл өенең ишек тоткасына тотынды да, ишекне төбенә кадәр каерып ачып, эчкә атлады. Сәмигулла бер мәлгә аптырап калды. Әле яңа гына фалчыга керергә дип, үз чиратын көтеп калган Тимершаны монда күрермен дип уйламаган да иде. Шул арада ничек өлгергән дә, кыш көнендә кызыл балчыгын каян алган диген! Тимерша, теге «Сәми урлаган» юшкәне бик шәплап кенә иске урынына урнаштырып маташа иде.

— Иплисеңме?— диде Сәмигулла, беркавым өнсез торганнан соң.

Тимерша, кеше килеп керер дип көтмәгән иде, күрәсең, каушавын сиздертмәскә тырышып, баскан урындыгыннан сикереп төште дә, мыскыллы оятсыз карашын Сәмигуллага текәп, балчыклы кулын мич йөзлегенә ышкый башлады.

— Күпне күрмә, яме!— диде ул янап.

— Ишшу куркытып торган була, хәчтерүш!— диде Сәмигулла.— Мышнавыңны бел! Мин алмаганны әйткәч, кем алганын да әйтеп бирер дип курыктыңмы? «Каракның бүреге яна-а!» — дип утырган була бит әле җыелышта... Синең башны пешергән ул бүрек!

— Әллә мин алдым дип әйткәнне көткән идеңме?

— Синнән кем яхшылык көтсен! Ярый инде, җиде ят килеп йөземне акләды. Әле дус, яшьти дип йөргән була. Шушы юшкә аркасында алдагы тормышымны да сорарга оныттым. Менә хәзер баш ват инде: Сәҗидәгә өйләнергәме, әллә Вагизәгәме? Шушы кәҗүнни юшкә аркасында яшь тормышым чәлпәрәмә килсә килер икән...

— Тиле! Әллә шул сукырның сүзенә карап өйләнер идеңме?

— Нишләп өйләнмәскә?! Аннан да дөрес сүз әйтүчене очратканым юк әле минем. Бар, ышанмасаң үзең сора. Сатып алгандай булдым мин бу юшкәне. Өч таңкә бир дә, юшкә сүзе чыгуга, җан фәрманга чыгып чап, имеш! Бар, бар, бар, бәлки, сиңа да акыл өйрәтер.

— Үз акылым үземә бик җиткән минем. Әле сиңа ачкан фал да миңа китереп сукты. Синең кебек шыр тиле түгел лә мин, халык арасына чыгып: «Тагы ниләр урлаганымны ачып салыгыз әле!» — диярга. Барыбыз да колхозда яшибез.

— Анда барып сорамасаң да бәләләр синең кем икәнлегеңне. Синең ише ике катлылар түгел, минем ише беркатлылар кешесе ул фал ачучы.

— Беркатлы...— диде Тимерша, мыскыллы көлеп.— Җитәкләп, өйдән өйгә фатир эзләшеп йөргәч — юшкә нәрсә, бәлки, өйләндереп тә китәр иде...

— Нәрсә?!— Сәмигулла Тимершаның якасына килеп ябышты.

— Шаяртып кына әйттем бит,— диде Тимерша.

— Бәйләнеп торасы килми,— диде Сәмигулла.— Утлы табага бастырырга була иде инде сине...

Ул, шулай диде дә, каравыл өеннән чыгып китте.

## 4

Сәмигулла чыгып киткәннән соң, фалчыга килүчеләр бераз көлеп, шаулашып алдылар. Кайберәүләр тел шартлатып, башын чайкап куйды, «ишеттеңме?» дигәндәй, бер-берсенә мәгънәле караш ташлады. Күпләрдә фал ачтыру нияте ныгыса да, бияләй эчендәге өчлекләрен тирләгән учларына ныграк кысып, тагын бер-ике кешегә әйткәнче түзәргә булдылар. Кайберәүләр кесә төпләренә төшеп җитә алмый азапланды, кесә төбенә төшеп җитсә, ничек тә бер өчлекне тартып чыгарыр кебек иде кыяфәтләре. Ә инде сәкегә аркаларын терәп, идәнгә аякларын сузып утырган ике карчык — Шәрифелтти белән Хәбибҗамалтти, оек кунычларын капшап куйдылар.

Фаягөл йомгагына карап алды. «Җепне азрак алганмын, өйдәгесен дә калдырмаган булсам, бу шәлнең уртасы бүген бәйләнеп бетәсе булган икән»,— дип уйлады ул. Аның янында утырган Миңлеҗамал, башын артка ташлап, авызын ачып, йоклап китеп бара иде инде. Бу шау-шуга кинәт уянып китте дә, миннән көләләр, ахрысы, дип, каударланып, җилкәсенә шуып төшкән яулыгын рәтләргә кереште. Алдында яткан бәйләме — идәндә, ә йомгагы, әллә кайларга тәгәрәп, күптән инде песи баласына уенчык булган иде. Миңлеҗамал тиз генә бәйләмен күтәреп алды да, йокы аралаш ялгышып, бишинәнең күзәнәкләрен тартып чыгарып, шуны җыярга тотынды. Ул монда бүген кул эше белән генә килмәгән, ире Миңлебайны да иярткән иде. Өйалдыннан анысының бертуктаусыз турыга кычкырып көлгәне ишетелеп тора иде. Миңле кушымчасы тагылган кешеләр күп безнең авылда. Миңлегөлләр, Миңлебикәләр генә дә әллә ничә. Хәтта бер Миңлерафаел да бар. Ә менә Миңлебайлар икәү. Берсе Гатин Миңлебай; ә икенчесе Миңлеҗамалның ире Миңлебай. Күп чакта аларны «миңсез» генә — берсе Гатин Бай дип, икенчесен Шыр Бае дип йөртәләр.

Шыр Баена рәхәт! Шыр — теләсә кайсы яктан шыр. Шыр ялангач, шыр ялганчы, шыр ялкау, шыр шаян! Бәлки, «шыр шаян» дип сөйләми дә торганнардыр, тик, «шыр» сүзен ишетүгә, безнең авыллар көлә башлыйлар. Коймасыз-капкасыз булса да — өе бар, өй эче тулы бала-чагасы бар. Кыш көннәрендә дә, җәй көннәрендә дә бала-чагалары шыр ялангач. Тик ник берсенең чирләп караганы булсын! Йоп-йомыры, төптән юан чыккан, берсеннән-берсе таза, томырылып торган балалар! Балалары гына әтиләре кебек шыр ачык түгел, йомыкыйлар. Ә инде Миңлебайның хатыны Миңлеҗамал — анысы көн буе биләмдә. Кул эшен тоткан була да, бөтен очны әйләнеп чыкмыйча, өенә кайтып керми. Ә нәрсә? Кая ашыгырга? Саварга сыеры юк, пешерергә — ризыгы, дигәндәй.

Миңлебай хатыны Миндеҗамалны күрше авылдан алып кайткан. Миңлеҗамалның кияүгә чыкканын ишеткән авылдашлары: «Әстәгъфирулла! Шуңа да кияү чыгар икән!» — дип шаккатканнар. Ә инде Миңлебай өйләнгәнне белеп, безнең авыллар: «Бу Миңлеҗамал Миңлебайга нәрсәләр генә уйлап чыкты икән»? — дип, исләре киткән. Тик, тора-бара, Миңлеҗамалның авылдашлары да, безнекеләр дә аңлаганнар мәхәббәтнең нәрсә икәнен. Чөнки болардан да пар килгән ир белән хатын авылда юк. Ул дуслык, ул татулык. «Ник моны эшләмисең?» юк, «Кайда йөрисең?» юк. Менә бәхетле ир дә, бәхетле хатын. Бәхетнең шундые да була икән аның. Унлап бала үстерделәр. Балалары да менә дигән. Халык аларның гайбәтен сөйләми. Нәрсәсе гайбәт булсын аларның? Кешегә зыяннары, үзләренә файдалары юк. Гыйбрәт инде, бер дә гайбәт түгел. Үзеннән-үзе көлә Миңлебай. «Мин — туып килүче пролетариат. Шуңа күрә, бернәрсәм дә юк минем. Бер нәрсә дә кирәк түгел миңа! Киттем бардым шәһәргә — бер күрешеп сөйләшергә зар-интизар булып торырсыз әле!» — ди.

Әле бүген Миңлеҗамал да, Миңлебай да ни күрәчәкләрен белмиләр. Үз бәхетләренә нык ышанган алар, шуңа күрә кеше фалын тыңлыйлар.

Хөснүрия, Сәмигулла утырырга кушып чыгып киткәннән соң, утырган урыныннан торды да, «Тәвәккәлләсәм ничек булыр икән», дигән шикелле, авылдашларыннан күз карашы белән теләктәшлек көтте.

— Җә инде, ялындырма... Утыр дигәндә инде...— диештеләр хатыннар.— Безнең өчен шул тикле җирдән килгән кешене тилмертмә. Монда син генә түгел, әйдә, әйдә...

Шундый уңайсыз булып китте Хөснүриягә. Эш анда гына торса, ул риза. Шул тикле халыкны көттерәме соң? Юк, бер минут та көттермәячәк.

Хөснүриянең өстендә — кара якалы, билен кысып торган, күз явын алырлык ачык зәңгәр төстәге кышкы пәлтә. Үз гомерендә беренче тапкыр киде ул аны бүген. Ташкенттагы апасы җибәргән иде. Тол да калгач, бердәнбер баласы да үлгәч, Ташкенттагы апасы игътибарлырак була башлады аңар. Сырып юрганнар да җибәргәләде. Бик мамыклы як икән ул Ташкент ягы. Мондый пәлтәне бәрәңге сатып кына ала алмас иде Хөснүрия. Аннан соң, пәлтә киеп кая барсын? Әле монысы да күпме ятты инде сандык эчендә. Матур пәлтә, әйтә торган да түгел. Мондый кием укытучыларда да юк әле. Башында — кәҗә мамыгыннан бәйләнгән, күпереп торган шәл. Мамыклы кәҗәсе бар Хөснүриянең, шәлне үзе бәйли. Дулкынланудан битләр кызарып чыккан.

Хөснүриянең болай, күз камаштырырлык итеп киенүенә фалчылар гына сәбәпче түгел бит! Юк! Мондагы сәбәпләрне әйтә китсәң! Кырыкка да җитмәгән, бөтен күзәнәгеннән бу тикле көчне, бу тикле назны кемнең иңнәренә, йөрәк ялкынын кемнең йөрәгенә түгеп арыныйм икән дип, иңгерәп йөргән чаклары Хөснүриянең. Болай булганы юк иде әле. Нигәдер соңгы айларда йөрәге башына юл куймый башлады. Ирләр назына мохтаҗ күңеленең нуры күзләренә бәреп чыкты. Башының иләс-миләс килгән чагы иде шул бу көннәр. Күңел бит ул, каһәр! Өмет белән күпме яшәтергә була аны. Кыш уртасы дип тә тормый икән, йөрәктә кан кайнаса, ашкына күңел! Шуның өчен дә җанына урын таба алмый йөдәде Хөснүрия. Нәкъ менә шушы көннәрдә Югары оч Миннисаның кече кызы кайтып төште авылга. Ул үзе генә кайтмаган, сабан туйларына чаклы озак дип, яңа кияуен күрсәтергә алып кайткан икән. Яңа кияүнең уңганлыгы, осталыгы, нәрсә кирәк шуны төзәтә белүе, сәгатьләрне өр-яңа итеп бирә икән, дигән сүзләр авылга бик тиз таралды. Нинди генә осталар килсә дә, сәгать төзәтүчеләрнең килгәне юк иде әле авылга. Хөснүриянең, үзе әйтмешли, «хан заманыннан» калган, җиз герле, җиз телле, бик матур итеп суга торган сәгате, ничә ел инде, моңаеп эленеп тора иде стенада. Шуны гына карап китмәс микән дип, чакырган иде яңа кияүне Хөснүрия. Әнә шул сәгатьтән башланды инде барысы да. Кем уйлаган ул кияүнең шундый матур, шундый ыспай, шундый тәвәккәл буласын. Кәтебрәк торса да, өенә ир кеше килеп кергәч, Хөснүрия югалды да калды. Кая барып бәрелергә белмәде, әле кунакка урын күрсәтте, әле самавырына барып тотынды. Шул кызулык белән сәгатьне дә алып бирмәкче иде Хөснүрия, тик, тукта әле, кая ашыгам, ишектән кермәс борын кешегә эш тоттыралармыни, дип, өенең уртасында басты да калды. Калтыранган куллары белән яулыгын рәтләде, алъяпкычын сыпырып куйды. Ә тегесе ник бер сүз әйтсен, әллә исәнләшмәде дә инде. Хөснүриянең каушавыннан кызык табып, көлемсерәп, пәлтә сәдәфләрен чишеп җибәрде. Күтәрелеп карарга бик оялса да, күзләре очраштылар шул. Карамыйча түзә алмады Хөснүрия. Әнә шул өтеп алган караштан әллә нишләде дә китте башы! Йөрәге дерт итеп урыныннан купты, бөтен тәне буйлап җылы бер дулкын йөгереп үтте. Шулай да, аны-моны сиздермәскә тырышып, ул җәһәт кенә урындык куйды, стенадагы сәгатькә үрелде. Әллә ашыгудан, әллә башка сәбәптән, кинәт кенә күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте Хөснүриянең. Янына басып, сәгатьне

алырга дип, ике кулын сузып торган «кияү»нең кочагына ничек килеп төшкәнен сизми дә калды.

Башкасын рәтләп хәтерләмәде дә Хөснурия. Әллә өндә булды, әллә төштә. Бигрәк назлы өермә булып чыкты бу сәгать төзәтүче! Алар сәгатьне дә, вакытны да оныттылар...

Нәрсә булды соң әле бу? Нишләтте мине бу кеше? Йомшаклыкның чигенә чыкканмын икән... Җебегән! Беренче килеп кагылган ир каршысында шулай мәлҗереп төш инде... Уф, үләм! Тагы нәрсәләр төзәттерәсем бар микән?! — дип уйлады Хөснурия.

Стенадагы сәгать, келт-келт йөреп, өйгә җан кертте. Тавышлары җыр кебек. Кай арада төзәтте соң ул аны? Тик «кияү» чыгып киткән иде инде. «Әй ходаем, тагы кемнәрнең сәгатьләрен төзәтеп йөри микән?» — диган, көнләшүгә охшаш бер нәрсә чеметеп үтте Хөснуриянең йөрәген. Ул идәнгә ишелеп төшкән «ташкент юрганнарын», мендәрләрне сәкегә күтәреп өйде дә, инде ничә айлар кулы кагылмаган сандыгын ачты. Буйлап салынган көе иң өстә яткан, әле бер генә тапкыр да киеп салмаган кара якалы зәңгәр пәлтәсен кулына алды. Пәлтәсен кочаклаган көе, сәкедәге мендәрләргә, стенадагы сәгатькә карап алды да, йөзе белән капланып елап җибәрде. «Нәрсә бу? Бәхетме, бәхетсезлекме? Барам әле фалчыга!»

Әнә шул сәгать төзәттергән көн иде ул. Нафталин исләрен аңкытып, Хөснурия фалчы каршысындагы бүкән өстенә килеп утырды:

— Исемең? — диде фалчы.

— Шәфыйкова Хөснурия.

— Исемеңне генә әйт инде, фамилиясе нәрсәгә? — диделәр төрле яклап.

— Хөснурия инде, Хөснурия!

Фалчы озын бармаклары белән калын китабының битләрен актарырга керешә. Бер бит, ике бит, өч бит... Дәшми фалчы. Бары елмая гына... Хөснурия әле фалчының йөзенә, әле китап битләренә карады. Их, язуын таныса! Менә бит, монда гына, якында гына язмыш хәбәре...

— Китабың минем турыда бернәрсә дә сөйләмимени, ник әйтмисең? — диде түземлеге беткән Хөснурия.

— Башыңда фикерләреңнең чуалган чагы, ахры, — диде фалчы, тагын бер битне ачып. — Тормышың турында уйла...

— Әнекәем! Минем тормышым турында мин уйламый кем уйласын?! Бер башыма мең исәп! Әйт инде бер генә сүз!

— Ялгыз яшисең икән...

— Яшим шул... ялгыз шул... аны белер өчен генә фал ачтыру кирәк булды микән...

— Бар әле, өеңә кайт, — диде фалчы, аптырап. — Озак итеп уйла да, яңадан килерсең. Акчаңны кире ал... Бәлки, яңадан киләсең дә килмәс... Бар, бар, туры өеңә кайт...

Хөснурия коелып төште. Фалчының акча сузган кулына борылып та карамады. Беркемгә дә күтәрелеп карамый тиз генә урыныннан торды да, башын аска иген көе, өйдән чыгып китте. Ишегалдында торучы яшьләр, алардан да бигрәк юк-бардан кызык табып, ихахайлап көлгән Миңлебай янынннан йөгереп диярлек үтеп китте. Урамга чыккач кына, «уф алла!» дип, авыр сулап куйды, әкрен генә өенә атлады. Капка төбенә килеп җиткәч, башын күтәреп караса... ни күзләре белән күрсен — каршысында сәгать төзәтүче «кияү» басып тора иде! «Үләм! Бу кешенең безнең капка төбендә торганын кайлардан белде микән бу фалчы?» — дип, Хөснуриянең исләре китте.

Нишләп белмәсен, фалчы бит ул шуңа күрә дә. Әле ул аңар күп нәрсәләр турында әйткән булыр иде. Әйтә генә алмады. Чөнки Хөснуриянең башындагы фикерләре чуалып, зиһене таралган чагы иде шул. Фалчы түгел, Хөснурия үзе дә очына чыга алмады ул фикерләрнең. Турысын ярып салырга авылдашлары алдында әллә кызгандымы инде Хөснурияне? Әгәр дә кызганмаган булса, ул аңар: «Озак тормас синең ул сәгать төзәтүчең, китәр, ләкин сине бәхетле итеп китәр», — дип, әйтер иде. Чөнки Хөснурия ул вакыйгалардан соң менә дигән бер малай алып кайтты. Әллә бәхете булды, әллә бәхетсезлек? Бәхеттер, мөгаен. Авыл халкы: «Бер ояЛды да бетте, бүгенге көндә Хөснуриянең таянычы бар, күп хатыннарга тәтемәде әле ул бәхет», — диде.

## 5

Хөснурия апа чыгып киткәч, җыелышкан халык шып булды. Фал ачтырырга дип бик ниятләнеп килгәннәрнең дә күңеленнән шик сыман бер нәрсә үтеп китте. «Булдыра алмый, ахры... Хөснуриягә дә әйтеп бирә алмагач инде... Аңар фал ачу өчен дә зур күрәзәлек кирәк микәнни?..» Шулай дип уйла-

салар да, фалчыны тыңларга дип, бик ныклап җыенып килгәнгә күрә, кымшанучы булмады.

Шулвакыт, өй эчендәге тынлыкны бозып, киерелеп ишек ачылды, авызы колагына җиткән Миңлебай килеп керде:

— Әллә барысына да борыч кыстырып чыгаралар инде,— дип авызын ерды ул.— Хөснуриягә бәхетнең ат башы чаклысын тоттырдыгызмы әллә? Чак бәреп екмады! Әй, монда мин генә юк икән! Тыңлыйм әле азрак, миңа да акыл кермәсме?

— Син генә житмәгән идең шул,— диде Миңлеҗамал назлы тавыш белән.— Мин эш белән утырам, өйгә кайтыр идең...

— Бергә кайтырбыз, карчык, култыклашып,— диде Миңлебай.— Кая, кем чираты, бер тыңлатыгыз инде. Әйдә әле, Шәрифелтти, куначыңны капшап утырма. Син олы кеше, көттермә кешеләрне, яшьләргә төн җитәрлек.

— Юк, юк, мин бернәрсә дә белмим,— диде Шәрифелтти.

— Синнән сорамыйлар, ул үзе әйтә, утыр әнә шул бүкәнгә.

— Юк, юк әнә Хәбибҗамалдан сорасын. Ул зиһенле, ул ир белән торган кеше.

— Фалчы бит бу. Кая килгәнеңне оныттыңмы әллә? Авыл сәвите түгел монда. Бар инде, ялындырма,— диде Миңлебай, хатыннарга күз кысып.— Нәрсә ишетергә кергән идең соң?

— Нәрсә ишетергәме...— дип, мүкәләп урыныннан торды Шәрифелтти.— Ат булып җигелдем, сыер булып савылдым, көпчәк булып тәгәрәдем, дөнья кудым. Дөнья мине тотты, мин дөньяны тота алмадым. Оҗмахлы буласың дисә, башка бернәрсә дә кирәк түгел...

— Оҗмах төбе саклаучы фәрештә дип белдеңме әллә син аны? Бәлки, хур егетләре турында сорарга килгәнсеңдер, ә?

— Әстәгъфирулла диген!

— Өчлегең бармы соң?

— Нәрсә дисең?

— Өчлексез туган анасына да ачмыйм дип әйтә ди...

— Әстәгъфирулла! Хәзер, хәзер, кая соң үзе...

Шәрифелтти, ашыга-ашыга, оек куначын капшарга кереште.

— Еракка яшерсәң, якыннан алырсың. Куначтагы — кулда, куендагы — юлда... Өчлекме бу?

— Шул инде, шул! Кулына тоттыр.

— Ничек дисең?

Акчага кагылышлы сүз булганда Шәрифелттине дөм саңгырауга әйләнә дигәннәр иде, дөрес икән.

Ниһаять, куначта ятып, тасланып беткән өчлекне калтыранган куллары белән фалчыга сузды.

— Бисмиллаһирахманиррахим...

— Исемең ничек?

— Исемемне әйтегез әле, оялам,— диде Шәрифелтти, шәл очы белән авызын каплап.

— Бар икән мулла кызы,— диде Миңлебай шаркылдап.— Шәрифел аның исеме, Шәрифел...

Белмим, нәрсәләр сөйләгәндер фалчы Шәрифелттигә, анысын мин ишетмәдем, йоклаган идем инде. Ләкин Шәрифелтти турында мин фалчыга караганда да күбрәк беләм. Чөнки безнең күршедә генә яши ул. Мин белә башлаганнан бирле, безнең өебезгә генә орынып, юан кәүсәле шомырт агачы үсә. Шәрифелттиләр шомырты. Безнең киртәнең теге ягындагы бәрәңге бакчасы да — аларныкы. Ә заманында шул шомырт агачы кырыенда калай түбәле, әйбәт каралты-куралы бай гына йорт та булган. «Шәех алашасы» дип йөртелә торган, авылга бер дан атлары да булган аларның... Бу гаилә турында гыйбрәтле бер вакыйганы онытмый авыл халкы...

Күптән булган бу хәл... Матур, җылы язгы көннәрнең берсендә, ул вакытта әле япь-яшь, сыгылмалы шомырт ап-ак чәчәктә утырган вакытта, бер хәерче керә Шәрифелттиләргә. Яшь килен Шәрифелтти мичтән ипи чыгарып йөри икән. Идәнгә, ярты өйне алып, орлык бәрәңгесе өелгән, кояшта күзәнәкләрен тутырып ята. Шәрифелтти ишек тавышына башын күтәреп караса, бусагада бер ир кеше басып тора икән. Ян ягына капчык аскан. Тез башына чаклы төшеп торган күлмәге киндерә билбау белән бәйләнгән, аягында чабата. Бер дә мөселман кешесенә охшамаган булган бу хәерче. Шәрифелтти, сәке өстенә тезгән ипиләренең өстенә тастымал ташлаган да, барлы-юклы урысчасы белән кулын селтәп:

— Нету, нету, бар, бар, юлыңны кара,— дип, гомердә халыкта булмаганны, хәерчене буш кул белән куып чыгарган.

Артыннан карап карыйм әле дип, ишегалдына чыга торган ян тәрәзәгә килсә... ни күрсен! Теге хәерче, утын яра торган бүкән өстенә утырган да,

кул аркасы белән бәддога укып утыра, имеш. «Әй ходаем! Харапчар гына булдым. Хозыр Ильяс булган бит!» — дип, Шәрифелтти ипи кисә башлый. Башка берәү булса, бөтен ипи күтәреп йөгерер иде. Ә ул ипи кискән арада исә Хозыр Ильяс юкка да чыга.

Бәддога озак көттерми. Шул ук төнне боларның бөтен авылга дан булган атларын, аякларына чабата кидертеп, урлап чыгалар. Хәерчеләр, Хозыр Ильяслар, ат каракчары бик күп булган замана бу. Ул заман аерым хуҗалык вакыты була. Һәркемнең аты үз кулында. Атлары урланып, ике-өч көн «ах-вах» килгәнче, бик яман ут чыгып, бернәрсәләрен дә коткара алмыйча, үзләре эчке күлмәк-ыштан белән калып, яналар болар. Үзләренә дә, аркаларына капчык асып, кешегә өйдәш булып керергә туры килә. Нигезләрендә шашынып үскән шомырт агачы гына кала. Аннан авыр еллар башлана. Өй салырлык рәтне берничек тә юнәтә алмыйлар. Кызы кияүгә чыгып, малай табып, әйбәт кенә яши башладык дигәндә, сугыш башланып китә. Шәрифелттинең кияве сугышта ятып кала. Карты да гүр иясе була. Болар, өч кисәк — аналы-кызлы һәм кызының улы белән — тормышның ачысын да, төчесен дә татыйлар. Башка урамдагы берәүләрнең мунчасын өй итеп, оныгы үсеп кеше булганчы, шунда гомер үткәрәләр. Ләкин шомыртлы бакчаларын ташламыйлар. Әле болары мин туганчы булган хәлләр. Ә менә мин белә белгәннән бирле шул бакчаларына бәрәңге утырттылар, ә Шәрифелтти шомырт агачын саклады. Һәр яз саен, шомырт чәчәк атуга, күрше урамда яшәгән Шәрифелтти, таякка таянып, чайкала-чайкала килә торган иде дә, шомырт төбенә утыра торган иде. Шомырт агачына бала-чаганы якын да җибәрмәде. Чәчәген генә түгел, яфрагын да өздертми иде. Ә инде шомырт җитлегә башлагач, әйткән дә юк! Яшь чагының, матур тормышының бердәнбер истәлеге булган бит аңар шомырт. Бәлки, ул аның төбендә утырган чакта фани дөньяны гына түгел, ахирәтне дә уйлагандыр. Бала-чагалардан шул шомыртны саклауны савaплы эшкә чутлагандыр. Торган өенең шушы шомырттан ерак булганы өчен үзүзен ачуланып, үз кайгысына үзе күмелеп утыргандыр. Кем белә бит? Шомырт аның бердәнбер куанычы, иң соңгы байлыгы булгандыр. Курка идек без Шәрифелттидән. Ул югында шомыртка үрмәләсәк тә, аны күрүгә, кычыткаңнарга чагыла-чагыла, бәрәңге бакчасы буйлап, бәладән ераккарак йөгерә идек.

Белмим, фалчы нәрсәләр әйткәндер Шәрифелттигә. «Оҗмахлы була дисә, башка бернәрсә дә кирәкми», — дигән иде. Урыны оҗмахта булсын, Шәрифелтти дөньяда юк инде...

### 6

Лампада керосин бетеп, ялкыны сикерә башлагач кына таралганнар кичә фалчыга килүчеләр.

Ә иртән буранлый башлады. Әти белән әни җибәрмәделәр фалчыларны.

Бүген мәктәптә мин дә фалчы булдым. Тәнәфес вакытында, класс журналын алып, барысына да фал ачтым. Шуның аркасында эләкте дә соң үземә. Башта фал ачу бик шома барган иде. Берсенә, укытучы булачаксың, дидем: икенчесенә, читкә китәсең, дидем. Сөендердем барысын да. Тик менә, Рәфкатьнең журнал тулы икеләрен күреп, күземне классның сөрөмләнеп беткән түшәменә терәп, фалчы тавышына охшатып:

— Быел күчми каласың икән... Икеләрең җибәрми сине бишенче класска... Эчке тәртип кагыйдәләрен белмисең икән... — дип кенә башлаган идем, ул:

— Менә сиңа эчке тәртип, менә сиңа тышкы тәртип, — дип салды да җибәрде. Авыртса да, тамчы да еламадым. Мин дә тик тормадым, журнал белән бәрдем башына. Икеле капчыгы! Әйтерсең, аның начар укыганына мин гаепле.

Мәктәптән кайтканда фалчы хатыны белән әни өстәл янында сөйләшеп утыралар иде. Эченә җылы керу генә түгел, күңеле дә йомшаган иде, ахры, бу апаның. Кичә авызын ачып бер генә сүз дә әйтмәгән иде. Сөйләшә белә икән үзе. Мин дәресләремә утырган булдым, ә колагым — аларда.

— Үзең әйтмисең, китеп барсагыз, исемегезне дә белми калырбыз инде, — диде әни.

— Исемемме... Ноябрина исемле мин.

— Ничек дидең?

— Ноябрина. Кызык бит, әйеме?

— Кызык дип инде, — диде әни. — Исем булгач, яраткан да ябышкан инде. Исем дигәннән, минем үземә исемем бер дә ошамый иде яшь чакта. Мәүҗидә! Шул да булдымы исем, ди торган идем. Бервакыт шулай бер хатын белән таныштым базар юлында. Исемемне сорагач «Гүзәл» дигән булдым.

Исемегез бигрәк матур икән, ди теге хатын, ә минем исемем Мәүҗидә, ди. Аптырап калдым. «И-и, адашлар, икән бит без»,— дидем дә, әйтеп бирдем инде Мәүҗидә икәнлегемне. Әнә шул хатын акыл өйрәтте үземә. Исемем ямьсез булганга гына Гүзәл дип әйткән идем дигәч: «И Мәүҗидә җаным, безнең исем Коръәнгә язылган бит ул, нишләп ямьсез булсын!» — диде.

— Ә минем исемне әни кушкан. Җиденче ноябрь көнне туганмын мин. Әни партия эшендә эшләгән ул вакытта. Әби үлгәнче әйтте: «Исемеңне генә күтәрә алмадың, шуңа күрә чирләшкә булдың»,— диде. Минем чирләү исемнән түгел инде анысы, тумыштан. Күзеңдә миң бар дип, әби, Миңленоябрина дип йөртсә дә, файдасы тимәде. Чәчемне күрсәтим әле мин сиңа.

Ул, безгә кергәннән бирле салмаган яулыгын чишеп җибәрде дә, курчак чәче кебек ап-ак ике толымын түшенә салындырды.

— Нәрсәдән агарды бу чәчләрең,— диде әни, шаккатып.— Шундый ак чәч буламыни яшь кешедә? Юләр кеше әйтмешли, әллә үз толымың түгелме?

— Үземнеке, Мәүҗидә апа. Тумыштан шундый. Альбинос чире диләр аны. Минем тәндә кара төсне күрсәтә торган матдә юк икән. Күзләрем дә начар күрә минем шуның өчен.— Ул, миңа карагыз дигән шикелле, күзләрен зур ачып, кечкенә сәдәф кебек төссез күзләрен тутырып әнигә карады.— Ак каргалар турында ишеткәнең бармы? Бәлки, күргәнең дә бардыр?

— Әллә инде...

— Әнә шул ак карга инде мин. Исемем белән дә, җисемем белән дә, дигәндәй...

— Ә бу фалчыны каян таптың соң?

— Сукырлар клубында танышкан идек. Кызлар белән симәнке чиртеп тора идек клуб каршында, килде дә, кызлар, сыйлагыз әле, дигән булды. Симәнке соравы бер сәбәп кенә булгандыр инде. Ноябрина, ди миңа, шушы адрес белән илтеп куй әле мине.

Озата киттем инде. Гел елмаеп сөйләшә, йомшак тавышлы. Начар кеше түгелдер, дип уйлыйм. Миннән күпкә олы булса да, өйләнешик дигәч, риза булдым да куйдым.

— Әти-әниең бармы соң синең? Алар турында берни дә әйтмисең. Алар нәрсә диделәр?

Ноябрина апа, беркавым дәшми торды да:

— Утыз җиденче елда икесе дә бер-бер артлы үлеп киткәннәр. Сыеныр кешем — картаеп беткән бер әбием иде. Авыр туфраклары җиңел булсын. Язмышны сынау иде инде бу. Язмышны сынамыйлар икән аны. Күпме сайласаң да, язмыштан узмыш юк. Кайчагында үкенәм, ә кайчагында сөенәм моңар ияргәнгә. Әйбәт кеше ул. Аның да беркеме юк. Яраткан кешесе булган аның. Ә сукырайгач, беркемгә дә кирәге калмаган. Әби дә аны «сукыр» дип кенә карады. «Сукырга таяк булганчы, күзлегә маяк бул!» — ди торган иде. Күңел күзе бар аның. Сабыр кеше ул. Исеме дә Сабирҗан бит аның. Миннән башка ияртер кеше тапмас идемени? Минә күпме йөрим инде мин аның белән, нича ел бергә яшибез, бер генә тапкыр да миңа фал ачканы юк аның. Әллә ташлап китәр дип курка инде. Нишләп ташлап китим инде мин аны. Беркем дә көчләп бирмәде бит, үзем теләп бардым.

— Аның сукырлыгы нәрсәдән соң? Синең кебек тумыштанмы, әллә чәчәктән калганмы?

— Юк, тумыштан да түгел, чәчәктән дә түгел. Әле яшь чагында Донбасс якларында шахталарда эшләп йөргән ул. Шунда нииндидер бер фаҗига булып, ташкүмер астында калган. Өч көннән соң гына казып чыгарганнар. Шунда сукырайган да. Әнә шул вакытта барлыкка килгән инде аның күрәзәлек сәләте. Яраткан кешесен дә шул вакытларда югалткан булырга тиеш. Сабирҗан бу турыда сөйләргә бер дә яратмый.

— Торырга өегез бармы соң? Әллә гел шулай йөрисезме?

— Почмагыбыз бар инде. Азрак акча эшләп булмасмы дип чыккан идек. Кая ул! Аның холкы белән. Күбесен бушка әйтеп йөри. Пенсиясе юк дисәң дә ярый. Тик бу юлы бер дә күңеле тартмый чыкты бу якларга. Юл шулай төште инде. Очрашмаска ант иткән кешем бар иде, аралар якыная, дип сөйләгән иде урманда юл тапмый йөргәндә. Нишлисең бит, яшәргә кирәк. Эшли торган җирдә дә бик аз түлиләр.

— Нинди эштә эшләде соң ул, күрмәгәч дим инде?— диде әни.

— Эш бетәмени. Сукырлар өчен дә бетми эш. Чыпта үрә идек, минә чыгып киттек әле. Ул юкә тузаны бөтен үпкәләрне тутырды. Аның үпкәсе болай да таза түгел. Ничә ел шахта тузаны йоткан бит әле ул...

Ишегалдында капка келәсе тавышына тәрәзәдән карасам, күршебез Айсылутти кереп килә икән.

— Әйдә, әйдә, Айсылутти,— диде әни, өй ишеген ачып— Әле нишләп керми микән, дип тора идем.

— Исәнлектә ятасызмы?— диде Айсылутти.— Әле, Мәүҗидә, кунакларың китмәгән икән. Үземә ала алмадым, шуңа эчеп пошып кердем әле. Безгә чәй эчәргә булса да кереп чыксыннар, дигән идем. Шикәрем дә бар, аче камырдан көлчә дә пешергән идем.

— Белмим инде, Айсылутти... Фалчы үзе ишегалдында. Минем дә ашым өлгерергә тора... Кара әле, нигә әле син фал ачтырмыйсың? Үзеңне булмаса, Санияне каратыр идең? Ул торфларда, юл эшләрендә күпме интегәсе бар микән аның?

— Әй, Мәүҗидәкәем... хаты килде әле Саниянең! Кичәдән бирле кулдан төшергәнем юк. Тагы бер укып бир әле...

— Карточкасы юкмы?

— Бу юлы җибәрмәгән. Укы әле, укы.

Сәламне укый башлауга ук, Айсылутти еларга тотынды. «Сезки минем өчен кадерле булган эти белән әнигә, безки сезнең өчен дә кадерле булган кызыгыз Саниядән, бик сагынып, бик күп сәлам...»

«Сәлам соңында,— дип дәвам итте әни укуын,— минем хәлләргә килсәк, сезнең хәер-догада, аллага шөкер. Үземә ялтыравыклы эрҗинкә итек алдым. Сезгә посылка салдым. Эшем авыр түгел, кайгырып ятмагыз...»

— Эшем җиңел дигән булган... җиңел буламы соң... Авызыннан өзеп, посылкалар салган була, балакаем... Әле ул җибәргән шикәрем дә бар... Мине жәлли инде,— диде Айсылутти, күз яшьләрен сөртеп.

— Әле җыр да язган икән,— диде әни алга таба укып.

— Хат саен җыр язмый калмый,— диде Айсылутти.— Йә, укы инде, миңа карама... Мин кичәдән бирле елыйм...

> Әнә килә автомобиль,
> Төягәннәр торбалар,
> Үзең монда, анаң кайда,
> Дип кычкыра торналар...

Айсылутти, ике куллап, чытырдатып хатка ябышты.

— И Мәүҗидә! Ник бәгырьләрне телгәли микән бу бала!— диде ул өзелеп.— Миңа бит ул торналар: «Үзең монда, балаң кайда-а...» дип кычкыра. Урман кисүгә йөреп интекте яшь башларыннан... Тагын, юл эшенә дип алып киттеләр... Кара кул инде, Хәбри... Үземне төрмәләрдә череткән иде, хәзер бала интегә. Ул язып бирмәсә, монда да эш бетмәс иде әле...

— Бетермә үзеңне, Айсылутти,— диде әни, аны юатып.— Ул бит яшь кеше. Рәхәтен дә күрер әле, бәхетен дә табар. Фал ачтырып кара әле. Үзеңә булмаса, Сания өчен ачтырып кара. Ачтырмасаң, тыңларга кер, ичмасам. Күңелләрең ачылып китәр.

— Әй, сөйләмә син... Кеше фалын тыңларга, дип, миннән башка да өең тулып килгәннәр, дип ишеттем. Исем сорап фал ачучыларны күргәнем бар минем. Йөрәгемә ярамый... Әле һаман да колак төбемдә яңгырап тора... «Исемең, фамилияң? Йә, сөйләп җибәр әле, колхозның социалистик мөлкәтенә кул сузарга ничек батырчылык иттең син?!» Ул вакытларны искә төшерсәң... Сания — үсмер бала. Мин төрмәдә чакта үлгән Шафигуллам — бишектә. Баланы басуга арбага салып алып барам, тартып алып кайтам. Шуның мендәре астына бер генә учма башак уып салган идем. Ачлыктан бит... Кемдер шуны Хәбригә җиткергән. Эштән кайтуга, тентү белән керделәр. Эзләделәр, эзләделәр, тапмадылар. Инде, аллага шөкер, ходай саклады, дип тора идем, аяк башына карап сөйләшә торган Хәбри, идәндә бер бөртек арыш күреп алган. Бер бөртек бит ул, бер бөртек! Кайлардан изреп кермәс! «Берсе булгач, моның иптәшләре дә булырга тиеш!» — дип, яңадан эзли башладылар. Бала мендәре астыннан яулыкка төрелгән теге бөртекләрне тартып чыгаргач, сыгылыплар төштем. Үземнең тагы авырлы чак. Ул бала төрмәдә туды да үлде. Хәтерлисеңдер инде. Ике ел утырып кайттым бит. Төрмәдә дә ачлык. «Ерак китә алмассың, бар, тамагыңны туйдырып кайт!»,— дип, хәер сорашырга чыгарып җибәрәләр. Ерак барып буламы соң... Аяклар шеш... Соңгы айларымны йөрим... Шулай хәер сорашып йөргәндә бер өйнең капкасын кактым. Керсәм, хуҗа хатын ишегалдында, ат тизәге кушып, тавыкларга бәрәңге төеп утыра. Минем хәлне күрде дә, рәхмәт төшсен аңар, хәзер, ипи алып чыгам дип, өенә кереп китте. Нинди ипиле йорт булгандыр инде ул заманда, белмим. Ул өенә кереп киткәч, ялгаш кырыена чүмәләдем дә, тегенең тавыкларга дигән бәрәңгесен, тизәкләреннән аерып, ашарга тотындым. Онытылырлык мени ул? Ә син фал ачтыр дисең. Мин күргәннәрне эт тә күрмәс... Фалчылар дигәч, әнә шул хәлләрне тагы бер кат уемнан кичердем дә, ник кертмәдем микән боларны, дип, төне буе йокламадым... Керсеннәр әле безгә. Көлчә белән чәй эчертермен...

Айсылутти бик каты чакырып, чыгып киткәч, әни күршеләрне мактарга тотынды:

— Күрше ходайдан инде ул,— диде.— Бернәрсә дә эшләп булмый. Бәхетең булса, әйбәт күршеләр бирә ходай, бәхетең булмаса — бер дә үпкәләрлеге юк. Кемгә үпкәлисең? Үпкәләп кенә эш бетми, дөнья көтәргә кирәк бит. Минем үземә калса, аллага шөкер, уңдым күршеләрдән. Ничә еллар инде, ике як күршеләребез белән дә камь-мәмер, тату яшибез. Тик шунысын да әйтергә кирәк, дөнья булгач, төрле хәлләр дә булгалый, кара мәчеләр дә юлны аркылы чыккалый... Тик, олы сүз итеп, авыз тутырып, безнең күршеләр «ай-һай» дип әйтерлек түгел. Бер күршемә карап фикер йөртсәм, икенчесенә карап шөкер итәм. Бер күршемә кереп үзем акыл өйрәнәм, икенче күршемә кереп, түкми-чәчми, акылны үзем өйрәтәм. Кешенең бәхете эш белән генә түгел бит ул. Аркылы аяклы бул, җебегән бул, тик бәхет кошың башыңда булсын. Күршем Гөлсирә турында әйтәм. Бәхет кошы башында булмый ни, күршесендә мин бит аның. Үзе дә әйтә, ярый әле күршемдә — син, син булмасаң, гомердә дә шушы Суык урамда гомер кичермәгән булыр идем, әтиләр нигезендә әйбәт иде безнең тормыш, ди. Әтиләр тормышында минеке дә әйбәт иде ул. Ә безнең урамга нәрсә булган? Суык урам дигән булалар да, шул урамның файдасын ник берсе ачып салсын! Бакча артында гына урман, урман белән бакча арасында менә дигән басу. Нинди генә иген чәчмәсеннәр — бакча башында булгач, ничек тә йокмый булмый инде. Бәрәңге чәчсәләр — утау чүбе җыясың, арыш басуы итсәләр — камылын чабасың. Шул басуга бер-ике адым гына керерлек итеп, бакча башына бозавыңны арканлыйсың. Кайчагында, әнә шул бозау аркасында, тавышланган төсле итеп алган булабыз Гөлсирә белән. Тавышлану түгел инде, Гөлсирә ирен җәлли. Чөнки Гөлсирәнең ире Касыйм пәләвәй булып эшли. Менә, ишеттеңме инде, күршебездә шундый, урындагы кешеләр безнең. Урындагы кеше — урамдагы кеше, дигәндәй, монысы — урында булса да — урыны ат өстендә, мендәре арты астында. «Касыймның бүсере сезнең уҗымга чыккан мал-туарны куып кына чыкты»,— ди Гөлсирә. Бозауның муенына муенчак салсаң да, казлар муенына муенчак кидертеп булмый шул. Казларның чайкала-чайкала басуга менеп барганнарын Касыйм күреп кенә ала да:

— Кө-ө-өш! Мур кыргырлары!— дип, бер-ике чакрымнан күкле-яшелле тавышы белән кычкырып җибәрүе була, тәрәзә пыялалары зеңләп кала. Астындагы аты өркеп, Мунчала күперенә чаклы дуамаллап алып китә үзен. Астындагы мендәре, җан-фәрман чапкан чакта төшеп кала да, урамнарда мамык бураны күтәреп, бөтен дөньяны каплый. Каһәр төшкән казлар, таныйлар бит шуның тавышын! Шул минутта, барган юлларыннан кире борылып, мәтәлә-кадала кирегә йөгерәләр, шыбырдап елгага коелалар. Нинди бүсер чыдасын аңар!

Әнекәем! Айсылутти тагы кереп килә. Ноябрина, бар инде, Сабирҗан абыйны ал да, кереп чыгыгыз, күңеле булыр күршемнең. Ә мин хәзер, Гөлсирә әйтмешли, токмач басып, токмач кисеп, токмач салып аш пешерермен.

Әни, Ноябринага авыз ачарга да бирмичә, кулына бишмәтен тоттырып, Айсылуттиләргә озатты.

## 7

Күрәзәчеләр килгән, дигән сүз таралгач — бөтен авылга бер хәбәр бит ул — һәр кеше үзенең тормышын, башыннан кичкәнен тагын бер мәртәбә күңеленнән үткәрде. Өмет дигән нәрсәнең гаҗәеп бер изге, ят кул кагылдырмый торган кадерле нәрсә икәнлегенә тагын бер мәртәбә, күңеленең кайсы төше беләндер сизенде авыл халкы.

Сәеттәрәй абый да өмет белән яши. Юк өмет белән, тамыры корыган өмет белән яши, тик ниндидер бер чаткысы сүнмәгәнгә генә калдырмый аны өмет. Әнә, ул бүген дә баскычына чыгып утырган. Әйтерсең, ялгызлыкны буш өенә бикләп калдырган да, үзе өмет чаткысын алып, көн дә уйлый торган уе аша узган гомеренә кире кайткан. «Әгәр дә теге дөньяда, кыямәт көнендә очрашсак, Маһирәдән иң беренче: «Син кайсы көнне вафат булдың соң? Мин бит синең хәлеңне белергә килгән идем, әйттеләрме?» — дип сорар идем, дип уйлый ул. Бу дөньяда сорый алмаячак, Маһирә апа юк инде бу дөньяда. Ә бәлки исәндер, өмет шулай уйландыра. Чөнки Сәеттәрәй абый хатынының чирләп ятканын да, җан биргәнен дә күрмәде. Каберенең дә кайда икәнен белми. Үз гомерендә өч чакрым ераклыктагы күрше авылны да барып күрмәгән Маһирәнең сөякләре кайсы җир астында ята торгандыр. Белми аны Сәеттәрәй абый. Ходай насыйп итмәде шул. Бер кеше язмышына төшсә дә төшә икән шундый сынау!

...Сугышның дүртенче елы. Сәетгәрәй абыйның хатыны Маһирә, быел илле биш яшен тутырып, колхоз эше өчен «гудтан» чыгарга тиеш иде. Көннәрдән беркөнне аны авыл советына чакырып: «Минимумыңа алты хезмәт көнең тулмаганны беләсеңме?» — дип сорадылар.

— Нишләп тулмасын! — диде Маһирә. — Бер генә көн дә эштән калганым юк бит, Хәбри балакаем! Закирәне сугышка озатканда да ярты гына көн чыкмый калган идем...

— Военный вримедә, — диде Хәбри, — лодырларга юл куйган юк, пнимаетели! Син монда Закирәне китереп кыстырма!

Хәбринең кычкырмаган кешесе юк инде, бөтен сөйләшү шушы булгандыр дип, тынычланып кайтып киткән иде Маһирә өенә. Моның белән генә бетмәгән, әле монысы башы гына булып чыкты. Икенче көнне, пунәтәйләр белән килеп, җилтерәтеп, районга алып чыгып киттеләр. Сәетгәрәй абый, капканы үзе ачып, артларыннан кул болгап калды. Мәхлук! Ир бул да, авыз ачып бер сүз дә әйтә алма инде! Бәгыреннән күтәрелгән җан ачысы бугазына төер булып капланды. Алты хезмәт көне өчен дидеме? Пунәтәйләр белән кереп! Үзләре ялгышкандыр, башкача булмас... Тикшерсеннәр әле... Аннан соң Сәетгәрәй абый үз-үзен тынычландырырга тотынды. Анда да кешеләр утыра бит, дип уйлады ул. Азрак ачуланырлар да, җибәрерләр. Шулай тынычланып җиткәч кенә китте Сәетгәрәй абый авыл советына. Шуның өстенә, каршысына очраган почта кызы Закирәдән хат та биреп киткәч, күңеле гел күтәрелде аның. Әнә шулай, кулына хат тоткан көе килеп керде ул Кара кул Хәбри янына. Ләкин хат тотып килеп кергән Сәетгәрәй абыйга Хәбри авызын да ачтырмады.

— Аның эше судта! — диде. — Райун хәл итәчәк. Совет блачы лодырларга юл куймый!

— Закирәдән хат бар иде... — диде Сәетгәрәй абый, башка яклаучысы булмаганга, яклаучысына ышыкланган кебек, хатны күрсәтеп.

— Кызым сугышта дип, иркәләнеп йөрисе түгел, — диде Хәбри, кара пирчәткәле кулын селтәп. — Алар сугышта кан түгә, пнимаетели, ә болар канса канис, җилкә симертә! Барыгызны бер шалунга төяп озатасы нәрсәләр!

Нәрсә әйтсен Сәетгәрәй абый? Бер сүз дә әйтмәде. Мөлдерәгән күзләре белән кулындагы хатка карап алды да...

— Хатны ничек күрсәтергә соң Маһирәгә? — дип сорады.

— Күрсәтәсең килсә, табарсың, райунда дидем бит, — диде Хәбри.

Шушы сөйләшүдән соң, районга барырга карар кыла Сәетгәрәй абый. Ике көн уйлана-уйлана да, юлга әзерләнә ул. Биштәренә бер кием оек-чабата сала. Берничә бәрәңге, алабута күмәче пешереп ала. Җомга көнне, иртәнге намаздан соң, ходайга тапшырып юлга чыга. Районда көнозын буталып йөргәннән соң гына, Маһирәсен Казанга озатканнарын белә Сәетгәрәй абый. Казанга! Шул тиклем җиргә! Алты хезмәт көне өчен!

Сәетгәрәй абыйның Казанда булмаганына инде күпме еллар! Бер кеше гомере үткән... Герман сугышыннан кайтканда кагылган иде Казанга. Барыймы, бармыйммы икән, дип, озак уйлап тормый ул. Өен күршеләре ташламас әле. Закирәнең фронттан килгән хаты көч өсти аңар. Бу хат белән теләсә кайда кереп булачак, дип уйлый Сәетгәрәй абый. Шулай булмый мөмкин түгел. Фронтта бит аның кызы! Ил өчен сугышып, кан коеп йөри.

Бер атна дигәндә барып җитә Сәетгәрәй абый Казанга. Йончып, ачыгып, каралып, хәлсезләнеп килеп керә. Казанда бик тиз таба төрмәне. Төрмә ишеге төбендә аның ишеләр байтак була. Ул да шул кешеләр янына баса. Чираты җиткәч, мунча төннегә кадәр тәрәзәгә башын тыгып, Маһирәсен сораша. «Солтангәрәева Маһирә!» — дип кайтарып сорый тәрәзә каршында утыручы. Аннары, кәгазьләр актаргалый да: «Больницада ята ул, сезнең янга чыга алмый», — дип куя. «Иртәгә терелер микән? Җәмәгате мин аның! Закирәдән хат бар иде... Авылдан килдем мин, әйтегез әле үзенә...» — дип инәлә Сәетгәрәй абый. «Үлмәсә, терелер, иртәгә кил!» — ди теге кеше. «Следующий!» — дип кычкыра ул, сүз бетканлекне аңлатып.

Сәетгәрәй абый кая барсын? Соңгы кисәк алабута күмәчен ашый да, шул төрмә капкасы төбендә төн чыга. Икенче көнне тагын шул тәрәзәгә күзен тери. «Маһирә Солтангәрәеваны күрергә мөмкинме?» «Кычкырып әйт, кем дисең?» «Солтангәрәева Маһирә...» — ди Сәетгәрәй абый хәлсез тавыш белән. — Минем җәмәгатем ул...» Тәрәзә артындагы кеше, ниндидер язуларны караштыра да, башын да күтәрмичә: «Юк ул бездә, юк!» — дип кычкыра. «Больницта диган идең бит кичә, бүген хәле ничек микән?» — ди Солтангәрәй абый. «Үлде, бабай, карчыгың, үлде, терелә алмады», — ди тәрәзә артындагы хәрби киемле кеше. Солтангәрәй абыйның күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китә. «Ялгыш карыйсыңдыр... шул арада кеше үләмени... Әйбәтләп кара әле... Фронтта безнең кызыбыз... Хаты бар... хаты...» — ди ул тәрәзәдән хатны күрсәтеп. «Фронтта» дигән сүздән соң, хәрбинең йөзенә җылы

иңгәндәй күренсә дә, кырыслыгы кимеми. «Үлде, бабай, карчыгың үлде...—ди ул ышандырырлык итеп.— Менә, бирегә шулай дип язылган...»

Сәетгәрәй абый, тәрәзә яныннан китә дә, төрмә стенасына ябышып бераз атлаганнан соң, аркасын терәп, җиргә чүмәли. «Ничек инде?.. Ясинсызнисез... Хәле авыр булган икән... Тукта әле, кайчан күмәләр микән соң? Ходай шулай язган икән, нишләмәк кирәк... Тукта әле, нигә сорамады соң?» Сәетгәрәй абый, көч-хәл белән урыныннан күтәрелеп, тагын чиратка баса. Теге кеше бу юлы шунда ук таный картны. «Бабай, әйттек бит инде, үлде карчыгың!» — ди ул, нигә юк белән борчыйсың, дигән кыяфәттә. «Үлүе дөрес инде, алайса,— ди Сәетгәрәй абый, үзалдына сөйләнгән кебек.— Күмешергә мине дә алыгыз әле...» «Рөхсәт ителми, аңлыйсыңмы, рөхсәт ителми...» «Ә Закирәгә нәрсә дип әйтермен,— ди ул, хатны күрсәтеп.— Истәлеккә бирәр нәрсәсе калмадымы? Күлмәген, яулыгын бирегез, ичмасам». «Үзе белән алып китте, күлмәген дә, яулыгын да... Тиле карт, кит әле тәрәзәдән! Анда чират җыелган. Синең хатын гына дип белдеңме әллә монда?» — дип кычкыра төрмә кешесе.

Үкереп елар иде — кеше күп. Аунап, җир тырмашып кычкырыр иде — халык карый. Ә кызына нәрсә дип җавап бирер ул? «Әниеңне саклый алмадым, диярме?.. Их, замана...»

Хәер сораша-сораша, ун көн дигәндә кайтып җитә Сәетгәрәй абый Казаннан. Фронт тикле фронттан Закирәсе дә исән-имин кайта. Тик әнисе генә булмый ул кайтуга...

Әнә шул уйлары белән утырды Сәетгәрәй абый баскычында. Бармады күрәзәчегә. Хатынының каберен генә сорамакчы иде, бармады. Очрашырга күп калмады инде, дип уйлады ул. Түзәрмен. Күпмегә түзгәнне, монысына гына түзәрмен. Бармады күрәзәчегә.

## 8

Сирәк эләгә торган чана шуута рәхәтләндем бүген. Ноябрина апа бишек янында бәйләп куйгандай утыра. Кич булып килгәндә генә, киез итекләр бозланып катып, суык тырнакларга киткәч кенә кайттым өйгә. Никадәр өшегәнемне өйгә кергәч кенә белдем. Туңып әрнегән кулларымны кая куеп җылытырга белмәдем. Туңдым дип, урамнан елап кайтканны әнинең җене сөйми. «Мин куштыммы!» — дияр. Җитмәсә, өйдә кешеләр бар. Үзеннән-үзе коелган күз яшьләремне тыеп, шакыраеп каткан итекләремне күтәреп, мышкылдый-мышкылдый мич башына менеп киттем. Газапларымны күрмәсеннәр, ичмасам. Минем болай туңып кайту беренче мәртәбә генә түгел инде. Андый чакларда әни туңган кулларымны карлы итекләрем өстенә куйдыртып тора иде. Шуңа күрә, карлары эрегәнче дип, үзем белән алдым ул итекләрне мич башына. Туңу җелегемә төшкән, ахры, карлы итекләрнең бер генә дә файдасы тимәде. Мин аларны аралыкка атып бәрдем дә үкереп еларга тотындым. Кушеккән кулларым орынмаслык булып авырта башлады.

— Иркәм, нәрсә булды?— дигән тавышка борылып карасам, янымда гына, кулларын миңа таба сузып, Ноябрина апа басып тора иде. Мин дәшмәдем. Елавымны дәвам иттем.

— Иркәм, берәр җирең авыртамы әллә?—диде Ноябрина апа ягымлы тавыш белән. Аның миңа «иркәм» дип эндәшүенә шунда гына чынлап игътибар иттем. Безнең авылда алай дип сөйләшмиләр.

— Туңдым-м,— дидем мин яшь аралаш.

— Хәзер җылынасың,— диде Ноябрина апа.— Мин аның серен беләм. Сал әле яулыгыңны.

Ул, яулыгымны салдырды да, минем кызышып янган кулларымны үзенең салкынча куллары белән тотып, чәчем арасына күмде.

— Кыймылда, кыймылда,—диде ул.— Кашы башыңны. Беләсеңме, чәчтә җылылык күпме? Кыймылдат бармакларыңны, кыймылдат... Җылынамы? Әйттем бит... Тырнагыңа киткән суык...

Ул минем кулларымны ике учына алды да битләренә куйды. Аның бите салкынча, ә минем кулларым ут кебек яна.

— Җылынганнар бит, иркәм,— диде Ноябрина апа.

Кулларым җылы булса да, әрнүе басылмады. Күпме утырырга була инде мич башында? Мин, әкрен генә төштем дә, букчамны эзләп алып, тәрәзә төбенә дәрес әзерләргә утырдым. Өстәл өстендә фалчы абыйның китаплары тезелеп куелган булганга, өстәл янына барырга кыймадым. Фалчы абый әти белән ишегалдына чыккан, ахры, ул өйдә юк иде.

Мин дәрес әзерлим. Тик кулларым үземне дә, тоткан ручкамны да тыңламый. Шулвакыт, кулларның да сызлавын оныттырырлык итеп, башым авыртырга тотынды. Әни әйтмешли, бер рәхәтнең бер михнәте шушы була

торгандыр инде. Китаптагы хәрефләр сикергән кебек була башлады, күз алларым әлҗе-мелҗе килде. Тик дәресләрне эшләми ярамый. Икеле алсам, фалчыларга сылтарлар тагын. Минем чана шуугга алар гаепле түгел бит.

Беркавымнан соң, ишегалдыннан фалчы абый кереп, үз урынына утырды. Өйгә кешеләр дә җыела башлады. Язмышларын белергә теләп тә, кичә өлгерми калганнар күп икән әле...

...Барысыннан да алдан килгән Фаягөл белән Миңлежамал, кичәге урыннарына урнаштылар да, кул эшләрен чыгарып, берсе — шәл, икенчесе оекбаш бәйләргә тотынды.

— И Фаягөл, ничекләр җитешәсең син барысына да? — диде Миңлежамал. Фаягөлнең бәйләгән саен күпереп барган мамык шәлен сыйпап.— Кара инде минекен, кичә башлаган оекбаш — куныычын бәйләгән көе, бүген бер күзәнәк тә алганым юк әле. Әллә нәрсә эшләдем бу арада, кичтән кичлегем юк, иртәгесен тора алмыйм.

— Әй, җитешмәгән җире җитешмәгән көе тора инде аның, Миңлежамал,— диде Фаягөл.— Әле, бу шәл бәйләүләр белән, бер эш тә карый алмыйм. Иртән торып, балаларны мәктәпкә озатканнан соң, эшнең кайсы башыннан тотынырга белми аптырап бетәм. Җитмәсә, тәрәзә артында бригадиры кычкыра башлый. Җәй көне эшләп җан чыга, кыш көненде ял булырмы дисең — кая ул! Әле өйдә генә күпме! Мал карыйсы, ипи изәсе, суга барасы... Сөйли китсәң, тавык та чүпләп бетерә алмас. «Уф» дип, бер кычкырып куям да, ятам да йоклыйм. Кич буе шәл бәйләгәч, йокы кала бит, көне буе кеше түгел аннары.

— Минем дә шулай, Фаягөл,— диде Миңлежамал.— Гел генә йокым килеп йөрим. Тамагым ачса — хәлем бетә, тамагым туйса — йокым килә...

Болар кырыена Фәгыйлә, Нәсимә, тагын берничә хатын килеп утырды. Болары — кичәгеләр. Болар — фал ачтыручылар түгел. Болар — тыңлаучылар. Инде бу хатыннарга, язга чаклы сөйләп, кышның озын төннәрен уздырырга ризык булды. Мин өебезгә җыелып килгән бу апаларның сүзләрен тыңласам да тыңладым, тыңламасам да тыңладым. Яратам мин өй тулып кеше килгәнне. Дәресләрне әзерләп бетерсәм дә, тәрәзә төбеннән һаман китмәдем әле. Тәрәзә пыяласына салкын бизәкләп ясаган «урман»да минем күзләр. Болай игътибар белән караганым юк иде, бигрәк матур икән бу рәсем! Киң яфраклы агачлар берсе өстенә икенчесе авып төшкән, алар бәскә төренгән әкият урманын хәтерләтә... Мин хыялым белән әкият урманына кереп киттем... Агачлар арасына тырнагым белән сызып юл салдым...

Шулвакыт, кояштай балкып, үз өенә кергән кебек, бер генә дә тартынып тормыйча, кәрә керешкә пәлтә сәдәфләрен җибәреп, Мәликә апа килеп керде...

## 9

Хатыннар килмәс дигәннәр иде аны. Алар инде кемнең киләсен, кемнең килмәсен күптән юрап куйганнар иде. Килде Мәликә. Нишләп килмәсен ул? Кешеләргә кирәк бәхет аңа да кирәк түгелмени? Аңа башкаларга караганда да кирәгрәк әле ул. Сугышка ирен озатып, кулына кара хәбәр алган бер ул гына булмаса да, Мәликәнең мәхәббәткә тансык йөрәге башкаларныкына караганда ярсурак булып чыкты.

Мәликә килеп кергәч, хатыннар утырган почмакта чыж-пыш китте. Аларга бер генә дә исе китмәде Мәликәнең. Кеше сүзенә «аһ» итә торган булса, Мәликә дә булмас иде ул. Хатыннар ягына кызык өчен генә булса да борылып карамады Мәликә. Гәүдәсе зифа, карашы горур, ә елмаюы... Әйтерсең, тумыштан ук елмаеп туган. Бер генә мизгелгә дә туктамый елмаюдан. Аның ачык чыраен күреп, тәмле сүзен ишетеп, ирләр генә түгел, хатын-кызлар да эреп китәләр. Аңа ачу саклаган берәр кеше бар микән авылда? Юктыр. «Без бит әле, иске булсак та, постау кисәге!» — дип йөргән Мәликәнең әйтсә дә хакы бар. Курчактай киенгән ул бүген. Башында — чуклы ефәк шәл... Элекке заманнардан калган шәл. Күпләрнең сандыгын ачтырган, ахры, бу фалчы. Мәликәдәге шәл авылда башка беркемдә дә юк. Аңда гына. Үзе җиңнәренә чаклы кама куеп тегелгән киң якалы пәлтә кигән. Үзе әйтмешли, постау пәлтә. Иске дип тә әйтерлек түгел. Әллә ничә елга бер мәртәбә генә чыгадыр сандыктан. Әллә йөзенә иннек-кершән дә тигән инде... Юктыр, Мәликә аларсыз да матур. Кайберәүләр кебек, кача-поса, ике бит очын чеметеп йөргәне юк. Бит урталары болай да алсуланып тора. Мәликә турында, миләүшә чәчәге белән ләйсән яңгыр тамчылары кушып, ислемай ясый дигәннәре дөрес, ахры. Ул керүгә, язгы урманда гына була торган миләүшә исе таралды өйгә.

Мәликә, барысы белән дә исәнләште дә, фалчы янындагы утыргычка килеп утырды.

— Җүнкәчләрем! Утырасызмы?—диде ул, ниһаять, кул эшләре белән утырган хатыннар ягына җиңелчә генә күз сирпеп.—Миңа да бер җыелып төшегез әле шулай!

— Син кешесез тормыйсың бит, Мәликә апа...—диде Фаягөл төче тавыш белән.—Әле монтер егетләр синдә, әле зелпе җыючылар.

— Миндә монтерларга да урын җитәрлек, сезгә дә. Күңелең киң булсын.

— Синең күңелеңә, Мәликә апа, бөтен авыл сыя инде, анысын беләбез,—диде Фаягөл, төче тавышына азрак зәһәр дә өстәп.

— Ярар инде, кызлар... Алай каты төрттермәгез,—диде хатыннарның кайсыдыр.

Фаягөл Миңлеҗамалның колагына нидер пышылдады да, тегесе пырхылдап көлеп җибәрде.

— Фаягөл! Ничә кешенең язмышы керде шәлеңә?—дип сорады Мәликә, хатыннарның көнләшүле-мыскыллы карашларын күрмәмешкә салышып.

— Керде инде монда...—диде Фаягөл, бәйли торган шәлен лампа каршысына күтәреп. Шәл артыннан аның:—Синең язмыштан читен бәйләрмен, Мәликә апа,—дигән тавышы ишетелде. Хатыннар тагын бер көлешеп алдылар, бер-берсенә төртеп куйдылар.

— Уф, җүнкәчем, телең!—диде Мәликә апа.

— Синнән өйрәнәбез бит, Мәликә апа!

— Миннән өйрәнмә, җүнкәчем! Минем көнгә ходай калдырмасын.

Хатыннар шып итте. Берсенең дә аның көненә каласы килми. Тик нәрсә булган аның көненә? Типтереп яши ләбаса! Бәхет сорап күршеләргә кергәне юк. Үзенеке үзенә җиткән. Җитмәсә, китереп бирәләр. Артып та китә кайчакта. Артып киткәне сүз булып авылда йөри. «Сөйләсеннәр! Арыгач туктарлар әле,—ди Мәликә.—Тел сөйләр өчен бирелгән ул. Әгәр дә мин булмасам, бик күңелсез булыр иде авылда».

Фалчы әлегә дәшми. Мәликә апаның әйтеп бетергәнен көтә. Кем килеп кергәнен ул шунда ук сизенде. Күзе күрмәгәнгә гомере буе үкенеп йөри торгандыр бу фалчы. Ә менә Мәликә апаны бер күреп алып, яңадан сукырайса да, гомерендә дә үкенмәс иде. Әгәр дә күзе күрсә, шушындый матур хатынның ни өчен болай ходай күрсәтмәслек тормышта яшәгәнен аңлап та бетмәс иде. Тик фалчы бит ул. Ул аңлый. Күзе күрмәсә дә, фалчылыгы күрсәтә аңа.

— Абый, тыңлама алар сүзен,—диде Мәликә.—Китабыңны ачып кына әйт әле: әйбәт кешеме мин, начар кешеме?

— Исемең?

— Мәликә...

— Исемеңнең мәгънәсен беләсеңме?

— Әй, абый җаным! Кая инде безгә! Исме-әгъзамнарны ишеткәнем булса да, укыганым юк шул!

— Фәрештә дигән сүз ул...

Болай да колакларын торгызып утырган хатыннар, фалның шулай башлануын ишетеп, кул эшләрен ташлап, күзләрен боларга текәделәр.

«Нинди сихер микән бу Мәликәдә? Шушы сукырны да үзенеке итте бит!»

— Фәрештәдәй булып туган идек, тормыш әйләндерде шайтанга!—диде Мәликә.

Фалчы китабын ачты. Мәликәгә кирәк җирен бик тиз тапты ул.

— Син бөтен кешеләргә дә яхшылык белән ярарга тырышасың икән. Тик кешеләр синең бу яхшылыгыңны аңламыйлар...

— Аңламыйлар, җүнкәч, аңламыйлар, абый җаным! Кайлардан килеп чыктың син безнең якларга! Бик дөрес әйтә дигәч, ышанмаган идем, ышаныч бирдең бит әле бу сүзләрең белән.

— Синең миңа ышанмаганлыгыңны мин инде син монда килгәнче үк белгән идем,—диде фалчы.—Күңеле белән ышанмаган кешеләргә фал ачмыйм мин. Тик сиңа ачам. Чөнки синең күңелеңдә усаллык, мәкер, көнчелек юк. Якты синең күңелең... Үзе фал китабы кебек...

— Күңелем фал китабы кебек булса да, иртәгәге көнемнең дә ничек башланып, ничек бетәсен белмим мин. Бер башлагач, әйтеп бир инде, абый җаным, теге монтерлар озак торырлар микән безнең авылда?

— Аларның юлы бу китапта түгел... Биредә синең язмыш кына. Тик синең язмыш бер дә алар белән бәйле күренми...

— Үземә генә сөйлә әле шул китабыңның сүзләрен, җүнкәч,—диде Мәликә, фалчының янына ук күчеп утырып. Минем күңелдәгене әйтеп бирә башласаң... күземне дә ачырмаслар аннары... Үзем шундый булсам да, күңелем тулы сагыш-хәсрәт минем. Ахирәтем бул әле, абый җаным...

Ачы-ачы сүзләр әйткәләсәләр дә, Мәликәне яраталар авылда. Ни өчен дисезме? Мин дә шулай диган идем элек. Ә хәзер белдем ни өчен ратканнарын. Авылның ирләре генә түгел, хәтта хатын-кызлары да, үзләрендә булмаган сихри дәрт бөркелеп торганга, көнләшү катыш хөрмәт итәләр аны. Аннан соң Мәликәнең ихласлыгы яраттыра. Үзендә бер кич уздырып чыккан ирләрнең бала-чагаларын, хатынын, әти-әнисен чын-чынлап ярата башлый Мәликә. Үзе әйтмешли, өе турыннан узган барлык ирләргә дә гашыйк ул. Сөйләгән кешеләренә әйткәне бар икән аның: «Ул ирләр бит миңа бәйрәмгә килгән кебек киләләр. Әгәр өйләрендә дә миндәге кебек бәйрәм булса, килмәсләр иде. Ә гомер буе башкаларга бәйрәм ясаган кешегә бик авыр яшәве, шуны белмиләр. Шушы ярату булмаса, ничек итеп яшәргә кирәк бу дөньяда. Шул яраттыру яшәтә дә мине».

Әллә инде сөйләгән, әллә сөйләмәгән бу сүзләрне... Кем белсен. Бәлки, уйлап чыгарганнардыр?

— Әллә үземә генә төшәсеңме, абый җүнкәч!— диде Мәликә апа, өзгәләнеп.— Төне буе укыр идек китабыңны. Бәхет дигән сүз һаман чыкмады бит әле... Өметеңне өзмә, дисең... Өмете өзелми аның, бәхетсезлектән үзәк өзелә... Әнә, алар минем бәхеткә көнләшеп утыралар. Көнләшәсез бит, кызлар, көнләшәсез? Оясы туздырылган тол хатыннан көнләшмәгез, кызлар... Тормышымны башлап җибәргәндә, әллә мин бүгенге бәхетемне күз алдымда тоттыммы? Бүгенге бәхетемне юрадыммы? Әгәр дә бу тормыш мин уйлаганча барып чыкса, барыгыздан да бәхетле булачагымны мин ул вакытта ук белә идем. Көнләшмәгез, кызлар, бәхетегезне сакларга өйрәнегез. Мин әле кеше өлешеннән төшкән валчыкларны да бәхет бөртекләре дип йөрим бит. Алдыйм үземне... Башны ташка бәреп булмый икән... җан изге...

Мәликәнең күзеннән аккан яшьләре бите буйлап агып төште дә, алсу иреннәре өстендә тукталып калды.

— Абый җаным, әллә алып китимме үземә генә...— диде Мәликә яшь аралаш елмаеп.— Ә-ә, монда көтеп утыручылар да бар икән... Рәхмәт, абый, сиңа, гомердә дә онытмам,— диде дә, кояштай елмаеп кергән Мәликә коелып-елап чыгып китте.

## 10

Минем әле һаман тәрәзә төбеннән киткәнем юк. Өйдәгеләргә аркамны куеп, суык бизәп ясаган урман эчендә йөрим кебек. Бармакларым белән эретеп, тәрәзәдәге киң «Яфраклы» агачларга «алмалар» эләргә тотындым. Хәзер инде кулымның туңуы беткән, тәрәзә салкынлыгыннан аларга рәхәт кенә... Бер «алма», ике «алма»...

Мәликә апа чыгып киткәч, аның урынына, кулына бер төргәк хатлар тотып, Гайнижамал җиңәчәй килеп утырды.

— Улымның хатлары,— диде Гайнижамал җиңәчәй, кабатлап. Ә менә боларын командиры язган. Бик әйбәт хезмәт итә, шундый ул үстергәнегез өчен рәхмәт сезгә, дигән. Тик менә, күптәннән инде, улымның хаты килгәне юк. Кайчан кайтыр микән, әйтеп кенә бирсәң иде...— Гайнижамал җиңәчәй кабалана-кабалана, хатларны төргәге белән фалчының кулына тоттырды. Фалчы нигәдер җиңәчәйнең исемен дә, улының исемен дә сорап тормады бу юлы. Китабын да ачмады. Хатларны кире җиңәчәйгә бирде дә:

— Улыңның юлы бик якында, апа... юлга чыккан,— диде.— Иртәгә булмаса да, күп тормас, кайтып җитәр...

Фалчы шушы сүзләрне әйткәндә, тәрәзәдәге урманым «алмалар» белән тулган иде инде. Кинәт... куе зәңгәр генә түгел инде (урамга төн караңгылыгы төшкән иде) кап-кара «алмам»ның берсендә нидер ялтырап китте. Абау! Нәрсә булды бу!? Мин ул «алма»га тыным белән өрдем дә, шул арада бозлана башлаган тәрәзә пыяласын эреттем... «Алма»ның уртасыннан, чекерәеп, зәп-зәңгәр күз карап тора иде миңа. «Әни!» — дип кычкырып җибәрүемне сизми дә калдым. Тик башкасын хәтерләмим. Әллә куркудан, әллә чирләп китүдән аңымны югалтып, тәрәзә төбеннән идәнгә егылып төшкәнмен... Күтәреп урынга салгач та, күпмедер һушыма килә алмый ятканмын. Күземне ачканда, янымда куркынган йөзле әни, фалчы абый, аның хатыны Ноябрина апа утыра иде. Ноябрина апа калтыранган куллары белән маңгаемны сыйпады.

— Ут яна...— диде ул, пышылдап.

Өйдә башка кеше калмаган, дисәм... Өйнең уртасында, аякларын киң җәеп басып, зәп-зәңгәр күзләре белән барыбызны да йотарга әзерләнгәндәй, Кара кул Хәбри тора иде. Менә кем күзләре булган икән тәрәзәдә!...

— Районнан килгән полномоченныйларны кертергә берсе дә риза түгел, пнимаетели! Ә монда җыен килмешәккә урын табалар!

— Хәбри балакаем, Хәбри балакаем...— җиңәчәй дә чыгып китмәгән икән, бу аның тавышы.— Алла бәндәләре алар, мосафирлар...

— Беләбез нинди алла бәндәләре икәнен! Налог түләми-нитми генә халык сыртын кимереп йөрүче килмешәкләр алар!

— Түгел, Хәбри балакаем, түгел, гөнаһлы булма,— диде Гайниҗамал җиңәчәй.— Әнә бит, улың кайта, диде миңа!

— Кайтмый кая барсын!— дип акырды Кара кул.— Әллә сугышка озаткан идеңме, ә?

Гайниҗамал җиңәчәй рәнҗеп авызын йомды да, улының хатларын кочагына алды.

— Син хөкүмәт кешесе инде, без надан халык.... ни әйтсәң дә, синеке дөрес...— диде ул, чыгып китәр алдыннан.

Каты итеп ишек ябылуга, мин тагы караңгылыкка чумдым. Әллә төштә, әллә өндә булды... Баздан ишетелгәндәй, гөрелдәп чыккан тавышлар белән төне буе саташып чыктым.

— Кунаклар!— диде Хәбринең мыскыллы тавышы. Беләбез аларның нинди кунаклар икәнен... Бу ниткән законсызлык бу, пнимаетели! Налог, заем дисәң, акчалары юк, ә боларга табалар! Мосафирлар, имеш! Районда алар артыннан күптән күзәтү билгеләнгән инде! Шпионнар алар! Немец шпионнары. Фал ачарга түгел, мәгълүмат җыярга чыккан алар!..

— Кычкырма, Хәбри...— диде фалчы абый тавышы.— Документлар чиста минем. Танылың бит син мине, нигә һаман кычкырасың... Куркытма кешеләрне... Балалар йоклый...

— Син?!— диде Хәбринең гыжлаган тавышы.

— Үлде дип сөенгән идеңме?! Үлмәдем мин ул чакта... Син бит ул вакытта миңа ярдәм итә ала идең... Куркак җан син... Таптылар мине забойдан, өч көн үткәч казып чыгардылар... Шуны гына әйт әле, Сәгыйдәне нигә дип алып киттең син шул чакта?

— Анысы минем эш! Әллә миннән сорау алмакчы буласыңмы?— диде Хәбри тавышы.

— Калсын... тик бәхетле генә булсын... кешегә бәхет бирүче кеше син түгел шул... Авылдашларыңның фалында да син күрсәткән җәберлекләр... Берсенә дә синең зәхмәтең тими калмаган.

— Мин сезне егерме дүрт сәгатьтә урнаштырыр урын табармын!— дип кычкырды Хәбри.

— Табасыңны беләм... бер сәгатьтә дә табарсың, синең кул озын... Тик көчәнмә, син рәхәт яшәгән сугыш заманалары узды инде... Телисеңме, фал ачам үзеңә? Теләмисең, әлбәттә... Тик, барыбер тыңла, бәлки үлем белән тартышканда исеңә төшәр...

— Син миннән алданрак үләрсең әле, сукыр тычкан!— диде Хәбри тавышы.

— Әлбәттә, үләрмен, тик бит син дә дөньяга гомерлеккә килмәгән. Халык өстендә селтәнгән кара йодрыкка төйнәп булмый ул гомерне... Курыкмыйм бит мин синнән. Ә син миннән куркасың. Миннән курыкма син, уттан курык. Әҗәлең уттан синең... уттан... Картаеп, гөнаһларыңа тәүбә китереп торырга булмаячак синең... Үлгәндә дә, үлгәч тә утта син... Тәмуг уты фани дөньяда чакта ук башланачак синең өчен... Утта...

— ...

— Ут яна бит бу бала...— монысы әни тавышы.— Нишләргә соң? Һаман саташа...

— Каргышың карга башына! Иртәгә үк сыпырт авылдан, атлы милиция чакырткачны!— диде Хәбри тавышы.

Кемдер елый. Ә нигә соң минем күзләремдә дә яшь. Бер генә сүз әйтергә дә авызым ачылмый. Кем елый соң анда?..

— Елама, Ноябрина, елама,— бу бит фалчы абый тавышы.— Шушы очрашуны сизеп чыкканмын мин юлга. Ә хәзер кайтып китсәк тә була. Кем белә, атлы милиция җибәрсә, немец шпионнары, дип ябып та куярлар... Ә без синең белән немецчә бер сүз дә белмибез... Елама...

Мин әле тагын өч көн башымны да күтәрә алмый, саташып ятканмын. Мин чирдән терелеп торып утырганда, фалчылар бездә юк иде инде. Алар икенче көнне үк киткәннәр безнең авылдан. Үзләре генә китмәгәннәр — бу хәбәрне ишеткәч, авыл халкы «аһ!» иткән — аларга ияреп, Хәбринең хатыны Сәгыйдә дә киткән авылдан.

Аларны озатып калмасам да, алар һаман минем күз алдымда. Ишегалдына чыгып, бакча артындагы урманга карагач, мин һәрвакыт алар турында

уйлыйм. Күз камаштырып җемелдәгән кар өстеннән, бәскә төрелгән ап-ак урманга таба өч кеше баралар сыман... Икесе алда, бер-берсенә ябышып атлыйлар... Ә өченчесе артта... Куып җитәрме ул аларны? Белмим. Фалчы абыйның кеме иде ул Кара Кул Хәбри хатыны Сәгыйдә? Бу әле миңа сер, һаман да ачылмаган сер...

Күпме еллар үтте инде бу вакыйгаларга... Күптән оныттылар инде ул фалчылар турында. Авылда да, авылдашларда да үзгәрешләр күп соңгы елларда. Бернечә еллар, «мин туып килүче пролетариат» дип йөри торгач, Миңлебай абый бу сүзләргә үзе дә ышанды бугай, бөтен оясын алып, тәки ташлап китте авылны. Еракка китмәде — район үзәгендә генә, тик барыбер авылда түгел. Фәгыйлә апа да кабат кияүгә чыкмады. Малайларын үстереп кеше итте. Тормышы ничек кенә авыр булса да, һаман җорлыгын ташламый ул. «Шәһәргә» барып урнашкан Миңлебай белән очрашуын сөйләде беркөнне:

— Танымассың син аны хәзер. Өстендә — парочка, аягында — елтырап торган күн итек. Сакал-мыек чиста итеп кырылган. Аны күрсәң, бер дә «шыр» димәссең. Мине күргәч, шундый сөенде, аркама аскан ун буханка ипи, кулымдагы ике төенчегем белән, «эһ» тә итми күтәреп алды да, зыр-зыр әйләндерә, мескенкәем! «Кит, кит, ташла!» — дим, башлар әйләнеп китте, каһәр! «Авыл кешеләре сагындырган бу шәһәрдә яшәп!» — дигән була. «Кайт, мин әйтәм, кунакка булса да кайт!» «Кайтабыз, кайтабыз, сабан туйлары гына җитсен әле!» — диген булды. «Әйдә әле, үзең безгә кунакка!» — дип, кыстый башлады. «Әй, авылдаш, ди, хәзер буйнийдә — мал суя торган җирдә эшлим! — ди. — Чиләк тутырып бушлай эчәгесен бирәләр, пешерәбез казан тутырып аш, — ди. — Ипине кукрәккә терәп кисәбез, рәхәтлеккә чыктык. Бездән дә бәхетле кеше дөньяда берәү дә юк, — ди. — Миңлежамал ашханәгә эшкә керде. Үз гомеремдә күрмәгән савыт-сабаларны юа хәзер. Балалар да үсте. Бер кызым кибеттә эшли, икенчесе — кулинариядә. Берсенең кулы — майда, икенчесенеке — маргаринда, — ди. — Бик бай яшибез, әйдә әле, авылдаш, кунак булып чыгарсың», — ди. Әйберләрем авыр, башка вакыт керермен, дип чүт котылдым.

Айсылуттиләр дә бөтен гаиләләре белән Себер якларына чыгып киттеләр. Кызлары Сания алып китте аларны. Авылда калмыйсыз, интеккән тормышыгыз турында хатлардан укып, йөрәкләребезне бозасыбыз юк, дигән ул. Тормышлар да җайлана башлаган иде югыйсә... Кара Кул Хәбриләр заманы узган иде... Урамыбызның ятимлеге, авылыбызның кителә баруы алардан башланды. Шул китүдән бер генә тапкыр да кайтмады Айсылутти. Урманнарны да, басуларны да кабат күрә алмады. Сагынуларга ничек чыдады икән, дим хәзер. Сагына башласа, төрмәләрдә узган авыр тормышын күз алдына китерде микән? Балалары да кайтмый. Әти-әниләренең каберә яннарында булгач, нишләп кайтсыннар...

Ә Хәбри... Мин авырып ятканда, әллә төштә, әллә өндә ишетелгән фалчының сүзләре дөрескә чыкты...

Фалчылар килеп киткән елны ук Хәбрине авыл советы рәислегеннән алдылар. Безнең авыл белән күрше авылга бер авыл советы ясадылар да, Хәбрине үзебезнең авылда бригадир итеп калдырдылар. Тик бригадирлыкны алып бара алмады Кара Кул. Үзе хакимлек иткән заманнарда, бигрәк тә сугыш вакытында һәр көн саен тенту белән кереп, эштән кайтучы хатыннарның чабата олтыраклары астына хәтле тикшереп, үзеннән тәмам гайрәтен чиктергән Хәбрине халык хөрмәт итмәде. Хәбринең элекке «авторитетын» искә алып, халык белән эшләргә тагын бер мөмкинлек бирде җитәкчеләр. Хәбрине ферма мөдире итеп куйдылар. Тик биредә дә рәте чыкмады эшенең. Бозаулары үлде, сыерлары сөт бирмәде, сарыкларына бүре ияләште. Бу хәлгә үзе дә аптырады Хәбри. Тик төпкә җигелеп тарту аның өчен түгел иде. Әнә шул эшендә йөргәндә маллардан тимерәү чире дә йоктырды ул.

Врачларга каралып күп йөргәннән соң, аның чирен электр тогы белән дәваларга дигәннәр. Сукыр фалчының сүзләре дөрескә чыкты. Шулай дәвалаган вакытта ток бәреп үтерген Хәбрине. Әллә карап житкермәгәннәр, әллә язмыш... Фалчы әйткән ут шул булды, күрәсең...

Фалчыларның безнең якларга яңадан килеп чыкканы булмады. Хәбри хатыны Сәгыйдә апа да авылга әйләнеп кайтмады.

Менә шулар. Балачагымның серле һәм гыйбрәтле бу вакыйгасы, фалчылардан калган истәлек булып, һаман да күңелемдә тора минем.

Ә без үзебез дә ТОРМЫШ дигән серле карурманда үз сукмакларын, үз язмышларын эзләүче гомерлек юлчылар түгелмени?

# ШИГЪРИЯТ

## Рәфикъ Юныс

### Качалар күселәр

*Эмигрант сүзе*

«Күседәй качасыз батасы корабтан!..»

Күселәр, әйе, хак, качалар иң алдан.
Күтәргәдер, бәлки, качканны капитан?
Ә бәлки күселәр тиештер батарга?

Әллә соң корабны күселәр «корды»мы?
Күселәр бардымы иң өстә, юл карап?

Кемнәр ул бакырды: «Иң хак юл — безнең юл!»
Ә кемнәр лаф орды:
«Һич батмас бу кораб, без моңа инаныйк!»
Ышандык, утырдык. Булган ул «Титаник»[1]...
Исерек капитан, лаякыл механик.
Әйткәндә аеклар, бармыйк, дип, ул якка,
Кемнәр ул чаңлатып ордылар яңакка?

Ошамый кемгәдер: качалар күселәр!
Гаепле — күселәр! Гаепле — күршеләр!
Гаепле...

Качмаслар — сез тагын куегыз зынҗырлап...
Кемгәдер ошыйдыр бату да җыр җырлап?
Тик... никтер... батарга теләми күселәр...

---

1 «Титаник» — 1911 елда айсбергка бәрелеп баткан гигант кораб. Заманның иң камил корабы саналганга, бату ихтималы бөтенләй юк дип уйланылган.

---

Рәфикъ ЮНЫС (1943) — *шагыйрь, «Вакыт чылбыры», «Җирдә яшим», «Учтагы песнәк» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Әллә ачык калган
Үткән тәрәзәсе?
Әллә бүгенгенең
Бу бер күрәзәсе?—
Яшь чирәмдә яшел
Чаңгы бөгәлҗәсе.

## Алла сакласын

Уйладыммы мин — «кызыл авыз»ым
Бабайлар сүзен кабатласын:
— Ак күлмәк кигән кызым урамда.
Алла сакласын. Алла сакласын!

Ноль бер, ноль ике — телефоннар күп.
Телефоннар күп, ләкин... язмасын:
— Гаиләм, дөньям язмыш күзендә.
Алла сакласын, алла сакласын!..

Шартларга торган бомба бит
Җир-шар —
Кемдә генә юк аның чакмасы:
Аллага түгел, җенгә табынырсың —
Сакласын бары, бары сакласын...

## Ялган

Мескен ялган каян шундый
Тиңсез кодрәт ала соң?
Ул — таракан, сыттың — ул юк.
Килми тик пычранасы.

Фотосурәт ул: «яктырт» тик —
Ул үлә, кара көеп.

Юк, без әзер рәсемнәрне
Карыйбыз күзлек киеп.

Ул кәгазь, кәгазь нибары.
Ерт — ул җан бирә шунда.
Ертмыйбыз шул, акча кебек
Йөртәбез кулдан-кулга.

*

Таң. Кошлар сайрый.
Хәйран-хуш җаным
Һәрбер яфракның сулышын тоя.
Бу — якты дөнья!

Әле шатлыгы, әле кайгысы.
Йөрәк пәрдә күк җилфердәп торса,
Каршы искән җил сөртсә яшебез,
Бу — без дөньяда!
Бу — без яшибез!

*

Төшемдә мин — бүтән.
Гел җыенам, гел каядыр китәм.
Поезд көтәм, йә самолет көтәм.

Бер вазифа каулый-ашыктыра:
Бераз хәтәр һәм бик мавыктыргыч...

Өндә — гади-салмак, өндә — тыныч.
Язмышымнан әллә читләштемме?
Яшәлмичә кала нинди тормыш?

*

Савыктың бит, савыктың!
Тузмасын җан савытым.
Янсын, янсын, янсын әле
Җан дигән серле утым!

## Сак бул

Әйбәт булу җитми, сак бул! —
Дөнья дигән кухня тар.
Җан, Горурлык, Бәхет дигән
Иң кыйммәтле касәләрне
Төшереп ватуың бар.

## Качу

Безнең яшәү — бары көтү,
«Иртәгә»не «бүген» итү.
Ә «бүген» безгә кызыксыз —
Гүя бер тонык рәсем.

Киләчәккә качабыз без,
Ачып бу көн «төрмә»сен.
Яшәүдән качып яшә дә,
Һәм үлем дә килмәсен!

## Бәхет төсе

— Ал микән ул, гөл микән ул,
Бәхет дигәннәре?
— Бар микән ул? Нурлы йөзен
Берәр күргәннәрме?..

Күкләр гамьсез, биек иде,
Ә йолдызлар — сафлар.
Ай ул чаклар, каш җыерып
Бәхәсләшкән чаклар!

Еллар, кыйнап, таныттылар
Миңа бәхет төсен.
Бәхетсез түгел икәнсең —
Димәк, бәхетле син!

## Арыдым да уйландым

Уй тәме китте, сүз тәме.
Ялыктырды «ил гаме».
Башны җылы ташка куеп,
Бераз йоклап алсаң иде —
Бразилиядәме?

Ел исәбен, айны-көнне,
Кемлегеңне онытып,
Суданда йә Суринамда
Йөрсәң иде — су буенда
Кабырчыклар ыргытып.

# Сафуан Муллагалиев

## Милләтем

Син минеке,
Мин синеке, диеп
Сиңа әйтә алыр идемме —
Сагышыңа чумып йөзмәсәм мин,
Иңләп йөзгән кебек Иделне.
Синең өчен утка ыргылырга —
Корбан итәргә — мин үземне
Әзер, дия алыр идеммени,
Таң йөзенә төбәп күземне,—
Өметеңә чумып йөзмәсәм мин,
Иңләп йөзгән кебек Иделне...
И милләтем!

*

...Ә шулай да үтеп барабыз ич
Явыз Иваннарның чоңгылын.
Сөембикә манарасында ай —
Халкым, синең якты символың!
Өметебез Ае
Нурын сибә —
Күңелләрдә энҗе җемелди.
Айлы халык — бөек халык бит ул,
Бөекләр һич кайчан җиңелми,—
Җиңә генә!
Үзе хуҗа булып,
Үз җиренә басып атлый ул.
Аның үз ае бар,
Үз яктысы —
Һәрчак аны көтә якты юл!

Иңебездән бүген
Ялган тарих
Кара ташлар булып ишелә.
Бар халыклар белән тигез булыйк,
Һәр халыкка да без иш кенә!
Иңебездән таулар ишелә...

---

Сафуан МУЛЛАГАЛИЕВ (1927) — *шагыйрь, өч шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

## Вакыт җитте!

Үзем иккән иген — хәләл ризык,
Ризыгын ник алыйм берәүнең?
Миңа күптән пычак кайрап йөргән
Күршемә дә сәлам бирәмен:
Бүген — дошман,
Иртәгә дус булыр,
Акыллылар аңлый хатасын...
Нинди йөрәк белән ут күршеңә
Оялмыйча уклар атасың?

Син дә, халкым, һаман тыйнак булдың,
Галәм нуры тулы күңелең.
Җир йөзендә булган бар халыкка
Һавабызны, җирнең киңлеген
Киң күңелең белән тоеп бирдең,—
Бар халыкның танып тиңлеген!

Тарихыңнан искән
Гөлләр исе
Әйтеп тора синең кемлекне.
Вакыт җитте —
Үз хакыңны белеп,
Яшә, халкым, булып иркле!

## Чын йөзе ачылган кайбер «дус»ларга

Татарстан
Мөстәкыйльлек алгач,
Күпердеме, әчеп, җаныгыз?
«Киң Россия»
Тарайдымы әллә —
Кара корым бөркеп яндыгыз...

Сез идегез
Безгә таянучы
Фашист явы килгән көннәрдә.
Бүген нигә, «милләтчеләр», диеп,
Охшатасыз әллә кемнәргә?..

Рухыбызны безнең, телебезне
«Ден»егезме куша таптарга?
Инде ничә гасыр үреләсез
Юк итәргә теләп — татарга.

Ялгышасыз!
Якты таңда, көндә
Күкрәр өчен тудык — бетмибез...
Без тигезләр арасында тигез,
Бар халыклар белән бер тигез —
Бетмибез!

Ризван Хәмид

# АКТАМЫРЛАР ИЛЕ

ТРАГЕДИЯ-РЕКВИЕМ

Катнашалар:

**Фани дөнья персонажлары**

Мөштәри — йөзъяшәр карт
Кифая — аның карчыгы
Мәрәс — аларның өлкән улы
Фаягөл — Мәрәснең кызы
Борһан — Фаягөлнең ире
Гәрәй — аларның улы
Фәридә — күрше авыл кызы
Бәкер — чучка карауччы

**Мифик персонажлар**

Актай — Актамыр ыруы егете
Таңсылу — Актамыр ыруы кызы
Ядомир — Күктамыр ыруы егете
Тәңре — мәҗүсиләр алласы
Хода — мөселманнар алласы
Офыктагы шәүлә

## АВТОРДАН

Өч тау итәгендә урнашкан Аксак авылы турында соңгы хикәят бу. Ташландык ул хәзер. Күз алдыбызга китереп карыйк. Ике тау арасындагы үзән аша бормаланып төшкән иске юл авылның бердәнбер урамына килеп керә һәм, ишек-тәрәзәләренә аркылы такта кадакланган ятим йортларны артта калдырып, түбәндә Кыдаш елгасына терәлеп туктый: чөнки күпер күптән җимерек. Юлның икенче башы, аргы өченче тау яныннан үтеп, күк читенә бәйләп куелгандай, офыкка тоташа. Шул юл белән авылга килүчеләр-китүчеләр күренсә, бу тәэсир тагын да көчәя төшә: әйтерсең лә барлык кешеләр күк гөмбәзендә яшәүгә күчкәннәр дә, авылның хәлен белергә аска төшеп, кире үз дөньяларына менеп китәләр. Әмма авыл әлегә, ташландык булса да, шактый төзек йортлы: каралты-куралар кыйшаймаган-нитмәгән, хәтта капка баганаларына, өй почмакларына куелган кызыл йолдызлар да исән — болары сугышта ятып калганнар истәлегенә куелган иде. Тик хәзер инде илне дошман явыннан коткаручыларның туган йорт-нигезләрен саклап торучы нәсел-кардәшләре дә авылда калмады. Бары тик бер генә йортның ишек-тәрәзәләре такта белән аркылы-торкылы кадакланмаган: монда авылның соңгы кешеләре — Мөштәри карт белән аның карчыгы Кифая яши. Ә авылның табигатенә ис-акылың китәр: Кыдаш буе тугайлары, тау сыртлары һәм хәтта авыл урамы да яшеллеккә күмелгән. Кайда да урман-куаклыклар, мең төрле чәчәк һәм хозурлык. Табигать кочагы нәкъ әнә шундый була торгандыр! Уң яктагы тауның аргы итәгендә каралып төсмерләнгән абзарлардагы чучкаларны санамаганда, тирә-якта бүтән бер тереклек иясе дә калмаган. Ни җитмәде икән монда кешеләргә?! Эзләсәң дә таба алмаслык гүзәл урын ич бу яшәр өчен! Ә Мөштәри карт белән Кифая карчык нишләп үзләре генә торып калганнар соң? Нәрсә мәҗбүр иткән аларны ирекле көннән ялгыз инте-

гергә?! Бу ташландык авылга килеп чыккан һәр кешедә әнә шундый сораулар тумый калмый. Тик аз сүзле карт белән карчык теләсә кем каршында авыз сагызы чәйнәргә ашыкмыйлар иде, ахрысы. Аларның ялгыз яшәве читләр өчен һаман да сер булып кала килде. Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзең — ботак тишеге, диләр ич!

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### Беренче күренеш

**Җәй башы. Кояшлы эссе иртә. Тынлык.**

**Авыл урамына керә торган юлның ике ягында җәйрәп яткан таулар өстендә бүген иртән ике кабер казылган. Аларны, ачы таңнан торып, Мөштәри карт казып куйган. Бу минутта ул үзе дә шул каберләрнең берсе янында уйланып утыра.**

**Мөштәри картның төгәл яшен, кыяфәтенә карап, тәгаен генә әйтеп булмый: аңа йөзне дә бирергә була, артыгракны да. Ул авыр эштән бик алҗыган, сулышы киселә, куллары сизелеп калтырый. Әмма карт үз-үзеннән бик канәгать күренә. Чөнки бүгенге эше аның аз булмаганга охшый. Каберләр янында артларына язулы фанералар беркетелгән ике урындык тора. Берсенә: «Авылның матурлыгы моннан әйбәтрәк күренә», икенчесенә — «Түбәндә элек Аксак авылы иде. 1913—1987 еллар» дип эре хәрефләр белән язылган. Кабер читендәге балчык өемнәренә дә язулы фанералар беркетелгән агач казыклар кадап куелган. Сул таудагы кабер чокыры кырыендагы фанерага: «Бүреханова Кифая Сәетхуҗа кызы. 12 гыйнвар 1897 ел — 7 июнь 1987 ел» дип, ә Мөштәри картның үзе янындагысына: «Бүреханов Мөштәри Котлыби улы. Якынча 1887 ел — 7 июнь 1987 ел», — дип язылган.**

**Мөштәри карт кабер чокырына текәлеп карап тора һәм, авыр гына кузгалып, урындыкка барып утыра. Астагы туган авылын, Кыдаш елгасы буйларын, аның артында җәйрәп яткан болын-кырларны, бөтен тирә-юньне карап чыга. Менә аның күз карашын нидер җәлеп итә.**

Мөштәри *(елмаеп куя һәм янында гына торган кешегә дәшкәндәй йомшак тавыш белән)*. Ипләп, аяк астыңда ни барын карап атла, корт чаккыры карчык... Тфү-тфү, авырлыгым егылган урынымда калсын, диген... Ә ул, тибеп, таштан үч ала... Их, карчык, карчык... Синең аякларың астында да түмгәкләр күбәя башлады соңгы вакытта... *(Шулай ук әкрен генә дәшеп, кул изи.)* Монда мин әле, анасы.

Кифая *(түбәннән ачы тавыш белән кычкыра)*. Нишләп җилгә кабарган ябалак кебек турсаеп утырасың анда, җен карты?! Кая олакты икән бу ачы таңнан дисәм!.. Төш, чәең суына дим! Гел артыңнан эзләп чыгарга кирәк!

Мөштәри *(кузгалмыйча)*. Мин аннан балта сорыйм — ул миңа чөшле суза... *(Мин, дип кабат кул изи.)* Көттермә, ике әйтергә яратмаганымны беләсең... Монда мин.

Кифая *(үзе һаман күренми)*. Нәрсә диден?! Алланың үги улы түгелсеңдер ич, утырма анда кояш ашап, төш тизрәк, дим! Йөзгә җитеп, акылга туймадың инде һаман!..

**Ниһаять, Кифая карчык ике тау арасына килеп чыга. Ул да тышкы кыяфәте белән картыннан артык аерылып тормый: бергә озын гомер кичергән ир белән хатын чынлап та бер-берсенә бик нык охшый башлыйлар бит. Мөштәри белән Кифая да, табигатьнең шул законына буйсынып, күрәсең, читтән караганда агалы-сеңелле бертуганнар кебек булып беткәннәр. Кифая карчык озак яшәп, күп кенә тату гаиләләрдә күзәтелгәнчә, үз картын баласыткандай һәм шул ук вакытта бик үк артык үсенмичә, чәпченебрәк сөйләшә, ә карты аның кыланышын ярым шаяруга юрагандай кабул итә һәм шулай иткәнлегенә төрттеребрәк җавап бирә, ләкин беркайчан да карчыгына катгый бер чикне атлап үтәргә ирек бирми. Кифая карчыкларча вак-вак атлап, ире янына менеп җитә. Бала-чаганы шелтәләгәндәй.**

Җә, бүген ни уйлап чыгардың инде тагын?.. Тозлы су сипкәннәр, ахры, монда! Торасың да шушында менеп кунаклыйсың... *(Яңа чокылган каберга күзе төшеп, сүзен әйтеп бетерер-бетермәс авызын ачып катып кала. Якынрак килеп карамакчы булып, чокырга таба атлый һәм җиңелчә абынып куя.)* Вәт тибә раз!.. Нишләвең бу, дивана сыңары?!

Мөштәри. Ипләп, анасы, башың белән мәтәлеп төшмә — сиңа дигәне әнә теге күрше тау башында.

Кифая *(ирексездән күрше тауга таба борыла, ничек аңларга да белмичә, бер картына, бер янындагы кабер чокырына карый. Менә аның күзе казыктагы язуга төшә)*. Бәрәч! Кем үлгән?! Кемне күмәргә җыенасың монда?!

Мөштәри. Кемне булсын, үзебезне, анасы, үзебезне... Бүтән беркемне дә түгел. Язу таный беләсең.

Кифая *(фанерадагы язуны укый)*. «Бүреханов Мөштәри Котлыби улы...» Әнекәем!.. Булыр-булмас кочең белән

үзеңә үзең кабер казып йөрисең! Вәт тиле карт... Сәгатең җитсә, кабер казучылар булмас, дидеңмени?!

Мөштәри. Әсин укы, укы.

Кифая *(ары укый)*. «Якынча бер мең дә сигез йөз сиксән җиденче ел...» Кем әйтте сиңа туган җылыңны җакынча шул җыл дип?! *(Ире эндәшмәгәч, укуын дәвам итә.)* «Җиденче июнь, бер мең дә тугыз җөз сиксән җиде»... *(Кинәт картына кутәрелеп карый.)* Тәүбә әстәгъфирулла. Бүген була бит инде! Дөньяга сыймый башладыңмы әллә, карт җуләр?! *(Кинәт гайрәтләнеп казыкка ташлана.)* Шушы казыгың белән әйбәтләп сырт буеңны үләчәрмен!..

Мөштәри *(җитез генә карчыгын туктата)*. Чү, чү, анасы... Кагылма. *(Казыкны кире урынына кадап куя.)*

Кифая. Кеше әйтеп кеше ышанмас!.. Баш чүлмәгеңә таракан ояладымы әллә?.. Нинди эш була инде бу?!. Көпә-көндез саташа башлагансың! Башта ай буе тиле Будик шикелле теләсә кая әллә нинди тузга җазмаган җазулар куеп җаныма тидең! *(Урындыкка беркетелгән язуны күрсәтә.)* Артыңнан җөреп җыеп бетерә алмыйча җык буллам!

Мөштәри *(тыныч)*. Бутама, анасы, мондый язуны беренче тапкыр күрәсең.

Кифая. Җыясы ризыгыңның капчыгына пичәт сукмаганнардыр ич?!. Кеше көлдереп йөрисең!

Мөштәри. Дөрес, анысы. Пичәт сукмаганнар әлегә.

Кифая. Личитсә иттерергә кирәк сине! Болай булмый бу. Артыкка китә башлады. Җүләрләнеп, тау башларына төрле җазулар куеп җөрүең тагы бер хәл! Монысы инде бер күпергә дә сыймый!

Мөштәри. Әйтәсе сүзең беткән булса, хәзер мине тыныч кына тыңла, анасы.

Кифая *(картының гадәттән тыш йомшак сөйләшүе аны сагайта, ул инде бөтен нәрсәне аңлаган, ләкин һаман да иренең эшен шаяруга алырга тели)*. Картайган саен балалыгыңа ныграк кайта барасың, ахры, атасы! Кеше әйтеп, кеше ышанмас нәрсә бит бу! Әйдә, утырма монда ала каргадан хәбәр көтеп. *(Пыр тузып, китәргә кузгала.)*

Мөштәри. Ашыкмый тор, дидем, анасы...

Кифая *(туктамыйча гына башын борып)*. Туктамыйм да, тыңламыйм да.

Мөштәри. Анасы, дим!

Кифая *(ачуы чыгып)*. Ат кушасыңмы әллә?! Анасы да анасы!

Мөштәри *(шаяртуга бора)*. Яңа исем кушып торудан ни файда. Барыбер гүргә кергәч корт ашар.

Кифая *(кул селтәп)*. Кабыгыңа сыя алмый башлагансың бугай син! Үзең теләсә нишлә, тик мине борчыма! Минем чәем суына. Тамагың ачыккач, нибуч җөгереп төшеп җитәрсең!

Мөштәри *(катгый рәвештә)*. Хатын!

Кифая *(сискәнеп куя)*. Нигә шулкадәр кычкырасың?.. Җитмеш ел буе хатын булып җәшим инде мин синең белән. *(Шулай да туктый.)*

Мөштәри. Якын кил.

Кифая *(уфтанып)*. Күрәселәр бар икән... И алла! *(Ире янына кире килә.)* Җә, килдем.

Мөштәри *(җирдә аунап яткан көрәген алып, куллары белән таяна)*. Әйт әле миңа: начар яшәдекме без синең белән?

Кифая. Менә сиңа иске авыздан җаңа сүз!

Мөштәри. Боргаланмыйча гына турысын әйт.

Кифая. Җакшы җәшәмәсәк тә хәзер инде ни кыласың?! Туйлар узган, туннар тузган!

Мөштәри. Нәрсә, берәр рәнҗешең бармы әллә миңа?

Кифая. Җук инде, җук! Бер аягың гүргә керергә торганда башымны катырмачы, зинһар!

Мөштәри *(кабер чокырына күз кырые белән карап ала)*. Гүрне читтә калдырып тор әлегә. Инде килеп тагын менә моны әйт: ата туфрагын рәнҗетерлек берәр кылыгыбыз булдымы?

Кифая. Сул аягың белән тордыңмы әллә син бүген? Нигә миннән сорау аласың?! Үз башың үз җилкәңдә бар ич! Хәтереңне дә, ходайга шөкер, сыер яламаган.

Мөштәри. Хәләл ирең сораган икән, туры гына җавап бир.

Кифая. Күз өстендә каш кебек яшәдек диген дә бетер инде! Гомергә шапырынырга җаратгың. Кукраерга дисәң, бөтен нәселең белән... Айны да учлап тотар идегез дә, буегыз гына җитми!

Мөштәри *(кырыс)*. Телең дилбегәсен кыскарта төш. Алга киттек. Кемгә дә булса бурычлы булып калдыкмы?

Кифая. Кемгә бурычлы булып калыйк ди без? Тузга җазмаганны. Бер нәрсәне авызына алса, өзми дә, куймый да!

Мөштәри *(аны хәзер үзе төшкән буразнасыннан беркем дә читкә чыгара алмый)*. Балаларыбыз йөзебезгә кызыллык китерерлек берәр кырын эш эшләделәрме?

Кифая. Әйдә, әйдә, тезеп кит! Оныкларыңны да исеңә төшер бер рәттән! Агын әйткәч, күген дә әйт. Берсен дә онытып калдырма! Сүзең бетәме инде, җукмы? Бозау имезәсең...

Мөштәри. Ат түгел, куалама, анасы. Инде килеп, соңгы соравым: фани дөньябызда үзебез үкенерлек берәр нәрсәбез булдымы?

Кифая. Җитәр инде, атасы. Ни кылануың инде бу? Чәй суына дим ич мин сиңа! Ак койрыклысын кайнаттым бүген. Һинд чәен.

Мөштәри. Калдырып тор чәеңне. Я, җавабыңны көтәм.

Кифая *(картының ужәтлеге аны шиккә төшерә башлый)*. Бер сүсне талкыды инде! Эчең пошамы әллә синең? Баш

жарылып, күз чыкмаган ич! Газраил каршына бүген барырга әзерләнгәндәй кыланасың... Үзе дә килә ул әҗәл. Син ашыктырмасаң да!

Мөштәри. Нәкъ өстенә бастың, анасы. Әле һаман да төшенеп бетмәдеңмени?

Кифая *(ни әйтергә дә белми)*. Мине сантыйга санап кыланмачы! Бергән гомереңә бәрәкалла дип яшисе урында... Авырып-интеп җан бирә алмый интегеп яткан көне булса ни дияр идең! Җитте! Башка бер сүзеңне дә ишетәсем килми!

Мөштәри. Чәбәләнми генә тыңлап бетер, анасы. Эш шунда да шул. Җан бирәлми яткан көннең килүен көтәргә ярамый. Бала акылы кергән икән моңа, дип уйлыйсыңдыр. Ялгышасың, анасы. Яшәсен яшәдек, ашасын ашадык, дигәндәй. Үкенерлек калмады кебек... Вакытында фани дөнья белән исәп-хисапны өзү әйбәтрәк. Икебез дә берьюлы түшәккә егылсак нишләрбез? Аерым-аерым егылсак та... Янибызда балаларыбыз булса икенче хәл. Хәбәр итәргә дә кул астында кеше юк бит. Бер кашык суга тилмереп, кычкырып ятарбызмы? Яшәүдән туйганга йөриммени мин... Шикләнмә, ачык җир өстендә тилмереп яткырмаячакмын мин сине. Иң элек бөтенесен җиренә җиткереп, синең белән эшне бетереп куям. Ләхетеңне махсус иркен итеп ясадым. Тыгыз булмасын, рәхәтләнеп иркенләп ятсын, дидем. Тәк ышту карга-коштан чукытмам тәнеңне. Аннан соң инде үземә чират... *(Елмаеп куя)*. Минем өчен дә борчылма: делә фурмы өчен генә куелмаган әнә теге тирәү тактасы. Ишеләсе балчыкны тотып тора ул. Тибеп өлгерәм мин аны.

**Кифая карчык, гаҗәпләнүеннән шаккатып, артка таба чигенә.**

Кифая. Кара, чынлап такылдый бит бу... Әҗәл көтеп алалмый интексә ни әйтер идең... Инсафетдиннең кыланмышын кабатларга булдыңмы әллә?! Ул да, башта бер кешене дә санга сукмыйча, борыны белән болыт сукалап, кәпрәеп җөрдәҗөрдә дә, үлсәң гәүдәңне күмүче дә табылмас дия башлагач: икебез өчен бер кабер казыйм да атып үтерәм үзебезне, дип җуаткан, имеш, карчыгын. Син дә шуның сыңары булмакчы, ахры.

Мөштәри *(планын бик яхшылап уйлап, алдан аклап куйганлыгы сизелә)*. Бутама, анасы. Инсаф бер нәрсә, без икенче. Ул исән чагында аны күмәрлек кеше җитәрлек иде авылда. Ә без үлсәк, кем җирләр? Сайла алайса, кайсы әйбәтрәк соң: кипкән балык кебек булып беткәнче берәрсен көтем ятумы, әллә җиренә җиткереп әзерләнгән гүр куенында тынычлanумы? Әгәренки инде... нияң... духың җитмәсә — икенче эш. Яшереп торма, турысын әйт. Гаепләмәм. Гайре табигый нәрсә була бит, дисәң дә бер сүз дә әйтмәм. Һәркемнең үз бизмәне. Шулай да... Сиңа бер бик зур гозерем бар, анасы, балалар кайтса-нитсә, колакларына киртләп куй: сәгатең суккач, сине дә куршегә куйсыннар. Мин әзерләгән җиргә. Ә миңа үпкә саклама. Ялгызыңны ташлап китте, дип. Сиңа мәшәкать калдырасым килми. Соңгы сүзем шул. Бар. Инде хәзер-чаеңне яңартсаң да була. Мунчаңны әйбәтләп як. Бераздан мин дә төшеп җитәрмен. Шикләнмә, анасы, сәламәт акылдан әйттем мин сиңа бу сүзләрне.

Кифая *(елап җибәрә)*. Нигә дип болай җәфалыйсың син мине?! Гомерең буе какканың-сукканың җитмәдемени?!

Мөштәри. Ничек — какканым-сукканым?! Юк, анасы, килешмим мин синең бу сүзең белән. Чөнки нахак сүз бу. Тырнак белән дә чирткәнем булмады ич минем сиңа! Юкка балавыз сыкма!

Кифая *(ярсып)*. Алаймыни әле? Балавыз сыгаммы?!. Күрсәтим әле мин сиңа балавыз суын! *(Пыр тузып тубәнгә ташлана.)*

Мөштәри *(карчыгы күздән югалганчы артыннан карап тора, җиңелчә көрсенеп)*. Мылтыкны миннән яшерергә китүе инде моның үзенчә... Аны гаепләп булмый шул... Нишләмәк кирәк... Һәр нәрсәнең бер чиге була... Исең бар чакта... *(Әкрен генә авыз эченнән нидер көйли: җыр дияр идең, сүзләре аңлашылмый, дога дияр идең — моңы ул түгел.)* Көне әйбәт туры килде анысы... *(Тирә-ягына карана, якындагы урманга игътибар итә.)* Җиле дә бик талгын. Агач башларын гына тәсбих әйттерә...

Кифая *(аның уйларын бүлдереп, астан чырулап кычкыра)*. Мылтыкны кая куйдың, җен карты?!.

Мөштәри *(үз-үзенә сөйләнгәндәй)*. Эзлә, эзлә, карчык... Мылтык күптән монда шул инде ул. Син тапмаслык җирдә... *(Туфрак астыннан чупрәккә төрелгән мылтыкны ала һәм тузанын кага.)*

Кифая *(көтелмәгән җитезлек белән курше тауга менә һәм кабер чокыры янына баса)*. Мин әзер, атасы.

Мөштәри *(бераз аңышмый тора)*. Нәрсәгә — әзер?

Кифая. Аңламаган сарык кебек кыланмасана! Кулыңда бит мылтыгың! Кыдашка илтеп томырып дип куркып, яшереп куйган булгансың ич! Җитмеш җыл бергә гомер сөреп, белмиммени мин сине?! Ни уйлаганыңны да белеп тора идем мин! Син генә ул... сукыр булып яшәдең!

Мөштәри. Туктале, анасы...

Кифая. Туктыйсы-нитәсе җук! Кочаклашып, авыз үлчәшеп бәхилләшмикме тагын?! Җарамаган тагын безгә! Барыбер оҗмахка керәсебез түгел! Беребез гомер иткән хатынын үтерә, икенчебез — үзе теләп башын гүргә тыга! Каберләребезне монда казып бик дөрес иткәнсең син! Безнең кебекләрне борын-борыннан зиратка кертмәгәннәр. Мир җаткан җиргә.

Мөштәри *(аны карчыгының бер сүзе шаккатырган)*. Туктале, сукыр булып нишләдем мин?! Нәрсә әйтмәкче буласың син миңа моның белән?!

Кифая *(булдерә)*. Кеше келдермә, ичмасам! Тәнем генә яшәде ич минем синең белән. Гәүдәм генә. Ә җаным гел... *(Нидер күреп, үзен-үзе бүлдереп тынып кала.)*

**Чынлап та, шулвакыт ике калкулык аермасындагы юлның офыкка китеп югалган җиреннән машина кычкырткан тавыш ишетелә. Карт белән карчык сискәнеп, шул якка таба борылып карыйлар, әмма урыннарыннан кузгалмыйлар. Тынлык урнаша. Менә юл башында яшь егет белән кыз күренә: болар соңгы модача киенгән Гәрәй белән Фәридә. Ашыкмый гына түбән төшәләр.**

Фәридә *(сизелер-сизелмәс татарча акцент белән сөйләшә. Кифаяга ымлый)*. Гарри, глянь — на горке божий одуванчик стоит...

Гәрәй. Ша. Фрида... А вдруг она — моя пробабушка... Во всяком случае, она — из здешних аборигенов! Ба! У них кажись, самосуд идет. Видишь, напротив стоит старик с ружьем! Похоже, старик решил казнить свою старуху!

Фәридә. А за что? *(Елмая.)*

Гәрәй. А за что же мужья казнят своих жен? Только за измену! *(Көлә.)*

Фәридә. Скажешь тоже! *(Кеткелдәп куя.)*

**Картлар янына җиткәч, Кифаядан нидер сорарга теләгәндәй, әкренәяләр. Картлар, кемнәр булыр икән болар дигән сыман, эндәшми генә карап торалар.**

Гәрәй *(Мөштәригә)*. Привет, дедуля! Не нас ли встречаете?

**Мөштәри дәшми.**

Фәридә *(пышылдап)*. Ты спроси у него: где живет твой прадед?

Гәрәй. Не суетись, старуха... Дед, а дед! Ты не сможешь нам сказать, где живет... как его?.. Историк Муштари! Во как его зовут!

Мөштәри *(аларга музейдагы экспонатларны күргәндәй карап торганнан соң)*. Ә син үзең кем буласың, тәти егет?

Гәрәй *(аптырап, юлдаш кызына карый)*. А чего он спрашивает?

Фәридә. А ты сам кто такой, говорит.

Гәрәй *(көлеп җибәрә)*. Во дает старик! С норовом! Пойдем, сами с усами, обойдемся без провожатых. Зайдем вон в тот теремок, там узнаем.

Фәридә *(бераз уңайсызланып)*. Может, я дальше к себе потопаю, Гарри? До моей деревни уже недалеко осталось. Мама заждалась, наверно, я ей писала, что сегодня к вечеру буду... И неудобно както.

Гәрәй. Неудобно, знаешь, что бывает? Брюки через голову надевать! Идем, старуха, не бойся...

**Яшьләр аска үтәләр. Кифая белән Мөштәри юлга төшәләр.**

Кифая. Безгә кереп киттеләр бугай ич болар! Кемнәр соң алар?

Мөштәри. Мин каян белим? Әйтмәделәр бит. Ишетеп тордың.

Кифая *(чәпчеп китә)*. Сорарга телең юк идемени?! Телең калмас иде әле!

**Мөштәри җавап биреп өлгерми, Гәрәй белән Фәридә кабат күренә.**

Гәрәй *(кычкыра)*. В хибарке ни души. Трудно сказать что ли, старик? Муштари где обитает?

Кифая. Сез үзегез кем буласыз соң, балалар?

Гәрәй. Опять они по-своему тарыбары...

Фәридә. Может, сказать, им, кто мы такие, Гарри? Про нас же спрашивают...

Гәрәй *(бүлдерә)*. Не мельтеши, старуха. Тут у них как в темном лесу. Лучше переводи им. *(Картларга кычкыра.)* Ну вы даете, почтенные! Зачем вам нужно знать, кто мы такие? Боитесь — не жулики ли?

Кифая. Чава раскричался?! Муклашка кирәкме? Иди свой даруга! *(Йодрыкларын төйнәп, егет өстенә бара.)* Жулик-мулик күрсәтермен мин сезгә!

**Гәрәй белән Фәридә, җилкәләрен җыерып, урам буйлап түбәнгә таба китеп баралар. Мөштәри рәхәтләнеп көлә.**

*(Ирена чәпчеп ташлана.)* Ә син нигә авызыңны ыржаясың?! Җүен чүрт-чурамаңнан өркеп торыйкмы әллә?

Мөштәри *(җитди)*. Аларның сиңа нинди яманлыгы тиде?

Кифая. Бетмәсләр монда!

Мөштәри. Пакранимер, берсе безнең оныкның баласына охшаган. «Гарри» дигәне. Фаягөлнең Гәрәе. Шуның пешмәгән җимеше булырга тиеш.

Кифая *(өнсез кала)*. Каян беләсең? Әйтмәде ич!

Мөштәри *(фәлсәфи тон белән)*. Ике чишмәне бергә кушсаң, берсе корый, дигәннәр бабайлар. Ана телләрен онытканнар болар. Тумыштан белми түгел иде, югыйсә, Фаягөлнең баласы өч яшенә хәтле бездә үсте.

**Юл башында Фаягөл белән Борһан күренә: яшьләренең кулларында берни дә юк иде, боларның берсе дипломат, икенчесе кечкенә сумка тоткан. Карар күзгә 40—45 яшьлек шәһәр кешеләре.**

*(Мөштәри аларны күрә.)* Әнә — Фаягөлең үзе дә Бүресен ияртеп кайтып килә! Гомерле булыр! Каршы ал — мин киттем! *(Китәргә кузгала.)*

Кифая. Кая?! Кунакларыңны каршы алмыйчамы?! Кара син аны! Иң якын кунаклары кайтып ята, ә ул сыртын күрсәтеп каядыр ычкынмакчы! Нинди гадәтсезлек бу?!

**Мөштәри.** Бер-ике сәгатькә генә кайтулары түгелдер — гуртлары белән куз-галганнар. Күреццү качмас, алар өчен йөрим. Кара сарыкны чалырга кирәк. *(Мылтыгына таянып китеп бара.)*

**Кифая** *(кунаклары якынлашып килгәнлектән, артык кызып китәргә уңайсызлана).* Кунаклар китсен генә — бисмилланны укытам әле мин сине бу кыланышларың өчен!.. *(Берни булмагандай, кунакларны ачык йөз белән каршы ала.)* Менә ичмасам маладислар! Машинагызны кайда калдырдыгыз? Тавышы колакка чалынган кебек булган иде бит? *(Кунаклары белән ике куллап күреша.)*

**Фаягөл** *(шактый нык сизелгән урысча акцент белән).* Зәйнәп чокырында су арткан икән, я застрять итәрбез, дидек. Нихәлләр генә яшәп ятасыз, бабуля? А дедуля кая помчался? Внукларын күрәсе килми, значит? *(Кычкырып көлә.)* Теге юлы кайткач, Боря кияве белән бик каты спорить иткәннәр иде — все еще аңа дуется?

**Кифая.** Нишләп дуется итсен ул! Мин үзем боргычлап җибәрдем. Бар, мин әйтәм, оныкларың кайтып килә — чал тиз генә кара сарыкны! Азау тешеңне ашагансың, мин әйтәм, кунак күргәч аптырап калдың. Тугайлыкка йөгерде. Кайтыр, бер кая да качмас! Күрешергә дә җитешерсез, башкасына да. Нишләп үзегез генә? Аталарыгыз кая? Нигә малаегызны калдырдыгыз?

**Борһан** *(көлә).* Почему үзебез генә? Сразы бишәү килеп төштек! Кая утырырга урын табалмый аптырашырсыз әле! *(Кемнедер эзләгәндәй, тирә-ягына карана.)*

**Кифая.** Бәрәч! Ә кая соң башкаларыгыз?

**Фаягөл.** Как? Гарри белән Фрида килеп җитмәде разве? Алар же, машинадан төшүгә, алга киттеләр. Скажи, Боря? А папа машина янында с вещами возиться итә.

**Кифая.** Әниең, Сәгъдәнә килен нишләп калды?

**Борһан.** Әбине кооперативта зав итеп калдырдык. Командовать итеп карасын әле! Банкротка чыкмаса без урап кайтканчы. *(Көлә.)*

**Кифая.** Бер үземе?

**Борһан.** Малай-шалайлар җитәрлек анда. Толковыйлары гына юк.

**Кифая.** Арпа эчендә бер бодай булып калган икән! Нишли генә ала соң ул анда бернинди белемсез?

**Борһан.** Акча үзе образауный, ди торган иде минем эти мәрхүм!

**Кифая.** Акчага дисәң, Сәгъдәнә килен ким-хур булмас! Акчага чукынган анысы... Ә Фрида дигәнегез кем була тагын?

**Фаягөл** *(көлә).* Гаррининң чираттагы увлечениесы...

**Борһан** *(шелтәләп, бүлдерә).* Ну, зачем ты так, Фаечка? Просто... *(Ул һаман кемнедер эзли.)*

**Фаягөл.** Ну ладно, не заводись при бабушке, сами знают, наверное... Сезнең күрше селодан ул, бабуля. Городта укый. Институтта, кажется. Фрида дип между собой йөртәләр алар. Фәридә аның чын исеме! Сезгә тагын бер килен әзерлибез. Правда, Боря?

**Борһан.** Я бы не спешил...

**Фаягөл** *(көлә).* Молчал бы уж! Твой вкус я уже как своих пять пальцев знаю! Ә кайда икән алар, в самом деле?!

**Кифая.** Адашмаслар, Фаягөл кызым, ана карыныннан бүген төшмәгәннәр. Бозык юлда йөрмәсәләр, кайтырлар. Әйдәгез, өйгә керәбез.

**Борһан.** Может, Гарри кызны авылына озата киткәндер?

**Фаягөл.** С него станет! Ты предупредил его, Боря, чтоб без глупости? Мало ли что... Этой дурехи нам еще не хватало!

**Борһан** *(шаярып).* Син берәр нәрсә аңладыңмы, карт әби?

**Кифая** *(сагаеп кала).* Аңлавын аңладым, төшенәсе генә калды. Киленегез булачак дисең ич үзең?

**Фаягөл** *(көлә).* Русчаны не хуже нас беләсең икән син, бабушка!

**Кифая.** Татарга тылмач кирәкми, кызым! *(Кулы белән тездән күрсәтә.)* Менә мондый чагыңнан ук урысча такылдый идең син минем белән. Тәк шшту, карт әбиегезне алдарга маташмагыз да. *(Фаягөлне юри ачуланган булып.)* Чичачже скажи свай бабуле правду! Ошамагач, нигә иярттеп йөртәсез соң ул баланы?

**Фаягөл.** Успокойся, бабулечка! *(Кифаяны кочаклап үбә.)* Разве сине алдап була! Боря киявегезнең сүзен генә әйтүем. Мин наоборот...

**Борһан.** Вот это новость! Ты что, Фая?

**Кифая** *(тирән мәгънәле итеп).* Алай икән. Тавык күкәй сала, әтәчнең арты ертыла икән! *(Бармак яный.)* Матри аны! *(Шатланып.)* Әнә атагыз да кайтып килә! И-и! Очят түгелме сезгә, балалар! Үзегез, ридикүл-фәлән генә тотып, ысплай кияү белән яшь келәш кебек, терт-терт алдан тәпиләгәнсез, ә алтынчы капчыкның авызын бәйләгән атагызга тау хәтле әйберләр күтәрткәнсез!

**Фаягөл** *(әбисен кочаклый).* Кайгырма, бабуля! Безнең этинең самый сок чагы әле. Безгә доверять итмәде. Анарда что-то бик секретный бер әйбер бар, ахры!

**Калкулыклар аермасындагы юлга Мәрәс килеп керә. Кифая әйтмешли, ул зур-зур сеткалар белән бик күп әйберләр күтәргән. Карбыз-кавын кебек тәмле ризыклар да күренә.**

**Кифая** *(килеп җитәр-җитмәс улын ачуланып ташлый).* Ай әттә генәсе! Нинди эш инде бу, ә?! Балаларың ысплай егет белән кыз кебек, кул очларына ридикүл тотып йөри, ә сиңа ишәк кебек төягәннәр! Алай итеп баланы бозып бетергәнче, бишектә үк ачы бирен тончыктыруың яхшырак! Булмаса да булыр икән! Бир әле монда бер сетканны! *(Улының кулыннан авыр сеткасын тартып алмакчы була.)*

Мәрәс *(әйберләрен җиргә куел, маңгай тирен сөртә).* Исәнлекме-тазалыкмы, әни? Күптән күрешкән юк. *(Кифаянең аркасыннан сөя.)*

Кифая. Әйбәт, улым! Бу кадәр дә әйбәт булганы юк иде әле! Дөбердәтеп яшибез!

Мәрәс. Шулаймы, әни? Менә рәхмәт, менә маладис, ичмасам, безнең әни!

Кифая. И-и! Син дә картаеп киләсең, Мәрәс улым.

Мәрәс. Без картаймый, кем картайсын инде, энкәй! Һаман дөнья куабыз ич!

Кифая. Хатыннары картайтмаса, ирләр картаймый ул, улым.

Фаягөл. Мамага тел тидермә, бабуля! *(Шаярып бармак яный.)* Любимая мамочка ул минем!

Кифая. Ә син, кыстыбый, кысылмый гына тыңлап тор! Атаң любимая түгел ыштули?

Фаягөл *(көлә).* Папа да «любимая», бабулечкау!

Мәрәс. Кем мендереп куйды анда ул урындыкларны, әни? *(Калкулыкларга ымлый.)*

**Барысы да ул күрсәткән якка карыйлар.**

Фаягөл. И в самом деле! Точно... как два царских трона! Вот күз икән синдә, папа! Целый сәгать басып торып күрмәдек.

Кифая. Атагыз куймый, кем куйсын инде...

Фаягөл. Смотри, Боря: там что-то написано! Ничего не пойму...

Мәрәс *(Кифаягә борылып).* Хатыңда язып җибәргән нәрсәләр чынга охшый башлады бит әле, әни... Күптәнме инде ул... шулай? *(Кулы белән чигәсенә төртеп күрсәтмәкче була, ләкин уңайсызланып тыелып кала.)*

Кифая *(караңгы чырай белән).* Үзегез күрерсез әле. Тирә-якта шундый язулар тормаган урын да калмады бугай инде! Кызылтау башында да бар, Дүртбогада да... Ә бүген бөтенләй!.. *(Кул селти.)*

Мәрәс *(шикләнеп).* Кая соң әле үзе? Авырып ятмыйдыр бит?

Кифая. Ни булсын диг аңа! Гүәрдин кебек таза әле. Гайрәтен кая куярга белми җөри. Җәгез, балалар, өйгә кердек.

Фаягөл *(әбисенә сумочкасын суза).* Сез керә торыгыз, бабулечка. Ә без Боря белән тау башындагы надписьләрне карап төшәбез. Пошли, Боря!

Кифая *(кинәт ачуланып).* Кәмит эзләп кайттыңмы әллә?! Дөлдел күкәе салып куймаганнар анда сезгә!

## Икенче күренеш

**Кыдаш елгасы буенда тугайлык. Анда-санда карама агачлары, шомырт, тал-тирәк. Тугайлык тау итәгенә кушылган җирдә иске зират. Заманында авыл халкы ата-бабалары каберләрен бик кадерләп карап торган, күрәсең: зират кара урман кебек булган. Хәзер инде чардуган-фәлән дә сакланмаган. Кабер өстендәге ташлар да җиргә сеңеп беткән, кайберләре генә чирәм астыннан борын төртеп тора. Аларын да бик нык игътибар белән караганда гына танып була. Шуңа күрә тугайлык буйлап йөргән Гәрәй белән Фәриданең зират агачларын чын урман дип уйлавы сәер түгел. Алар, Мөштәри картның өен эзлисе урында, шунда килеп чыгалар.**

Фәрида. Карале, Гарри, нинди искиткеч матур урман! Ой, кайчаннан бирле урманда булганым юк минем! Көлмәсәң, бер серемне әйтәм мин сиңа, Гарри: кечкенә чагымда урманда адашырга ярата идем мин. Чын! Урман буйлап юри барасың-барасың да, бервакыт адашканыңны сизә башлыйсың. Тәннәрең чемердәп китә! Барыбер эзләп табачакларын беләсең, әлбәттә. Безнең авылның урманы — аркылыга-буйга өч адым гына ич! *(Көлә.)* Сабый чакта гына ул шулай зур тоелган. Шунысы кызык, хәзер шулай икәнен әйбәт беләм, ә барыбер шулар исемә төшкәч йөрәк жу итеп куя, ә адашу үзенә бер төрле рәхәт иде. Ышанмыйсыңмы?

Гәрәй. Кызык кеше син...

Фәридә. Ой, беләсеңме, беренче мәртәбә шәһәргә баргач, нәкъ бәләкәй чагым кебек хис иттем үземне! Имеш тә мин урман буйлап атлыйм, тик ул бөтенләй таныш түгел — аркам чемердәп куйды хәтта... Ой, йөзеңнән күренеп тора, минем белән күңелсез сиңа! Дөрес бит! Яшермә!

Гәрәй *(көлә).* Шәп кыз син, Фрида! Телисеңме, менә шушында тотам да... бер суырып үбәм үзеңне! Бит очыңнан гына!

Фәридә *(егетнең сүзләре аның йөрәгенә сары май булып ята, шул ук вакытта ул аны шаярту дип кабул итә).* Фи! Бит очын гынамы?! Шундый юк-бар өчен генә...

Гәрәй. Матур сөйләшүне бүлдереп торасы да юкмы?

Фәридә *(көлә).* Нәкъ өстенә бастың!

**Бераз тынып торалар.**

Гәрәй. Үзең турында берәр нәрсә сөйләле, Фрида!

Фәридә. Ә мин сиңа сөйләсен сөйләп бетердем инде.

Гәрәй. Койрыгыңны боргалама! Өч сүз дә әйткәнең юк әле синең миңа.

Фәридә *(җитди).* Ә мин үзем турында сөйли белмим... Юләр кыз әле мин, Гарри. Белеп тор! Нигә елмаясың?.. Чын әйтәм. Менә миңа инде унтугыз... тулачак тиздән. Гомер булса! *(Көлә.)*

Гәрәй *(кушылып көлә).* Карап, карап торам да, күрәм, яшисен яшәгәнсең инде син бу дөньяда, карчык! Оят белергә кирәк! Дөньяда болай да әби-чәбиләр буа буарлык, адым саен барып төртеләсең! Әйдә үзем теге дөньяга китәргә ярдәм итәм сиңа! У-у! *(Шаярып, бармакларын тырпайта һәм Фәридәне буарга тырышкан кебек кылана.)*

Фәридә *(ул да Гәрәйнең шаяртуын күтәреп ала һәм, курыккан булып, читкә йөгерә).* Тоттырды ди!.. Мин әле синнән соң да яшим... Юри сиңа үч итеп йөзгә җитәчәкмен!

Гәрәй *(куудан туктый).* Ә ни өчен — миңа үч итеп?

Фәридә. Көт, әйтте ди сиңа! *(Тел күрсәтә.)*

Гәрәй *(ярым шаярып).* Әйт әле, Фрида... Кара аны — мин сиңа бала-чага түгел! Синең... берәр кемең бармы?

Фәридә. Бар, әлбәттә!

Гәрәй. Һәм... күптәнме?

Фәридә. Күптән.

Гәрәй. Ну и.. ничек соң?

Фәридә. Нәрсә — ничек?

Гәрәй. Гомумән... Ул... ярыйсымы?

Фәридә *(аңа егетне шаярту ошый).* Ничек кенә әле! Беренчедән, ул үтә чибәр...

Гәрәй. Икенчедән?

Фәридә. Икенчедән, үтә кыю! Кайберәүләр кебек түгел инде!

Гәрәй. Бу нәрсә — кайберәүләргә кинаяме?

Фәридә. Өченчедән...

Гәрәй. Боже мой! Өченчедән дә бармыни тагын!

Фәридә. Беләсең килсә, көнче рыцарь, мин аның турында көне буе бер туктамый сөйли алам! Чөнки ул...

Гәрәй *(«сөяркәң» димәкче).* Синең...

Фәридә. ...бертуган абыем! *(Эчкерсез рәхәтләнеп көлә.)*

Гәрәй *(моңдый борылышны көтмәгән).* Шул гынамы?!

Фәридә. Нишләп алай булсын? Минем әле тагын кайбер кешеләрем бар.

Гәрәй. Менә-менә... Безне нәкъ әнә шул «кайбер кешеләр» кызыксындыра да, унтугыз яшьлек кадерле карчык!

Фәридә *(бармакларын бөгә).* Бертуган абыем — бер булдымы. Ул күптән түгел генә Әфганстаннан кайтты. Ике ордены бар — белдеңме!

Гәрәй *(ирония белән).* Ну, орденлы да булгач!..

Фәридә *(абыйсы өчен бераз үпкәләп).* Ә син бар, үзең алып кайтып кара! Ихтиозавр син, Гарри! Хәтта үз бабаңнарны да танымадың! Чөнки иркәләп бозып бетергәннәр сине. Әтиең белән әниең — үз янында. Бабаң белән әбиең — тирә-ягыңда бөтерелеп кенә торалар. Шулай булгач, кайдадыр кеше аягы басмаган ташландык авылда яткан карт бабаңнар нигә кирәк сиңа!

Гәрәй *(елмая).* Килешәм. Тач әйттең! Мин — ихтиозавр! Һәм мин сине хәзер кабып йотам! *(Фәридәне куып йөри.)* Киемең-ниең белән бергә!

Фәридә *(тоттырмый).* Мине кабып йотарга ярамый шул!

Гәрәй. Ни өчен ярамасын? Бик тәмле дә күренәсең!

Фәридә. Чөнки минем тәндә ата-бабаларымның хәтере саклана!

Гәрәй. Нинди хәтер ди тагын!

Фәридә. Сезнекеләр әнә — берьюлы дүрт буын исән... Ә минем беркемем дә юк диярлек. Карт әнием дә абыем. Мин компьютер кебек булырга тиеш. Тагын бер җитди сәбәп бар!

**Куышудан туктыйлар.**

Гәрәй. Менә ничек? Әйтеп кара! Сер булмаса.

Фәридә. Мин... нәселебезне дәвам итәргә тиешмен!

Гәрәй *(кычкырып көлә).* Үзең әйтеп торасың ич, сезнең запаста Әфганстан герое бар! Аннан соң... Нәсел фамилиясен хатын-кыз сакламый!

Фәридә *(бик җитди).* Абыема өйләнергә ярамый... Бик каты яраланып кайтты ул. Врачлар теге дөньядан кайтардык сине, дип әйттеләр ди. Әфганстанга ничек эләккәнен сөйлимме?

Гәрәй *(исе китмичә).* Проблема тапкансың. Маңгай чәчен кырганнар да — кулына автомат тоттырганнар.

Фәридә. Алай түгел шул! Ул башта Мәскәү янында иде. Бер генералның дачасына каравыл итеп куйганнар.

Гәрәй. Туктап тор! Дәвамын үзем сөйләп бирәм. Ары, значит, болай булуы мөмкин: дачага каравыл итеп куйгач, абыең бик нык гарьләнә дә тиешле җиргә рапорт яза: шулай да шулай, мин армиягә генерал дачасын сакларга килмәдем, ә чын совет егете кебек туган илгә хезмәт итәргә килдем! Ярый, алайса, дип җавап бирәләр моңа, патриотик хисләреңне егасыбыз килми. Һәм абыеңны... туп-туры Әфганстан ялкынына томыралар! Шулай булганмы?

Фәридә *(бераз гаҗәпләнеп).* Кызык түгел синең белән, Гарри, син бөтенесен алдан белеп торасың! Нәкъ шулай була!

Гәрәй. Абзаңнан өйрән, мамзель! Тик мин пәйгамбәр түгел, мин тормышны яхшы беләм. Мин әле уйлап торам, теге генерал абыең артыннан спецдепеша да җибәргәндер! Беләм мин аларны!

Фәридә. Кайдан килеп чыгалардыр шундыйлар... Кеше бит ул!.. Килеп төшкән беренче көнне үк атакага кудылар, ди... *(Егет алдында күңеле йомшаруын күрсәтмәскә тырышып.)* Шулай булгач, сиңа мине исән калдырырга туры килә!

Гәрәй *(беренче мәртәбә җитдиләнеп).* Син үзең... тарихи казылма экземпляр икәнсең, карчык!

Фәридә. Булсын! Я, нәрсә, киттекме?

Гәрәй. Кая китәбез? Загска булса — мин шушы секундта ук әзер!

**Тугайлыкка Мөштәри карт килеп чыга. Ул җилкәсенә сарык тиресенә төреп ит күтәргән.**

*(Картны күргәч, Фәридәне җитәкләп, тиз генә агачлар артына яшерелә.)* Теге карт!

Ф ә р и д ә *(пышылдап).* Чынлап та, ул синең карт бабаңдыр, бәлки?

Г ә р ә й. Ну да! Яшь бабайларның сөйләвенә караганда, аңа йөздән артык булырга тиеш инде. Ә бу әнә ничек эләдертә! Аннан соң... җан тартмаса да кан тартыр иде!

**Шулвакыт Мөштәри кинәт алар ягына карап куя. Яшьләр карт күздән югалганчы тынып торалар.**

Г ә р ә й *(кулын иңләп кенә Фәридәнең иңнәренә куя).* Яшьләр кебек йөгереп йөри әле бу!

Ф ә р и д ә *(Гәрәйнең кулына игътибар итми).* Шулай да кызганыч ул миңа.

Г ә р ә й. Ни өчен?!

Ф ә р и д ә. Ну, үзең уйлап кара: авылларда хәзер аның кебек карт-корылар гына калды бит. Ярдәм итүче юк. Әнә безнең авылда да күпме алар! Берүзләре интегәләр, мескеннәр! Берәр йомшак күңелле күршесе...

Г ә р ә й *(шаярткан булып, бүлдерә).* ...үзенең тешсез әбисе берәр төнгә биреп торса гына инде, шулаймы! *(Кочаклый.)* Эх, син! Унтугыз яшьлек Айболит! *(Көлә.)* Пардон, иң яңа модалы варенка кигән Айболит!

Ф ә р и д ә *(ярым ачуланып, Гәрәйнең кочагыннан чыга).* Әй, синең белән... Син юри минем бөтен сүзне шаяруга борасың!

Г ә р ә й *(кабат иңләп кенә кочаклый).* Ачуланма, карчык!.. Болай гына ич мин... Чөнки... Яратам мин сине, Фрида! Күптән инде... Дискотекада беренче күрүдән үк... Хәтереңдәме, имтихан вакытында? Сине күрүем булды, шундук үземнеке була дидем... *(Кинәт Фәридәне күтәрә һәм битләрен, күзләрен, муенын үбәргә тотына.)*

Ф ә р и д ә *(куркып кала, аннан соң һушына килеп, Гәрәйдән ычкынырга тырыша).* Син нәрсә, Гарри... Җибәр... Кирәкми, үтенәм синнән!.. Кеше карап торыр... Я инде, нишлисең син, Гарри... Якты чак бит... Акылыңа кил!

Г ә р ә й *(ниһаять, кызны җиргә бастыра).* Син үзеңнең нинди икәнлегеңне белмисең әле, Фридочка... *(Ашкынып иреннәрен үбә.)*

**Фәридә башта аңардан читкә тайпылып карый, ләкин Гәрәй аны, бик каты кочаклап, җибәрми. Гәрәй аның кулларын үзенең иңнәренә сала. Әкренләп Фәридә егетнең ихтыярына буйсына һәм аны чын күңелдән кысып кочаклый. Яшьләр, янәрындагы кабер өстендә үскән каенга сөялеп, бик озак онытылып үбешеп торалар.**

Ф ә р и д ә *(тыны бетеп, бар көченә читкә тартыла һәм Гәрәйнең кочагыннан чыга).* Ой!.. *(Якты көннән оялгандай, куллары белән йөзен каплый.)* Икебез дә шашкан без синең белән... *(Чайкалып китә.)*

Г ә р ә й *(ул сизелерлек авыр сулый, шулай да кызны егылудан тотып кала).* Ни булды сиңа?

Ф ә р и д ә. Башым әйләнеп китте... Мин бит... Гомеремдә беренче тапкыр шулай... Аякларым да тотмый... Син көлмә, зинһар, Гарри...

Г ә р ә й *(кызның ихласлыгы аңа да тәэсир итә).* Ну, син нәрсә!.. Уйлап та карама... Үлеп яратам ич мин сине... Әйдә, утырып торабыз... Менә бу түмгәккә... Бөтенесе дә үтәр...

Ф ә р и д ә *(җиңелчә карышып).* Кирәкми, Гарри... Озак йөрдек инде... Хәлем дә яхшырды...

Г ә р ә й *(кызны борынгы кабер өстенә утырта, шаярган була).* Минем белән бәхәсләшәсе булма, карчык! Кем гаилә башлыгы булырга тиеш, йәле, әйт әле! Ә, телеңне тешләдеңме! Чөнки итне кем мәчесе ашаганын беләсең... *(Шулай шаярашаяра, Фәридә янына утыра һәм аны иңнәреннән кочаклый.)*

**Бераз вакыт тын гына утыралар.**

Ф ә р и д ә *(үз хәләтен егеттән яшерергә теләгәндәй).* Башыңны күтәреп кара әле, Гарри! Бөтен күк җете-кызыл төскә кергән!

Г ә р ә й *(Фәридәгә текәлеп утыра).* Кичке шәфәкъ нуры ул. Димәк, иртәгә дә аяз булачак.

Ф ә р и д ә. Алай карама миңа, Гарри... Оялам мин синнән... *(Пышылдап.)* Әни белән абыем алдында да... Алар беләсеңме минем өчен ничек ут йотып торалар!

Г ә р ә й. Ояласың?!. Юктан шикләнүчән кеше син, Фрида! Йәле, баш миеңнең сырлары буйлап сәяхәт итеп кара: яратасыңмы син мине?

Ф ә р и д ә. Белмим.

Г ә р ә й. Мин беләм аның каравы... Яратасың!

**Фәридә каршы дәшми.**

Г ә р ә й. Ә мин сине?

Ф ә р и д ә. Монысын белмим дә белмим инде...

Г ә р ә й. Ну и тип син, карчык! *(Көлә.)* Димәк, болай карар иттек: без бер-беребезне кайнар яратабыз. Присяжныйлар суды шуны ачыклады!

Ф ә р и д ә *(бүлдерә).* Бәлки, яратабыздыр да, «кайнар» түгел.

Г ә р ә й. Гаилә башлыгы бүлдермәвегезне үтенә!

Ф ә р и д ә *(елмая).* Ну, бүлдермим, бүлдермим! Тик мин һаман да кая таба каезлавыңны аңлап бетермим...

Г ә р ә й. Хәзер аңларсың. Мәңгегә колагыңа киертеп куй, мамзель кадерлем,

яратышкан кешеләр арасында бер генә оят нәрсә дә юк. Син мине аңладыңмы? Бер ге-нә дә!

Ф ә р и д ә. Бик акыллы булып күренә башладың әле...

Г ә р ә й. Тукта, аңладыңмы минем ни әйтергә теләгәнемне?

Ф ә р и д ә *(елмая).* Аңладым... итне кем мәчесе ашарга теләгәнне!

Г ә р ә й. Ә мин сине бернинди мәчегә бирмим! Бигрәк тә, ата мәчегә! Мин үзем рәхәтләнеп ашыйм сине! *(Аны-моны әйтеп өлгергәнче, дәртләнеп кызның иреннәрен үбәргә тотына.)*

**Фәридә бу юлы карышмый: үзе дә, утырган килеш, Гәрәйне кочаклый. Яшьләр чирәмгә сузылып яталар. Шушы минутта Гәрәйнең үз-үзен тотышы кинәт үзгәрә: ул күз ачып йомганчы кызның изү төймәләрен ычкындырып ташлый, җитез куллары белән аны үзенә таба тарта...**

Ф ә р и д ә *(Гәрәйнең сөлек кебек ябышкан иреннәреннән аерыла һәм кочагыннан котылырга азаплана).* Гарри!.. Җибәр, нишләмәкче буласың син?! Ой, әнием... Гарри, җаныем, кирәкми... Зинһар, дим... Кычкырам!.. Исеңә кил, юләркәем минем... Ишетәсеңме?! Кагылма!.. Неужели ялгыштым мин синең турыда?.. Син шундый түбән җанлы кешемени?.. Тешлим... Җибәр дим ич мин сиңа!.. Сволочь икәнсең син... Син мине махсус шушы урманга алдалап алып килгәнсең... Бетте!.. Моннан соң мин беркайчан да синең белән очрашмаячакмын!.. Ой! Чынлап кылана ич бу... Гарри!.. Кирәкми... Кирәкми, Гарри!!. Ой!.. Ой!.. Туктале!.. Туктале, дим ич мин сиңа! Күзеңне ачып кара: күрәсеңме, без кайда ятабыз икән?! Гарри!.. Кабер ташы бит бу! Менә язуы да бар! Гарәпчә язылган. Бераз укый беләм мин. Урман түгел икән бу, Гарри! Зират бу! Без кемнеңдер кабере өстендә ятабыз!. Коточкыч бит!.. Бәлки, ул синең карт бабаңнарның берсенекедер!!! Авырттырасың ич!!! О-ой!.. Әнием!!! *(Кинәт тынып кала.)*

**Яшьләр күпмедер вакыт хәрәкәтсез яталар. Бераздан Гәрәй, мышный-мышный, кызның тынсыз гәүдәсеннән аерыла һәм, торып, өс киемнәрен рәткә китерә. Вакыт-вакыт җирдә яткан Фәридәгә карап ала — ул селкенми.**

Г ә р ә й *(гафу үтенгән сыман йомшаграк итеп әйтергә тырышып).* Ярар, Фрид, тор әйдә... Юктан трагедия ясамыйк...

**Шулвакыт алар янына Мөштәри карт килеп чыга: Гәрәй әлегә аны күрми. Мөштәри мондагы хәлне ничек аңларга да белмичә, башта катып тора.**

Ну, җитәр инде, дим, тор!.. Өс-башыңны рәтлә бераз... Ыру башлыклары каршысына барып басарга вакыт безгә... Янда син булганда миңа беркем дә кирәкми дә... Нишлисең бит — алар да кешеләр! *(Борчыла башлап, Фәридә янына чүгәли һәм аның изү төймәләрен каптыра, өс киемен рәтли.)* Нишләп соң алдан кисәтмәдең... Ни икәнеңне... Беркем белән дә булмаганыңны... Ну, зыян юк... Дөньяда булмаган хәл түгел... Өстәвенә, бәлки өйләнешербез дә... Әлбәттә, син үзең теләсәң... *(Кызның һушсыз ятуын аңлап.)* Чынлап та аңын югалткан инде әллә бу?!. Шул гына җитмәгән иде! *(Нишләргә белмичә, Фәридәне бик каты селкетә.)* Җитте!.. Һушсыз яткан булып кыланма, дим!

М ө ш т ә р и *(ниһаять, монда әле генә булган хәлне аңлап).* Нишләдең син, имансыз чучка?!. *(Кулындагы юан таягы белән Гәрәйнең сыртына сала.)* Нишләттең ул кызны, кабахәт?!

Г ә р ә й *(ачы итеп кычкыра, сикереп тора).* Ой!.. *(Мөштәринең таягын кинәт тартып ала: карт инерция белән җиргә тәгәри.)* Опять ты, проклятый старикашка?! Убирайся отсюда, пока жив! *(Сугарга теләгәндәй кизәнә.)*

М ө ш т ә р и *(яткан җиреннән күтәрелә төшеп).* Сук! Сук! Йөз яшьлек карт дип торма!

Г ә р ә й. Говори по-человечески! Я не понимаю твою тарабарщину! Кто ты такой?! Не лезь не в свое дело!

М ө ш т ә р и. Мөштәри бабаңны танымассың шул! Башың үзеңнеке булмагач!

**Гәрәй кизәнгән җиреннән кинәт туктап кала: ниһаять, ул Мөштәринең үз бабасы икәнлеген аңлый.**

*(Мөштәри Фәридә янына килә.)* Сандугач баласыдай кызны харап иткән бит, мөртәт!.. Адәм хәшәрәте!.. Кадалыплар китәсе нәмәрсә!.. *(Фәридәне һушына китерергә тырыша, иләп кенә яңакларына суккалый, кесәсеннәнниндидер дару алып иснәтә, үзе һаман ачынып сөйләнүен дәвам итә.)* Һушыңа килгәч, бу мәсхәрәләргә ничек кенәләр йөрәгең түзәр икән синең, балакай... Ничек кенәләр кичерерсең икән безне... Кемнеңдер күз алмасыдай карап торган бер баласыдыр инде син... Ата-анаң, туган-тумачаларың бардыр, бахыр... Алар каршына кайтып ничек кенәләр басарсың икән... Дөньяда Гәрәй кебек хәшәрәтләр барлыгын белми идеңмени соң син?.. Нишләп иярергә булдың син аңа, башсыз бала, сынамаган-нитмәгән көенә!

**Ниһаять, Фәридә хәрәкәткә килә башлый. Гәрәй кулындагы таягын читкә ыргыта һәм зират урманы эченә ташлана.**

*(Гәрәйнең артыннан кычкырып кала).* Ерак кача алмассың, сукин сын! Анаңның имезгән сөте хәрам сиңа, бәдбәхет!

## Өченче күренеш

**Мөштәри картның йорты. Гадәти авыл өе. Хуҗалар мал артыннан кумаган, күрәсең, өйдә күзгә чалынырлык әллә ни күренми. Түрдә зур сәке, аның өстенә ак киез җәелгән. Өстәл, урындыклар, эскәмия — барысы да Мөштәринең үз кулы белән эшләнгән, буяусыз-лаксыз. Бер чөйдә Мөштәринең мылтыгы эленеп тора.**

**Өйдә, Мөштәри картның юклыгыннан файдаланып, гаилә киңәшмәсе оештырылган. Төп мәсьәлә — картлар белән нишләргә?**

М ә р ә с *(өйдәге ирләр арасында иң өлкән булуыннан файдаланып, дәрәҗәсен белеп сөйләшә)*. Ярар, әни, күп сүз — юк сүз. Вак-төяк калып торсын. Синең фикерне тыңлап карыйк. Дөрес, артык баш ватасы юк монда, минемчә: эти белән икегез дә бик олыгайдыгыз инде хәзер, су китерү, утын тураклау да проблема хәзер сезнең өчен. Мал-туар асрау турында әйткән дә юк. Элегрәк кузгатканда безнең янга күчәргә аяк терәп каршы булдыгыз. Көчегез бар чак иде, анысы... Абынсагыз, торалмый егылып ятыр чагыгыз җитте, дию-ем түгел, шулай да...

Б о р һ а н *(ул өстәл артында катык ашап утыра)*. Алай ук кистереп әйтмә әле син, яшь бабай... Может, хәзер фикерләре үзгәргәндер... Бигрәк тәмле катыгың, карт әби... Эмм!.. Фая, рецептын язып ал. Кафе-бызда клиентларга предложить итеп карарбыз. Барачак бу!

М ә р ә с *(киявенең сүз очын читкә җибәрүен өнәп бетерми)*. Катыгыңны калдырып торчы, кияү!

Ф а я г ө л *(көзге каршында крем белән битен эшкәртә)*. Боря, оставь для меня!.. Из простокваши бит өчен менә дигән маска получается...

М ә р ә с. Я, әни, ни әйтерсең?

К и ф а я *(өстәл янына килә)*. Ни әйтергә дә аптыраган инде, Мәрәс улым... Авыз күгәрмәсен өчен генә димәсәгез, киңәшик соң... Талканы коры шул атагызның... Йөрәкне курку басты. Тауга менгереп куйган урындыкларын үзегез күрдегез. Ачулана башласаң, төпченмә әле, ди дә авызны томалый. Бөтен сүзе — бавырга кермә!

Ф а я г ө л. Старость — не радость, бабуля...

Б о р һ а н *(дилбегәне үз кулына ала)*. Тәк... Кемдә тагын нинди тәкъдим калды?

Ф а я г ө л. Ә син, Боря, вперед батьки не лезь...

Б о р һ а н. Ша! Хәзер мине тыңлыйсыз.

Ф а я г ө л. Наконец, киявегез дә проснулся! *(Көлә.)* Что, простокваша в голову ударила?

Б о р һ а н. Ша, дидем!

**Тынып калалар.**

Башта карт әбигә минем ике соравым бар. Как я понял, авылда хәзер карт бабай белән икегездән башка — ни души? То есть, бер җан әсәре дә юк?

Ф а я г ө л. Үзең видел же!

Б о р һ а н. Кифая әбидән сорыйм мин.

К и ф а я. Каян килеп булсын? Күзгә кырып салырлык та кеше калмады. Җиде җыл була торгандыр инде, кая барырга белмәгән сарык кебек карт бабаң белән икәү мәшәләнәбез.

Б о р һ а н. Аңлашылды монысы. Хәзер икенче сорау. Авыл тирәсендә читтән килеп-нитеп йөрүчеләр күзегезгә чалынмадымы?

М ә р ә с *(дилбегәне үз кулыннан тартып алуны ошатып бетерми)*. Таптың син дә, кияү, сорап торыр нәрсә! Кемгә кирәге бар дисәң бу ташландык авылның? Бөтен Рәсәй тоташ ташландык авыл хәзер...

К и ф а я. Кем килсен инде безгә, Борһан кияү... Адашып килеп чыксалар гына! Калхузның айхаенда да юк. Чучка фермасы тирәсендә күренгәлиләр. Җылына бер-ике мәртәбә. Персидәтелне әйтәм.

Б о р һ а н. Ә еракмы моннан?

Ф а я г ө л *(елмая)*. А это уже третий вопрос, Боря!

Б о р һ а н *(булдерә)*. Салып торып әйләндерермен!.. *(Шаяруга бора.)* Кеше сүзенә не к месту тыгылган кешегә эти шулай дип әйтә торган иде. Еракмы соң ул ферма?

К и ф а я. Дәлү-ү-кә дә тагын бер балта сап буе, кияү. Җарты чакырым!

М ә р ә с. Сүзеңнең очын күрмим әле мин, кияү?

Б о р һ а н. Ашыкмагыз, хәзер күрерсез.

Ф а я г ө л *(туганнары алдында иренең үзе белән дорфа сөйләшүенә үч белән)*. Понесло берәүне! Бүтән чакта кирәкле сүзне авызыннан клещами не вырвишь!

К и ф а я *(ул да оныгы өчен рәнҗеп куйган, ахры)*. Бер дә гаҗәпләнмә син аңа, Фаягөл кызым: марсык җана белмәс, җанса сүнә белмәс, ди! *(Көлә.)* Әйдә, кияү, әйтеп бетер инде әйтәсе сүзеңне. Хатынкыз сүзе бетмәс ул.

Б о р һ а н. Синең сүзгә үпкә юк, Кифая әби! Минем тәкъдимне белмисез ич әлегә. Белсәгез, телегезне тешләячәксез. Бигрәк тә Фая! Потому что... сүз аның малае турында бара.

Ф а я г ө л. Сиңа да малай түгел что ли ул?

Б о р һ а н. Оставь пока! *(Кифаяга.)* Монда бер генә выход күрәм мин, Кифая әби: Гарри сезнең янда остается.

**Бу тәкъдимне чынлап та беркем дә көтмәгән — аптырашып торалар.**

*(Борһан, тамагызга тыгылдымы, дигәндәй һавалы гына аларга карап чыга.)*

Бүлдерми генә тыңласагыз, аңларсыз. Во-первых, малайга кимендә биш-алты ай чамасы городта күренергә ярамый. Монысы, Фая, для твоего утешения. Күкәй сала алмаган тавык шикелле аңгы-миңге ходила син в последнее время.

К и ф а я. Кеше күзенә күренергә ярамаслык нәрсә эшләде соң ул?!

М ә р ә с. Бер кызның бакчасына кәҗә булып кергән, борын җилеге кипмәгән нәмәрсә! Шау-шуы узганчы шәһәрдән югалып торуы әйбәтрәк булыр дибез. Борһан киявенең тәкъдиме чынлап та бик кулай күренә.

К и ф а я. Ә баягы кыз кем? Ул — икенче кешемени?

Ф а я г ө л. Ул кыз турында, бабуля, Борядан сора инде син. Ул аны лучше нас знает!

Б о р һ а н *(бераз уңайсызланып, шулай да артык сер бирмичә).* А это уже фантазия, Фаечка... *(Тирәнгә җибәрмичә, сүзне дәвам итә.)* Икенчедән, сезгә менә дигән помощник булыр. Эшләсен әле рәхәтләнеп! Кызганып тормагыз. Нибуч, дурацки выходкалары онытылыр! А, в-третьих... Эш болай тора, Кифая әби. Без монда бер бик шәп план корып кайттык. Кооператив оештырдык без, әби. Кафе-столовый ачтык. Хәзер рөхсәт бит. Налогын гына исправно түлә! Ну вот, столовый өчен тегесе-монысы, мае-шикәре, ипие-тозы, бигрәк тә ите кирәк, дигәндәй. Ә дәүләт әйтә: менә сезгә шиш, ди. Продуктны үзегез табыгыз, ди. Кем ничек булдыра — шуннан таба. Ә почему, мин әйтәм, сезнең авылда бер ташландык өйне файдаланмаска? Әйтик, к примеру чучка балалары үрчетер өчен? Бөтенләй хуҗасыз калган йортлар бармы? Ну, читтә дә беркеме дә калмаган?

К и ф а я. Нишләп булмасын?.. Бөтенесе хуҗасыз хәзер. Бер дә белмим шул, балалар... Килешер микән?.. Законга сыя торган нәрсәме соң ул?

Б о р һ а н. Ансы өчен борчылма, Кифая әби! Закон үзебезнеке хәзер. Авыз белән кош тота башласаң да беркем бер сүз әйтми!

К и ф а я *(уйланып).* Туганнан туган энем Ситдыйк бабаңнарныкын ачсагыз гына инде...

Б о р һ а н. Бигрәк әйбәт, әби! Значит, случайно килеп бәйләнүче дә булмаячак. Бабайныкы — илнеке, дип әйтте ди берәү!

М ә р ә с. Ә үрчемгә ул кәпәч борыннарны каян табарбыз?

Б о р һ а н. Май кап, яшь бабай! Есть у меня тут один хороший источник... Бөтенесе в ажуре булыр! Шулай килештекме? Значит, карт бабайга...

К и ф а я *(тышка колак салып).* Чү!.. Бабагыз кайтып килә бугай... *(Ишеккә бара.)*

**Мөштәри карт белән Фәридә кайтып керә. Кыз бик сәер халдә күренә. Өйдәгеләр, гаҗәпләнеп, тынып калалар. Фәридә томанлы күзләре белән барысына да карап чыга һәм кире ишеккә ташлана. Мөштәри аны җибәрми.**

Ф ә р и д ә. Не хочу к ним!.. Җибәрегез мине!.. Мин әни янына кайтам!

М ө ш т ә р и *(Кифаяга).* Ни карап каттың?! Тиз бул — урын түшә теге якка! Күрмисеңмени — бала үз акылында түгел!.. *(Фәридәгә.)* Хәзер, балакаем, хәзер... Тынычлан... Үтә ул... Бераз йоклап ал... Мин сиңа бер дару бирәм — шундук ярдәме тияр... *(Кифаяга.)* Ну! Буласыңмы инде?!

**Кифая, хафаланып, икенче бүлмәгә ташлана.**

*(Кызны, юата-юата, шул якка алып кереп китә.)* Әйдә, балакай, әйдә.

Б о р һ а н *(беренче булып телгә килә).* Что это значит?

Ф а я г ө л. Припадок, наверно... Или — истерика. А ты еще своего единственного сына познакомил с ней!..

**Тынып калалар: эчке яктан ишекне нык-лап ябып, картлар чыга.**

М ә р ә с. Берни дә аңламый калдык без, эти: ни булган аңа?

Б о р һ а н. Гарри кайда калды?

М ө ш т ә р и *(өйдәгеләрне, беренче мәртәбә күргән кебек, күзләп чыга).* Кайсыгыз тәрбияләде аны?.. *(Фаягөл белән Борһанга.)* Үзегез генәме?..

**Тегеләр ни әйтергә дә белмиләр.**

Әллә сезнең өлеш тә бармы? *(Мәрәскә таба борыла.)*

М ә р ә с. Загадкаларсыз гына сөйләче, эти: ни дип аңларга моны?!

М ө ш т ә р и. Гарриегызның кабахәтлеге!.. Зиратка алып кереп мәсхәрә иткән мескен баланы! Мин урап кайтканчы, җавабыгыз әзер булсын штубы! *(Кифаяга.)* Ә син, анасы, матри, күз-колак бул: бала, уянып, үзе белән ул-бу бер хәл эшләп ташламасын! *(Чөйдә эленеп торган мылтыкны алып, чыгып китә.)*

**Өйдәгеләр, котлары очып, өнсез кала.**

К и ф а я. Күрәселәр бетмәгән икән әле!.. Багалма кебек кыз баланы!..

Б о р һ а н *(уйланып).* Что-то тут не то!.. Мин үзем потолкую аның белән!

М ө ш т ә р и   к а р т ы н ы ң
а я г ү р ә   т ө ш   к ү р ү е

**Шул ук көнне кич белән. Ике калкулык-тау аермасындагы юлда мылтыгына таянып Мөштәри карт басып тора. Ул бик нык алҗыган. Менә ул әкрен генә башын күтәрә һәм сискәнеп китә: чөнки тау өстендәге артлы урындыкларда мәһабәт кыяфәтле ике карт утыра! Мөштәри карт, үз күзләренә ышанмагандай, кулы белән битен сыпыра, ләкин сурәт югалмый. Юга-**

**рыда утыручылар дәшми-тынмый Мөштәри картны күзәтәләр.**

Тәңре *(ак сакаллысы)*. Күрәм: рухың сынган синең. Аксак авылның соңгы карты Мөштәри! Ә хәтерең ни хәлдә?

Мөштәри *(ул куркып калган, әмма сиздермәскә тырыша)*. Син кем, җан иясе?

Тәңре. Димәк, оныткансың мине!

Хода *(күк сакаллы)*. Яки — беркайчан да белмәгән!

Тәңре. Яхшылыбрак кара, хәтерсез карт!

Мөштәри. Йа, ходаl..

Хода. Дөрес әйттең. Аксак авылның соңгы карты! Ходаң каршында басып торасың. Ә Тәңрене танымадың!

Тәңре. Бер дә гаҗәп түгел, коллега... Заманында мәҗүсилекне кыргыйлыкка санап, үз язмышларын синең кулыңа тапшырмаган булсалар, мондый мескен көнгә калмаслар иде алар. Тугыз йөз егерме икенче ел харап итте аларны!

Хода. Мәнә сиңа иске авыздан яңа сүз! Ни әйтмәкче буласың бу сүзләрең белән, мәҗүсиләр алласы?! Бәлки, аларга турыдан-туры аның каршына барып тезләнергә кирәк булгандыр? *(Арыдагы Чатырбаш тавында төсмерләнгән Шәүләгә ымлый: чынлап та анда кемдер басып тора.)*

Тәңре. Халкыңның рухы сынган, коллега. Бары шул гына.

**Еракта җан өшеткеч сәер көлү яңгырый. Мөштәри карт сискәнеп китә.**

Хода. Ходаларын оныткан мәхлукларга карап фикер йөртәсең, Тәңре! Ата-бабаларының рухи байлыгын оныкларына тапшыра белмәгән бичаралар синең заманда да житәрлек иде. Хакыйкать анда түгел. Андыйлар күзгә күренеп кубәя — менә нәрсәдә хикмәт!

Мөштәри. Мин җирдә намуслы яшәдем!

Тәңре. Шулаймы икән?

Хода. Ялгышасың, карт!

Тәңре. Ә авылыңны кемгә калдырасың? Тарихын беләсеңме соң син?

Мөштәри *(ашыкмыйча дигәндәй, кулын күтәреп куя)*. Хәтерсез түгел мин, изге җаннар! Бик озын гомерле булмады шул безнең авыл. Ә таралуы революция алдыннан менә шушы юлдан башланды. Башта иң чая кешеләребез шушы юлдан китеп, революция утында яндылар. Аннан соң аклар килеп, ирек даулаучыларны юк итте. Кызыллар кайткач, аклар ягын Кыдаш елгасы ярында кырып салдылар. Тегеләре дә, болары да авылыбызның иң гайрәтле, иң күркәм кешеләре иде! Колхоз төзү башлангач, тагын дөньяның асты өскә килде!.. Булдыклы егетләребезнең башы тагын вакытсыз өзелгән алма кебек, кара җиргә коелды... Аннан — афәтле сугыш... Сугыштан соң ил өчен яңа завод-фабрикалар, тимер юллар салырга күчле куллар кирәк диделәр, үсеп җиткән яшьләребез китә торды. Киттеләр дә югалдылар, киттеләр дә югалдылар. Дөрес, кайдадыр исән-имин яши алар. Тик берсе дә җан биреп якын туганнарының авызына бер кашык су салырга кайта алмады. Хәзер инде туган авылыбызны карчыгым белән икәү саклыйбыз.

Тәңре. Ә син үзең ирек даулаучыларга катнаштыңмы соң, авылның соңгы адәме Мөштәри?

Мөштәри. Юк, катнашмадым, изге Тәңре.

Хода. Кайнар башларга ияреп, акларга да кушылмадыңмы?

Мөштәри. Аларга да кушылмадым, изге Хода. Чөнки... кеше үтерергә теләмәдем мин.

Тәңре. Афәтле сугышка бардыңмы?

Мөштәри. Бармадым. Чөнки яшем узган иде инде.

Хода. Димәк, син үз гомереңдә кешегә каршы бер генә мәртәбә дә корал күтәрмәдең?

Мөштәри. Әйе, күтәргәнем булмады, изге Хода.

Тәңре. Шулай булгач, нишләп соң син бүген кулыңа мылтык алдың, Мөштәри?!

Хода. Иртәгесен калдырып торыйк. Үзеңнең нәселеңне дәвам итүче бердәнбер оныгыңа каршы утлы корал күтәрдең син? Аның тәнендә синең каның ага бит! Ул үлсә — нәселең бетәчәк!

**Тәңре белән Гайсә утырган калкулыклар бер-берсенә якыная, Мөштәри басып торган юлны ике яктан кыса башлый.**

Мөштәри. Сез хаклы, изге аллалар...

Хода. Ишеттеңме, Тәңре. Ул — ялгышты бүген!

Мөштәри. Ялгышмадым, изге аллалар... Бер тарих сөйлим мин сезгә. Рөхсәт итсәгез.

**Тәңре белән Гайсә утырган калкулыклар элекке урыннарына чигенәләр.**

Бик борынгы заманнарда бу урында көчле һәм азат халык яшәгән. Актамырлар ыруы дип аталган ул.

Тәңре. Хак сүз, тарихчы Мөштәри! Яшәде андый халык! Дәвам ит сүзеңне.

Мөштәри. Гаҗәеп матур халык булган ул! Чөнки алдашу белән хәйләне, куркаклык белән хыянәтне белмәгәннәр алар. Тик алар хәзерге кешеләргә охшамаган булганнар: бер-берсенә гашыйк булганчы гына адәм сурәтендә йөргәннәр. Егет белән кыз беренче тапкыр үбешүгә, чәчәккә күмелгән агачка әйләнеп, җиргә тамыр җибәрә торган булганнар, имеш.

Тәңре. Бусы да хак, тарихчы Мөштәри! Тирә-яктагы урманнар — шул актамыр ыруының дәвамы! Ләкин бит бу урманнарда хәзер агачлар бер генә төрле түгел, моны ничек аңлатырсың?

Мөштәри. Моның сәбәбе бар, диләр... Бервакыт бу якларга икенче төрле

ыру килеп чыга. Куктамырлар ыруы дип аталган анысы. Ике арада тарих күрмәгән орыш-талаш китә башта. Тора-бара, солых төзеп, ике ыру бергә аралашып яши башлый. Тик актамырлар ыруы өчен бик хәтәр солых була ул: куктамырларга актамырлар арасыннан кем кушылса да, куктамыр агачына әйләнәләр икән. Бары рухлары бик көчле булган актамырлар гына үз төсләрен саклап кала алганнар, ди. Менә ни өчен безнең як урманнарында күбрәк күк төстәге агачлар очрый, имеш...

Х о д а. Бу урман — төрле-төрле мәхәббәт җимеше, Мөштәри! Ә мәхәббәтнең яхшысы-яманы булмый!

М ө ш т ә р и. Табигать биргән үз төсеңне югалту яманлык түгелмени, изге Хода? Мин бүген яманлыкка каршы күтәрдем мылтыгымны...

**Аллалар дәшмиләр.**

Ник дәшмисез?

Т ә ң р е. Җавабыңны ишеттек. Без уйлыйбыз, бүлдермә, тарихчы Мөштәри!

М ө ш т ә р и *(кинәт җанланып)*. Уйларыгыздан аз гына вакытка аерылып торсагызчы, изге аллалар! Әнә күктамыр егете белән актамыр кызы килә!

**Чыннап та, ике калкулык аермасындагы юлда бер сәер пар пәйда була. Һәм шул ук мизгелдә гавамга гаҗәеп матур әкияти моң тарала, әйтерсең лә күктән җылы ләйсән яңгыр ява башлый. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән искиткеч гүзәл яшь егет белән кыз, кулга кул тотынышып, тәэсирле моң астында Мөштәри карт янына килеп җитәләр һәм... җисемсез рухлар шикелле, аны аркылы үтеп китәләр. Мөштәри карт моңа аз гына да гаҗәпләнми, яшьләргә сокланып карап тора. Аларның киемнәре дә бик сәер, тәннәренә сыланып тора. Кызның өс киеме ап-ак, ә егет күк төстән киенгән. Чалбар балакларыннан, агач тамырларын хәтерләтеп, ефәк чуклар асылынып-асылынып тора. Яшьләр шундый җиңел хәрәкәт итәләр — әллә атлыйлар алар, әллә биилэр, белмәссең...**

К у к т а м ы р е г е т е *(сизелерлек шелтә белән)*. Таңсылу! Менә ничәнче яз инде без синең белән икәү шушы мәхәббәт таулары арасыннан үтәбез, ә син һаман: «Мин риза, Ядомир!» дип әйтүне сузасың! Йөрәгең белән киңәшеп карагының булдымы?

А к т а м ы р к ы з ы *(назлы тавыш белән)*. Булды, Ядомир дустым... Күп тапкырлар киңәштем! Синнән аерылган саен читлегеннән очып чыгарга омтылган кошчык шикелле талпынган йөрәгемнән сорау алам!

К у к т а м ы р е г е т е *(ялкынлы карaш белән)*. Ул ни дип җавап бирә, Таңсылу?

А к т а м ы р к ы з ы. Ул һаман да дәшми...

К у к т а м ы р е г е т е *(катгый итеп)*. Бүген — соңгы тапкыр очрашуыбыз, актамырлар кызы, чибәрләрдән чибәр, гүзәлләрдән гүзәл Таңсылу!

А к т а м ы р к ы з ы *(башын күтәрә, горур)*. Яхшы, куктамырлар егете, кыюлардан кыю Ядомир дустым!.. Билгеләп куй: әнә көмеш ай-бөркет, канатларын җәеп, Кызылтау башындагы иң биек агачның очына кунарга бара! Ул, шунда кунып, тынып калуга минем соңгы сүземне ишетерсең!

К у к т а м ы р е г е т е *(ул да горур рәвештә башын югары чөя)*. Яхшы, мин риза, Таңсылу. «Әйе!» дигән сүзең яңгырауга, иреннәребез иреннәргә кушылыр!

А к т а м ы р к ы з ы. Шулай булыр, Ядомир дустым!

**Яшьләр, күктәге урак айга карап, тынып калалар. Серле музыка да каядыр еракка китеп барган шикелле, тоныклана, бик әкрен ишетелә башлый. Аның каравы, без ике яшь йөрәкнең дөп-дөп тибүен ап-ачык ишетәбез. Ләкин алар бер ритмда типмиләр. Егет моны ачык сизә һәм, тирән борчылып, янындагы сылу кыздан күзен алмый...**

К у к т а м ы р е г е т е *(талпынып)*. Таңсылу! Көмеш ай-бөркет Кызылтау өстендәге агач башына кунды! Син вәгъдә иткән серле мизгел килде!

А к т а м ы р к ы з ы *(вакытны сузарга теләгәндәй)*. Юк әле, Ядомир дустым!.. Көмеш ай-бөркет, канатларын җыеп, тынып калсын!.. Тагын аз гына көт!.. *(Ниһаять, бер карарга килеп, егеткә таба борыла.)*

М ө ш т ә р и *(сихерләнеп басып торган җиреннән яшьләргә таба ташлана)*. Соңгы сүзеңне әйтергә ашыкма, актамыр сылуы Таңсылу!.. Табигать биргән үз төсеңне сакла!

**Яшьләр, әлбәттә, Мөштәринең ачыргаланып кычкырганын ишетмиләр.**

А к т а м ы р к ы з ы *(ул шулай да, кинәт сискәнгәндәй, тирә-ягына карап ала)*. Хәзер... *(Кыз егет белән убешергә үрелгән җиреннән туктап кала: чөнки ул үзе кебек ап-актан киенгән бер егетнең килүен күреп ала.)*

**Тәңре белән Хода аяк өсте торып басалар.**

А к т а м ы р е г е т е *(кулларын кызга таба суза)*. Таңсылу!

А к т а м ы р к ы з ы *(егете кочагыннан сөлек кебек сыpылып чыгып, ак егеткә таба таптыла)*. Актай! Синме бу?! *(Кулларын аңа таба суза, җилкәсе аша Куктамыр егетенә таба борылып карый.)* Үпкә саклама миңа, Ядомир дустым!.. Шушы мизгелгә кадәр мин сиңа тугры булдым!.. *(Һәм ул, шундук Куктамыр егете турында онытып, йөзен Актамыр егетенең киң күкрәгенә яшерә.)*

**Серле моң кабат терелә, көчәя, бөтен җиһанны били. Сылуы артыннан кулларын сузып калган Куктамыр егете бөгелеп**

**төшә һәм җиргә убылгандай юкка чыга. Яшьләр сихри музыка астында талгын гына бөтерелеп биниләр. Актамыр егете, кочып биегән уңайга иелеп, берничә мәртәбә кызның иреннәрен үбәргә омтылып карый, ләкин кыз бәхетле мизгелне сузарга теләгәндәй, үбәргә ирек бирми, һәрвакыт читкә борылып өлгерә, әмма үзе кайнар йөрәгеннән ташкан мәхәббәтен яшермичә, кычкырып-кычкырып көлә. Менә егет, җаен туры китереп, тагы бер мәртәбә аның иреннәренә сарылырга омтылыш ясый, тик кыз арага кулын куеп өлгерә.**

Актамыр кызы. Ашыкма, Актай бәгърем!.. Бу бәхетле мизгелне мин гомеремнең таңыннан башлап өзелеп көтеп алдым!.. Хәзер инде аны бездән беркем дә тартып ала алмый... Әнә, күрәсеңме, изге Тәңребез безгә карап елмая.

Актамыр егете. Күрәм, җаналмам Таңсылу!.. Ләкин күрше тауда мин тагын бер шәүлә күрәм!.. Ә аның йөзен кара болыт каплаган!

Актамыр кызы. Борчылма, Актай бөркетем: Тәңребез саклый безне!.. Тәңребез!

**Мөштәри, ирексездән, Тәңре утырган якка борылып карый: ләкин тау өстендә беркем дә юк. Карт, аптырап, икенче тауга таба борыла, анда да урындык буш. Ул яшьләр басып торган якка борыла — алар да юкка чыккан. Сихри моң кинәт өзелә.**

Кифая *(Мөштәри карт янына килә)*. Атасы! Нишләп, төн карачкысы кебек, берүзең басып торасың монда?! Сине эзлиэзли җаным чыкты! Көне буе ач йөрисең үзең, җитмәсә... *(Картының кулыннан мылтыгын ала)*. Шушы тутыккан авыр нәмәрсәңне кая куярга белмәдең инде...

Мөштәри *(ул һаман да әле генә күз алдыннан кичергән вакыйгалар тәэсирендә)*. Хәтереңдәме, анасы, без синең белән менә шушы урында беренче тапкыр үбешкән идек?

Кифая *(картының маңгаен тотып карый)*. Ярар, атасы, ярар... Булгандыр... Яшь чагында ниләр булмас... Әйдә, өйгә керәбез...

Мөштәри. Их карчык, карчык!.. Гомергә хискә сүрән кеше булдың син... (Катгый). Бир монда! *(Мылтыгын кире тартып ала.)* Кайдале алар — сабакы малайның аталары?!

**Караңгылыкка кереп югалалар.**

## Дүртенче күренеш

**Мөштәри карт өендә «хәрби» киңәшмә. Мөштәри карт белән карчыгы кайтып кермәгәннәр әлегә. Гәрәйнең корбаны Фәридә икенче якта булырга тиеш, чөнки Фаягөл вакыт-вакыт эчке ишек янына әкрен генә барып колагын куеп тыңлый. Өйдә бу вакытта, шулай итеп, өлкәннәрдән Мәрәс белән Борһан һәм Фаягөл генә.**

Фаягөл *(иреннәренә бармагын куеп)*. Тс!.. Дрыхнет бугай.

Борһан. Карт бабай аңа нинди дару бирәм дигән иде бит... Йоклата торганны каптыргандыр. Кереп карап чыгыйм әле үзен...

Фаягөл *(өстәл янына килеп утыра)*. Еще чего?!. Ну, дорогие, мои, нишлибез?

Мәрәс. Өйләндерәбез сукин сынны! Икенче тапкыр бит инде! Ахмак!

Фаягөл. А я плевать на нее хотела!.. С высокой каланчи! Аның кебек проституткалардан куркып утырырга гына калды! Себерке асты саен кияү хәзер яшьләр өчен... Минем кайчандыр укыганым бар: если женщина үзе теләми, ирләр ничего не могут!..

Борһан. Туктале син...

Фаягөл. А ты молчи в тряпочку! Сиңа же не жалко его! Не твой сын! *(Елап җибәрә.)*

Мәрәс *(кызa төшеп)*. Молчать! Син дә сүз ясыйм дип утырган буласың! Атагыз әйткәнне тыңлагыз хәзер! Төрле хәлләр килеп чыгуы мөмкин. Дөнья бу. Шуңа күрә, алдан ук барысына да әзер булырга кирәк! Кәҗә тәкәсе шикелле чапкан малаен сүгәсе урынга!.. Һе! Менә инде... фикеремне өзде!.. Болай итәбез!.. Күпме акча бар янычгызда?

Фаягөл *(сагаеп кына)*. Зачем? Шул проституткага бирергәме?!

Мәрәс *(ачуы чыгып)*. Цыц!.. Кияү дә, син дә акча кортлары! Күпме бар янчыгызда — барысын да өстәлгә чыгарып салыгыз. Уен уйнар чак түгел монда!

Борһан. Алыр дисеңме, бабай? Акчасын алып, безне карама көленә утыртып калдырмасмы! Андыйлар да күп хәзер дөньяда!

Мәрәс. Алырмы, юкмы — кулда акча җитәрлек булсын.

Борһан. Гарри өчен генә инде!.. Мин гомерем буе хәләл көчем белән яшәдем! Бер сынык ипи табалмый интеккәндә дә хәлең ничек, дип килеп сораучы булмады. Башта — авылда чабатага туймадык. Соңыннан, хәтта диплом алып, түшкә инженер значогы таккач та, йөз тәңкәгә молиться иттек... Хәзер үзебез теләгәнчә яши башлагач кына... Хәерчегә җил каршы, дигәндәй! Башта ачыкларга кирәк әле, кыз булганмы ул, әллә анасына гына кызмы...

Мәрәс. Син дә сүз ясап утырма инде, Борһан кияү... Инженер булып ни кыр-

дың да, кооперативта ни майтарасың? Бер күлне сасытып, икенче күлгә килгән үрдәк кебек... Сәгъдәнә әбиең белән мин булмасам! Безгә рәхмәт әйтегез, укыгучы башыбыз белән, абруебыз түгелә, дип тормадык... Йә, бушатыгыз кесәләрегезне!

Ф а я г ө л *(кәҗә тоягы курсәтә)*. Вот — шиш ей! Миндә сансыз акчалар юк!

М ә р ә с. Малаегызны кәҗүнни ипи ашарга җибәрәсегез килмәсә, бишкуллап бирергә риза булырсыз.

**Борһан сүзсез генә кесәләрен актарып, өстәлгә акча ташлый. Мәрәс, җитди кыяфәт белән, акчаларны саный.**

М ә р ә с. Шушы гынамы?! Син нәрсә?! Бүген генә дөньяга килдеңме әллә? Кайбер нәрсәләрне кузгатканны көтмә, Борһан кияү. Күпме бар янызгызда — бөтенесен дә чыгарыгыз!

Б о р һ а н. Ладно, Фая, не скупись! Без акчаны тапмыйбыз, акча безне таба!

Ф а я г ө л *(әтисе алдына акча ташлый)*. Ну ладно, Боря, я тебе напомню это!

М ә р ә с *(тыныч кына)*. Икенче вакыт... *(Акчаларны саный.)* Җәмгысе дүрт мең дә җиде йөз сиксән дүрт сум... Биш мең итәргә кирәк булыр. Ярар... Үзебезнеке бераз бар...

Ф а я г ө л. Башта мин үзем с ней поговорю!

М ә р ә с. Карарбыз... Ул да, сезгә охшап, акча ярата торган нәмәрсә булып чыкса... Ә болай... Кыз менә дигән, минемчә. Сезнең ата ялкау малаегызга ул кыз да әрәм әле! Авылда туып үскән...

**Мөштәри карт белән Кифая карчык кайтып керә. Өйдәгеләр тынып калалар. Мөштәри, балаларына карамыйча гына, мылтыгын чөйгә элә.**

К и ф а я. Фаягөл кызым, казан астын терелтеп җибәрче?

Ф а я г ө л. Хәзер, бабуля...

**Шулвакыт эчке яктан Фәридә чыга. Өйдәгеләр барысы да аңа карыйлар. Фәридә шактый тыныч күренә. Хәзер алар каршында шашкан кыяфәтле мескен кыз түгел.**

М ө ш т ә р и *(кызның хәле җиңеләюен күреп)*. Хәлең аруландымы, кызым?

Ф ә р и д ә *(салкын)*. Балаларыгызның җавабы әзерме, бабай? Чыгып киткәндә сез аларга шулай дип әйткән идегез.

**Өйдәгеләр бераз югалып калалар.**

Ф а я г ө л *(ачы тавыш белән)*. Ага! Я вам что говорила?! Видите?!

Ф ә р и д ә *(ул үзен тыныч тота)*. Аларның нинди икәнлеген үзегез дә белеп бетермисездер әле, бабай. Рәхмәт сезгә, даруыгыз бик шәп булды! Тәрәзәне ачып, чыгып качмакчы идем, мине алдарга план кора башладылар.

Ф а я г ө л. Подслушивала, стерва! Пошла ты, знаешь, куда!

Ф ә р и д ә. Мин кумасагыз да китәм... *(Мөштәригә сөйли.)* Ә планнары мондый, бабай: миңа биш мең тәңкә акча биреп котылу.

**Мөштәри балалары өчен оялудан башын аска иеп тора.**

*(Кыз аның күз яшьләрен күреп ала.)* Еламагыз, Мөштәри бабай!.. Мин үзем гаепле монда... Шул кирәк миңа! Мәхәббәтнең күзе сукыр була, дигәнгә ышанмый идем... *(Башкаларга.)* Котыгыз алынмасын: судка бирмим Гарриегызны. Үзегезгә булсын! Ләкин җиңел генә котылдык дип уйламагыз: кая үзара талаша-талаша мине сатып алыр өчен җыйган акчаларыгыз? Китерегез монда!

**Аңа гаҗәпләнеп карыйлар, хәтта Мөштәри дә үз колагына үзе ышанмый тора.**

М ә р ә с *(җиңел сулап)*. Менә шулайрак булып бетәр бу мәрәкә, дип көткән идем аны! *(Кесәсеннән акчалар чыгара.)* Әҗер булсын, рәхим ит! И матри, башканы өмет итмә, аң бул! Әүвәле-ахры шушы булсын!

Ф а я г ө л. Не давай ей ничего!

М ә р ә с. Ник бирмәскә? Бирәбез! Без аңардан гына калмаган ич! Мә, кызым, рәхәтен күр! *(Фәридәнең кулына акча суна.)* Форсат барында нигә файдаланып калмаска, шулай бит, Борһан кияү? *(Фәридәне җилкәсеннән какмакчы була, ләкин кыз читкә тайпыла.)* Хәзерге заманда акчасыз берни дә эшләп булмый! Менә, ничек бит ул, эти, ә син безгә шикләнеп карыйсың. Хәзер шундый ул дөнья.

**Фәридә Мәрәснең сүзләренә игътибар итмичә, учак янына үтә һәм акча төргәген янып торган мичкә ташлый.**

Ф ә р и д ә *(үз-үзенә әйткәндәй)*. Менә шушы акчалар кебек көлгә әйләнде минем яшьлегем...

**Өйдәгеләр югалып кала: алар мондый борылышны көтмәгәннәр.**

*(Акчаларга дөрләп ут кабынганын көтеп тора да, ишеккә таба юнәлә.)* Алла сезгә түземлек бирсен болар белән, Мөштәри бабай!

Ф а я г ө л *(Фәридә китеп өлгергәнче учак янына ташлана)*. Ах так! Не бывать по-твоему! Не для твоей комедии копила я свои кровные деньги! *(Ялкын эченнән акчаларны тиз генә урелеп алмакчы була.)*

Ф ә р и д ә. Аһ, шулаймыни әле?! *(Чөйдә эленеп торган мылтыкны ала.)* Китегез мич яныннан!

**Фаягөл, аның янавына игътибар итмичә, кисәү агачы белән учакка үрелә.**

*(Фаягөлне куркытырга теләп, тушәмгә атып җибәрә.)* Я не шучу, тетя Фая! Мица хэзер терять нечего! Отойдите! Раз... *(Мылтыгын Фаягөлгә төзи.)*

Мөштәри. Ишетмәдеңмени?!

**Фаягөл әз генә арткарак чигә, ләкин һаман да бирешергә теләми.**

*(Фәридәгә.)* Бир монда, кызым, мылтыкны... Харап итмә үзеңне! *(Мылтыкка үрелә.)*

Фәридә *(Мөштәри яныннан читкәрәк тайпыла).* Юк инде, Мөштәри бабай! Болай булгач, шул пычрак акчалар янып бетмичә китмим мин!

**Шулвакыт Гәрәй атылып килеп керә.**

Гәрәй. Фрида! Брось ружье! Я женюсь на тебе!

Фәридә *(аңа таба борылып, мылтыгы белән Борһанга күрсәтә).* Вот как?! А он что скажет?! *(Борһанның калтырап төшүен күреп, мылтыгын атып бәрә һәм урамга ташлана.)* Сами разбирайтесь!

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### Бишенче күренеш

**Ике бүлек арасында бер елга якын вакыт узды.**
**Аксак авылында үткән көзге вакыйгалардан соң шактый зур үзгәрешләр булды. Гәрәй, чынлап та, әтисенең планы буенча Кифая карчык күрсәткән ташландык йортта чучка баласы үстерә башлады. Ачык кына әйткәндә, Гәрәйнең вазифасы әллә ни катлаулы түгел: симертергә дигән кәпәч борыннарны Бәкер исемле бер ир кайдандыр табып китереп тора, ә Гәрәй аларны вакытында ашата-эчертә, ә кондициягә җиткәннәрен Гәрәйнең әтисе Борһан машинасы белән шәһәргә ташый. Кыскасы, гади генә ит конвейры. Мөштәри карт белән карчык Кифая аларга комачауламадылар. Бигрәк тә Мөштәри карт. Фәридә белән булган хәлләрдән соң, өныгы белән сөйләшергә теләми иде. Хәер, Гәрәйнең моңа бик эче пошмады: аның максаты бер генә — акылсызлыгы аркасында гаиләкооперативына ясаган «ущерб»ны тизрәк эшләп кайтару да, кая да булса читкә таю. Соңгы вакытта аның эше тагын да җайлаша төште: Борһан белән Бәкер кайдандыр бер бик зур ана дуңгыз алып кайттылар. Чөнки кәпәч борыннарның бик зәгыйфьләрен күпмедер вакыт кулдан имезергә туры килә иде. Бу моментта Гәрәй иске йортның алгы ягында чучка балалары өчен иртәнге азык әзерләп маташа: мундирлы килеш пешерелгән бәрәңгене улакка салып, агач тукмак белән төя.**
**Тышкы ишектә Бәкер күренә. Ул, киндер капчыкка салып, чучка балалары тоткан. Таза гына, 40—45 яшьләрдәге ир. Ул телсез, шуңа күрә Гәрәй белән бары тик ымлап кына аңлаша. Гәрәй аңа, яшереп тә тормыйча, җирәнеп карый.**

Гәрәй *(сискәнеп).* Чего еще притащился?!

**Бәкер елмаеп капчыгына күрсәтә һәм эчке якка кертеп капчыкны бушатам, дип ымлый.**

*(Гәрәй аның капчыгын кулыннан тартып ала.)* Давай сюда! Нечего тут... В грязных сапогах... *(Эчке якка үтеп, капчыктагы дуңгыз балаларын бушатып чыга. Ишек ачылганда аннан дуңгыз мыркылдавы, чучка балалары чинавы ишетелеп куя. Бушаган капчыкны Бәкергә бирә.)* Топай.

**Бәкер, нидер сорарга теләгәндәй, ишек төбендә таптанып тора.**

Чего еще?!

**Бәкер, бармаклары белән ишарәләп, акча кирәк, дип аңлата.**

Иди, иди, топай, сказал. Бог подаст!.. Да нет у меня денег! У папы спроси. Он через неделю будет... *(Бәкергә аркасы белән борылып, эшен дәвам итә.)*

**Бәкер мескен кыяфәт белән күпмедер көтеп тора һәм, өмет чыкмаячагын аңлап, кул селтәп чыгып китә. Өйдә кабат тынлык урнаша. Бары тик Гәрәйнең тукмак белән шак-шок бәрәңге төюе генә ишетелә. Ул эченнән генә нидер сызгырына. Бераздан ул, эшен бетереп, улак белән бәрәңге боткасын эчке якка алып кереп китә. Тышкы ишек кабат саклык белән генә ачыла һәм... одеалга төреп яшь бала тоткан Фәридә күренә. Ул кергәч тә шулай ук саклык белән ишекне яба, тупса яныннан гына өйне күзләп чыга. Өйдәге искә чыдамыйча борынын җыерып куя — чучка фермасы бит!**

Гәрәй *(өстендәге пычрак халатына кулларын сөртә-сөртә эчке яктан чыга).* Син?!

**Озак кына карашып торалар. Гәрәй гаҗәпләнүдән авызын ачкан.**

Фәридә. Иягең төшеңә «дыңк!» итә бит, Гарри! Нәрсә, танырлык түгелме

әллә?.. Фридаң инде, Фридан!.. Күреп торасың — берүзем генә түгел мин. Кабул итмим, дисәң... туп-туры карт бабаңнарга барам!

Гәрәй. Мин нәрсә... Мин каршы түгел!.. Тик... Ничек инде алай... Үз балаңмы соң ул?

Фәридә *(көлеп).* Прокатка алып тордым!.. Чит кеше баласы нигә кирәк миңа?.. Мин үзем дә хатын-кыз... Йә? Ни әйтерсең?

Гәрәй *(ык-мык килеп).* Ни бит... Бик сәер... Син... һәм бала!

Фәридә *(мыскыллы).* Мине зиратта күчләгәндә... нәтиҗәсе болай булып бетәр дип көтмәгән идеңме?

Гәрәй. Нигә инде син алай... Яратып бит мин...

Фәридә *(кырт бүлдерә).* Әй! Шулай яратып кына мыскыл иттеңмени әле син мине! Ә мин, юләр, шикләнеп йөргән булам тагын! Яратмагандыр ул, мин әйтәм, яратса, бабаларының кабере өстенә салып таламас иде мине! Менә рәхмәт сиңа ачыгын әйтеп бирүең өчен! Хәзер күңелем тынычланып калды, ичмасам! Бер шигем дә калмады!

Гәрәй. Ярар!.. Син теләсәң ничек уйла... Тик бернәрсә аңламаган сабый балага санама мине! Мин дә... кайбер нәрсәләрне аңлый башладым хәзер... Ә гомумән — миңа барыбер! Нишләп ишек төбендә катып торасың — үт. *(Бераз шамакайланып һәм каушавын яшерергә тырышып, тиз генә баланы куяр өчен сәкегә урын әзерли: халат җиңе белән тузанны сыпыра, шактый каралып таушалган иске мендәр китереп куя.)* Рәхим итегез, мамзель!.. Онытканчы гафу үтенеп куям: алдан телеграмма сукмагач, чәчәк белән каршылый алмадым!

Фәридә *(баласын мендәргә яткыра).* Мэрси! *(Артында таптанып торган Гәрәйгә игътибар итмичә, одеалны чишә, кечкенә шешә белән сөт алып куя.)*

Гәрәй *(ул чыннан да бик каушаган, шуңа күрә югалып калган.)* Шәп булды әле бу!.. Берүземә бик күңелсез иде!.. Акылдан шашуың мөмкин! Кәпәч борын чучкалар да мин генә ич монда... Әй! Ана дуңгызны әйтми калдырганмын икән!.. Исеме бармы? Юк, малаймы, кызмы, дип сорамакчы идем?

Фәридә *(ул егетнең югалып калуына шат кебек.)* Исемен әйтсәм, малаймы, кызмы икәнлеген аера алырсыңмы соң?

Гәрәй *(иронияне сизми кала).* Әйтеп кара? *(Шунда гына аның аңына Фәриданең шаяртуы барып җитә.)* Чынлап сорыйм мин синнән!

Фәридә *(көлеп җибәрә).* Ярый әле бу өйдә көзге-фәлән юк икән!

Гәрәй. Аңламадым, көзгенең ни катнашы бар монда?

Фәридә. Кыяфәтеңне күрсәң үзең куркып качар идең!

Гәрәй. Ә миңа шулай ошый! Күрүче юк. Чучка караучы мин хәзер. Крестиян!

Фәридә *(җитди).* Шаһитлар юк дисәң дә... Ә мин килеп керер алдыннан гына кем чыгып бара иде моннан?

Гәрәй. А! *(Кул селтәп.)* Аны шаһитка санамаска да була.

Фәридә. Кем соң ул? Нишләп синең янга килеп йөри? Шешәдәшеңме әллә?

Гәрәй. Алкоголикка саныйсыңмы әллә мине?! Әгинең танышы. Дөресрәге, компаньон. Ул кәпәч борыннар табып бирә, мин аларны симертәм, шәһәргә җибәрә торам. Бер мәхлук шунда... Телсез ул. Күрсә дә, серең ачылыр, дип курыкма! *(Ул инде уз-үзен кулга алган.)*

Фәридә *(уйланып).* Кайдадыр күргәнем бар шикелле тоела ул миңа...

Гәрәй. Берәрсе белән бутыйсың син... Беркая да китеп йөрми ул. Фермада гына яши. Элегрәк урман каравылчысы булып эшләгән, диләр. Бик каты төшерә торган булган. Авыл халкы өчен урман каравылчысы да патша бит! Һәркем тегене сыйлый икән. Әкренләп үзе, йорт саен кереп, талап диярлек эчә башлаган. Килеп керүенә өстәлдә шешә белән аракы торсын, янәсе. Артыгын кылана торгач, бер мужик, тегенең гадәтен белеп, бер шешәгә кислота салып куйган. Теге, стаканга салып, авызына кабуы булган, ярты теле — капут! Ярый әле, кире төкереп өлгергән, ди. Шуннан калган ул телсез булып.

Фәридә *(күзләрен киереп ачып, Гәрәйгә карап тора).* Искә төште! Ә беләсеңме, ул бит... *(Телен аркылы тешләгәндәй тынып кала һәм шундук сүзне икенчегә бора.)* Исемебезне беләсең килә инде, әй?.. *(Баласы белән булыша.)* Бик беләсең килсә, әйтәбез аны, әйеме?.. Яшереп тормабыз, диген...

**Гәрәй, аның нидер әйтеп бетермәвен сизеп, шикләнеп карый.**

Исемем минем, бик беләсегез килә икән, Алсу була... Матурмы минем исемем?.. Әллә ошамыймы — җавапны ишетмәдек?

Гәрәй *(ваемсыз төс ала).* Ә миңа барыбер... *(Шулай да түзми.)* Бәкер абыйны каян беләсең син?

Фәридә *(исе китмәгән булып).* Калдыр әле шул телсез абыйны, диген, кызым... Фу! Кәпәч борын исе килә монда, ә минем борын тишекләре андый сасы искә күнекмәгән... Икәүләп янымда бөтереләсез, ә тәрәзәне булса да ачарга башыгызга килми!.. Тыш җылы... Әбекәйләр чуагы вакыты... Курыкмагыз, мин бу исле йортта озак тормаячакмын, әнием белән бик еракка китәм мин... Бөтенесен дә уйлап куйдык инде, диген...

Гәрәй. Миңа дисәгез... Хет ел буе торыгыз... *(Бер тәрәзәне ача.)*

Фәридә *(җитди).* Менә нәрсә, Гарри... Мин сиңа тагылырга дип килмәдем монда. Шикләнмә. Әлегә торыр урын булмаганга гына...

Гәрәй. Әнием куып чыгардымыни?

Ф ә р и д ә *(кискен)*. Анысы синең эш түгел! Тыгылма! Алсуның буыннары аз гына ныгысын. Күп булса... күп булса бер ай чамасы торырга урын кирәк безгә. Аннан соң — мин сине белмим, син мине белмисең! Килештекме!

Г ә р ә й. Ә бала кемнеке?

Ф ә р и д ә. Ничә ай үтте икән, санап карале?

Г ә р ә й. Ә... куып чыгарсам?

Ф ә р и д ә *(сынап карап тора)*. Куып чыгармыйсың, Гарри... *(Ачу белән.)* Куып чыгарасың икән — бөтен дөньягызның астын-өскә китерәчәкмен! Коры куркыту гына түгел бу! Син әле мине яхшы белмисең...

Г ә р ә й. Бераз белә башладым бугай инде!

Ф ә р и д ә *(кырт кисә)*. Белә башласаң бик әйбәт! Телеңне аркылы тешлә дә тик тор. Барыбыз өчен дә яхшырак булыр!

Г ә р ә й. Куркып калды бу димә!.. Миңа жәл түгел, теләсәң күпме яшә дидем бит инде.

Ф ә р и д ә. Димәк, килештек. Кабат кузгатма. *(Шыңшый башлаган баласын карый.)* Нишләп һаман мине ашатмыйсыз? Ничә чакрым юл түзеп килдем бит инде... Икесе сөйләшәләр дә сөйләшәләр... Ә минем турыда уйлап та караучы юк...

Г ә р ә й *(урында таптанып)*. Мин... чыгып торыйммы?

Ф ә р и д ә. Кирәкми, диген, кызым... Мин әниемнең күкрәгеннән иммим бит... Әниемнең нервлары бик какшаган, ахры диген... Шуңа күрә күкрәк сөте качкан, дип әйт... Башка төрле тәмле сөтебез бар безнең, әйбит, кызым... Үс-үс-үс-үс!.. Менә шулай... *(Баласына имезлек белән шешәдәге сөтне каптыра.)* Онытканчы, Гарри, Мөштәри бабаңнарның сыеры бармы, Алсуга көн дә шактый күп сөт кирәк булачак.

Г ә р ә й. Юк бугай... Кәҗәләре бар. Анысы точно.

Ф ә р и д ә *(башын чайкый)*. Шуны да белмисеңме? Нинди пошмас җан син, Гарри?

Г ә р ә й. Нәрсәгә кирәк миңа аны белү? Сыерлары бар ни миңа, юк ни! Миңа үз проблемам да менә моннан ашкан! *(Баш түбәсен күрсәтә.)*

Ф ә р и д ә. Чынлап та, ихтиозавр син, Гарри.

Г ә р ә й *(бераз үпкәләп)*. Каян беләсең син мине?!

Ф ә р и д ә *(сер белән)*. Ялгышасың, Гарри... Синең турыңда белгән нәрсәләрне сөйли башласам!.. Белмәвең яхшы.

Г ә р ә й *(чыгырыннан чыга башлый)*. Ярар, җитте! Ниндидер кинаяләр белән...

Ф ә р и д ә *(килешергә теләгәндәй)*. Җитте тек, җитте! *(Елмая.)* Карале, кызым, ирләрчә дә сөйләшә белә икән ул!

Г ә р ә й. Тагын бер сүз әйтсәң!... Йә бәреп үтерәм...

Ф ә р и д ә. Йә?

Г ә р ә й. Нишләргә икәнен үзем белермен! *(Кырт борылып чыгып китә.)*

Ф ә р и д ә *(артыннан кычкырып кала)*. Сөт алып кайтырга онытма... Кара аны, безнең монда икәнне бабаңнарга әйтеп салма тагын!.. *(Әкрен генә көлеп куя.)* Чынлап та гашыйк булганга охшый башлады бит әле бу, кызым... Дурак булса да жәл ул безгә, әйе бит?

## Алтынчы күренеш

**Икенче көнне таң алдыннан. Әлегә шактый караңгы чак. Тышта көчле яшенле яңгыр булырга тиеш, чөнки өй эче яктырып-яктырып китә. Йортның алгы яктагы сәкесендә Гәрәй белән Фәридә йоклап яталар. Урыннары аерым. Ә баланы, чучка балалары өчен боламык төя торган агач улакка урын түшәп, ике арага куйганнар. Хәтта кара төн дә яшьләрне кавыштырмаган. Иртәнге авыр йокы чагы. Ара-тирә эчке яктан ана дуңгызның мыркылдавы һәм кәпәч борыннарның нечкә итеп чинап куюлары гына ишетелеп китә.**

**Кинәт көчле итеп күк күкри һәм бөтен өй эчен гөлт итеп яктыртып яшен яшьни.**

Ф ә р и д ә *(куркып уяна һәм узенең кайда икәнлеген чамаларга тырышкандай тирә-ягына карана, ике арада яткан баласын, коры матраста бөрешкән Гәрәйне күрә)*. Гарри!.. Гарри, син йоклыйсыңмы?

Г ә р ә й *(ул алданрак уянган, күрәсең)*. Йоклыйм, әлбәттә!

Ф ә р и д ә *(аның йокламавына сөенеп)*. Ә ничек ишетәсең соң мине, алай булгач?

Г ә р ә й. Породам шундый минем... Кәпәч борыннарга охшаганмын... Алар да шулай... Бер күзләре ачык, икенчесе йомык килеш мышныйлар... Йоклыйлар, ахры, болар, дип карыйсың, алар — ана дуңгызның имчәкләрен имеп ята... Шуңа тиз үсәләр дә алар.

Ф ә р и д ә. Ә минем Алсу көне-төне бәй итә... Үз вакытында искә төшереп ашатмасаң, ачтан үләр иде!.. Ә инде бер ачыксамы!.. *(Әкрен генә көлеп куя.)* Бөтен дөньяга разбой сала!.. Түзеп кенә тор!.. Ярый әле Мөштәри бабаңнарның савым сыеры бар икән...

Г ә р ә й. Барын бар да... Кичтән кайтмаган әнә... Бүре-мазарга азык булмасын тагын, ди Кифая әби...

Ф ә р и д ә. Алла сакласын! Алсу белән нишләрбез аннан соң...

**Шартлап күк күкри һәм өй эче яктырып китә.**

Ой!.. Күк гөмбәзе шартлап ярылды, ахры!.. Әни шулай ди торган иде... Яшеннән куркам мин, Гарри. Ә син?

Гәрәй. Курыксаң... минем янга күчеп ят!

Фәридә. Акылың алтын икән...

**Тынып торалар.**

Син минем турыда... урам себеркесе икән бу, дип уйлыйсыңдыр инде.

Гәрәй. Һәркем үз тәненә үзе хуҗа...

Фәридә. Телисеңме, бер нәрсә сөйлим мин сиңа?

**Гәрәй дәшми.**

Әллә йокың киләме?

Гәрәй. Тыңлыйм ич.

Фәридә. Дәшмисең бит... Бик зур бер кимчелегем бар минем. Барыбер сиңа кайчан да булса «дуслар»ым сөйләрләр... Үзем алдан әйтеп куюм әйбәтрәк булыр... Кинәт куркытсалар, яисә көтмәгәндә берәр төрле авыр хәбәр ишетсәм, үлеп йокым килә башлый минем... Чын! Хәтта бер врачның әйткәне бар: әгәр дә, ди, кинәт бик каты котың алынса, мәрткә китүең бар, ди... *(Әкрен генә көлеп куя.)* Гомереңне йоклап үткәрәсең килмәсә, куркуга каршы чыныгырга тырыш, ди... Язган булса!

Гәрәй. Аңламадым соңгы сүзеңне?

Фәридә. Татар әйтеме ул... ана телеңне белмәгәч, аңламыйсың шул... Менә шулай, тәти егет! Беләсең килсә, теге вакытта зиратта нәкъ әнә шундый хәл булды минем белән! Ә син — һуштан язды, бу дип уйладыңмы?

Гәрәй. Димәк, безнең ике арада мышнап яткан бала... мәрт кошы була? *(Көлеп куя.)*

Фәридә *(ачусыз)*. Ахмак син...

Гәрәй. Шаяртырга да ярамый синең белән...

Фәридә. Уеннан уймак чыкты ич инде бер мәртәбә!.. Ашыкма, монсы баласы гына әле, мичтә булыр анасы, дип әйтте ди, бераү... Әтиең белән мөгезгә-мөгез килмәгәегез бер матур көнне... Кулына сугып тормасаң!

Гәрәй *(торып ук утыра)*. Ничек?!

**Яшен яшьнәп, күк күкри.**

Фәридә. Ят, ят... Күпне белсәң, тиз картаерсың...

**Тынып торалар.**

Синең турыда да шактый күп нәрсәләр беләм мин, Гарри... Кайберләре искә төшсә, тәннәрем чымырдап китә!.. Дөньяда яшисе бала булмагансың икән син... Бәхетең булган... Калганын әйтеп тормыйм инде, йокла...

Гәрәй *(бераз дәшми торгач)*. Мин үзем дә беләм аны, Фрида...

Фәридә. Нәрсә беләсең икән? Әйтеп карале?

Гәрәй. Беләм дигәч, беләм инде!.. Күрше хатыны сөйләде... Әниең ничек итеп кияүгә чыкканчы бераүдән алданганлыгын да...

Фәридә. Җитте, артыгын сөйләмә, Гарри...

Гәрәй. Нигә сөйләмәскә... Әкият кебек кенә тоела ул хәзер миңа... Үзем белән булган кебек түгел... Иң беренче мәртәбә ишеткәндә генә... Әниең мине тапкан төнне чүпрәккә төреп чүплеккә ыргытуы... Бр-р! Борһан исемле бер егет шунда килеп чыкмаган булса!..

Фәридә *(ул караңгыда Гәрәй янына килеп җиткән)*. Кирәкми, Гәрәй җаным!.. Телгәләмә үз җаныңны... Ничек йөрәгең түзеп шулай җиңел сөйли аласың?!. Хәтта мин тыныч кына тыңлый алмыйм! *(Башта ул, сөйләмә, дип Гәрәйнең авызын кулы белән каплый, аннан соң аны үбәргә тотына.)* Икебезнең арада теге хәл киртә булып тормаса, беркемгә дә бирмәс идем мин сине!.. Төшләремә керәсең син минем!.. Гарри, дип дәшәсем килми минем сиңа... Гәрәй ич синең чын исемең!.. Баламның теле ачылганда сине дә татарча сөйләшергә өйрәтер идем мин... Алсу турында әйтмим мин...

Гәрәй. Юк!.. Теләмим татарча өйрәнергә!! Чөнки ул әниең туган теле. Ә мин аны теге хәлләрне белгәннән бирле күрәлмим!

Фәридә *(үбә)*. Юләр... Барыбер әни ич ул сиңа... Сиңа дөнья бүләк иткән кеше...

Гәрәй. Дөнья чүплек дип аталса, син хаклы!

Фәридә. Дәшмә...

**Аларның сөйләшүе ишетелми башлый. Яшенле яңгыр да тына. Караңгылык бермәлгә куерып киткәндәй була һәм бераздан сызылып таң ата. Тиздән өй эчендә бөтен нәрсә ачык төсмерләнә башлый. Сәкедәге бер урын буш: Гәрәй белән Фәридә бергә кочаклашып йоклыйлар. Бер читтә агач улакта сабый бала йоклый.**

**Менә, беренче булып, Гәрәй уяна һәм, янында Фәридәнең йоклап ятуын күреп, елмаеп куя. Иплән кенә Фәридәнең куенынннан шуышып чыга, киенә, малларына иртәнге азык әзерли башлый. Моның өчен аңа улак кирәк була: ул йоклап яткан баланы сак кына «бишеге»ннән күтәреп ала һәм сәкегә куеп, мендәренә яткыра. Бала уянып елый башлый. Гәрәй аны тиз генә кулына күтәреп тирбәтергә тотына.**

Фәридә *(бала тавышына уяна)*. Хәерле иртә, Гәрәй!.. Кичә бик арыган... Китер үземә.

Гәрәй. Юк, үзем генә... Бик иртә әле... Менә — тынды да. *(Баланы мендәргә яткыра.)* Мин Мөштәри картларга сөткә барып киләм. Сыерлары кайткандыр инде. Бер уңайдан балаңа бишек тә ала кайтыр-

мын... Моннан өч-дүрт йорт аша гына бер ишегалдында аунап ятканны күргән идем. Син йокла, йокла, Фрид...

Ф ә р и д ә. Фәридә, диген!.. Ә син бик тырыш хуҗа булырга чамалыйсың, Гәрәй... Кемгә охшап икән?

Г ә р ә й. Ярар, сүзне икенчегә бордык!

Ф ә р и д ә. Баш өсте, иптәш фермер! Сүзне икенчегә бордык дигәннән. Кифая әбиеңә кем өчен кирәк дип аңлаттың соң?

Г ә р ә й. Ә кәпәч борыннар? *(Эчке якка ымлый.)*

Ф ә р и д ә. Бер котмәгәндә бабаңнар үзләре өскә килеп керсәләр, кая кереп качарга тишек тапмаячакбыз без синең белән, Гәрәй!

Г ә р ә й. Бог не выдаст, свинья не съест, диләр руслар! Мин киттем, йоклагыз... *(Чыгып китәргә әзерләнгән жиреннән туктый һәм, Фәридә аны-моны уйлап өлгергәнче тиз генә янына менеп үбеп ала.)* Синнән дә татлырак кыз юк дөньяда, Фрида! *(Ашыгып чыгып китә.)*

Ф ә р и д ә *(Гәрәй чыгып киткәч, житдиләнеп уйланып ята).* Ни белән генә бетәр инде бу... Хәерлегә булсын! *(Уйланып ята торгач, кабат йокыга китә.)*

**Бераздан өйгә Бәкер килеп керә. Йөзе бик борчулы. Кулында кечәге капчык, тик ул бүген буш. Сәкедә йоклап яткан Фәридә белән балага гаҗәпләнеп карап тора, үзенчә тел шартлата. Юләрләр дигәндәй, бармагын чигәсе янында бөтерә. Башын кашып тора һәм ишегалдына чыгып, кире әйләнеп керә. Кесәсеннән кәгазь-каләм алып нидер яза. Кәгазен Гәрәй күрерлек жиргә куярга теләп, тирә-ягына карана һәм улакка сала. Эчке якка үтеп, капчыгына дуңгыз балалары тутырып алып чыгып китә. Озакламый Гәрәй кайтып керә. Аның да йөзе чытык, чөнки сөт алып кайтырга әзерләгән савыты буш. Димәк, карт бабаларыннан сөт таба алмаган. Шуңа борчылуыннан, ахры, ул бала бишеге турында да оныткан. Ул кайтып керүгә бала уянып, елый башлый.**

Г ә р ә й *(тиз генә баланы кулына ала һәм юатырга тырышып, кулында тирбәтә, әмма бала әзгәләнеп шыңшыдан туктамый).* Астың юешме әллә синең? *(Капшап карый.)* Юк, юешкә охшамаган... Ашарга сорый торгандыр инде бу... *(Буш шешәдән имезлеген алып, баланың авызына каптыра.)*

**Бала бераз гына тынып тора да яңадан елый башлый. Гәрәй, уянмаса ярар иде дигәндәй, Фәридә яткан якка карый-карый баланы тынычландырырга тырыша. Бер дә тынычландыра алмагач, ишегалдына алып чыгып китә. Анда да чара таба алмыйча, кире өйгә алып керә.**

Г ә р ә й. Нишләргә инде моның белән?.. Кәпәч борын түгел ич син, шулар янына илтеп кенә куяр идем дә... Стоп! Ә нигә эксперимент ясап карамаска? Әниеңә әйтеп тормыйбыз... Бер суырганнан дөньяң җимерелмәс! Сыртыңа да кыл үсмәс, әйеме? Тазарак кына булырсың!.. *(Баланы эчке якка алып кереп китә. Бераздан бала елаган тавыш тына, бары тик ана дуңгызның мыркылдавы ишетелгәли.)*

Г ә р ә й *(эчке яктан чыга, аның кулында бала юк, ә йөзендә тирән гаҗәпләнү).* Кая булганнар бу кәпәч борыннар?! *(Сәке астына иелеп карый, идәндә яткан агач улакка абына һәм андагы язуны күрә. Укып чыга һәм Фәридәгә ташлана).* Фрида!.. Тор әле!.. *(Израп йоклаган Фәридәне уята.)* Мин югында кем керде монда?.. Теге телсез Бәкерме?!

Ф ә р и д ә *(йокысыннан айный алмый тора).* Ни булды, Гәрәй?.. Белсәң иде шундый начар төш күреп ята идем!.. Ярый әле син уяттың!.. Йөрәгем әле дә калтырап, леп-леп итеп тора... Сөт алып кайттыңмы?

Г ә р ә й. Сөт кайгысы түгел әле монда! Күрмәдеңме, мин монда югында кем кереп чыкты?!

Ф ә р и д ә. Ничек күрим?.. Изелеп йокладым, дим ич! Нәрсә булды?

Г ә р ә й *(ачулы).* Чучка балаларын кемдер төяп алып чыгып киткән! Менә язуы! Автограф калдырмаган!

Ф ә р и д ә *(киерелә-киерелә язуны карап чыга).* Берни аңламыйм... Нинди тикшерү?.. Кемне тикшерәләр?

Г ә р ә й *(язуны тартып ала).* Безне тикшерәчәкләр! Чучка балалары колхоз фермасыннан урланган булган икән! Шул ачылган! Белгән булсам!.. Шул адәм актыгы Бәкернең эше инде бу! Сволочь! Күренсен генә!

Ф ә р и д ә *(Гәрәйнең куркуы аңа да тәэсир итә).* Әтиеңнәр беләме икән соң? Чучка балаларының урланган икәнлеген, дим?

Г ә р ә й. Каян белим мин аны?! Бәкер белән әти килешкән иде. Күрәләтә ул да җинаятькә бармас иде инде!.. Хәер, акча исе чыкса, анысы да...

Ф ә р и д ә. Нишләргә уйлыйсың инде хәзер?

Г ә р ә й. Нишлим? Ана дуңгызны артына тибеп куып чыгарам да, ишекне аркылы такта белән кадаклыйм. Өстәвенә, ансы да урланган мал булып чыкса!.. Алып кайтканда икесенең дә авызы колак артына эленгән иде!

Ф ә р и д ә *(үзенчә нәтиҗә ясап).* Димәк, миңа да моннан үкчәне күтәрергә туры киләчәк... Ә бала кайда?! *(Ул шунда гына баласының өйдә юклыгын күрә.)*

Г ә р ә й *(кул селти).* Балаң өчен кайгырма, монда гына ул. Рәхәтләнеп сөт имә...

**Шулвакыт эчке яктан үзәк өзгеч ачы итеп бала кычкырган тавыш ишетелә.**

Мине чакыра! Хәзер... *(Эчке булмәгә ташлана.)*

Ф ә р и д ә *(башын чайкап).* Ирләр акылы — ирләр акылы инде!.. Берүзен калдырып чыккан... *(Торып өстен рәтли: ул эч-*

*ке кулмәктән генә. Кулмәген кия башлый һәм Гәрәйнең озаклавына бераз гаҗәпләнеп, ишеккә килә.)*

Гәрәй *(шашкан кыяфәт белән эчке яктан атылып килеп чыга һәм, Фәридәнең якынаюын күреп, артыннан ишекне яба. Аның кулында бала юк).* Сиңа керергә ярамый анда, Фрида!.. Кертмим!.. *(Ишеккә аркылы баса, үзенең бөтен тәне бизгәк тоткан кебек калтырый.)*

Фәридә *(ул әлегә берни дә аңламый).* Ничек инде ярамый? Кызык... Алсу шунда ич! Ташлале, шаярма. Кара, нишләп алып чыкмадың аны?

Гәрәй. Алсу юк анда, Фрида... Ул анда түгел... Бүтән җирдә ул... Хәзер алып киләм мин аны... Син... ишегалдында юына тор... Анда комган белән су бар...

Фәридә *(сагаеп).* Ничек инде?!. Әле генә чырыйлап бала кычкырды ич?!

Гәрәй. Алсу түгел ул!.. Чучка баласы чинаган... Берсен онытып калдырганнар.

Фәридә *(ниһаять, ниндидер коточкыч хәл булганлыгын сизенә башлый).* Я, шаярма, дим, Гарри!.. *(Гәрәйне читкә этеп җибәреп, ишеккә ташлана.)*

Гәрәй *(җан ачысы белән).* Бәреп үтер мине, Фрид! Мин генә гаепле монда! Бик каты елады да... Түзмәдем... Мин аны бер генә каптырып карарга теләгән идем! Шундый рәхәтләнеп имә башлады! Аерырга кызгандым! Сыерныкы да, аныкы да бер үк төрле сөт бит! Балта белән тураклыйм мин аны хәзер! *(Сәке астыннан балта тартып чыгара.)*

Фәридә *(пышылдап).* Нәрсә дидең?!

Гәрәй *(коелып төшә, балтасы шапылдап идәнгә бәрелүен дә сизми).* Алсу юк анда, Фрида... Аны... аны дуңгыз таптап үтергән!

Фәридә *(урмәкүч пәрәвезе сарылгандай, кулы белән битен берничә мәртәбә сыпыра, үзе тыела алмыйча тоташтан авызын ачып исни башлый).* Тере баланымы?.. Юри кыланасыңмы әллә?.. *(Гәрәйнең сүзләре, ниһаять, аның аңына барып җитә. Ул тиз генә эчке ишекне бәреп ача һәм, бертын карап торганнан соң, ишек яңагына сөялеп, йокыга тала.)*

*Гәрәй (Фәридәнең идәнгә ава башлавын күреп, тотып кала, нишләргә белмичә, аны селкетә, яңакларына суккалый).* Фрида!.. Йоклама!.. Минем ни әйткәнне аңладыңмы?! Мәрткә китәсең бит!.. Ишетәсеңме мине?! Мәрткә киткән кеше тиз генә уяна алмый, диләр!.. Йоклама, зинһар! *(Фәридәнең яңакларына катырак итеп суга.)*

Фәридә *(бик авыр итеп күзләрен ача, ләкин йокылы-уяулы сәер хәленнән чыга алмый).* Ә, Гарри... Син икәнсең... Ә бит баланы берүзен юри калдыргансың син... Кансыз кеше син, Гарри... *(Кабат күзләрен йома һәм гәүдәсе белән Гәрәйнең кулына салынып төшә.)*

Гәрәй *(тетрәнеп).* Нәрсә дидең?!. Кабатлале!.. *(Фәридәне җилтерәтә.)* Уян, дим! *(Сәке читендә торган чәйнектән су кабып, Фәридәнең йөзенә бөрки.)*

Фәридә *(күзләрен ачар-ачмас).* Җәфалама мине зинһар, Гарри... Мин сиңа бер нәрсә әйтермен, дигән идем... Яратуым турында түгел... Татар кызлары кычкырып әйтмиләр аны... Әнием шулай, ди... Ә! Исемә төште... Теге телсез кеше турында... Бәкер исемле дидеңме әле?.. Әйе, Бәкер бугай... Ул синең әтиең икән, Гарри... Борһан абый сөйләгән иде... Алар кайчандыр әниең белән... Кунакка кайткан саен... урманда очраша торган булганнар... Искиткеч матур бит бу якның урманнары... *(Йокыга чума.)*

**Гәрәй аны төрлечә кыландырып уятып карый, ләкин Фәридә аны-моны сизәрлек хәлдә түгел. Алар шулай идән уртасында чайкалып басып торалар. Гәрәй бите буйлап тәгәрәп төшкән күз яшьләрен дә сизми, ахрысы...**

## ЭПИЛОГ

**Бер ел чамасы вакыт узган.**

**Кара-каршы яткан ике калкулык буш: урындыклар да, Мөштәри карт үткән ел кадап куйган язулар да юк. Бары тик ул казыган кабер чокырлары гына калган. Калкулыклар аермасында Мөштәри карт таякка таянып басып тора. Аны танырлык түгел. Карт өчен җиңел булмаган, күрәсең, бу ел. Ул күзгә күренеп нык бирешкән, тагын да бөкрәя төшкән. Мөштәри карт калкулыкларның берсенә менмәкче булып урыныннан кузгала, ләкин, хәле бетеп, туктап кала. Кире юлга төшеп, бераз офыкка таба атлый һәм озак кына туктап кала. Кире юлга төшеп, ял итеп тора. Менә аның игътибарын калкулыкларның берсенә үрмәләп менеп барган ниндидер бик кечкенә җан иясе җәлеп итә,— ул, гаҗәпсенеп, аның (берәр төрле бөҗәк-мазардыр инде!) хәрәкәтен күзәтеп тора.**

Мөштәри. Һе!.. Шушы тырнак чаклы җан иясенең дә үзенә күрә ниндидер бер максаты бардыр инде!.. Әйдә, әйдә, тырыш, бөҗәк, мин менә алмадым үргә — син мен! Хәрәкәтлән шулай — хәрәкәттә бәрәкәт!

Тәңре *(бөҗәк менеп барган калкулык өстендә пәйда була).* Аягың астында кыймылдаган кечкенә бөҗәктән дә көнләшәсеңме хәзер, тарихчы Мөштәри?!. Кызыкма син аның күз иярмәс җитез аякларына: ул мәхлукның гомере шушы кал-

кулыкка менеп җиткәнче генә калды. Монда менеп җитүгә бер чыпчык кабып йотачак аны!

Мөштәри *(Тәңренең пәйда булуын ул табигый хәл итеп кабул итә).* Баеп барган кояш айга кырын карый, имеш, изге Тәңре! *(Таягы белән бөҗәкнең юлын бүлеп, кире якка таба борып җибәрергә тели.)* Вәт кире беткән уҗәт бөҗәк... Менмә анда! Әҗәлең көтеп тора анда сине.

Хода *(ул курше калкулыкта пәйда була).* Язмыштан узмыш юк, авылның соңгы бәндәсе Мөштәри! Калдыр ул бөҗәкне! Үз язмышыңны уйла! Аның гомере киселгәндә синең сәгатең дә сугачак! Фани дөньяда бәхилләтәсе кешең калды, дип уйласаң — ашык! Язмышыңа үпкәли алмыйсың. Күпме теләдең, шулай яшәдең. Бөтен авылдашларыңнан озаграк. Үзең дә беләсең: кан-кардәшләреңне, нәсел-нәсәбеңне бәхилләтергә вакытың җитми, дип куркасы юк: бөтен нәселең читләктә, теләсәң дә күрешә алмассың.

Мөштәри *(тетрәнеп).* Өлкән улым Мәрәс иректә ич! Ул минем мирасчым булып калырга тиеш!

Тәңре. Үз-үзеңне алдап юанма, тарихчы Мөштәри: син аңа күптән кул селтәдең. Акламады ул синең көткәнеңне! Чөнки казна ашаган казалы булыр, дип вакытында әйтмәдең син аңа. Үзе аңлар, дидең. Ә бит кешене юлга чыгарып җибәргәндә юнәлешне күрсәтәләр.

Мөштәри *(авырлык белән пышылдый).* Тын алырга ирек бир, изге Тәңре... Мин гомерем буе бала үз ата-анасына охшап үсә дип ышандым.

**Шулвакыт офык янындагы калкулык-тау ягыннан мыскыллы көлү тавышы яңгырый: менә ул көчәя, бөтен гавамны тутыра. Өчесе дә шул якка борылып карыйлар: анда ниндидер шәүлә генә төсмерләнә...**

Тәңре. Яхшы, тарихчы Мөштәри. Син үзеңне «Аксак авылының соңгы карты» дип йөри идең. Бер соравым бар сиңа.

Хода. Бөҗәк калкулыкның уртасына менеп җитте, кыскарак тот, коллега.

Мөштәри *(ирексездән калкулыкның урта җиренә карап ала).* Гомеремнең соңгы секундлары якынлаша, изге Тәңре! Ни сорарга теләвеңне аңладым кебек мин. Туган авылымның бетүенә кем гаепле, шуны сорамакчы идең... Мин үзем гаепле!

Тәңре. Ачыграк аңлат, тарихчы Мөштәри?

Мөштәри. Кифая карчыгым белән икәү ике малай, өч кыз үстердек без. Беренче малаема, варисым булыр дип, Мәрәс дигән исем бирдем. Дөрес әйттең — өметем акланмады. Икенче улыбыз яшьли сугышта башын салды. Өч кызыбыз, өчесе дә балигъ булырга өлгерүгә, урыс балаларына кияүгә чыгып, читкә китеп бардылар... Бүгенге көндә Мәрәс яше зур булу аркасында гына акчасыз фатирда кәҗүнни ипи кимерми. Ныклап уйлап карасаң, нәселемне дәвам итүче бердәнбер оныгым Гәрәй хәзер. Ул да читләктә. Ләкин бер әйләнеп кайтачак бит ул!

Хода. Игә килүенә өметләнәсеңме? Ул бит синең телеңне дә белми. Ничек аңлашырсыз икән?

Мөштәри. Өметсез бер шайтан диләр, изге Хода! Аңлар ул мине! Бер генә мәртәбә булса да күрештерегез безне!

Тәңре. Йөрәгеңне учыңа каты итеп кыс, тарихчы Мөштәри! Бу хәтта безнең кулдан да килми торган эш!

Мөштәри *(тетрәнгән зәгыйфь тавыш белән).* Аңларга тиеш ул мине, изге Тәңре! Болай китәргә ярамый миңа! Урыс башлы булып туган бала түгел иде бит ул! Анасы да атасы да, ләгънәт төшсен аларына, татар балалары!

Хода. Муенына таккан тәресен күрдеңме соң оныгыңның?

**Мөштәри карт кинәт чайкалып куя.**

Егылмый тор, йөзьяшәр Мөштәри! Гомереңнең соңгы мизгеле түгел әле бу. Бөҗәк калкулыкка менеп җитмәде әле... Тагын нидә гаеплисең үзеңне?

Мөштәри. Тагын нидә гаеплимме?.. *(Уйлап тора.)*

Тәңре *(боеру тоны белән).* Ашык, Мөштәри! Бөҗәк калкулыкка менеп җитеп килә! Әҗәле ашкындыра аны!

Мөштәри *(башын күтәрә).* Хәзер, бер генә секунд, изге Тәңре... Тыным кысыла... *(Үзләренең йортлары ягына таба борыла.)* Күзләрем томалана!.. *(Коты алынып.)* Кем ул анда?!

Тәңре *(Мөштәри карт әйткән якка карап).* Бер җан иясе дә күренми, Мөштәри!

Мөштәри *(кулы белән төртеп күрсәтә).* Әнә бит! Кемдер атасының баш сөягеннән тустаган ясап аракы эчә!..

**Аллалар Мөштәригә таба борылалар: карт юлга егылып җан биргән инде.**

**Калкулыктагы аллалар, пәйда булган кебек үк, томанланып югалалар. Бары тик офыктагы шәүләнең шаркылдап көлүе яңгырый.**

Кифая *(аның тавышы башта өйләре ягыннан ишетелә, әкренләп ул үзе дә, кулына зур курчак тоткан Фәридә дә күренә башлый).* Ә мин синең килерене белдем, кызым...

Фәридә *(бераз оялып, ләкин үз кадерен үзе белгәндәй).* Баламны юындырасы иде, Кифая әбекәй... Җылы су әзерләп буламы?

Кифая *(Фәридәгә сынау белән карап тора).* Ник булмасын? Самавыр кайнаган... Әнә теге чиләктә — салкын су... Кәритәсе, өйалдына кергәндә күргәнсеңдер, чөйдә эленеп тора...

**Фәридә сүзсез генә Кифая карчык әйткәннәрне эшли: алгы якка чыгып, таз алып керә һәм, ике урындык куеп, аны**

**шулар өстенә урнаштыра, самавырдагы кайнар суга салкын су өстәп, тазга сала. Ул арада Кифая Фәридәнең курчагын төргән одеалны сүтә.**

*(Иркә тавыш белән.)* Олан икән!.. Тфү-тфү, күз тимәсен, минем кулым түгел, Гайшә Батман кулы... Әйдә, үс-үс... *(Кулларыбелән пластмасса курчакның аякларын-кулларын сыйпый.)* Менә шулай... Менә шулай төзәлә ул юлда ватылган гәүдә... Күнегә башла... Ә син ат ите ашаганга кызыккан урыс кызы кебек катып торма!

Ф ә р и д ә *(суын әзерләп бетереп, Кифая карчыкның курчакны иркәләвен карап тора: бу яшь хатын белән йөзьяшәр карчык әйтерсең лә беркайчан да аерылышмаганнар, бер-берсен бер-ике сүздән аңлыйлар).* Су әзер, Кифая әбекәй...

**Кифая карчык, үзең юындыр дигәндәй, читкәрәк китә һәм Фәридәнең хәрәкәтләрен күзәтә: бала карый беләме, юкмы! Фәридә ышанычлы салмак хәрәкәтләр белән курчакны юындыра башлый.**

К и ф а я *(бераз сүзсез генә карап торганнан соң).* Нишләп балаң белән бер дә сөйләшмисең?! Телеңне җәллисеңме әллә?

Ф ә р и д ә *(гаҗәпләнеп).* Нәрсә аңлый әле ул, Кифая әби!..

К и ф а я. Аңламас!.. Үзегез аңсыз үскәч тә!.. Карынында чакта ук сине тыңлап үскән ул! Әйдә, кабатла минем арттан... *(Бераз көйләп такмаклый башлый.)*

Атаң кискән утын түгел,
Анаң яккан мунча түгел...

Нишләп авызыңа су каптың?.. Минем арттан кабатла, дим ич!

Ф ә р и д ә *(аңа Кифаяның такмагы бераз көлке булып тоела, ләкин шулай да олкән кешене упкәләтәсе килми).* «Атаң кискән утын түгел...» Дәвамын оныттым да инде, Кифая әби! *(Йомшак кына көлеп куя.)*

К и ф а я *(ачуланып).* Китер әле үземә!.. *(Фәридәне читкәрәк этәреп, курчакны үзе юындыра башлый.)* Ә син отып калырга тырыш!.. Инде хәзер аларны үзең дә белә башларга вакыт — ана булгансың... *(Такмаклый-такмаклый курчак юындыра.)*

Атаң кискән утын түгел,
Анаң яккан мунча түгел.
Аю баласын чабам,
Бүре баласын чабам...

*(Сиздерми генә Фәридәгә карап куя: авыз эченнән генә такмакны кабатларга тырышуын күргәч, дәвам итә.)*

Имәндәй нык бул,
Чыршыдай биек бул,
Каендай ак бул,
Чишмәдәй саф бул!
Аталы-аналы бул,
Алтын канатлы бул...

**Фәридә, кинәт күз яшьләренә буылып, үкси башлый.**

*(Аның елавын бүлдереп.)* Туктама, кабатла! Намазны да бүлдермиләр, ә бу — намаз гына түгел! *(Дәвам итә.)*

Бай дәүләтле бул,
Кортлы-коңгызлы бул!
Бабайны күрсәң, —
Бабай, дип әйт.
Әбине күрсәң, —
Әби, дип әйт.
Өлкәнне күрсәң, —
Абый, апа, дип әйт.
Кечене күрсәң, —
Сеңлем, энем, дип әйт.
Кечене кече ит,
Олыны олы ит!
Тәмле-татлы телле бул,
Ата-анаңа итагатьле бул!

**Тора-бара, Фәридә, Кифая карчык артыннан чын күңелдән ияреп, аның такмагын кабатлый.**

...Озын гомерле бул!
Бер кулың майда,
Бер кулың балда булсын!
Башыңа шербәт сиптем —
Шифалы булсын!
Тәнеңә сулар сиптем —
Сихәтле булсын!
Аю баласы!
Бүре баласы!
Бүрәнәдән — май,
Ябалактан — йон!..

*1989—1990*

# ИХЛАСЛЫК

*Торгынлык дип йөртелгән елларда шактый гына әдипләребез бик яшь көенчә бу дөнья белән саубуллаштылар. Фаил Шәфигуллин, Тәуфикъ Камалиев, Ринат Рәхимов... Аларның басылмаган әсәрләре дә калды.*

*Менә безгә шагыйрь Ринат Рәхимов калдырып киткән шигырьләр. Аларда Ринатның эчкерсез күңеле, кешеләргә һәрчак яхшылык кына эшләп торган йөрәге. Һәр сүзендә, һәр эндәшендә йөрәгенең типкәне сизелеп, үзенең яшәвен әле дә белдертеп тора.*

*Шигырьләрдә без шагыйрьнең куанычлары, борчылулары белән тагын бер мәртәбә очрашабыз һәм тере шагыйрьнең үзен күреп, сөйләшеп торган кебек булабыз. Ихлас сүз, керсез йөрәк — кеше үзе китсә дә — исәннәр белән бергә кала, бергә яши икән...*

**Хисам КАМАЛОВ**

## Ринат Рәхимов

### Чишмә бурасы

Имәннән булсын өске ниргәсе,
Каеннан булсын аскы ниргәсе.
Үсмер кызлар бар, яшь киленнәр бар
Шушы чишмәгә суга киләсе.

Имәннән булсын өске ниргәсе,
Каеннан булсын аскы ниргәсе,
Каен тузыдай ак өмет белән
Су юлларыннан иркәм киләсе.

Каен суыдай татлы су булсын;
Суга тәм бирсен, елмайсын сиңа,
Соклансын сиңа судагы рәсем.

Имәннән булсын өске ниргәсе,
Каеннан булсын аскы ниргәсе,
Чиләгең, сеңлем, төпкә тимәсен,
Үзеңнән саклан, күзең тимәсен.

*

Язлар житкәч, чыгып китәрмен,
Болан сыман, чемченергә үлән тамырларын...
Сабый чагымда болын-кырлардан
Витамин җыеп мин исән калдым.

Җир генә кипсен, чыгып китәрмен,
Авыз итәрмен үлән тамырларын.
Юа, кузгалак, акбал, какылар,
Кәҗә сакалын... таныйм мин барын.

Яшәрсен генә җир, чыгып җитәрмен,
Өшәнгән ат сыман, исеннән табармын
Шифалы үләнне — кешелек тамырын.

Юып алгандай булыр авыруым.
Табигать улы мин, үләннәр — даруым.

## Туктый алмый...

Телелентадагы кебек,
акрын гына әйләндереп,
Үткәннәрне уйлыйм.
Тукта, мизгел! Син бит изге.
Ул чагында әйтә алмый калдым
иң кирәкле сүзне.
Гамьсез әңгәмәче сыман,
хәтер тупас өзде.
Шул мизгелдә кыйммәт иде
синең әйтер сүзең,
Мизгел туктый алмый, вакыт битараф ул,
син гаепле — үзең.

*

Бер уч утлы күмер син,
Кулдан кулга күчерәм.
Янсам янам, көйсәм көям,
Әмма җиргә төшермәм.

Һәм бозланган тимер син,
Учтан учка күчерәм...
Өши-туңа, яна-көя,
Шулай сине төшенәм.

*

Җырлар язмыйм, бары орлык чәчәм:
Күңелемдә серле җыр шытса,
Сокланудан тәүге кыякларга,
Сүз табалмый телем тотлыкса;
Җырлар язмыйм, бары иген игәм:
Күңелемдә өмет-җыр шытса,
Сокланудан тулган башакларга,

Тел очында гына сүз торса,
Җырлар язмыйм, бары иген җыям:
Күңелемдә әгәр җыр туса,
Сокланудан алтын көшелләргә,
Шул игеннән җирем сыгылса,
Уңыш бәйрәмнәре мул булса,—
Мин җырымны ишетәм кешеләрдә!

❁

— Әй, син, егет, үз өстеңә күп аласың!—
Кисәттеләр канатланган җир баласын,
Күп аласың, күп аласың, тиз арасың...
Болай булса алай ерак баралмассың.—
Тау кичсәң дә бу үрләрне алалмассың.

— Әй, син, егет, үз өстеңә күп аласың!—
Кисәттеләр җир яшәрткән җир баласын.
Уттай янып күп эш тоҗыра алмассың.
Болай булса артык ерак баралмассың.—
Тау кичсәң дә бу үрләрне алалмассың...

— Әй, син, егет, үз өстеңә күп аласың.—
Кисәттеләр җир бизәген — җир баласын.
Каян килгән шөбһәләнү, аңламассың.
Үткәнгәме, бүгенгеме зар-аваз соң?
Кеше өчен яна егет: кичкән инде тау арасын!

❁

Ут алмага килгән сыман
Ашыгам мин бу дөньяда,
Туар көннәр аяз сыман,
Тик бик азы истә кала.
Ашыгам мин бу дөньяда
Ут алмага, ут бирмәгә

Игелек итү — ярты гомер,
Мәңгелеккә киленмәгән.
Йөрәгем — чакма ташыдай,
Кешеләр утка килгәндә.
Яшим әле бу дөньяда —
Ут алмага, ут бирмәгә.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Тәлгать Миңнебаев

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ХОЛКЫ: ИКЪТИСАДИ ТАМЫРЛАРЫ, СӘЯСИ ТОРМЫШТА ЧАГЫЛЫШЫ

Урамдагы кешене, аңа түбәтәй яисә камзул кидереп кенә татар ясап булмаган кебек, төрле сыйфатларны, хисләрне, тойгыларны да татарлаштыру мөмкин түгел, һәм бу кирәкми дә. Шул ук вакытта тарих безгә икътисади халәтнең мөшкелләнгән, рухи кыйблалар буталган, сәяси аңның чуалган, о хакимлек мөнәсәбәтләренең асты өскә килгән чагында фаҗиганең тамырын да, аңардан чыгу юлларына да фәкать милли характерга, халык холкына таянып кына эзләү мөмкинлеген кат-кат искәртеп килә. Бусы бер. Икенчедән, Рәсәйнең сан ягыннан икенче өлешен биләгән татарның сәяси, икътисади һәм әхлакый тәртибе империянең җимерелү процессларына төрлечә тәэсир итүче хәлиткеч көч булачак. Мәсьәләнең өченче ягы да бар: фәндә һәм төрле кәсеп өлкәләрендә, мәдәнияттә һәм хокук эшчәнлегендә, сәяси системада һәм сәүдәдә — моны ничек кенә инкарь итәргә тырышмасыннар,— күзәнәк саен татар холкы, табигате, мөнәсәбәте кергән. Шуңа күрә, милли дәрткә ияреп, бөтен дөньяны татарлаштыру «омтылышы» уңышлы нәтиҗәгә китермәгән кебек, Рәсәй тормышын «татарсызлаштыру» да барып чыкмаячак.

Һәрхәлдә, милли холыкның, тирә-юньгә төрле куелыкта сибелүе аерым шәхесләрнең һәм бөтен бер төркемнәрнең көндәлек адымнарында, ил күләм карарлар кабул итү стилендә һәм аларны тормышка ашыру тәкъдирендә чагылышы бүген көн кебек ачык, бәхәссез. Шуңа күрә безне, татарны башка милләтләрдән аерып тора торган сыйфатлар белән бергәттән, аларның башка халыкларга даими тәэсир ясап үсүе яисә сүнүе, сәяси система структураларына «монтажлау» һәм килештерү ысуллары, мөшкел хәләтләрдәге коткару роле, тыныч шартларда «батыру» вазифасы һәм тагын башка мөмкинлекләре кызыксындыра. Милли холыкка игътибар белән караган кеше аның «чиккән бизәк», галимнәр фантазиясе һәм уйдырмасы да түгел, ә чынбарлык икәнлегенә тәмам ышаналар. Чыннан да шулай ич: авыр чакларда, милләт турында аһәңле яки купшы сүзләрне кабатламасак та, кем икәнлегебезне хәтергә төшереп, үҗәтләнәбез, тырышабыз, сер бирмәскә исәплибез, эчтән янабыз.

Гомер бәрабәренә генә аңлашыла, ачыла торган сер: бу тормышның ачысы-төчесе, михнәтләре һәм сынаулары — син татар булган өченме, әллә киртәләрне, упкыннарны вә киенлыкларны җиңә алуың — фәкать татарлыгың хакынамы? Еллар узган, яшь үзгәргән, тәҗрибә тупплаган саен бу хакта ешрак уйланасың, әмма ул диалектик бәйләнешләрне, телефон шнурларын сүткән кебек, ансат кына берсеннән-берсен аерып куя алмыйсың. Аның таза-саф Татарстан кешесендә табылмыйча да, инде җиде йөз ел элек урыслашкан нәсел вәкилләрендә сакланган социаль, мотивацион, психологик «пигмент» икәнлегенә дә еш ышанасың.

**«Безнең нәселдә татар («бар», «юк», «әйтергә кыенсынам»).**

Мондый кыю социологик тикшерену үткәрелсә, җавапларның өч төрле генә түгел, утыз өч төрле биреләчәге шиксез, чөнки бу мәсьәләгә караш битарафлык, кызыксыну, каныгу яисә яклау котыпларында гына ятмый. Берәүләр, инде телләрен, гореф-гадәтләрен, исемнәрен югалтсалар да, үзләренең татар нәселеннән икәнлекләрен әйтеп, шуңа басым ясап тукып торалар. Икенчеләр, киресенчә, бите-чырае, исем-җисеме белән чыкылдап торган татар булсалар да, моны инкарь итәләр, «Я — Федя»,— дип искәртергә тырышалар. Өченчеләре татар икәнлекләрен конъюнктурага карап йә онытала, йә искә төшерәләр. Дүртенчеләр ач карынга җавап бирергә риза түгелләр. Бишенчеләре... Монда, минемчә, тенденцияләргә игътибар итү кулайрак, чөнки алар шактый

гына кызыклы төсмерләрне алга чыгаралар, көчәйтәләр. Әйтик, менталитет, милли аң үсү, ил эчендәге милләтара мөнәсәбәтләрнең шактый катлауланулы, мылтыклы дәлилдән генә файдаланган «старший брат»ның абруе төшүе һәм, гомумән, мескенгә калуы, хәерчеләнүе күпләрне бабаларын рюриклар һәм вятичлар җебеннән барып түгел, ә хәтта Батый сукмакларыннан ук эзләргә этәрә. Гасыр ахырына хас хәрәкәттерме ул, яисә иртәгесе көнгә ышаныч булмауның бер шаукымымы, «генеалогик агач» кәүсәсе буйлап «гомосоветикус» бер туктамый чаба, сикерә, үрмәли башлады. Ун ел элек Америка халкы өчен, филателиядән генә калышып, икенче урында торган өстәмә шөгыль — үз килеп чыгышының тамырларын өйрәнү — безне дә биләп алды. Димәк, кеше, тамагы тук булса да, ачыга башласа да, барыбер чишмә башын эзләргә тырыша икән.

Абайламыйча калмагансыздыр, шәт: туксанынчы еллар башыннан татар милли аңы үсү аның эчке активлыгына, горурлыгына гына китерми, ә башка милләтләрнең дә,— кайберләренең сагаеп, кайберләренең исе китеп, кайберләренең сокланып,— татарга булган мөнәсәбәтен үзгәртә, киңәйтә, үзенә күрә яхшырта да кебек. Һәрхәлдә, эчтән дә, тыштан да санга сугу барлыкка килде. Милләтара мөнәсәбәтләрдә маятник «туң» ноктадан чыкты, татар сәгате сугар вакыт җитте.

Әмма бу халәткә буш кул белән барып керү һич кенә дә килешми. Милли аң үсеше фикри, фәнни эзләнүләргә нигезләнсә генә матур нәтиҗәләргә китерер, шуңа күрә татар тормышы тарихы, аның тәртибен билгеләүче холкы, сәяси система белән мөнәсәбәтләре — барчасы да ашыкмыйча, кабаланмыйча, әмма кичектергесез рәвештә өйрәнелергә, барланырга, гомумиләштерелергә һәм фәһемләнергә тиештер.

## Төп билге түгел, әмма мөһиме

Күп очракта күрәсе килгән әйберне генә чамалыйсың. Киресенчә дә була — кырыеннан узып-капшап-сыйпап та, табу бәхетеннән мәхрүм каласың. Милләтне милләт иткән сыйфатлар да шундый язмышка дучар: алар, стереотип бәяләнмәләргә кереп, шәхеснең акыл-сыйфатына карамастан, аңа булган мөнәсәбәтне калыпка салалар: икенчеләре мәзәк, мәкаль «сурәте» алып, көлдерә, алтырата, үзәккә үтә, өченче төрләре фәкать бала куркытырга гына ярый. Сыйфатлар төрле милләтләргә тигез өләшенеп, үзенә күрә бер аскы чик, «минимум» тәшкил итәләр, дисәк, ялгыш булмас.

Әмма бу фикерне юл чатында калдырып булмый. Эш шунда ки, бу сыйфатлар, төрле хәлләрдә бер-берсе хакына көчәеп-кимеп, милләтнең саклануына яисә таркалуына китерәләр. «Сараннар», «комсызлар», «хәйләкәрләр», «ялкаулар», «җигелүчәннәр», «ахмаклар», «эшлеклеләр», «мәкерлеләр» шулай барлыкка килә инде. Икенче яктан, милләтнең үзенә, аңа гына хас холкы, сыйфатлары нигезендә сәяси система, дәүләт структуралары төзелә. Милләтнең эчке ихтыяҗына таңгәл килсә генә, ул чыдам, тотрыклы була, аны беринди чир, бәла, революция җиңә яисә тарката алмый.

Шулай итеп, сәяси системага туры килгән очракта гына милләткә муафыйк «төс» җиңел, халыкның табигатен билгеләрлек дәрәҗәдә куерып чыга.

Без урыс холкына туры килә торган системага «береккәнбез», аңарга үреләп үскәнбез, һәм үзебез дә сизмәстән аның тотрыклылыгына ярдәм итеп киләбез. Аның соңгы вакытта чатнавыннан файдаланып, төрле милләтләр үз холыкларына лаеклы формалар эзләргә тотындылар, зилзиләдә яхшысы-яманы буталды, кылган изгелекләр онытылды, үпкәләр кичерелмәс булды. Җир һәм тарих бүлешеп, без сугышчанлыкның, якалашуның аерым бер милләтләргә хас сыйфатлар икәнлеген онытып та җибәрәбез.

Теләсә кайсы татар авылының агае да, чит ил галимнәре дә, урысларның үз философлары һәм зур әдипләре дә аларның «вече», «соборность» кебек төшенчәләргә мөкиббән китүенә ишарә итәрләр. Дөресе дә шулай: җыелышып хезмәт итү йә вакыт сарыф итү, бәйрәм итү йә сугышу, татуланышу йә булышу аларга бик тә хас. Бер үк вакытта ул сыйфатлар абсолютлаштырылмаган: уңай векторлар шактый якын куелган чикләргә бәреләп «сыналар». Соборность, ни генә әйтсәң дә, нивелировка, минималь активлык, тигезләү фәлсәфәсен алга сөрә, шәхескә җан иреге дә, икътисади байлык та бирергә теләми. Мондый ялкаулыкка корылган системаның иртәгесе көнне нинди фикер белән уянасын тәгаен генә әйтү кыен, безнең хәрби, сәяси адымнарда ул билгесезлек факторы зур, кискен, куркыныч. Аннан да бигрәк, ул сыйфат төрле законнарга, кагыйдәләргә, инструкцияләргә, «төрелеп» беркетелә, дистәләрчә еллар дәвамында көчләп канга сеңдерелә, кешенең бар мохитен сугара. Аңардан: «Татарстанда дуңгызчылык фермаларын бетерик!» — дип кенә котыла алмыйсың.

Шаккатырганы шул: төп сыйфатны һәр милләт үзенчә уңай бәяли, аны башкаларга көчләп тагып, үзенчә бәхетле итмәкче була, аны назлап үрчетә, аның белән горурлана. Азияне һәм Африканы, Европаны һәм Африканы урысча яшәргә өйрәтү кебек изге теләк әле безнең генералларны гына түгел, «гади халыкны» да җиләтеп ала. Чиратта торып хәлсезләнгән кешеләр: «Балтыйк буе халыклары бездән аерылып харап булыр»,— дип кайгыра. «Азат итү», «дуслыкны ныгыту», «халыклар дуслыгы» кебек төшенчәләр дә, үзләрендә капма-каршы мәгънә саклап, сәламәт фикер йөрткән кеше-

не аптыраšта калдыра. Янә өстәп әйтергә кирәк: йөгәннән чыгу рухи халәте, «әчкерсез кеше» кыяфәте һәм фигыле безгә нык үтеп кергән, бушка актыгын бүләк итү, тәяп җибәрү дә, «эһ» тә итмичә бүтәннәрнең соңгы сыныгын, талап-салдырып алу да бүген бер милләткә генә хас түгел инде.

Татар өчен, киресенчә, таркалу, сибелү хас, ул сыйфатлар аңа шәхес буларак ныгып китәргә, үзен танытырга форсат, мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта бергәләшеп максатчан эш җәелдерергә, һөҗүм итәргә комачаулый. Өстен булып калырга тырышу, күмәк җиңеп чыгу теләге шуңа күрә безнең гомуммиллләт холык-фигылен түгел, ә аерым шәхесләрнең үз милләттәшләренә мөнәсәбәтләрен генә күрсәтә. Ул сыйфатның фәкать «икенче тизләнеше» генә милләтара яисә сәяси орбитага чыгуы ихтимал, әмма ул инде урыслашкан, ассимиляцияләнгән, «зиһеннең читкә саркуы» нәтиҗәсендә пәйда булган шәхесне тудыра. Минемчә, бу объектив процесска фаҗига итеп карарга кирәкми: ахыр чиктә һәрбер якты шәхеснең тырышлыгы, милләттәшләребезнең үз урынында йөзгә кызыллык китермичә эшләве вә яшәеше милләтнең гомуми абруен, дәрәҗәсен күтәрә.

Бүтән халыклар безне «татарның өе тирә-юньдәге иң бай йорт булырга тиеш», «татарның хатын-кызы башкаларга караганда матуррак киенергә тиеш» кебек таләпләр аша бәяләләр икән: моңа сөенергә генә кирәк. Тик менә безнең үзара татулаша алмавыбыз гына борчый: төрле төбәкләрдән җыелган, төрле шивә вәкилләре булган милләттәшләребез тату, тоташ, тотрыклы көч булып формалаша алмыйлар әле. Мин моны шулай ук үз табигатенә муафыйк система таба алмау белән дә аңлатыр идем, димәк, җыелышып киңәшү («соборность», «вече») баскычларын мең ел элек узган халык өчен бүгенге икътисади һәм сәяси система аркавын төзү, тергезү шарт!

Башка милләтләр татарның үз-үзен кимсеттермәскә, кимсенмәскә, сер бирмәскә тырышуын күзәтеп, фольклорларында, әдәбиятларында, музыкаларында теркәп килгәннәр. Әмма бу сыйфатның милләт эченә юнәлгән ягында башкалар тарафыннан абайланмаган көнчелекнең барлыгын да танырга кирәк. Башка милләт вәкилләре катнашмаган, яисә бик астыртын гына бу чирне пыскытып, көчәйтеп торган очракта татарның бер-берсенә мөнәсәбәте көнчелекнең төрле бизәкләре белән чуарланган.

Үзара низаг, бәхәс, аңлашылмаучылык очракларын төрле комиссияләр составында күп өйрәнергә туры килде миңа. Берничә закончалык күзгә ташлана: гел татарлардан гына торган коллективлар «тип-тигез җирдә», берниндди сәбәпсез берничә төркемгә бүленеп, үзара дошманлашып яши башлыйлар, хәтта шуңардан ямь, ләззәт, мәгънә дә табалар: әгәр татар хезмәтендә үсә, күтәрелә башласа, алга үрмәләсә, уңышларга ирешсә яисә аңа «читтән» игътибар итсәләр, аның чабуына беренче чиратта үз милләттәшләре килеп асылына, үзенекеләр аяк чала, әнә шулай рухи эшчәнлек вәкилләренә, зыялыларга ихтирам кими, хезмәткә лаеклыларны лаексызлар белән тигезләргә, пычратырга тырышу хисе көчәя. Мондый төр көнчелек культура, әдәп, кешелеклелек сыйфатларының хәзерге тормышта гаҗәп загыйфьләнүен исбатлый.

Билгеле, мин көнчелекнең социаль шартлар нигезендә килеп туган очракларын да инкарь итә алмыйм. Нидер бүлешкәндә, урын «дәгъвалаганда», нәрсәдер өләшкәндә гасырлар буе үзенә тиешен алу бәхетеннән мәхрүм татар кабаланырга, өтәләнергә мәҗбүр булган. Башка милләтне, билгеле сәбәпләр аркасында, этә-төртә алмый, шуңа күрә үзенекен чукырга кала. «Өстән» нәкъ әнә шундый исәп белән калҗа тамызып, ызгыштырып-талаштырып, тамаша ясап киләләр. Икенче яктан уйласаң, мондый геноцид һәм җәбер үзенә күрә санитарлык ролен дә башкарган икән ләбаса! Хәзер инде бу халыкның, нинди генә репрессив алымнар кулланса да, кайларга гына сөрсәң дә, чукынмаган өчен бәкеләргә салсаң да, баш бирмәслеге һәркемгә ачык. Мондый төр генетик сайлау, күп корбаннар бәрабәренә булса да, тарихи бурычын үтәп чыккан.

Татар үз эченә бикләнсә дә, үзеннән качмаган, җыелырга ашыкмаса, таләмәсә дә, эчтән ныгыган, аның үзәге, умыртка сөяге таза, һәм бу татарның ныклы психологик потенциалы барлыгын дәлилли. Аларны бер йодрыкка җыйнау һәм туплау өчен тирән фикер иясе, көчле оештыручы гомум максат, ятышлы система кирәк. Бер регионда бер республика төзү генә җитмидер аңа.

Димәк, татар потенциалын арттыру өчен аның үз дәүләтен төзү белән беррәттән (сүзнең бүтәнчә куелуы мөмкин дә түгел), башка мәмләкәтләрнең сәяси, икътисади күзәнәкләренә керергә, дөнья күләм икътисади һәм рухи хәрәкәтләрдә катнашырга кирәк. Заманында андый мөмкинлекне мәмлүкләр камил төстә тормышка ашырганнар.

Әйтергә кирәк, бу эш каршылыксыз гына бармаячак, җәмгыятьтәге төшемле урын буш булмый бит. Татарга әлеге дә баягы хәрби заводларда кара эш тәкъдим итүдән узмаслар. Миңа татарларның хәрби хезмәттә, төгәл фәннәрдә һәм сәясәттә үсеш «траекториясен» анализларга туры килгән иде. Әйтергә кирәк, төрле республикалардан бүләкләргә, делегатлыкка тәкъдим ителүчеләр исемлекләрендә,— гәрчә ул төбәкләрдә милләттәшләребез күпләп яшәсә дә, алны-ялны белмичә эшләсә дә,— татар исемнәренең еш очрамавы тарихи селекциянең һаман да көчле икәнлегенә ишарәли. Гуманитар, иҗтимагый даирәләрдә татарның аз күренүе аларның акылы-зиһене чамалы дигән сүз түгел әле. Төгәл фәннәрдә, космик һәм хәрби эзләнүләрдә ил терәге татар булуы исә сәләт ягыннан татарның элитага керүе хакында сөйли. Димәк, әлеге дә баягы социаль селекция хәл итә, чөнки милли холыкны йөзек кашыдай балкытырлык, сәләтләребезне мәйданга чыгарырлык система юк.

Халык тулаем гына гел ялкау да, гел тырыш та була алмый: аның хәрәсәнеренчәге, өтеге-азгыны да, елгыры-эшчәне дә билгеле бер күләмдә һәм нисбәттә формалаша. Шул ук вакытта эшчән карусызлыгы белән билгеле татарның бөлгенлек божрасыннан чыга алмавы ялкаулыкның сан да, сыйфат та, рәвеш тә, хәтта социаль сәятәт тә икәнлеген исбат итә. Чыннан да, кайбер милләтләр өчен ялкаулык — табигый халәт кенә түгел, аның тартып алынмаслык бер сәләте дә, инде ничә еллар буе митинглар, милләтара ызгышлар һәм сугыш шартларында яшәсәләр дә, кайбер милләтләр татарга караганда җитешрәк көн күрә. Без исә аларга нефть химиясе, авиация промышленносте товарлары белән бергә ит, сөт, май һәм бүтән азык-төлек җибәреп тору өстенә, тагын әйберләтә, акчалата ярдәм дә күрсәтәбез.

Ялкаулык һәр милләткә аерым сукмак сала. Берәүләрдә ул вакыт-вакыт читкә сугышырга, таларга бару һәм шуның хисабына типтереп яшәү дәрте тәрбияләсә, икенчеләрдә азау ярган бу сыйфат сүз активлыгы, үз-үзләрен мактау, реклама рәвешен ала. Шахталарда шартлап һәлак булган, сугыш кырларында ятып калган кешеләрнең исемлекләрен барлаганда, татарның эштә дә, яуда да алгы сафта хәрәкәт итүен ачыклыйсың. Генетик хас аңа тырышлык, әмма...

Ялкаулыкны күп өйрәнергә дә, күзәтергә дә, язарга-тасвирларга да туры килде, шуңа күрә аның пассив, мәлҗерәп, йокымсырап утырган бер халәт түгел, киресенчә, фәлсәфи нигезе күренеп торган бер сыйфат, «тарихи «вируслары» булган социаль чир икәнлегенә тәмам ышандым. Пәҗеп, җебеп, аркылыны буйга алып салырга иренеп тору — ялкаулыкның гөнаһсыз бер билгесе генә. Үзе чынлыкта,— шунысы кызык та инде,— гаҗәп актив, үткен, дөньяны куерта торган иблис ул: юк кына эштән дә качу, пүчтәк кенә мәсьәләне хәл итүдән баш тарту өчен, галиҗәнаб Ялкаулык, мең мәртәбә артык көч түгеп, мәкергә, җинаятькә бара. Аны авызлыкларга, җигәргә, тәртәгә кертергә теләүчеләргә, ай-һай, кыен!

Ялкауны, бәлки, кызганырга да кирәктер, әмма ул үзен бәхетсез дип санамый: башын җүләргә салып, җавапсызлыгы белән тилмертә. Иң аянычы шул ки, ялкау башкаларга лаеклы тормыш итәргә комачаулык итә, башкисәрләнә, көнләшә, талауның төрле камил формаларын уйлап таба. Әгәр дә социаль мохит ирек бирә икән, ялкаулык тиз үрчи, ялкаулар арасында табигый селекция, сайланыш башлана һәм аның иң көчлеләре — системаның әхлакый принципларына таңгәл килүчеләре — җиңел чыга.

Төрле милләтләрнең тормышы, аерым кешеләрнең тәртибе дә бу хакыйкатьне гел раслап тора: ялкаулык белән хәерчелек бертуган булган кебек, ул әле усаллыкның, дошманлыкның, коткының да якын кардәше. Кем җәнҗәл чыгара, эләкли? Ялкау. Кем теләсә кайда фетнәдә, сугышта, бәрелештә? Ялкау. Кемнең уенда талау хисабына баю һәм көн итү кәсебе? Фәкать аңарда, чөнки эш белән мәшгуль кешедә — бүтән фикер, бүтән ваем, бүтән ният.

Тора-бара бу халәт аерым бер кешенең генә түгел, бер төркемнең, катламның һәм хәтта халыкның да күзәнәкләренә үтеп керә. Әгәр дә социаль шартлар кулай икән, ул канга күчә, кагыйдәгә әйләнә, асыл сыйфатка әверелә. Шулай итеп, аерым кешегә хас һәм җәмгыять таралырга ирек биргән сыйфат һәр икесенең дә тискәре якларын берләштерә. Шуңа күрә ялкаулыкны аерым бер милләт даирәсеннән генә эзләү гыйльми яктан дөрес булмас иде. «Ялкаулык урыстан күчте» дигән гыйбарәне дә урынсыз куллануны искәртергә тиешмен: аларның да тырышлары күп, безнең дә ялкауларыбыз җитәрлек.

Империя тарихы гына түгел, бу чир еллар, гасырлар буе барган сугыш тарихы да әле ул. Сер шунда ки, империя пәйда булу өчен кайбер милли сыйфатларның, шул исәптән ялкаулыкның һәм эшләмичә, башкаларны барып-барып талау хисабына типтереп яшәү теләгенең өстенлек алуы шарт. Аннан соң инде система ялкаулыкны үзе назлап үстерә, аздыра, сәясәткә һәм фикер йөртү ысулына әйләндерә, аңа тотрыклы, кануный төс бирә. Моның шулай икәнлегенә Явыз Иваннан башлап бүгенгечә кабул ителгән карарлар, законнар, әмерләрнең эчтәлеге белән танышкач ышанасың. Йөгәнсезләр күңеленә хуш килә торган карарларны «яңа Советларның» да күпләп кабул итүе борчый.

Татарга килгәндә, ялкаулык — милләтне гомумән характерлаучы сыйфат түгел, ә аның сәяси һәм рухи тормышының бер ноктада туңып, эрергә һәм кайнарга тырышмавы, әзер булмавы. Аның берничә билгесе, үзенә күрә шомы бар: беренчедән, фән, мәдәният, сәясәт һәм башка өлкәләрдә эшләү өчен яшь алмаш әзерләүнең системасыз, мантыйксыз, килделе-киттеле оештырылуы; икенчедән, халыкның үзендә, бигрәк тә яшь буында булдыксызлык, мескенлек комплексы барлыкка килү, хәерчелеккә риза булып яшәү: өченчедән — мөстәкыйльлектән курку, ирекле фикер йөртү мөмкинлегеннән өркү, качу.

Соңгысына аерым туктапасы килә. Империянең экономик кризистан чыга алмаячагы белгечләргә көн кебек ачык, һәм бу мөшкел халәттән котылуның бердәнбер ысулы: үрмәле алырдайның аягыннан тартмыйча, үз кыйбласына җибәрү — котыла алса, котылыр. Әгәр дә инде илне бүгенге чикләрендә саклыйсы килә икән, бу исә объектив мөмкин түгел,— аны алга киткән илләргә, колхозларны шефларга бүлеп биргән кебек,

беркетергә кирәк. Ләкин моңа кем генә риза булыр икән? Шулай ук безнең һаман да «спонсор», бай көтеп ятуыбыз аптырата. Йә мәгърибтән, йә мәшрикътән «хуҗа кулы» эзләвебез белән бер кочактан котылып, тагын да кысанрак икенчесенә эләгергә маташабыз бит!

Шулай итеп, система, татар халкын үзенә бөгеп, аның мөмкинлекләреннән даими файдаланып килсә дә, аңа сәяси һәм икътисади тормышта тулысынча ачылырлык калып бирүдән баш тарта. Дәүләт төзелеше белән милләт арасындагы каршылыклар тепәсә кайсы илгә хас, әмма илле икътисади-иҗтимагый шартлар булганда алар милләткә эчтән ныгырга бер этәргеч ясыйлар. Безнең өчен система җитешсезлеге шәхесне чирпе җәмгыятькә «бәйләп» кую белән генә тәмамланмый, аны милләттән дә аера. Хөкүмәт белән милләт арасындагы ераклык — күпмилләтле хакимлек чылбыры булуда түгел, сәбәпне моңарда гына күрү — сәяси самимилек. Минем күзәтүемчә, башка милләттән булган җитәкчеләр, шартына җайлашып, адымнарын бик уйлап, чамалап ясыйлар, аларны «татарны сөймәүдә» гаепли алмыйсың. Шуңа күрә, үз милләтеңнән җитәкчеләр кую өчен ызгыша башлаганчы, инде сайланган, билгеләнгәннәреннең милли җанлы булуына ирешү хәерлерәк.

Мәсьәләне ничек кенә куйсаң да, аңа дөрес җавап бирәү генә: безгә милләт холкына ятышлы икътисади тормыш көйләү зарур.

## Милләт баерга тели. Әмма ничек?

«Әгәр дә нефтебезне үзебез сатсак, әллә кайчан Кувейт кебек яшәр идек»,— дөньячеләр байтак.

Әлмәт, Шөгер, Карабаш ягы халкының холкын яхшы белгәнгә, татарлар нефть сатып баюны төп эш итеп карамас иде, дип әйтергә хаклыбыз, чөнки җирне һәм җир маен, җилеген уңга-сулга тарату татар өчен, гомумән, хас түгел. Ул, беренче чиратта, өстәмә капитал, сәүдә, оештыру экономикасы белән шөгыльләнергә күнеккән, чимал сату аның өчен бик примитив, паексыз, кимсетә торган һөнәр. Күптән табылып, үзеннән-үзе агып ятса да, бу яктагы татар байлары нефтьне сатып өрәм-шөрәм итәргә ашыкмаган, җаен, вакытын көткәннәр. Хәзерге алга киткән илләр кебек, авыл хуҗалыгын тотрыклы чыганак итәргә тырышканнар.

Кайчагында, татарлар элек кәбестә дә үстермәгән бит, дигән «дәлил» ишетергә туры килә. Янәсе, кая инде ул җир эшкәртү культурасы сездә!..

Чыннан да, кайбер татар төбәкләрендә җиләк-җимеш, яшелчә үстерү традицияләре югалган һәм моның үзенә бер тарихы бар. Заманында татарлар балыклы зур елга ярларыннан гына куылмаган, аларның һәр алма агачына, җимеш куагына салым да салынган. Шунлыктан «ялкаулана» төшкәнбез дә инде. Хәзер дә җирне бүлеп бирергә тырышучылар күренми, чөнки колхоз-совхоз системасы шул ук ялкаулыкны таҗлаган бер коры бота.

Кара җирне сайлап ала белгән татарның җиргә мөнәсәбәте рус язучыларын да таң калдырган, ул хакта Аксаков, Бунин, Лесковлар яза.

Мисал өчен, Әлмәт якларыннан элек-электән Чистайга, патша пристанена төрле яшелчә һәм ярма җибәреп торганнар, Мәскәүгәчә озатырлык сыйфатлы булган, димәк. Кыярны, мәсәлән, ел да төрле урынга чәчкәннәр, моның өчен тауның кыйблага караган ягында агач төпләп, урын әзерләгәннәр, фәкать яңа төпләгән имән, юкә, каен туфрагына гына орлык салу кулай дип саналган. Билгеле ки, милләтнең матди хәлен яхшырту өчен аңа яңадан кыяр үстерү серләрен искә төшерергә димәгән. Әмма безгә күчкән, мәҗбүри рәвештә йоктырылган ялкаулыктан котылыр өчен татарның холкына туры килә торган икътисади шөгыльләрне киңрәк җәяргә кирәк.

Татар халкына гына хуш килә торган һөнәрләр бармы соң?

Әйткәнебезчә, татар кара эштән дә курыкмый, ат кебек җигелә: абстракт фикер йөртү сәләтен таләп иткән эшләргә дә көче җитә, сәнгатькә дә хирес. Шулай да, минемчә, татар бүтәннәргә караганда яратыбрак, һәм нәтиҗәлерәк башкара торган хезмәт даирәләре өчәү: сәүдә һәм маркетинг, фән һәм сәнгать, җир биләү.

Сәүдә һәм маркетинг, коммерция — үз фәлсәфәсеннән, кагыйдә һәм принципларыннан гыйбарәт булган иҗат тармагы. Татарның бу тармактагы хәрәкәте базарда алышбиреш итүенә генә кайтып калмый. Меңьеллык тәҗрибә, инде рефлексларын югалта барса да, яңа экономик шартларда терәкләнеп, яшәреп китәчәк. Моның өчен бу юнәлештә татар яшьләреннән менеджерлар, коммерсантлар, экономистлар әзерләүне максатчан программа нигезендә башлап җибәрү шарт. Сәүдә ул дипломатияне, психологияне, арапашу серләрен, күрәзәлек сәнгатен таләп иткән даирә, шуңа күрә татар, анда барып керә икән, башкаларның өйрәнчеге булып, озак җәфаланмас — сәүдәгәр сыйфатлары аңарда җитәрлек. Космик эзләнүләрдә, хәрби тармакта, экономикада ирешкән уңышлары татарларның дөньяга урам себереп баер өчен яратылмаганын көн дә исбатлап тора.

## Альберт Хәсәнов

# БӘРӘҢГЕ

Йә ходай, көлгә күмгән бәрәңгедән дә тәмле ризыгың бармы икән бу җиһанда?! Юктыр. Булмас та! Нәкъ менә шулай уйлый торган идем нәни чакларымда. Хәер, ул еллардан соң инде күп кышлар авышса да, күп сулар акса да, фикерем үзгәрмәде.

Безнең малай чаклар сугыштан соңгы аеруча авыр, ач елларга туры килде. Күңелдә туган бар дәрт, бар якты хыяллар, ахыр чиктә, туйганчы бер ашауга әйләнеп кала иде. Алай да көзге чорларда бер кинәнеп кала торган идек. Мәктәптән кайтып, капчык киндереннән теккән биштәрләрне ишек катына, йә сәке астына атабыз да, бәрәңге басуына ашыгабыз. Аның бит әле сәбәбе дә чыгып тора: йә шунда арык бозау, йә аңгыра сарык бәрәне кайтмаган була. Башка җирдән эзләп йөрисе юк, алар да әлеге бәрәңге җире өстендә юаналар. Әниләр-апайларыбыз, бригадир күзәтүе астында, ни хәтле генә тырышып чүпләсәләр дә, җир өстендә безгә җитәрлек кенә бәрәңге барыбер кала. Калмыйммы соң!? Хәйләкәр бит ул бәрәңге, качып ята. Көзге яңгырлар явып киткәч, уңышы инде алынган бәрәңге җире өстенә барып керсәң, күзең камаша!

Шунысы үкенечле, аларны өеңә алып кайтырга ярамый. Шунда калса калсын, черерсә чересен, әмма өеңә алма! Чөнки ул — колхоз байлыгы. Аны өйгә алу урлашу була. Шул җир өстенә барып ут ягып, көлгә күмеп кинәнсәң генә инде.

Көзен генә түгел, әле язын барып җыярлык та була торган иде җир өстендә калган бәрәңге. Әнкәй бичараларыбызның өшегән, черегән бәрәңгедән пешергән коймакларын, күмәчләрен, кәлҗемәләрен ашап кына исән калган малайлар бит инде без.

Җир өстенә барып җитүгә, күп итеп коры камыл өеп, ут ягабыз, көл төшерәбез. Итәкләребезгә җыйган басу бәрәңгесен һәр малай башына исәпләп, көлгә күмәбез. Бераз шаярышып алырга да өлгермисең, пешеп тә чыга торган иде шушы бәрәңге.

Шушы бәрәңгене ашап һич туярдай булмыйсың инде. Яртылаш янган, кара күмер булган кабыгы үзеннән дә тәмлерәк. Юк, юк, егетләр, мин менә бүген дә шул фикердә, баягы сүземнән кайтмыйм. Көлгә күмеп пешергән бәрәңгедән дә татлы һәм шифалы ризык юктыр төсле миңа бу мәгърур җиһанда!

Үзенең тыйнак гомерендә дөньяны күп күргән, аркасына биштәр асып күп җирләрне гизгән, бик мөхтәрәм геолог агай миңа менә боларны да сөйләде. Сугыш алды елларында булган бу. Ул елларда әлеге агаем — Мәскәүдәге Тау эшләре академиясе студенты. Икеме-өчме курс укыгач, көннәрдән бер көнне, академияне вакытлыча ябып, боларның барысын да ерак Себергә, алтын ятмалары эзләргә озаталар. Чөнки Европа өстендә икенче Бөтендөнья сугышының кара сөреме куера башлаган еллар була бу. Сугыш чыга-нитә калганда, чит дәүләтләрдән самолетлар, танк-туплар сатып алу өчен дәүләт казнасына алтын кирәк! Әлеге агаем — бүген фәннәр докторы, профессор, ул чакта исә очкын кебек егет. Алдан елгасының кушылдыгы Индигирка ярларына барып эләгә.

Шушы елга бассейнында иң гади ысуллар белән алтын юдырып шөгыльләнгән экспедициягә иптәш егете белән барып төшәләр болар, алтын юдырырга керешәләр.

Төрле җирдәге комнарны юдырып-юдырып карыйлар, юк, бик аз чыга алтын. Башкалар шуннан да канәгать. Ә студент халкында нәфес зурдан була бит. Авантюристлык исә башларыннан ашкан. Алар бит бирегә акчаны көрәк белән көрәп алырга, өс-башларын карарга, алдагы елларда иркенләп укыр өчен бераз мая тупларга килделәр. Үзләренә бирелгән сыңар күзле алаша җилкәсенә патрон төяп, палатка салып, берәр айга җитәрлек ризык алып, иптәше белән икесенә бер винчестер асып, офык читенә, бик серле күренеп торган яссы тауларга таба чыгып китәләр болар. Исәпләре — алтынны көрәк белән көрәп табу. Серле җемелдәп, үзенә чакырып торган тауның очына да менәләр, арт ягына да төшәләр. Капчыклары һаман буш. Инде кайтыр юлга чыккач кына бай ятмага очрап куялар. Нишләргә? Боларга һич кичекми кайтыр юлга кузгалырга кирәк. Төп базага — кимендә ун көнлек юл. Ә буш капчык белән кайтасы килми. Алтын бит әнә — аяк астында гына, юдыр да юдыр. Айлар эчендә миллионер буласың. Егетләр... калырга тәвәккәллиләр.

Экспедициядә тәртип шундый: билгеләнгән көнгә кайтмаучыларны көтеш юк. Чөнки бирелән кая да булса качып китү мөмкин түгел, кышка калу — ачка үлү дигән сүз. Моңа бирәү дә бармаячак. Билгеләнгән көнгә кайтмау — һәлак булу дигән сүз.

Әмма егетләр исән. Алар, дөньяларын онытып, алтын юдыралар.

Салкыннар башлана. Әлбәттә, ике тап-таза егет тик тормый, күп итеп утын әзерлиләр, палаткаларын ылыслы ботаклар белән каплыйлар, җылыталар. Әйләнә-тирәдә көртлек-куян күп. Мүк җиләге эскәтер булып ята. Егетләр исән-имин кышлыйлар, хәтта алашаларын да исән асрап чыгалар.

Иртә яз башыннан тагын алтын юарга керешеп, байтак кына мая туплап, бер заманны болар Иркутскига кайтып төшә. Беренче эшләре итеп базардан бер капчык бәрәңге сатып алалар да шәһәрнең иң затлы ресторанына юнәләләр болар. Официантны дәшеп, шушы бәрәңгене мичкә тәгәрәтеп пешерергә кушалар. Берәр тәлинкә киндер мае табып куй, диләр. Йөгеребрәк йөрсен өчен, картның кулына берәр кашык алтын комы сибәләр.

Бераздан әлеге егетләребез утырган өстәлгә мичкә тәгәрәткән бер коштабак бәрәңге, бер чирек белән киндер мае чыгарып куялар. Ә залга соң, залга! Синең бөтен эчке халәтеңне биләп, башыңны борчулы уйларыннан арындырып, мичкә тәгәрәткән бәрәңге исе тарала. Йә хода, каян бирдең син бәрәңгегә мондый тәмле, татлы исне?!

Беренче булып болар янына кырыс карашлы, киң җилкәле, күп диңгезләрне кичкән кораб капитаны килә. Ул, зур түбәнчелек белән, күрше генә өстәлдә утыручы кәләшенә бер генә бәрәңге бируләрен үтенә. Бәясеннән тормаячак, алла сакласын! Егетләр капитанның көрәктәй учларына бәрәңгене санамый салалар. Әмма аның аягы бик җиңел була. Бер генә бәрәңге сораучылар күбәя. Егетләр ахырда бар ресторан кунакларын үз өстәлләренә чакыралар. Официант карт исә бәрәңгене коштабак белән кухня яктан ташып кына тора...

Менә шулай: бәрәңге һәркайсыбызның бик яратып ашый торган ризыгы. Германиядә чыккан бер белешмәдә, бәрәңгедән биш йөз төрле тәмле ризык әзерләп була, дип язылган. Биш йөз бик зур сан инде ул. Шуңа күрә ул кадәресенә үк үрелмим. Минем әни, мәрхүмәм, аны тозга ярып пешерергә бик оста иде.

Баздан аның иң тәмлеләрен, алларын, бәләк кебек озынчаларын гына сайлап алып менәбез. Әни аларны казан мунчаласы белән ышкып-ышкып, кат-кат юа. Аннары урталай гына ярып, ике-өч кат бисмилласын әйтеп казанга сала. Аскан казаның пыскып та утырмасын, үрле-кырлы сикереп тә кайнамасын. Тозлырак булса, тәмлерәк була, дип әни шушы бәрәңгегә тозны ярыйсы мул тондыра торган иде. Аннарымы?! И-и, аннары шушы бәрәңгене арыш ипие, салкын катык белән, көнбагыш маена манчый-манчый суганы кушып ашасаң. Гомер эчендә ник бер махмырлатсын?! Төшкә ашаган булсаң, кичкә тагын сагынып торасың. Әни шушы татлы ризыгын «чикмәнле бавырсак» дип йөртә иде.

Шунысы сәер: моннан әле ике йөз еллар гына элек безнең халык бәрәңгенең дөньяда барлыгын да белмәгән. Бодай, тары, ясмык, солы иккәннәр. Арыш ипие, бодай кабартмасы, тары боткасы ашаганнар, солы кисәле эчкәннәр. «Борчак — дары ташы, ясмык — муллалар, тары — түрәләр ашы»,— дип сөйләгәннәр. «Ашасаң тары — китәрсең ары, ашасаң арпа — беләктә көч арта»,— дип балаларын тәрбияләгәннәр. Ә бәрәңге турында бер сүз юк. Чөнки безнең Идел буе тирәсенә әле ул бик соң килә, халыкның мәхәббәтен соң гына яулый. Әмма — мәңгегә!

Рәсәйдә бәрәңгенең күренә башлавы Петр патша исеме белән бәйле. Кораблар төзү серләрен өйрәнү максаты белән, ул Европа буйлап сәяхәткә китә. Әлбәттә, исемен-атын, кем булуын яшерә. Голландиянең кораблар төзү верфендә гади балта остасы булып эшләүче, ачык күңелле, шаярырга-көләргә яраткан бу сәер рус кешесен берәү үзенә ашка дәшә.

Хуҗаның сые кунакка бик ошый. Ошамаска соң, яхшы сортлы немец шәрабен табада кыздырган, кетер-кетер килеп торган, бәрәңге белән эчеп кара әле син! Икенче көнне Петр патша, базарга чыгып, бер капчык бәрәңге сатып ала һәм аны «бик кыйммәтле йөк» итеп Рәсәйгә озата.

Ә 1765 елда Сенат бәрәңгене бөтен җирләрдә киң мәйданнарда игә башларга дигән махсус карар кабул итә. Моның өчен орлыклык бәрәңгене Европа илләреннән күп күләмнәрдә сатып ала башлыйлар. Шулай итеп, бәрәңге бөтен илләрдә диярлек халыкның төп туклану ризыкларының берсенә әверелә. 1980 елда бу культураны дөньяда егерме ике миллион ярым гектарда утырталар. Һәр гектардан дөньякүләм уртача уңыш 133 центнер. Чагыштырып карагыз, үз бакчагыздан, колхоз басуларыннан сез күпме уңыш аласыз? Әйтик, үзебезнең Лениногорск районында бәрәңге уңышы елдан-ел ким алына — саннар шул хакта сөйли.

Ә 1990 елгы уңышны телгә аласы да юк. Тоташтан яңгыр койды, җир өстенә керерлек булмады. Уңышның күп өлеше җирдә калды, череде, юкка чыкты. Маңгаеңны каткат уып, нәгеңә таянып, уйланыр нәрсәләр бар монда, уйлана белгән җитәкчеләргә. Бәрәңгедән дөньякүләм уңыш — гектардан уртача 133 центнер. Ә кара карга канатыдай кап-кара туфраклы Лениногорск, Әлмәт, Бөгелмә районнарында 35—50 центнердан артмый. Бу ни хәл бу? Гаеп кемдә, сере нәрсәдә? Әллә бәрәңге безнең җирләрне яратмый, үсәргә теләмиме? Һич юк, минемчә. Эш биредә агрономнарның Рапо җитәкчеләренең ялкаулыгында, эшсезлегендә, яңача ысуллар кертмәүдә, индустриаль технология кулланмауда, системаның бернигә ярамавында. Мәскәү өлкәсенең Раменское районында «Заворово» тәҗрибә-күргәзмә хуҗалыгы бар. Бу хуҗалык бәрәңге игү фәнни-тикшеренү институтына карый. Журналның кушуы буенча анда да барып кайттым. Хуҗалык 270 гектарга бәрәңге утырта. Менә күрсәткечләре: 1981 нче елда гектар саен — 132 ц; 1982 дә — 170 ц; 1983 тә — 272 ц; 1984 тә — 273 ц; 1985 тә — 253 центнер.

Алдыбызга килеп баскан саннарыбыз бик шыксыз булганлыктан, соңгы вакытта без аларга бөтенләй игътибар итми башладык. Бу юлы алай да күз салыгыз әле. Әлеге хуҗалыкта йөз кило бәрәңгенең үзкыйммәте — нибары унике сум сиксән тиен. Моның

бит кинsocы унике-унөч тиен генә була! Гомумән алганда исә аның бездәге үзкыйммәтен, исәпләп бетерерлек тә түгел, чөнки бәрәңге игү технологиясе шулкадәр артта, шулкадәр примитив, бу турыда сөйләргә дә оят.

Тагын тарихка күз салыйк әле. Бүгенге табынын шушы ризыксыз күз алдына китерә алмаган Идел буе халкы бәрәңгегә тиз генә күнекми. Хөкүмәтнең бәрәңге игүгә юнәлдерелгән карарларына каршы крестьяннар, кулларына корал алып, баш күтәргәннәр.

Гаеп хөкүмәтнең үзендә дә була. Бәрәңге утырту өчен крестьяннарның иң яхшы, иң уңдырышлы җирләрен тартып алалар. Укымаган, караңгы халык, бу сәер нәрсәне ничек утыртырга, кайчан казырга, уңышын ничек җыярга икәнен дә белми. Сабагын ашап карыйлар. Алмаларын ашап агуланалар, үлүчеләр дә була. Бәрәңге утырткан җирләрне киредән сөреп ташлыйлар, староста ларны алыштыралар, патша чиновникларын тотып кыйныйлар, фетнәчеләрне бастырырга җибәрелгән вак отрядларны корапсызландыралар. Моның өчен күп җирләрдә крестьяннарны судсыз-нисез аталар, меңнәрчә һәм меңнәрчә баш күтәрүчеләрне солдатка озаталар.

Бәрәңге — безгә әнә шундый катлаулы юл узып, каршылыкларны җиңеп килгән ризык. Бүген беребез дә ансыз яши алмый. Җаена төшенгәч, аны үстерү мәшәкатьләре дә әллә ни түгел. Язын бакчаңа бер төртеп чыгасың. Җәй урталарында, чәчәккә бөреләнер алдыннан чүбен утап, төбенә өеп чыгасың. Ә көзгә инде басуга, җир өстенә, капчыкларыңны кыстыра кил. Базың ныклап томаланган булса, өшетмәсәң, су төшмәсә, бәрәңге анда язга тикле шикәр кебек татлы, тәмле, ярмалы булып саклана. Моннан бернечә генә еллар элек шулай иде әле, җәмәгать... Ә бүген?

Галиҗәнаб бәрәңге хәзрәтләре турында, аның тарихы, аннан әзерләнә торган татлы һәм затлы ризыклар турында, шулай тәфсилләп язуымның сере менә нәрсәдә: соңгы елларда республикабызда бәрәңге үстерү мәйданнары катастрофик тестә кимеде. Хәтта шәхси хуҗалыкта да. Сәбәбе — колорада коңгызының котыруында. Аның белән һич көрәшер чара юк. Бәрәңге, балакаем, җирдән борынын төртергә дә өлгерми, коңгызлар аны инде сарып та ала. Өч-дүрт көн дигәндә, җир өстендә каңгыраеп, коры сабак кына кала. Кендеге белән җиргә береккән авыл агае көрәшмәде түгел бу афәт белән. Бик нык көрәшеп карады, җиңен сызганып, тешен кысып. Һәр йортның, һәр хуҗалыкның аягында басып торырдай бала-чагасы, карт-корткасы иртән, кояш чыкканнан алып, кич кояш батканчы, бакчада булды. Олысы-кечесе коңгыз җыялар. Шулай бер ел узды, дүрт-бише дә узып китте. Әмма дәүләт тә, хөкүмәт тә, җирле Советлар да бәрәңге үстерүчегә ярдәмгә килмәде. Алай гынамы?! Әле административ-бюрократия аппараты кешеләре бу турыда авыз ачтырмаска тырыштылар. «Колорада коңгызы бездә юк, башкаларны белмибез, күп сөйләшеп йөрмә!» — дип янау белән кисәтеп тә куялар иде. Мин фәкыйрегез дә, моннан ун еллар элек, шушы ук мөхтәрәм журналга, нәкъ менә шушы турыда, республикабызның бәрәңге плантацияләрен саранчаның яңа төре, коточкыч комсыз хәшәрәт баса, дигән шөбһәле хәбәр китергән идем. Басылып чыкмады. Главлит рөхсәт итми иде. Сәбәбен, без монда беренче чиратта дәүләт иминлеген, аның халыкара мәйданда югары абруен күздә тотабыз, дип аңлаттылар. Янәсе, безнең республика кайсыдыр бер чит илгә яшел борчак сата икән. Моннан дәүләт казнасына валюта керә икән. Әгәр дә капиталистлар безнең басуларда колорада коңгызы барын белсәләр, алар бездән әлеге борчакны сатып алмаячаклар, дәүләт казнасына валюта керү туктапачак имеш.

Халык хак әйтә: әҗәтен яшергән бөлгән, чирен яшергән үлгән, ди. Әлеге «чир»не яшерү, вакытында чара күрмәү республикабызга һәм бөтен Рәсәйгә миллион вә миллион сумнар югалту булып кайтты. Сумнары — бер хәл, халык өстәленә куелырга тиешле арзанлы һәм татлы ризыкның күләме кимеде.

Терсәкне тешләргә тырышсак та, хәзер соң инде. Татарстанда хәзер шушы буй-буй кафтанлы корткыч җәберләмәгән бер генә сутый җир дә юк. Җәй көннәрендә алар борчак, көнбагыш, кукуруз басуларына да басып керә. Дөрес, әлегә алар бәрәңге сабагын гына коры чыбыкка калганчы кимерәләр. Алга табан тагын ни кыланырлар?..

Шушындый хәвефле хәлдә йомры башлы авыл агае нишләде, дисезме? Хөрмәтле хөкүмәт, бәрәңге сиңа кирәкмиме? Сиңа кирәкмәсә, миңа да аның хаҗәте шул чаклы гына, дип белдерде ул зур үпкәсен. Ул гомер-гомергә бәрәңгене егерме биш-утыз сутыйлап утырта иде. Үзенә дә җитә, абзары тулы эреле-ваклы терлегенә дә кала. Байтагын дәүләткә тапшыра. Райпотребсоюзлар, сельполар халыктан җыйган тәмле бәрәңгене дәүләт амбарларына эшелоны-эшелоны белән озата торган иде.

Агайларның өлгеррәкләре, бакчасында бик кадерләп үстергән бәрәңгесенең, иң эресен, иң матурын, бер карау белән нәфесеңне уята торганын, машиналарга төяп, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Казан базарларына да алып чыга иде.

Бакчалары, бәрәңге плантацияләре өстенә дошман явы булып ябырылган колорада юлбасары белән көрәшеп берни чыкмагач, ә дәүләт берничек тә ярдәм итмәгәч, авыл агаеның бу эштән тәмам гайрәте чикте. Күп сектәдә. Бәрәңге җитештерү инкүләм кискен кимеде. Авыл агае хәзер бәрәңгене үзенә кыш чыгарга җитәрлек кенә утырта башлады. Бакчасының калган төшенә күп итеп азык чөгендере, суган чәчә. Суганын сата, чөгендере белән мал симертә. Өч-дүрт сутый гына бәрәңгедәге коңгызны ничек тә җиңә инде ул. Ә бит утыз сутый җирнең кортын кул белән генә җыеп бетерү һич

мөмкин түгел. Көн буе, атна буе, ай буе таптый торгач бәрәңге төбе дә нык таптала, буразна ишелә. Андый бакчадан нинди уңыш көтәргә кирәк?

Халык тырышҺмады түгел, җан тартышып көрәшеп карады. Әлеге кортны агулыйм, дип үзе дә чиргә сабышып бетте. Бу хәшәрәт белән көрәштә бөтен өмет химиядә икәнен чамалап халык шул агуны эзләргә керешге. Районнардагы «Сельхозхимия» амбарларына кайткан целлофан капчыклардан, кайсы бер чиләк, кайсы бер алъяпкыч, кайсы бер бүрек эләктерә агуны. Ничек кулланырга икәнен өйрәтүче юк. Авыл җирендә бер чама инде ул: бер чиләккә — бер уч. Кортны күз алдында ук кәкерәйтә кәкерәйтүен, әмма агуның күп өлеше җиргә төшә, бәрәңгегә дә үтә. Әйе, бу өлкәдә мыскал да белеме; хәбәрдарлыгы булмаган халык, тәмам иза чикте әлеге агулар белән. Агулануучылар күп булды.

Инде килеп, җәмәгать, бу кадәресен дә бәян итим, кулдан, базардан сатып алган бәрәңге бүген дә шикле. Чөнки хәзер базарда бәрәңге кыйбат. Нәфесле җаннар өчен аның белән сәүдә итү хәзер бик отышлы кәсепкә әйләнде. Андыйлар бәрәңгене басуга ярты гектар чамасы утырта. Кулында машинасы. Бәрәңге кырын һәр кичне бер агулап кайта. Бәрәңгенең дә чат агу булып үсүендә аның эше юк. Үзе ашыйсы ризык түгел ич, ул аны базарда сатачак.

Дөрес, бүгенге көндә колхоз-совхоз кырларында үскән җир алмаларын да химикатлар белән «иркәләп» үстерәләр. Әмма андагы плантацияләрне белгечләр, агрономнар эшкәртә. Санитария хезмәткәрләре тикшереп кенә тора. Бу өлкәдә аларга зур җаваплылык йөкләнгән. Уен эш түгел. Узган җәйне «Казан утлары»ның махсус кушуы буенча, шушы мәсьәләне өйрәнеп, мин республикабызның күпчелек районнарын йөреп чыктым. Берочтан Башкортстан, Куйбышев өлкәләренә дә сугылдым. Шунысы сөенечле, хәзер һәркайда колхоз-совхозларда бәрәңгене бүгенге көндә иң алдынгы ысул — голландлылар ысулы белән игәргә тырышалар. Бәрәңге утырту, бәрәңге алу машиналары елдан-ел күбрәк кайта. Бу машиналар беренче чиратта хезмәт җитештерүчәнлеген нык күтәрә, аны җыеп алуны җиңеләйтә. Күп җирләрдә «Гатчинская» дигән уңдырышлы, корылыкка бирешмәүчән, кыш саклауга чыдамлы һәм тәмле бәрәңге игәләр.

Шытып чыккан көненнән алып, казый башлаганчыга тикле, аны шушы комсыз корт ашап, кимереп торса да, системалы чәчү әйләнешенә корылган, ашламасы сибелгән, тиресе мул чыгарылган колхоз басуларында бу бәрәңгенең зур уңыш биргән еллары була.

Бәрәңге игәргә теләге булган кеше шуны онытмасын: аның бөтен азыгы — көл. Бәрәңге бит үзе дә крахмалдан һәм калийдан гына тора. Шуңа күрә нинди иске-москың, кипкән кура-камылың, такта башы, йомычка кисәкләрең бар, берсен дә әрәм итмә. Яндыр да, көлен җыеп куй. Язын бәрәңге утырткан чакта һәр төпкә берәр уч салып, җир белән бутасаң, шәп булачак. Мондый төпләрдә көзгә куш йодрык, бәләк буе җир алмаларының үсәсен көт тә тор.

Хәзер колорада коңгызының тамырын корытырдай мөмкинлекләр дә бар. Узган җәйне Казанда Бөтенроссия табигатьне саклау җәмгыятенең Бөҗәкләрне саклау секциясенең махсус киңәшмәсе булды. Бөҗәкләр генә дигәч тә, аларның көндәлек тормышыбызда тоткан рольләре чиксез, моны һәркем белә булыр.

Бу киңәшмәдә Рәсәйнең бик күп өлкәләреннән килгән зыялылар, профессорлар, фән докторлары, аспирантлар, студентлар һәм киң җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты. Билгеле ки, бөҗәкләрнең әһәмияте туфракны тукландыруда, чәчүлек мәйданнарны саклауда чиксез зур. Бу өлкәдә күбрәк аларга таянырга кирәк тә икән. Ә без күбрәк химиягә баш ябез. Бер очтан үзебез өчен бик тә файдалы бөҗәкләрне, ышанычлы дусларыбызны да кырабыз. Шушы өлкәдә танылган галимнәрнең чыгышларын, залдагыларга җиткергән хәбәрләрен, авызымны ачып тыңлап утырдым.

Сүз бирелә бөҗәкнең бер төре, корткычның бер гайрәтлесе — әлеге Колорада коңгызы турында да барды. Аның төп чыгышы — Төньяк Америкадан. Европада, Франция бәрәңге басуларында 1982 елны ук күренә башлый. Шуннан бөтен Европага тарала. Бездә башта Белоруссиядә, Латвиядә, Литвада очрый. Аннары зур тизлек белән бөтен илгә тарала. Чөнки бу корткычның шундый җитезлеге бар: бер урында кысрыклый, җәберли башласалар, ул кырык чакрымнан алып, өч йөз чакрымга кадәр күчә ала. Бер колхоз, бер район җирендә тамырын корыттым дисәң, ул үзенең «эшчәнлеген» икенче районда, күрше өлкәдә җәелдереп җибәрә. Шулай булгач, аның белән көрәш ысуллары комплекслы, күрше-тирә районнар, өлкәләр белән килешеп эшләнергә тиеш.

Әлеге зур киңәшмәдә катнашкан галимнәр бу турыда дәлилләп сөйләделәр. Әйтик, шушы хәшәрәтнең туган җире Төньяк Америкада, үзенең «уги баласыннан» котылу өчен, Америка Кушма Штатлары үз җирләрендә инде утыз җиде ел бәрәңгене, гомумән, икми. Бәрәңге дөнья базарында кыйммәтле продукт булып саналмый. Алар аны Европадан, бигрәк тә Польшадан сатып алалар. Үзләренә җитәрлек күләмдә. Бу өлкәдә америкалылар илле елга исәпләнгән махсус программа нигезендә эш итәләр. Шушы ысул белән җирләрен, чәчүлекләрен әлеге комсыздан тәмам арындырмак булалар икән.

Бездә андый мөмкинлекләр юк. Ил алдында, халык алдында иртәгә нәрсә ашарбыз, дигән мәсьәлә тора. Бу корткыч белән көрәшү чаралары да бездә башкачарак, оператив булырга тиеш. Авыл һәм шәһәр җирләрендә бүгеннән ук җыеннар җыеп аңла-

ту кирәк. Халык үз бакчасына, дачаларга бер төп тә бәрәңге утыртмасын. Аларга бәрәңге утырту өчен җирләрне колхоз-совхоз басуларыннан бирергә кирәк. Совхоз аларга җирне сукалап, тырмалап, эшкәртеп тә бирсен. Бөтен кешенеке бер тирәдә, бер басуда булганлыктан, аны трактор белән эшкәртү, төбенә өеп чыгу да ярты көнлек кенә эш. Район җирләрендәге «Сельхозхимия» бүлекчәләре бу басуны тәртибен һәм вакытын, чамасын белеп, агу белән эшкәртә. Көзен бу бәрәңгене оешкан төстә җыеп та аласың. Дөрес, әлеге хезмәтләрне оештырган өчен колхоз-совхоз кассаларына беркадәр түләргә туры килачәк.

Халыкны бүгеннән үк менә шуңа әзерли башларга кирәк. Соңару — үзебезне ачлыктан үлемгә дучар итү. Моны һәркем аңларга тиеш, үзебез кайгыртмасак, безне бер ил дә, бер дәүләт тә туйдыра алмаячак. Чөнки без сан ягыннан гаять күп — өч йөз миллион! Уйлап кына карагыз: эшләргә теләмәгән, ялкау күршегезне үзегез күпме кызгана, күпме туйдырып тора алыр идегез?!

Бөтен районнарда, бөтен республикада көрәшне «Сельхозхимия» үз өстенә алганда, бу корткычны авызлыкларга мөмкин булыр иде. Моның өчен бер генә кеше дә, бәрәңгене тиешсез җиргә утыртмасын! Хәтта аларны чүплеккә дә ташларга ярамый. Әйтик, иң кирәкле чагында «Сельхозхимия» бердәм кубып, бу корткычка каршы көрәш ача, аларны кырып сала. Ә кемнеңдер бакчасындагы дүрт-биш түтәл бәрәңгедә, яисә чүплек башында калыккан бәрәңгеләрдә, бу хәшәрәтләр — мыжлап утыра. Бу чакта әлеге көрәш бернинди нәтиҗә дә бирмәячәк. Берәр атнадан, алар яңадан бөтен басуыңны басачаклар. Җирле Советларыбызга бу өлкәдә моңарчы күрелмәгән өлгергәнлек, уяулык, оста оештыручанлык, халык белән ышандырып, көндерел сөйләшә белү кирәк. Киңәшмәдә катнашкан мөхтәрәм галимнәрнең фикере шул. Башка көрәш чарасы юк.

Кардәшләр! Никадәр вакытыгызны бирел укыган очеркымны өметле авазлар белән тәмамлыйсым килә. Кешелек тарихында һәм үзебезнең ил тарихында катаклизмнар һәрчак булып торган. Акыл көчен эшкә җигеп, кешелек аларны һәрчак җиңә килгән. Ышаныгыз, матураячак тормышыбыз. Чөнки арабызда аны бизәрдәй матур кешеләр күп. Безнең шәһәрдә бәрәңге үстерү остасы Рөстәм Хәсәншин дигән һәвәскәр яши. Ир уртасы бу уңган җан үзенең бакчасында, алты-җиде сутый җирнең һәр сутыеннан тонна-тонна ярым уңыш ала. Зинһар, автор бераз арттыра, чамасыз күпертә, дип уйлый күрмәгез. Рөстәм әфәнде — исән-имин кеше, «Лениногорскнефть» идарәсендә өлкән инженер. Бәрәңге үстерүнең бик күп серләрен белә, шушы турыда шәһәр һәм республика газеталарында мәкаләләр дә бастыра. Ирешкән уңышларын ул һич тә соңгы чик дип санамый. Бәрәңгедән тагын да мулрак уңыш алырга мөмкин икән. Бездә әле икенче Хәсәншин да бар. Монысы һәвәскәр генә түгел, ә чын профессионал, районның баш агрономы. Монысының исеме Рәис. Авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, докторы да булырга җыена. Республикабыз кырларында минераль ашламаларны ничек чамасын һәм кадерен белеп кенә кулланырга кирәклеге турындагы фәнни хезмәтен Рәис Хәсәншин Мәскәүгә барып яклый. Бу да — бәрәңге яратучы егет. Шушы бик кирәкле һәм тәмле ризыкны безнең районда мул итеп игү, мул итеп уңышлар алу максатында, бу изге эшкә ул җиң сызганып тотынды. Хәзер безнең районда бәрәңгене әлегә иң алдынгы булып саналган «голландиялеләр технологиясе» белән үстерү өчен бөтен чаралар күрелә.

Тагын бер хәл искә төште. Миңа яхшы таныш авыл хуҗалыгы училищесы егетләре моннан дүрт-биш ел элек Мәскәүгә Бөтенсоюз Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенә бардылар. Кендеге тумыштан җиргә берекән малайларның күзе авыл хуҗалыгы павильонында күргәзмәгә куелган бәрәңгегә төшә. Төшмәслек тә түгел. Станокта кырдырган шарлар төсле барысы бер зурлыкта икән алар. Күзләре дә тирәнгә, эчкә батмаган. Әрчи башласаң, ярты бәрәңгең кабыкка чыкмаячак. Бәрәңгене соң кем саклап торсын, павильон шүрлекләрендә алар тәгәрәшеп, хәтта кызыктырып яталар. Бик кызыккач, «сорап алырга кыймыйча гына», берәр бәрәңгене кесәләренә салалар малайлар. Берсеннән-берсе яшереп, әлбәттә. Күрсәләр, карак, диярләр. Әмма номерларына кайткач карасалар, уналты малай берәр бәрәңге чәлдергән. Бәрәңгене җыеп замполитларына бирәләр. Анысы да авыл егете. Капчыгына салып куя, авылга алып кайта. Кыш буе кадерләп саклап чыга, язын бакчасына утырта. Кыскасы, замполит егет бу орлыклардан беренче елны ук егерме дүрт чиләк уңыш ала. Бу бәрәңге безнең кара җирләрне бик килештергән күрәсең. Тәгәрәп уңган. Ул аны алдагы елларда дусиштәренә, таныш-белешләренә дә тарата башлый, орлыклык өлеш чыгара.

Аңлашыла торгандыр: соңгы ике-өч ел эчендә үзем дә шул сорт җир алмасын утыртам әле. Өлеш миңа да тиде. Бәләк тикле булып уңа. Ул чорларда башка мәшәкатьләрне онытып торырга туры килә. Басудан, күрше бакчалардан очып килеп төшкән әлеге буй-буй кафтанлы юлбасарны тавык урынына чүпләп торам. Аягың тыпылдамаса, авызың шапылдамый. Бәхәссез хакыйкать. Аның каравы — уңып та карый! Һәр төпне яратып, сөеп, иркәләп, сәнәк очы белән генә ачып җибәрәсең, як-якка куш йодрыктай эре бәрәңге тарала. Ә тәме инде! Кабыклы килеш кенә пешереп җибәрәсең. Пешеп чыгу белән коштабакка бушатып куясың. И-их!

Инде бу тикле итеп язгач, мактангач, дигәндәй, юлыгыз-сәфәрегез безнең якларга төшсә, авыз итәргә керегез! Ипиең ак, чәең кара булса да ярар, дигән шаярулы әйтем бар. Чәем кара, ипием ак. Өстәлдә ярмаланып пешкән кабыклы бәрәңге, ягъни чикмәнле бавырсак бу бөркеп утыра. Рәхим итегез!

# КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕ

## «Буруҗ» («Йолдызлыклар») сүрәсе

СИКСӘН БИШЕНЧЕ СҮРӘ,
ЕГЕРМЕ ИКЕ АЯТЬ

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيْمِ
وَالسَّمَآءِ ذَاتِ الْبُرُوْجِ ۝ وَالْيَوْمِ الْمَوْعُوْدِ ۝ وَ
شَاهِدٍ وَّمَشْهُوْدٍ ۝ قُتِلَ اَصْحٰبُ الْاُخْدُوْدِ ۝
النَّارِ ذَاتِ الْوَقُوْدِ ۝ اِذْ هُمْ عَلَيْهَا قُعُوْدٌ ۝ وَّهُمْ
عَلٰى مَا يَفْعَلُوْنَ بِالْمُؤْمِنِيْنَ شُهُوْدٌ ۝ وَمَا نَقَمُوْا
مِنْهُمْ اِلَّآ اَنْ يُّؤْمِنُوْا بِاللّٰهِ الْعَزِيْزِ الْحَمِيْدِ ۝ الَّذِيْ
لَهٗ مُلْكُ السَّمٰوٰتِ وَالْاَرْضِ ۝ وَاللّٰهُ عَلٰى كُلِّ شَيْءٍ
شَهِيْدٌ ۝ اِنَّ الَّذِيْنَ فَتَنُوا الْمُؤْمِنِيْنَ وَالْمُؤْمِنٰتِ

ثُمَّ لَمْ يَتُوْبُوْا فَلَهُمْ عَذَابُ جَهَنَّمَ وَلَهُمْ عَذَابُ الْحَرِيْقِ ۝
اِنَّ الَّذِيْنَ اٰمَنُوْا وَعَمِلُوا الصّٰلِحٰتِ لَهُمْ جَنّٰتٌ تَجْرِيْ مِنْ
تَحْتِهَا الْاَنْهٰرُ ذٰلِكَ الْفَوْزُ الْكَبِيْرُ ۝ اِنَّ بَطْشَ رَبِّكَ
لَشَدِيْدٌ ۝ اِنَّهٗ هُوَ يُبْدِئُ وَيُعِيْدُ ۝ وَهُوَ الْغَفُوْرُ
الْوَدُوْدُ ۝ ذُو الْعَرْشِ الْمَجِيْدُ ۝ فَعَّالٌ لِّمَا يُرِيْدُ ۝
هَلْ اَتٰىكَ حَدِيْثُ الْجُنُوْدِ ۝ فِرْعَوْنَ وَثَمُوْدَ ۝
بَلِ الَّذِيْنَ كَفَرُوْا فِيْ تَكْذِيْبٍ ۝ وَّاللّٰهُ مِنْ وَّرَآئِهِمْ
مُّحِيْطٌ ۝ بَلْ هُوَ قُرْاٰنٌ مَّجِيْدٌ ۝ فِيْ لَوْحٍ مَّحْفُوْظٍ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Вәс-сәмәэи затил-буруҗи (2). Вәл-йаумил-мәугуди (3). Вә шаһидин вә мәшһуд (4). Кутилә әсхабул-ухдуди (5). Ән-нари затил-вәкуди (6). Изһум галәйһа кугудув (7). Вә һум галә мә йәфгалунә бил-муэмининә шуһуд (8). Вә мә нәкаму минһум иллә әй-йуэмину билләһил-газизил-хамид (9). Әлләзи ләһу мулкус-сәмәвати вәл-ард, вәл-лаһу галә кулли шәйэин шәһид (10). Иннәл-ләзинә фәтәнул-муэмининә вәл-муэминати суммә ләм йәтубу фә-ләһум газабу җәһәннәмә вә ләһум газабул-харикъ (11). Иннәл-ләзинә әмәну вә гамилус-салихати ләһум җәннәтун тәҗри мин тахтихәл-әнһар заликәл-фәузул-кәбир (12). Иннә батшә раббикә лә-шәдид (13). Иннәһу һувә йубдиэу вә йугыйд (14). Вә һувәл-гафурул-вәдуд (15). Зул-гаршил-мәҗиду (16). Фәггалул-лимә йурид (17). Һәл этакә хадисул-җунуди (18). Фир-гаунә вә Сәмуд (19). Бәлил-ләзинә кафәру фи тәкзибив (20). Вәл-лаһу мив-вәраэиһим-мохит (21). Бәл һувә Коръәнум-мәҗидун (22). Фи ләухим-мәхфуз.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Йолдызлар иясе булган Күк белән ант итәмен, һәм дә вәгъдә ителгән (кыямәт) көне белән, һәм дә гуаһ, ягъни шаһит булучы һәм гуаһ булынган,

ягъни кыяматтэгеләр белән ант итәмен. Яндыручы ут булган ухдүд ияләре[1] ләгънәт ителде. Ул халык — ут өстенә утыручылар һәм дә үзләренең мөэмин-мөселманнарга кылган эшләрен күреп торучылардыр. Ухдүд — җирдәге ярыклардыр. Кяферләрдән бәгъзеләре мөэминнәрне җир ярыкларына ут ягып һәлак кылдылар. Мөэминнәрне җир ярыкларына ташлагач, Аллаһы Тәгалә мөэминнәрне, җаннарын утка төшүдән элек алып, ут газабына төшүдән сәламәт калдырды. Соңыннан шул ярыклардан ут чыгып, шул кяферләрне үзләрен һәлак итте (2, 3, 4, 5, 6, 7). Ул кяферләр мөэминнәрнең хәлләреннән һәрнәрсәгә көчле һәм һәрбер мактаулы сыйфатлы булган Җир һәм Күкләр милкендә булган, һәрбер нәрсәне күреп торучы Аллаһы Тәгаләгә иман китерүләреннән башка хәлләренә каршы тормыйлар, кяферләрнең бар сөймәгәннәре — мөэминнәрнең Аллаһыга иман китерүләре генәдер. Мөэмин ирләрне һәм дә мөэминә хатыннарны ут белән яндырып җәфалаучылар бу эшләреннән соң тәүбә итмәсәләр, аларга җәһәннәм газабы, һәм дә ут белән яндыру газабы булыр (8, 9, 10). Дөреслектә, иман китереп, изге гамәл кылган кешеләр өчен асларыннан елгалар ага торган җәннәтләр булыр. Бу җәннәтләргә керү — олуг сәгадәт һәм зур бәхеттер. Дөреслектә, синең Раббеңнең газап белән тотуы — катыдыр, ягъни кяферләр мөэминнәргә дөньяда җәфа кылсалар да, Аллаһы Тәгаләнең аларга кылачак газабы — аларның мөэминнәргә кылган җәфаларыннан күп өлеш катырак булыр. Дөреслектә, Ул, Аллаһы Тәгалә, халыкны башта да бар кылучы һәм үлгәннән соң да тергезеп кайтаручыдыр. Ул, Аллаһы Тәгалә, гөнаһларны барын да ярлыкаучы, үзенә буйсынучыларны дус тотучы олуглык Иясе, Гарше-Күк хуҗасы, һәрбер теләгән нәрсәсен кылучыдыр (11, 12, 13, 14, 15, 16). Әй, Мөхәммәд! Кяферләрнең үзенең ялганга чыгаруларына үзеңне сабыр кыл! Дөреслектә, фиргавен һәм Сәмуд кавеменең сүзе, аларның пәйгамбәрләрен ялганга чыгаручылары ирештe сиңа. Кяфер булган кавем үз пәйгамбәрләрен ялганга тотучан булалар. Әмма Аллаһы Тәгалә аларны һәрбер яктан чолгап алгандыр, ягъни алар Аллаһының газабыннан котыла алмаслар. Кяферләр кадерен белмәсәләр дә, ул китап-вәгазь булган олуг кодрәт иясе Аллаһы Тәгаләнең кадерле китабыдыр. Ул Коръән — ләүхел-мәхфүздә, ягъни язмыш тактасында язылган (17, 18, 19, 20, 21, 22, 23).

## «Әт-тарикъ» («Төнлә калкучы йолдыз») сүрәсе

СИКСӘН АЛТЫНЧЫ СҮРӘ,
УНҖИДЕ АЯТЬ

بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ
وَٱلسَّمَآءِ وَٱلطَّارِقِ ۝ وَمَآ أَدۡرَىٰكَ مَا ٱلطَّارِقُ ۝
ٱلنَّجۡمُ ٱلثَّاقِبُ ۝ إِن كُلُّ نَفۡسٖ لَّمَّا عَلَيۡهَا حَافِظٞ ۝
فَلۡيَنظُرِ ٱلۡإِنسَٰنُ مِمَّ خُلِقَ ۝ خُلِقَ مِن مَّآءٖ دَافِقٖ ۝
يَخۡرُجُ مِنۢ بَيۡنِ ٱلصُّلۡبِ وَٱلتَّرَآئِبِ ۝ إِنَّهُۥ عَلَىٰ
رَجۡعِهِۦ لَقَادِرٞ ۝ يَوۡمَ تُبۡلَى ٱلسَّرَآئِرُ ۝ فَمَا لَهُۥ مِن
قُوَّةٖ وَلَا نَاصِرٖ ۝ وَٱلسَّمَآءِ ذَاتِ ٱلرَّجۡعِ ۝ وَٱلۡأَرۡضِ
ذَاتِ ٱلصَّدۡعِ ۝ إِنَّهُۥ لَقَوۡلٞ فَصۡلٞ ۝ وَمَا هُوَ بِٱلۡهَزۡلِ ۝
إِنَّهُمۡ يَكِيدُونَ كَيۡدٗا ۝ وَأَكِيدُ كَيۡدٗا ۝ فَمَهِّلِ
ٱلۡكَٰفِرِينَ أَمۡهِلۡهُمۡ رُوَيۡدَۢا ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Вәс-сәмәэи вәт-тарикый (2). Вә мә әдракә мәт-тарику (3). Ән-нәҗмус-сәкыйбу (4). Ин куллу нәфсил-ләммә галәйһа хафиз (5). Фәл-йанзурил-инсану миммә хуликъ (6). Хулика миммәзин дафикый (7). Йахруҗу мимбәйнис-сулби вәт-тәраэиб (8). Иннәһу галә рәҗгыйһи лә-кадир (9). Йаумә тубләс-сәраэиру (10). Фәмә ләһу мин кувватив вә лә насыйр (11). Вәс-сәмаэи затиррәҗгый (12). Вәл-арди затис-садгый (13). Иннәһу лә-каулун фаслув (14). Вә мә һувә бил-һәзл (15). Иннәһум йәкидунә кәйдәв (16). Вә әкиду кәйда (17). Фә-мәһһилил-кәфиринә әмһилһум рувәйда.*

[1] Ухдүд ияләре — үзләренең иманнары өчен, кайбер дингә ышанучыларны салып яндыра торган тирән чокыр ияләре (Ә. Х.).

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Күк һәм дә кичне яктыртучы гаҗәп сыйфатлы булган йолдыз белән ант итәмен: һәрбер җан өчен аталган сакчы бардыр. Инде адәм үзе ни нәрсәдән яратылганны гыйбрәт белән карасын, ул — адәм ирләрнең аркасыннан, хатыннарның күкрәк тарафыннан атылып чыккан судан яратылды (2, 3, 4, 5, 6, 7). Адәмне шул судан бар кылган Аллаһы Тәгалә ул адәмне һәрбер яшерен серләр сынала торган Кыямәт көнендә кайтадан тергезергә, әлбәттә, көче җитәчәктер. Башлап бар иткән Аллаһыга үлгәннән соң тергезә алмас дип карышкан кешенең кубарган көндә газаптан котылуга көче дә булмас, башка бер булышучы да булмас (8, 9, 10)! Бер төшеп, бер менеп ява торган яңгыр иясе булган Күк белән ант итәмен, һәм дә ярыгыннан чишмәләр чыга торган Җир белән ант итәмен, дөреслектә ул Коръән — хак белән ялган арасын аеручы сүздер һәм төпсез, уйнап сөйләнгән сүз түгелдер (11, 12, 13, 14). Дөреслектә, ул Мәккә мөшрикләре, ягъни мәҗүсиләре үзләренчә олуг хәйләләр кылалар. Коръәнне өскә чыгармаска тырышалар. Аларның хәйләләренә каршы Мин дә хәйлә корырмын. Инде син алар белән һәм аларның карышуларын кире кагу белән шөгыльләнмә, бәлки аларга ялганлыкларында-бозыклыкларында йөрергә ирек бир. Мин дә аларга аз гына ирек бирермен (ягъни Бәдәр сугышына кадәр ирек биреп, Бәдәрдә аларга тиешле җәзалары бирелде) (15, 16, 17).

## «Әгъла» («Иң биек») сүрәсе

### СИКСӘН ҖИДЕНЧЕ СҮРӘ, УНТУГЫЗ АЯТЬ

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
سَبِّحِ اسْمَ رَبِّكَ الْأَعْلَى ۝ الَّذِي خَلَقَ فَسَوّٰى ۝
وَالَّذِي قَدَّرَ فَهَدٰى ۝ وَالَّذِي أَخْرَجَ الْمَرْعٰى ۝
فَجَعَلَهُ غُثَاءً أَحْوٰى ۝ سَنُقْرِئُكَ فَلَا تَنْسٰى ۝ إِلَّا
مَا شَاءَ اللهُ إِنَّهُ يَعْلَمُ الْجَهْرَ وَمَا يَخْفٰى ۝ وَ
نُيَسِّرُكَ لِلْيُسْرٰى ۝ فَذَكِّرْ إِنْ نَفَعَتِ الذِّكْرٰى ۝
سَيَذَّكَّرُ مَنْ يَخْشٰى ۝ وَيَتَجَنَّبُهَا الْأَشْقَى ۝ الَّذِي
يَصْلَى النَّارَ الْكُبْرٰى ۝ ثُمَّ لَا يَمُوتُ فِيهَا وَلَا يَحْيٰى ۝
قَدْ أَفْلَحَ مَنْ تَزَكّٰى ۝ وَذَكَرَ اسْمَ رَبِّهِ فَصَلّٰى ۝ بَلْ
تُؤْثِرُونَ الْحَيٰوةَ الدُّنْيَا ۝ وَالْآخِرَةُ خَيْرٌ وَأَبْقٰى ۝
إِنَّ هٰذَا لَفِي الصُّحُفِ الْأُولٰى ۝ صُحُفِ إِبْرٰهِيمَ وَمُوسٰى ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Сәббихисмә раббикәл-әгъла (2). Әлләзи халәка фәсаууә (3). Вәл-ләзи каддәрә фә-һәдә (4). Вәл-ләзи әхраҗәл-мәргә (5). Фә-җәгаләһу гусаән әхвә (6). Сәнукъриэукә фә-лә тәнсә (7). Иллә мә шәәл-лаh, иннәһу йәгъләмул-җәһрә вә мә йахфә (8). Вә нуйәссирукә лил-йусра (9). Фә-зәккир ин-нәфәгатиз-зикра (10). Сәйузәккәру мәй-йахшә (11). Вә йәтәҗәннәбуһәл-әшка (12). Әлләзи йаслән-нарал-кубра (13). Суммә лә йәмуту фиһа вә лә йахьйә (14). Кад әфләhа мән тәзәккә (15). Вә зәкәрасмә раббиһи фә-салла (16). Бәл туэсирунәл-хайатәд-дуньйа (17). Вәл-ахирату хайрув вә әбка (18). Иннә һазә лә-фис-сухуфил-улә (19). Сухуфи Ибраһимә вә Муса.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Әй, Мөхәммәд! Һәрбер кимчелекләрдән пакь булган Раббеңнең исемен кимчелекләрдән пакьла! Ул Раббең шундый Заттыр — һәр нәрсәне яратты һәм дә гүзәл кылды, янә дә шундый Заттыр — ул Раббең һәр нәрсәне тәкъдир итте дә шул тәкъдир иткән нәрсәсенә күндерде. Һәм шундый Заттыр — ул Раб-

беӊ хайваннар ашый торган болынлыкларны чыгарды һәм дә Ул үләннәрне, яшеллекләре соңында кара һәм кипкән хәлдә кылды (2, 3, 4, 5). Әй, Мөхәммәд! Сиңа аятьләр укытырбыз. Син аны онытмассың, бары яшерен вә ачык нәрсәләрне белүче Аллаһы Тәгалә онытыруны теләгән нәрсәләрне генә онытырсың (6, 7). Әй, Мөхәммәд! Без сине җиңел булган ислам шәригатенә муафикъ кылырбыз. Коръән белән халыкны вәгазьлә, әгәр дә аның белән вәгазьләү файда бирсә, Аллаһы Тәгаләдән курыккан кеше, әлбәттә, Коръән белән вәгазьләнер (8, 9, 10). Һәм дә олуг утка керәчәк иң яман ул кеше Коръәннән читтә булыр, ул Коръәннән качкан кеше тәмугка керер дә, ул тәмугта газапны сизмәслек дәрәҗәдә үлмәс һәм дә торырлык, йөрерлек дәрәҗәдә тереклек күрмәс (11, 12, 13). Дөньяда вакытта кяфер һәм мәҗүсилектән пакьланып, Раббесенең исемен телгә алып намаз кылган кеше ахирәттә газаптан котылып, үзе теләгән җәннәткә керер. Ул азгыннар иман китерми. Коръән белән вәгазьләнми, дөнья тереклеген ахирәт тереклегеннән артык күрәләр, әмма ахирәт — дөньядан изге һәм дә дөнья кебек фани булмый торган мәңгелек йорттыр. Ошбу нәрсәләр, ягъни көфердән пакь булып намаз кылган кешеләрнең җәннәтле булуы, ахирәтнең мәңге булуы — әүвәлге китаплардан булган Ибраһим китабы белән Муса китапларында бәян ителгән хөкемнәр. Хәзрәти Ибраһимга Аллаһы Тәгаләдән ун кәгазь иңдерелгән, хәзрәти Мусага «Тәүрат» исемле китап иңдерелгән (14, 15, 16, 17, 18, 19).

## «Әл-гашийә» («Үлекләр терелә торган көн») сүрәсе

СИКСӘН СИГЕЗЕНЧЕ СҮРӘ,
ЕГЕРМЕ АЛТЫ АЯТЬ

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ
هَلْ أَتَاكَ حَدِيثُ الْغَاشِيَةِ ۝ وُجُوهٌ يَوْمَئِذٍ
خَاشِعَةٌ ۝ عَامِلَةٌ نَاصِبَةٌ ۝ تَصْلَىٰ نَارًا حَامِيَةً ۝
تُسْقَىٰ مِنْ عَيْنٍ آنِيَةٍ ۝ لَيْسَ لَهُمْ طَعَامٌ إِلَّا مِنْ
ضَرِيعٍ ۝ لَا يُسْمِنُ وَلَا يُغْنِي مِنْ جُوعٍ ۝ وُجُوهٌ
يَوْمَئِذٍ نَاعِمَةٌ ۝ لِسَعْيِهَا رَاضِيَةٌ ۝ فِي جَنَّةٍ
عَالِيَةٍ ۝ لَا تَسْمَعُ فِيهَا لَاغِيَةً ۝ فِيهَا عَيْنٌ جَارِيَةٌ ۝
فِيهَا سُرُرٌ مَرْفُوعَةٌ ۝ وَأَكْوَابٌ مَوْضُوعَةٌ ۝ وَ

نَمَارِقُ مَصْفُوفَةٌ ۝ وَزَرَابِيُّ مَبْثُوثَةٌ ۝ أَفَلَا
يَنْظُرُونَ إِلَى الْإِبِلِ كَيْفَ خُلِقَتْ ۝ وَإِلَى السَّمَاءِ
كَيْفَ رُفِعَتْ ۝ وَإِلَى الْجِبَالِ كَيْفَ نُصِبَتْ ۝ وَ
إِلَى الْأَرْضِ كَيْفَ سُطِحَتْ ۝ فَذَكِّرْ إِنَّمَا أَنْتَ
مُذَكِّرٌ ۝ لَسْتَ عَلَيْهِمْ بِمُصَيْطِرٍ ۝ إِلَّا مَنْ تَوَلَّىٰ
وَكَفَرَ ۝ فَيُعَذِّبُهُ اللَّهُ الْعَذَابَ الْأَكْبَرَ ۝
إِنَّ إِلَيْنَا إِيَابَهُمْ ۝ ثُمَّ إِنَّ عَلَيْنَا حِسَابَهُمْ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Һәл әтәкә хәдисул-гашийә (2). Вуҗуһуй-йаумәэизин хашигатун (3). Гамиләтун-насыйбәтун (4). Тасла наран хамийәтән (5). Туска мин гайнин анийә (6). Ләйсә ләһум тагамун илла мин даригыйл (7). Лә йусмину вә лә йугъни мин җугый (8). Вуҗуһуййаумәэизин-нагыймәтул (9). Лисәгыйһа радыйәтун (10). Фи җәннәтин галийәтил (11). Лә тәсмәгу фиһа лагыйә (12). Фиһа гайнун җарийәтун (13). Фиһа сурурум-мәрфугатув (14). Вә әквабум-мәудугатув (15). Вә нәмарику масфуфәтув (16). Вә зәрабиййу мәбсусә (17). Ә фә-лә йәнзуруна иләл-ибили кәйфә хуликат (18). Вә иләссәмәэи кәйфә руфигат (19). Вә иләл-җибали кәйфә нусыйбәт (20). Вә иләл-арди кәйфә сутыйхат (21). Фә-зәккир иннәмә әнтә музәккәрун (22). Ләстә галәйһим би-мусайтыйр (23). Илла мән тәвәллә вә кәфәра (24). Фә-йугаззибуһул-газабәл-әкбәр (25). Иннә иләйна ийабәһум (26). Суммә иннә галәйна хисабәһум.*

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Әй, Мөхәммәд! Чыннан да сиңа адәмнәрне куркытучы көннең хәбәре килде. Ул көндә кяфер булганнар хурлыкта һәм дә төрле мәшәкатьтә булып, кызулыкта чиктән тыш булган утка кереп, бик эссе булган чишмәнең савытларыннан сугарылыр. Ул кяферләргә симертми һәм дә туйдырмый торган тигәнәлектән башка ризык та булмас (2, 3, 4, 5, 6, 7). Ул көндә кайбер йөзләр нигъмәттә булырлар. Үзләренең кылган эшләренә разый булып, олуг булган җәннәттә, мәгънәсез сүзләр ишетми утырырлар. Ул җәннәттә агып торучы чишмә, беренче дәрәҗәдә булган урындыклар, алларына куелган савытлар, кайберсе кайберсенә янәшә куелган түшәкләр, җәеп куелган паласлар булыр (8, 9, 10, 11, 12, 13, 14, 15, 16). Адәмнәр ул ничек яратылган диеп, гыйбрәтле күзләре белән тәвәгә карамыйлармы? Ничек биек кылынган диеп, күккә карамыйлармы?! Ничек беркетелгән диеп, тауларга карамыйлармы?! Ничек түшәлгән дип, җиргә карамыйлармы (17, 18, 19, 20)?! Инде син, әй, Мөхәммәд! Халыкны вәгазьлә! Син бары вәгазь кылучы гынасың, ягъни кяферләрне Коръән белән вәгазь кылудан башка эш сиңа бирелмәде. Инде ул кяферләрнең иманнан йөз чөереп, Коръәнне инкяр кылганнарын Аллаһы Тәгалә аларны иң олуг булган газап белән газаплар. Ул кяферләр синең сүзеңне тыңламыйлар икән, син алар өчен бер дә борчылма, алар соңгы көндә Безнең тарафыбызга кайтачаклар! Шуннан соң аларны хисаплау да Безнең кулыбызда. Син аларны хаклыкка өндә дә, кабул итсәләр — хуш, итмәсәләр — кыямәттә җәзаларын Мин үзем бирермен (21, 22, 23, 24, 25, 26).

## «Фәҗер» («Таң») сүрәсе

СИКСӘН ТУГЫЗЫНЧЫ СҮРӘ.
УТЫЗ АЯТЬ.

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيْمِ
وَالْفَجْرِ ۝ وَلَيَالٍ عَشْرٍ ۝ وَالشَّفْعِ وَالْوَتْرِ ۝ وَ
الَّيْلِ اِذَا يَسْرِ ۝ هَلْ فِيْ ذٰلِكَ قَسَمٌ لِّذِيْ حِجْرٍ ۝
اَلَمْ تَرَ كَيْفَ فَعَلَ رَبُّكَ بِعَادٍ ۝ اِرَمَ ذَاتِ الْعِمَادِ ۝
الَّتِيْ لَمْ يُخْلَقْ مِثْلُهَا فِي الْبِلَادِ ۝ وَثَمُوْدَ الَّذِيْنَ
جَابُوا الصَّخْرَ بِالْوَادِ ۝ وَفِرْعَوْنَ ذِي الْاَوْتَادِ ۝
الَّذِيْنَ طَغَوْا فِي الْبِلَادِ ۝ فَاَكْثَرُوْا فِيْهَا الْفَسَادَ ۝
فَصَبَّ عَلَيْهِمْ رَبُّكَ سَوْطَ عَذَابٍ ۝ اِنَّ رَبَّكَ
لَبِالْمِرْصَادِ ۝ فَاَمَّا الْاِنْسَانُ اِذَا مَا ابْتَلٰىهُ رَبُّهٗ
فَاَكْرَمَهٗ وَنَعَّمَهٗ فَيَقُوْلُ رَبِّيْ اَكْرَمَنِ ۝ وَاَمَّا
اِذَا مَا ابْتَلٰىهُ فَقَدَرَ عَلَيْهِ رِزْقَهٗ فَيَقُوْلُ رَبِّيْ
اَهَانَنِ ۝ كَلَّا بَلْ لَّا تُكْرِمُوْنَ الْيَتِيْمَ ۝ وَلَا
تَحٰٓضُّوْنَ عَلٰى طَعَامِ الْمِسْكِيْنِ ۝ وَتَاْكُلُوْنَ
التُّرَاثَ اَكْلًا لَّمًّا ۝ وَّتُحِبُّوْنَ الْمَالَ حُبًّا جَمًّا ۝
كَلَّا اِذَا دُكَّتِ الْاَرْضُ دَكًّا دَكًّا ۝ وَّجَآءَ رَبُّكَ
وَالْمَلَكُ صَفًّا صَفًّا ۝ وَجِايْٓءَ يَوْمَئِذٍۭ بِجَهَنَّمَ
يَوْمَئِذٍ يَّتَذَكَّرُ الْاِنْسَانُ وَاَنّٰى لَهُ الذِّكْرٰى ۝ يَقُوْلُ
يٰلَيْتَنِيْ قَدَّمْتُ لِحَيَاتِيْ ۝ فَيَوْمَئِذٍ لَّا يُعَذِّبُ
عَذَابَهٗٓ اَحَدٌ ۝ وَّلَا يُوْثِقُ وَثَاقَهٗٓ اَحَدٌ ۝ يٰٓاَيَّتُهَا
النَّفْسُ الْمُطْمَئِنَّةُ ۝ ارْجِعِيْٓ اِلٰى رَبِّكِ رَاضِيَةً
مَّرْضِيَّةً ۝ فَادْخُلِيْ فِيْ عِبَادِيْ ۝ وَادْخُلِيْ جَنَّتِيْ

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1).*
*Вәл-фәҗри (2). Вә ләйәлин гашрив (3). Вәш-шәфгыйи вәл-вәтри (4). Вәл-ләйли иза йәсри (5). Һәл фи заликә касәмуллизи хиҗр (6). Әләм тәра кәйфә фәгалә раббукә би-Гадин (7). Ирәмә затил-гыймади (8). Әлләти ләм йухләкъ мислуһа фил-билад (9). Вә*

*Сәмудәл-ләзинә җабус-сахра бил-вади (10). Вә Фиргаунә зил-әутад (11). Әлләзинә тагау фил-билади (12). Фә-эксәру фиһәл-фәсадә (13). Фә-саббә галәйһим раббукә сәута газабин (14). Иннә раббәкә лә-бил-мирсад (15). Фә-әммәл-инсан иза мәбтәлаһу раббуһу фә-әкрамәһу вә нәггамәһу фә-йәкулу рабби әкрамән (16). Вә әммә иза мәбтәлаһу фә-кадәра галәйһи ризкаһу фә-йәкулу рабби әһанән (17). Кәллә бәл-лә тукримунәл-йәтимә (18). Вә лә тәхаддунә галә тагамил-мискин (19). Вә тәэкулунәт-турасә әкләл-ләммәв (20). Вә тухиббунәл-малә хуббән җәммә (21). Кәллә иза дукәтил арду дәккән дәккәв (22). Вә җаэә раббукә вәл-мәләку саффән саффа (23). Вә җиа йаумәэизим-би-җәһәннәмә йаумәэизин йәтәзәккәрул-инсану вә әннә ләһуз-зикра (24). Йәкулу йа-ләйтәни каддәмту ли-хайати (25). Фә-йаумәэизил-лә йугаззибу газабәһу әхадүв (26). Вә лә йусику вә сакаһу әхәд (27). Йа әййәтуһан-нәфсул-мутьмәэиннәһ (28). Иржигый илә раббики радийәтәм-мәрдыййә (29). Фәдхули фи гыйбади (30). Вәдхули җәннәти.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Таң белән, һәм дә унынчы зөлхиҗҗә белән, җефт һәм дә так булган, ягъни парлы яки ялгыз булган нәрсәләр белән, һәм дә кичнең үткән заманы белән, ант итәмен, бу нәрсәләрдә, әлбәттә, гакыл ияләре өчен ант итү бардыр (2, 3, 4, 5). Әй, Мөхәммәд! Белмәдеңме син, Раббең Ирем кавеменнән булган Гад кавеменә ни кылды? Ул Ирем кавеме шәһәрләрдә үрнәге ясалмаган олуг биналар иясе иде, һәм дә чокырлардагы каты ташларны кисүче Сәмуд кавеменә Раббең ни кылды? Һәм дә күп гаскәр иясе булган Фиргавенгә ни кылды? Ул Фиргавен кавеме шәһәрләрдә азгынлык кылдылар, анда күп бозыклыклар кылдылар, шуннан соң алар өстенә Раббең төрле газап кылды (6, 7, 8, 9, 10, 11, 12, 13, 14). Дөреслектә, синең Раббең, әлбәттә, һәр нәрсәне күзәтүче һәм ирегендә тотучыдыр (15). Инде кайчан кешене Раббесе байлык һәм дәрәҗә белән сынаса, шул вакытта берсә аны хөрмәтләсә, һәм дә дәрәҗә белән нигъмәтләндерсә, ул вакытта кеше әйтер: «Минем Раббем мине хөрмәтләде»,— дип (16). Инде кайсы заман адәмнең Раббесе аны фәкыйрьлек белән бәлаләндерсә, ризыгын киметсә, шул вакытта әйтер: «Ул — минем Раббем, мине хурлады,— дип (17, 18, 19, 20). — Әй, Мәккә кяферләре! Аллаһының хөрмәтләве — байлык белән, хурлавы фәкыйрьлек белән түгел. Сез — Мәккә кяферләре! Ятимнәрне хөрмәтләмисез һәм дә мескеннәрне ризыкландырырга үзегез дә кызыкмыйсыз, башкаларны да кызыктырмыйсыз. Тагы да мирасны бөтенләй ашау белән ашыйсыз, һәм дә малны чын сөю белән сөймисез!» Ягъни мирасны тиешле варисларга бирмисез, малны чын күңелдән сөювегездән фәкыйрьләргә бер дә бирмисез (21, 22, 23, 24)! Бу эшегез — яраксыз эштер. Әгәр Җир чын ярылу белән ярылса, Раббеңнең әмере килеп җитсә, фәрештәләр саф-саф тезелсәләр, һәм дә шул көндә җәһәннәмне китерсә, шул көндә адәм Аллаһының вәгъдәсен уйлап, эшнең төбен белер, әммә ул көндә белү файда бирмәс. Шуларны күргәч кяфер әйтер: «Эх, мин бу соңгы көндә терелүем өчен изге гамәлләр әзерләгән булсам иде!» — дип (25, 26). Инде ул көнне кяферләрне Аллаһы Тәгалә кылган газап кебек газап белән һич кем дә газап кылмас, яки ул көндә Аллаһы Тәгаләнең газабын һичкем дә милекләнмәс, һәм дә Аның кебек һич кем дә кяферләрне богауламас (27, 28, 29, 30). Әй, газабыннан имин булган мөэмин җан! Савап белән разый булып, Раббең каршында ризаланганың хәлдә Раббең тарафына кайт! Шуннан соң: «Әй, колым! Изге колларым арасына рәхим ит тә шулар белән берлектә җәннәтемә кер!» — дип әйтелер.

## «Бәләд» («Шәһәр») сүрәсе

ТУКСАНЫНЧЫ СҮРӘ,
ЕГЕРМЕ АЯТЬ

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ
لَا أُقْسِمُ بِهَٰذَا الْبَلَدِ ۝ وَأَنتَ حِلٌّ بِهَٰذَا الْبَلَدِ ۝
وَوَالِدٍ وَمَا وَلَدَ ۝ لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ فِي
كَبَدٍ ۝ أَيَحْسَبُ أَن لَّن يَقْدِرَ عَلَيْهِ أَحَدٌ ۝ يَقُولُ
أَهْلَكْتُ مَالًا لُّبَدًا ۝ أَيَحْسَبُ أَن لَّمْ يَرَهُ أَحَدٌ ۝
أَلَمْ نَجْعَل لَّهُ عَيْنَيْنِ ۝ وَلِسَانًا وَشَفَتَيْنِ ۝ وَ

وَهَدَيْنَٰهُ ٱلنَّجْدَيْنِ ۝ فَلَا ٱقْتَحَمَ ٱلْعَقَبَةَ ۝ وَمَآ
أَدْرَىٰكَ مَا ٱلْعَقَبَةُ ۝ فَكُّ رَقَبَةٍ ۝ أَوْ إِطْعَٰمٌ فِى
يَوْمٍ ذِى مَسْغَبَةٍ ۝ يَتِيمًا ذَا مَقْرَبَةٍ ۝ أَوْ مِسْكِينًا
ذَا مَتْرَبَةٍ ۝ ثُمَّ كَانَ مِنَ ٱلَّذِينَ ءَامَنُوا۟ وَتَوَاصَوْا۟

بِٱلصَّبْرِ وَتَوَاصَوْا۟ بِٱلْمَرْحَمَةِ ۝ أُو۟لَٰٓئِكَ أَصْحَٰبُ
ٱلْمَيْمَنَةِ ۝ وَٱلَّذِينَ كَفَرُوا۟ بِـَٔايَٰتِنَا هُمْ أَصْحَٰبُ
ٱلْمَشْـَٔمَةِ ۝ عَلَيْهِمْ نَارٌ مُّؤْصَدَةٌۢ ۝

**ТРАНСКРИПЦИЯ**

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Лә укъсиму би-һазәл-бәләди (2). Вә әнтә хиллум-би-һазәл-бәләди (3). Вә валидив вә мә вәләдә (4). Ләкад халәкънаљь-инсанә фи кәбәд (5). Ә йәхсәбу әл-ләй-йакъдира галәйһи әхад (6). Йәкулу әһләкту мәләл-лубәда (7). Ә йәхсәбу әл-ләм йәраһу әхад (8). Ә ләм нәҗгаль-ләһу гайнәйни (9). Вә лисанәв вә шәфәтәйни (10). Вә һәдәйнаһун-нәҗдәйн (11). Фә-ләкътәхамәл-гакабәтә (12). Вә мә әдракә мәлгакабәһ (13). Фәкку ракабәтин (14). Әу итгаму фи йаумин зи мәсгабәтин (15). Йәтимән за мәкърабәтин (16). Әу мискинән за мәтрабәһ (17). Суммә кәнә минәл-ләзинә әмәну вә тәвасав биссабри вә тәвасив бил-мәрхәмәт (18). Уләәикә әсхабул-мәйманәһ (19). Вәлләзинә кәфәру бил-айатина һум әсхабул-мәшьәмәһ (20). Галәйһим нарум-муәсадәһ.*

**СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ**

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Эш кяферләр уйлаганча түгел, ошбу шәһәр белән ант итәмен (2). Син ул шәһәрдә туучысың (3), һәм дә ата вә анаң тудырган кешеләре белән ант итәмен, ягъни, әй, Мөхәммәд! Син тора торган Мәккә шәһәре белән һәм дә атагыз Адәм һәм аның нәселеннән туган синең белән ант итәмен (4). Чыннан да, Без адәмне мәшәкать һәм авырлыкта итеп яраттык, ягъни адәмнәр дөньяда мәшәкать күрүче, дөнья кайгысын тотучы булалар (5). Әллә адәм үзенә һичкемнең көче җитмәс дип уйлыймы (6)? Ул адәм әйтә: «Мин бик күп мал һәлак иттем»,— дип (7). Әллә аның сарыф кылган малын таратканда, һичкем дә күрмәде, дип уйлый микән? Ягъни рәсүлуллага дошманлык итеп, рәсүлулла зарарына күп маллар тыгучы кяферләрнең үзара мактанышуларын бәян итә (8). Без ул адәмгә ике күз (9), бер тел һәм ике ирен бирмәдекме? Күзләре белән күреп, теле белән сөйләп, иреннәре ярдәмендә сүзләрен гүзәл итеп чыгарырга (10), һәм дә Без ул адәмне күз алдында булган изге һәм дә явызлык юлларын күрсәтмәдекме? (11) Инде бу нигъмәтләргә якынлык иясе булган ятимне (12), һәм дә бик фәкыйрь булган мескенне (13), ачлык көнендә ризыкландыру (14), яисә кол азат итүдән гыйбарәт булган нәтиҗәне йөкләп (15). Безнең тарафыбыздан бирелгән (16) нигъмәтләргә шөкер кылмады (17). Шул чакта иман китергән кешеләрдән булды ул, һәм дә бәгъзеләре бәгъзеләренә Аллаһының буйсынуына сабыр итү белән, һәм дә бер-берсенә мәрхәмәтле булу белән васыять итештеләр (18). Мондый сыйфатлы кешеләр — уңлыкияләредер, ягъни эшләре уң һәм бәхетле (19). Инде Безнең аятьләребезгә карышкан кешеләр — шомлыкияләредер (20).

## «Әш-шәмсү» («Кояш») сүрәсе

ТУКСАН БЕРЕНЧЕ СҮРӘ.
УНБИШ АЯТЬ.

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ
وَٱلشَّمْسِ وَضُحَىٰهَا ۝ وَٱلْقَمَرِ إِذَا تَلَىٰهَا ۝ وَٱلنَّهَارِ
إِذَا جَلَّىٰهَا ۝ وَٱلَّيْلِ إِذَا يَغْشَىٰهَا ۝ وَٱلسَّمَآءِ وَمَا

بَنَىٰهَا ۝ وَٱلْأَرْضِ وَمَا طَحَىٰهَا ۝ وَنَفْسٍ وَمَا
سَوَّىٰهَا ۝ فَأَلْهَمَهَا فُجُورَهَا وَتَقْوَىٰهَا ۝ قَدْ أَفْلَحَ
مَن زَكَّىٰهَا ۝ وَقَدْ خَابَ مَن دَسَّىٰهَا ۝ كَذَّبَتْ

ثمود بطغواها ۝ إذ انبعث أشقاها ۝ فقال
لهم رسول الله ناقة الله وسقياها ۝ فكذبوه
فعقروها فدمدم عليهم ربهم بذنبهم
فسواها ۝ ولا يخاف عقباها ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Вәш-шәмси вә дуhаhа (2). Вәл-камәри иза тәләһа (3). Вән-нәһари иза җәлләһа (4). Вәл-ләйли иза йагшәһа (5). Вәс-сәмәэи вә мә бәнәһа (6). Вәл-арди вә мә таһаһа (7). Вә нәфсив-вә мә сәвваһа (8). Фә-әлһәмәһа фә-җурәһа вә тәкъваһа (9). Кад әфләха мән зәккәһа (10). Вә кад хабә мән дәссәһа (11). Кәззәбәт Сәмуду би-тагваһа (12). Изим-бәгасә әшкаһа (13). Фә-калә ләһум расулул-лаһи накатал-лаһи вә сукъйаһа (14). Фә-кәззәбуһу фә-кагаруһа фәдәмдәмә галәйһим раббуһум би-зәмбиһим фә-сәвваһа (15). Вә лә йухафу гукъбаһа.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).

Кояш һәм дә аның яктылыгы белән ант итәмен (2), Ай белән ант итәмен, әгәр ул Ай-Кояшка якын булса (3), һәм дә көн белән ант итәмен, әгәр ул көнне Кояш нурландырса (4), һәм дә төн белән ант итәмен, әгәр ул төн караңгылыгы белән Кояшны капласа (5), тагын Күк белән һәм дә аны яраткан Зат белән ант итәмен (6). Җир белән һәм дә аны җәйгән Зат белән ант итәмен (7), һәм дә җаннар белән, һәм дә аларны тигез итеп яраткан Зат белән ант итәмен (8). Ул җаннарга Аллаһы Тәгалә бозыклыкны һәм дә тәкъвалыкны белдерткән иде (9). Үткәндәге нәрсәләр белән Мин ант итәмен: дөреслектә, җанын гыйлем һәм гамәл белән пакьләгән кеше максатына ирешер (10), кемдер җанын наданлык һәм яманлык белән буяса, ул кеше рисвай булыр (11). Сәмуд кавеме үзләренең азгынлыклары сәбәпле рәсүлләрен ялганга чыгардылар (12). Шул вакытны ялганга чыгардылар, ул вакытта Сәмудның иң яманы урыныннан торып хәзрәти Салихның могҗизасыннан булган төвәне үтерергә теләде (13). Шул вакытта Аллаһының рәсүле булган хәзрәти Салих әйтте: «Әй, бәндәләр! Аллаһының төвәсенә тимәгез, ул төвәнең су нәүбәтенә дә тимәгез, ягъни хайваннарны сугару өчен нәүбәт ясап, нәүбәтләп эчертәләр иде (14). Бу Сәмуд кавеме рәсүлне ялганга чыгардылар, төвәне бугазладылар (15). Шул чакта аларның Раббеләре аларны гөнаһлары сәбәпле газап белән каплады, һәм дә газабын һәрберсенә дә тигез кылды, һәм дә Раббең Сәмудны һәлак итүнең соңыннан курыкмас!

## «Ләйл» («Төн») сүрәсе

ТУКСАН ИКЕНЧЕ СҮРӘ,
ЕГЕРМЕ БЕР АЯТЬ

بسم الله الرحمن الرحيم ۝
والليل إذا يغشى ۝ والنهار إذا تجلى ۝ وما
خلق الذكر والأنثى ۝ إن سعيكم لشتى ۝
فأما من أعطى واتقى ۝ وصدق بالحسنى ۝
فسنيسره لليسرى ۝ وأما من بخل واستغنى ۝
وكذب بالحسنى ۝ فسنيسره للعسرى ۝ وما
يغني عنه ماله إذا تردى ۝ إن علينا للهدى ۝
وإن لنا للآخرة والأولى ۝ فأنذرتكم نارا
تلظى ۝ لا يصلاها إلا الأشقى ۝ الذي كذب
وتولى ۝ وسيجنبها الأتقى ۝ الذي يؤتي ماله
يتزكى ۝ وما لأحد عنده من نعمة تجزى ۝
إلا ابتغاء وجه ربه الأعلى ۝ ولسوف يرضى ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Вәл-ләйли иза йагъша (2). Вән-нәһари иза тәҗәлла (3). Вә мә халәказ-зәкәра вәл-унсә (4). Иннә сәгъйәкум лә-шәттә (5). Фә-әммә мән агъта вәттәка (6). Вә саддака бил-хуснә (7). Фә-сә-нуйәссируһу лил-йусрә (8). Вә әммә мән бәхилә вәс-тагънә (9). Вә кәззәбә бил-хуснә (10). Фә-сә-нуйәссируһу лил-гусра (11). Вә мә йугъни ганһу мәлуһу иза тәраддә (12). Иннә галәйна тукум наран тәләззә (15). Лә йаслә̄һа иллә̄л-әшка (16). Әлләзи кәззәбә вә тәвәллә (17). Вә сә-йуҗән-нәбуһаль-этка (18). Әлләзи йуэти мә ләһу йәтәзәккә (19). Вә мә ли-әхадин гыйньдәһу мин нигъмәтин туҗзә (20). Илләбтигаэә вәҗһи раббиһил-агълә (21). Вә лә-сәуфә йарда.*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Төн белән ант итәмен, әгәр ул төн яктылыкны капласа (2), һәм дә көндез белән ант итәмен, әгәр яктылык ачыкланса (3), һәм дә ир һәм хатынны яраткан зат белән ант итәмен (4), дәреслектә сезнең гамәлләрегез төрледер (5). Инде бирәү Аллаһы Тәгаләнең хакларын биреп, Аллаһы Тәгаләгә карышудан сакланса (6), һәм дә гүзәл булган, «лә иләһә илләл-лаһу» сүзен дөрес итеп тотса, ул кешене җиңел булган юлга күндерербез (7). Әмма бирәү үзеннән чыгарырга тиешле булган хакны чыгаруда саранланса (8), һәм дә дөньясы белән ахирәт савабыннан өлешсез калса (9), гүзәл булган «лә иләһә илләл-лаһу» сүзен ялганга чыгарса (10), ул кешене авырлыкка тартырбыз, ягъни тәмугка (11), тәмугка төшкән заманында уттан аны малы коткармас (12). Безнең үзебездә тугрылык булыр (13). Һәм дә безнең милкебез дә ахирәт һәм дөнья йорты булучыдыр (14). Инде Мин сезне пәйгамбәрне ялганга чыгарып, иманнан йөз чөергән кяферләр генә керә торган, янып торучы ут белән куркытам (15), ягъни тугрылыкны бәян итү — Миннән, Мин аны сезгә бәян итәмен (16). Ахирәт белән дөнья һәр икесе дә Минеке, инде боларны Минем ризалыгым белән генә өстәгез (17). Аллаһыдан куркып (18), саранлыктан пакьланып, фәкыйрьләргә биргән малы бәрабәренә каршы бирелә торган җәза өмете булмас (19). Мәгәр малын фәкыйрьләргә бирүдә Аллаһының ризалыгын эстәб кенә бирер (20). Һәм дә бу кеше киләчәктә үзенең Раббесенең биргән җәзасыннан разый булыр, ягъни фәкыйрьләргә малын биргәндә нияте бары тик Аллаһы ризалыгы булып (21), фәкыйрьләрдән хезмәт йә коллык өмет итмичә, малын тараткан кешеләр, Аллаһының ризасы булган чиксез әҗерләргә ирешерләр.

## «Духа» («Иртә») сүрәсе

ТУКСАН ӨЧЕНЧЕ СҮРӘ,
УНБЕР АЯТЬ

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Вәд-духа (2). Вәл-ләйли иза сәҗа (3). Мә вәддәгакә раббукә вә мә кала (4). Вә ләл-ахирәту хайрул-ләкә минәл-улә (5). Вә лә-сәуфә йугътыйкә раббукә фәтәрда (6). Ә ләм йуҗидкә йәтимән фә-ава (7). Вә вәҗәдәкә даллән фә-һәда (8). Вә вәҗәдәкә гаилән фә-агъна (9). Фә-әммәл-йәтимә фә-лә тәкъһәр (10). Вә әммәс-сәилә фә-лә-тәнһәр (11). Вә әммә би-нигъмәти раббикә фә-хаддис.*

بسم الله الرحمن الرحيم
والضحى ۝ والليل إذا سجى ۝ ما ودعك ربك و
ما قلى ۝ وللآخرة خير لك من الأولى ۝ و
لسوف يعطيك ربك فترضى ۝ ألم يجدك
يتيما فآوى ۝ ووجدك ضالا فهدى ۝
ووجدك عائلا فأغنى ۝ فأما اليتيم فلا
تقهر ۝ وأما السائل فلا تنهر ۝ وأما بنعمة
ربك فحدث ۝

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Кояшның күтәрелгән вакыты белән ант итәмен (2). Һәм дә киһнең карацгыланган вакыты белән ант итәмен (3). Дөреслектә, синең Раббең сине ташламады да, сиңа ачуланмады да[1] (4), әлбәттә, ахирәт дөньядан изгедер (5). Бик тизлектә сиңа Раббең синең сораган нәрсәңне биреп, сине разый кылыр (6). Әй, Мөхәммәд! Синең Раббең ятим хәлеңдә, тәрбиячесез вакытыңда Әбү Талибкә биреп тәрбияләндермәдеме (7)? Синең бернәрсә белмәгән хәлеңдә вәхи белән күп хөкемнәр һәм хикмәтләр белдереп, тугрылыкка күндермәдеме (8)? Сине фәкыйрь хәлеңдә Хәдичәне никяхлатып бай кылмадымы? Инде сине шул хәлләреңнән коткарып, Раббең моннан соң сиңа күп нигъмәтләр бирер (9). Инде, әй, Мөхәммәд! Ятимне рәнҗетмә (10) һәм дә хаҗәт сораучыны тыйма (11). Һәм дә Раббеңнең нигъмәте белән сөйләш! Ягъни ятимнәрне ригая кыл, хаҗәт сораучыларны тыйма, Аллаһының хикмәтләрен өйрәтү һәм ирештерүдә бул!

## «Инширах» («Ачылу») сүрәсе

ТУКСАН ДҮРТЕНЧЕ СҮРӘ.
СИГЕЗ АЯТЬ.

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ
أَلَمْ نَشْرَحْ لَكَ صَدْرَكَ ۝ وَوَضَعْنَا عَنكَ وِزْرَكَ
الَّذِي أَنقَضَ ظَهْرَكَ ۝ وَرَفَعْنَا لَكَ ذِكْرَكَ ۝
فَإِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ۝ إِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا ۝
فَإِذَا فَرَغْتَ فَانصَبْ ۝ وَإِلَىٰ رَبِّكَ فَارْغَبْ ۝

ТРАНСКРИПЦИЯ

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1).*
*Ә ләм нәшрәх ләкә садракә (2). Вә вәдагъна ганкә визракә (3). Әлләзи әнкада зәһракә (4). Вә рәфәгъна ләкә зикрак (5). Фә-иннә мәгаль-гусри йусран (6). Иннә-мәгаль-гусри йусра (7). Фә-иза фәгагтә фансаб (8). Вә илә раббикә фәргаб (9).*

СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Әй, Мөхәммәд! Без синең күкрәгеңне мәгърифәт нуры белән нурландырмадыкмы (2) һәм дә синең өстеңнән (3), Сиңа авырлык бирүче йөкне төшермәдекме (ягъни пәйгамбәрлеккә кадәр булган наданлык күз алдында тотыла) (4)? Һәм дә, әй Мөхәммәд! Синең зикереңне югары күтәрдек, ягъни исемеңне һәр вакытта олуглап зикер итеlә торган кылдык (5). Әй, Мөхәммәд! Һәр эштә дә әүвәл катылык була, соңра рәхәтлек буладыр. Шул сәбәптән дә син әлек кяфирләр тарафыннан уңайсызлыклар күрдең, соңра җиңеп чыгып, алардан өстен булдың (6). Дөреслектә, һәрбер катылык белән берлектә җиңеллек буладыр, монысы дөньяда һәм дә дөньядагы авырлык бәрабәренә ахирәттә тагын бер җиңеллек буладыр (7). Инде син, әй, Мөхәммәд! Кайчан Минем хөкемнәремне ирештерүдән бушансаң, аның шөкеренә Миңа гыйбадәт кыл (8)! Һәм дә Раббеңә генә күңелеңне куй!

[1] Бу сүрәнең бу кадәресе — бер сәбәп белән бер арада вәхи иңү тукталып, хәзрәти Җәбраил иңми торганда рәсүлулланың күңеле тынычсызланганнан соң иңгән, диләр, һәм дә кяфирләр рәсүлулланың һәм башка мөселманнарның фәкыйрь булуларыннан көлгәч, рәсүлулланы юату өчен соңгы аятьләр иңде. Ш. Хәмиди искәрмәсе.

ТУКСАН БИШЕНЧЕ СҮРӘ.
СИГЕЗ АЯТЬ.

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيْمِ ۝
وَالتِّيْنِ وَالزَّيْتُوْنِ ۝ وَطُوْرِ سِيْنِيْنَ ۝ وَ
هٰذَا الْبَلَدِ الْاَمِيْنِ ۝ لَقَدْ خَلَقْنَا الْاِنْسَانَ
فِيْٓ اَحْسَنِ تَقْوِيْمٍ ۝ ثُمَّ رَدَدْنٰهُ اَسْفَلَ
سٰفِلِيْنَ ۝ اِلَّا الَّذِيْنَ اٰمَنُوْا وَعَمِلُوا الصّٰلِحٰتِ
فَلَهُمْ اَجْرٌ غَيْرُ مَمْنُوْنٍ ۝ فَمَا يُكَذِّبُكَ بَعْدُ
بِالدِّيْنِ ۝ اَلَيْسَ اللّٰهُ بِاَحْكَمِ الْحٰكِمِيْنَ ۝

**ТРАНСКРИПЦИЯ**

*Бисмилләһир-рахмәнир-рахим (1). Вәт-тини фәз-зәйтуни (2). Вә тури сининә (3). Вә һазәл-бәләдил-әмин (4). Ләкад халәкъналь-инсанә фи әхсәни тәкъвим (5). Суммә радәднәһу әсфәлә сафилинә (6). Илләл-ләзинә амәну вә гамилус-салихати фә-ләһум әҗрун гайру мәмнун (7). Фә-мә йукәззибукә бәгъду бид-дин (8). Ә ләйсәл-лаһу би-әхкәмил-хакимин (9).*

**СҮРӘНЕҢ ТӘФСИРЕ**

Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ хакына (1).
Тин, ягъни инҗир, зәйтүн агачлары белән ант итәмен (2). Һәм дә җимешле агач иясе булган Тур тавы белән (3), һәм шулай ук тынычлык урыны булган шәһәр (Мәккә) белән ант итәмен (4), дөреслектә, Без адәмне бик гүзәл тормышта яраттык (5). Шуннан соң ул адәмне түбәннәрнең түбәне булган тәмугка төшерербез (6), бары тик иман китереп тә, изге гамәлләр кылган кешене генә аңа төшермәбез[1] (7). Инде, әй, кяфир! Сиңа ни нәрсә Кыямәт көнен ялганга чыгарадыр? Адәмне ратып, соңыннан тагын зәгыйфьлеккә кайтару бәян кылынганнан соң, үлекләрнең терелеп кабердән кубарылуын ялганга чыгарырга, әлбәттә, юл калмый (8). Аллаһы Тәгалә — һәр эшкә хөкем итүчеләрнең иң олугысы. Ул ничек хөкем итсә, эш шул рәвештә булыр.

Әнвәр ХӘЙРИ
*әзерләде.*

*Ахыры бар*

[1] Чөнки мондый кешеләр өчен бер дә киселми торган әҗер булыр, ягъни бер кеше сәламәт вакытында ни кадәр изге гамәл кылса, ул кешенең картлык, йә зәгыйфьлек сәбәпле гамәл кылуга көче җитмәс дәрәҗәгә ирешеп, гаҗиз калса да, һаман сәламәт вакытында кылган гамәлләр кадәр савабы булыр. Моның мисалы — пенсия кебек. Сәламәт вакытларында бер урында хезмәт иткән кешеләр зәгыйфьләнсәләр яки картлык сәбәпле хезмәткә яраксызлансалар, боларга вазифаларны биреп тору гадәте бар. Бу гадәт шәригатьтә дөрес һәм тиеш булуы ошбу аятьтән аңлашыла. Ш. Хәмиди искәрмәсе.

**Китап күзәту**

# ЗАМАНЫБЫЗ ШУНДЫЙ БУЛГАЧ...

Ринат Мөхәммәдиевның күптән түгел дөнья күргән китабына исем биргән «Кенәри — читлек кошы» романында Сания образы бар. Чисталык, пөхтәлек яратучы намуслы хезмәт кешесе, ательеда тегүче булып эшләүче Сания апаның жыйнак бүлмәсендәге читлектә искиткеч нәфис кошлар — кенәриләр яши, алар күңелгә моң салып еш кына сайрап та жибәрәләр. Сания апа үзе зур фажига кичергән: Әфганстандагы сугышта аның улы һәлак булган. Шушы шомлы хәбәрдән соң хәтерен жуйган Сания апа кенәриләренең читлеген ябарга онытып ачык калдыра һәм бәхетсез кошчыклар явыз мәченең корбанына әйләнәләр.

Әсәрдәге беренче карашка искә дә алмаслык бу хәл-вакыйгалар асылда шактый гыйбрәтле, катлаулы кеше язмышларына киная булып күзаллана. Баксаң, читлек кошы кенәриләргә охшаш затлар кешеләр арасында да бар икән. Романдагы әхлаксыз, бозык ирләр үзләренең очраклы сөяркәләрен — чибәр яшь хатыннарны да «кенәриләр» дип, ә үзләрен дөньяны тетрәтеп торучы куәтле хужалар — «арысланнар» дип атап йөртәләр.

«Кенәри — читлек кошы» исемле роман моңа кадәр без укып килгән гадәти әсәрләргә охшамаган. Андагы вакыйгалар да, сурәтләнгән тормыш та — моңача әдипләр каләме тимәгән диярлек үзенчәлекле чынбарлык. Романның геройлары да күнегелгән, гадәти шәхесләр түгел, элегрәк без кире типлар дип атап йөрткән кешеләр.

Тирәнгә төшмичә өстән генә караганда әсәр — кулларында дөнья байлыклары булган ир-атларның, әлеге «арысланнар»ның, яшь матур сылулар — «кенәриләр» белән табигать кочагындагы ябык, яшерен дача, пансионатларда мәхәббәт уены уйнаулары турында мавыктыргыч мажаралы хикәят ул. Романны беренче кат укыганда миңа да шулайрак тоелган иде. Яңадан укыгач, әсәр уйландыра төште. Әйе, мажаралар әсәрдә байтак. Ләкин асылда романның темасы, эчтәлеге, мәгънәсе шактый тирәнрәк, катлаулырак.

Роман — торгынлык дәвере, команда-административ мөнәсәбәтләр хакимлек иткән гаделсезлек чорында кешеләрнең әхлагында, үзара мөнәсәбәтләрендә, эчке дөньясында тамыр жәйгән әхлаксызлык, рухсызлык, бозыклыкның көннән-көн үсә баруы, илдәге башбаштаклык, йөгәнсезлек турында художество осталыгы белән сурәтләнгән шактый күп планлы, тормышчан әсәр. Ул укучыны битараф калдырмый, дулкынландыра, уйландыра. Әсәрдә гәүдәләндерелгән геройлар — һәрберсе кабатланмас язмышы, характеры булган жанлы шәхес. Алар безнең арада бүген дә яшәп яткан гади дә, бер үк вакытта катлаулы да кешеләр.

Әсәрнең үзәгендә — яшь чибәр кыз, соңыннан бердән-бер бала анасы, сылу хатын Асия образы. Мин аны фажигале, трагик образ дип бәһалар идем. Асия — безнең заман үстергән, үзендә аның барлык катлаулы билгеләрен, бөтен капма-каршылыкларын жыйган хатын-кыз язмышының реаль чагылышы, чорыбызның типик бер вәкиле. Үсмер чактан ук үзенең матурлыгын тоеп үскән гаиләдәге бердәнбер кыз баланың язмышы, бер карасаң, әллә ни авырдан да түгел, шул ук вакытта шактый кызганыч та. Гаиләдә Асиягә игътибар бик күп тә булган кебек, ә чынында аңа әллә ни тәрбия эләкми дә. Әнисе — мәктәптә укуукыту бүлеге мөдире — кызының укуы белән генә кызыксына, соңыннан аны, үзенең теләгеннән тыш, медицина институтына укырга керергә мәжбүр итә. Асиянең әтисе дә — елгачы, жәй буе өйдә булмый, кызын тәрбияләү урынына иркәләүдән артмый. Студентка кызның Әстерханга карбыз жыярга баруы, анда бер егеттән алдануы да ышандыра. Үзсүзле Асиянең институтны ташлавы һәм күршедәге Сания апа ярдәмендә шәһәрдәге иң затлы «Йосыф-Зөләйха» дигән тегү ательесына эшкә керүе табигый хәл буларак сурәтләнә.

Әлеге Сания апа ярдәмендә Асиянең авылда үскән тыйнак шофер егет Фидаилгә кияүгә чыгуы, ир бала үстерүе — болар барысы да әсәр героинясы язмышындагы гадәти күренешләр.

Романның хәлиткеч вакыйгалары Асиянең, Уфа аэропортында буран булу сәбәпле, Казанга очып китә алмыйча самолет көткән залда башланып китә. Нәкъ шунда бу матур яшь хатын белән үзен шактый горур, ышанычлы тота торган мәһабәт гәүдәле ир кеше — Арсланның танышуы Асиянең тормышын тамырыннан үзгәртә. Героиняның моннан соңгы кичерешләре шушы «арысланнар» нәселеннән бул-

---

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ. Кенәри — *читлек кошы. Роман, повесть, хикәя. — Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1990, 446 бит.*

ган иргә мөнәсәбәте, мөкиббән китеп аңа гашыйк булуы белән бәйләнгән. Фидаилга яратмыйча кияүгә барган Асиянең мәхәббәт мажараларында шактый тәжрибәле Арсланга чын-чыннан табынып яшәве, аның белән бергә яңа гаилә корып бәхетле булачагына өметләнүе, якты хыялларга бирелүе романда истә калырлык күренеш һәм детальләрдә чагылдырылган.

Әсәрдә сурәтләнгән мәхәббәт мажаралары үзе бер гыйбрәтле детектив булырлык. Асия эшләгән тегү ательесына Арсланның хатыны һәм кызы, алар артыннан үзе килеп чыгуы героиня язмышына жил-давыл булып бәреп керә. «Арсланнар» һәм «кенәриләр» эпопеясы шуннан башлана да инде.

Каядыр Аккош күле буендагы тын нарат урманы кочагында төзелеп яткан профилакторий бинасы, аның янындагы күл, мунча-сауна — Арслан белән кунакка килгән Асияне таң калдыру, аның башын әйләндерү дә табигый хәл буларак кабул ителә. Бирелдәге «арысланнар» белән «кенәриләрнең» «мәхәббәт ярымутравы» күренешләрен автор тәфсилләп, жанлы күренешләрдә тасвирлый.

Шушы табигать кочагында язучы безне романның яңа геройлары — төзелеш оешмасы житәкчесе Лев Белялович, гастроном директоры Капкаев кебек «арысланнар» һәм аларның сөяркә «кенәриләре» Гуля-Гөлсинә һәм Асиянең мәктәптәге классташы, хәзер билгеле профессор хатыны Юля белән таныштыра. Аларның һәркайсының үз йөзе, характеры бар.

Романдагы бу персонажлар — торгынлык дәверенең чын «геройлары»: аларның кулында дөнья байлыгы, алар һәммәсе дә — кирәкле кешеләр. Шәһәр аръягында шашлык кыздырып, шампан шәрабына коенып тәтәй кыз-хатыннар белән күңел ачу — әлеге «арысланнарның» төп шөгыле булуны автор тирән ирония һәм сатира ярдәмендә сурәтли.

Әсәрдә бик дус, бер-берсенә тугрылыклы булып күренгән бу төркем эчендә көнләшү, яшерен дошманлык, мәкер хөкем сөрүе дә оста ачыла. Аз-маз гына кытыршылыклар, кыенлыклар килеп чыкканда да «аерылмас дуслар» бер-берсен чокырга этәрергә, юкка чыгарырга торалар.

Ринат Мөхәммәдиев хәл-вакыйгаларны эзлекле сурәтләү аша бәхетсез Асиянең чын мәхәббәт хакындагы хыяллары чәлпәрәмә килүне күз алдына бастыра. Аның база хужасы Арслан «сөеклесе» икәнен белгәч тә эш таләп итмиләр, аны серле «профсоюз киңәшмәләренә» чакырып алалар. Ә тышта «кенәрине» дачага алып китә торган машина көтү — менә шул «яшь белү» билгесе.

Асиядән аермалы буларак, Арслан күңелендә исә бернинди хис тә, мәхәббәт тә юк, Асия аның өчен — чираттагы курчак кына. Арсланны сагынып аның эш урынына килгән хатынны салкын каршылавы, телефон аша да «кенәри» белән сөйләшергә теләмәве — тәкәббер «арысланны» характерлый торган сыйфатларга ишарә. Арсланның үзен генә яратучы, яман кеше, хыянәтче булуын әдип романның соңгы битләрендә бөтен ямьсезлегендә ачып сала: дачадан ике кешелек көймәгә төялеп качып китеп барганда Асия егылып суга төшкәч, Арслан аңа кул да бирми, ташлап китә. Димәк, «дөнья хужаларының» кешелеклелеге, әхлагы шундый.

Романдагы бүтән ир-атлар да күңелдә жылылык уятмый. Лев Белялович дигәне «кенәри»ләрен алыштырып тора. Капкаев бер үк мәгънәсез жырны кабатлый, куркак, саран зат.

Истә калырлык образлардан халык дошманы дип «фаш ителгән» язучы-галим Гыйрфановның улы Гыйлем һәм оныгы Жантимерне күрсәтергә кирәк. Бу нәселнең язмышы фажигале: язучыны утыз жиденче елны атканнар, ә Гыйлем үзе гомерен эт атучы булып үткәргән. Жантимернең хәле аеруча кызганыч: ул, врач булса да, наркоманга әйләнгән, әлеге «Мәхәббәт ярымутравындагы» дачаны этләр белән саклап торучы мескен бәндә.

Романның «антигеройларына» язучы намуслы хезмәт кешеләре Сания апа белән гади авыл егете — шофер Фидаилны каршы куйган. Үзенең сөекле хатыны Асиянең хыянәтен күрү — Фидаил өчен чын трагедия. Шуңа карамастан, соңгы исәптә Фидаилнең Арслан ташлап калдырганнан соң күлгә батып баручы Асияне үлемнән коткаруы — үзе зур батырлык, әхлаклылык күренеше.

Романның теле, стиле үзенчәлекле. Халык сөйләү теленең бетмәс-төкәнмәс байлыгына, образлы нечкәлегенә таянып эш итә автор. Шуңа да китап бер тын белән укыла.

Замандашларның кабатланмас язмышлары роман укучыларны да уйландыра, яшәү мәгънәсе, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, әхлак кагыйдәләре турында тәплерәк, тирәнрәк фикер йөртергә чакыра. Әсәр безнең заманда шактый киң таралган алдау, урлашу, күз буяу, дәүләт милкен талау хәлләренә укучының игътибарын юнәлтеп, әһәмиятле эш эшли. Ул кешеләрне гаделлеккә, уяулыкка өнди.

Гомумән, Ринат Мөхәммәдиев әсәрләре дәверебезнең үткер, четерекле, актуаль мәсьәләләрен күтәрүләре белән игътибарны жәлеп итә.

Язучының яңа китабына кергән «Ак кыялар турында хыял» исемле моңсу повесть — үзенә бертөрле романтик алым, үзгә бер нәзакатлелек, нечкәлек белән аерылып торган әсәр. Ул да без укырга гадәтләнгән әсәрләрдән нык аерыла, андагы гажәп сөйкемле йорт хайваны — елкылдап торган зәңгәрсу тунлы кәжә бәтиеннән гыйбрәтле тәкәгә әйләнгән Микәй образы безне сокландыра. Шушы ягымлы образ баланың күзаллавы, дөньяга карашы аша да, матур кәжә Микәйнең үзенең «кичерешләрен» сурәтләү ярдәмендә дә тудырылган. Тылсымлы жан иясе Микәйнең аңында аны алга, югарылыкка чакырып ерактагы иркен ил — ак кыялар турында канатлы хыял яши. Менә ул чиксез сөйкемле, мәһабәт хайванның үзенчә дөньяны тоюы:

«Кинәт, әллә нидән генә аякларына көч, гәүдәсенә дәрт, нәни мөгезләренә гайрәт килә башлавын тойды ул. Бер урында тик кенә басып тора алмыйча, алгы аяклары белән түбәдәге карны тырнарга кереште. Күзләре очкынланды, иңбашларына пар канатлар чыккандай хис итте ул кинәт үзен. Менә хәзер

шушы лапас түбәсеннән кушаяклап этенеп китсә, аның иңбашында канатлар җилпенә башлар, һәм күз ачып йомганчы ул урман аръягындагы теге ак юлларга барып житәр».

Сөйкемле кәҗә Микәй язмышы турындагы хикәя авыл балаларының шөгыль-хәрәкәтләре һәм өлкәннәрнең тормыш-көнкүрешенә бәйләнгән хәл-вакыйгалар белән янәшә куелып тасвирлана. Нурлы Алан дигән авылга күрше авылдан Айсылу исемле бик чибәр килен төшүе, аның эшчән, басынкы табигатьле Миңлегали белән тату гына яши башлавы әсәрдәге тормышның ямен раслаучы якты җирлек булып күз алдына баса. Авылның кечкенә хуҗалары — нәни Азат, Миңлегаяз, Вакыйфларның үз дөньясы да игътибарны тарта. Балаларның яраткан дусы булып киткән Микәйнең дә үсүе, чынытуы, үзенчә батырлыклар күрсәтүе мавыктыргыч итеп гәүдәләндерелгән.

Болытсыз балачак хыяллары, сөйкемле хайван Микәйнең маҗаралы тормышы яктысында язучы үзенең лирик повестенда бик җитди, глобаль проблема күтәрә. Ул — халык арасында ныклап таралып өлгергән яман гадәт — эчкечелек мәсьәләсе. Әсәр башындагы туйда күтәрелгән «гөнаһсыз» стаканнар торабара, сиздермичә генә, уңган колхозчы Миңлегалинең чиренә әверелә, шул аркада чибәр килен Айсылу азак чиктә ирен, гаиләсен ташлап үз авылына кайтып китәргә мәҗбүр була. Болар йөрәк әрнеткеч күренешләр аша тасвир ителә.

Әсәрдә сурәтләнгән бу фаҗига Микәйнең дә һәлакәтенә китерә. Шаярып кына тәмәке чәйнәргә өйрәнгәннән һәм ындыр табагында эчкечеләр аракы белән сыйлаганнан соң Микәйнең трагик үлеме — кешеләргә искәртү ул.

Повестьның нәни герое Азатның уйланулары беркемне дә тыныч калдырмаслык:

«Микәйнең бөтен язмышы күз алдыннан узды. Чана башындагы толып астыннан әле генә көмеш нурлар сирпеп башын калкыткан бер нарасый иде ич ул. Ә хәзер әнә — чокыр төбендә... Аның һавада эленеп калган зур мөгезләре сорау билгеләре булып тоелды малайга. Эре-эре сорау билгеләре...»

Ринат Мөхәммәдиев үзенең әсәрләрендә катлаулы тормыш каршылыкларын чишәргә, әхлакның шактый четерекле проблемаларын күтәрергә омтыла. Югарыда без карап үткән ике әсәр янына китапка автор шундый ук мөһим темага багышланган тагын бер әсәр өстәгән. Ул — «Урман карачкысы» дигән хикәя.

Урман каравылчысы Нурфаязның саф күңелле, эчкерсез, беркатлы кеше булуы аның һәрбер хәрәкәтеннән, уй-фикер йөртүеннән сизелеп тора. Ул — үзе өчен түгел, ә кешеләр өчен яшәүче шәхес. Урманда үзе үстергән меңләгән чыршыларны кешеләргә яңа ел бүләге итеп кисеп биргән Нурфаязның үзенә дип тәгаенләнгән чыршыны, кызганып, кисми калдыруы ук герой характерының үзенчәлеген ача торган бер штрих. Ә урман сакчысының боланнарны, пошыйларны ихлас яратуы, аларны саклавы — шулай ук саф күңелле кешенең асыл сыйфаты. Яңа ел алды кичендә явыз адәмнәрнең иң матур пошыйларның берсен үтерүе, аңа ярдәмгә ташланган Нурфаязны каты яралавы, геройның шуннан соң булган кичерешләре хикәянең сюжет юнәлешен, аның эчтәлеген билгели. Ярадан байтак кан югалткан Нурфаязны врачка алып китәргә дип килгән ветврач егет Марсель белән сөйләшүләрендә дә ниндидер әйтеп бетерелмәгәнлелек, серлелек бар. Эчкерсез геройның врачка барырга теләмәве дә аның кешеләргә яхшы мөнәсәбәттә булуына кайтып кала: Нурфаяз хәтта үзен авыр җәрәхәтләгән адәмнәрнең дә хөкем алдына басуларын теләми икән. Үзен шаярып «урман карачкысы» дип атаган гаять намуслы, тормышны, табигатьне, кешеләрне эчкерсез яратучы кеше генә шундый киң күңелле була ала икәненә ышандыра безне язучы.

Бер китапта өч жанрдагы өч әсәр — роман, повесть, хикәя. Алар, минемчә, ниндидер эчке юнәлешләре белән бер-берсенә тыгыз бәйләнгәннәр, бер-берсен тулыландыралар.

Бу китап Ринат Мөхәммәдиевның тормыш үзәгендә булуы, заман сулышын яхшы тоюы, җәмгыять алдында торган үткен, мөһим мәсьәләләрне тормышчан образлар, җанлы характерлар аша оста чагылдыруы хакында сөйли. Бу юлда әдипне илһамлы яңа эзләнүләр, бәхетле ачышлар һәм куанычлы табышлар көткәнenә шикләнмәскә мөмкин.

Гыйлемдар **РАМАЗАНОВ**.
Уфа.

# КҮРШЕ ТАВЫГЫ... КӨЛӘ!

„Көлү — көлкеле эш булса да, уен эш түгел. Шагыйрьнең табигый сәләте белән бәйле булса да, шәхси-хосусый эш кенә түгел. Ул халыкның рухи дөньясы, җәмгыятьнең үсеше белән бәйле күренеш»,— дип язган Нил Юзиев үзенең «Шигърият дөньясы» исемле хезмәтендә (1981 ел). Әйе, сатираның җәмгыятьтәге үзгәрешләр белән турыдан-туры бәйле булуы беркемгә дә сер түгел. Көлке жанрлары узган «баганалы» һәм «тар» сукмаклы юлларга күз төшерсәк тә, без аның төрле тарихи шартлар, илдәге төрле иҗтимагый-сәяси хәл җирлегендә төрлечә тормышка ашырылганын күрербез.

Сугыштан соңгы әдәбиятта көлке әсәрләр туа торса да, ирекле фикер дошманы бюрократлык патшалык иткән шартларда мондый әсәрләргә дөнья күрү, матбугатка чыгу өчен бик күп киртәләр куелды. Ягъни алар шул чор таләбенә «җавап бирергә» мәҗбүр булды. Бәлки шуңа да көлке әсәрләр җыентыгы чыгу — сирәк күренештер. Бу бигрәк тә шигъри сатирага кагыла.

Сиксәненче елларның икенче яртысы — милли поэтик сатира үсешендә яңа битне ачып җибәрде. 1988 елда Г. Афзал һәм Г. Рәхимнең көлке әсәрләре дөнья күрде. Узган ел шигъри сатирага тагын бер күркәм китап өстәлде. Ул — Ләбиб Леронның «Күрше тавыгы» исемле «эпиграммалар, пародияләр һәм башкалар» җыентыгы.

Л. Леронның көлке шигырьләре белән укучы көндәлек матбугат аша таныш иде. Китапка кергән пародияләрнең байтагы сиксәненче еллар дәвамында «Чаян» журналында дөнья күрде. 1990 елгы «Идел» журналында да шагыйрьнең бер төркем көлке әсәрләре чыкты. Һәм, ниһаять, «Күрше тавыгы» боларның барысын да бергә төркәгән. Алгарак китеп, шуны әйтәсе килә: җыентык шактый бай һәм төрле, хәтта каршылыклы да. Монда эпиграммалар, пародияләр генә түгел, сатирик шигырьләрнең төрле формалары (җыр, бәет, мини-шигырь, акрошигырь, диалог, «рифмалар»), проза белән шигъри форманың синтезын тәшкил иткән пародрама, чәчмә белән язылган хикәя, инсценировка, шулай ук нинди дә булса жанр кысаларына куып кертүе кыен башка төрләр дә бар.

Җыентыкның иң мөһим өлешен эпиграмма алып тора. Милли сатираның аксакаллары Г. Тукай, Ш. Бабич, М. Гафурилар нигез салган бу жанрга Л. Лерон заман рухы өрә. Каләмдәшләренә бер мөлаем елмаеп, бер усал караш ташлап, әрләшеп, гапләшеп, шатланып, шагыйрь бүгенге әдәбиятның иң авыр мәсьәләләрен кузгата. Каләмдәшләренең кимчелекле якларына төрттергәндә дә, аларның сүз белән ясалган карикатураларын иҗат иткәндә дә Л. Лерон саклык белән эш итә, тупаслык, дорфалыктан качып, каршы кую, үткен чагыштыруларны эшкә уңышлы җигә. Тапкыр язу ысулы белән коралланган сатирик еш кына фикерне әйтеп бетермәү, уй йому, ишарәләү, читләтеп әйтү белән чикләнә, укучыга хыялланырга, хыялын эшкә җигәргә урын калдыра.

Төрле композицион формаларны куллануның эпиграммада зур роль уйнавына галимнәр һәрвакыт игътибар итеп торалар. Л. Лерон эпиграммаларында бу әмәл әсәрнең халыкчанлыгын, камил яңгырашын тәэмин иткән. Халык такмагы формасына нигезләнгән «М. Хуҗинга», мәкальдән этәреш алган, дөресрәге, халык акылы җимешен «эшкә җиккән» «М. Маликовага», «Г. Зәйнашевага», Муса Җәлил шигыренә тәкълид итү үрнәге булган «Ф. Миңнуллинга» эпиграммалары уңай бәягә лаек.

Аның бу төр әсәрләренә тагын бер үзенчәлек хас. Кечкенә әсәрдә ул адресатның исемен атауны да тормышка ашыра, аны төрлечә үзгәртеп, кыскартып шигъри тукымага үрә.

*Кыяфәтең — Белинский,*
*Мансурский — язганың...*
*«Бездә шигырь юк»,— дип түгел,*
*«Тәнкыйть юк»,— дип яз тагын,*

— ди ул, тәнкыйтьче Мансур Вәлиевкә шелтә белдереп.

«Лаконизм, кыскалык һәм ачыклык, аз сүзлелек һәм төгәллекне» эпиграмма өчен зарур сыйфатлардан саный Ү. Гыймадиев («Сатира теориясе мәсьәләләре», Уфа, 1984). Л. Леронның уңышлы эпиграммаларында да шушы сыйфатлар ачык чагыла. Тагын шунысы мөһим: шагыйрь язучыга заман күзлегеннән карый, аның җәмгыятькә, табигатькә мөнәсәбәтен чагылдыра, глобаль проблемаларга кагыла.

*Нефть, факелларны мактап*
*Язуыңны ташладың...*
*Әллә шуңа үч итепме*
*Җир тетри башлады?!*

— ди автор Г. Ахуновка багышланган

дуртьюллыгында. Шулай итеп, тар гына мәйданда шагыйрь каләмдәшләренең иҗади портретын да, әсәрләрендәге аерым кимчелекләрне дә, дөньяга карашын да сыйдыра ала.

Эпиграмма тышкы көлүгә, елмаеп аркадан сыйпауга корылган әсәр генә була алмый. Ул борын-борыннан ук көчле тәнкыйть, көрәш коралы булып килгән. Л. Лерон бу традицияне сакларга тырыша. Шулай да аның бирише эпиграммалары көлке дә уята, уйландыра да алмый. Рифмалары да тартәгә тибеп тора. Үрнәк дисезме? Менә Илдар Юзеевка багышланган эпиграммасы:

*Поэма арты поэма*
*яза Илдар Юзеев...*
*Кайчан ачарлар икән соң*
*«И. Юзеев исемендәге*
*Поэмалар музее»н?*

Китапның икенче өлешен пародияләр алып тора. Пародия — шагыйрьнең көлү талантын тәгаен чагылдырган һәм аның бик тә яратып эшләгән жанры. Каләмдәшләренә, шигърияткә булган зирәклек, теләсә кемнең язу манерасына стильләшү сәләте, аларның җитешсезлеген, фикри каршылыгын әлектереп алып, күпертү, арттыру, кабарту осталыгы хас Л. Леронга. Шагыйрьнең фикер сөрешендәге кимчелекләрне, мәгънәви төссезлекне, ябышыр-ябышмас фикерне пародияче кирәгенчә ассызыклап укучыга тәкъдим итә. Теге яки бу шигырьнең үзен-үзе гади булмаган, «сирәк экземпляр» итеп күрсәтү ниятен, шигърияткә «мин» культын алып керергә маташуын пародист «Тукай белән очрашу», «Сөер җан» дигән әсәрләрендә калкытып куя:

*Минем кебек, Тукай, син дә бөек,*
*Шуның өчен рәхмәт, җаным! — дидем...*
*Ә ул шулчак:*
*— Мин бит Тукай түгел,*
*Мин бит — Илдус Әхмәтҗанов...*

— диде.

Л. Лерон пародияләре шигырьләрдә артык еш кабатланган тәкъбирләргә, тапталган фикерләргә каршы да («Вакыт җитте», «Канат яңгыры»), поэзиядә яңа сүз әйтү дәрте белән ят терминнарга мөрәҗәгать итүдән көлеп тә («Биошигырь») иҗат ителгән.

*Бу юлларны алдан кем язган соң,*
*Бу юлларны уйлап кем тапкан?..*
*Кем тапса да вакыт бугай инде*
*Бер-берсенә охшаш шигырьләрне*
*Теркәп куюю берәр китапка!*

— ди шагыйрь «Вакыт җитте» әсәрендә Р. Низамиев һәм Г. Латыйп шигырьләренә ишарәләп.

Л. Лерон каләмдәшләреннән талант һәм илһам таләп итә. Аның пародияләре, әдәби максаттан тыш, бүгенге көнне борчуга салган башка проблемаларга да кагыла. Мәсәлән, Ш. Галиев шигырьләренә язган «Һай, конфет», «Шикәр» әсәрләрендә ул илдәге иктисадый кризиска ишарәли.

Мәгълүм булуынча, безнең күпчелек шагыйрьләр, хәтта Э. Фәйзи, З. Мансур, З. Нури, Г. Рәхим кебек бу жанрның осталары да, күбрәк вакытларын тәнкыйтьчеләр белән бил алышуга, шәхси үпкәләрен әйтеп калуга багышлыйлар. Л. Лерон язмаларында бу нәрсә сизелми диярлек. Шулай да китапның иң ахырында Т. Галиуллинның берәүне дә рәнҗетмәскә, үпкәләтмәскә тырышып, санап чыгу юлына басуына төрттереп ала ул. Озын исемлек укыганда «ә юморы кая бу өзекнең?» — дип уйлап утыру гына пародиячение бик ук уңышы турында сөйләми.

Җыентыкның «һәм башкалар» дигән бүлегендә «Суда йөзаласыңмы?», «Абайлап түгел — айлап», «Кул болгадым поездларга...» исемле хәзерге поэзиянең җитди мәсьәләләрен эченә алган, жанр ягыннан милли әдәбият өчен яңарак әсәрләр урнашкан. Шигъри әсәрләрдәге бер үк фикер тирәсендә әйләнү, уй торгынлыгыннан ычкынып китә алмау күренешен автор дистәләрчә мисалларда раслый. Охшаш шигърн юлларны ул ЭВМ дәрәҗәсендә тәгәл тезеп китә. Монда аның замандашлары тарафыннан иҗат ителгән меңнәрчә шигырь юлларын «эшкәртеп» чыгу сәләте шатландыра.

Л. Леронның шушы китаптагы «Телефон», «Телсез шаһит», «Хәерле кич» кебек әсәрләре дә чорыбызның сатирик прозасына мәгълүм өлеш кертә. «Тәгәри китте җөмләгем», «Дип әйтте ди берәү...» бәйләмендәге үткен фикергә корылган җөмләләр афоризм дәрәҗәсендә көчле яңгырый. Шулай ук Тукайлар традициясенең матур үрнәге булган «Игълан тактасында ни булмас...» дигән баш астындагы кечкенә әсәрләрнең дә нигезендә тирән комизм ярылып ята.

Китап азагындагы шигъри әсәрләргә килсәк, төрле күренекле шәхесләрне үзәккә алган юмористик шигырьләр, язучылар тормышын «рифмалаган» юллар белән очрашабыз. Хәер, соңгыларын барлык укучылар да кабул итеп бетермәскә дә мөмкин. Мәсәлән:

*Канатлы вә тышаулы ат*
*вәт дулаган —*
*Илле яшь тулганын белгәч Батуллага!*

яки:

*Очып төшкәч йомшак креслодан,*
*Яшеренгән, имеш, крысадай,*

— кебек юлларда ни әйтергә теләгәнен шагыйрь үзе генә аңлый булыр... «Яшерен фикер хисси тәэсирне көчәйтә», — диләр беренче тапкыр язу ысулын өйрәнүчеләр. Ләкин фикерне укучы тапмаслык еракка яшерү дә уңышка алып килми бит. «Бюрократ», «Көлке» кебек дуртьюллыкларга да көлке әсәре өнәмәгән фикер буталчыклыгы хас.

Ләкин китапта бик тә үзенчәлекле «Вакытсыз вафат булган шешә бәете», «Сиңа әйтәм, карале...» кебек шигырьләр дә күп. Шуңа күрә укучы җыентыктан, һичшиксез, канәгать калачак.

**Ләйсән КӘШФИЕВА,**
Казан дәүләт университеты аспиранты.

## Мирфатыйх ЗӘКИЕВ

# ХАЛКЫБЫЗ ТУРЫНДА ТУЛЫ БЕЛЕМ

(ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ)

Г**омуми мәгълүмат.** Теге яки бу милләтнең һәрьяклап тулы энциклопедиясен төзи башлау, төзү барышы, бигрәк тә аны киң катлам укучыларга җиткерү халыкның алга таба үсешендә зур бер сикерешне тәшкил итә. Моны без беренче француз энциклопедиясе мисалында да бик ачык күрәбез. Мәгълүм булганча, 1751 — 1780 елларда Д. Дидро җитәкчелегендәге энциклопедиячеләр коллективы 18 томлык (төрле өстәмә һәм белешмә китаплары белән бергә 35 томлык) француз энциклопедиясен эшләп чыгара. Һәм бөтен дөнья таныганча, «Энциклопедия яки фән, сәнгать һәм һөнәрчелекнең аңлатмалы сүзлеге» дип аталган бу фундаменталь хезмәт французларның үзаңын үстерү эшен башкара. Теге яки бу халыкның энциклопедиясен төзү —ул бер үк вакытта шул халыкның матди һәм мәдәни тарихына караган уйдырмаларга каршы көрәш тә, ул халыкның үзаңы ныгуын, киләчәк үрләрен билгеләү омтылышы да булырга тиеш.

Дөньякүләм танылган «Британия энциклопедиясе» дә шундый ук тарихи рольне уйный. 1768 елда чыга башлаган бу күптомлык тора-бара җир шарындагы иң зур акыл ияләренең гомуми хезмәтенә әйләнә. Һәр басмасы киңәйтелеп, ул чынлыкта Британия-Америка энциклопедиясе дип әйтерлек дәрәҗәгә үсеп җитә.

Энциклопедиягә тартым аңлатмалы сүзлекләр төзү Россиядә дә күптән башлана, ләкин аларның энциклопедиягә инде шактый якынайганы танылган тарихчы В. Н. Татищевның 1793 елда басылган «Лексикон Российской исторической, географической, политической и гражданской» дигән хезмәте була. XIX йөзнең 20 нче елларында күптомлык рус энциклопедик сүзлеген төзү эше реаль юлга салына. Уйланылган 40—45 томның өч томы хәтта чыгып та өлгерә. Ләкин аны төзүчеләрнең күбесе декабристлар булганлыктан, алар белән бергә бу энциклопедик сүзлекнең инде дөнья күргән өч томы да юкка чыгарыла. 1835 — 41 еллар арасында А. А. Плюшар тарафыннан оештырылган «Энциклопедический лексикон»ның томнары басыла. Шуннан соң без дөньякүләм галимнәр тарафыннан эшләнгән атаклы Ф. А. Брокгауз һәм И. А. Ефрон энциклопедиясен һәм атаклы бертуганнар А. һәм И. Гранат энциклопедик сүзлеген соклану хисләре белән искә төшерәбез.

Төрки халыкларның чын мәгънәсендә универсаль энциклопедиясе XI йөзнең 60 — 70 нче елларында Мәхмүт Кашгарлы тарафыннан төзелә. 1070 — 1073 елларда ул кульязма энциклопедия хәленә китереп язылa һәм аңа «Диваны лөгат әт-төрек» (төрки сүзләр җыелмасы) дигән исем бирелә. Гарәп мәдәнияте тәэсирендә гарәп телендә язылган башка бөек хезмәтләр кебек үк, бу энциклопедия дә, югалып, берничә гасыр буе кулланылыштан чыгып тора. Бары XX йөз башында гына табылып, ул Төркиядә бик зур өч томда басыла. 60 нчы елларда аның үзбәк теленә тәрҗемәсе дөнья күрә. Хәзер инде Мәхмүт Кашгарлының бу гомумтөрки энциклопедиясе үзбәк галимнәре тарафыннан русчага тәрҗемә ителде, тиздән ул басылып та чыгар дип өметләнергә кирәк.

Мәхмүт Кашгарлыдан соң төрки халыкларның тулы энциклопедиясе дип әйтерлек хезмәт язучылар булмый. Соңыннан бу төр хезмәт төзүгә төрки телле халыклар арасын-

---

Мирфатыйх ЗӘКИЕВ (1928) — *телче галим, егермедән артык китап авторы, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе. Тел, әдәбият һәм тарих институты (ТӘҺТИ) директоры. Казанда яши.*

нан иң элек үзенең тулы суверен дәүләте булган төрекләр генә керешә алалар. 1968 нче елдан башлап бик интенсив рәвештә 80 шәр, 100 әр басма табактан тора торган күптомлыкларын «Төрек энциклопедиясе» (Türk ansiklopedisi) дигән исем астында чыгара да башлыйлар. Бу хезмәт төрки телле халыклар энциклопедияләре арасында иң зурысы һәм уңышлысы дип әйтергә була. Шуңа күрә ул безгә дә бер үрнәк хезмәтен үти.

Совет чорында төрле тармаклар буенча энциклопедик сүзлекләр төзүгә күбрәк игътибар ителә. Шуның белән бергә, гомуми характердагы зур һәм кече совет энциклопедияләрен эшләү дә ышанычлы юлга салына. Бу эшләрне башкару өчен махсус нәшрият төзелә. Ләкин шуны да өстәргә кирәк: «Зур совет энциклопедиясе»нең өченче чыгарылышы күп кенә мәсьәләләр буенча объективлыктан шактый читкә авыша, сталинчыл идеологиянең өстенлекләрен күрсәтергә тырышу үзен тискәре яктан бик нык сиздерә.

Марксизм-ленинизмны милләтләрнең үзара кушылуына китерүче өйрәтмә дип аңлау аркасында, аерым халыкларның милли энциклопедияләрен төзи башлау бик озак тоткарланып тора. Бары 60 нчы елларда гына бу эшкә керешелә, ләкин аны башкару союздаш республика халыкларына гына рөхсәт ителә. Автономияле республика халыкларына яки «тагын да түбәнрәк сортлы» халыкларга андый мөмкинлек тудырылмый. 60 — 70 нче елларда барлык союздаш республикаларда күп томлы энциклопедияләр дөнья күрә.

Союздаш республикаларда бу эш КПСС ҮКнең махсус карарына нигезләнеп башкарыла. Андагы госкомиздатлар һәм фәннәр академияләре каршында 100—120 кешелек энциклопедия институтлары яисә редакцияләре төзелә. Соңыннан алар союздаш республиканың КПСС ҮК каршына күчереләләр һәм шунда энциклопедиянең даими эшли торган Баш редакциясенә әйләнәләр. Алар үз халыкларының күптомлык энциклопедияләрен төзеп чыгаргач, хуҗалык һәм фәннең төрле өлкәләре буенча энциклопедик сүзлекләр төзү өстендә эшли башлыйлар.

Бездә, союздаш республикалар тәҗрибәсеннән чыгып, татар энциклопедиясен төзү өчен махсус институт яки ТӘҺТИ каршында бүлек оештыру омтылышы, партиянең Татарстан өлкә комитеты һәм Министрлар Советы тарафыннан яклanса да, реаль булып чыкмады. Моңа КПСС ҮКның автономияле республикаларда энциклопедия төзү турында махсус карары чыгарылмау һәм шуның аркасында СССР Фәннәр академиясеннән акча бүленмәү төп тоткарлык булды. Ләкин ТӘҺТИ дә татар энциклопедиясен төзүне оештыруга омтылыш бервакытта да тукталып тормады. Әзләгәндә, җае табыла бит. Бу җайны рус энциклопедиясе төзүне оештыру тәҗрибәсе тудырды.

Мәгълүм булганча, «Зур совет энциклопедиясендә башлыча рус тормышы яктыртылган булса да, рус галимнәре бары махсус рус энциклопедиясен төзүне оештырырга булдылар. Моның өчен илдән һәм чит илләрдәге руслардан акча җыюны игълан иттеләр һәм кирәкле оешмаларын төзеп эшкә керештеләр. Бу 50 томга исәпләнгән фундаменталь хезмәтне бастыру Италиядә башкарылырга һәм 2000 елга тәмамланырга да тиеш.

Г. Ибраһим исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында русларның бу тәҗрибәсен кабатларга кирәк дигән фикергә киленде, ләкин аңа акчаны аерым кешеләрдән түгел, ә предприятиеләрдән җыеп алу юлы сайланды. Бу эш Татарстан Министрлар Советында яклау тапты һәм 1989 елның 6 сентябрендә «Татар энциклопедиясе»н (ТЭ) төзү турындагы махсус карарга кул куелды.

Карар нигезендә, банктагы счетка акча күчерергә ризалык биргән оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләре составында энциклопедиянең гыйльми-оештыру советы, төрле тармакта эшли торган галимнәр составында Баш редколлегия булдырылды. Боларның икесендә дә рәис итеп М. Х. Хәсәнов, аның урынбарасы итеп М. З. Зәкиев билгеләнде. ТЭсен төзү урыны итеп ТӘҺТИ беркетелде һәм анда «Татар энциклопедиясе»нең гыйльми үзәге төзелде, эшне конкрет башкару өчен Татар энциклопедиясе бүлеге оештырылды. ТЭ гыйльми үзәге энциклопедия белән турыдан-туры шөгыльләнүче галимнәрдән тора.

Энциклопедиянең махсус счетына Министрлар Советыннан ел саен 100 мең сум, төрле предприятиеләрдән шулай ук күп кенә акча кереп бара, аны туплау даими дәвам итә (Баш редакция коллегиясенең СССР МФО 265016 Жилсоцбанкның Татарстан республикасы идарәсендәге 142630 счеты). Шушы счет хисабына 1990 ел башында ТӘҺТИдә оештырылган махсус төркем төрле энциклопедияләрдән, хезмәтләрдән татарга һәм Татарстанга (Элекке Болгарстан һәм Казан ханлыгына) караган материаллар туплый, төрле җирдәге татарлар, төрле оешмалар белән бәйләнеш оештырып, алардан материаллар ала. ТЭ бүлеге галимнәр, белгечләр һәм киң җәмәгатьчелек ярдәмендә 1990 ел эчендә ТЭ өчен сүзлекчәнең (словникның) беренче вариантын төзеде.

ТЭнә нәрсәләр турында язылыр соң? Бу, билгеле, бик катлаулы мәсьәлә. Аны әле кат-кат өйрәнергә, киң катлау укучылар белән дә, төзүчеләр белән дә уйлашырга ки-

рәк булачак. Баштан ук төп принцип түбәндәгечә билгеләнде. Татар энциклопедиясенә Татарстанга һәм, гомумән, татар халкына (чит илләрдә яшәгәннәрен дә кертеп) теге яки бу мөнәсәбәте булган әйберләр, төшенчәләр, вакыйгалар, оешмалар, объектлар һәм күренекле шәхесләр турында белешмә-мәкаләләр кертеләчәк. Вакыт ягыннан ул иң борынгыдан алып бүгенге көнгә кадәр булган чорны эченә алачак.

Бу концептуаль билгеләмәне конкретлаштыра башлаганчы, тагын бер катлаулы мәсьәләне әйтеп китмичә ярамас. Ул — «татар» сүзенең мәгънәсе белән бәйләнгән нәрсә. Әзерләнә торган хезмәт Идел буе татарлары энциклопедиясе булса да, анда «татар» этнонимының барлык мәгънәләрен дә исәпкә алырга кирәк булачак. Ә ул мәгънә гаҗәеп киң. «Татар» сүзе төрле тарихи чорларда төрле халыкларны атау өчен кулланылган. Көнбатышта хәтта рус җирләрен дә «татар» (яки тартар)» сүзе белән атый торган булганнар. «Татар» сүзенә бәйле булган һәрбер төшенчә энциклопедиядә шулай ук урын алачак. ТЭнең төп объекты — Идел буе татарлары һәм аларны формалаштыруда катнашкан төрки телле кабиләләр һәм халыклар. Ләкин Идел буе татарларына карамаган татарлар турындагы мәгълүматларның безнең тарихка бәйләнеше булганнары шулай ук ТЭндә урын алырга тиешләр.

Энциклопедиягә Идел буе татарларын формалаштыруда катнашкан барлык компонентлар да, мәсәлән, татарның өч диалекты — урта, көнбатыш, көнчыгыш (Себер) шивәләре вәкилләре, Әстерхан татарлары барысы да бөтен тарихы белән керәчәк. СССРдагы һәм чит илләрдәге татар диаспорасы (сибелеп яшәүче милләттәшләребез) шулай ук тулысынча урын алырга тиеш.

Моннан тыш, хәзерге көндә «татар» этнонимы белән аталган Кырым татарлары, Добруджа татарлары, Литва — Польша — Белоруссия татарлары бар. Соңгылары Алтын Урдадан аерылып китеп, телләрен югалтсалар да, этнонимнарын (халык исеме), диннәрен һәм күп кенә гореф-гадәтләрен саклап калганнар. Чыгышлары уртак һәм үзләренең ризалыклары булганлыктан, алар турындагы барлык төр мәгълүматлар да ТЭндә урын алачак.

Румыния күзгалышларына кадәр Добруджа татарларыннан да ризалык алынган иде, киләчәктә бәйләнешләр тергезелеп, алар турында да мәгълүмат туплау башланыр дип уйларга кирәк.

Кырым татарлары белән бәйләнеш шуны күрсәтте: безнең кайбер эшмәкәрләр аларны Идел буе татарлары арасында эретергә омтылыш күрсәтсәләр дә, кырым татарлары бу омтылыштан бик нык сакла免налар, үзләре аерым милләт буларак, үз республикаларын булдырырга, торгызырга тырышалар. Шуңа күрә, алар турындагы мәгълүматларның Идел буе татарларына мөнәсәбәте булганнары гына алыныр дип уйлыйбыз. Шушы ук мөнәсәбәт башка халыклар турындагы мәгълүматларга карата да күрсәтеләчәк.

Хәзер инде бераз җентеклик: энциклопедия мәкаләләрендә нәрсәләр турында язылачак?

1. Татар тарихында булган дәүләт-ханлыклар, аларга турыдан-туры мөнәсәбәте булган башка дәүләтләр. Хәзерге Татарстан дәүләте, аның төрле замандагы составы, министрлыклар, ведомстволар, предприятиеләр, учреждениеләр, профсоюзлар, партияләр, үзешчән оешмалар, коллективлар һ. б. Татарстанда булмасалар да, бу төр оешмаларның Татарстанга һәм татарларга караганнары.

2. Татарстандагы, аннан читтәге татарлар күп төбәкләр (республика, район, өлкә, округ һ. б.), шәһәрләр, авыллар; аларның урнашуы, җире, суы, һавасы үзенчәлекләре, үсемлек һәм хайваннар дөньясы, иҗтимагый-икътисади, сәяси һәм мәдәни тарихлары, хәзерге торышы.

3. Татарстанда булган һәм аннан тыш татарлар белән бәйләнгән күренекле вакыйгалар, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр: баш күтәрүләр, эш ташлаулар, съездлар, конгресслар, походлар, ярминкәләр, сату-алу эшләре һ. б.

4. Татарстандагы халыкларның һәм барлык татарларның этнографик үзенчәлекләре: тел-шивәләре, ашау-эчү, кием әзерләү, хуҗалык итү, гаилә кору, бала тәрбияләү, бәйрәм итү, күңел ачу, дөньяви һәм дини йолаларны, спорт уеннарын әзерләү һәм үткәрү ысуллары һ. б.

5. Татарстанга һәм гомумән, барлык татарларга мөнәсәбәте булган атаклы шәхесләр, эшлеклеләр, герой-каһарманнар, ачыш ясаган билгеле галимнәр — академиклар, член-корреспондентлар, докторлар, язучылар, композиторлар, артистлар, рәссамнәр һәм күренекле фәнни, әдәби китап авторлары; атказанган фән, сәнгать хезмәткәрләре, күп төрле лауреатлар; күренекле дәүләт, партия, профсоюз, җәмәгать эшлеклеләре; әре министрлык, ведомство, предприятие җитәкчеләре; спортчылар, төрле өлкәдә рекорд куйган кешеләр һ. б.

ТЭ төзүнең иң авыр өлеше менә шушы шәхесләр турындагы мәкаләләр булачак. Татарстанда туып формалашкан, эшләгән яисә татар булган шәхесләр турындагы мәка-

ләләрне ТЭнә кертү турында бәхәс юк. Ләкин, мәсәлән, Уильям Шекспир кебек шәхесләр энциклопедиядә булырлармы? Ул бит татар да түгел, Татарстанда тумаган да, татарларга турыдан-туры хезмәт тә итмәгән. Ләкин шулай да мондый шәхесләр ТЭндә, һичшиксез урын алырга тиешләр. Чөнки У. Шекспир әсәрләре күптән инде татарчага тәрҗемә ителгәннәр, татар сәхнәләрендә куелганнар. Димәк, ул үзенең әсәрләре белән татар мәдәниятендә урын ала. У. Шекспир турында ТЭ өчен мәкалә язучы анық татар мәдәниятенә мөнәсәбәтен ассызыклап күрсәтергә тиеш була.

Әйтергә кирәк, әгәр дә без ТЭнә Татарстанда туган, торган, эшләгән яисә татар булган шәхесләрне генә (әйберләрне, төшенчәләрне, вакыйгаларны да шулай ук) кертергә дип карар кылсак, ул энциклопедия аркылы татар халкының дөньяга карашын бик нык тарайтып, бозып күрсәткән булыр идек.

6. Татар мифологиясендә, фольклорында, профессиональ сәнгатендә танылган персонажлар. Башка халыкларның шундый персонажлары да, татар халкында танылган булса, энциклопедиядә урын ала.

7. Татарстанның һәм татар халкының тарих һәм мәдәният һәйкәлләре. Бу һәйкәлләр, гадәттә, икегә бүленеп җыелалар һәм өйрәнеләләр: бер урынга береккән һәйкәлләр һәм бер урынга берекмәгән һәйкәлләр. Бер урынга береккән һәйкәлләрне туплап, өйрәнеп, аларның җыелмаларын чыгару эше илебездә шактый күптән башланды. Бу эш бездә дә бара. Бу җыелма үзе дә Татарстан һәйкәлләре энциклопедиясе булачак, димәк, ул киләчәктә татар энциклопедиясенә кереп кенә утырачак. Шуңа һәйкәлләр җыелмасына кинрәк тукталу артык булмас дип уйлыйм.

Һәйкәлләр җыелмасын төзү турында 1937 елның ноябрендә РСФСР Министрлар Советының махсус карары кабул ителә. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан бу эшне башкарырга ризалык булгач, Татарстан Министрлар Советы да шундый ук карар кабул итә. Татарстан һәйкәлләре җыелмасын чыгару өчен, үзәк редколлегия тарафыннан, безгә 100 басма табаклык бер том вәгъдә ителә.

Бу эшне башкару өчен, ТӘҺТИдә Татарстан Мәдәният министрлыгы акчасына махсус бүлек төзелә. Турысын әйтергә кирәк, җыелма бер ТӘҺТИ галимнәре көче белән генә башкарырлык эш түгел. Шуңа күрә һәйкәлләр җыелмасы бүлеге бу катлаулы һәм җаваплы эшкә республикадагы барлык белгечләрне килешү нигезендә җәлеп итә. Болар арасында тарихчылар да, сәнгатькәрләр дә, архитекторлар да, археологлар да бар.

Татарстан тарих һәм мәдәният һәйкәлләре җыелмасын төзү эшен менә шулай килешү нигезендә һәм барлык белгечләрне дә тартып оештыру татар энциклопедиясе эшен башлап җибәрү өчен үзенә күрә бер үрнәк булды.

Һәйкәлләр җыелмасына, аның Союзда кабул ителгән положениесе буенча, бер урында беркетелгән, күчеп йөрми торган һәйкәлләр кертелә. Болар — тарихи әһәмиятле вакыйгалар, авыллар, кырлар, урманнар, шәһәрләр, биналар, төбәкләр; атаклы шәхесләр белән бәйләнешле урыннар; шуларны мәңгеләштерү өчен куелган һәйкәлләр, истәлекләр, халыкның югары архитектура осталыгын һәм зәвыгын күрсәткән төзелмәләр; уку йортлары, мәчетләр, чиркәүләр, административ, культура һәм торак биналары; күренекле археологик казылмалар; кеше тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйләнешле табигать истәлекләре (тау куышлары, бакыр, күмер, нефть базлары кеше кулы белән утыртылган парклар, урманнар, кеше чыгарган чишмәләр һ. б.). Хәзерге көнгә кадәр сакланмаган һәйкәлләр район яки шәһәр буенча языла торган тарихи очеркларда искә алыналар.

Күчеп йөри торган һәйкәлләр, мәсәлән, атаклы тарихи кулъязма, танылган дастан, халыклашкан музыка әсәре, танылган рәсем, роман, поэма һ. б. үзләренең исеме белән җыелмада алфавит тәртибендә бирелми. Ләкин аларны язып алган авыл, аларның иҗат ителгән урыны, бинасы җыелмада күрсәтелә, шунда инде күчеп йөрерлек һәйкәлләр турында да сүз алып барыла.

Татарстан тарих һәм культура һәйкәлләре җыелмасын иң элек яңадан барлап чыгу, аларның фоторәсемнәрен, сызымнарын алу өчен, Татарстан ССР Министрлар Советы күрсәтүе буенча һәр районда, шәһәрдә махсус комиссияләр төзелде, алар белән җирле Советлар башкарма комитетларының культура бүлекләре җитәкчелек итә, анда район архитекторлары да актив катнаша. Безнең институт һәр районга бер тарихчы галимне беркетте. Алар һәйкәлләрне барлау, яңаларын ачу белән бергә берьюлы җыелмага шул килеш кертерлек итеп, паспорт-мәкаләләр төзиләр. Кабатлап әйтим, Татар энциклопедиясенең бер өлеше булачак һәйкәлләр энциклопедиясе шул рәвешле күмәк көч белән төзелеп ята. Димәк, ТЭнең дә бер өлеше инде эшләнелә диган сүз. Матди һәм рухи культураның бер урынга беркетелмәгән һәйкәлләре безнең энциклопедиядә беренче мәртәбә яктыртылачак, шуңа күрә бу эшне башкару энциклопедия төзүчеләр өстенә төшәчәк.

Күчмә һәйкәлләргә, кыска гына әйткәндә, түбәндәгеләр керә: күренекле мифоло-

гия һәм фольклор әсәрләре; галимнәр, язучылар, шагыйрьләр, рәссамнар, артистлар һәм халык осталарының профессиональ әсәрләре; журналлар, газеталар, атаклы гыйльми, әдәби җыентыклар, альбомнар һ. б.

8. Татарстан халкына һәм татарларга хас булган, яисә алар куллана торган мал-товарлар, ашамлыклар, эчемлекләр, мал ризыклары, акча берәмлекләре һ. б.

9. Тарихи атамалар, гомумән ономастикада сакланган матди һәм рухи мәдәният эзләре, ягъни этнонимнар, топонимнар, ойконимнар, гидронимнар, зоонимнар, бионимнар, космонимнар, теонимнар, мифонимнар, политонимнар (эмблема, герб, гимн исемнәре) һ. б.

Татар энциклопедиясе сүзлекчәсен оештыру, үзен төзү барышында бу әйтелгән объект һәм шәхесләр әле, һичшиксез, тагын да конкретлаштырылыр, бәлки тулыландырылыр да.

**Тагын берничә гомуми мәсьәлә.** Татар энциклопедиясе төзүнең тагын бер бик әһәмиятле ягына игътибарны юнәлтми булмый. «ТЭндә Татарстанга һәм, гомумән, татар халкына кагылган әйберләр, төшенчәләр, вакыйгалар, шәхесләрнең борынгыдан алып хәзергә кадәр булганнары урын ала» дигән гомуми билгеләмәне без киң мәгънәсендә аңларга тиешбез. Шәхесләр турында югарыда әйтелде инде (У. Шекспир мисалында). Әйберләр, төшенчәләрнең дә бары Татарстанда яисә татарлар тарафыннан гына уйлап чыгарылганнарын яки ясалганнарын алсак, энциклопедиядә татар халкының башка халыклар белән бәйләнешен читтә калдырган булыр идек. Татарлар бит бөтен дөньяда танылган фәнни ачышлар, төшенчәләрдән дә, әйберләрдән дә файдаланалар, алар халкыбызның тормышына органик рәвештә килеп керә. Димәк, мондый әйберләр, төшенчәләр, ачышлар да татар халкына билгеле мөнәсәбәттә торалар һәм алар ТЭдә урын алырга тиеш булалар. Ләкин мондый әйберләр, ачышлар һәм төшенчәләрнең чиге шулай ук татарга яки Татарстанга караган критерийлар белән билгеләнгән булырга тиеш. Мәсәлән, Америка Кушма Штатлары Висконсин штатының башкаласы Мадисон шәһәре энциклопедиядә якынча болайрак яктыртылырга тиеш. Башта бу шәһәр турында белешмә бирелә, аннан соң аның татарга булган мөнәсәбәте әйтелә: биредә татар-төрки тарихын, телен, иҗтимагый тормышны өйрәнә торган гыйльми җәмгыять бар; аның конгрессларына татар галимнәре дә бара; бу шәһәрдә татарлар да тора һәм ниһаять бу татарлар турында кыскача мәгълүмат бирелә.

Тагын бер мисал. «Плазма» сүзе татарга турыдан-туры карамый. Ләкин ул татар энциклопедиясендә урын ала. Чөнки, бердән, татарлар өчен бу сүз ят түгел, икенчедән, аның үзенчәлекләрен өйрәнү буенча татар галимнәре дә (акад. Р. З. Сәгъдиев) өлеш кертканнәр. Энциклопедиядә иң элек «плазма»га гомуми аңлатма бирелә, аннан соң аны өйрәнүдә һәм куллануда катнашкан татар яисә Татарстан кешеләре турында языла.

Энциклопедия төзүгә (барлык фәннәр буенча) галимнәрне, журналистларны, язучыларны, һәвәскәрләрне ни кадәр күбрәк тарта алсак, ул эшне башкару вакыты да шул кадәр кыскарачак, сыйфаты да шул дәрәҗәдә күтәреләчәк.

Энциклопедия мәкаләләре рәсемнәр, сызымнар, карталар, фоторәсемнәр белән баетылган булырга тиеш. Шуңа күрә теге яки бу объект яисә шәхес турында язарга алына торган белгечләр мәсьәләнең бу ягына аерым игътибар бирергә тырышачаклар. Фоторәсемнәр төсле булырга тиеш.

Энциклопедия төзүдә катнашырга дәрте һәм мөмкинлеге булган һәрбер шәхесне эшкә чакырабыз. Эш бушка түгел, килешү нигезендә түләүле булачак.

ТЭ төзүгә барлык төбәкләрдә (чит илләрдә дә) яшәгән татарларны тартуны тәртипкә салу өчен, төрле илләрдә һәм шәһәрләрдә Татар энциклопедиясе гыйльми үзәгенең филиалларын оештыру да башланды.

1991 елга кергәндә, Татар энциклопедиясе сүзлекчәсенең (словнигының) беренче варианты төзелеп тикшерелде. Шуның нигезендә иң элек бер томлык «Татар энциклопедик сүзлеге» эшләп чыгарылачак. Аннан соң тагын да тулыландырылган сүзлекчә буенча күп томлык энциклопедия төзү башланачак.

Эш тәртипкә салынгач, Татар энциклопедиясе бүлегенең, ТӘҺТИдән бүленеп чыгып, махсус гыйльми учреждение булып оешуы да күз алдында тотыла.

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ӨЛКӘН ӘДИП БЕЛӘН ОЧРАШУЛАРЫМ

Сәйфи ага Кудашны беренче тапкыр күрүем алтмышынчы еллар башында булды. Мин ул вакытта 1917—32 еллардагы татар әдәби тәнкыйтенең үсеш, формалашуын өйрәнә идем. Аспирант чак. Казанда, Мәскәүдә, Уфада һәм Свердловскида чыккан бөтен татар газета-журналларын өйрәнеп бетергән идем. Әмма мин өйрәнгән ул еллар белән минем ул «бүгенгем» арасында бик катлаулы, авыр фаҗигаләр булып узган, шуларның берсе — Бөек Ватан сугышы. Әдәбият белемендә буыннар, заманалар бәйләнеше өзелгән иде. Мәктәптә укыган елларны безгә, әдәбият дөньясында дүрт галим бар, дип өйрәткәннәр иде. Болар — Мөхәммәт Гайнуллин, Гали Халит, Хәй Хисмәтуллин һәм Хәсән Хәйри. Ә мин актарган газета-журналларда безнең буын ишетмәгән йөзләрчә исем... Кая барырга, кемнән ачыкларга? Шунда миңа әйттеләр: дөньяда иң хәтерле кеше Афзал Шамов. Мин аның белән таныш идем, тиз генә янына йөгердем. Дөрес сөйләгәннәр: Афзал ага аерым шәхесләрне генә түгел, ул шәхесләрнең кайсы газетада, журналда, кайчан нинди мәкаләсе чыкканны берничә карамыйча сөйли дә бирә. Фәнни информациягә ачыккан аспирант башы тула, тула... Очрашуларның берсендә Афзал ага әйтә куйды:

— Сиңа,— диде,— Сәйфи Кудашны күрергә кирәк, иртәгә ул Казанга килә, менә өлкәннәр шуны каршы алырга йөрибез әле...

Икенче көнне Афзал аганың телефоннан хәбәре булу белән «Казан» гостиницасына киттем. Әлбәттә инде куркып, оялып кына. Ул елларда Уфадан язучылар еш килә иде, алар килгәндә вокзаллар, аэропортлар, гостиницалар, заллар шау итә, дер селкенә иде. Гостиница номерының ишеген шакыганда мин шулай күз алдына китердем: өстәл өстендә әнә тәртер урын юк, агай-эне кызган, бәхәс, шау-шу, тәмәке төтене, шигырь уку, мәзәк сөйләү... Шулай булгалый иде, уфалылар бик тере, хәрәкәтчән бит! Әмма ялгышканмын: люкс номерының зур өстәле янында Сәйфи агай утыра, өстәлендә тышлыгы гарәп хәрефләре белән басылган бер журнал, блокнот, берничә каләм. Ялгыз, тынлык. Күрештек, чишенеп килеп утырдым, ул инде минем гозеремне белә иде. Мин блокнотымны чыгардым.

...Ике сәгатькә якын барган бу мөсахәбәдә үземнең булачак диссертациям өчен бик күп материал алдым дип кенә әйтсәм, мин бу очрашуның бәясен бик нык төшергән булыр идем. Юк, алай гына түгел. Бу сөйләшүдә мин интеллигент булу өчен (элек «зыялы» диган сүз бар иде) миңа һәм минем тирәдәге галим-голәмәгә нәрсә җитми икәнен аңлап чыктым. Ихтимал, блокнотыма информация язудан бигрәк, мин шул турыда күбрәк уйлап утырганмындыр. Минем күз алдыма Луначарский, Чичерин, Горький, Фадеев, Мулланур Вахитов, Фатих Әмирхан кебек шәхесләр килде. Аларның берсен дә минем күргәнем юк, әмма китаплардан укып беләм — алар чын мәгънәсендә интеллигент булганнар.

Интеллигентлык — эчке культурага ия булуда. Кеше белән сөйләшә белүдә. Үткәндәге вакыйгаларга тарихилык ягыннан килеп бәя бирә белүдә. Мин бу сыйфатларны якынча белә идем. Әмма Сәйфи ага белән сөйләшкәндә үзем өчен бер яңалык ачтым: интеллигент булу өчен каршыңда утырган кешене тыңлый белү дә бик кирәк икән. Сәйфи ага шул сөйләшүдә миңа Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Хәлим Искәндәрев, Хөсни Ишбулатов, Галә Ходаяров кебек әдәбиятчы-тәнкыйтьчеләр турында дөнья кадәр материал бирде. Кайда нәрсә бар, каян нәрсәне табасы бар, кемгә нинди адрес буенча язарга, нәрсәне ачыкларга — ул миңа гомерем буе эзләнерлек юнәлеш бирде. Шул уңайдан мактаныйм әле: Сәйфи ага күрсәткән юлдан кереп китеп, унбиш-егерме ел эчендә мин әдәбият тарихы буенча шундый материаллар тупладым, шулкадәр баедым ки, хәзер инде аларны эзләп хәтта Башкортстанның үзеннән дә киләләр. Казандагы газета-журналларда эшләүче яшьләр өрзлексез телефоннан чылтыратып торалар — әдәбият тарихына кагылышлы хәлләрне ачыклыйлар. Сәйфи ага мине әнә шулай мәңгелек эзләнү бәхетенә — мәшәкатьле, борчулы бәхет дөньясына юнәлтте...

Икенче, өченче очрашканда без инде — остаз һәм шәкерт — кемгә нәрсә кирәген, кемнең нәрсә бирә алганын яхшы белә идек. Сәйфи ага Казанга ике-өч елга бер тапкыр килә — рәсми шау-шусыз килә иде. Баштарак мин аның нәрсә өчен килгәнен аңламый идем, ахырдан ачыла төште. Ул берниндн максатсыз, кешеләрне сагынганы аркасында гына килә икән. Нинди олы, күркәм сыйфат! Ул көннәрдә әдәбият аксакаллары ду-чат килә: авырулары терелә, кайсыныңдыр «Кудаш килгән» дип больницадан чыкканы да булды. Ул көннәрдә китә мөсахәбәләр... Кечке чәй мәҗлесләре. Иң элек Хәсән Туфан-

га визит. Аннан Нәкый Исәнбәткә, Гомәр Бәшировка. Мин белгәннәре шулар. Г. Бәширов, Х. Туфан, С. Хәким яшәгән «Аккош күле» дачасының җәйге бер көне аеруча хәтердә калган: язучы хатыннары йөгерешә — кемдер гөбәдия пешерә, кемдер токмач кисә, язучылар дача капкасы тирәсендә йөренәләр: ни бар, нәрсә булган?

— Сәйфи ага килә, Сәйфи!

— Кит аннан! Сәйфи Кудаш үземе?

— Үзе инде үзе! Кичә аэропортта каршы алдык, менә бүген аны Союз машинасы белән монда китерәчәкләр.

Менә дача капкасыннан мөлаем чырай белән мәһабәт гәүдәле Сәйфи ага килеп керә. Затлы киемнән. Мин шунда уйлап алдым, язучы — затлы киенергә тиеш. Г. Ибраһимов, Г. Колахметов, Ф. Әмирхан, Г. Газиз шулай шәп йөргәннәр. Менә Г. Бәширов торган йортның киң верандасы, өстәлдә җиләк-җимеш. Сәйфи аганы кая утырту турында ярты секундлык кына бәхәс, менә Хәсән Туфанның балаларча саф шатлануы, Гомәр аганың эчке яшерен горурлыгы (знай наших: Сәйфи ага башта минем йортыма килде!), менә Сибгат Хәкимнең яратып, сокланып Сәйфи аганың алдына минераль су куюы...

Минем яшь чак, таза чак, миңа нәрсә, мин кулга борау белән «открывалка» (татарча әлегә аның исеме юк) алам да, «батырлык»ка әзерләнәм: ничә шешәне фермага кереп сарык буган бүре тизлегендә ачып бирим? Ничә секунд кирәк?

Сүз үзенең нигезенә керде. Истәлекләр китте. Сәйфи аганы яраткан темасына тиз тартып керттеләр: Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич, Сәгыйть Рәмиев, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Мулланур Вахитов... Карале, нинди бай безнең халкыбыз! Никадәр төрле-төрле кешеләр, никадәр язмыш...

Бераздан Аккош урманына чыгып киттек. Минем ул вакыттагы таза беләкләргә эш булмый калды, каһәр. Эчмиләр! Эчмиләр! Шайтаннар... Гел мөсахәбә.

Мәҗлес тәмамланганда игътибар иттем: Сәйфи аганың алдында ат күзе кадәр рюмкага салынган «Рислинг» яртылаш кимегән иде. Хәсән Туфан өстәлдә үзе яраткан «Герцеговина флор» тартмасын онытып калдырган икән...

...Хәсән Туфанның 80 еллык бәйрәменә Сәйфи Кудаш белән Наҗар Нәҗми килә икән, дигән хәбәр Казан халкының йөрәгенә май булып ятты. Театр бинасында халык шыгрым иде. Менә кемнеңдер сизүе белән зал кул чаба башлады, дәүләт, партия хезмәткәрләре һәм өлкәннәр сафында атлап сәхнәгә Сәйфи Кудаш чыкты. Егерменче еллар интеллигенты: кара тройка, ак күлмәк, башта кара бәрхет түбәтәй. Юпитерләр кабынды, телеоператорлар эшкә тотынды. Юпитерларның кеше миенә, күзенә рәхимсез рәвештә тишеп керәсен алдан белгән Сәйфи Кудаш бу юлы кара күзлек кигән иде. Кабартылган печән шикелле үҗәт, көлсу-көмеш чәчлесе—Наҗар Нәҗми. Залның шатлыгына чик-чама юк иде. Наҗар Нәҗми — Казан халкының шулай ук яраткан кунагы, аның «Гомер агышлары» бездә — тәсбих урынында. Очрашуларда, мәҗлесләрдә бездә әлегә Наҗар төсле чын күңелдән көлә белгән бер генә кеше дә юк! Делегация шәп, башкортлар кемгә кемне җибәрәсен беләләр, шайтаннар! Шәп, билләһи! Сәйфи Кудаш үзе килгән! Үзе! Хәсән Туфан көне шул бу, чиста күңелле зур әдипнең туган көне шул бу...

Кичә барышында Сәйфи Кудашка котлау өчен сүз бирделәр. Сүзенең ахырында ул бер шигырь укыды — зал тынсыз калды! Сиксәнне узган шагыйрь кичә-бүген генә шундый да итеп шигырь язган! Ул шигырь кайдадыр басылды да шикелле, әмма андагы иң матур бер мәгънә истә калган: Өфедән Казанга очабыз, ди шагыйрь, Туфан юбилеена очабыз. Аэропортта күп сумкаларын, багажларны үлчиләр, авырлыкларын ведомостька, билетка язалар. Барысын да үлчиләр. Ләкин аэропорт хезмәткәрләре үлчи алмый торган бер нәрсә бар иде бездә. Ул безнең Туфанны яратуыбыз. Менә без, ди шагыйрь, бизмән белән үлчәнми торган шул хисебезне сиңа алып килдек.

Чүмәлә чәчле Наҗар, трибуна янына килеп, Сәйфи аганың артында гел басып торды: Наҗар Нәҗми — сугыш утын кичкән, Ватанны саклаган кеше — белә: сиксәнне узган карт шагыйрьне сакларга кирәк. Трибунада дулкынланып сөйләгәндә кемгә нәрсә булмас! Бари Рәхмәт, Хәким Сәлимҗанов кебек татар халкының асыл уллары дөнья белән сәхнәдә, студиядә аерылышмадылармыни!

Сәйфи Кудаш шунда борынгы ыруг аксакалы кебек акыллы сүзе, мәһабәт гәүдәсе, затлы киеме һәм Казан халкын чиксез яратуы бәрелеп торган зыялы йөзе белән залны алды. Өфедән килеп Казан залын алды. Ә зал Хәсән Туфан дигән олы затны яратучылар белән шыплап тутырылган иде.

...Икенче көнне мин хезмәтем буенча командировкага киттем. Бармый калырга ярамый иде, юлда йөрәк бик сыкрады: мин ул көнне кичкә Хәсән Туфанның өенә чәй мәҗлесенә чакырулы идем. Менә кич җитте, мин барып төшкән шәһәрнең гостиницасында, элек танышкан һәм әле генә танышкан иптәшләр арасында утырам, «открывалка» инде минем кулда түгел, бүлмә шау итә, түшәмнәр бер төшеп бер менеп хәрәкәтләнә сыман. Без — шәп, без — дөньяның кендеге, без булмасак бу җәмгыять нишләр иде... Әңгәмә шулайрак кызды, әмма мин вакыт-вакыт сызланып куйдым: Хәсән Туфан бүлмәсе, өстәлдә чәк-чәк, хуш исле чәй һәм халкыбызның үткәне, культурасы, сәнгате, затлы кешеләре турында гүзәл мөсахәбә: әңгәмәне кара бәрхет түбәтәйле Сәйфи ага Кудаш алып бара... Мин күпме матур фикер ишетми калдым, күпме рухи байлык югалттым.

Бу югалтуны мин беркайчан да, берни белән дә каплый, тутыра алмам инде...

## Ризван Хәмидкә 50 яшь



Драматург Ризван Хәмид (Ризван Мирхәбибулла улы Хәмидуллин) 1941 елның 24 октябрендә Башкортстанның Ярмәкәй районы Усман Ташлы авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, Октябрьск шәһәрендә техник училищеда укый; аяк киемнәре тегү фабрикасында, «Нефтеавтоматика», Уфадагы электр аппаратуралары заводында эшли. 1963 елда Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә, шуннан хәрби хезмәткә алына, нәтиҗәдә, институтны 1971 елда гына тәмамлый. «Чаян» журналында фельетончы, хатлар бүлеге мөдире булып эшли. 1978—79 елларда Мәскәүдәге бер еллык Югары театр курсларында укый, аннары — ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында иҗат яшьләре белән эшләү буенча җаваплы хезмәткәр. 1981—83 елларда исә кабат Мәскәүгә китеп, М. Горький исемендәге әдәбият институты каршындагы ике еллык Югары курсларда укый. 1984—85 елларда Чаллы язучылар бүлегенең җаваплы сәркатибе, 1985—87 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары булып эшли. Бүгенге көндә ул — профессионал язучы.

Р. Хәмид, драматург буларак, җитмешенче еллар азагында танылды. Аның «Синең урыныңа кайттым...» исемле беренче драмасы 1978 елда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт театрында, аннары Әлмәттә, азак русчага тәрҗемә ителеп, берничә рус театрында куела.

«Иске йорт кешеләре» (1979), «Каен җиле» (1982) драмалары Әлмәт дәүләт драма театрында, «Кайтыр идем» драмасы илнең рус, чуваш, кабардин, лак, башкорт театрларында куелды. «Китәм инде» пьесасы «Современная драматургия» альманахында басылды — бу драма шулай ук чуваш, төрекмән, латыш, литва телләренә тәрҗемә ителде. Юбилеен драматург өр-яңа әсәрләр, шул исәптән Казан ханлыгы чорыннан «Хан кызы» драмасын язып каршылый.

Р. Хәмид юмористик хикәяләр һәм балалар өчен кечкенә күләмле сәхнә әсәрләре авторы буларак та билгеле.

1984 елдан аңа Татарстан комсомолының М. Җәлил бүләге, 1991 елда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеме бирелде.

Р. Хәмид — 1981 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлыйлар, аңа сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр.**

### ХАЛКЫБЫЗ БӘЙРӘМЕ

30 августта Татарстан Республикасы шәһәрләрендә, район үзәкләрендә Республика көне уңаеннан бәйрәм тантаналары үткәрелде. Тантаналарның үзәге — Казанның Ирек мәйданы булды. Бирердә иртәдән үк җырлар яңгырап торды, күмәк уеннар, биюләр оештырылды. Дөресрәге, тантаналар алдагы кичтә, ягъни ТССР Югары Советы сессиясе тәмамлангач ук башланган иде. Аларда СССР, РСФСР, ТССР халык депутатлары катнашты. Республикабызның күп кенә шәһәрләреннән милли-азатлык хәрәкәте вәкилләре килгән иде.

Халык алдында ТССР халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова, Бөтенсоюз Татар иҗтимагый үзәге президенты М. Мөлеков, Идел-Урал берлеге рәисе Г. Фәйзрахманов, Иорданиянең Амман университетында укучы Камил хәзрәт, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле артистлары чыгыш ясады.

Бу көнне ТССР Президенты М. Шәймиев тә халык белән очрашты. Ул суверенлык юлыннан бер адым да читкә тайпылмаячагын белдерде.

Шушы ук көнне Сөембикә манарасы янында җомга намазы укылды, азатлыгыбыз өчен һәлак булучылар рухына багышлап дога кылынды.

### ҖӘЛИЛ ҺӘМ АНЫҢ КӨРӘШТӘШЛӘРЕНЕҢ БЕЗГӘ БИЛГЕЛЕ БУЛМАГАН ДӘФТӘРЛӘРЕ

Совет разведкасының 70 еллыгына багышлап, СССР Дәүләт иминлеге комитетының Беренче баш идарәсе түбәндәге хәбәрне бастырып чыгарды: «Кайчакта разведка беренче карашка аның катнашы кирәк булмаган өлкәләрдә дә файда китерә иде. Сугыш ахырында разведчик Н. М. Горшков, Италиядә яшәгәндә, үзенең бәйләнешләре аша татар совет шагыйре Муса Җәлилнең фашист төрмәсендә язган көндәлекләрен кулга төшерде».

Бу уңайдан ТССР Дәүләт иминлеге комитетының җәмәгатьчелек белән бәйләнешләр үзәге башлыгы Равил Кашапов түбәндәгеләрне хәбәр итә:

— Мин Мәскәүдә отставкадагы полковник, совет разведкасының 40—50 елларда Италиядәге резиденты Горшков фатирында булдым. Николай Михайлович һәм аның хатыны безнең якташлар икәнен, Казан авиация институтын тәмамлауларын белеп, бик гаҗәпләндем.

Разведчикның әйтүенчә, 1944 елда, союзниклар Аппенинга килеп төшкәч, ул Римга кайта. Шул елларда совет илчелегенә билгесез бер кеше Муса Җәлилнең көндәлекләрен китереп бирә. Шулай итеп, алар Горшков кулына килеп керә. Аңа, Казанда яшәгән кеше буларак, Җәлил исеме таныш була һәм ул көндәлекләр белән кызыксына башлый: әмма, алар гарәп хәрефләре белән татарча язылганга күрә, бер генә сүзне дә укый алмый. Ул аларны Үзәккә җибәрә.

Без, ПГУга яңадан запрос ясап, М. Җәлил көндәлекләренең 1944 елда Италия резидентурасыннан кайтарылу фактын архив документлары нигезендә раслауларын үтендек. Аннан килгән җавап мине һәм минем хезмәттәшләремне шаккатырды! Аның кыскача эчтәлеге болай: «1946 елда Римдагы резидентура белән язышкан архивлардан күренгәнчә (Горшков әйтүенчә, 1944 елда түгел), 1946 елның 4 январенда, башка күп материаллар белән бергә, Үзәккә 9 куен дәфтәре — Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Баттал, Әхмәт Симаевларның көндәлекләре җибәрелде». Шунда ук: «Илчелеккә бу дәфтәрләрне 1921 елда Гөлҗа-Синьцзян шәһәрендә туган Казыйм Миршан дигән кеше китереп бирде, дәфтәр ияләренең немецларда әсирлектә булып, 1944 елның 7 ноябрьдә Дрезденда атып үтерүләрен әйтте. Кулга алыныр алдыннан алар Миршаннан бу язмаларны илләренә тапшыруын үтенгәннәр. Без аларны укый белмәгәнгә, авторларның кемлеген ачыклый алмадык»,—диелә.

1946 елның 28 январенда бу документлар ТССР Дәүләт иминлеге комитетының беренче идарәсеннән Оборона халык комиссариатының «СМЕРШ» контрразведкасы баш идарәсе начальнигы урынбасары генерал-лейтенант Бабичка тапшырыла.

Болар — Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында яңа мәгълүматлар. Хәзерге көндә бу көндәлекләрне эзләү бара.

### СУВЕРЕНИТЕТ ЯКЛАУГА МОХТАҖ

Тулы бәйсезлекләрен игълан иткән элеккеге союздаш җөмһүриятләр үз кораллы көчләрен төзи башладылар. Әйтик, күршебез РСФСРда, эчке һәм саклану гаскәрләре өстенә, 40 мең кешелек милли гвардия булдырырга карар кылынды.

Бөтенсоюз Татар иҗтимагый үзәге илдәге фетнә көннәрендә республиканың төрле шәһәрләрендә мөстәкыйльлекне яклау максатыннан үзеннән-үзе оеша башлаган халык ополчениесе төркемнәрен бер үзәккә туплау һәм алар белән идарә итү җаваплылыгын үз өстенә алды.

Әлегә Татарстанның кораллы көчләре юк. Эчке эшләр министрлыгы, Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты РСФСРга буйсына. Шунлыктан халык ополчениесен оештыру һәм

аның нигезендә милли гвардия төзү кирәклеге көн үзәгендәге бурыч булып килеп басты.

Ополчениенең баш командующие итеп отставкадагы полковник Р. Сафин билгеләнде. Төркемнәрне якын арада тулы әзерлеккә җиткерү күздә тотыла. Хәзергә ополчение 9 мең кешене берләштерә.

## ТАТАР ЗЫЯЛЫЛАРЫНЫҢ ВАКЫТЛЫ СӘЯСИ КОМИТЕТЫ

Мәскәүдә булып үткән хәрби фетнә нәтиҗәсендә җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеге куркыныч астына куелды.

Менә шушы кискен шартларда 19 сентябрьдә Татар иҗтимагый үзәгендә республикабыз зыялыларының, иҗтимагый хәрәкәт һәм оешма активистларының җыелышы булды. Анда сүз мөстәкыйльлегебезне саклап калу өчен хәлиткеч чаралар күрергә кирәклеге турында барды. Бу эшне җитәкләү өчен төрле хәрәкәтләр, оешмалар вәкилләреннән, күренекле шәхесләрдән торган комитет төзергә килешенде. Аның максатлары да билгеләнде. Халык арасында аңлату эше алып бару, мөстәкыйльлекне саклауга омтылучы көчләрне бергә туплау, бу хәрәкәттә тәртипсезлекләргә юл куймау максатыннан халык ополчениесенең эшен активлаштыру, хөкүмәтебез һәм парламентыбыз белән эшлекле сөйләшүләр алып бару — болар комитетның төп бурычлары булып тора.

Язучылардан әлеге комитетка М. Хәбибуллин, Р. Батулла, З. Зәйнуллин, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов әгъза итеп сайландылар.

## МӘҮЛИД КИЧӘСЕ

20 сентябрьдә В. И. Ленин Үзәк музееның Казан филиалында Мөхәммәт пәйгамбәрнең туган көне — Мәүлид кичәсе уздырылды. Аны Казан мөселманнары дини нәзарәте һәм «Иман» исемендәге ислам мәдәнияте яшьләр үзәге оештырды.

Мәүлид кичәсендә, бабайлар һәм әбиләр белән бергә, яшьләр дә бик күп иде. Алар Татарстан Республикасының баш мөхтасибе, СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте казые Габделхак хәзрәт Саматов, Мәскәүдәге ислам мәдәни үзәге рәисе Габделвахит Ниязов, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты галиме Әнвәр Хәйри, Камил хәзрәт Бикчәнтәев чыгышларын бик кызыксынып тыңладылар.

Кичәдә Иордания короле Хөсәеннең киңәшчесе, ил парламенты әгъзасы шәех Абдул Бакый Жамо Шишани да чыгыш ясады. Ул ислам диненең дөньяда елдан-ел көчәя баруын билдерде. Советлар Союзында мөселманнарның үз диннәрен тотуга иркенлек алуларын хуплавын әйтте.

Соңыннан кичәнең «Иман» исемендәге ислам мәдәнияте яшьләр үзәге оештырган концерт өлеше булды. Үзешчән артистлар халкыбызда элекке чорда киң таралган мөнәҗәтләр, борынгы шагыйрьләребезнең шигырьләрен укыдылар.

## ӨР-ЯҢА ЖУРНАЛ

Зеленодольск шәһәрендә «Ажаган» исемле әдәби-нәфис журналның беренче саны басылып чыкты. Журнал халкыбызның әдәби һәм мәдәни тормышын яктыртуны, укучыларга билгесез яки аз таныш булган әсәрләрне, рухи кыйммәтләрне даими бирен баруны үз өстенә ала. Әлеге редакциянең йорты да, малы да юк. Аның каравы, Татарстан ССР халык депутаты Әхмәт Хәсәен улы Яппаров җитәкли торган «Раифа» җәнлек совхозы кебек игелекле спонсоры, ярдәмләшергә әзер торган иҗат көчләре бар.

«Ажаган» Татарстан ССР Нәшриятлар, матбугат һәм китап сәүдәсе буенча дәүләт комитетында яшьләр һәм өлкән класс укучылары өчен әдәби-нәфис журнал буларак теркәлде.

Журналның баш мөхәррире — язучы Азат Вергазов.

Редакциянең адресы:
422520, Татарстан ССР,
Зеленодольск шәһәре,
Юбилей урамы, йорт номеры 5, кв. 10.

## ФӘРИТ ЯРУЛЛИН ИСТӘЛЕГЕНӘ

Татарстан ССР Министрлар кабинеты күренекле татар композиторы Фәрит Заһидулла улы Яруллинның истәлеген мәңгеләштерү буенча байтак кына чаралар билгеләде. Мәгълүм булганча, Фәрит Яруллинның кыска гомере Мамадыш районы Кече Сон авылы белән нык бәйле.

Аның этисе — халык музыканты, «Тукай маршы»ның авторы Заһидулла Яруллин шушы авылда туып үскән, иҗат иткән. Заһидулла аганың кече улы композитор Мирсәет Яруллинның да иҗат юлы шушыннан башланган. Шуңа күрә Кече Сон авылында Яруллиннар музеен оештырырга карар бирелде. Мәдәният министрлыгына авылдагы мәдрәсә һәм мәчетне дәүләт карамагындагы архитектура истәлекләре исемлегенә кертергә кушылды.

## МӘКТӘПТӘ — ЯЗУЧЫ ИСЕМЕ

Быел Татар Танае авылы язучы Афзал Шамов истәлегенә бәйле вакыйгаларга бай булды. Биредә авыл халкы март башында ук әдипнең 90 еллык юбилеен мәктәптә, китапханәдә, мәдәният йортында зурдан билгеләп үткән иде. Менә яңа уку елы башланган көнне танайлылар язучы исеменә бәйле тагын бер вакыйгада катнаштылар. Биредәге урта мәктәпкә язучы Афзал Шамов исеме бирелү уңаеннан тантаналы митинг булды. Анда ТССР Министрлар кабинетының карары укылды. Әлеге карарда Зеленодольск районының Татар Танае урта мәктәбенең шушы көннән башлап Афзал Шамов исемен йөртә башлавы турында бәян ителә.

Мәктәпнең икенче катында язучының тормыш һәм иҗат эшчәнлегенә багышланган зур күргәзмә оештырылган иде. Фотоларны, документларны, китапларны Афзал Шамовның кызлары һәм уллары авыл халкына бүләк иткән. Күп кенә автографлы китапларны язу-

чы, үзе исән вакытта ук, китапханәгә тапшырган булган. Шулар нигезендә мәктәпнең бер бүлмәсендә язучы музеен оештырырга ниятлиләр.

## САДРИ ҖӘЛӘЛ УРАМЫ

Апас — әдәбият һәм сәнгатькә мәшһүр кешеләр биргән як. Арада репрессия чорында һәлак булган шәхесләр дә бар. Танылган әдип Садри Җәләл — шуларның берсе.

Якташлары бу әдипне олы хөрмәт белән искә алалар. Садри Җәләлнең 100 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә Апас авыл советы башкарма комитетының утырышы булды. Комитет әгъзалары — халык депутатлары Апасның көнчыгыш ягында яңа төзелә башлаган урамга Садри Җәләл исемен бирү турында карар кабул иттеләр.

## НУР БАЯН ИСТӘЛЕГЕНӘ

Чаллыда 1930 елда чыга башлаган «Трактор» газетасының беренче мөхәррире Нур Баян була. Ул, Чаллыда ике ел эшләп, район газетасын аякка бастыруда һәм кадрлар туплауда зур көч куя.

Чаллылар күренекле фронтовик шагыйрь Нур Баян эшчәнлеген онытмыйлар. Аның якты истәлеген мәңгеләштерү уңаеннан, күзәнәкле бетон заводы поселогындагы бер урамга Нур Баян исемен бирү турында карар кабул ителде.

## ДӨНЬЯ ЧЕМПИОННАРЫ

Татарстан Республикасының спорт йолдызлыгында тагын бер йолдыз балкыды. Аны Чаллы кызы Лилия Нуретдинова кабызды. Япония башкаласы Токиода — җиңел атлетика буенча дөнья чемпионатында — ул 800 метрга йөгерүдә алтын медаль яулап алды. Совет җиңел атлетикасы тарихында әлеге төр буенча беренче шундый зур бүләк булуы белән истәлекле бу медаль.

* * *

Бразилиядәге Маринга каласында дөньяның үсеп килүче яшь шахматчылары (26 яшькә кадәрге) арасында барган команда очрашулары тәгәлләнде. Безнең илдән гроссмейстер В. Епишин, спорт мастерлары В. Крамник, А. Харлов һәм якташыбыз — Казан егете Илдар Ибраһимов катнашында чыгыш ясаган команда анда, АКШ вәкилләрен икенче урынга калдырып, алтын медаль яулады.

## КЫСКАЧА

Үзбәкстанның көньягында урнашкан Термез шәһәр Советы президиумы 155 урам һәм тыкрыкның исемнәрен үзгәртү турында карар чыгарды. Шәһәр үзәгендәге бер тыкрык бөек татар шагыйре Габдулла Тукай исемен йөртәчәк.

* * *

Бөтен дөньяга танылган бию остасы Рудольф Нуриевның балет сәнгатен якын арада симфоник оркестр дирижеры таякчыгына алыштырачагын берәү дә уйламагандыр. Әмма бу шулай булды. Италиянең Варезе театрында Нуриев житәкчелегендә чын-чынлап уникаль концерт узды. Анда Бетховен, Прокофьев әсәрләре яңгырады.

* * *

Быел урыс телендә «Суверенитет» газетасы чыга башлаган иде.

Анда басылган язмаларның берсендә урыс телендә язучы Диас Вәлиев адресына «манкорт» дигән сүз кулланылган. Моның өчен Д. Вәлиев мәкалә авторы З. Нигъмәтуллинаны һәм «Суверенитет» газетасы редакциясен судка тартты. Вахитов районы судына биргән гаризасына караганда, ул редакциядән 100000 сум (?!.) акча таләп итә.

* * *

Литва хөкүмәте республикада яшәүче мөселманнарга мәчет төзү өчен 5 гектарга якын жир бүлеп бирде. Мәчет Вильнюс телебашнясы күршесендә төзеләчәк. Берничә ай элегрәк кенә Каунастагы торгызылган мәчеттә намаз укылган иде. Литва башкаласында ачылган «Ислам һәм Литва татарлары» дигән күргәзмәгә дә халык күпләп йөргән иде.

* * *

Танылган шагыйрь һәм публицист Айдар Хәлим исеменә Казагстан Республикасы Президенты Нурсолтан Назарбаевтан телеграмма килде.

Әлеге телеграммада ул Айдар Хәлим бүләк итеп җибәргән «Кайгы китабы яки җирле кеше язмалары» дигән фәлсәфи-публицистик әсәре өчен авторга кайнар рәхмәтен белдергән һәм якташыбызның бу китабын урыс һәм казак телләрендә бастыру өчен нәшриятка бирелүен хәбәр иткән.

# ТУЙ СӨЛГЕСЕ

Сезнең игътибарыгызга тәкъдим ителгән бизәкле сөлге, казан татарлары тарафыннан чигеп эшләнгән әйберләр арасында кабатланмас үзенчәлекле үрнәк буларак, СССР халыкларының этнография музеенда (Санкт-Петербург) саклана. Бу сөлгенең үзенчәлеге — бизәкнең борынгы үрнәгендә, композициясендә һәм XIX—XX гасыр башларында йола сөлгеләрен бизәүдә инде сирәк очрый торган чигү техникасында. Казан сөлгесе дип йөртелүче бу сөлгеләр сабантуй, жыен кебек халык бәйрәмнәре, борынгы йолалар, гореф-гадәтләр сулышы белән әртелгән бай образлы символлар булып торалар. Үзләрендә сурәтләнгән мотивларның матурлыклары һәм гадилекләре, орнамент-бизәкләрнең искиткеч бай булуы һәм төсләр гаммасының күзләрне камаштырырлык ачыклыгы белән күңелне җәлеп итәләр алар. Бизәкле сөлгеләр туй, бала туу, җеназа озату йолалары сабантуй бәйрәмнәренең зарури, аерылгысыз юлдашлары булганнар. Алар көнкүреш йолалары белән тыгыз бәйләнештә булганлыктан, сөлгеләрдәге бизәкләргә дә аерым бер символик мәгънә салына. Сәнгати эшләнеше ягыннан төгәл булган казан сөлгеләрендә чәчәк бәйләме яки, борынгы бабаларыбыз күзаллавынча, фани дөньяны гына түгел, мәңгелек галәмне дә чагылдыручы һәм яшәү чыганагы булган «тормыш агачы» мотивы үзәк урынны тота.

Рәсемдәге сөлгедә «тормыш агачы» мотивы, борынгы башка сөлгеләрдәге кебек үк, өч өлештән торган композициянең үзәгенә урнашкан. Ян-якларында көзгедәгедәй чагылышта чәчәк бәйләмнәре мотивы урын алган. Күләме ягыннан зур булмаган «тормыш агачы» сөлгенең гомуми бизәкләре фонында югалып калган кебек, әмма композициядә бизәкнең үзәген тәшкил итүче буларак аерылып тора. Чәчәкләрдән, яфраклардан, гранат һәм йөзем җимешләреннән, үрентеләрдән, бөтеркә бизәәләрдән торган орнамент, сөлгенең инен тутырып, ике баш-башына урнашкан һәм ике яктан тар гына чигүле кайма белән уратып алынган. Сөлгедә чәчәк һәм үсемлекләрнең борынгы болгар үрнәге бирелгән һәм алар шартлы рәвештә сурәтләнгәннәр. Бу шартлылык болгар-татар орнаментының борынгы үрнәкләренә аеруча хас. Әлеге үзенчәлекләрдән чыгып, без сөлгенең XIX йөзнең беренче яртысына караганлыгын әйтә алабыз.

Бизәкнең үзәген тәшкил итүче «тормыш агачы» мотивы биредә, һичшиксез, башка мәгънә белдерә. Безнең карашыбызча, агач ботакларындагы җимешләр — гранат, йөзем тәлгәшләре, уңыш алиһәсе символы буларак сурәтләнгәннәр. Алардан югарырак урнашкан, уртасында ноктасы булган түгәрәк исә — борынгы кояш символы. Кояш мотивы белән бастылган бу агач үзе үк иминлек һәм байлык, гаилә тормышы ныклыгының символы булып тора. Һәм без аны берсүзсез никах йоласы белән бәйле туй сөлгесе дип атый алабыз. Юка ак киндер тукымага чигелгән сөлгенең барлык бизәкләре дә ачык декоратив характерда. Чигелеше ягыннан затлы-зиннәтле сөлге купшы-тантаналы йола өчен әзерләнгән булгандыр мөгаен. Ул, ихтимал, кәләшнең бирнәсендә булгандыр. Кыз аны, буыннан-буынга күчүче туй йоласына хас символик үрнәкләрне кулланып, туй көненә үзе чиккән булырга да мөмкин. Әлеге сөлгенең шәһәрдә яшәүче татарлар культурасына хас икәнлеге бәхәссез. Үзенчәлекле фактурасы бизәкләренең тәфсилләп-җентекләп эшләнеше, йөзем тәлгәшләре үрнәген еш кабатлау, атлас, ефәк, алтын укалы төрле тасмалар өстәп тегү һәм чигештә ялтыравыклар куллану шуны раслыйлар. Сөлгедәге бизәк йон һәм эрләнгән-ишелгән ефәк җепләр белән тамбурлы чигү (күпертелгән элмә) техникасы белән эшләнгән. Тамбурлы чигү — төрки халыклар сәнгатендә иң киң таралган чигү алымы. Сөлгедә чәчәк һәм яфрак үрнәкләренең контурлары эре кабарынкы җөйләр белән, ә аларның эчке өслекләре ваграк җөйләр белән башкарылган. Шулай итеп, күзне камаштырырлык ачык төсләр һәм фактура контрастлылыгына ирешелгән.

Бу сөлгене чигүче ритм, пропорция һәм масштабны нечкә тойган. Сөлгенең бизәгенә һәр ике яктагы почмакларда кызгылт көрән төстәге җепләрдән чигелгән ярым ай мотивы да кергән. Ул «тормыш агачы»ның мөгезсыман ботагына тәңгәл рәвештә яраша һәм композиция гаҗәеп бер төгәллеккә, ритм гармониясенә һәм сәнгатьчә камиллекнең югары дәрәҗәсенә ирешә. Бу югары сәнгать әсәре — халык иҗатының эстетик идеалын үзендә чагылдырган борынгы татар чигүенең классик үрнәге.

Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА,
сәнгать белгече.

Тышлыкның дүртенче битендә: танылган язучы Вакыйф Нуруллин.

Юрий ФИЛИМОНОВ фотолары

# КИТАПЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

Татарстан китап нәшрияты соңгы вакытта түбәндәге китапларны басып чыгарды:

**Гаяз Исхакый.** Зиндан. *Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре.* 672 бит, портрет белән. Б. 8 с.

Яңа әдәби телебезгә нигез салучы, күренекле әдип, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе Г. Исхакый революциягә кадәр үк халкыбызның сөекле язучысы булып танылга. Ул дәвердә әдәбиятыбыз күгендә Тукай һәм Исхакый йолдызлары башкаларныкыннан яктырак яна. Әмма, эмиграциягә киткәнлектән, Исхакый исеме соңгы житмеш елда бары каралтып, сүгеп кенә телгә алынды, әсәрләрен уку тыелды. Бу җыентык — акланган язучының хәзерге элифбабызда басылган беренче китабы. Анда «Зиндан», «Тормышмы бу?», «Сөннәтче бабай» повестьлары, байтак хикәяләре, мәшһүр «Зөләйха» драмасы һәм бүтән сәхнә әсәрләре кертелгән. Җыентык сүз башы, искәрмәләр, авторның әсәрләре исемлеге белән тәэмин ителгән.

**Чыңгыз Айтматов.** Бер көн — бер гомер. *Роман.* 288 бит, портрет белән. Б. 1 с. 20 т.

**Абдулла Алиш.** Хикәяләр һәм әкиятләр. 192 бит, рәсемнәр белән. Б. 85 т.

**Зәки Азизов.** Могжизалар мәктәбе. *Укучы язмалары.* 112 бит. Б. 25 т.

**Дәрҗия Аппакова.** Кечкенә Бануның тарихы. Повестьләр, хикәяләр, әкиятләр. 168 бит, рәсемнәр белән. Б. 65 т.

**Фатыйма Вәлиева.** Халыкка багышланган тормыш. *Җырчы, гармунчы, композитор турында очерклар.* 64 бит. Б. 40 т.

**Әхәт Гаффар.** 771 аршын җир. *Әфганстан сугышы: нәтиҗәләр, язмышлар.* 110 бит. Б. 20 т.

**Анатолий Головков.** Авыл ашлары. 176 бит, рәсемнәр белән. Б. 2 с.

**Гөлбакча.** *Балалар бакчалары өчен хрестоматия.* 254 бит, рәсемнәр белән. Б. 1 с.

**Михаил Девятаев.** Тәмугтан качу. *Хатирәләр.* 216 бит. Б. 1 с. 50 т.

**Сәйдә Зыятдинова.** Айның туган чагы. 96 бит. Б. 15 т.

**Заһит Мәхмүдов.** Профессор Мияугол. *Фантастик хикәяләр.* 88 бит. Б. 60 т.

**Хәйретдин Мөҗәй.** Сугыш язмалары. *«Мәктәп китапханәсе» сериясеннән.* 303 бит. Б. 1 с. 40 т.

**Александр Рабинович.** Бакчадагы дару үләннәре. 192 бит, рәсемнәр белән. Б. 85 т.

**Флера Сафиуллина.** Татар теле. *Үзлегеңнән өйрәнү өчен дәреслек.* 448 бит, рәсемнәр белән. Б. 3 с. 80 т.

**Әдхәт Синугыл.** Коньяк гөлләре. *Шигырьләр.* 128 бит. Б. 30 т.

**Игорь Скурихин, Валерий Шатерников.** Дөрес туклану серләре. 240 бит. Б. 2 с.

**Габдулла Тукай.** Шигырьләр, әкиятләр, поэмалар. 256 бит, рәсемнәр белән. Б. 1 с. 80 т.

**Фатыйх Урманчиев.** Дастаннарга лаек замана. *Борынгы фольклор һәм хәзерге шигърият. Тикшеренү.* 224 бит. Б. 60 т.

**Шәмси Хамматов, Касыйм Тәхау.** Каләмне штыкка тиңләп. *Очерклар.* 95 бит. Б. 20 т.

**Заһит Хәбибуллин.** *Күңелле мажаралар. Габдулла Тукай шигырьләренә язылган җырлар.* 24 бит, ноталар белән. Б. 25 т.

**Айдар Хәлим.** Йөрәк ташы. *Шигырьләр, балладалар, поэма.* 96 бит. Б. 40 т.

**Афзал Шамов.** Соры мәче. *Хикәя.* 72 бит. Б. 15 т.

**Фаил Шәфигуллин.** Өй салуның ние бар. *Повестьлар.* 304 бит, портрет белән. Б. 1 с. 30 т.

**Миргазиян Юныс.** Юлда уйланулар. *Повестьлар.* 416 бит. Б. 1 с. 70 т.

**Әбрар Юнысов.** Солдат хәтере. *Истәлекләр.* 80 бит. Б. 20 т.

**Илдар Юзеев.** Гашыйклар тавы. *Шигырь белән язылган сәхнә әсәрләре.* 144 бит. Б. 65 т.

**Фәнис Яруллин.** Зәңгәр күлдә ай коена. *Әкиятләр.* 272 бит. Б. 50 т.

**Нур Әхмәдиев.** Күктә ничә йолдыз бар. *Фантастик повестьлар, әкиятләр.* 224 бит. Б. 2 с. 10 т.

**Рәшит Әхмәтҗанов.** Моңлану. *Шигырьләр һәм поэмалар.* «Шигырь китапханәсе» сериясеннән. 432 бит, портрет белән. Б. 2 с. 70 т.

**Садри Җәләл.** Дим буенда. *Повесть һәм хикәяләр.* 256 бит. Б. 1 с. 40 т.

Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша сорап алдырырга мөмкин. Адреслар: 420057, Казан шәһәре, Октябрьская урамы, 18. «Китап-почта» кибете. 420084, Казан шәһәре, Бауман урамы, 19. 1 китап кибете, «Китап-почта» бүлеге. 420021. Казан шәһәре, Татарстан урамы, 13. 3 китап кибете.

Бәясе 1 сум 50 тиен.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог